АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В трех томах

I том

Казань
2015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ

Өч томда

I том

Казан
2015

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Т 23**

*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Томның авторлары:**
филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев;**
филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина;**
филол. фән. канд. **Р.Ф. Фәттахова;**
филол. фән. канд. **Ә.К. Булатова**

**Фәнни редактор** – филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина**

**Рецензентлар:**
филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин;**
филол. фән. канд. **Ф.И. Таһирова**

**Т 23** **Татар лексикологиясе:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 352 б.
ISBN 978-5-93091-193-0

Монография – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тормышка ашырыла торган «Татар лексикологиясе» проектының беренче томы. Әлеге хезмәттә татар теле лексикасының төп берәмлекләре булган сүз һәм тотрыклы әйтелмәләрнең мәгънәсе, кулланылыш үзенчәлекләре һәм килеп чыгышы мәсьәләләре яктыртыла. Шулай ук татар тел белемендә этимология тармагы формалашу һәм үсүгә кагылышлы мәгълүмат, этимологик тикшеренү ысуллары, сүзнең состав өлешләре булган тамыр, нигез һәм кушымчалар этимологиясе махсус карала.

Хезмәт тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-193-0**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2015

# КЕРЕШ

Дөнья фәненең соңгы казанышларын исәпкә алып, өйрәнү объектын мөмкин кадәр эзлекле, тулы яктырткан күп томлы хезмәтләр басылу татар тел белеменең тирән тарихы, аның буенча тупланган гыйльми һәм гамәли материалларның тулы булуын, фәнни тикшеренүләрнең бай тәҗрибәсен күрсәтә.

Татар теле өлкәсендә тикшеренүләр алып барган фәнни һәм белем бирү үзәкләрендәге белгечләрнең эшчәнлеген бергә туплап, татар тел белеме буенча фундаменталь хезмәтләр әзерләү юнәлешендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уңышлы һәм нәтиҗәле эш алып бара. Соңгы елларда гына да Институтның зур проектларны тормышка ашырырга алынуы шуны дәлилли. Әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, 2015 елда өчтомлык «Академик лексикология», дүрттомлык «Татар әдәби теле тарихы», өчтомлык «Татар теленең академик грамматикасы» кебек басмалар нәшер итүгә әзерләнде. Татар тел белеме өчен генә түгел, гомумән, төрки дөнья өчен әһәмиятле булган алтытомлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н, «Татар сөйләшләренең диалектологик Атласы»н аерым атау зарур.

XX гасырның 80 нче еллары башында татар теленең тулы академик фонетикасын, грамматикасын, лексикологиясен һәм диалектологиясен, шулай ук әдәби тел тарихын булдыру мәсьәләсе игътибар үзәгенә алынды. Аерым алганда, XX гасыр ахырында «Татар грамматикасы», 2003 елда «История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.)» һ.б. хезмәтләр нәшер ителде. Шулай ук лексикологиянең аерым тармаклары буенча күләмле һәм киң кырлы фәнни хезмәтләр, сүзлекләр дөнья күрде. Аеруча соңгы

берничә дистә елда татар теле лексикасының төрле катламнарын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрнең саны артты, лексиканы өйрәнү методлары һәм алымнары төрләнәнде.

Татар теленең лексикологиясенә багышланган әлеге хезмәт берничә әһәмиятле максатны күздә тотып төзелә. Беренчедән, лексик фондка караган фәнни һәм гамәли фактларны тирәнтен өйрәнеп, хәзерге татар теленең сүзлек составын тулы, төзек система буларак тасвирлау. Икенчедән, әлеге система эченә кергән берәмлекләрнең мәгънә үзенчәлекләрен, эчтәлеген һәм формасын, алар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен һәм төрләрен өйрәнү, лексик система формалашуда лингвистик һәм экстралингвистик шартларның йогынтысын ачыклау. Өченчедән, татар теленең лексик составы формалашу этапларын һәм генезисын, кулланылыш үзенчәлекләрен һәм төрләрен, баю һәм үсеш-үзгәрешен комплекслы якын килеп өйрәнү. Дүртенчедән, сүзлек составын милли мәдәният белән бәйләнешле өйрәнеп, лексик катламның милли тел нигезе булуын күрсәтү.

Хезмәт өч том буларак күзаллана, биредә лексиканың состав өлешләре булган сүз, фразеологик әйтелмә, семантик һәм кулланылыш үзенчәлекләре ягыннан беркадәр үзгә булган ономастик берәмлекләр тулы бер система элементлары буларак өйрәнелә. Академик лексикология проектының җитәкчесе – академик М.З. Зәкиев.

Беренче томда татар теле лексикасының төп берәмлекләре булган сүз һәм фразеологик әйтелмәләр тикшерелә, аларның мәгънәләре, семантик үсеш-үзгәрешләре күрсәтелә. Мәгънә белән тыгыз бәйләнгән булганлыктан, этимология тармагы да шушы томга кертелә.

Икенче том татар теленең лексик составы формалашу, үзгәрү һәм үсү тарихын, лексиканың кулланылыш үзенчәлекләрен яктыртуга багышлана.

Өченче том татар ономастикасын һәм лингвокультурологиясен тасвирлауны максат итеп куя. Шулай ук лексик берәмлекләрне туплап, алар турында мәгълүмат бирә торган лексикография бирелә.

Тәкъдим ителгән беренче том үз эченә семасиология, фразеология һәм этимология тармакларын ала. Әлеге тармакларны берләштерә торган төп нигез буларак мәгънә һәм аны реконструк-

цияләү алына. Бу томны язуда төп чыганак булып хәзерге татар теленең лексик-фразеологик фонды тора.

Хезмәтнең беренче бүлегендә татар лексикологиясенең өйрәнү объекты һәм аның тармаклары турында мәгълүмат бирелә. Бүлекнең авторлары – академик М.З. Зәкиев һәм филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина.

Икенче бүлек сүзнең мәгънәви структурасын, лексик мәгънә һәм аның төрләрен ачыклауга, татар теленең лексик-семантик системасы һәм андагы бәйләнешләрне тасвирлауга һәм төп лексик берәмлекләрдән күп мәгънәле сүзләр, омонимнар, паронимнар, синонимнар, антонимнарны өйрәнүгә багышлана. «Телнең универсаль берәмлеге буларак сүз», «Сүзнең лексик мәгънәсе», «Хәзерге татар теленең лексик-семантик системасы» һәм «Татар телендә синонимия күренеше» бүлекләрен филология фәннәре докторы Г.Р. Галиуллина, «Сүзнең күпмәгънәлелеге», «Татар телендә омонимия күренеше», «Татар телендә антонимия күренеше» бүлекләрен филология фәннәре кандидаты Ә.К. Булатова язды. Шулай ук филология фәннәре докторы Р.С. Абдуллина материалларына нигезләнеп, «Татар телендә паронимия күренеше» бүлеге дә урнаштырылды.

Өченче бүлектә татар теле фразеологиясенең төп семантик, грамматик, структур һәм функциональ үзенчәлекләре ачыклана. Бүлекнең авторы – филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Фәттахова.

Дүртенче бүлектә сүзләрнең һәм сүзнең состав өлеше буларак кушымчаларның этимологиясе турында мәгълүмат бирелә. Бүлек академик М.З. Зәкиев тарафыннан эшләнде, анда филология фәннәре докторы Р.Г. Әхмәтьянов материаллары да файдаланылды.

Хезмәтнең библиография өлешен Л.Г. Хәбибуллина эшләде.

Татар теленең лексикологиясен әзерләү һәм киң кырлы хезмәт буларак тәкъдим итү – бер буын гына түгел, татар тел белемендә эз калдырган берничә буын тел галимнәренең тырышлыгы нәтиҗәсе.

# ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ ФӘНЕНӘ КЕРЕШ

## § 1. Лексикология фәне турында төшенчә, аның өйрәнү объекты һәм юнәлешләре

Телнең сүзлек байлыгы *лексика* дип, ә шул байлыкны өйрәнә торган тел тармагы *лексикология* (грек. *lexikos* – сүз*, logos* – өйрәнү) дип атала. Лексикология фәне сүзне төрле яклап өйрәнүне үзенең максаты итеп карый. Беренче чиратта лексикология фәне кысаларында сүз мәгънәсе, аның типлары, сүзлек составының катламнары, сүзләрнең килеп чыгышы, кулланылыш үзенчәлекләре, телнең лексик составы баю, тулылану юллары тикшерелә.

Телнең сүзлек составы даими рәвештә тулыланып, үсеш-үзгәреш кичереп яши. Сүзнең фонетик тышчасы, төзелеше үзгәрү гасырлар дәвамында бара, ә сүзлек составы исә унбиш-егерме ел эчендә шактый үзгәрергә мөмкин. Бу беренче чиратта телгә җәмгыять, иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормыш тәэсире белән аңлатыла. Халык яшәешендә булган һәрбер яңалык, иң беренчеләрдән булып, сүзлек составында чагылыш таба, аның алга таба үсеш юнәлешләрен билгели.

Милли телнең лексик составы аерым сүзләр җыелмасыннан тора, алар исә үз чиратында тел кулланыла торган һәрбер өлкәдә чагылыш таба. Шунлыктан лексика термины аша, телнең лексик составын атау белән бергә, аерым язучы әсәрләренең яки нинди дә булса әсәрнең сүзлек хәзинәсен һәм аерым бер сөйләш, диалектның сүзлек составын да атыйлар.

Лексикология фәненең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) сүз һәм тотрыклы әйтелмәләрне семасиологик яктан тасвирлау, ягъни мәгънә типларының эчке төзелешен һәм төрле типтагы системалы мөнәсәбәтләрне өйрәнү; 2) лексик һәм фра-

зеологик берәмлекләрне билгеләү һәм алар арасындагы аермалы якларны ачыклау; 3) тотрыклы әйтелмәләрне сүз һәм ирекле сүзтезмәләр белән чагыштырып тасвирлау; 4) аерым бер телгә хас сүзләр, тотрыклы гыйбарәләрнең башка берәмлекләр белән үзара бәйләнешләрнең төп закончалыкларын күрсәтү; 5) телнең лексик составы тарихын, килеп чыгышын өйрәнү; 6) сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең кулланылыш дәрәҗәсен һәм даирәсен билгеләү.

Лингвистикада лексикологияне берничә төргә бүлеп күрсәтү гадәткә кергән. Шуны искәртү зарур: лексикология фәне өйрәнү объекты, күләме, методлары һәм өлкәләре ягыннан үзенчәлекле булганлыктан, тел белемендә аның төрләрен аеруда да төрлелек күзәтелә. Биредә без киң таралган һәм тел белеме буенча җитди хезмәтләрдә аерыла торган төрләренә тукталырга булдык. Алар түбәндәгеләр:

г о м у м и  л е к с и к о л о г и я лексик составның төзелеш, кулланылыш һәм үсешенә бәйле гомуми закончалыкларны өйрәнә;

х о с у с ы й  л е к с и к о л о г и я – аерым бер телнең яки кардәш телләрнең сүзлек составына бәйле мәсьәләләрне өйрәнүне максат итеп куя;

т а с в и р л а м а  л е к с и к о л о г и я (синхроник лексикология) сүзлек составының хәзерге торышын өйрәнә;

т а р и х и  л е к с и к о л о г и я (диахроник лексикология) тарихи яссылыкта телнең сүзлек составын, сүз атаган предмет, күренешләр белән бәйле рәвештә сүз мәгънәсенең үсешен, тулаем лексик составның яки аның бер катламының үсеш динамикасын өйрәнә. Өйрәнү предметы буларак, аерым сүз яки лексик система, сүзнең семантик үзгәреше (тараю, киңәю, семантик күчеш), семантик структурадагы үзгәрешләр алына. Тарихи лексикологик эзләнүләр семасиологик (аерым сүз яки сүзләр төркеменең мәгънә үзгәрешен тикшерү) яки ономасиологик (атама бирү ысулларының үзгәрүен өйрәнү) юнәлештә булырга мөмкин;

ч а г ы ш т ы р м а  л е к с и к о л о г и я, телләрнең генетик туганлыгын, телләр арасындагы структур-семантик охшашлыкны яки аерымлыкны танып белү максатыннан, гомуми лексик закончалыкларны ачу өчен, төрле генетик якын телләрнең сүзлек составын чагыштырып өйрәнә;

т е о р е т и к  л е к с и к о л о г и я лексикага караган төшенчә, категория һәм берәмлекләргә фәнни-лингвистик аңлатма бирә,

аларны төркемләү принципларын, лексикологик тикшеренүләрнең методологиясен ачыклый;

гамәли лексикология телнең куллану өлкәсенә бәйле берничә яссылыкта эш алып бара, шулар арасында киң таралганнары: сүзлекләр төзү, тәрҗемә теориясен һәм гамәлләрен өйрәнү, лингводидактика (тел укыту-өйрәтү) проблемаларын тикшерү, сөйләм культурасына бәйле мәсьәләләрен чишү.

Телнең лексик фонды гомумлингвистик тикшеренү метод һәм алымнарына таянып өйрәнелә. Шулар арасында киң таралыш тапканы – дистрибутив метод. Әлеге метод ярдәмендә сүзнең, аның морфологик төзелешенең, семантикасының чикләре ачыклана. Субституция методы ярдәмендә сүз мәгънәләре, синонимия күренешенә басым ясала. Компонент-оппозитив метод лексик берәмлекнең мәгънә структурасын, сүзнең семантик структурасын, мәгънә үзгәрешен, аерым бер контекст эчендә мәгънә ачылышы мәсьәләләрен ачыкларга ярдәм итә. Лексик берәмлекләрнең кулланылыш ешлыгы статистик метод ярдәмендә билгеләнә.

Лексикология фәне тел гыйлеменең башка тармаклары белән дә тыгыз бәйләнештә яши. Мондый бәйләнешләрнең асылы сүзне төрле яктан өйрәнүгә бәйле, чөнки теләсә кайсы телдә сүз төп урынны алып тора. Телнең төп берәмлекләре арасында ул – мөстәкыйль яшәешкә ия бердәнбер берәмлек, мәсәлән, *китап, сайлау, акыллы, барырга* һ.б. Сөйләмдә фразалар, җөмләләр ярдәмендә аралашу барса да, аларның барысы да сүз ярдәмендә төзелә. Морфема һәм фонемалар исә – сүз төзи торган берәмлекләр, ләкин алар сөйләм агышында мөстәкыйль формада яшәмиләр. Шулай итеп, сүз телнең һәр ярусында теге яки бу формада яшәеш таба.

Фонетика һәм лексикология бәйләнеше сүзнең тышкы формасы һәм аның эчтәлеге яссылыгында ачыла. Фонетика фәне өчен сүз – аерым авазлар тезмәсе, ягъни сүзнең тышкы формасы. Шуннлыктан фонетика кысасында фонетик сүз төшенчәсе мөһим, чөнки әлеге тармак сүзнең аваз ягын өйрәнә[1].

Сүз ясалышы һәм лексикологиянең кисешү ноктасы телнең лексик фонды яңа ясалган сүзләр белән баюында һәм ясалма сүзнең мәгънәсе белән ясагыч нигез арасындагы мәгънә мөнәсәбәтендә күренә. Һәр яңа ясалган сүз тел кысаларында яңа лексик

[1] Сүзнең фонетик, сүз ясалыш һәм грамматик үзенчәлекләре семасиология тармагында бирелә.

мәгънәгә ия мөстәкыйль берәмлек санала, мәсәлән, *җыр – җырла – җырчы; акыл – акыллы – акылсызлык* һ.б. Атама бирү процессын һәм нәтиҗәсен өйрәнү ягына бәйле, тел белемендә сүз ясалышын лексикологиянең бер тармагы дип карау да очрый.

М о р ф о л о г и я белән бәйләнеш исә сүз составындагы лексик һәм грамматик мәгънәләр бергәлегендә ачыла. Морфологиядә шулай ук сүз мәгънәсе өйрәнелә, әмма бу очракта төп игътибар грамматик мәгънәгә юнәлә. Нигездә, морфология сүзнең формасын, сүзнең төрләнү үзенчәлекләрен һәм төрләнеш нәтиҗәсендә белдергән мәгънәләрен өйрәнә.

С и н т а к с и с белән бәйләнешен сүзнең аерым бер контекстта куллану, башка сүзләр белән ярашу мөмкинлегендә һәм шуларга бәйле семантик реальләшүендә күрәбез.

Классик лексикологиянең нигезен телнең сүзлек составы формалашуы һәм үзгәрүе, барлыкка килү ягыннан системалаштыру, кулланылышы һәм активлыгы ягыннан төркемләү, сүзлек составындагы парадигматик һәм синтагматик мөнәсәбәтләрне өйрәнү тәгълиматлары алып торса, соңгы берничә дистә ел аралыгында лексиканы яңа методлар кулланып өйрәнү активлашты. Бу төр эзләнүләрдә мәгънә-концепт мөнәсәбәтләре, сүзлек составының дөньяны танып белү эшчәнлеген чагылдыру, шуннан чыгып, лексик-семантик системаның мөмкинлекләрен яңача аңлату мөмкинлеге алгы планга куелды.

Әйтелгәннәр нигезендә тел белемендә к о г н и т и в  л е к с и к о л о г и я фәне – телнең сүзлек составы һәм кешенең менталь лексиконы арасындагы бәйләнеш үзенчәлекләрен өйрәнү юнәлеше барлыкка килде. Бүгенге лингвистика фәнендә когнитив лексикология гомуми лексикологиядән үсеп чыккан һәм төп игътибарын лексик байлыкны дөньяны танып белү процессында туплаган белемнәрне күрсәтә торган универсаль когнитив чара, когнитив инструмент буларак өйрәнүгә юнәлткән фән санала.

Когнитив лингвистика кысаларында берничә фән формалашып, аларның һәрберсе лексикология фәне белән тыгыз бәйләнештә яши. Шуларның берсе – үсешкә ирешкән һәм татар тел белемендә формалашып җиткән лингвокультурология фәненә тукталып үтик. Тел һәм мәдәният бәйләнешен өйрәнә торган лингвокультурология фәнендә сүзнең эчке потенциалының милли мәдәният үзенчәлекләрен чагылдыра алу мөмкинлеге

алгы планга куела. Теге яки бу телнең семантик системасының асылын, анда сакланган мәдәни кодларны өйрәнү, нигездә, сүз мәгънәсенең асылын ачу процессы аша ирешелә. Шунлыктан лингвокультурология фәне беренче чиратта ономасиология һәм семасиология тармаклары белән тыгыз бәйләнештә яши. Ономасиология һәм лингвокультурология бәйләнеше чынбарлык предметларын атау барышында барлыкка килгән этник үзенчәлекләр системасын өйрәнгәндә ачылса, семасиология һәм лингвокультурология арасындагы мөнәсәбәт мәдәни концептларның мәгънәви эчтәлегендә булган үзенчәлекле якларны системалаштыру һәм өйрәнү барышында туа.

Лексикология тел һәм җәмгыять, аның төзелеше, үсеше арасындагы мөнәсәбәтләрне, үзара бәйләнешләрне өйрәнә торган с о ц и о л и н г в и с т и к а фәне белән дә тыгыз бәйләнештә яши. Кешенең коммуникатив эшчәнлеген, тел һәм сөйләмнең функцияләрен, телнең яшәеш формаларын, тел һәм мәдәният, дөньядагы халыклар һәм телләр, тел ситуацияләре һәм арадаш телләр, милли тел сәясәте, җәмгыятьнең тел үсешенә тәэсир ясау мөмкинлеге һ.б. мәсьәләләрне өйрәнү процессында төп объект буларак шулай ук сүз алына. Төрле иҗтимагый һәм территориаль диалектларның лингвистик үзенчәлекләре, традицион лингвистикада кулланылыш даирәсе ягыннан телнең сүзлек составын өйрәнү лексикологиянең төп бурычларыннан санала.

Лексикология фәнендә тупланган мәгълүматларны п с и х о л и н г в и с т и к а фәне дә үз максатларында куллана. Психолингвистика – сөйләм эшчәнлегенең психологик һәм лингвистик якларын, тел кулланылышының иҗтимагый һәм психологик якларын өйрәнә торган фән. Лексикология һәм психолингвистика фәннәренең кисешү ноктасы булып төрле типтагы сөйләм эшчәнлегендә сүзнең мәгънәви структурасының формалашуы һәм кулланылышы тора.

Гомуми тел гыйлемендә яңа фәннәрдән саналган н е й р о л и н г в и с т и к а да лексикология белән бәйләнештә яши. Нейролингвистика – психология, неврология һәм тел белеме фәннәре чигендә барлыкка килеп, сөйләм эшчәнлеге механизмнарының баш мие зарарлану нәтиҗәсендә үзгәрүен өйрәнә торган тармак. Лексикологиянең әлеге фән белән бәйләнеше афазия (баш миенең аерым өлкәләре зыян күргәндә, сөйләмдә барлыкка килгән кимчелекләр) вакытындагы семантик үзгәрешләр һәм сүзләр

арасындагы бәйләнеш юкка чыгу, актив сүзлек составының пассивлашуы яки кимүе процессларын өйрәнгәндә ачык чагыла.

Әйтергә кирәк, психолингвистика һәм нейролингвистика тармаклары хәзерге татар тел гыйлемендә формалашу стадиясендә тора.

Лексикологиянең катлаулы һәм күп аспектлы фән булуын ассызыклап үткән идек. Хәзерге тел белемендә лексикология терминын ике төрле аңлату бар. Киң мәгънәдә әлеге термин сүз һәм тотрыклы әйтелмәләрне өйрәнә торган тәгълимат буларак кабул ителә (мәсәлән, В.В. Виноградов, Н.М. Шанский, Д.Н. Шмелёв һәм башка галимнәрнең хезмәтләре). Тар мәгънәдә әлеге фәннең өйрәнү объекты булып бары тик сүз алына һәм төп игътибар хәзерге телнең лексик составын өйрәнүгә юнәлә. Тагын шуны искәртү кирәк: традицион хезмәтләрдә сүз һәм тотрыклы әйтелмәнең табигатен, аларның мәгънәсен, мәгънә үсеш-үзгәрешен, исем-атама бирү закончалыкларын, сүзнең тарихи үсешен һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән тармакларын лексикология кысасында карау киң таралыш тапкан. Мондый фикер аерым телнең сүзлек составын өйрәнә торган тармак буларак лексикология фәненнән төзелгән дәреслекләрдә аеруча еш очрый.

Хәзерге лингвистикада сүзнең эчке табигатен һәм кулланылышын төрле яклап өйрәнә торган тармакларны лексикология фәне кысасыннан киңрәк планда, тел белеменең аерым тармаклары буларак карау формалашкан. Бу тармакларга лексик семантика, этимология, лексикография, фразеология, ономастика керә. Әлеге фән тармакларының өйрәнү объекты буларак, сүз һәм аның семантик табигате алына.

Семасиология (грек. *semasia* – мәгънә, *logos* – өйрәнү) сүзләрнең мәгънәләрен, мәгънә үсешен, үзгәрешен өйрәнә. Ул тел берәмлекләренең эчке табигатендә объектив чынбарлык күренешләренең чагылыш үзенчәлекләрен, форма аша мәгънә бирелешен тикшерүне максат итеп куя.

Ономасиология (грек. *onyma* – исем, *logos* – өйрәнү) – әйбер, күренешләргә атама бирү закончалыкларын өйрәнә торган тармак. Ономасиология атама бирү үзенчәлекләрен, алымнарын һәм техникасын, атама бирү процессында объектив чынбарлык күренешләренең чагылышын телнең барлык берәмлекләренә мөнәсәбәтле тикшерә. Әлеге тармак мәгънәнең бирелеш формаларын өйрәнүгә йөз тота.

Тел белемендә семасиология һәм ономасиология тармаклары лексик семантика – сүзнең мәгънәсен өйрәнә торган фән кысасында берләшәләр.

Этимология (грек. *etymon* – чын, *logos* – өйрәнү) – сүзнең килеп чыгышын һәм мәгънә үсешен өйрәнә торган фән. Ул сүзнең мотивлаштыру мөмкинлеген, сәбәпләрен өйрәнә, мәгънә үсешендә барлыкка килгән үзенчәлекләрне ачыклый.

Фразеология (грек. *phrasis* – тәгъбир, *logos* – өйрәнү) – тотрыклы әйтелмәләрне өйрәнә торган тармак.

Лексикография (грек. *lexsikos* – сүз, *grapho* – язу) – тел белеменең сүзлекләр төзү теориясен һәм практикасын өйрәнә торган фән ул.

Ономастика (грек. *onomastike* – исем кушу сәнгате) – тел белеменең барлык төр ялгызлык исемнәренең үсеш-үзгәреш, ясалыш, номинацияләү закончалыкларын, кулланылу үзенчәлекләрен өйрәнә торган тармагы. Ялгызлык исеменең төренә карап, антропоним, топоним (гидроним, ороним, ойконим, микротопоним), зооним, космоним, эргоним һ.б. аерыла. Ономастика фәне ялгызлык исемнәрен фонетик, морфологик, этимологик, семантик, сүз ясалышы яссылыкларында өйрәнә. Ул тарих, этнография, археология, әдәбият белеме, текстология, география, психология кебек фәннәр белән тыгыз бәйләнештә яши һәм үсә.

Шулай итеп, лексикология фәне үзенең өйрәнү объекты, юнәлешләре ягыннан шактый киң һәм күп аспектлы фән санала. Тел белемендә барлыкка килгән яңа тикшеренү методлары һәм алымнары телнең лексик составын төрле яклап өйрәнү мөмкинлекләрен ача.

## § 2. Татар теле лексикасын өйрәнүдә төп чыганаклар

Татар тел гыйлеменең башка тармаклары арасында татар лексикологиясе чагыштырмача соң формалашкан һәм аз өйрәнелгән өлкә санала. Лексиканың төрле катламнарына караган фактик материалны туплау һәм өйрәнүгә бәйле аерым хезмәтләрнең әзерләнү һәм дөнья күрү тарихы шактый тирән дәверләргә барып тоташуына карамастан, татар теле лексикасын системалы һәм фәнни яссылыкта өйрәнүгә багышланган хезмәтләр XX гасырның 30–40 нчы елларында гына басыла башлый. Шулай да, төрки-татар лексикасының диахроник планда үсешен һәм үзгәрешен билгеләргә ярдәм

итә торган күп санлы чыганаклар татар теленең сүзлек составын һәм аны өйрәнә торган фән тармагының формалашу һәм үсеш этапларын тулаем күзалларга ярдәм итә.

Бу төр чыганаклар рәтендә Болгар дәүләте чорында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» (Кол Гали), «Ана вә угыл» дастанын; Алтын Урда чоры чыганакларыннан «Кыйссасел-әнбия» (Насреддин Рабгузи), «Нәһҗел-фәрадис» (Мәхмүд Болгари әс-Сараи), «Мәхәббәтнамә» (Харәзми), «Хөсрәү вә Ширин» (Котб) һ.б.; Казан ханлыгы чорының Мөхәммәдьяр, Өмми Кәмал әсәрләрен, «Мәҗмәгыль-кавагыйд» хезмәтен һ.б.; XVII–XVIII гасыр әдәбиятыннан Мәүла Колый, Габдессәлам, Габдерәхим Утыз Имәни һ.б.әсәрләрен, XIX гасыр – XX гасыр башына караган Г. Кандалый, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акъегет, З. Бигиев, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай һ.б. әсәрләрен атау кирәк.

XX гасыр һәм хәзерге татар әдәбиятының ядкярләре шулай ук татар теленең лексик составын өйрәнүдә төп чыганак булып торалар.

Моннан кала халыкның җанлы сөйләм теле, диалект һәм сөйләшләрдә кулланыла торган лексик берәмлекләр дә телнең сүзлек байлыгын төрле яклап өйрәнүдә алыштыргысыз роль башкаралар.

Чыганаклар арасында **сүзлекләр** зур әһәмияткә ия. Татар сүзләренең сүзлекләргә теркәлеп, беркетелеп калуы бик борынгы заманнарга карый. Шулардан иң борынгысы – Мәхмүд Кашгарый тарафыннан XI гасырда төзелгән «Диване лөгатет-төрк» исемле сүзлек. Төрки телләр сүзлеге булган бу хезмәттә шул замандагы күп санлы төрки кабиләләрнең тел үрнәкләре, бай фольклор материалы урын ала. Анда аерым җырлар, мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар тупланган. Сүзлекнең нигезен төрки сүзләр тәшкил итә. Автор, ул сүзләрнең кулланылышын күрсәтү өчен, китерелгән мисалларга гарәп телендә аңлатмалар биреп бара. Мондагы сүзләрнең, халык авыз иҗаты материалларының шактые хәзерге татар телендә дә яшәп килә.

XIII–XIV гасырлар чигендә гарәп галиме Ибне Мөһанна «Китабе тәрҗемәи фарси вә төрки вә магулый» дип аталган сүзлек төзи. Гарәп телендә язылган әлеге хезмәттә төрки телләрнең фонетикасы, морфологиясе хакында мәгълүматтан тыш, йөзләгән лексик

берәмлек бирелә. Әлеге сүзлектә бирелгән фигыльләрнең зур күпчелегенең хәзерге татар телендә дә актив кулланылышта йөрүе сүзлекнең татар теленә якынлыгын дәлилли торган фактларның берсе булып тора (Ногман, 1969: 9).

Татар теленең борынгы элементлары «Кодекс Куманикус» (Коман мәҗмугасы) сүзлегендә дә урын ала. Танылган тюрколог В.В. Радлов бу китаптагы команн теленең Идел буе татарлары теленә, аеруча мишәр диалектына якынлыгын әйтә (Радлов, 1884).

1581 елда хаҗи Бәйрәм Хаҗи Булат 10 меңнән артык сүздән торган «Гарәпчә-төркичә сүзлек» төзи. Казан университеты китапханәсендә генә сакланып калган 296 битле әлеге кульязмада хәзерге татар телендә кулланыла торган сүзләрне дә күрергә була.

XVI гасырда Казан ханлыгын рус дәүләтенә кушканнан соң, гамәли куллану өчен төзелгән татарча-русча һәм русча-татарча сөйләүнамәләр, тәгъбирләр, аңлатмалар һәм сүзлекләр төзелә башлау татар теле лексикасын теркәү юнәлешендә яңа бер этап була. Шундый сүзлекләрдән XV–XVII гасырларга караган тел материалларын, шул исәптән 40 ка якын татар сүзе һәм тәгъбирен туплаган рус галиме П.К. Симонинның «Памятники старинной русской лексикографии по рукописям XV–XVII веков» (1908) хезмәтен һәм билгесез автор тарафыннан төзелгән «Сборник рукописей конца XVII и начала XVIII века» исемле кульязма җыентыгын атарга кирәк. Соңгы кульязма эчендә «Наука языку турскому» дип аталган 15 битлек аңлатмалы сүзлекчә бар һәм, рус сүзләренә татарча аңлатма бирелеп, алар «турский», «по-персидски», «по-татарской речи» дигән бүлекләргә аерып күрсәтелә.

1740 елларда П.И. Рычков төзегән «Русча-татарча-калмыкча сүзлек»тә татар теле шул чор сүзлек составын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак ролен үти.

XVIII гасырның соңгы чирегендә татар теле рус гимназияләрендә һәм университетларында укытыла башлый. Шул уңай белән күп кенә русча-татарча сүзлекләр дөнья күрә. 1785 елда Сәгыйть Хәлфин 23000 сүзне эченә алган «Татарский словарь в пользу обучающихся при Казанских гимназиях юношества татарскому языку» дип исемләнгән сүзлек төзегән.

1804 елда Санкт-Петербург шәһәрендә Иосиф Гигановның 682 битле русча-татарча сүзлеге басыла.

Ибраһим Хәлфиннең 1600 сүзне эченә алган татарча-русча һәм өлешчә русча-татарча сүзлеге 1822 елда «Жизнь Джингиз хана и Аксак Тимура с присовокуплением разных отрывков, до истории касающихся, в коих все слова для обучающихся расположены по алфавиту» дигән китабына кушымта буларак басыла.

Казанның рухани семинариясендә татар теле укытучысы А.Троянский рус руханилары булып чыгучыларга мөселман дине әһелләре куллана торган иске татар теле нигезендә «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нём речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии священника Александра Троянского» исемле ике томлык сүзлек төзи, әлеге сүзлек Казанда басылып чыга (1 том, 1833, 629 б.; 2 том, 1835, 340 б.).

Салихҗан Кукляшевның 1859 елда Казан университеты типографиясендә басылган «Словарь к татарской хрестоматии» сүзлеге дә игътибарга лаек (106 б.).

Санкт-Петербург университетының Көнчыгыш факультеты доценты Лазарь Будагов «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий» исемле бик зур сүзлек төзи, аның I томы Санкт-Петербургта 1869 елда басыла (820 б.), II томы шунда ук 1871 елда чыга (416 б.).

Керәшеннәрне рухани уку йортларында укытучылар да керәшенчә-русча сүзлекләр төзү эшенә керешәләр. Шундый сүзлекләрнең иң күренеклесен Н.П.Остроумов төзеп чыгара. Ул «Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещённых татар Казанской губернии» дип атала. Казан университеты типографиясендә 1876 елда басыла, 145 биттән тора. Моннан тыш, 1892 елда шунда ук «Татарско-русский словарь Н. Остроумова» дигән хезмәт нәшер ителә (250 б.).

XIX гасырның II яртысында татар теленең лексикасын өйрәнүгә һәм туплауга Каюм Насыйри күп көч сарыф итә. 1878 елда аның «Татарча-русча лөгать» исемле 120 битлек китабы дөнья күрә. 1892 елда Каюм Насыйриның «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» дигән сүзлеге чыга. 263 битлек әлеге сүзлектә 20 мең сүз теркәлгән.

Каюм Насыйриның татар теленең сүзлек составын өйрәнүгә багышланган әһәмиятле хезмәтләреннән тагын берсе – «Ләһҗәи

татари» дигән ике томлык аңлатмалы сүзлек. Бу хезмәт университет типографиясендә басыла: I томы (226 б.) – 1895 елда, II томы (106 б.) 1896 елда дөнья күрә.

Шуны искәртү кирәк: татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү идеясен 1829 елда ук Казан университетында гарәп һәм фарсы телләре укытучысы профессор Франц Эрдман күтәреп чыга, аның проекты университет советында уңай бәя ала, ләкин бу идея ул чорда кадрлар булмау аркасында реальләшми кала.

Билгесез авторның «Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом» китабы 1880–1891 еллар арасында биш мәртәбә басылып чыга.

1894 елда А.А.Воскресенский «Русско-татарский словарь с предисловием о произношении и этимологических изменениях татарских слов» дип аталган 374 битлек сүзлек бастыра.

XX гасыр башында дөнья күргән сүзлекләр күләм һәм лексик фондның тулылыгы белән аерылып тора. 1913 елда Солтан Рахманколый һәм А.Карам 35 000 сүзне эченә алган «Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого языка, со включением иностранных слов, вошедших в употребление в русском языке» дигән сүзлек чыгаралар. Әлеге сүзлек, И.Кулиев һәм Т.Мәмлиев тарафыннан эшкәртелеп, 1920 елда тагын нәшер ителә.

XX гасырның 20 нче елларында аңлатмалы сүзлек төзү эшен Җамал Вәлиди күтәреп ала һәм «Татар теленең тулы сүзлеге» исеме астында 1927 елда аның беренче томын һәм 1929 елда икенче томының беренче өлешен чыгара.

Бу чыганаклар татар теленең сүзлек байлыгын, семантик үзенчәлекләрен өйрәнүдә алыштыргысыз байлык вазифасын үтиләр һәм татар лексикологиясе фәне формалашуның башлангыч этабы булып торалар.

XX гасырның 40 нчы елларыннан фәнни яктан эшкәртелгән һәм билгеле бер системага салынган сүзлекләр төзелә башлый, алар телнең лексик байлыгын өйрәнүдә төп чыганак булып тора. Шундыйлардан 1938–1951 еллар арасында Г. Нугайбәк, Ф. Әмирхан, М.Корбанов, С.Файзуллин, Р.Газизов, М.Гимадиев тарафыннан төзелгән татарча-русча сүзлекне, 1966 елда Мәскәүдә «Совет энциклопедиясе» нәшриятында Г.С.Әмиров, А.Ш.Әсәдуллин, У.Ш.Байчура, Ш.С.Ханбикова

редакцияләгән, соңрак Ш.С.Ханбикова һәм Л.Т.Мәхмүтова тарафыннан кабат редакцияләнгән «Татарско-русский словарь» сүзлеген атарга кирәк.

XX гасыр урталарыннан сүзлекләр төзү эшен Тел, әдәбият һәм тарих институты башкарып килә. Институт галимнәре тарафыннан төзелгән күптомлык сүзлекләрдән дүрттомлык русча-татарча сүзлекне билгеләп үтү зарур. Аның беренче томы Р. Газизов, М. Гимадиев тарафыннан 1955 елда чыгарыла (XI + 359 б.), икенче томы Р.С. Газизов, Л.Т. Мәхмүтова, Э.М. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова тарафыннан төзелә һәм 1956 елда нәшер ителә (XII + 448 б.) өченче томын Р.Ф. Шакирова, Э.М. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.С.Фасеев төзиләр, бу том 1958 елда дөнья күрә (X + 483 б.), дүртенче томы Э.М. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмүтова, Р.Ф. Шакирова, Ф.С. Фасеев, Р.Ш. Шакуров, Г.С. Амиров тарафыннан 1959 елда чыгарыла (VII + 448 б.).

1971 елда 50 000 сүз кергән 803 битлек русча-татарча бер томлык сүзлек төзелә. 1984 елда «Русский язык» нәшриятында Ф.Ә. Ганиев редакциясендә русча-татарча сүзлек дөнья күрә (736 б.). Әлеге сүзлек 1985, 1991, 1997 елларда кабат нәшер ителә.

1988 елда И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналееваның 25 мең сүзне эченә алган татарча-русча сүзлеге дөнья күрде, 1995 елда ул кабат нәшер ителде. 2014 елда әлеге сүзлекнең алтынчы басмасы басылды.

Тел, әдәбият һәм тарих институты аңлатмалы сүзлек төзүгә аерым әһәмият бирә һәм аны өч томда чыгаруга ирешә: 1 том – 1977 елда (XVI + 476 б.), 2 том – 1979 елда (728 б.), 3 том 1981 елда (832 б.) чыга. Өч томда редколлегиясе Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров һәм Ш.С. Ханбикова редакциясендә дөнья күрә.

2005 елда ТӘҺСИнең лексикография бүлеге Ф.Ә. Ганиев (баш ред.) К.С. Минибаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффаровалар редакциясендә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н яңартып чыгарды. Ул – 848 биттән торган һәм 58 000 гә якын берәмлекне туплаган бер томлык хезмәт.

2007 елда икетомлык татарча-русча сүзлекнең чыгуы татар тел гыйлеме, аерым алганда лексикологиясе үсешендә бик зур бер уңышлы адым булды. Редколлегиясе: Ш.Н. Асылгәрәев, Ф.Ә. Ганиев, М.З. Зәкиев, К.М. Миңнуллин, Д.Б. Рамазанова.

Сүзлек үз эченә 56 мең сүзне, 7 400 фразеологик берәмлекне ала. Күләме: 1 нче том – 725 б., 2 нче том – 727 б.

Хәзерге көндә татар теле лексикасын өйрәнүдә электрон сүзлекләр, татар теленең «Туган тел» милли корпусы һәм татар телендәге электрон текстларны туплаган татар теленең язма корпусы да әһәмиятле чыганак булып торалар.

Югарыда саналган һәм биредә аталмаган, әмма татар теленең сүзлек составын, аның үсеш-үзгәрешен, кулланылыш үзенчәлекләрен эзлекле һәм комплекслы өйрәнүгә нигез булган чыганаклар татар лексикологиясе фәненең бүгенге дәрәҗәсен һәм үсеш юнәлешләрен билгеләгәндә зур роль уйныйлар.

# СЕМАСИОЛОГИЯ

## § 3. Тел белемендә семасиология фәнен өйрәнү тарихы

Семасиология лексик берәмлекләрнең мәгънәләрен ачу һәм тикшерү белән шөгыльләнә.

Рус тел белемендә семасиология үсеше XIX гасырда дөнья күргән А.А. Потебня, М.М. Покровский хезмәтләренә бәйләнешле карала. А.А. Потебня үзенең хезмәтләрендә тел һәм аң, сүз һәм төшенчә мәсьәләләре турында кызыклы фикерләрен чагылдыра. М.М. Покровскийның «Семасиологические исследования в области древних языков» (1896) исемле күренекле академик хезмәте XX гасыр семасиологлары хезмәтләренең методологик нигезен тәшкил итә.

Билгеле булганча, XX гасыр урталарында совет тел белемендә зур күләмле аңлатмалы һәм ике телле сүзлекләр төзелә. Шул уңайдан, сүзнең лексик-семантик төзелеше, лексик мәгънәнең компонентлары, алар арасындагы бәйләнеш-мөнәсәбәтләрне, үсеш-үзгәрешләрне махсус рәвештә өйрәнү ихтыяҗы барлыкка килә. Бу юнәлештә рус тел белемендә күп кенә хезмәтләр дөнья күрә башлый. Шулардан В.В. Виноградовның «Основные типы лексических значений слов» мәкаләсендә, сүзнең реаль лексик мәгънәсен күзаллау өчен, сүзне телнең тулаем системасына (лексика, сүз ясалышы, грамматика), шул телдә сөйләшә торган халыкның тарихы, гореф-гадәте, фикер һәм тәкбирләү үзенчәлегенә бәйле рәвештә кенә карау зарурлыгы мәсьәләсе күтәрелә (Виноградов, 1953: 12). 1957 елда В.А. Звегинцевның «Семасиология» хезмәтендә семасиология фәне, аның башка лингвистик өлкәләр белән бәйләнеше, лексик мәгънә мәсьәләләренә игътибар бирелә. 50–70 нче елларда совет семасиологиясендә лексик микросистемаларны

тарихи яктан өйрәнү юнәлеше киң тарала. Бу юнәлеш, А.А. Уфимцеваның «Опыт изучения лексики как системы» (1962) хезмәте чыкканнан соң, киң резонанс ала. Бу юнәлештә сүзнең лексик-семантик төзелешен тикшергән күп санлы монографияләр Көнбатыш Европа телләре материалына нигезләнеп языла, шул телләрдә чагылыш тапкан теоретик күзаллауларга игътибар ителә (Смирницкий, 1956; Звегинцев, 1957; Никитин, 1970, 1974; Степанов, 1976; Уфимцева, 1980).

XX гасырның 50–70 нче елларында совет тел белеменең семасиология юнәлешенә зур импульс биргән В.А. Звегинцев, А.А. Уфимцеваның монографияләреннән соң 80 нче еллар уртасында семасиология фәне семантика мәсьәләләрен көн үзәгенә куя башлый.

Соңгы елларда рус тел белемендә семасиология фәненең яңа ачышларга нигезләнеп, «сүзнең лексик мәгънәсе», «мәгънә эчтәлеге» (лексик-семантик төзелеше, әлеге төзелешне барлыкка китерә торган компонентлар), «лексик мәгънәнең типлары» дигән төшенчәләр билгеле бер дәрәҗәдә яңача яктыртыла (Толстая С.М., 1995; Апажаева М.Л., 2004; Левитская В.В., 2012; Маклакова Е. А. , Стернин И. А., 2015). Сүзнең мәгънә эчтәлеген аның лексик һәм грамматик мәгънә бәйләнешләренең берлеге итеп карарга кирәклеге семасиологиянең методологик нигезе итеп кабул ителә. И.М. Кобозаева (2000), М.А. Кронгауз (2001) хезмәтләрендә телдә һәм сөйләмдә тел берәмлекләренең мәгънә үсеше семантикага бәйләнелешле аерым фәнни юнәлеш итеп үстерелә.

Татар тел белеме фәнендә семасиология мәсьәләләре XX гасырның 60 нчы елларында лексикология дәреслекләрендә күтәрелә (Сабиров, 1965: 17; Сафиуллина, 1999: 14–56). Авторлар дәреслекләрдә семасиология бүлекчәләрендә сүзнең лексик мәгънәсе, аның типлары, сүздәге күчерелмә мәгънәләр (метафора, метанимия, синекдоха, вазифа буенча күчеш), омонимнар, синонимнар, антонимнар мәсьәләсе тикшерелә.

Татар тел белемендә семасиология беренчеләрдән булып монографик планда И.Б. Бәширова тарафыннан өйрәнелә. Авторның әлеге фәнгә багышланган «Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» (2006) монографиясендә лексикологиянең гомуми мәсьәләләре, татар лексикасында парадигматик бәйләнеш-мөнәсәбәтләр, синтагматик бәйләнеш-мөнәсәбәтләр һәм лексикада ассоциатив-деривации-

он-эпидигматик бәйләнеш-мөнәсәбәтләр гомум лексикологиянең соңгы казанышларына таянып яктыртыла. Соңрак авторның «Татар әдәби теле. Семасиология» (2010) китабында 2006 елда чыккан монографиясендә теоретик-нәзари планда куелган проблемалар, тагы да киңәйтелеп, сүзнең лексик мәгънәсе, мәгънә эчтәлегенең компонентлары (денотат-сигнификат) һәм мәгънә типлары (объектлы, субъектлы, структур); татар лексикасында парадигматик, синтагматик, ассоциатив-эпидигматик һәм когнитив-концепт бәйләнеш-мөнәсәбәтләр; лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма нигезендә төркемләнү мәсьәләләре тикшерелә.

Соңгы елларда төрки тел белемендә лексикологиягә багышланган хезмәтләрдә дә, аерым монографик хезмәтләрдә дә семасиология мәсьәләләре яктыртыла (казах телендә Сарсенова Қ.Қ. «Қазіргі қазақ тілінің лексикологиясы» (2010), каракалпак телендә Айназарова Г. «Ҳәзирги қарақалпақ тили. Лексикология» (2006) һ.б.; төрек тел белемендә Duymaz Enes-Turan Abdulkadir «Türkçede Anlam Bilgisi» (2006), Birleşi Aksan Doğan Anlambilim Konuları ve Türkçenin Anlambilimi» (2009); Будагова З.И. «Азәрбайҗан теленең семасиологиясе», Курбанов А. «Азәрбайҗан теленең семасиологиясе», Вердиев З., Агаева Ф., Адилов М. «Azərbaycan dilinin semasiologiyası» һ.б.).

## Телнең универсаль берәмлеге буларак сүз

### § 4. Сүзгә гомуми билгеләмә

Татар теленең гаять дәрәҗәдә бай һәм төрле катламнарны үз эченә алган сүзлек составында җәмгыятьнең дөньяны кабул итү нәтиҗәләре, милли мәдәниятнең үсеш баскычлары чагылыш таба. Кешелек җәмгыяте туплаган тәҗрибәне, төрле төшенчәләрне, мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне буыннан-буынга тапшыруда төп рольне сүзләр уйный.

Сүз дип үзенең эчтәлегендә мәгълүм төшенчә алган, реаль чынбарлыкның теге яки бу ягын чагылдырган, халык тарафыннан кабул ителгән авазлар системасы ярдәмендә мәгънә берлегенә ия булган, теге яки бу грамматик категориягә билгеле бер мөнәсәбәттә торган тел берәмлеген атыйлар. Үзенең лингвистик табигате ягыннан шактый катлаулы, күпкырлы берәмлек булган сүз, аерым халәттә һәм башка берәмлекләр белән бәйләнешкә кереп,

чынбарлык турында мәгълүматларны төрле яклап чагылдыра, дөньяны милли күзлектән кабул итүгә бәйле чынбарлык күренешләренә төрле яклап бәя бирә.

Сүзнең асылын ачыкларга, аның табигатенә хас төп үзенчәлекләрне барларга омтылу шактый күптән башланса да, әлегәчә аның төп асылына бәйле фикер төрлелеге күзәтелә. Хәзерге тел белемендә сүзгә график, фонетик, структур, грамматик, лексик-семантик һәм башка принциплардан чыгып бирелгән җитмештән артык билгеләмә яши. Шуларның барысында да диярлек сүзнең аерым бер системага каравы һәм эчке төзелеше, чикләре һәм атаган объект, күренешләр белән мөнәсәбәте исәпкә алына.

Лексик-семантик принципка бәйле, хәзерге тел белемендә сүзнең предмет, күренеш, билге, процесс, төрле мөнәсәбәтләрне атый торган, танып белү нәтиҗәсендә реаль чынбарлык турында һәртөрле мәгълүматны үзенә туплаган номинатив (лат. *nomination* – атау) һәм когнитив (лат. *cognition* – танып белү) берәмлек булуы бәхәссез таныла.

Тел – мәгълүматлар кодын берләштергән аралашу чарасы, икенче яктан, аның кеше аңы үсешен билгели торган менталь мәгълүмати даирә икәнен дә билгеләү зарур. Аралашу процессында телнең төп һәм иң кечкенә мәгълүмати берәмлеге булган сүзләрдә танып белү нәтиҗәсендә аңыбызда барлыкка килгән менталь образлар реальләшә, үзара бәйләнешкә керә, башкаларның мәгълүматны ни рәвешле кабул итүенә йогынты ясый. Шуның нәтиҗәсендә телнең төп функцияләреннән саналган аралашу (коммуникатив), чынбарлыкны танып белү (когнитив) һәм эмоциональ (хис-тойгы белдерү) функцияләрен башкаруда сүз иң әһәмиятле урын били. Сүзнең гомуми үзенчәлекләреннән аның аралашучылар арасында төрле мөнәсәбәт урнаштыру мөмкинлеген, дөньяны кабул итүдә төп чара һәм тәэсир итү көченә ия булуын, бәя бирү, милли мәдәният турында мәгълүматларны саклау һәм аларны буыннан-буынга тапшыруда код, шифр ролен башкару үзенчәлекләрен дә күрсәтү кирәк. Болар барысы да сүзнең шактый катлаулы һәм күп яссылыкта тасвирлана торган берәмлек булуын исбатлый.

Сүз – беренче чиратта телнең мәгънәгә ия төп берәмлеге, әмма башка тел берәмлекләреннән ул үзенең эчке табигате (мәгънәсе) һәм тышкы төзелеше (фонетик тышчасы һәм грамматик төзелеше) белән шактый аерыла. Ул – телнең лексик-семантик катламына карый,

аның нигезен тәшкил итә. Сүзне барлыкка китерүдә телнең мәгънәгә ия булган беренчел элементлары – фонема һәм морфема катнаша. Мәсәлән, *ташчы* сүзендә 5 фонема: *[т][а][ш][ч][ы]* бар, шуларның беренче өчесе *[т][а][ш]* сүзнең тамырын хасил итсә, калган икесе исә сүзнең мәгънәсен үзгәртүдә катнаша торган сүз ясагыч морфеманы барлыкка китерә. Үз чиратында *ташчы* сүзе югарырак дәрәҗәдәге тел берәмлекләрен – сүзтезмәләрне, җөмләләрне, ягъни синтаксик конструкцияләрне барлыкка китерүдә катнаша. Мәсәлән: *ташчы хезмәте, тырыш ташчы, абыем ташчы булып эшли* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, тел берәмлекләре иерархиясендә сүз төп бәйләүче чылбыр вазифасын башкара.

Сүзнең мәгънәгә ия булган башка тел берәмлекләре белән уртак һәм аермалы яклары бар. Ул да мәгънәгә ия, үзеннән югарырак дәрәҗәдә булган тел берәмлекләрен төзүдә катнаша, үзеннән кечерәк дәрәҗәдәге берәмлекләрне берләштерә. Әмма сүзне башка тел берәмлекләреннән аера торган гаять әһәмиятле үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, мәгънә аеруга хезмәт иткән, әмма үзе мәгънә белдерми торган тел берәмлеге фонемадан аермалы буларак (чагыштыр: *ат-от-ут-ит*), сүз фонетик тышчага һәм мәгънәгә ия булган тел берәмлеге, билге санала. Морфемадан мөстәкыйльлеккә ия булуы, сөйләмдә иркен яңгырату мөмкинлеге булу белән аерыла (чагыштыр: *апа, матур, аккош; -чы; -даш, -лар, -да*). Үз чиратында татар телендә бик күп сүзләр бер морфемалы санала, ягъни тамырдан гына тора, һәм алар телдә аерым сүз буларак кулланылалар, мәсәлән: *ак, тук, әти, китап, күз* һ.б.

Аерым сүзләрнең ияртүле бәйләнештә килеп, предмет, күренеш, процесс, билге һ.б.ны төгәлләп, аныклап атаган сүзтезмәдән аермалы буларак, сүз эчке һәм тышкы төзелеше ягыннан бербөтен берәмлек итеп күзаллана (чагыштыр: *бала, күңел, күз, сары; бала күңеле, сары күз*). Сүзтезмә синтаксик атау берәмлеге саналса, сүз лексик атау берәмлеге булып тора. Сүзтезмә – сүз белән җөмләне үзара тоташтыра торган баскыч ул.

Үзенең төзелеше ягыннан да сүз күпьяклы һәм катлаулы булуы белән үзенчәлекле. Беренче чиратта сүз – матди тышчага һәм шушы телдә сөйләшүчеләргә аңлашыла торган мәгънәгә ия булган структур-семантик берәмлек. Әмма сүзнең бу ике үзенчәлеге генә үзәккә алынса, аны тел системасыннан аеру булыр иде. Шунлыктан

структур яктан сүздә фонетик, морфологик, семантик аспектларны аерып карау мөһим.

Ф о н е т и к яисә г р а ф и к яктан сүзне тасвирлаганда, беренче чиратта аның авазлар берлегеннән торган матди тышчага ия булуы күрсәтелә. Язмада ул аерым хәрефләр аша белдерелсә (*тәрәзә, болыт, алдынгы*), сөйләм телендә авазлар ярдәмендә тәкъдим ителә: *[тәрәзә], [бŏлот], [а°лдыйңғы]*. Сүзнең фонетик яктан бөтенлеге басымга бәйле, чөнки сүз басымы турыдан-туры аның семантик эчтәлегенә тәэсир итә, аны үзгәртә, мәсәлән: алма́ – а́лма, чишмә́ – чи́шмә һ.б.

М о р ф о л о г и к яктан сүз, югарыда әйтелгәнчә, морфемалардан тора һәм аерым сүз төркемнәре составында яши. Нинди сүз төркеменә каравына бәйле, сүз төрле лексик-семантик төркемнәр составында яши, мәсәлән, исем сүз төркеменә караган предметлыкны белдергән сүзләр (*китап, бала, күлмәк*), матдәлекне белдергән исемнәр (*он, тоз, май*), төрле грамматик формаларда килеп, аралашу процессында башка сүзләр белән төрле мөнәсәбәтләргә керә, чынбарлык күренешләрен төрле яклап атый һәм бәяли. Сөйләм барышында сүзләр төрле грамматик формаларда белдерелә ала, мәсәлән *йорт* сүзе *йортка, йортның, йорттан, йортым, йортлар* һәм башка грамматик формаларда сөйләмдә кулланыла.

С е м а н т и к яктан бәяләгәндә, сүзнең мәгънәгә ия һәм төшенчә белән турыдан-туры бәйләнештә яшәгән тел системасының бер билгесе (знагы) булуы үзәккә алына. Сүзнең эчке табигатен, асылын күрсәтә торган төп билге булып семантик як исәпләнә. Ул, тел системасының бер билгесе буларак, сүз белән чынбарлык арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау максатын куя, әмма бары тик семантик үзенчәлекне генә алгы планга кую сүзнең табигатен һәм башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен тулысынча ачмый.

Сүз үз эчендә сөйләмдә бирелү мөмкинлеген һәм эчтәлеккә ия булу кебек ике сыйфатны берләштерә, һәм әлеге сыйфатлар сүзнең төп асылын билгели торган төп күрсәткечләр санала. Сүзнең фонетик, морфологик аспектлары аның сөйләмдә бирелеш ягын тасвирласа, семантик як исә сүзнең эчтәлек белән мөнәсәбәтен билгели.

Шулай итеп, үзенең гомуми табигате ягыннан сүз – чынбарлык күренешләрен атау һәм аларга хас булган төрле мәгълүматны

саклау вазифасын башкарган, үзеннән кечерәк булган фонема һәм морфемадан төзелгән, милли телнең авазларыннан торган тышкы формага һәм эчке мәгънәви структурага ия булган тел берәмлеге. Аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сүз үзеннән югарырак дәрәҗәдәге берәмлекләрне барлыкка китерә һәм алар ярдәмендә фикерне башкаларга җиткерүдә төп чара булып тора.

## § 5. Сүзнең асыл сыйфатлары (билгеләре)

Сүз тормыш-көнкүрештәге предмет, билге, процесс һәм төрле мөнәсәбәтләр турындагы белем-мәгълүматларны атау, алар турында хәбәр итү өчен хезмәт итә торган төп берәмлек санала. Югарыда сүзнең төп асылын билгели торган сөйләмдә бирелү мөмкинлеге һәм эчтәлеккә ия булу ягы турында әйтелгән иде. Болар сүзне башка тел берәмлекләреннән аера һәм тел системасының бер берәмлеге буларак тасвирлый торган төп билгеләр булып тора. Әлеге билгеләрнең сүзләрдә ачылышына киңрәк тукталыйк.

Беренче чиратта сүз – с т р у к т у р  б ө т е н л е к к ә ия берәмлек. Сүзнең структур бөтенлеге дигәндә, фонетик һәм грамматик яктан бөтен берәмлек булуы күзаллана.

Сүзнең фонетик бөтенлеге ул – телнең фонетик үзенчәлекләренә нигезләнеп барлыкка килгән авазлар тышчасына ия булуы, шушы формада даими кулланылуы (*[ба$^{о}$л]*, *[тәрәзә]*, *[ҡа$^{о}$ра]*, телдә кабул ителгән формада аһәң, яңгырашка һәм бер басымга ия булуы дигән сүз. Гадәттә, татар телендә сүзләр бер басымлы, әмма аерым очракларда сөйләм агышына бәйле кайбер сүзләр басымын югалтырга мөмкин: *ти́з генә, и́ң матур, алды́ бит, бара́ икән, табарга́ тиеш, шу́л кирәк;* татар телендә кушма сүзләрдә төп басым белән беррәттән, икенче – көчсез басым да күзәтелергә мөмкин: *бала́-чага̀, тиме́р-томы̀р; ю́лбаса̀р, чы̀нбарлы́к, кара̀бода́й* һ.б.

Сүзнең грамматик бөтенлеге дигәндә, сүзнең сөйләмдә аерым бер грамматик мәгънә белдергән грамматик формаларда кулланылуы күзаллана, мәсәлән: *тәрәзә, тәрәзәнең, тәрәзәдә, тәрәзәм, тәрәзәләр.*

Татар телендә грамматик формаларның синтетик (модаль һәм бәйләгеч кушымчалар) һәм аналитик төрләре аерыла. Грамматик мәгънә белдерүче аналитик чараларның ачык мисалы итеп фигыльнең заман формаларын китерергә мөмкин: *бара иде, барган иде, бара торган иде* һ.б. Аналитик грамматик форма бу очракта

кушымча + *иде* ярдәмче фигыле белән ясала. Грамматик форма – морфологик чара ярдәмендә ясалган сүз формасы (сүзформа) ул. Грамматик формалар җыелмасы сүзнең теге яки бу сүз төркеменә каравын күрсәтә. Мәсәлән, *башø, баш**ның**, баш**лар**, баш**ым*** – исем сүз төркеменә, *ак, ак**сыл**, аг**рак*** – сыйфат сүз төркеменә, *барø, бар**а-лар**, бар**абыз**, бар**ды**, бар**ган*** һ.б. – фигыль сүз төркеменә ишарәли торган сүз формалары. Татар телендә шулай ук бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү күренеше дә киң таралган, мәсәлән, *кара (язу карасы), карт, ярлы, бай, ялагай, сукыр (сукырлар йорты), телсез* кебек сыйфатларның, морфологик яктан аерымланып (изоляцияләнеп), тулысынча исем сүз төркеменә күчү очрагы күзәтелә. Мондый сүзләрнең грамматик ягы да үзгәреш кичерә, ягъни алар, сөйләмдә үзләренең беренчел табигатьләренә хас булган төрләнү сыйфатын югалтып, исемгә хас грамматик формаларда киләләр: *каләмемнең карасы беткән; картлар әйткән сүз; байның йорты* һ.б. Шулай итеп, сүзнең грамматик бөтенлеге дигәндә, беренче чиратта аның аерым сүзформалары системасын күзаллыйлар. Сөйләм агышында сүзнең бары тик бер генә формасы (сүзформа) кулланыла.

Икенчедән, структур яктан бөтен булган сүз аерым лексик мәгънәгә ия була, ягъни һәр мәгънәдә чынбарлыкның бер өлеше чагыла, мәсәлән: *өй – торак; түгәрәк – геометрик фигура.* Һәр лексик берәмлек өчен бердәнбер, индивидуаль саналган лексик мәгънә чынбарлыкның билгеле бер күренешен генә чагылдыра.

Өченчедән, сүз реаль тормыш, чынбарлыктагы әйбер, күренеш, процесс, билгеләрне атый һәм аларны лексик мәгънә кысаларында шушы телдә сөйләшүчеләргә җиткерә. Сүзнең атау берәмлеге булуы аның төп билгеләреннән санала.

Дүртенчедән, сүз чынбарлык күренешләре турында төрле *мәгълүмат чыганагы* булып тора.

Бишенчедән, сүз – чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия берәмлек. Башка сүзләр чолганышында гына түгел, ә аерым кулланылганда да аның мәгънәсе татар телендә сөйләшүчеләргә аңлашыла, мәсәлән: *чылбыр, фәрештә, кул, яңгыр, тиз, кара, бару, җырлау* һ.б.

Сүзнең алтынчы билгесе буларак, аның валентлыгын, ягъни башка сүзләр белән ярашып, сүзтезмә (*әнинең күлмәге, йорт төзү, тиз атлау*) яисә җөмлә төзү (*Әнинең күлмәген саклап тотам. Эшчеләр бик тиз арада йортны төзеп бетерделәр. Мин аның, тиз*

*атлап, күршеләргә кереп киткәнен күрдем*) мөмкинлеген билгелиләр. Мәсәлән, *сорау* фигылендә субъект (сораучы кеше), предмет (нәрсә турында сорыйлар), адресат (кемнән сорыйлар) аерыла. Шуннан чыгып, *сорау* сүзе өч валентлы санала. *Ачулы* сүзе дә өч валентлы, чөнки, субъект буларак, ачулы кеше күзаллана, кыек объект – кемгә ачулы, сәбәп – ни өчен ачулы.

Шулай итеп, сүз – фонетик, грамматик һәм лексик-семантик яктан формалашкан тел берәмлеге. Бу график яктан да чагылыш таба. Татар телендә киң таралган саф кушма (*коточкыч, баш-баштаклык, кульяулык*), тезмә (*үги ана яфрагы, аю үләне, гафу итү*), парлы сүзләр (*бала-чага, үрле-кырлы, ир-егет*), аналитик сүзләр (*егыла язды, җырлап җибәрде, туктап калды*) аның ачык мисалы. Берничә компоненттан торуларына карамастан, әлеге сүзләр бер лексик берәмлек (лексема) булып калалар, чөнки алар бер лексик мәгънәгә ия, алар арасына, сүзнең мәгънә бөтенлегенә зыян китермичә, башка сүзне куеп булмый. Шул рәвешле, сүзнең үткәрмәүчәнлек үзенчәлеге дә барлыгын искәртү кирәк.

Югарыда саналган билгеләр шактый тел белгечләре тарафыннан сүзнең тел системасында яши торган берәмлек буларак табигатен тулысынча ачучы төп сыйфатлар булып танылса да, тел белемендә сүзнең асыл сыйфатларын билгеләүдә шактый киң караш яши. Аерым алганда, танылган рус лингвисты Н.М. Шанский түбәндәге сыйфатларны аерып күрсәтә: 1) фонетик яктан формалашкан булу; 2) семантик валентлык; 3) үткәрмәүчәнлек; 4) бер генә басымга ия булу; 5) лексик-грамматик яктан ярашу; 6) яңгыраш һәм мәгънә бердәмлеге; 7) яңгырашка ия булу; 8) бербөтенлек; 9) башка сүзләр белән ярашу киңлеге; 10) аерым халәттә яшәү мөмкинлеге; 11) атау мөмкинлеге; 12) тотрыклылык. Иң әһәмиятлеләре буларак, әлеге сыйфатлар арасыннан сүзнең фонетик яктан формалашкан булуы, лексик-грамматик ярашу һәм үткәрмәүчәнлекне аера.

Ф.С. Сафиуллина, сүзнең төп билгеләре буларак, түбәндәгеләрне күрсәтә: «Сүз фонетик яктан формалашкан була: сүз башы, сүз ахыры закончалыгы, фонемаларның үзенчәлекле тезмәләре, бер басымга ия булу, бөтенлек (сүз эченә авазлар өстәү мөмкин түгел) – бу сыйфатлар һәр сүзгә хас. Грамматик яктан сүз чагыштырмача бөтенлеге һәм бер формага ия булуы белән аерыла, икенче төрле әйткәндә, сүз теге яки бу сүз төркеменә карый. Лексик яктан

һәр сүз билгеле бер мәгънәгә ия. Сүзгә атау вазифасы – номинатив вазифа хас» (Сафиуллина, 1999: 7).

Сүзләрнең төп билгеләрен аерганда, яңгыраш һәм эчтәлек арасындагы бәйләнешнең традицион, телнең тарихи үсеше белән тыгыз бәйләнгән булуын истә тоту кирәк. Еш кына бу бәйләнешнең асылын аңлатып бирү җиңел түгел, әлеге үзенчәлек тел белемендә сүзнең идиоматик сыйфаты буларак карала. Телдә яңгырашы һәм грамматик төзелеше ягыннан бертөрле булган сүзләрнең берничә лексик мәгънәгә ия булу күренеше киң таралган. Моңа мисал буларак, күпмәгънәлелек һәм омонимия күренешләре карала ала. Мәсәлән, шул ук *өй* сүзенең, «торак» мәгънәсеннән тыш, «хуҗалык», «гаилә тормышы», «нәсел җебе», «ил», «дәүләт», «халык» кебек мәгънәләре дә бар. *Түгәрәк* сүзенең дә, икенчел мәгънәсе буларак, даирә, оешма (*музыка әһелләре түгәрәге, драма түгәрәге*); һәр яктан җитеш (*түгәрәк тормыш*); аерым бер тулылык (*түгәрәк сан, түгәрәк дата, түгәрәк яшь*) очраклары карала.

Омонимик мәгънәдә булган *яр* – елга яры һәм *яр* – сөйгән яр, *яр* – боерык фигыль формасы; *тиен* – җәнлек, *тиен* – акча берәмлеге очракларында да мәгънә – яңгыраш бәйләнеше төрле.

Телнең универсаль күренеше булган синонимиядә исә сөйләмдә бирелү мөмкинлеге һәм эчтәлек арасындагы бәйләнеш үзенчәлекле. Биредә исә яңгырашлары төрле булган сүзләрдә мәгънә төсмерләренең охшашлыгы (*өй, йорт, бина; матур, күркәм, чибәр, ягымлы, бер кашык су белән йотарлык*) яисә тулысынча тәңгәллеге күзәтелә (*су сыеры – гиппопотам – бегемот; библиотека – китапханә; шифаханә – хастаханә – больница*).

Шулай итеп, сүзнең төп, асыл сыйфатлары төрле тип һәм төркемгә караган сүзләрдә төрлечә ачыла. Сүзнең асыл сыйфатларын билгеләүдәге төрлелекнең төп сәбәпләреннән берсе сүзнең аерым торгандагы халәтенә һәм башка сүзләр янәшәсендә тулырак ачылган табигатенә бәйле.

## § 6. Сүзнең функцияләре

Алдагы бүлекчәдә каралган асыл билгеләр сүзнең төп функцияләрен аерганда нигез булып торалар. Шунысын искәртү зарур: татар теленең лексик составындагы сүзләр үзләренең семантик һәм грамматик үзенчәлекләре ягыннан гаять дәрәҗәдә төрле, һәм алар сөйләм барышында төрле функция башкаралар.

С ү з н е ң ф у н к ц и я с е ул – сөйләмдә лексик берәмлекнең кулланылу максаты һәм мөмкинлеге. Тел белемендә сүзнең функциясе өч юнәлештә карала: коммуникатив функция (сүз – аралашу, аңлашу, хәбәр итү чарасы); номинатив функция (сүз – предметны атау чарасы); эстетик функция (сүз – сәнгатьчә сурәтләү чарасы). Сүздә әлеге функцияләр үзара тыгыз бәйләнештә, бер-берсен тулыландырып яшиләр. Семасиология фәнендә төп игътибар сүзнең номинатив функциясенә юнәлдерелә һәм сүзләрнең табигатен ачыклаганда да, ул нигез вазифасын үти.

Сүзнең иң мөһим функциясе булып н о м и н а т и в (лат. *nomination* – атау) функция, ягъни әйләнә-тирә чынбарлыктагы күренеш, билге, процесс һ.б.ны аерып алып атау санала. Сүз ярдәмендә конкрет предметлар (*өстәл, каләм, утын, йорт*), абстракт төшенчәләр (*матурлык, дуслык, бурыч, яшьлек*), матдә (*май, бал, төтен*), табигать күренешләре (*яңгыр, җил, кар, яшен*), предметларның билгеләре (*аксыл, матур, кыска, кадерле*), процесс һәм халәт (*йөгерү, эшләү, уйлау, йоклау*) һәм башкалар атала. Әмма телдәге сүзләрнең табигате ягыннан төрле булуын исәпкә алсак, сүзнең атау, ягъни номинатив функциясе төрле сүзләрдә төрлечә чагылуын күрәбез.

Билгеле булганча, сүз бер үк вакытта һәм лексик, һәм грамматик системаның төп берәмлеге санала. Лексик-грамматик берәмлекләр буларак, сүзләр аерым сүз төркемнәренә берләшәләр һәм, үз чиратында, лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләренә бәйле, мөстәкыйль сүз төркемнәре, ярдәмлек сүз төркемнәре (бәйләгечләр) һәм модаль сүз төркемнәренә аерылып йөртеләләр. Лексик-семантик яктан сүз төркемнәрен аерганда, төп күрсәткеч буларак, аларның гомуми лексик мәгънәләре күрсәтелә. Мөстәкыйль сүзләр лексик-семантик яктан реаль лексик мәгънәгә ия, ягъни алар чынбарлык күренешләрен атыйлар, предмет, күренеш, билге, эш-хәлләрне белдерәләр, яки аларга гомуми рәвештә ишарә итәләр (Хисамова, 2006: 72). Ярдәмлек һәм модаль сүз төркемнәре исә предметларны, билгене һ.б. турыдан-туры атамыйлар, ә чынбарлык күренешләре арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерәләр. Әмма семантик яктан караганда, ярдәмлек һәм модаль сүзләрдән тыш, мөстәкыйль сүзләр рәтендә йөргән лексик берәмлекләрнең дә атау функциясе төрле булуы күренә. Шунлыктан телдә кулланыла торган сүзләрне номинатив

төркемнәргә берләштереп карау киң таралган. Номинатив төркемнәргә сүзләр түбәндәгеләргә нигезләнеп берләшәләр: 1) сүзнең атау һәм чынбарлыкның төрле күренешләрен танып белү мөмкинлеге; 2) сүзнең чынбарлык күренешләренә хас мәгълүматны җиткерү мөмкинлеге; 3) сүзнең теге яки бу сүз төркеменә каравы (Современный русский язык, 2001: 193).

Югарыда саналган үзенчәлекләрнең сүзләрдә тулысынча яки өлешчә табылуга һәм башкарган функцияләренә бәйле биш номинатив төркем аерыла: мөстәкыйль мәгънәле сүзләр, алмашлык сүзләр, ярдәмче сүзләр, модаль сүзләр һәм ымлыклар.

М ө с т ә к ы й л ь  м ә г ъ н ә л е  с ү з л ә р атау, мәгълүмати танып белү функцияләренә, лексик мәгънәгә ия, аларның чынбарлык күренешләре белән бәйләнеше көчле. Бу төркемгә исем, фигыль, сыйфат, сан һәм рәвеш сүз төркемнәре керә. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләр чынбарлык күренешләрен гомумиләштереп атыйлар, мәсәлән, ботаклары ябалдашлы, каты кәүсәле, күпьеллык үсемлекләрнең барысы да гомумиләштереп *агач* сүзе белән атала; ашау яки язу өчен кирәкле, яссы өслеге һәм аяклары булган предметларның барысы да *өстәл* сүзе белән; тәне каурыйлар белән капланып, алгы очлыклары канатка әйләнгән, җирдә ике аяклап йөри торган умырткалылар классына караган җан ияләре *кош* дип атала.

Әгәр мөстәкыйль мәгънәле сүзләрне тулы бер парадигма буларак күзалласак, аның үзәгендә предметлыкны белдергән исем сүз төркеменә караган сүзләр тора, ә периферијасендә исә билге мәгънәсенә мөнәсәбәтле булган фигыль, сыйфат, рәвеш, сан сүз төркемнәренә кергән сүзләр урнашкан. Шул ук тәртиптә барсак, предметлык төшенчәсенә ия булган сүзләрнең табигате дә бертөрле булмавын күрәбез.

Предметлык төшенчәсенең үзәгендә конкретлык төшенчәсенә ия булган сүзләр тора, чөнки бу төр сүзләр чынбарлык белән турыдан-туры бәйләнештә, алар атаган күренешләр, предмет, билге, процессны күреп, тоеп, сизеп була: *икмәк, кәбестә, яңгыр, сары, йоклый, утыра* һ.б. Шулай итеп, әйбер, күренеш һ. б. барлык билгеләре белән тулысынча күз алдына китереп бастыра торган сүзләр к о н к р е т  м ә г ъ н ә л е  с ү з л ә р дип атала.

Абстракт төшенчәләрнең атамалары исә бу парадигманың периферијасендә булырга тиеш, чөнки аларның чынбарлык белән бәйләнеше турыдан-туры түгел, бары конкрет төшенчәләрнең

атамалары аша бара, мәсәлән, *картлык* – өлкән яшькә җиту, чәч агару, биткә җыерчыклар чыгу һ.б. билгеләрнең барлыкка килүе; *матур* – күрер күзгә күркәм, йөз, сын сызыкларының нәфислеге, гармониясе; *сагыш* – кемнедер, нәрсәнедер сагыну, моңаю, шуларга бәйле күңел төшенкелеге, эчке сиземләү белән тоела торган канәгатьсезлек.

Алар конкрет мәгънәле сүзләр белдергән төшенчәләрне гомумиләштерәләр, мәсәлән: *батырлык, даһи, гүзәллек.* Төшенчәнең бер үзенчәлекле сыйфаты буенча гына, күренешләрне гомумиләштереп атый торган сүзләр а б с т р а к т  м ә г ъ н ә л е  с ү з дип атала.

Абстракция ул – объектив чынбарлыктагы предметларның иң әһәмиятле, иң асыл сыйфатларын аерып алу, ә очраклы, әһәмияткә ия булмаган үзенчәлекләрне читләтеп үтү дигән сүз. Конкрет мәгънәле сүзләр беренчел саналалар, алар нигезендә абстракт мәгънәле сүзләр барлыкка килгән.

Мөстәкыйль мәгънәле сүзләр арасында үзенчәлекле урын биләгән, исем сүз төркеменә караган сүзләр шулай ук ике зур төркемгә бүленәләр: күмәклек һәм ялгызлык исемнәр.

Бер төрдән булган предмет, күренеш, процесс, билгене гомумиләштереп атый торган сүзләрне күмәклек сүзләр термины белән атап йөртәләр. К ү м ә к л е к  с ү з л ә р – төшенчә белән логик бәйләнешле, реаль чынбарлыкны төрле яклап гомумиләштереп атый торган тулы семантик структурага ия, сөйләм барышында төрле коннотацияләр алырга сәләтле тел берәмлекләре. Алар татар теле лексик составының зур күпчелеген тәшкил итә, исем сүз төркеменә караган сүзләрдән тыш, башка сүз төркеменә караган берәмлекләрне дә берләштерә. Шуны искәртү зарур: лексик составны күмәклек һәм ялгызлык исемнәргә аеру бары тик исем сүз төркеменә генә хас, башка сүз төркемнәренә караган сүзләр бары тик күмәклек сүзләр буларак кына билгеләнәләр.

Күмәклек сүзләрдән кала, телдә ялгызлык исемнәр дә кулланыла. Я л г ы з л ы к  и с е м н ә р  дип телдә билге (знак) буларак яшәгән, субъект яки объектны төрле яклап характерламыйча, бары тик берсен аерып алып атаган, семантик яктан тулы эчтәлеккә ия булмаган тел берәмлекләрен атыйлар. Аларның күмәклек сүзләрдән өстенлеге булып мәгълүмат чыганагы булу, әйләнә-тирә чынбарлыкны тулырак чагылдыру тора. Бу төр сүзләр предмет, күренешләрне гомумиләштереп атамыйлар, бәлки зур төркемнән

берсен аерып алып атыйлар, мәсәлән: *Казан* барлык төр шәһәрләр арасыннан берсен – Татарстан Республикасының башкаласын атый; *Габдулла Тукай* татар халкының шагыйрьләреннән берсен – иң танылганын атый, *Базарлы Матак* авылларның аерым берсен, Әлки районында урнашканын аерып алып атый, *Чишмәле урамы* Казан шәһәрендәге урамнар арасыннан берсен аерып алып атый һ.б.

Шулай итеп, мөстәкыйль мәгънәле сүзләр номинатив функциягә ия берәмлекләр саналалар. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләрнең тагын бер үзенчәлекле сыйфаты булып танып белү (гносеологик), әйләнә-тирә чынбарлык турында мәгълүмат туплау (кумулятив) функцияләре дә тора. Билгеле булганча, телдә кулланылышта йөри торган сүзләр, халыкның гасырлар буенча тупланган тәҗрибәсе нигезендә, теге яки бу күренешне атыйлар. Шулай ук халыкның милли, дөньяны танып белү һәм аңлау үзенчәлекләре сүзләр ярдәмендә буыннан-буынга тапшырыла. Сүзнең әлеге функцияләре когнитив семасиология фәненең өйрәнү объекты булып тора.

Номинатив төркемнәр арасында икенче урында алмашлык сүзләр тора. Тел белемендә алмашлык сүз төркеменә караган сүзләрне киңрәк планда «алмашлык сүзләр» дигән лексик-семантик төркемгә кертеп карау киң таралган. Сүз төркемнәренә бүленештән аермалы буларак, «алмашлык сүзләр» лексик-семантик төркеме үз эченә сүзләрне алмаштыруга сәләтле лексик мәгънәгә ия булган, төрле сүз төркемнәренә караган сүзләрне берләштерә (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 294–295). «Татар теле грамматикасы»ның II томында (Татар грамматикасы, 2002: 308–310) «фигыль алмашлыклары», «теркәгеч алмашлыклары», «кисәкчә алмашлыклары» төркемчәләре бирелү дә «лексик-семантик төркемчә» төшенчәсен киңәйтеп карауга бәйле булса кирәк.

Алмашлык сүзләр, мөстәкыйль мәгънәле сүзләр кебек үк, грамматик яктан мөстәкыйль сүз төркемнәре составына керә, мөстәкыйль җөмлә кисәге булып килә, телнең төп лексик һәм грамматик фондын тәшкил итә. Академик В.В. Виноградов билгеләвенчә, «сөйләмнең мәгънәви, лексик һәм грамматик нигезен хасил итәләр» (Русский язык, 1972: 102). Әмма семантик яктан алмашлык сүзләр мөстәкыйль мәгънәле сүзләрдән беркадәр аерылып тора. Беренчедән, аларның атау һәм чынбарлыкның төрле

күренешләрен танып белү мөмкинлекләре чикләнгән, икенчедән, алар чынбарлык күренешләре турындагы мәгълүматны җиткермиләр, бары тик контекстта мәгълүмати функция башкарган объект, субъект һ.б.га күрсәтәләр. Мәсәлән, *Ниндидер могҗиза белән бу авылда сакланып калган бердәнбер ала каз безнең солдатларда зур кызыксыну тудырды. Барысы да аны бик тиз күреп алдылар* (Ә. Еники) өзегенең икенче җөмләсендә кулланылган *барысы* алмашлыгы – беренче җөмләдәге *солдатлар* сүзенә, *аны* алмашлыгы *ала каз* сүзенә күрсәтә. *Солдатлар* (кем булулары) һәм *ала каз* (төсе, йорт кошы) сүзләре үз чиратында субъектлар турында мәгълүматны хәбәр итә.

Алмашлык сүзләр контекстта номинатив функциягә ия мөстәкыйль мәгънәле сүзне алыштырып килеп кенә тулы лексик мәгънәгә ия булалар, шунлыктан аларны мәгънә ягыннан тулы хокуклы дип атап булмый, мәсәлән, *бу, бөтен, син, анда, монда, нәрсә, кем, ничә* һ.б. Контекстта алмашлык сүзләр д е й к т и к ф у н к ц и я (грек. *deixis* – күрсәтү) башкаралар, аларны дейктик сүзләр дип тә атыйлар.

Алмашлык сүзләр, югарыда искәртелгәнчә, контекстта сөйләмдә катнашучы субъектка/субъектларга күрсәтү функциясен башкаралар. Бу очракта еш кына зат һәм күрсәтү алмашлыклары кулланыла: *Әнә агарган сакаллы, көмеш чәчле, олылыклы, зур доктор... **Ул** нинди рәхимле, нинди түбәнчелекле...* (Г. Ибраһимов); ***Менә бу*** *ике агай ничаклы чит сүзне үз сүзләре кеби иттереп, сүзләре арасына катыштырып җибәрәләр.* (М. Гафури)

Сөйләм объектына күрсәтү функциясен башкаралар: *Күлнең бу ягында озын, күп җире кеше керә алмаслык булган күллек һәм баткаклыклы бер камышлык бар. Халык **моның** хакында әллә нинди ят, куркынычлы әкиятләр сөйлиләр. Шуңа күрә бу камышлык мине шикләндерә. **Аңа** якын килү түгел, хәтта исемен ишетү дә күңелгә бер каушау бирә башлый иде.* (Г. Ибраһимов)

Сөйләм объектының урынына яки вакытына күрсәтү функциясен башкару очраклары да киң таралган: *Алар ярты чакрым чамасы җирне ачык болын уртасыннан бардылар да ярым караңгы әрәмә арасына килеп керделәр. Юл **монда** тигез иде, шулай да арба әледән-әле як-якка чайкалды.* (Н. Фәттах)

Эчтәлекне гомумиләштереп күрсәтү функциясе дә аларга хас функцияләрдән санала: *Башын кинәт өскә чөеп, чәчләрен вакыт-*

*вакыт артка җибәрүләре, чигүле чүәкләренең сукмак үләннәрен ертып «йөзеп» барулары, билен бераз гына боргалап, килешле итеп атлаулары –* ***барысы да*** *синеке!* (Ф. Яруллин)

Мөстәкыйль мәгънәле һәм алмашлык сүзләрдән аермалы буларак, ярдәмче сүзләргә атау һәм мәгълүмати функцияләр лексик мәгънә хас түгел, алар сүзләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне белдерәләр. «Татар грамматикасы»нда әлеге төр сүзләр «бәйләгечләр» термины белән бирелгән һәм бу төркемгә бәйлек, бәйлек сүзләр һәм теркәгечләрне кертәләр. Алар, чынбарлык белән мөстәкыйль мәгънәле сүзләр аша бәйләнеп, бергәлек, корал, чагыштыру, сәбәп, максат, вакыт, урын һәм башка мөнәсәбәтләрне оештырып, грамматик мәгънә аңлаталар: *укытучы белән* (сөйләшү); *карандаш белән* (язу); *таң кебек* (нурлы); *тау чаклы* (зур), *әни һәм мин; я эссе, я салкын* һ.б. Ярдәмче сүзләр, мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән килеп, бер җөмлә кисәге була алалар (бәйлек һәм бәйлек сүзләр) яисә, җөмлә кисәге составына кермичә, җөмләләрне бәйлиләр (теркәгеч). Бу төр сүзләрне ярдәмче функция башкарган сүзләр дип атыйлар.

Модаль сүзләр шулай ук атау һәм мәгълүмати функцияләргә ия түгел, әмма, ярдәмче сүзләрдән аермалы буларак, алар лексик бөтенлеккә ия. Бу төр сүзләр модальлек белдерәләр һәм сөйләмнең субъектив-стилистик нигезен хасил итәләр. Модальлек ул – сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен (реальлеген, мөмкинлеген, кирәклеген, тиешлеген, ихтималлыгын, ниятен һ.б.) сөйләүче аша белдерү. Сөйләм модальлеген белдерүдә катнашкан лексик чара буларак, модаль сүзләр аерыла.

Мәгънә төсмерләре һәм синтаксик функцияләре буенча модаль сүзләрне Д.Г.Тумашева ике төркемгә бүлеп карый: 1) сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен объектив рәвештә белдерә торган модаль сүзләр (*бар, юк, кирәк, тиеш, мөмкин, ярый*); 2) сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүченең субъектив бәяләве аркылы белдерә торган модаль сүзләр (*әлбәттә, дөрес, чыннан да, билгеле, ахры, имеш, бәлки, бугай, шаять, ичмасам* һ.б.) (Тумашева, 1978: 297).

Сөйләмдә модальлекне белдерүдә, модаль сүзләрдән тыш, кисәкчәләр дә катнаша, мәсәлән: ***тик*** *сине* ***генә*** *сагынам* (чикләү мәгънәсе); *үлсәм* ***дә*** *үкенмим* (көчәйтү мәгънәсе); ***әллә*** *бар,* ***әллә*** *юк* (билгесезлек мәгънәсе); *әйттем* ***бит****, күргәнсең* ***ич****, килде* ***лә-***

***баса*** (раслау мәгънәсе) һ.б. Грамматикада кисәкчәләрне, сүзләргә һәм җөмләләргә модаль-экспрессив мәгънә төсмерләре өсти торган үзенчәлеген исәпкә алып, модаль сүз төркемнәре рәтенә кертәләр (Татар грамматикасы, 2002: 12).

Шулай итеп, сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүдә катнашкан сүзләрне модаль функция башкара торган сүзләр дип атыйлар һәм бу төркемдә төп урынны модаль сүзләр били.

Номинатив төркемнәр арасында кешеләрнең хис-тойгыларын, эмоцияләрен, ихтыярын белдерә торган сүзләр – ымлыклар аерым урын тота. Аларны эмотив функция башкара торган сүзләр дип атап йөртәләр. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләрдән аермалы буларак, алар хис-тойгыларны атамыйча күрсәтәләр генә: *Әллә, **Ходаем** (шомлану), имтихан башланган да инде?!* (Ф. Шәфигуллин); *–* ***Фу, фу*** (ирония)*, – диде әтисе, – сез әллә мин кайтуга бизәнеп тордыгызмы? Одеколонга манчылгансыз.* (М. Әмир); ***Аһ, гөнаһым шомлыгы*** (шелтәләү)*, бу кучеры бик тын тагын, Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын.* (Г. Тукай); *Юк, нишләп уйныйм ди, Аллам сакласын!* (курку) (Ә. Еники); ***Һай*** (гаҗәпләнү) *бу гомер!.. Көтеп-көтеп, туган кадәр дә юк!* (Р. Фәйзуллин)

Ымлыклар аңның эмоциональ катламы белән бәйле һәм чынбарлыктагы күренешләргә төрле мөнәсәбәт белдерәләр. Шунлыктан ымлыкларны модаль сүзләр рәтенә кертеп карау да очрый. Бу аеруча ымлыклар кереш сүз ролендә килгән очракта күзәтелә: ***Йә,*** *шулкадәр михнәтләр белән тәрбияләп үстергән бердәнбер баламны мин шуларга бирергә тиешме?* (Г. Исхакый); ***Эх,*** *булган бит заманалар!* (Р. Ишморат)

Шулай итеп, үзләренең семантик табигатьләренә бәйле рәвештә телдә кулланылган сүзләр төрле функция башкаралар. Сүзләрне номинатив төркемнәргә бу рәвешле аеру гадәти классификация генә түгел, ә иерархик система тәшкил итә. Бу системаның үзәгендә мөстәкыйль мәгънәле сүзләр тора, ә башка сүз төркемнәре бу системаның периферијасенә керәләр, үз чиратында аларны якын (алмашлык сүзләр) һәм ерак (ярдәмче сүзләр, модаль сүзләр һәм ымлыклар) периферияләргә аеру кирәк.

## § 7. Сүзләрнең тәңгәллеге һәм аерымлыгы

Сүз телнең универсаль, шул ук вакытта гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм бәхәсле берәмлекләреннән санала. Сүзнең табигатенә хас төп үзенчәлекләрне билгеләгәндә, аның аерым торгандагы һәм сөйләм барышында ачыла торган үзенчәлекләрен игътибар үзәгендә тоту мөһим. Моның өчен тел һәм сөйләм төшенчәләренә аерым тукталып, аларның чикләрен ачыкларга һәм сүзнең һәр икесендә ни рәвешле ачылуын аңлау зарур.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә күрсәтелгәнчә, тел ул – кешеләргә үзара аңлашу, фикерләү һәм уй-фикер казанышларын беркетү өчен хезмәт итә торган һәм, гадәттә, һәр халыкта үзгә, үзенчә була торган сүзләр һәм грамматик чаралар системасы. Шул системаның аерым төркем, профессияләр өчен характерлы булган варианты (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 528, 498). «Сөйләм» терминына исә түбәндәгечә аңлатма бирелә: *сөйләм* 1) аралашу, аңлашу чарасы буларак тел; 2) аерым затның фикерләрен, уйларын белдерү өчен әйткән сүзләре, җөмләләр җыелмасы; 3) телдән файдалану алымы, формасы; тел стиле. Сөйләм барышында тел чынбарлыкка, сөйләм ситуациясенә, вакытына һәм аралашучыларның социаль, интеллектуаль, психик халәтенә бәйле ачыла. Әгәр тел гомуми, объектив, абстракт, формаль, вакыт һәм пространствога бәйсез, үзгәрешсез саналса, сөйләм исә конкрет, субъектив, актуаль, хәрәкәтчән һәм һәрбер сөйләм аралыгы өчен генә кабатланмас санала. Сөйләм агышында тел берәмлекләре, шул исәптән сүзләр берләшәләр, тел исә аларның аерымлыгын саклауга омтыла. Тел иҗтимагый күренеш саналса, сөйләм исә аерым индивидның иҗади эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, алгы планга чыга.

Тел белемендә тел һәм сөйләм төшенчәсенә беренчеләрдән булып швейцар галиме Фердинанд де Соссюр игътибар итә һәм аларга хас төп билгеләрне күрсәтә: «Сөйләм эшчәнлеген өйрәнү ике өлешкә бүленә; беренчесенең предметы – тел, ягъни иҗтимагый һәм индивидка бәйсез; икенчесенең предметы – сөйләм эшчәнлегенең индивидуаль ягы, ягъни фонацияне дә үз эченә алган сөйләм» (Соссюр, 1972: 57). Гомуми тел белемендә Ф. де Соссюр концепциясе, кискен аерып куюга бәйле тәнкыйтьләнүгә карамастан, тел һәм сөйләм арасындагы уртак һәм аермалы якларны билгеләгәндә, нигез буларак хезмәт итә. Алда сөйләмгә бирелгән билгеләмәдә дә бу ачык чагыла.

Татар тел белемендә сөйләмне өйрәнгән күренекле галим Ф.С. Сафиуллина «тел» һәм «сөйләм» төшенчәләренә түбәндәге аңлатманы бирә: «тел кеше аңында даими яши торган системаларның җыелмасы булса, сөйләм тел формаларын вакыт эзлеклелегенә реализацияли. Тел без ишетеп һәм күреп кабул иткән сөйләм агышындагы структур элементлар нигезендә барлыкка килгән абстракция булса, сөйләм телгә бәйле була, чөнки сөйләмдәге күренешләр тел системасына бәйле булалар, һәм сөйләүче үз фикерләрен нәкъ менә шул системага нигезләнеп әйтә» (Сафиуллина, 1993: 4).

Шулай итеп, аерым контексттан тыш кулланылган тел чараларын без тел дип, ә инде билгеле бер контекст эчендә шул ук чараларның кулланылуын сөйләм дип атыйбыз. Тел чаралары халык тарафыннан кабул ителгән, татар теленең кагыйдәләренә нигезләнеп барлыкка килгән сөйләм барышында реальләшәләр.

Сүзләрнең тел берәмлеге буларак бирелеше (статик – субстанциональ халәте (Бәширова, 2010: 55)), аларның татар телендә калыплашкан мәгънәләре сүзлекләрдә урын ала, мәсәлән: **чыбык** *и.* 1) Агачның нечкә ботагы. *Тал чыбыгы. Чыбыктан үргән кәрзин. Чыбыктан үргән тарантас. Агач чыбык чакта бөгелә.* Мәкаль. 2) Металлдан эшләнгән сыгылмалы бау яки җеп. *Бакыр ч. Алюмин ч. Телеграф чыбыклары.*◊ **Чыбык очы** ерак кардәшлек, ерак туганлык турында (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 661).

Конкрет грамматик формалар һәм мәгънәви вариантлар берлегенә ия булган һәм сүзлек составының төп берәмлеге саналган сүзне л е к с е м а (грек. *lexis* – сүз) дип атыйлар. Сүз, лексема буларак, сүзлекләрдә урын ала һәм аңлатыла. Лексема – телнең абстракт берәмлеге, ул сүзнең конкрет бер сөйләм агышында кулланылуын күзалламый, бәлки аның телдә гомумән кулланыла алу мөмкинлеген, формаларын берләштерә. Мәсәлән, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *башлау* сүзенең номинатив һәм күчерелмә мәгънәләреннән тыш, ярдәмче фигыль функциясендә, башка сүз төркемнәренә кучү мөмкинлеге һәм бәйле мәгънәдә кулланылышы да теркәлгән: **башлау** ф. **1.** 1) берәр төрле шөгыльгә тотыну, керешү. *Сүз б. Эш б.*; 2) нәрсәнедер ачып, кулланырга тотыну. *Яңа тартма чәй б.*; 3) сир. җитәкләп бару, юнәлеш бирү. *Тугры юлга б.* **2. башлап** бәйл. мәгъ. Берәр нәрсә тәмамлангач, узгач, шуның артыннан. *Беренче көннән үк башлап.* **3. башлап** рәв. мәгъ. Иң алдан, иң элек, беренчеләрдән булып. *Б. чыгыш ясау.* **4.** Ярд. ф. функ.

Тезмә фигыльләрдә килеп, теге яки бу эшнең башлануын белдерә. *Укый б. Китә б. Башлый тору. Башлап алу. Башлап ату. Башлап бару. Башлап бирү. Башлап кую.* ◊ *Башлап алып китү* Эшкә керешеп китү, эшкә тотыну. *Башлап йөрүче* Әйдәп баручы, җитәкчелек итүче; инициатива күрсәтүче.

Мисалдан күренгәнчә, сүзлектә «башлау» лексемасының татар телендә калыплашкан, кулланылырга мөмкин булган мәгънәви, грамматик һәм кулланылыш вариантлары бирелә.

Сөйләм агышында сүзләр, гомум кабул ителгән, сүзлекләрдә теркәлгән мәгънәви һәм структур формадан тыш, телдә кабул ителмәгән, яисә таралыш тапмаган эчке яки тышкы формада кулланылырга да мөмкиннәр. Моңа мисал буларак, аерым авторларга хас индивидуаль метафораларны, неологизмнарны китерергә мөмкин. Мәсәлән, *Мин Марстан, тик марсиан түгел, мин **Җирский**, гади бер бала.* (Р. Гаташ); *...Без – **Җирдәш** шул. Кеше булып яшәргә килгән җаннар.* (Р. Фәйзуллин); *Сагынуларның-сагышларның **яшеле дә, алсуы да...** Һәммәсе дә җанымда!* (Р. Фәйзуллин); *Күк биеклегендә йөргән яфрак – Күк иде лә аның мөнбәре. Ята әнә **сүнгән яшел йолдыз**. Яфрак – хәзер җирнең мендәре.* (Б. Рәхимова). Бу төр сүзләрнең күпчелеге, тел яссылыгына күчмичә, бары тик сөйләм үзенчәлеге буларак кына сакланып калалар, әмма кайбер яңа сүзләрнең тел күренеше булып китүе дә билгеле. Моңа мисал итеп татар теленә XX гасыр ахырында сөйләм аша килеп кергән *әйдаман, санак, илбаш* кебек сүзләрне китерергә мөмкин. Телдә кулланылышка кергән яңа төр сүзләр башта сөйләмгә килеп керәләр, соңрак исә берегеп, калыплашып, мөмкин булган грамматик формалар алып, телдә берегәләр.

Тел берәмлеге буларак, сүзнең аерым торгандагы үзенчәлеге шуннан гыйбарәт, әмма сөйләмгә килеп кергән һәр сүз, башка сүзләр белән бәйләнешкә кереп, төрле фонетик, грамматик, билгеле бер дәрәҗәдә семантик үзгәрешләргә дучар була. Лингвистлар арасында сүзнең аерым торгандагы халәтеннән бигрәк, сөйләм процессында үзенең индивидуальлеген саклау-сакламау мәсьәләсе бәхәс тудыра. Татар тел белемендә моңарчы әлеге проблема күтәрелмәсә дә, гомуми тел белемендә, рус тел гыйлемендә әлеге мәсьәләгә шактый күптән игътибар итәләр. Аерым алганда, XX гасыр уртасында А.И. Смирницкий, О.С. Ахманова һәм В.В. Виноградов хезмәтләрендә әлеге мәсьәлә күтәрелеп, хәзерге рус лексикология-

сенә багышланган хезмәтләрнең һәркайсында диярлек сүзнең сөйләм процессында реальләшкән очраклары бер үз лексеманың вариантларымы яисә төрле сүзләрме дигән мәсьәләгә җавап эзләнә. Бу очракта сүзләрнең т ә ң г ә л л е г е һәм а е р ы м л ы г ы проблемасы алгы планга чыга. Сүзнең аерым торгандагы, ягъни статик халәттә мәгънәви бөтенлеге, грамматик төрләнеш парадигмасы билгеле бер дәрәҗәдә ачык, аңлаешлы булса, сөйләм процессында бер үк сүзнең төрле лексик-семантик вариантларда, грамматик формаларда килүе, сөйләм агышында башка сүзләр белән керешеп, морфонологик үзгәрешләргә дучар булуы аркасында, сүзнең бөтенлеге, ягъни тел берәмлеге буларак статик халәттәге үзенчәлекләре сакланамы соң?

Сүзнең сөйләмдәге төп вазифасы – аралашу. Аралашуның төренә һәм максатына карап, сөйләм эчендә сүзләрнең эчке табигате (мәгънәсе) һәм тышкы формасы беркадәр үзгәреш кичерә, сүзгә хас асыл сыйфатларның кайберләре югалырга да мөмкин. Аерым алганда, сүзнең эчтәлегенә бәйле төрле төсмерләр (*алтын балдак, алтын кеше, алтын күз, алтын вакыт* һ.б.), сүзнең тышкы формасында позицион үзгәрешләр (*кара алтын* [*қа°рāлтын*]; *кара әле* [*қарәлә*]) барлыкка килергә мөмкин. Татар телендә эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерү өчен, кайбер фигыльләрнең, ярдәмче функция башкарып, төп фигыльнең лексик мәгънәсенә өстәмә төсмерләр өстәве дә киң таралган, мәсәлән: *укый башлау, укып бетерү, укып яту, укып чыгу* һ.б. Соңгы мисалларда *укый* мөстәкыйль фигыленең эчке бөтенлеге саклануын, бары тик мәгънәви төсмере үзгәрүен күрсәк, ярдәмче фигыль функциясен башкарган *башлау, бетерү, яту, чыгу* фигыльләре исә, үзләренең кайбер асыл, төп үзенчәлекләрен югалтып, ярдәмче функция башкаруга күчүләре күзәтелә. Әмма бу үзгәрешләр, гомумән алганда, сүзнең мәгънәви һәм тышкы бөтенлегенә зыян китерми, ягъни сүз үзенең мөстәкыйльлеген саклый. Бу очракта сүз беренче чиратта сүзнең вариантлары турында барырга тиеш.

С ү з н е ң в а р и а н т л а р ы дип бер үк сүзнең, тәңгәллегенә, мәгънәви бөтенлегенә зыян китермичә, төрле фонетик, грамматик формаларда килүен атыйлар.

Тел белемендә и н в а р и а н т (сүзнең гомумән кулланыла алу мөмкинлеген күзаллаган телнең абстракт берәмлеге) һәм в а р и а н т (тел берәмлегенең сөйләмдә конкрет кулланылышы) сүзләре

капма-каршы куелып өйрәнелә һәм аның нигезе тел – сөйләм арасындагы аермага барып тоташа. Семасиологиядә «инвариант» төшенчәсе «лексема» төшенчәсе белән тәңгәл санала.

Гадәттә, сүздә фонетик, грамматик һәм лексик-семантик вариантлар аерыла. Сүзнең *фонетик вариантлары* дип аның эчке табигате (мәгънәсе) сакланган хәлдә, тышкы формасы үзгәреш кичерүне атыйлар (*акрын – әкрен, ата – әти, ана – әни*). Фонетика фәнендә алар сингармоник парлар буларак өйрәнелә.

Сүзнең грамматик вариантлары дигәндә, беренче чиратта сүзформаны күздә тоталар. Сүзформа – сүзнең, аерым бер грамматик формада үзенең эчтәлеген, мәгънәви бөтенлеген саклаган хәлдә, теге яки бу контекстта кулланылышы. Сүзнең (лексеманың) барлык сүзформалар җыелмасы әлеге сүзнең парадигмасын хасил итә, мәсәлән: *бала – балалар; баланың, балага, баланы, баладан, балада, балам, балаң, баласы, балаларыбыз, балаларыгыз, балалары* һ.б. Контекстта грамматик вариант, ягъни сүзформа кулланылганда, сүзнең эчке табигатенә зыян килми, ә грамматик формаларның вариантлашуы гына күзәтелә.

Татар телендә сүзформа барлыкка китерүдә мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар һәм ярдәмлек сүзләр актив роль уйный. «Татар грамматикасы»нда билгеләнгәнчә, татар телендә «кушымчалар, сүзләргә ялганып, синтетик формалар, икенче төрле әйткәндә, сүзформаның синтетик төрен барлыкка китерәләр: *авылга, әтинеке, кайттым* һ.б. Ярдәмлек сүзләр, сүзләр янында килеп, аналитик формалар, икенче төрле әйткәндә, сүзформаның аналитик төрен барлыкка китерәләр: *авылга таба, синең өчен, әти булып әйтү, кеше булып сөйләшү* һ.б.» (Татар грамматикасы, 2002: 24). Сүзнең грамматик вариантлары, сүзтезмә, җөмлә кысаларында реальләшеп, беренче чиратта грамматик мәгънә белдерү өчен кулланылалар.

Сүзнең лексик-семантик вариантлары ул – тышкы формасы тәңгәллеген саклаган хәлдә, сүзнең эчтәлегендә беркадәр үзгәреш барлыкка килү. Сүзнең лексик-семантик варианты дип лексик-семантик системаның сөйләмдә реаль кулланылышта йөри торган иң кечкенә икеяклы берәмлеген атыйлар (Общее языкознание, 1972: 418).

Сүзнең семантик вариантлашуы бер лексема кысасында барлыкка килә, сүзнең вариантлары, мәгънәви яктан бер-берсенә

бәйле булып, бер сүз эчендә булган семантик парадигманы барлыкка китерәләр. Бер сүзнең номинатив мәгънәсе һәм денотат белән бәйләнешле булган өстәмә мәгънәләре аерым бер контекст кысаларында гына реальләшә. Мәсәлән, *нигез* лексемасының лексик-семантик вариантлары *ата-баба нигезе, фәнни нигез, сүз нигезе, әсәр нигезе, дәүләт нигезе, пирамида нигезе* һ.б. контекстларда төп мәгънәнең әһәмиятле үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, семантик яктан беркадәр үзгәреш кичергәннәр.

Сүзнең лексик-семантик вариантлылыгы[1] тел белемендә күпмәгънәлелек (полисемия) күренешенә бәйле аңлатыла. Рус тел белемендә лексик-семантик вариантлылык мәсьәләсе В.В. Виноградов, А.И. Смирницкий, О.С. Ахманова, Д.Н. Шмелёв, Р.А. Будагов, Ю.Д. Апресян, Н.М. Шанский, А.А. Уфимцева, Л.А. Новиков хезмәтләрендә киң яктыртыла. Татар тел белемендә исә монографик планда И.Б. Бәширова, Д.М. Гаптелганиева, Ә.К. Булатовалар тарафыннан өйрәнелгән. Югарыда аталган галимнәр сүзнең лексик-семантик вариантлылыгы аның тәңгәллегенә зыян китермәвен күрсәтәләр. Алда әйтелгәнчә, конкрет сөйләм, контекст кысаларында сүзнең бары тик бер генә варианты реальләшсә, барлык вариантларның җыелмасы лексеманы хасил итә.

Шулай итеп, сүзнең тәңгәллеге аның тышкы формасына да, эчке табигатенә дә кагылырга мөмкин. Сүзнең төрле вариантларда кулланылышы аның тәңгәллегенә зыян китерми, ягъни сүз мөстәкыйль, бер үк берәмлек буларак күзаллана. Сүзнең эчке бәйләнеше һәм бөтенлеге тышкы форманың беркадәр үзгәреш кичереп, эчке табигатендә үзгәреш булмаганда яисә, киресенчә, эчке табигате беркадәр үзгәреп, тышкы формасы үзгәрешсез калганда, сүзнең тәңгәллеге саклана.

Сүзнең тәңгәллеге турында сүз алып барганда, тышкы формалары тулысынча тәңгәл килгән сүзләр – омонимнар турында әйтеп үтү зарур. «Мондый төр сүзләр бер үк сүзнең вариантларымы, әллә икесе (өчесе һәм аннан да артык булырга мөмкин) ике сүзме?» дигән сорау туа. Мисал өчен, *яр* сүзен алыйк. Сүзлектә аның өч мөстәкыйль мәгънәсе күрсәтелгән: Яр I. *ис.*

---

[1] Кара: Тулырак мәгълүмат «Татар телендә күпмәгънәлелек күренеше» бүлегендә; Бәширова И.Б. Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010. 32–67, 104–174 б.

Сулыкларның коры җир белән чикләнгән һәм күтәрелеп торган чите. ***Яр*** *өстендә басып тору.* Яр II. *ис.* Яраткан, сөйгән кеше. *Син минем гомерлек ярым.* Яр III: яр салу, хәбәр салу, кычкырып белдерү. *Керү белән яр салды* (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 78). Моннан кала сөйләмдә *яру* фигыленең аерым грамматик формада *яр* сүзе белән омонимлашып килүе очрый, мәсәлән: *син утын яр.*

Татар поэзиясендә мондый төр сүзләрне аерым бер стилистик максатларда янәшә кулланып, поэтика тудыру да киң таралган: *Кара әле, кара: Каен яфрак* ***яра (1).*** *Каюм утын* ***яра (2),*** *Кулларында –* ***яра (3).*** *Бабай, шаулап кара, Чыбык белән* ***яра (4).*** *Менә әйбәт чара – Шәрәф шәрран* ***яра (5).*** (Р. Миңнуллин) Әлеге мисалда *яра* сүзе биш тапкыр кабатлана. Бу бер үк сүзнең вариантларымы, ягъни тәңгәллек сакланамы, яисә биредә берничә мөстәкыйль сүз кулланылганмы икәнен карыйк. Биредә 1, 2, 3, 4 нче очракларда *яр* фигыленең лексик-семантик вариантлары кулланыла, чөнки һәрберсендә номинатив мәгънәгә хас ‘кисү, уртага аеру’ семасының саклануы сизелә. Дүртенче, сөйләм теленә хас күчерелмә мәгънәдә кулланылган *чыбык белән* ***яра*** очрагында да, беренчел мәгънәдән шактый ераклашуга карамастан, бәйләнеш өзелмәгән. *Шәрәф шәрран* ***яра (5)*** очрагында исә *яра* сүзе идиоматик, тотрыклы әйтелмә составында *шәрран* сүзе белән бергә «кычкыру» мәгънәсен бирә. Бу очракта без алдагы очраклар белән тәңгәл булмаган мөстәкыйль аерым сүз (лексема) кулланылган дип әйтә алабыз.

Алдагы сорау ясалма сүзләргә бәйле дә туарга мөмкин. Билгеле булганча, ясагыч нигез (мотивлаштыручы сүз) белән ясалма сүз (мотивлашкан сүз) арасында семантик бәйләнеш яши, мисал өчен, *эш → эшче; төй → төйгеч; аш → аша* һ.б. Шуңа карамастан әлеге сүзләр тышкы (сүз ясагыч кушымча ялгана) һәм эчке яктан (сүзнең лексик мәгънәсе үзгәрә) үзгәреш кичерәләр (*эш* – предмет, *эшче* – субъект; *төй* – процесс, *төйгеч* – предмет, корал; *аш* – предмет, *аша* – процесс), нәтиҗәдә мотивлаштыручы сүздән үзгә яңа мөстәкыйль сүз барлыкка килә.

Йомгак ясап әйткәндә, тел берәмлеге буларак, сүз сөйләм процессында төрле үзгәрешләр кичерә. Әгәр бу үзгәрешләр сүзнең эчке һәм тышкы табигатенә хас төп үзенчәлекләр, сыйфатлар белән бәйләнешен сакласа, сүз тәңгәллеген саклый, ә инде бу бәйләнеш юкка чыкса, төрле мөстәкыйль сүзләр кулланыла.

## Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның эчтәлеге

### § 8. Сүз мәгънәсе турында гомуми мәгълүмат. Сүзнең лексик, грамматик һәм сүз ясалыш мәгънәләре

Тел белемендә сүзнең мәгънәви ягын семасиология өйрәнә һәм әлеге фән «сүз мәгънәсе» төшенчәсенә билгеләмә бирүне, аның төрле якларын өйрәнүне максат итеп куя. Сүзнең катлаулы һәм күпьяклы табигате аның мәгънәсен аңлатканда да кыенлыклар тудыра, аерым алганда, гомуми тел белемендә, шул исәптән татар тел белемендә дә, сүз мәгънәсен аңлатуда хәзергәчә төрлелек һәм күп аспектлылык күзгә ташлана. Сүзнең кайсы ягын өйрәнүгә басым ясауга карап, тел белемендә, философия фәнендә сүз мәгънәсен аңлатуга бәйле күпләгән билгеләмә очрый. Аерым алганда, гомуми тел белемендә сүз мәгънәсен функциональ, концептуаль, саф лингвистик (семасиологик) юнәлешләрдә аңлату бар.

Сүз мәгънәсенә функциональ юнәлештә билгеләмә бирү Л. Витгенштейнга барып тоташа. Аның фикеренчә, «знак үзе чагылдыра алмаганны аның кулланылышы чагылдыра, знакларда яшеренгән мәгънә аларның кулланылышында ачыла» (Витгенштейн, 1959: 39). Бу фикере «Философские исследования» хезмәтендә тагын да үстерелеп, сүз мәгънәсе предмет белән бәйләнештә түгел, бәлки сүзнең кулланылышында чагыла, дигән нәтиҗәгә китерелә. Шул рәвешле сүз, гомумән алганда тел, корал буларак күзаллана, гносеологик аспектта тел берәмлекләрен өйрәнүдән читләшә. Рус тел белемендә сүз мәгънәсен кулланылышка бәйле аңлату В.А. Звегинцевта да очрый: ул лингвистик планда сүз мәгънәсен сүзнең сөйләмдә кулланылышы белән тиңли (Звегинцев, 1957: 123).

Сүз мәгънәсен концептуаль (когнитив) аспектта өйрәнүчеләр мәгънәне концептның (коллектив аңында теге яки бу тел формасында предметлаштырылган күпкырлы, мәдәни яктан әһәмиятле социопсихик төзелмә) бер өлеше буларак карыйлар. Бу юнәлеш кысаларында сүз мәгънәсе нинди дә булса матди тышча кысаларындагы предмет, күренеш, процесс һ.б. шул телдә сөйләшүчеләрнең аңында чагылышы буларак күзаллана. Теге яки бу күренешне атау процессында аерым бер милләт вәкиленең дөньяны кабул итү үзенчәлекләре зур роль уйный. Аерым бер тел системасына караган тел берәмлекләре мәгънәсенең үзенчәлекле кушылуыннан

семантик картина барлыкка килә. Лексик берәмлекләрнең семантик асылы халыкның тарихи һәм мәдәни үткәне нигезендә барлыкка килгән дөньяны кабул итү үзенчәлекләре нәтиҗәсендә формалаша. Концептуаль юнәлеш вәкилләре концептны кешенең когнитив аңы продукты, ә мәгънәне тел аңы, ягъни сөйләмне булдыруда катнаша торган бер компонент буларак билгелиләр. Гомуми тел белемендә бу юнәлеш В.Гумбольдт, Э.Сепир, Б.Л. Уорф һ.б.; рус тел белемендә тел фәлсәфәсе буенча танылган хезмәтләр авторлары К.С. Аксаков, Н.П. Некрасов, Ф.Ф. Фортунатов, А.А. Шахматов, А.А. Потебня, В.Н. Телия, Ю.С. Степанов, А.Д. Арутюнова, Н.И. Толстой, В.А. Маслова, Е.С. Кубрякова һ.б.; татар тел белемендә Р.Р. Җамалетдинов, Г.Р. Галиуллина һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба.

Сүз мәгънәсен саф лингвистик, төгәлрәк әйтсәк, семасиологик аспектта өйрәнү барышында да «сүз мәгънәсе» төшенчәсен төрлечә аңлату очрый, мәсәлән, мәгънә – чынбарлык предметының аңда чагылышы (О.С. Ахманова); мәгънә ул – мөнәсәбәт (Л.С. Бархударов); сүзнең мәгънәсе – аның лексик-семантик вариантлары җыелмасы (В.А. Звегинцев) һ.б. Сүз мәгънәсенә аңлатма бирүдәге төрлелек сүздә берничә мәгънә бердәйлеге яшәү белән аңлатыла.

«Сүз мәгънәсе» төшенчәсенә аңлатма биргәндә, төп нигез буларак, лексик мәгънә күзаллана. Әмма төп мәгънә саналган лексик мәгънәдән тыш, сүздә грамматик һәм сүз ясалыш мәгънәләре дә аерыла. Шунлыктан «мәгънә» терминын тел берәмлекләренең эчтәлеген, эчке формасын аңлатканда кулланалар, һәм ул тел берәмлекләренең тышкы формасына, ягъни сөйләмдә бирелү үзенчәлегенә каршы куелып карала.

Шулай итеп, семасиология фәне мәгънәгә ия булган лексик һәм грамматик тел берәмлекләренең эчке табигатен өйрәнә. Телнең төп мәгънәви берәмлекләре булган сүз, морфема һәм синтаксеманың үз мәгънәләре бар, шул ук вакытта аларның табигате бары сүз кысаларында гына ачыла ала. Шул сәбәпле семасиология фәнендә күбрәк лексик мәгънә өйрәнелсә, морфология һәм синтаксис грамматик мәгънәгә төп игътибарны юнәлтә, ә сүз ясалышы бүлегенең өйрәнү объекты буларак, сүз ясалыш мәгънәсе аерыла.

С ү з н е ң л е к с и к м ә г ъ н ә с е ул – сүзнең эчтәлеге, эчке табигате, сүздә чынбарлыкның теге яки бу күренеше (предмет (*өстәл, кашык, тәрәзә*), билге (*ак, кара, сыек*), эш-хәл (*бару, уку, карау*), мөнәсәбәт (*ярату, ачулану* һ.б.) чагылышы.

Сүзнең грамматик мәгънәсе дип бер төркем сүз һәм сүзформаларга, синтаксик конструкцияләргә хас булган гомумиләштергән, абстракт мәгънәне атыйлар (Языкознание. Большой энциклопедический словарь, 2000: 116). Грамматик мәгънә сүзне аерым бер грамматик төркем элементы (мәсәлән, *бала* исем сүз төркеменә карый, предметлыкны белдерә), формалар рәте элементы (*бала – бала-ның, бала-га, бала-ны; бала – бала-лар* һ.б.), сүзтезмә яки җөмлә элементы буларак (*баланың тубы, бала елый*) тасвирлый.

Сүзнең лексик мәгънәсе индивидуаль, бер сүзне башкалардан аера, чикли, ә грамматик мәгънә исә категориаль, ул гомумиләштерә, аерым зур төркем сүзләр өчен хас. Чагыштыру өчен *тәрәзә, каләм, чынаяк* сүзләрен алыйк. Әлеге сүзләр исем сүз төркеменә карыйлар, баш килештә, берлек санда, предметлыкны (категориаль мәгънәне[1]) белдерә торган төркем элементлары, әмма һәр өчесенең үзләренә генә хас лексик мәгънәләре бар һәм бу мәгънәләр кабатланмас, индивидуаль саналалар. Мисал өчен, *тәрәзә*[2] – эчендә кеше яши, эшли яисә кереп йөри торган корылмаларның диварында яктылык керсен өчен пыяла куелган ачыклык, уем; *каләм* – язу, сызу, буяу өчен кулланыла торган корал; *чынаяк* – фарфор яки фаянс савыт.

Югарыда аталган мәгънәләрдән тыш, сүздә сүз ясалыш мәгънәсе дә аерыла. Сүз ясалыш мәгънәсе дип сүз ясагыч

[1] Гадәттә, сүздә, нигез мәгънәләре буларак, лексик һәм грамматик мәгънәләр санала, шулай ук тел белемендә бу ике мәгънәне берләштергән категориаль – сүз төркемнәренә хас мәгънәне аеру да күзәтелә. Бер төркем галимнәр бу төр мәгънәне – лексик мәгънә, икенчеләре исә грамматик мәгънә кысаларына кертеп карыйлар. Категориаль мәгънә – бер төркем сүз төркеме өчен хас мәгънә ул. Мәсәлән, исем сүз төркеменең категориаль мәгънәсе – предметлык, фигыль сүз төркеменә хас эш-хәл, процесс, сыйфат – предмет билгесе һ.б. Кайбер галимнәр (мәс., В.С. Юрченко) бу төр мәгънәне сүзнең семантик структурасында үз урыны булган компонент буларак карау ягында. Аның фикеренчә, бер төркем сүзләрдә лексик, грамматик, категориаль мәгънәләрнең һәрберсе табылса, икенче берләрендә исә алар өлешчә генә яши. Мисал өчен, *йорт* сүзенең лексик мәгънәсе – бина, категориаль мәгънәсе – предметлык, грамматик мәгънәсе – килеш, тартым, сан. *Нәрсә* алмашлыгында категорик мәгънә – предметлык, грамматик мәгънә – килеш, лексик мәгънә юк; *аһ* ымлыгында исә өчесенең берсе дә юк. Бу турыда тулырак: Юрченко В.С. Философия языка и философия языкознания: Лингвофилософские очерки. М.: комКнига, 2005. С. 81.

[2] Мисалларда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә таянып, сүзнең төп, номинатив мәгънәләре генә бирелде.

нигез белән яңа ясалган сүз арасында барлыкка килә торган гомумиләштерелгән мәгънәләр атала. Мәсәлән, фигыльдән исем ясый торган *-гыч/-геч (-кыч/-кеч)* кушымчалары күбрәк нигездә белдерелгән эшнең коралы мәгънәсендәге исемнәр ясый: *кис-кеч, сөз-геч, төй-геч, сөрт-кеч.* Бу төзелештәге ясалма исемнәр шулай ук эшне башкаручы субъект мәгънәсендә дә булырга мөмкин: *бел-геч, ерт-кыч, корт-кыч.* Бу мисалларда сүз ясалыш мәгънәсе – корал һәм субъект мәгънәләре. Сүз ясагыч нигез күпчелек очракта яңа ясалган сүзнең гомумиләштерелгән мәгънәсен билгели (мотивлаштыра). Шуңа күрә лингвистикада ясагыч нигезне – мотивлаштыручы сүз, яңа ясалган сүзне мотивлашкан сүз дип тә атыйлар (Хисамова, 2006: 32). Мотивлаштыручы сүз белән мотивлашкан сүз арасында структур яктан гына түгел, мәгънә ягыннан да бәйләнеш була. Әгәр андый бәйләнеш булмаса, ул сүз ясалыш закончалыгына туры килми. Мәсәлән, *тарак* дигән ясалма сүзнең төзелеше *тара-к – тарак* була; тарак – тарауның коралы. Әгәр ул сүзне *тар-ак* рәвешендә бүләбез икән, мәгънә бәйләнеше юкка чыга. Икенче бер мөһим закончалык – ясалма сүз составындагы нигез шул ук мәгънәдә телдә аерым кулланыла алырга тиеш. Мәсәлән, *иләк* һәм *чиләк* сүзләре аваз составы буенча охшаш, әмма *чиләк* сүзе – тамыр сүз, аны төзелеше буенча *чил-әк* дип аерып булмый. *Иләк* сүзенә килгәндә, шулай ук татар телендәге *ил* тамыры белән *иләк* сүзе арасында мәгънәви бәйләнеш юк, әлеге сүз, *иләү* фигыленнән барлыкка килеп, эшне башкару өчен кирәкле корал мәгънәсен белдерә.

Татар телендә сөйләшүчеләрнең аңында беренчел һәм икенчел мәгънәләр, ягъни мотивлаштыручы сүз белән мотивлашкан сүз арасындагы мәгънәви бәйләнеш аерыла һәм, гадәттә, теге яки бу сүзнең кайсы берәмлек нигезендә барлыкка килүен (әгәр ул бәйләнеш тел үсеше процессында тәмам югалмаган булса) шул телдә сөйләшүчеләр җиңел аера (чагыштыр: *тимерче* – тимер белән эш итүче кеше; *авылдаш* – бер авылда яшәүче кеше; *берсүзсез* – мотивлаштыручы нигездә белдерелгән мәгънәнең юклыгы; (*күк, яфрак*) *йөзе* – тышкы яссылык, өслек, күренеп торган өлеш һ.б.).

Грамматик мәгънә барлыкка китерә торган чаралардан аермалы буларак, яңа сүз ясый торган кушымчаларда универсальлек күзәтелми, аларның яңа сүз ясау мөмкинлекләре чикләнгән (Ганиев, 2006: 17). Тагын шуны искәртү кирәк: сүз ясалыш мәгънәсе

үзенең табигате ягыннан лексик мәгънәгә беркадәр якын тора, ягъни ул грамматик мәгънәгә караганда конкретрак, индивидуаль, ул бер сүз ясалыш тибы өчен хас мәгънә белдерә. Мисал өчен, *иләк, көрәк, сәнәк, тарак* кебек сүзләрдә корал мәгънәсе; *аксак, елак, куркак* сүзләрендә фигыльдән *-к/-ак* кушымчасы ярдәмендә процессны башкаручы кеше мәгънәсе барлыкка килә. Әмма аның индивидуальлеге бер сүз эчендә түгел, бәлки бер сүз ясалыш тибы кысаларында ачыла.

Лексик мәгънәдән аермалы буларак, грамматик һәм сүз ясалыш мәгънәләре һәрвакыт билгеле бер формалар ярдәмендә тәгъбир ителә; грамматик мәгънә модаль, бәйләгеч кушымчалар яки башка бәйләүче чаралар ярдәмендә белдерелсә, сүз ясалыш мәгънәсе сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә белдерелә.

Күренекле рус тел белгече академик В.В. Виноградов билгеләвенчә, сүз мәгънәсе сүз белдергән төшенчә белән бәйләнештә генә түгел, кайсы сүз төркеменә каравы, грамматик категорияләрнең үзенчәлеге, кабул ителгән, калыплашкан контекстларга, башка сүзләр белән бәйләнешләргә, стилистик һәм экспрессив бизәкләргә бәйле билгеләнә (Виноградов, 1977: 26).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, сүзнең гомуми мәгънәсенең компонентлары булып лексик, грамматик, сүз ясалыш (ясалма сүзләрдә) мәгънәләре санала. Шулардан сүзнең төп мәгънәсе саналган лексик мәгънә сүзнең грамматик, сүз ясалыш мәгънәләреннән индивидуаль булуы, бер сүз кысаларында яшәве белән аерыла, калган һәр икесендә исә гомумиләштерү, абстрактлык күзгә ташлана. Шулай ук алар лексик мәгънәнең состав өлешләре, компонентлары буларак яшиләр. Сүзнең семантик структурасы бары тик әлеге компонентларның үзара керешеп яшәүләреннән генә барлыкка килә.

Сүз мәгънәсе һәм аның эчтәлеге мәсьәләсенә кагылып, тагын түбәндәгеләрне әйтергә кирәк. Лексик мәгънәнең барлыкка килүе һәм яшәеше лингвистик һәм экстралингвистик факторларга бәйле. Әлеге факторларның күпкырлы булуы, сүз мәгънәсендә төрлечә чагылышы сүзнең лексик мәгънәсен түбәндәге аспектларда өйрәнүгә этәрә:

1) семиологик аспект – әйләнә-тирә чынбарлыкны чагылдыру мөмкинлегенә бәйле лексик мәгънәнең эчтәлеге;

2) структур-семантик аспект – сүзнең мәгънәви төзелешен барлыкка китерү мөмкинлегенә бәйле лексик мәгънә эчтәлеге;

3) прагматик аспект – сүзнең кулланылыш мөмкинлекләренә бәйле лексик мәгънә.

Лексик мәгънәнең табигатен һәм эчтәлеген тулысынча күзаллау өчен, бу яссылыкларның һәрберсен карап үтү мөһим.

## § 9. Сүз мәгънәсенең семиологик ягы

**Семиологик** (грек. *sēmeion* – билге, знак) яссылыкта сүзнең лексик мәгънәсен тикшерү ул – сүз аша объектив чынбарлыктагы күренешләрнең кеше аңында ни рәвешле чагылышын өйрәнү дигән сүз. Бу очракта сүз б и л г е, з н а к, ягъни чынбарлыктагы күренеш, предмет, процесс, билге һ.б. фикерләү, сөйләм барышында алыштыра торган берәмлек буларак күзаллана. Тел знагы (билгесе), матди тышчадан торган төзелмә, аның эчке табигате – мәгънәсе һәм тышкы формасы бар дидек. Ул аңда, фикерләү барышында туа, сүзләр ярдәмендә реальләшә. Шунлыктан сүз тел знагының иң киң таралган, типик төре буларак кабул ителә, чөнки тел коллективының гасырлар дәвамында туплаган белемнәре, дөньяны кабул итү үзенчәлекләре нәкъ менә сүзләр ярдәмендә буыннан-буынга тапшырыла. Сүз, аның эчтәлеге – мәгълүмат туплау, аны, милли күзлектән чыгып, төрлечә тасвирлау, аңлату алымы ул.

Сүзнең беренчел, номинатив мәгънәсе турыдан-туры знак (билге) белән бәйләнештә яши, шул рәвешле номинатив мәгънә, башка мәгънәләр барлыкка килү өчен, терәк, нигез вазифасына әверелә. Халыкның озак дәверләр дәвамында туплаган мәгълүматы тулысынча сүзнең беренчел мәгънәсендә саклана, шуның нигезендә төрле күзаллаулар, чагыштырулар, тәңгәллекләр знакның табигатен баета, яңа төсмерләр өсти. Тел системасында башка знак, билгеләр белән бәйләнешкә кереп, билге икенчел, күчерелмә мәгънәләргә ия була башлый. Мисал өчен, *таш* сүзенең номинатив мәгънәсе – каты тау токымы һәм шуның бер кисәге (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 523). Әлеге төп мәгънә *таш* сүзенең шактый күптөрле күчерелмә мәгънәләре барлыкка килүгә нигез вазифасын үти. Әлеге күчерелмә мәгънәләр арасында ‘миһербансыз’, ‘мәрхәмәтсез’, ‘каты, нык’ кебекләре аеруча актив кулланыла.

Борынгы төрки телдән үк номинатив мәгънәсен саклап килгән икенче бер сүзне – *тимер* сүзен алыйк. Әлеге металл сыйфатына хас үзенчәлекләр метафорик мәгънәләр барлыкка килүгә нигез

булып торган. Семантик үсеш, абстракцияләү нәтиҗәсендә икенчел мәгънәләр барлыкка килгән һәм тимер лексемасында ‘каты’, ‘нык’, ‘көчле’ семалары активлашкан. Әйләнә-тирә чынбарлыкны танып белүнең яңа этабы, аерым алганда, әлеге металлның тормышка ныклап үтеп керүе төрле тотрыклы әйтелмәләр составында *тимер* сүзенең берегеп калуына китергән, мәсәлән, *тимер йөрәк, тимер кул, тимер холык* һ.б. фразеологизмнар, метафорик күчеш нәтиҗәсендә барлыкка килеп, тотрыклы кулланылышка кереп киткәннәр.

Чынбарлык күренешләрен семиологик яссылыкта атау беренче чиратта билгенең беренчел, нигез ясалышы, мәгънәсе белән бәйле, чөнки, билге буларак, сүз тел системасының когнитив берәмлеге санала. Бу очракта ул чынбарлык күренешләрен фикерләү күренешләренә әйләндерү вазифасын башкара, шул рәвешле фикерләүдә барлыкка килгән яңа формалар, төсмерләрнең чыганагын, нәтиҗәсен күрсәтә. Мисал өчен, *җил* сүзен алсак, әлеге тел знагының беренчел мәгънәсе һава агымының хәрәкәтен белдерә. Татар теленең знаклар системасында әлеге сүз гасырлар дәвамында тупланган шактый мәгълүматны чагылдыра. Беренче чиратта татар халкы әлеге сүз аша нәрсәнең дә булса йогынтысын, тәэсирен, шаукымын аңлый. Мәсәлән, *бәйрәм җиле* – ниндидер вакыйганың, хәлнең башлангыч билгеләре. Шулай ук татар телендә *хөррият җиле, тормыш җиле, язмыш җиле, картлык җиле* кебек гыйбарәләр дә кулланыла, һәм аларда әлеге тел знагының икенчел мәгънәсе реальләшә. *Җил* сүзе нигезенә салынган мәгълүматның төрле төсмерләре татар халык авыз иҗаты ядкярләрендә дә ачык чагыла. Мисал өчен, *җил тидермәү* – бик нык саклау, *җилгә җигелеп, бозга бозаулап йөрү* – теләсә кемне тыңлап, бушка гомер уздыру, *җилләр исү* – кинәт юкка чыгу, *җилдә өлгер, эштә сизгер* – бик булдыклы кеше турында һ.б.

Семиологик яссылыкта лексик мәгънә структурасында ике як аерыла. Аның беренчесе – д е н о т а т (лат. *denotatum* – аңлатучы, мәгънә белдерүче, күрсәтүче), ягъни аталган, күрсәтелгән предмет. Гадәттә, сүзнең денотаты булып предмет, күренеш, вакыйга, хис, процесс, төрле төшенчәләр һ.б. тора. Денотат бер төрдән булган предмет, күренешләрне аңлата, мәсәлән, *өстәл, тәрәзә, урман, болыт* – предметларны, *утыра, бара, йоклый, укый* – процесс, эш-хәрәкәтне, *матур, ак, боек, язгы* билгене аңлата, алар нигезендә

яткан төшенчәнең күләмен билгели. Сүзнең денотатив мәгънәсе – сөйләмдә сүзнең атый, предмет турында гомуми мәгълүмат бирә торган, стилистик бизәкләрдән азат мәгънәсе, ягъни сүзнең беренчел, туры мәгънәсе күзаллана.

Сүзнең денотаты турында сүз алып барганда, «референт» төшенчәсенә дә тукталып үтү зарур. Сөйләм эчендә сүзнең лексик мәгънәсе реаль чынбарлыкның конкрет бер күренеше, предметы, процессы белән бәйләнештә яши. Мәсәлән, *Койма буеннан, чулпыларын чылтыратып, үзара көлешә-көлешә, кызлар узып бара* (Г. Бәширов) җөмләсендә *койма, чулпыларын* сүзләренең мәгънәләре әлеге сөйләм эчендә аңлашылган конкрет предметларны атый. Әлеге сүзләр белән аталган предметларны – референт (лат. *referendum* – тыңләү) дип, ә сүзнең бу очрактагы мәгънәсен конкрет-референт мәгънә дип атыйлар. Сөйләүче бу очракта билгеле бер предмет яки күренешне күзаллап атый: *Авылда тагын бер карт кеше бар. Анысы – Гөлҗиһан әби...* (И. Гази) контекстында *Гөлҗиһан әби; Койма буенда зәңгәр тышлы дәфтәр ята* (Г. Сабитов) җөмләсендә *дәфтәр* сүзләре моңа мисал булып тора.

Денотат предмет рәтенең гомуми атамасы булса, референт исә – телдән тыш чынбарлык объекты. Аерманы аңлату өчен, күрә, тотып карый ала торган предмет буларак урындык һәм предмет төркеменең нигез, төп атамасы буларак, *урындык* очрагына тукталыйк. *Мин йомшак урындыкта утырам* мисалында *урындык* сүзе аерым бер предмет атамасы буларак кулланыла, һәм бу очракта без реаль чынбарлыкның бер күренешен атадык. Әлеге контексттагы очрак ул – референт, чөнки биредә исем-атаманың конкрет кулланылышы күренә. *Урындык – йорт җиһазлары арасында иң кирәкле предмет* мисалында денотатив мәгънә күзаллана, чөнки биредә гомумиләшкән мәгънә – бер төркемгә кергән предмет атамасы бирелә.

Предметлар классы тотрыклы семантик структурага ия; сөйләм барышында төрле үзгәрешләр, вариатив кулланышлар күзәтелсә дә, сүзнең эчтәлегенә зыян килми. Шулай итеп, сүзнең денотатив мәгънәсе сөйләм процессында үзенең актуальлеген, беренчел мәгънәгә хас үзенчәлекләрен югалтмый, аның төп үзлекләрен һәрвакыт саклый.

Лексик мәгънә структурасының икенче ягы – сигнификат (сигнификатив мәгънә). С и г н и ф и к а т (лат. *significātum* – табылу) –

тел берәмлегенең төшенчә белән бәйләнеше. Сигнификатив мәгънә дигәндә, кешенең аң-фикерендә аерым бер предмет, күренеш, билге, процессның гомуми чагылышын күзаллыйлар. Семиотик теория нигезендә, сигнификатив мәгънә знак, билгенең сигнификатка, төгәлрәк әйтсәк, төшенчәгә мөнәсәбәтле чагыла.

Конкрет бер предметны, яисә абстракт объектны атаганда, сүз аерым бер предметны гына белдерми. Беренче чиратта теге яки бу сүз предметлар, күренешләр турында гомумиләшкән күзаллау тудыра. Мисал өчен, шул ук *урындык* сүзен алыйк. Әлеге сүз конкрет бер урындыкны түгел, ә безнең аңыбызда әлеге предметка хас булган үзлекләрне туплаган мәгълүмат бирә; барлык урындыклар өчен хас төп үзлекләрдән, өслеге булган, утырырга яраклы предмет күзаллана. Үз эчендә инде урындыкның төрләре (өсте тукымалы яки тактадан булган, арты булган яки артсыз һ.б.) аерыла. *Йоклау* фигылен атаганда да, кемнең, нинди шартларда йоклавы түгел, гомумән, бу халәт күзаллана. Безнең аңыбыз теге яки бу предмет, күренеш, процесс, билгене, гомумиләштереп, төшенчә буларак, аңыбызда саклый.

Телдә кулланыла торган күпчелек сүзләрнең эчке формасында денотатив һәм сигнификатив компонентларны аерып була, әмма телдәге бер төркем сүзләрдә, аерым алганда дейктик сүзләрдә, аталган мәгънәләр тулысынча чагылмый. Мисал өчен, ялгызлык исемнәргә, аерым алганда, антропонимнарга тукталыйк. Антропонимның денотаты – исемне йөртүче конкрет кеше, ул бер төркем кешеләр арасыннан берсен аерып алып атауга ярдәм итә. Бу ягы белән ул башка лексик берәмлекләрнең денотатыннан аерыла. Аталган теләсә нинди исем шул исемне йөрткән кешегә бәйле күзаллаулар тудыра. Исемнәрнең сигнификатив ягы башка төр лексик берәмлекләрдән шулай ук аерыла. Әгәр күмәклек сүзләрнең сигнификатив мәгънәсе төшенчә аша ачылса, кеше исемнәрендә ул конкрет бер кеше белән бәйле, аның турында билгеле бер дәрәҗәдә мәгълүмат бирә, аталган кешенең милләте, якынча яше, җенесе хакында белергә була.

Семасиология фәнендә сигнификатны төшенчә белән тиңләштереп, төшенчә терминына бәйле аңлату традицион юнәлештә язылган хезмәтләрдә киң таралыш тапкан. Татар теле лексикологиясенә багышланган фәнни хезмәтләрдә, дәреслекләрдә дә «сигнификат» термины урынына «төшенчә» термины кулланылып килде. Шунлыктан

без, алар арасындагы тәңгәллекне танып, «төшенчә» терминына аерым тукталып үтүне кирәк саныйбыз.

Т ө ш е н ч ә дип чынбарлыктагы предмет, күренешләрнең гомуми һәм әһәмиятле билгеләрен чагылдыручы фикерләү берәмлеген атыйлар (Сафиуллина, 1999: 12). Конкрет бер предметны яисә абстракт объектны атаганда, сүз аерым бер предметны гына белдерми. Беренче чиратта теге яки бу сүз предметлар, күренешләр турында гомумиләшкән күзаллау тудыра.

Башта кешеләр аңында күреп, тоеп була торган предметлар чагылса, фикерләү сәләте арткан саен, абстракцияләүгә дә юл ачыла. Төшенчәләрдә теге яки бу предметка караган аерым билгеләр түгел, ә гомуми төп, әһәмиятлеләре генә чагыла. Төшенчәләр барлык халыклар өчен дә уртак, әмма алар милли характерга ия булган сүзләрдә реальләшәләр. Мәсәлән, *төлке* сүзе асылында яткан төшенчә – этләр семьялыгыннан булган озын койрыклы ерткыч хайван. Әлеге хайванга хас булган төп үзенчәлекләр (хәйләкәрлек, елгырлык, билгеле бер дәрәҗәдә матурлык) сүзнең өстәмә, күчерелмә мәгънәләре барлыкка килүгә җирлек булып тора. Шул рәвешле, бу сыйфатларга ия кешене *төлке* сүзе белән атыйлар: *Төлке дә инде ул!; Син төлкеләнмә* һ.б.

Сүзләр белдергән төшенчәләр, гадәттә, энциклопедик сүзлекләрдә урын ала, чөнки аларның тасвирлау предметы булып чынбарлык предметлары, күренешләре һәм төшенчәләр тора. Лингвистик сүзлекләр төренә бәйле, сүзнең семантик, грамматик билгеләре тасвирланса, ә энциплопедик сүзлекләрдә төшенчәгә аңлатма бирелә. Мисал өчен, *яшен* сүзен алыйк. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә әлеге сүзгә бәйле түбәндәге мәгълүмат тәкъдим ителә: *Яшен – ис.* 1) атмосфера электрының һавада бушануыннан барлыкка килгән, кисәк кенә ялтырап киткән көчле чаткы. *Җәйге я.*; 2) *күч.* Көчле хисләр кичергәндә, кинәт күзләрдә чагылып китә торган чаткы, нур турында; 3) *күч.* Җитез кешегә карата әйтелә. *Я. кебек атылды* ◊ **Яшен суккандай булу (калу)** Аптырап катып калу. **Яшен ташы (кебек)** Бик кызу, тиз, хәрәкәтчән, үткен кеше турында. **Яшен тизлеге белән (тизлегендә)** Бик тиз (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 739).

Энциклопедик сүзлектә яшенгә, аңа бәйле күренешләргә түбәндәге аңлатма бирелә: *яшен* – җир өслеге һәм болытлар арасында барлыкка килә торган, озынлыгы берничә километрга сузылган,

диаметры берничә дистә сантиметрлык, озынлыгы секундның дистә өлешен хасил иткән электр чаткысы, гадәттә, күк күкрәве белән кушыла. *Яшенле яңгыр* – атмосфера күренеше, өер болытларда яки болытлар белән җир өсте арасында электр разрядлары барлыкка килә: яшен яшьни һәм күк күкри, җилләп, давыллап яңгыр яки боз явып үтә. ТРда елына 23–32 көн яшенле яңгыр явуы күзәтелә. Май һәм сентябрьдә сирәгрәк, июнь-июльдә аеруча күп була, уртача 1,6–2,2 сәгатькә сузыла (Татар энциклопедия сүзлеге, 2002: 817).

Төшенчә белән сүз арасында бәйләнеш кешеләрнең үзара эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә. Һәр аерым чорның шушы чорда яшәүчеләргә аңлашыла торган сүзләре бар. Төшенчә белдергән сүзнең төп функциясе – номинатив функция. Ул бер күренеш, предметны башкалардан аерып алып атау өчен хезмәт итә. Шунысын искәртү зарур: телдә барлык сүзләр дә төшенчә белдерми. Бу үзенчәлек бары тик мөстәкыйль сүзләргә генә хас. Мөстәкыйль сүзләр арасында да, алдагы бүлекләрдә искәрткәнчә, төшенчә атамасы булмаган сүзләр бар. Боларга ялгызлык исемнәр, алмашлыклар, ымлык, аваз ияртемнәре керә.

Шулай итеп, төшенчә – сүз мәгънәсенең төп, әмма бердәнбер булмаган билгесе ул. Сүз мәгънәсенә төшенчәдән тыш экспрессив элементлар, грамматик билгеләр, контекстуаль-стилистик күзаллаулар дә сыя. Мәсәлән, «ак» төшенчәсен *ап-ак, ак, аксыл* сүзләре ярдәмендә белдерә алабыз. *Агарту, аклау* фигыльләре дә әлеге төшенчәне белдерергә ярдәм итә. Абстракт мәгънәле *аклык* сүзен дә бирегә кертеп карыйбыз. Бу сүзләрнең мәгънәләре уртак, чөнки алар бер төшенчә белән бәйле.

Шулай итеп, сүздә денотатив һәм сигнификатив (төшенчә) мәгънәләр турыдан-туры бәйләнештә яши. Денотат предметны атаса, сигнификат исә аның даими, я булмаса вакытлы булган билгеләрен, гомумиләштереп, үзендә туплый.

## § 10. Сүз мәгънәсенең структур-семантик ягы

Лексик мәгънәнең структур-семантик ягы сүз мәгънәсенең төзелешен, аның эчке семантикасының башка мәгънәләр ясау өчен нигез була алу мөмкинлеген характерлый. Сүзнең лексик мәгънәсендә реаль чынбарлыкның кеше аңы кабул итә һәм аңа аңлатма бирә ала торган типик һәм үзгә сыйфатлары сакланып кала. Лексик мәгънә эчендә аерыла торган берничә төшенчәгә тукталып үтик.

1. Гадәти, көндәлек төшенчәләр – кешенең гамәли, рухи, мәдәни эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән, аның көндәлек тормышын алып бару өчен кирәкле белемнәр. Әлеге белемнәр озак вакытлар халык телендә кулланып формалашалар һәм сүз мәгънәсенең асылын тәшкил итәләр. Мәсәлән: *су – аш-су әзерләү, сусауны басу өчен кирәкле төссез сыекча.*

2. Фәнни төшенчәләр – теге яки бу предмет, күренешкә хас төп сыйфатларны тасвирлаган, аерым бер фән тармагында кулланыла торган белемнәр. *Су – водород һәм кислородның химик кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган үтә күренмәле төссез сыеклык.*

3. Коннотацияләр, ягъни татар телендә аерым бер сүз мәгънәсендә табыла торган стилистик, эмоциональ-экспрессив өстәмә мәгънәләр (коннотация турында тулырак мәгълүмат алга таба бирелә). Мәсәлән, шул ук *су* сүзенең мәгънәсендә ‘бик сыек’, ‘буш’ семалары өстәмә мәгънә компоненты буларак кулланыла: *ашы су гына булу; сөйләме су гына; су кебек эчү* һ.б.

4. Потеницаль мәгънәләр – сүз бирергә сәләтле мәгънәләр. Алар сүзлекләрдә теркәлмиләр, контекстта гына ачылалар, татар телендә сөйләшүчеләргә билгеле булалар һәм җиңел аңлашылалар. Мәсәлән, *Кар сулары кебек акты гомер, былбыл булалмадым тирәктә* (Г. Афзал) шигъри юлларында гомер – су тәңгәллеге – татар кешесе өчен ачык аңлашыла торган мәгънә. *Утлар эчеп, сулар сибеп кенә дәвам иттерүме тормышны? Бу хәятне кемдер яратмас та, без белгәнме башка торышны?* (Б. Рәхимова) шигъри юлларында *ут, су* сүзләре аша «тормыш кыенлыклары» мәгънәсе бирелә.

5. Энциклопедик мәгънә – үз эченә фәнни һәм көндәлек төшенчәләрне берләштергән, объектның кулланылыш мөмкинлекләрен тасвирлаган мәгънә. Мәсәлән, *туфрак* – литосфераның өске катламнарындагы су, һава һәм тере организмнар тәэсирендә үзгәрүчән һәм генетик яктан үзара бәйләнешле катламнардан (горизонтлардан) торган табигать җисеме. Каты (беренчел һәм икенчел минераллар, органик матдәләр), сыек (Т. эремәсе), газсыман (Т. һавасы) һәм тере (бактерияләр, суүсемнәр, гөмбәләр, гади һ.б. тереклек ияләре) өлешләрдән гыйбарәт. Уңыш бирү сыйфатына ия. Генетик типларга бүленә. ТРда *соры урман туфраклары, кара туфраклар* киң таралган. Шактый зур мәйданнарны кәсле-көлсу, кәсле-корбанатлы, аллювиаль һәм кара болын Т. лары били. Торфлы сазлык, болын-сазлык, тозлак һәм катыр Т. ларның мәйданнары зур түгел.

ТР территориясендә Т. ларның таралып урнашуы геогр. киңлек закончалыкларына бәйле. Авыл хуҗалыгында төп җитештерү чарасы (Татар энциклопедия сүзлеге, 2002: 673).

Структур-семантик яктан тикшергәндә, сүзнең лексик мәгънәсендә ү з ә к н е (конкрет һәм фәнни төшенчәләр), ү з ә к н е ң ә й л ә н ә с е н (коннотацияләр), п е р и ф е р и я с е н (потенциаль һәм мөмкин булган барлык мәгънәләр) аералар. Телдә кулланыла торган зур күпчелек сүзләрнең семантик структурасы әлеге компонентларны берләштерә, шулар нигезендә сүзнең тулы семантик структурасы барлыкка килә. Мисал өчен, *йомшак* сүзен алыйк. Әлеге сүз мәгънәсенең үзәген «каты булмаган, капшап, татып карауга тыгыз булмаган» мәгънәсе тәшкил итә. Үзәкнең әйләнәсенә «зәгыйфь, начар, көчсез» (*йомшак ишетү, йомшак сизү*); «ихтыяр көче булмаган, басынкы, тыйнак» (*йомшак кеше, йомшак холык*); «тиешле дәрәҗәдә түгел, кимчелекле, начар» (*йомшак әсәр, йомшак доклад*) һ.б. шундый мәгънәләр керә. Перифериясен исә *йомшак алтын* (кыйммәтле мех); *йомшак баш* (томана, аңгыра) кебек телдә сирәк кулланыла торган мәгънәләр тәшкил итә.

## § 11. Сүз мәгънәсенең прагматик ягы

Сүзнең знак буларак кулланылышы өч яссылыкта характерлана: семантика, синтактика, прагматика. Семантик аспект традицион кулланылыштагы «мәгънә» төшенчәсенә туры килсә, синтактика знак, билгенең сөйләмдә, аерым бер текст эчендә башка знаклар белән бәйләнешкә керүен күзаллый һәм «сүзләрнең ярашуы» төшенчәсенә туры килә. Сүзнең башка берәмлекләр белән ярашу мөмкинлеге алдагы бүлекләрдә каралачак.

П р а г м а т и к а (грек. *pragma* – эш, гамәл) термины сөйләм актында знакның катнашучыларга мөнәсәбәтен белдерә. Аның төп максаты – сөйләмдә знак, билгенең кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау. Знакның прагматик ягы аралашу процессында, сөйләмнең максатына карап, аерым бер ягының актуальләшүен белдерә. Әлеге термин тел белемендә чагыштырмача яңалардан санала, чөнки ул фәндә актив әйләнешкә XX гасырның 30 нчы елларында гына семиотиканың бер тармагы буларак килеп керә. Шуңа карамастан хәзерге тел белемендә әлеге тармак шактый өйрәнелгән, популяр юнәлешләрдән санала. Сүз мәгънәсенең субъектка һәм сөйләм максатына бәйле төрле яссылыкларда кулланылышы, даими,

статик булмаган мәгънәләрнең барлыкка килүе, сөйләм тактикасы, кагыйдәләре, сөйләм агышында әйтелә һәм кабул ителә торган мәгълүмат, сөйләмдә кулланылган знакларның яшерен яисә көчерелмә мәгънәләре, сөйләүченең хәбәр ителә торган мәгълүматка мөнәсәбәте, бәя бирү юллары һ.б. үзенчәлекләрне өйрәнү нәкъ менә прагматик яссылыкта бара. Болар барысы да татар теле формалашу һәм үсешендә тәэсир ясаган тарихи, мәдәни, иҗтимагый алшартлар белән бәйле, чөнки тел знакларын куллану, аларның теге яки бу мәгънәсен актуальләштерү мөмкинлекләре тел үсешендә туплаган мәгълүматлар нигезендә генә башкарыла ала.

Лексик мәгънәнең сөйләшүчеләрнең сөйләм объектына мөнәсәбәтләрен белдергән прагматик ягы үз эченә, денотатив, сигнификатив мәгънәләрдән тыш, эмоциональ-экспрессив, коннотатив мәгънәләрне дә берләштерә. Болар исә үз чиратында тел үсешенең тарихи-мәдәни үзенчәлекләре белән дә, сөйләшүчеләрнең социаль статусы, психологик халәте белән дә тыгыз бәйләнгән.

Сүзнең прагматик ягы дигәннән, знакның телдә кабул ителгән төп объектив үзенчәлекләре белән субъектив факторлар йогынтысында тулыландырылган, үзгәртелгән мәгънәсен атыйлар. Шуңа бәйле семасиология фәне үсешенең соңгы этапларында сүзнең статик халәтеннән (денотат белән сигнификат бергәлеге) тыш, тел знакларының кулланылышта, сөйләм контекстында гына ачыла ала торган эмоциональ-бәяләү мөмкинлекләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә башлады.

Лексик мәгънәнең семантик структурасы кысасында денотатив һәм сигнификатив яклар белән үрелеп, прагматик як бер үк төрле мәгънәви эчтәлеккә ия булган знаклар арасыннан берсен сайлап алып, атала торган күренеш, предметка мөнәсәбәт белдерергә ярдәм итә. Тел берәмлекләренең лексик мәгънә структурасында прагматик аспект булганда төп үзенчәлек булып аларның аңлаешлы булуы гына түгел, ә хис-кичереш белдерүе дә тора. Җыеп әйткәндә, тел берәмлекләре аралашу вазифасын гына түгел, бәяләү функциясен дә башкаралар.

Кагыйдә буларак, лексик мәгънәнең прагматик аспекты сүзнең эмоциональ, экспрессив-стилистик үзенчәлекләрен, аларның табигатен аңлату өчен кулланыла. Мәсәлән, *Җәһидә кызларны назлап сыйпады: Ярый,* ***үскәнем,*** *ярый,* ***шикәрем,*** *юыныйм да хәзер килермен, тутам көтеп тормасын, сез китегез* (Г. Исхакый)

җөмләсендә *үскәнем, шикәрем* сүзләре ярдәмендә адресатка карата булган җылы ярату хисләре белдерелә, әлеге берәмлекләрнең лексик мәгънәсендә аралашучылар арасындагы уңай хис-кичерешләр ачык чагылыш таба.

Тел белгечләре фикеренчә, сүзнең лексик мәгънәсендәге денотатив, сигнификатив һәм прагматик аспектлар макрокомпонентлар буларак кабул ителә. Аларның һәрберсе тагын да ваграк компонентлардан тора. Прагматик аспектның микрокомпоненты буларак коннотатив мәгънә санала.

Коннотатив мәгънә (лат. *connotatio* – өстәмә мәгънәгә ия булу) – сүзнең төп, атау, денотатив мәгънәсен тулыландырып килә торган эмоциональ-экспрессивлыкка, стилистик бизәк, төсмергә ия лексик мәгънә компоненты.

Хәзерге семасиология фәнендә сүз мәгънәсенә салынган коннотацияләрнең асылын ачыклау мәсьәләсе әһәмиятлеләрдән санала. Аерым алганда, В.В. Виноградов, М.А. Кронгауз, В.Н. Телия, И.В. Арнольд, В.И. Шаховский, Э.С. Азнаурова, А.В. Филиппов, З.Д. Попова, И.А. Стернин, Л.А. Сергеева, В.И. Говердовский, В.Н. Манакин, А.Н. Приходько, татар тел белемендә И.Б. Бәширова, Г.Р. Галиуллина һ.б.ның хезмәтләрендә сүздә денотатив һәм коннотатив мәгънәләрнең үзара мөнәсәбәтләре чагыштырма, тасвирлама һәм когнитив аспектларда чагылыш таба. Әлеге галимнәрнең эзләнүләрендә сүзнең лексик мәгънәсе структурасында коннотатив компонентның урыны проблемасы бәхәсләр уята. Мәсәлән, бер төркем галимнәр (Э.С. Азнаурова, И.В. Арнольд, В.Н. Телия, В.И. Шаховский һ.б.) коннотатив компонент номинатив берәмлекләрнең семантик структурасының состав өлеше дип караса, икенчеләре исә (Ю.Д. Апресян, Н.Г. Комлев, Д.Н. Шмелёв һ.б.), киресенчә, коннотацияне сүз мәгънәсенең состав өлеше буларак карауга каршы. Татар тел белемендә исә сүзнең коннотатив ягы турында гомуми фикерләр генә очратабыз.

Коннотатив мәгънәне ике яклы аңлап була: тар мәгънәдә карасак, коннотатив мәгънә тел берәмлегенең объектив, беренчел мәгънәсен тулыландыра, төрле ассоциатив-образлы күзаллаулар нәтиҗәсендә икенчел номинация җирлеге булып тора. Киңрәк мәгънәдә «коннотатив мәгънә» термины сүзнең денотатив һәм грамматик эчтәлеген тулыландырган, аңа экспрессивлык өсти торган компонент буларак күзаллана.

Коннотация бәяләү, хис-тойгы, эмоциональлек, экспрессивлык, ассоциатив-образлылык, стилистик элементлардан тора. Бары тик билгеле бер эмоция, кичереш белдергәндә генә, сүз коннотатив мәгънәгә ия була. Гадәттә, эмоцияләрне уңай һәм тискәре төрләргә бүләләр. Үкенү, ачулану, гаҗәпләнү, мәхәббәт, ярату, өнәмәү, үпкәләү кебек хис-тойгылар сүзнең мәгънәсендә когнитив компонент буларак яшиләр. Мәсәлән, *карлыгачым, җимешем, алтыным, сандугачым, күз карам* кебек лексик берәмлекләр, сөйләм эчендә күчерелмә мәгънәдә килеп, синоним буларак яшиләр, аларда ярату, якын итү кебек коннотатив компонент күзгә ташлана.

Коннотатив мәгънәнең икенче бер әһәмиятле элементы – экспрессивлык. Сүздә бу компонент табылсын өчен, төп алшарт – сүзнең образлылыгын арттыру, яисә башка бер чара ярдәмендә сүз атаган чынбарлык элементын ассызыклау, аерып күрсәтү күздә тотылу. Мәсәлән, сөйләм процессында сөйләүче тасвирлана торган объект, субъектның аерым бер сыйфатларын ассызыклау максатын куйса, төрле экспрессив чаралар куллана, шул рәвешле төгәл бәя бирергә омтыла. Телебездә кешенең тышкы сыйфаты булган озын буен бәяләү өчен кулланыла торган *колга* сүзе, эчке сыйфатын тасвирлаганда очрый торган *ишәк, куян, әтәч* сүзләре шундыйлардан. Объектның ераклык дәрәҗәсен күрсәткәндә кулланыла торган *Каф тавы артында, җәһәннәмдә, Агыйделнең аръягында* берәмлекләре дә әйтелгән фикергә мисал булып тора.

Сүзнең лексик мәгънәсендә бу элементларның булу-булмавы, турыдан-туры тел шәхесе, татар телендә сөйләшүче кешенең дөньяны, әйләнә-тирә чынбарлыкны кабул итү үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Төгәлрәк әйтсәк, сүзнең лексик мәгънәсе – кешенең дөньяны объектив һәм субъектив танып белү нәтиҗәсендә туплаган белемнәре ул. Әлеге белемнәрнең объектив ягы предмет, күренеш, билге һәм процессларның физик үзенчәлекләрен кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килсә, субъектив ягы күренешләрне атау барышында аларга бәя бирү, әлеге предметларга хас төп үзенчәлекләрне аеруда ачык чагыла. Мәсәлән, төрки-татар чыгышлы *чүп* сүзен алыйк. Татар телендә сөйләшүчеләр өчен бу сүзнең эчке формасы, семантикасы ачык аңлашыла. Аның номинатив мәгънәсе – кирәксез, ташландык әйбер калдыклары, төрле вак-төякләр; төрле эшләнмәләр ясаганда кала торган чимал, материал калдыклары (*пычкы чүбе, ышкы чүбе* һ.б.). Татар телендә

*чүп* сүзе, *үлән* сүзе белән янәшә килеп, иген яисә башка культураларны чәчкән җиргә чыгып үсә торган кыргый үләнне атау өчен актив кулланыла, шул рәвешле *чүп үләне* тезмә сүзен барлыкка китерә. Тел үсеше процессында кешенең дөньяны субъектив кабул итүе, төрле чагыштырулар, ассоциацияләр нәтиҗәсендә әлеге сүзнең когнитив мәгънәләре барлыкка килгән. *Чүп* сүзенең семантик структурасында аңлашыла торган әһәмиятсез, кирәксез, файдасыз нәрсә (*чүп сүз*); җиңел, ансат эш (*бу эш синең өчен чүп кенә*) кебек мәгънәләр лексик мәгънә структурасының когнитив компоненты булып тора. Телдә калыплашкан, тотрыклы кулланылышка кергән *чүпкә дә санамау, чүп өстенә чүмәлә, чүпкә чыгу* һ.б. шундый фразеологик әйтелмәләр тел шәхесенең дөньяны объектив кабул итүе, хис-кичерешләр, күзаллаулар нәтиҗәсендә субъектив бәяләве аркасында барлыкка килгәннәр. Саналган мисалларда *чүп* сүзе ярдәмендә тискәре бәяләү ачык күренә, һәм бу антропоцентрик фактор белән турыдан-туры бәйләнгән. Татар теле вәкилләренең *чүп* сүзенең беренчел номинатив мәгънәсе нигезендә барлыкка килгән күзаллаулары кеше аңында төрле үзгәрешләр китереп чыгара, әлеге үзгәрешләр исә сүзнең мәгънәви компонентында аерым сема буларак берегеп калалар һәм алга таба яшәеш, таралыш табалар.

Сүзнең коннотатив мәгънәсе белән бәйле берничә факторга тукталып үтү зарур. Беренчедән, сүз мәгънәсендә табыла торган коннотатив компонент вакыт һәм тел нормалары, җәмгыятьтә өстенлек алган стандартлар, иҗтимагый төркемнәр, мәдәни һәм сәяси алшартлар белән тыгыз, турыдан-туры бәйле. Икенчедән, сүзнең мотивлашуында ныклы нигез булу, аны тел коллективының аңлавы һәм кабул итүе мөһим.

Тел чаралары арасында сүзләр, аларның мәгънәләре халык менталитетын, милли үзенчәлекләрне буыннан-буынга җиткерергә сәләтле. Сүзләрнең лексик мәгънәсенә салынган мәгълүмат халыкның милли күзаллауларында булган үзгәрешләрне күрергә ярдәм итә. Сүзнең эчтәлегендә, лексик мәгънә белән берлектә, мәдәни компонент та яши, ул – сүзнең лексик мәгънәсе кысаларына кереп бетмәгән, шул ук вакытта аны тулыландырып килә торган мәгълүматларны берләштерә. Сүздә денотатив, сигнификатив һәм коннотатив якларның үзенчәлекләрен, дөньяны танып белүдә халыкның милли үзенчәлекләрен, бәяләү

мөмкинлекләрен төрки чыгышлы *бүре* лексемасы мисалында карап үтик. Хәзерге татар телендә кулланыла торган борынгы төрки лексика арасында табигать белән, үсемлекләр, хайваннар дөньясы белән бәйле сүзләр кулланылыш үзенчәлекләре, семантик һәм мәдәни потенциаллары белән аерым игътибарга лаек. Алар телнең борынгы катламнарыннан бүгенгәчә килгән мәгънә үсеш-үзгәрешен күрсәткән берәмлекләрдән санала. Шулай ук бу төр лексикада халыкның дөньяны үзенчә бәяләве, күрә алу сәләте ачык чагыла.

*Бүре* сүзенең беренчел мәгънәсе ерткыч җанварны белдерә. Барлык халыкларда, аңа хас сыйфатлар буларак, ерткыч, ач, куркыныч булуы күрсәтелә. *Бүре* сүзе борынгы төрки телдән үк билгеле. Ул *кашгар, корт* синонимнары белән бергә кулланылган һәм язма истәлекләрдә еш чагылыш тапкан. Аерым алганда, М. Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә ул дистәдән артык кабатлана. Биредә *бүре* сүзе, нигездә, «кыргый хайван» мәгънәсендә бирелә, шулай ук күчерелмә мәгънәдә «усаллык», «явызлык», «куркыныч» мәгънәләрендә кулланылуын да очратабыз (Kaşgarlı Mahmut, 2006, 1 cilt: 36, 106, 136, 336).

Телдә сүзнең кулланылыш даирәсен киңәйтүдә, мәгънә мөмкинлекләрен күрсәтүдә метафорик күчеш зур роль уйный. Читләтеп әйтү нигезендә сүз яңа ассоциацияләр тудыра, һәм алар, милли аң аша үткәрелеп, миллилек күзлеге аша аңлатылып, сүзләрдә реальләшәләр. Әйбер, предметлар арасындагы охшаш һәм аермалы якларга нигезләнеп, атаманы күчерү телдә киң таралыш тапкан. Безнең фикеребезчә, мәгънә катламының тирәнлеге тел байлыгын билгеләү критерийларының әһәмиятлесе буларак каралырга хокуклы. Телдә *бүре* сүзе метафорик күчеш нигезендә икенче яшәеш ала, ягъни әлеге күчеш процессында сүзнең яңа мәгънәләре барлыкка килә. Татар милли шәхесе *бүре* сүзен икенчел атама итеп бирү процессында әлеге сүз тудырган образ, стереотиплар һәм символларны куллана.

*Бүре* сүзе ярдәмендә туган образлар һәм стереотиплар нигезе төрки бабаларның мәҗүси ышануларына барып тоташа. Беренче чиратта бүре – изге хайван, төрки кабиләләрнең тотемы. Бу очракта ул уңай коннотацияләрне берләштерә.

Борынгы җәмгыятьтә үк бүрегә карата ике төрле мөнәсәбәт киң таралыш тапкан була. Беренчедән, югарыда әйтелгәнчә, ул

изгелек символы саналса, икенчедән, кешегә, терлекләргә зыян салуы белән куркынычлык символына әверелгән. *Бүре* сүзенең кеше аңында яшәгән ике мәгънәви-мәдәни коды бүгенгәчә килеп җиткән. Мәсәлән, хәзерге татар кешесенең аңында әлеге ике код яшәвен бу сүзнең хәзерге татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлгән «ерткыч җәнлек» һәм «усал, явыз кеше» мәгънәләренә карап та белеп була (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 108). Бүрене изгеләштерү эзләре *бүресе улау* фразеологизмында да сакланып калган. Н. Исәнбәтнең «Татар теленең фразеологик сүзлеге»ндә әлеге тотрыклы әйтелмә «теләгәненә, байлыкка, дәрәҗәгә ирешү, бәхет басу» мәгънәсендә теркәлгән. Галим күрсәткәнчә, төркиләрдә бүре улауны яхшыга юраганнар. Бу ышануның нигезе борынгы төркиләрдә бүренең улап, аларга дошман кавеменнән котылырга юл күрсәтүе һәм шуның белән дөньяда төрки халыкның нәселен юкка чыгудан саклап калуы турындагы легендага барып тоташа (Исәнбәт, 1989: 209).

Шулай да бүгенге көндә татарлар аңында бүре явызлык һәм дошманлык символы буларак ешрак очрый. Бу төр метофорик яшәешнең нигезе шулай ук борынгы чорга – кабиләчелек җәмгыятенә барып тоташа. Аучылык, терлекчелек тормыш итүнең төп чыганагы булган бу чорда бүре кешенең дошманы, азыктан мәхрүм итүче буларак гәүдәләнә. *Бүре* сүзенең тискәре коннотацияләре алгы планга чыга башлый, сүзнең явызлык мәгънәсе актуальләшә. Халык авыз иҗаты ядкярләреннән моңа күп санлы мисаллар табарга була. Без фикеребезне фразеологик әйтелмәләр нигезендә исбатларга алынабыз. *Бүре тиресе ябынган; бүреләр белән яшәсәң, бүречә уларсың; бүрек астында бүре балалары асрау; эчендә бүресе улый кебек* мисалларда «явызлык» төшенчәсе *бүре тиресе, бүречә улау, бүре балалары* сүзләре ярдәмендә калкурак күрсәтелә һәм тискәре мәгънә төсмере артуга китерә.

Бүренең еш кына хуҗалыкка азык эзләп килүе, ач булуы тотрыклы әйтелмәләрдә аның ачлык, хәлсезлек символы буларак та гәүдәләнүен күрсәтә: *бүре сырхавы* (ачтан интегү); *бүре ерткыры; бүре азыгы* (ябык терлекләргә карата әйтелә); *бүре кебек ач, елан кебек ялангач; бүре авыз* һ.б.

Татар телендә кулланыла торган *улау* сүзенең туры һәм күчерелмә мәгънәләренең семантик потенциалы да *бүре* сүзенә барып тоташа. Беренчел мәгънәсендә ул эт, бүре тавышы белән бәйле

аңлатыла. Метафорик күчеш нигезендә *җил улау* сүзтезмәсе кулланыла башлый. Бу очракта тискәре коннотациянең сизелерлек дәрәҗәдә алгы планга чыгуы күзгә ташланмый. *Улау* сүзе сөйләм телендә сузып елауны, йогышсыз тавыш белән җырлауны яисә кычкыруның югары дәрәҗәсен белдерү максатыннан кулланыла. Биредә сөйләүченең тискәре мөнәсәбәте ачык сизелә.

Еш кына *бүре* сүзе, милли шәхес аңында үзенең тискәре коннотатив мәгънәсен саклаган хәлдә, башкачарак төсмерләр бирү өчен дә кулланыла. Тотрыклы әйтелмәләрдә *бүре* сүзе ярдәмендә бирелгән түбәндәге мәгънәви-мәдәни үзенчәлекләр аерыла:

1. *Бүре бүрене ашамас; бүре күршесен ашамас; бүре дә күршесенә тими; бүре дә күршесенә касд кылмас* кебек мәкаль вариантларында ул тугрылык символы буларак та гәүдәләнә.

2. Бүре – көч символы да: *Бүре екса, эт тә туя, кош та туя; бүренең көче – тешендә*. Аның көчле булуы кешегә хас куркаклыкны тасвирлаганда да алгы планга чыга: *бүредән куркып, урманга бармау; бүре күргән эт төсле; бүрек ташлап, бүре куркыту; бүрәнә аша бүре куу*.

3. Күп кенә тотрыклы әйтелмәләрдә бүренең табигать киңлегендә яшәве ирек символы буларак кулланылуына китергән: *бүрене никадәр кадерләсәң дә, урманга карый; бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый; бүре малае*.

Югарыда каралган коннотатив үзенчәлекләр мөстәкыйль мәгънәле сүзләргә хас иде. Дейктик сүзләргә хас коннотатив мәгънә үзенчәлекләрен антропонимнар мисалында карап үтик. Алда әйтелгәнчә, антропонимик лексикада денотатив һәм сигнификатив мәгънә аерым бер субъект белән бәйле. Антропонимның семантик структурасындагы коннотатив компонент исемнең кулланылышына бәйле, ике төрле ачыла. Беренчедән, сөйләм агышында ялгызлык исемнәре, төп кешене атау функциясеннән тыш, төрле окказиональ кулланылышка ия булалар. Исемнең төп үз вазифасында коннотатив компонентның активлашуы төрле стилистик чараларга бәйле. Мәсәлән, исем составында кулланыла торган иркәләү-кечерәйтү кушымчалары (*-кай/-кәй: Гөлкәй, Илкәй, Саниякәй, Сылукай; -ай/-әй,-и: Рамазан – Рамай; Гибадетдин – Гибай, Имаметдин – Имамый / Имай; -уш/-үш: Зәйнетдин – Зәйнүш*), I зат тартым кушымчасы (*-ым/-ем: Галиям, Алмазым, Лилиям*) аталган субъектка карата уңай хис-кичерешләрне белдерәләр.

Коннотатив мәгънә ялгызлык исемнәренең окказиональ кулланылышында (икенчел номинациядә) тагын да ачык сизелә, чөнки бу очракта исем, үзенең төп сыйфатларын югалта төшеп, күмәклек сүзләренә якынлаша. Гадәттә, мондый төр күчеш татар милли мохитендә киң кулланыла торган, эчтәлегендә аерым күзаллаулар тудыра торган исемнәрдә ачык чагыла. Мәсәлән, *Мамай явы, Хуҗа Насретдин, Шәкүр карак, Шомбай, Мәҗнүн гыйшкы* кебек очраклар татар халкының күпчелегенә таныш. Аерым бер контекст эчендә ялгызлык исем семантик яктан киңәя, күмәклек сүзләренә хас эчке формага ия була башлый: *Гобәй белән Хобәй булу; Рамазан агай килде; Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә; Бәдигъ мәзин күркәсе; Галигә дуслыктан түгел, Могавиягә дошманлыктан; Габдулла биясе; Хуҗа Насретдин ишәге; Тыр-тыр Зариф; Сафура бураны* һ.б.

Шулай итеп, сөйләм агышында сүзләр, денотатив, сигнификатив мәгънәләр белән бергә, коннотатив эчтәлеккә дә ия булалар. Аларның бергә кулланылышы сүзнең эчке табигатен, формасын барлыкка китерә һәм сөйләм эчендә төрле семантик вариантлылыкка юл ача. Лексик мәгънә үз эчендә сөйләм эчендә ачыла ала торган барлык төр компонентларны да берләштерә, шулар ярдәмендә чынбарлык күренешләрен атап кына калмый, бәлки төгәл бәя дә бирә.

## § 12. Лексик мәгънә структурасы

Сүзнең табигатен, мәгънәсен өйрәнү шуны күрсәтә: лексик мәгънә барлыкка китерүдә лингвистик һәм экстралингвистик факторларның бергәлеге зур роль уйный. Беренче чиратта лексик мәгънә эчендә реаль чынбарлык, фикерләү, тел системасы үзенчәлекләре чагылса, болардан кала сүзнең лексик мәгънәсе кешенең эмоциональ-психологик эшчәнлеген, аталган чынбарлык күренешенә мөнәсәбәтен дә (прагматика) чагылдыра. Болар барысы бергә лексик мәгънә структурасының нигезен, компонентлы составын хасил итәләр. Компонент дип лексик мәгънәнең аерым бер факторлар тәэсирендә барлыкка килгән состав өлешен атыйлар. Югарыда аталган компонентлар **макрокомпонентлар** дип атала, чөнки алар лексик мәгънә барлыкка китерүдә төп рольне башкаралар, һәм үзләре тагын да ваграк өлешләргә – **микрокомпонентларга** таркалалар.

Һәрбер сүз әйләнә-тирә дөньяның бер өлеше белән тыгыз бәйләнештә яши, чөнки ул аларны атый, шул рәвешле лексик мәгънәдә

предмет белән бәйләнеш барлыкка килә. В.В. Виноградов лексик мәгънәнең бу аспектын «предмет-әйбер эчтәлеге» дип атый. Сүзнең предмет белән бәйләнеше түбәндәгедән гыйбарәт: лексик мәгънәдә аталган предметларның иң әһәмиятле билгеләре чагылыш таба һәм алар әлеге сүзне башкалардан аерып күрсәтә торган төп күрсәткеч саналалар. Сүзлекләрдә сүзнең нәкъ менә әлеге билгеләре төп күрсәткеч буларак билгеләнә. Мәсәлән, *балта* – агач саплы, яссы киң чөй формасындагы үткен йөзле чабып кисү коралы; *балтачы* – балта белән эш итүче оста.

Аталган предмет реаль, материаль булмаска да мөмкин, мәсәлән, абстракт төшенчәләрнең атамалары: *зәвык* – яшәештәге һәр нәрсәгә бәя бирә белү сәләте, эстетик сиземләү, эстетик тәрбия. Шулай ук аталган предмет хыялда, аңда гына яши торган фантастик образ да була: *убыр* – ут рәвешендә йөри торган рух-җан. Алдагы бүлектә лексик мәгънәнең бу үзенчәлеге *денотатив мәгънә* буларак каралды, һәм бу мәгънә сүзнең төп макрокомпонентларының берсе санала.

Предмет – мәгънә бәйләнеше турыдан-туры түгел, ә фикерләү аша бара, дидек. Сүзнең төшенчә белән бәйләнешен сигнификат дип атап, лексик мәгънә структурасының икенче әһәмиятле макрокомпоненты буларак *сигнификатив мәгънәне* аерабыз.

Лексик мәгънәнең өченче макрокомпоненты булып *структур мәгънә* тора. *Структур мәгънә* телнең лексик системасы үзенчәлекләре нигезендә барлыкка килгән лексик мәгънә микрокомпонентлары булу-булмавына бәйле ачыла.

Билгеле булганча, тел системасы, шул исәптән лексик система да, парадигматик һәм синтагматик мөнәсәбәтләр кысасында яши. Аларның һәрберсе аерым сүзгә хас индивидуаль лексик мәгънәнең компонентлы төзелешен, составын билгели. Мисал өчен, *йорт* сүзенең лексик мәгънәсендә «торак» компоненты гына түгел, «кешенең яшәү урыны» компоненты да аерыла, чөнки йортны башка торак объектларыннан аера торган төп компонент булып нәкъ соңгысы тора. Үз чиратында *йорт, корылма, торак, бина, өй* синонимнары да бер-берсеннән күләмнәре, материалы, кулланылуы белән аерылалар. Мәсәлән, *йорт* төшенчәсе «яшәү өчен, төрле оешмаларны урнаштыру өчен билгеләнгән корылма» мәгънәсен белдерә; *корылма* – «корылган киртә, каралты-кура, бина» мәгънәсендә; *торак* – яшәү, тору өчен билгеләнгән бина; *бина* –

зур йорт, архитектура корылмасы; *өй* – яшәү өчен салынган бина. Системалы парадигматик мөнәсәбәтләргә (бу очракта синонимик) бәйле, индивидуаль лексик мәгънәдә һәр компонент аерылып тора. Бу синонимнар бер-берсеннән мөмкинлекләре белән дә аерылалар. Мәсәлән, *университет бинасы, банк бинасы, театр бинасы* дип әйтү татар телендә табигый яңгыраса, шушы ук очракларда *өй* сүзен куллану лексик мәгънә бөтенлегенә зыян китерә (*университет өе, банк өе, театр өе*), ягъни бу – сүзләрнең ярашу мөмкинлекләре туры килми дигән сүз.

Сүз лексик системаның гына түгел, грамматик системаның да төп элементы санала. Шуңа күрә сүзнең грамматик төзелешендә, статусында барлыкка килгән үзгәрешләр лексик мәгънәгә дә турыдан-туры йогынты ясый. Мәсәлән, *баштан* сүзенең исем сүз төркеменә караган, чыгыш килешендә кулланылган очрагындагы мәгънәсе белән изоляцияләнеп рәвешкә күчкән очрагындагы мәгънәсе бердәй түгел. Семантик күчеш кичергән *йомгак* сүзенең *җеп йомгагы* һәм *дәрескә йомгак* очракларының да мәгънә структурасында төрлелек күзәтелә.

Лексик мәгънә сүзнең грамматик формасына бәйле дә билгеле бер дәрәҗәдә үзгәреш кичерергә мөмкин. Мәсәлән, исемнәргә һәм саннарга ялганып килгән күплек сан кушымчасын алыйк. Абстракт исемнәргә ялганып, әлеге кушымча сүзләргә конкретлык төсмерен өсти: *батырлыклар, миһербансызлыклар* һ.б. Саннарга ялганып исә, чама мәгънәсен бирә: *сәгать бишләрдә, кырык-кырык сигез яшьләр булыр, меңнәрчә йолдыз, йөзләрчә кеше* һ.б.

Шулай итеп, сүзнең лексик мәгънәсе формалашуда һәм үсүдә «предмет – төшенчә» контексты гына түгел, телнең грамматик системасы да билгеле бер дәрәҗәдә роль уйный.

Лексик мәгънә оештыруда микрокомпонентларның әһәмияте шулай ук бик зур. Сүзләрнең мәгънәсе кечкенә компонентлардан – семалардан тора. С е м а дип лексик мәгънәнең иң кечкенә компонентын атыйлар. Семалар җыелмасы мәгънәнең с е м а с т р у к т у р а с ы н барлыкка китерә. Сүзнең лексик мәгънәсенең эчтәлеген барлыкка китергән семалар реаль чынбарлыкны чагылдырган төшенчәләрнең төп билгеләре белән туры киләләр. Икенче төрле әйткәндә, сема лингвистик билгеләрне генә түгел, телдән тыш күренешләрне дә чагылдыра. Мәгънә составындагы семалар, төп һәм өстәмә семаларга бүленеп, мәгънә эчендәге эчке

бәйләнешне, сүз мәгънәсендә табылган төп мәгънәне тулыландыралар. Сүз мәгънәсендә табылган семалар берлеге с е м е м а – с ү з н е ң  э ч т ә л е г е дип атала. Семасиологиядә «семема» һәм «лексема» төшенчәләре аерып күрсәтелә. Семема дигәндә, беренче чиратта сүзнең аерым бер очракта кулланылган мәгънәсен күзаллыйлар. Л е к с е м а дигәндә исә, семемалар җыелмасы күздә тотыла. Аларның һәр икесе сүзнең тулаем табигатен барлыкка китерә. Мәсәлән, *күз* сүзен лексема буларак характерласак, аның барлык мәгънәләрен: *күрү органы, караш, билгеле бер мөнәсәбәт, кемнең дә булса игътибары, күзәтүче, ризыклардагы кечкенә тишек, күзәнәк, җептән гыйбарәт элмәк, нәрсәнең дә булса уртасы* кебек мәгънәләренең җыелмасын күз алдында тотабыз. Семема буларак караганда, һәр аерым очракта бер мәгънәнең кулланылуын аерабыз. Мәсәлән: *Шунда тамсын* ***күз яшемнең*** *иң ачы һәм татлысы!* (Г. Тукай); *Әнкәйләрнең нечкә күңелләрен* ***күз карасы*** *кебек саклагыз!* (Р. Миңнуллин); *Сайлаган җебегез белән ничә* ***күз бәйләргә*** *кирәклеген каян белерсез тагын?* («Сөембикә» журналы)

Сүз мәгънәсендәге семалар иерархик структурага ия. Алар арасында гомуми, әһәмиятлеләре һәм сүзне башкалардан аерып тора торганнары була. Сүз мәгънәсендәге семаларны анализлаганда, барлык төр семаларның үзенчәлекләре, аларның аерым бер сүзне барлыкка китерү үзенчәлекләре, бер сүзнең төрле мәгънәләрендәге һәм башка сүзләр белән бәйләнешне булдырудагы үзенчәлекләре исәпкә алына. Иерархик система буларак караганда, семема структурасын ике төрле тасвирлап була. Беренчесе – семеманы тулысынча тасвирлау, ягъни лексик һәм грамматик мәгънәләрнең эчтәлеген тудырган семаларга анализ. Икенчесе – өлешчә тасвирлау, ягъни семеманың лексик мәгънә семаларын гына анализлау.

Сүзне тулы бер семантик система рәвешендә караганда, семеманың тулы составын тикшерү отышлы санала, чөнки бу очракта парадигматик, синтагматик һәм эпидигматик мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүен тулы бер картина рәвешендә күзалларга җиңел.

Семемага тулы анализ түбәндәге сема типларын берләштерә: **классема** – лексик-грамматик мәгънәнең гомумкатегориаль семасы. Ул – сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын искәртә. Мәсәлән, предметлык мәгънәсен белдергән сүзләр исем сүз төркеменә карый, эш-хәрәкәт мәгънәсенә ия сүзләр фигыль сүз төр-

кеменә керәләр һ.б. предметлык, процесс, билге кебек мәгънәләр гомуми, абстракт грамматик сема буларак күрсәтеләләр.

**Лексограммема** – лексик-грамматик сема, ул сүз төркемнәренең лексик-грамматик төркемчәләрен күрсәтә: исемдә матдә, предмет, абстрактлык, җыелмалылык, конкретлык; сыйфатта асыл яки нисби төркемчәгә карау; фигыльдә аспектуальлек, юнәлеш һ.б.

**Гиперсема** яки **архисема** – объектларның төркемен: табигать күренешләре, кеше, төс, кешенең эчке һәм тышкы сыйфатлары, хәрәкәт фигыльләре һ.б.ны белдерә.

**Гипосема** – бер предметны шул ук төркемдәге икенче предметтан аера торган, аларның үзгә сыйфатларын күрсәтә торган дифференциаль билге. Мәсәлән, *каен, усак, карлыган* сүзләре предметлык классемасына; предмет лексограммема; үсемлек гиперсемасына керәләр, аларның гипосемалары: *каен* – яфраклары йөрәксыман ак тузлы зур үсемлек (агач*); усак* – шома кайрылы, киртләч яфраклы зур үсемлек (агач); *карлыган* – эчкелтем җимешле куак үсемлек.

Югарыда аталган төп семалардан кала, лексик мәгънә эчендә өстәмә семалар да була ала. Тел белемендә аларны факультатив, периферик семалар дип атап йөртү бар. Бу төркемгә коннотатив, потенциаль һәм ихтималлык семалары керә.

**Коннотатив** сема – өстәмә стилистик (эмоциональлек, бәяләү, экспрессивлык) эчтәлек ул. Мәсәлән, *Алар матур гына гөрләшеп утыралар* җөмләсендә *гөрләшү* – якын кешеләрнең үзара сөйләшүе (уңай коннотация); *Әй гөмбә! Шуны да белмисең!* контекстында *гөмбә* аңгыра яки җебегән кешегә карата әйтелә (тискәре коннотация).

**Потенциаль** сема – конкрет бер контекстта ачыла торган мәгънә компоненты: *Яраланган канат асларында* ***каурый бала*** *– йөрәк парәсе* (Б. Рәхимова) мисалында *каурый бала* – «кечкенә, күкрәк сабые» мәгънәсен бирә. *Бу* ***йорттагы*** *бәхет, үзара аңлашып яшәү күпләргә билгеле иде* (Вакытлы матбугаттан) җөмләсендәге *йорт* сүзенең лексик мәгънәсендә *гаилә* потенциаль семасы ачыла.

Факультатив семаларның тагын берсенә – конкрет бер текст кысаларында сүзләрнең окказиональ бәйләнеше нигезендә ачыла торган **ихтималлык семасына** тукталып үтү кирәк. Мондый төр сема телдә киң таралыш тапмый, бәлки аерым сөйләм ситуациясендә генә ачыла ала. Мисал өчен, Г. Тукай иҗатында кулланылган

*ага* фигылен карыйк. *Безнең урам аркылы* ***ага*** *суның салкыны* мисалында *ага* фигыленең мәгънәсен гипосема буларак аерсак, *Китмәсен алып тургайны, күктә бер козгын* ***ага*** мисалында исә *ага* сүзендә ихтималлык семасы ачыла.

Сememага өлешчә анализ вакытында, нигездә, лексик мәгънә семаларын (гиперсема, гипосема, коннотатив, потенциаль һәм ихтималлык семалары) аеруны гына күздә тота.

Сүз мәгънәсендә табыла торган *интеграль*, ягъни сүзнең барлык мәгънәләре өчен уртак семалар һәм һәрбер мәгънәне башкалардан аера торган *дифференциаль* семалар төрле сүзләрне бер-берсеннән аерырга, шул ук вакытта уртак якларны,тәңгәллекләрне күзалларга ярдәм итә.

Шулай итеп, семема (сүзнең мәгънәсе, эчтәлеге) үзара тыгыз бәйләнгән, бер-берсен тулыландыручы буыннардан торган иерархик төзек сема структурасыннан гыйбарәт. Әлеге семалар сүз мәгънәсенең киңәюен, күчүен барлыкка китерүдә төп рольне башкаралар. Күчерелмә мәгънә ясалган вакытта, архисема һәм дифференциаль семалар әһәмиятләрен беркадәр югалтса, потенциаль семаларның исә, киресенчә, әһәмиятләре арта, алар дифференциаль сема вазифасын үти башлыйлар.

## § 13. Функцияләре буенча лексик мәгънәләрнең типларга бүленеше

Тел белемендә сүз мәгънәсен ачыклау нинди яссылыкта булуына карап, лексик мәгънәне төрле типларга аерып өйрәнәләр. Беренчеләрдән булып әлеге мәсьәлә академик В.В. Виноградов тарафыннан игътибар үзәгенә алына. Аның 1977 елда «Основные типы лексических значений слова» хезмәте (Виноградов, 1977: 162–189) басылып чыга, соңрак әлеге хезмәттә бирелгән төркемләү башка галимнәрнең хезмәтләрендә тулыландырыла; аңа, кайсы яктан төркемләүгә карап, өстәмәләр кертелә. Нәтиҗәдә төрле параметрлар нигезендә лексик мәгънәнең берничә тибы аерылып карала башлый. Рус теле лексикологиясе һәм семасиологиясеннән басылып чыккан хезмәтләрдә, дәреслекләрдә лексик мәгънәнең типларын билгеләүдә бераз төрлелек күзәтелсә дә, төп аеру критерийларында билгеле бер дәрәҗәдә тотрыклылык саклана. Рус тел белемендә очрый торган кайбер төркемләүгә тукталып үтик:

1) сүзнең атау (номинатив) функциясе буенча лексик мәгънә тибын туры һәм күчерелмә мәгънәләргә бүләләр[1]. Кайбер хезмәтләрдә бу төркемгә кергән типларны чынбарлык белән мөнәсәбәттә аералар (Фомина, 2001: 45). Шулай ук бу төр бүленешне денотат белән бәйле аеру да очрый (Рублёва, 2004: 62);

2) мотивлашу дәрәҗәсенә карап, мотивлашмаган һәм мотивлашкан мәгънәләр була;

3) лексик ярашу (синтагматик) принцибы буенча ирекле һәм бәйле мәгънәле сүзләр аерыла.

Соңрак басылып чыккан хезмәтләрдә бу төркемләүне тагын да тулыландыру, конкретлаштыру күзгә ташлана. Мисал өчен, О.Л. Рублёва тарафыннан эшләнгән дәреслектә лексик мәгънә типларының унике төре аерыла.

Татар теле лексикологиясе буенча басылган хезмәтләрдә, башлыча дәреслекләрдә, лексик мәгънә типларын аерып бирү Ф.С. Сафиуллинаның дәреслегеннән башлана (Сафиуллина, 1999: 15), гәрчә Г.Х. Әхәтовның «Хәзерге татар теленең лексикологиясе» дәреслегендә дә (Әхәтов, 1979; 1985) туры һәм күчерелмә, абстракт, конкрет мәгънәләр аерылып күрсәтелә.

Ф.С. Сафиуллина үзенең мәгълүм дәреслегендә лексик мәгънә типларыннан чынбарлыктагы әйбер яки күренешләргә мөнәсәбәтле рәвештә атау һәм сигнал, туры һәм күчерелмә, конкрет һәм абстракт мәгънәләргә зур игътибар бирә, аларның төп үзенчәлекләрен бәяли. Икенче тип буларак, аңга (фикерләүгә) мөнәсәбәтле терминологик һәм гомуми, образсыз һәм образлы, эмоциональ һәм эмоциональ булмаган мәгънәләрне күрсәтә. Тел структурасындагы лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап, синонимик, антонимик, монолексик һәм омонимик, мотивлашкан һәм мотивлашмаган, нигез һәм ясалма мәгънәләрне аера. Лексик мәгънә типларыннан Ф.С. Сафиуллина тагын ирекле һәм бәйле, вакытлы мәгънә типларына да туктала.

Г.Р. Галиуллинаның татар теле лексикологиясе буенча кулланмасында һәм уку-укыту әсбабында (Галиуллина, 2007; 2013: 13)

---

[1] Бүленешне түбәндәге хезмәттән алдык: Современный русский язык: Теория. Анализ языковых единиц: учеб. для студ. высш. учеб. заведений: в 2 ч. / Е.И. Диброва, Л.И. Касаткин, Н.А. Николина и др.; под ред. Е.И. Дибровой. М.: Академия, 2001. Ч. 1: Фонетика и орфоэпия. Графика и орфография. Лексикология. Фразеология. Лексикография. Морфемика. Словообразование. С. 217.

лексик мәгънәнең атау функциясе буенча, лексик ярашу принцибы буенча, мотивлашу дәрәҗәсе буенча өч тибы аерылып, алар үз эчендә тагын да төгәлрәк төркемчәләргә бүленә.

Татар теле семасиологиясенә багышланган беренче монографик хезмәтләр, алда әйтеп үтелгәнчә, И.Б. Бәширова тарафыннан эшләнде. Аның «Татар әдәби теле. Семасиология» (Казан, 2010) хезмәтендә лексик мәгънә типларына аерым урын бирелә (Бәширова, 2010: 20–30). Галимә, рус тел белемендәге В.В. Виноградов классификациясенә нигезләнеп, өч мәгънә тибын аера: номинатив, лексик тип; сүзләрнең фразеологик тезмәләрдәге мәгънә тибы; функциональ-синтаксик мәгънә тибы (Бәширова, 2010: 20–21). Шулай ук автор рус тел белемендә XX гасырда басылып чыккан хезмәтләргә күзәтү ясый, лексик мәгънә үзенчәлекләрен күрсәтә, шулай ук конкрет, абстракт мәгънәле сүзләрнең сыйфатларына туктала.

Без, югарыда саналган хезмәтләргә, шулай ук хәзерге тел белеме казанышлары нигезендәге өстәмәләргә нигезләнеп, түбәндәге лексик мәгънә типларын аеруны кулай күрдек.

**1. Атау (номинатив) функциясе буенча лексик мәгънә тибы.** Сүзнең номинатив функциясе ягыннан мәгънә тибын аеру өчен, төп җирлек булып сүз мәгънәсенең реаль чынбарлык, ягъни денотат белән бәйләнеше тора. Кайбер хезмәтләрдә лексик мәгънәнең бу тибын денотатив лексик мәгънә тибы дип аерып карау да очрый. Бу яссылыкта лексик мәгънәнең өч тибы – туры һәм күчерелмә мәгънәләр, атау функциясенә ия булмаган сигнал мәгънәләр аерыла.

Сүзнең т у р ы  м ә г ъ н ә с е дип чынбарлыктагы предмет, күренеш, процессның, билгенең турыдан-туры атамасын әйтәләр. Бу мәгънә төшенчә, аның аерым билгеләре белән туры бәйләнештә тора. Аны б е р е н ч е л ,  т ө п мәгънә дип тә атап йөртәләр. Туры, төп мәгънә төгәл мәгънәви чикләргә ия, мәгънә үсешендә беренчел дигән термин белән дә аталып йөртелә, чөнки мәгънә киңәйгәндә, үскәндә, ул төп функцияне башкара. Сүзнең беренчел, төп мәгънәсе мәгънә төсмерләре һәм күренешләре өчен төп таяныч, иҗтимагый кабул ителгән нигез булып тора. Мәсәлән, *тел* сүзенең *умырткалы хайваннар һәм кеше авызындагы тәм тою, тәм сизү һәм чәйнәү-кушәүгә булышу органы* (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 528) мәгънәсе әлеге сүзнең калган ундүрт мәгънәсе өчен нигез вазифасын башкара.

К ү ч е р е л м ә  м ә г ъ н ә дип төрле күзаллаулар, чагыштырулар, ассоциацияләрдә туган, алар нигезендә төрле предмет күренешләрне берләштергән мәгънә атала. Күчерелмә мәгънә денотат белән турыдан-туры түгел, беренчел мәгънә аша бәйләнә. Чагыштырулар, күзаллаулар нигезендә ике предмет, күренеш арасында охшашлык туа. Әлеге охшашлык бер предмет атамасын икенчегә күчерергә мөмкинлек бирә, шунлыктан бу төр мәгънәне и к е н ч е л дип тә атыйлар. Икенчел, күчерелмә мәгънәне метафорик, метонимик, синекдохик төрләргә бүлеп карыйлар[1].

Шуны искәртү кирәк: телнең лексик составына бәйле сүздә беренчел, икенчел мәгънәләрне аеру синхроник планда лексиканы тикшергәндә генә объектив санала, чөнки хәзерге телдә беренчел саналган мәгънәләрнең кайберләре, диахроник яссылыктан тикшергәндә, икенчел булырга мөмкин. Телдә төп, беренчел мәгънә белән бәйләнеш вакыт үтү белән өзелергә мөмкин, мәсәлән, *ай* сүзенең *күк җисеме* һәм *вакыт берәмлеге* очраклары кайчандыр мәгънәви бәйләнештә яшәсәләр, хәзерге татар телендә ике мөстәкыйль мәгънәгә ия булган, икесе дә беренчел мәгънәдә кабул ителгән берәмлекләр санала. Мондый күчешне хәзерге тел мисалында да күзәтергә мөмкин, гадәттә, образлылыгын югалтып, тел метафорасы буларак аерыла торган күчерелмә мәгънә төрләре шундый күчеш алдында торалар дияргә җирлек бар, мәсәлән, *тел* сүзенең *сәгать теле* очрагы; *кой* фигыленең *су коям, яңгыр коя* очракларында күчерелмә мәгънәгә хас образлылык югалып бара.

С и г н а л  м ә г ъ н ә дип төшенчә атамасы булмаган, бары тик аңа ишарә генә итә торган мәгънә (алмашлык, ялгызлык исемнәр, ярдәмлек сүзләр, ияртемнәр, ымлыклар). «Сүзнең функцияләре» темасында без бу төр сүзләрнең табигатьләренә җентекләп туктылган идек, шунлыктан биредә санап үтү белән чикләнәбез.

Шулай итеп, атау (номинатив) функциясе ягыннан лексик мәгънәнең өч тибы аерыла: туры һәм күчерелмә мәгънәләр һәм сигнал мәгънәләр. Күчерелмә мәгънәләр үз чиратында образлы һәм образлылыгын югалткан төрләргә бүленәләр.

**2. Сигнификат белән мөнәсәбәттә лексик мәгънә тибы.** Сүзнең әлеге функциясе ягыннан мәгънә тибын аеру өчен, төп җирлек булып мәгънә – төшенчә мөнәсәбәте тора. Гәрчә бу төр сүзләр

[1] Алар алга таба күпмәгънәлелек күренешенә бәйле бүлектә тулырак карала.

номинатив характерда, атау функциясенә ия булсалар да (шунлыктан кайбер хезмәтләрдә әлеге сүзләр беренче тип кысасында каралалар), аларның төп билгесе булып сигнификат белән бәйләнеш алгы планга чыга. Әлеге үзенчәлек ягыннан конкрет һәм абстракт, гомуми (көнкүреш) һәм фәнни (терминологик) мәгънәләр аерыла.

Конкрет мәгънә дип күренешләрне барлык билгеләре белән тулысынча күзаллап, тоеп, сизеп була торган сүзләр мәгънәсен атыйлар. Мәсәлән: *зур өстәл, яшел кыяр, җиңел машина, абый бара, яңгыр ява.*

Абстракт мәгънә ул – төшенчәнең бер үзенчәлекле сыйфаты буенча гына күренешләрне гомумиләштерә торган мәгънә: *фикерләү, сафлык, аклык, батырлык, җитмәүчәнлек*[1].

Гомуми (көнкүреш) мәгънә – кешеләрнең реаль чынбарлык турындагы гомуми, беренчел күзаллаулары нигезендә туган мәгънә. Бу төр сүзләрнең көнкүрештә кулланыла торган мәгънәләрендә реальләшәләр һәм аларда наив дөнья картинасы чагылыш таба. Гомуми мәгънәләрдә төшенчә өстәмә төсмерләр нигезендә баетыла.

Фәнни (терминологик) мәгънә дип көнкүреш фикерләү нигезендә барлыкка килгән һәм фәнни төшенчәләрдә реальләшкән мәгънәләрне атыйлар. Бу төр мәгънә төшенчәгә тәңгәл килә: *сингармонизм, квант, атом, тартымлы исем, инфинитив* һ.б.

Гомуми мәгънәләр телнең аңлатмалы сүзлегендә теркәлсә, терминологик мәгънәләр терминнар сүзлегендә яки энциклопедик сүзлекләрдә урын ала. Мәсәлән, *Тоз* – 1) *Аш тозы; ашамлыкны тәмләтү өчен кулланыла торган ак кристаллик матдә;* 2) хим. *Кислотадагы водород урынына берәр металл урнашу нәтиҗәсендә барлыкка килә торган кристаллик матдә;* 3) күч. *Сүзгә әчтәлек үткенлеге бирә торган мәгънә яки фикер.* Әлеге мисалда беренче һәм өченче мәгънәләр гомуми булса, икенче мәгънә фәнни мәгънә булып килә. Гомуми мәгънә телдә сөйләшүче һәркем өчен индивидуаль кабул ителсә, терминологик мәгънә объектив кабул ителә.

**3. Мотивлашу дәрәҗәсе буенча лексик мәгънә тибы.** Сүз мәгънәсенең әлеге тибын аеру сүзнең ясалган булу-булмавына бәйле аерыла. Телдәге сүзләрнең бер төркеме бүтән берәмлекләр өчен ясагыч нигез вазифасын башкарса, икенчеләре исә баш-

[1] Тулырак «Сүзнең функцияләре» бүлегеннән кара.

ка берәмлекләр нигезендә барлыкка киләләр. Телдә сүзләр ясалу ике төрле була: семантик һәм сүз ясалышы ысуллары нигезендә. Башка сүзләр ясалу өчен җирлек, нигез булган мәгънәне беренчел, мотивлашмаган мәгънә дип атыйлар. Мотивлашмаган мәгънәне аңлату өчен, икенче мәгънәгә мөрәҗәгать итеп булмый.

Мотивлашкан мәгънә дип икенчел, семантик яисә сүз ясалышы буенча мотивлашкан, ясалган мәгънәне атыйлар. Мәсәлән, *йомгак* сүзенең мәгънәләренә игътибар итик: 1) җеп чорнавы; 2) эш нәтиҗәсе; 3) буталчык нәрсәләр. Биредә икенче һәм өченче мәгънәләр беренче мәгънәгә карата мотивлашкан саналалар. Аеруча икенче мәгънәнең беренче мәгънәгә бәйләнеше көчле. Бу мисалда семантик мотивлашу очрагын күрдек, шулай ук сүз ясалышы ягыннан мотивлашу да телдә киң таралган, мәсәлән, *йомгаклау* сүзе *йомгак* сүзенә карата сүз ясалышы яссылыгында мотивлашкан санала. Үз чиратында *йомгак* сүзе тарихи планда шушы ук яссылыкта мотивлашкан, әмма хәзерге татар теле күзлегеннән караганда, бу сүз мотивлашмаган буларак каралырга хаклы, чөнки хәзерге телдә мотивлаштыручы нигез яки мәгънә белән турыдан-туры бәйләнешне ачыклау авыр.

**4. Лексик ярашу принцибы буенча лексик мәгънә тибы.** Бу типны сүзләр арасындагы синтагматик мөнәсәбәтләр нигезендә барлыкка килгән мәгънә буларак та карыйлар. Әлеге тип буенча лексик мәгънәне аерып чыгару сүз мәгънәсенең контекстта башка сүзләр белән бәйләнешкә керү киңлегенә нигезләнә. Сүзнең лексик мәгънәсе, гадәттә, контекст, ягъни башка сүзләр әйләнәсендә реальләшә. И.Б. Бәширова татар лексикасында синтагматик бәйләнеш-мөнәсәбәтләр турында язганда, «тар» һәм «киң контекстлар» төшенчәләренә туктала һәм, О.С. Ахманова билгеләмәсенә нигезләнеп, аларның асылын аңлата (Бәширова, 2010: 94). Галимә синтагматик мөнәсәбәтләр киң контекстка бәйле барлыкка килә дигән фикердә тора. Без, зур әдәби әсәрләрдә (киң контекстта) мәгънә үзенчәлеген аңлатуны үзмаксат итеп куймыйча (бу күбрәк поэтика кысаларында карала), саф семасиологик планда сүз мәгънәсенең контекст эчендә ачылуын караячакбыз.

Сүзнең башка сүзләр белән мөмкин кадәр иркле яраклашкан, контексттан азат мәгънәсе иркле мәгънә дип атала. Мәсәлән, иркле мәгънәле сүзләр рәтендә телдә актив кулланыла торган *күз, баш, урман, чәчәк, малай, китап, чәй* һ.б. сүзләрне

кертеп була. Әмма шуны искәртү кирәк: лексик мәгънәнең ирекле булуы чагыштырмача шартлы, чөнки теләсә кайсы сүз мәгънәсенең башка сүзләр мәгънәсе белән чикләре бар. Бу – төшенчәләрнең туры килү-килмәвенә бәйләнгән, мәсәлән, *аяк* сүзе *матур, ямьсез, төз, юан, зур, кечкенә, авырта, сызлый* һ.б. шундый берничә сүз белән иркен яраклаша, әмма *көлә, елый, ашый, куе, сирәк* һ.б. сүзләрнең мәгънәләре белән *аяк* сүзенең мәгънәсе яраклаша алмый.

Синтагматик чиклелек берничә төрле була:

1) лексик ярашу ягыннан чиклелек ике яки берничә сүзнең үзара яраша алуына бәйле. Югарыда китергән мисал моны ачык чагылдыра;

2) семантик ярашу ягыннан чиклелек, мәсәлән, *туры* сүзе, номинатив мәгънәдә килгәндә, «төз», «кыска», «якын» мәгънәләре белән генә кулланыла: *туры сызык, туры юл;* күчерелмә мәгънәдә исә «дөрес», «ачыктан-ачык», «намуслы» мәгънәләрен белдергән сүзләр белән яраклаша: *туры кеше, туры сүз, туры эш* һ.б.;

3) синтаксик ярашу ягыннан чиклелек, мәсәлән, *төз* сыйфаты, нигездә, исем сүз төркеменә кергән сүзләр белән генә очрый: *төз гәүдә, төз аяк* һ.б.

Бәйле мәгънә дип башка сүзләр чолганышында гына тулысынча аңлашылган, контекстка бәйле мәгънәне атыйлар. Сүзнең контекстта куллана алу-алмавы аның семантик валентлылыгына бәйле була. Билгеле булганча, сүзләрнең мәгънәсе бары тик контекст эчендә генә тулысынча һәм төгәл ачыла ала. В.В. Виноградов бәйле мәгънәнең ике төрен – фразеологик һәм синтаксик бәйлелекне аера (Виноградов, 1977: 186).

Фразеологик бәйле мәгънә дип сүзнең чикләнгән даирәдә ике яки берничә сүз белән бергә килеп, бер мәгънә бирүдә катнашуын атыйлар. В.В. Виноградов билгеләвенчә, фразеологик бәйле мәгънә тотрыклы мәгънәви үзәккә ия түгел. Гомуми предмет-логик үзәк ирекле мәгънәдәге кебек ачык чагылмый, шулай ук мәгънәдә чынбарлык белән бәйләнеш тә бераз юыла төшә (Виноградов, 1977: 186). Билгеле бер дәрәҗәдә моның сәбәбе сүзнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуына бәйле. Мәсәлән, *еру* сүзенең «көлү» мәгънәсе *авыз еру* фразеологизмында гына ачыла; *кагу* фигыленең «югалту» мәгънәсе *колак кагу* контекстында гына барлыкка килә һ.б.

Теге яки бу бәйле мәгънәле сүз янында туплана торган һәм фразеологик төркем барлыкка китерә торган сүзләрнең күләме,

семантик потенциягә һәм предмет-мәгънә бәйләнешенә карап, бердән алып дистәгә якын булырга мөмкин. Мәсәлән: *салындыру* (*авыз, борын, баш, каш*); *ачу* (*карын, корсак, тамак*); *кот* (*чыгу, очу, ботка төшү*) һ.б.

Синтаксик бәйле мәгънә – аерым бер синтаксик позициядә генә реальләшә торган мәгънә. Гадәттә, телдә кабул ителгән типик синтаксик функциясеннән читкә китеп, аерым синтаксик конструкцияләрдә калыплашкан мәгънәләрне бу төркемгә кертеп карыйлар, мәсәлән, *Мин бик шат* конструкциясендәге *шат* сүзе хәбәр функциясендә килә, гәрчә сыйфат сүз төркеменә караган бу сүзнең киң таралган функциясе аергыч, кайбер очракларда хәл була. Күчерелмә мәгънәдә кешене атау өчен кулланыла торган хайван атамалары да җөмләдә күбрәк хәбәр, эндәш сүз функцияләрен башкара: *Аһ,* ***көчек****! Авызыннан ана сөте кипмәгән, үз әтисенә фәлсәфә сата бит…* (М. Галәү); *Быел укытучы юклыктан узган елда укытылмаган тарих фәне керә башлады. Укытучы –* ***күркә****!* (М. Мәһдиев); *Колак янында гына Әркәшә – мин уйнаганны карап тора. Лыч-лыч ипи чәйни,* ***дуңгыз****.* (М. Мәһдиев) *Көчек, күркә, дуңгыз* сүзләренең туры мәгънәсе җөмләдә ия, тәмамлык булганда реальләшә.

**5. Башкарган функциягә (прагматик аспект) бәйле лексик мәгънә тибы.** Бу юнәлештә ике төркем аерыла: номинатив мәгънәләр, ягъни предмет, күренеш, процесс һ.б. атау өчен кулланылган мәгънә. Әлеге мәгънә төшенчә белдерү үзлегенә бәйле ачыла. Бу төр мәгънә тибы беренче (номинатив) тип белән охшаш, әмма телдә сүзләрнең мәгънәләре атау функциясен генә башкарып калмыйлар, бәлки өстәмә төсмерләр дә алалар.

Сүз мәгънәсенең төп үзенчәлеге булып коннотация, экспрессив-бәяләү төсмере алгы планга чыккан очраклар экспрессив-синонимик мәгънәләр дип атала. Теләсә кайсы синонимик ояда без, предметларны атаудан тыш, төрле хис-тойгы белдергән сүзләрне дә очратабыз. Мәсәлән, *тузыну – дулау, пырдымсызлану, чәпчү, пыр тузу.* Бу сүзләрнең лексик мәгънәләре атау функциясен генә башкармый, ә сөйләүченең сөйләү объектына төрле бәясен дә белдерәләр. Бирелгән синонимик оядагы сүзләрнең мәгънәләрендә иң беренче чиратта бәяләү төсмере алга чыга. Сүзлекләрдә эмоциональ-экспрессив мәгънәле сүзләрнең күбесе аерым лексик берәмлек буларак теркәләләр, мәсәлән, *лыгырдау, лыкырдау, лыгыр-лыгыр; быгырдау, быгырдык, быгыр-быгыр, быдырдау,*

*быдырдык, быдыр-быдыр* (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 100, 348) һ.б. – *сөйләү/сөйләшү* сүзләренең мәгънәләренә бәйле, биредә коннотатив мәгънә беренче, төп функцияне башкара. Татар телендә сөйләшүчеләр өчен алар беренче чиратта атау мәгънәсе буларак кабул ителәләр.

**6. Тел һәм сөйләм мөнәсәбәтенә бәйле *виртуаль* (тел) һәм *актуаль* (сөйләм, ситуатив, контекстуаль) мәгънә типлары** да аерыла. Бу очракта аерым бер сүзнең телдә кабул ителгән төп мәгънәсе һәм аның нигезендә барлыкка килгән һәм сөйләм процессында актуальләшә торган башка мәгънәләре күзаллана.

**7. Телдә кабул ителгән нормага бәйле узуаль,** ягъни халык тарафыннан кабул ителгән, гомумтел мәгънәсе һәм **окказиональ**, ягъни индивидуаль, аерым бер авторга хас **мәгънә типлары** аерыла. Мәсәлән, *Дулкыннардай ярсу хисләрем, диңгезләрдә калсам нишләрем? Зәңгәр ялкын булды бөтен су – диңгез яндыра бит йөрәгем* (Б. Рәхимова) мисалындагы *зәңгәр ялкын* очрагы телдә кабул ителгән *кызыл, сары ялкын* очракларыннан индивидуаль, авторныкы булу белән аерыла. Шулай ук *Хәрәкәт, тереклек инде бөреләр дөньясында. Яшел йолдызлар кабына агачлар арасында.* (Р. Миңнуллин) мисалындагы *яшел йолдыз* очрагы да татар телендә гомум кабул ителгән *ак йолдыз, сары йолдыз, якты йолдыз* очракларыннан үзгә позициядә тора.

## Хәзерге татар теленең лексик-семантик системасы

### § 14. Тел берәмлекләре җыелмасы буларак лексик-семантик система

Тел берәмлекләре аерым-аерым гына яшәмиләр, бәлки, тулы бер система буларак, бер-берсе белән бәйләнештә, бер-берсенә керешеп яшиләр. Тел системасы кысаларында тел берәмлекләренең яшәү үзенчәлекләрен өйрәнгәнче «система» төшенчәсенә билгеләмә биреп үтү кирәк.

С и с т е м а дип эчке яктан үзара бәйләнгән, бер-берсе белән тыгыз, тотрыклы мөнәсәбәттә торган берәмлекләр җыелмасын атыйлар. Система булсын өчен, түбәндәге өч шартның үтәлүе мөһим:

1) берәмлекләрнең эчке оешканлыгы (иерархия);
2) берәмлекләрнең шартлылыгы;
3) берәмлекләрнең үзара бәйле булуы.

Тел системасы сүзе үзара эчке бәйләнештә торган һәм бер-берсе белән тотрыклы инвариант мөнәсәбәтле берәмлекләр җыелмасын белдерү өчен кулланыла. Системалы мөнәсәбәтләр телнең фонетик, лексик, грамматик катламнарында күзәтелә, ягъни тел берәмлекләре һәрвакыт билгеле бер система кысасында яшиләр, шул система эчендә төрле мөнәсәбәтләргә керәләр.

Телнең семантик катламы тәртипсез, бер-берсе белән бәйләнмәгән элементлардан түгел, киресенчә, берәмлекләре арасында тыгыз һәм тәртипкә салынган бәйләнеш-мөнәсәбәтләрдән торган ныклы система хасил итә. Нәкъ шул бәйләнешләрне күздә тотып, белгечләр «лексик-семантик система» төшенчәсенең асылын ачарга омтылалар.

Тел белемендә лексик система турында тотрыклы фикерләр XX гасыр урталарыннан күренә башлый. Рус һәм Ватан тел белемендә В.В. Виноградов, Д.Н. Шмелёв, Ю.Д. Апресян һ.б. күренекле галимнәрнең хезмәтләрендә лексикадагы системалы мөнәсәбәтләрне махсус өйрәнү күзәтелә. Татар тел белемендә телне тулы бер система буларак карау фонетика, грамматика юнәлешләрендә язылган хезмәтләрдә XX гасырның икенче яртысыннан даими әйтелеп килсә дә, лексикадагы системалы мөнәсәбәтләрне махсус өйрәнү XXI гасыр башында гына очрый башлады (Бәширова, 2006).

Телнең лексик-семантик системасы дип үзара мөнәсәбәттә яшәгән һәм тулы бер бөтен хасил иткән лексик берәмлекләр җыелмасын атыйлар. Лексик-семантик системаның төп элементы булып аерым бер мәгънәдә кулланылган сүз (лексик-семантик вариант) тора. Сүз чынбарлыктагы күренеш һәм әйберләрне атый, дидек, һәм шул сыйфаты аша сүз реаль тормышның системалылыгын турыдан-туры чагылдыра. Лексик-семантик система хасил булсын өчен, бу сыйфат төп билгеләрдән санала. Сүз – төгәл системалардан торган, чынбарлыкны чагылдыра торган төп чара. Сүзләр ярдәмендә реаль тормыш-көнкүрешне чагылдыра алырга сәләтле формалар, берәмлекләр, мәгънә төрләре формалаша. Үз чиратында сүзнең лексик мәгънәсе (семема) төрле семалар җыелмасын берләштерә. Шулай итеп, лексик-семантик системаның иң кечкенә берәмлеге булып сема тора.

Телнең лексик-семантик системасы үз эченә ике үзлекне, ике системаны берләштерә: беренчедән, ул – эчтәлек, икенчедән, шул эчтәлекне бирергә сәләтле лексик берәмлекләр җыелмасы.

Лексик-семантик системаның телнең фонетик, грамматик системаларыннан аермасын билгеләп үтү зарур, чөнки аталган системаларның чикләре анык, төгәл, ә лексик-семантик система билгеле бер дәрәҗәдә күзгә ташланмый, аның чикләрен төгәл билгеләп булмый. Әгәр фонетик, грамматик система составындагы берәмлекләр билгеле бер дәрәҗәдә калыплашкан, тотрыклы, үзгәрешләргә бирешмәс булсалар, лексик-семантик система экстралингвистик тәэсирләргә бирешүчән, динамикада булуы белән аерылып тора. Мисал өчен, XX гасырның ахырында җәмгыятьтә булган үзгәрешләр телнең лексик-семантик системасына шактый сүзләрнең семантик яктан үзгәрүе белән бергә, лексик составның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрешенә дә китерде.

Тагын бер үзенчәлек: тел системасы составындагы лексик берәмлекләр аерым, бикләнеп яшәмиләр, ә башка берәмлекләр белән охшашлык, тәңгәллек, капма-каршылык мөнәсәбәтләре нигезендә бәйләнгән тел системасының элементлары саналалар. Һәрбер берәмлек аерым бер семантик кыр составында яши һәм үз чиратында үзара бәйләнгән һәм керешкән башка кырлар составындагы берәмлекләр белән бәйләнешкә керә. Үзара бәйләнешкә кергән берәмлекләрнең һәм мәгънәләрнең уртак һәм аермалы якларын билгеләү өчен, аларны оппозициягә куеп карарга кирәк, сүзләрнең контексттагы позицияләрен ачыклау зарур, шул очракта гына аларның төп үзлекләрен һәм кулланылу мөмкинлекләрен аңларга мөмкин.

С ү з н е ң с е м а н т и к п о з и ц и я с е дип күп мәгънәле сүзнең аерым бер мәгънәсе кулланыла алуга этәргән шартларны атыйлар. Семантик яктан ике төрле позиция аерыла: көчле позиция – сүзнең мәгънәсен төрлечә аңлауга юл калмау, ачык, конкрет рәвештә күренеп тору, башка сүзләр белән киңлеге: *Мин ашка тоз салдым* – аш тозы турында сүз баруы тулысынча аңлашылып тора. *Авылга капчык белән тоз китерделәр.* Әлеге контекстта аш тозымы, әллә силитра, минералмы икәнлеге анык түгел. Бу очракта көчсез семантик позиция барлыкка килә, ягъни мәгънә конкрет аерылып тормый, күп мәгънәле сүздә мәгънә дифференциациясе барлыкка килми, эчтәлегендә билгелелек сизелми, әлеге очракта, мәгънәне аңлау өчен, башка сүзләр дә җитми. Тагын бер мисал: *Югарыда яшәп туйдым, җиргә төшәргә кирәк.* Биредә *җир* сүзендә кайсы мәгънә: чынбарлыкка күз ачылумы, әллә йортның аскы катына яшәргә төшәргә омтылумы икәнлеген аңлап булмый.

Лексик-семантик системаны телнең башка системаларыннан аера торган тагын бер әһәмиятле як булып лингвистик һәм экстралингвистик факторларның нәкъ әлеге системада кисешүе тора. Чынбарлыкның һәр яктыртылган сыйфаты тел берәмлегендә чагылыш таба, әмма сүз яки мәгънә кысаларында эчтәлек һәм форманы кискен каршы куеп булмый, чынбарлык һәм аны чагылдыра торган сүз мәгънәсе шулкадәр бер-берсе белән кисешә, аларның чикләрен, аермаларын һәрвакыт билгеләп булмый, сүзнең атау функциясендә аларның тыгыз бәйләнеше нәтиҗәсе чагылыш таба. Мисал өчен, телдә, чынбарлыкның бер үк күренешен атау өчен, төрле лексик берәмлекләр яки сүзнең төрле мәгънә вариантлары кулланылырга мөмкин, бу – милли-мәдәни факторга, кешенең психологик һәм интеллектуаль үзенчәлекләренә, эмоциональ-бәяләү критерийларына һ.б.га бәйле булырга мөмкин. Әгәр «зур – кечкенә» семантик оппозициясен карасак, татар телендә, әлеге төшенчәләрне бирү өчен, төрле тел берәмлекләре кулланылуын күрербез: *зур, олы, дәү, тау кадәр, фил чаклы, баш бетмәле – кечкенә, бәләкәй, нәни, кечтеки, бармак башы кадәр,чыпчык хәтле* һ.б. Түбәндәге контекстта, бер үк төшенчәне белдерү өчен генә дә, ике төрле берәмлек кулланыла: *Күпмедер юл киткәч, кабина идәнендә нидер кыштырдаган төсле булды. Карасам, утыргыч астына таба уч төбе кадәр генә* ***соры күләгә*** *шуып үтте.* ***Тычкан!*** (Р. Зәйдулла)

Шулай итеп, лексик-семантик берәмлекләр арасындагы системалы бәйләнешләр төрле факторларга бәйле була һәм төрле дәрәҗәдә чагылыш таба. Сүзләрне төркемләү, чынбарлыктагы күренешләрнең уртак якларына бәйле дә, семантик уртаклыкка, охшашлыкка бәйле дә булырга мөмкин. Алга таба әлеге уртаклыклар нигезендә сүзләрне төркемләүгә киңрәк тукталырбыз.

## § 15. Татар теленең лексик-семантик системасында парадигматик мөнәсәбәтләр

Тел берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәтләр ике төп принципка нигезләнә. Ул – сайлау һәм ярашу принциплары.

Бер төркем сүзләр арасыннан кирәклесен сайлап алу сүзләрнең охшаш һәм аермалы якларына нигезләнеп башкарыла. Мисал өчен, сүзләр чынбарлык күренешләренең гомуми һәм конкрет бер ягын тасвирларга, үзара капма-каршы мәгънәдә булырга яки

семантик охшашлыкка ия булырга, уртак тематик уртаклык буенча зуррак төркемнәргә берләшергә мөмкиннәр. Саналган һәрбер очракта да сүзләр арасында парадигматик мөнәсәбәтләр күзаллана. Сөйләм агышында контекст кысаларында сүзләрнең тел закончалыклары нигезендә бер-берсе белән ярашуы, кушылуы исә синтагматик мөнәсәбәтләр хасил итә.

Парадигма (*paradeigma*) – грек теленнән кергән термин, ул «өлге», «үрнәк» мәгънәсен аңлата. Парадигма дип бер-берсенә капма-каршы куелган, шул ук вакытта уртак билгеләре булган яки уртак күзаллаулар тудыра торган тел берәмлекләре төркемен һәм әлеге төркем барлыкка килсен өчен кулланыла торган модель, схеманы атыйлар (Языкознание, 2000: 366). «Лексик парадигма» төшенчәсенә төрле аңлатмалар очраса да, нигездә, бу терминны уртак семантик бергәлеккә ия булган, грамматик яктан бертөрле сүзләр җыелмасын атау өчен файдаланалар. Бер лексик парадигмага кергән сүзләрнең мәгънәсендә уртак яклар гына түгел, бәлки аларны аерып тора торган билгеләр дә чагылыш таба. Бер төркемгә кергән сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләр парадигматик мөнәсәбәт дип атала. Бер сүз эчендәге парадигматик мөнәсәбәтләр уртак семага нигезләнгән лексик-семантик вариантлар эчендә күзалланса, сүзара парадигма уртак мәгънәгә нигезләнә.

Парадигматик мөнәсәбәт лексиканың системалылыгын билгеләгәндә төп күрсәткеч булып тора. Мәсәлән, *өстәл, урындык, диван, кресло, эскәмия* кебек сүзләр уртак төшенчә белдерәләр һәм җиһаз төркеменә берләшәләр. Әмма аларның һәрберсенә хас индивидуаль, бу төркемгә кергән башка сүзләрдән аерып тора торган дифференциаль билгеләре бар. Нәкъ менә шул аермалы яклар нигезендә без бу төркемгә кергән сүзләрне бер-берсеннән аерабыз. Парадигматик мөнәсәбәтнең структурасы сүз знагының уртак һәм аермалы якларына нигезләнгән төрле оппозицияләр җирлегендә барлыкка килә (Васильев, 1993: 39).

Сүзара парадигматик мөнәсәбәтләр беренче чиратта синонимик, антонимик рәтләр, төр мөнәсәбәте (гипер-гипонимик парадигма), лексик-тематик төркемнәр (тематик парадигма), лексик-семантик төркемнәр (парадигмалар), ассоциатив рәтләр (кыр) ягыннан төркемнәр арасында ясала.

Телдә кулланыла торган сүзләр үзара тыгыз бәйләнештә яшиләр. Телне гамәли яктан куллану процессында без даими

рәвештә зур төркем сүзләр арасыннан кирәклесен, сөйләм кысаларына яраклысын сайлыйбыз. Аерым бер телдә сөйләшүчеләрнең аңында кирәкле сүзне сайлап алып, сөйләм әйләнешенә кертү аңга бәйсез рәвештә, автоматлашкан формада бара. Аерым бер сөйләм контекстына сүзләрне сайлау төрле ысуллар белән башкарылырга мөмкин. Мәсәлән, билгеле бер дәрәҗәдә аерым төшенчәне төрле яклап тасвирлаган сүзләр арасыннан кирәклесен сайлау предмет, билге, процесс, халәтне белдергән мәгънәләренә карап, я булмаса төрле класс, төркемне белдергән мәгънәләргә нигезләнеп башкарылырга мөмкин. Сөйләм агышында теге яки бу төшенчәне бөтен тулылыгы белән әйтеп бирү ихтыяҗы туганда, без уртак мәгънәгә ия булган сүзләргә мөрәҗәгать итәбез һәм шулар арасыннан кирәклесен сайлап алабыз. Бу очракта парадигматик мөнәсәбәтнең бер төре булган с и н о н и м и я күзаллана. Әгәр әйбер-күренешләрне бер-берсенә каршы куеп сурәтләү кирәк булса, а н т о н и м и я күренешен истә тотабыз. Бу ике төр парадигматик мөнәсәбәтне хасил итә, әмма сүзләр арасында парадигматик бәйләнешләр тудыра торган башка очраклар да бар.

Бер төрдәге булган сүзләр арасында шулай ук парадигматик мөнәсәбәт яши. Чынбарлык күренешләрен билгеләгәндә, сүз мәгънәсендә объектлар арасындагы мөнәсәбәтләр чагылырга мөмкин. Шул мөнәсәбәтләрнең берсе – предмет, күренеш, билге, эшләр арасындагы бәйләнешне чагылдыра торган төр, төркем бәйләнеше. Бер төрдәге чынбарлык күренешләрен атау барышында сүзләрнең мәгънәсендә аерма яши: сүзләр предметны, эш-хәлне, билгене, халәтне һ.б.ны атарга мөмкиннәр. Аталган төркемнәр эчендә карала торган сүзләр арасында да аерма бар. Мисал өчен, бер төркем сүзләр предмет, күренеш, халәт, билге, эш-хәлнең төрләрен атаса, икенчеләре исә гомумиләштерү сәләтенә ия. Мәсәлән, *сулык* сүзе *күл, елга, чишмә, буа* сүзләрен гомумиләштереп атый. Мондый гомумиләштерүче сүз *гипероним* (грек. *hyper* – өске, *onyma* – исем) дип, ә шул әлеге төркемгә керә торган, шул исем астында берләшә торган сүзләр *гипоним* (грек. *hipo* – аскы, *onyma* – исем) дип атала. Мәсәлән, *ярату, кайгы, шатлану, шатлык, үпкә* кебек гипонимнар өчен *хис* сүзе гипероним, ягъни барысы өчен дә уртак атама ролен үти. Билге мәгънәсенә ия *якты* гиперонимы а*чык, аяз, кояшлы, чиста, нурлы, көләч, балку* кебек гипонимнарны берләштерә.

Шулай итеп, предмет, күренеш, билге, эш-хәрәкәт, халәт һ.б. бер төркемгә берләштерә торган сүз һәм шул төркем эчендәге төркемчәләргә кергән сүзләр арасындагы мөнәсәбәт төр мөнәсәбәте (гипер-гипонимик парадигма) дип атала. Сүзләр арасындагы төр мөнәсәбәтен белү сөйләмне логик яктан дөрес төзергә ярдәм итә.

Телдә сүзләр гомуми һәм аермалы яклар нигезендә генә төркемләнеп калмыйча, аерым тематик төркемнәргә (парадигмаларга) дә бүленәләр. Тематик парадигма мәгънәләре уртак гиперсемага ия булган сүзләрне берләштерә. Телдә кулланылган сүзләр күптөрле тематик төркемнәр составында яшиләр, мәсәлән, «Ризык атамалары», «Кеше әгъзалары атамалары», «Күк җисемнәре атамалары» һ.б.

«Хәрәкәт фигыльләре» тематик төркемен алсак, бу төркемгә *хәрәкәт итү, йөрү, китү, ерагаю, чыгу, таралу, килү, китү, керү, кайту, җыелу, үтү, узу, кичү, чыгу, чабу, сөйрәлү, титаклау* һ.б. фигыльләр керә (Татар грамматикасы, 2002: 105). Әлеге фигыльләр өчен уртак гиперсема – «хәрәкәт итү», «йөрү», калганнары исә төрле юнәлештә һәм сыйфатта йөрүне тасвирлый. Бирелгән сүзләрнең һәрберсендә, уртак семадан тыш, төп аерманы күрсәткән сема да урын ала: ноктага якынаю – *килү, кайту, җыелу*; хәрәкәтне тасвирлау – *сөйрәлү, титаклау* һ.б.

Тематик төркемнәр составы һәм интеграль семаларның саны ягыннан да аерылып торалар. Югарыда китерелгән «Хәрәкәт фигыльләре» тематик төркемендәге сүзләрне берләштерә торган сема шактый ачык беленеп торса, «Кеше әгъзалары атамалары» төркемендә мондый семаның эчтәлеге бераз җуела төшә*: аяк – кул* сүзләре оппозициядә ачык аңлашылса (өс – ас), *борын, эч, муен* сүзләрендә исә уртак семаны табу авыр.

Тематик төркемнәр составы ягыннан да төрле була, мәсәлән, «Хайваннар дөньясы» тематик төркемен үз эчендә кечерәк төркемнәргә – «Кыргый хайваннар» (*аю, бүре, кабан дуңгызы, төлке, куян* һ.б.), «Йорт хайваннары» (*сыер, сарык, кәҗә, ат* һ.б.) төркемнәренә дә бүлеп карап була. Алары үз чиратында тагын да ваграк төркемгә аерылырга мөмкин, мәсәлән, йорт хайваннары арасында эт, песи һәм ат, сыер, сарык бер-берләреннән функцияләре, хуҗалыкта тоткан урыннары белән аерылып торалар. «Үсемлекләр дөньясы» тематик төркеме белән дә шул ук хәл.

Күп мәгънәле сүзләр шулай ук төрле тематик төркемнәргә керергә мөмкин, мәсәлән, *канат* сүзе, туры мәгънәдә килгәндә, «Хайваннар дөньясы» – «Кош әгъзалары атамалары» төркеменә керсә, күчерелмә мәгънәдә кулланган очракта «Детальләр» (*самолёт канаты, тегермән канаты*) төркеме составында карала.

Тематик төркемләү сүзләрне төрле мөнәсәбәтләр: гомуми – аерым, уртаклык, кисешү, билге, предмет, функция охшашлыгы һ.б. ягыннан аерырга ярдәм итә.

Парадигматик мөнәсәбәтләргә нигезләнгән төркемнәрнең иң күләмлесе булып л е к с и к - с е м а н т и к  т ө р к е м тора. Бу төркемгә кергән сүзләр төп семантик компонент нигезендә берләшәләр. Бер яктан, әлеге төркем алда караган төр мөнәсәбәтенә нигезләнгән гипер-гипонимик парадигма һәм тематик парадигма составындагы сүзләр арасындагы мөнәсәбәткә охшаш, әмма әлеге төркемгә караган аермалы яклар да шактый. Беренчедән, төп, нигез семантик компонент берничә гиперсеманы берләштерергә сәләтле. Мәсәлән, «*Табигать*» лексик-семантик төркемен карасак, бу төркемнең төп семантик компоненты бертөрле, әмма мәгънә ягыннан тагын да төгәлрәк булган ике парадигманы оештыра торган «*Җанлы табигать күренешләре*», «*Җансыз табигать күренешләре*» гиперсемаларын берләштерә. Икенчедән, лексик-семантик парадигмадагы сүзнең сема составы уртак һәм аермалы яклардан тора. Әгәр уртак сема *табигать* сүзендә ачылса, аермалы, дифференциаль семалар *җанлы* һәм *җансыз* сүзләрендә капма-каршы куелып ачыла. Өченчедән, лексик-семантик төркем (парадигма) составында семантик яктан төрле булган берничә парадигма берләшергә мөмкин. Мәсәлән, «Кешенең темпераменты» лексик-семантик төркемен алыйк. Әлеге төркем түбәндәге парадигмаларны берләштерә: 1) *кызу* синонимик парадигмасы: *дуамал, йөрәкле, кызу, холыксыз, елдам, кыдрач, килделе-киттеле, тотнаксыз* һ.б.; 2) *җитез* антонимик парадигмасы: *җәһәт – сүлпән, тиз – әкрен, мыштыр – тере* һ.б.[1]; 3) хәрәкәтчән тип тематик парадигмасы: *тере, тынгысыз, үткер, җитез, булдыклы, елдам, тиз* һ.б.

Парадигматик мөнәсәбәтләр рәтендә карала торган тагын бер төркем булып а с с о ц и а т и в  р ә т л ә р төркеме аерыла.

[1] Мисаллар түбәндәге сүзлекләрдән алынды: Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999; Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка / авт.-сост.: А.Г. Шайхулов, Л.У. Бикмаева, З.Р. Садыкова. Уфа: РИО БашГУ, 2005. Т. 1. С. 2.

Ассоциатив рәттәге сүзләр мәгънә ягыннан якын булалар, әмма алар арасында синонимик мөнәсәбәт булмый. Бу төркемгә кергән сүзләр төрле күзаллаулар, ассоциацияләр нигезендә берләшә. Теге яки бу сорауга җавап биргәндә, фикер әйткәндә, аерым бер милләт вәкиленең тел аңында яшәгән һәм ныклап урнашкан стереотипларга нигезләнеп сайлап алынган сүзләр арасындагы бәйләнешне ассоциатив мөнәсәбәт дип атыйлар. Бу төр мөнәсәбәт күбрәк халыкның мәдәни тормышы белән бәйле һәм милли бизәкле була. Мәсәлән, *зур авыз – бәлеш авыз; кечкенә авыз – уймак; өй – туган авыл, туган җир, гаилә* һ.б. Ассоциатив мөнәсәбәтләр һәр сүзне аерым бер ассоциатив кыр кысасына кертергә мөмкинлек бирә. Бу кырлар гомумхалык һәм индивидуаль төрләргә бүленә. Татар телендә аралашучылар өчен аңлашыла торган, калыплашкан ассоциацияләр гомумхалык телендә тотрыклы яшәсә, индивидуаль ассоциацияләр сөйләм барышында аерым бер кеше аңында барлыкка килә һәм сөйләмдә реальләшә. Хәзерге тел белемендә аерым бер тел кысаларында калыплашкан ассоциатив рәтләрне экспериментал ь ысул белән ачыклау киң таралган.

## § 16. Татар теленең лексик-семантик системасында синтагматик мөнәсәбәтләр

Аерым бер контекст кысаларында сүзләрнең бер-берсе белән ярашуы, кушылуы синтагматик мөнәсәбәтләр хасил итә. Парадигматик мөнәсәбәтләрдән аермалы буларак, синтагматик мөнәсәбәт бер төркем эченнән бер лексик берәмлекне аерып алуга түгел, ә сүзләрнең үзара янәшә килә алу-алмавына корылган.

Хәзерге тел белемендә киң таралыш тапкан «мәгънә бары тик контекст кысаларында гына тулысынча ачыла ала» тезисы (Ахманова, 1957; Курилович, 1960; Кацнельсон, 1965; Колшанский, 1980; Гудавичюс, 1985; Крысин, 2007; Фидаева, Юсупов, 2002; Бәширова, 2010 һ.б.) сүзләр арасындагы синтагматик мөнәсәбәтләрне тирәнтен өйрәнүгә этәрде. Тел белемендә бу юнәлешнең барлыкка килүе һәм таралыш алуы Казан лингвистика мәктәбе, аерым алганда Ф. де Соссюр һәм Бодуэн де Куртенэ исемнәре белән турыдан-туры бәйләнгән.

Хәтердә сакланган сүзләрне сайлап, сөйләм агышында аларны кушу үзенчәлекләре һәм мөмкинлекләре хәзерге семасиологиянең төп асылын тәшкил итә. Гадәттә, сүзнең башка сүзләр белән

кушылуы, шуның нигезендә лексик мәгънәнең чагыштырмача тулы ачылуы бер синтагма кысаларында башкарыла. С и н т а г м а (грек. *syntagm*а – бергә төзелгән, кушылган) дип контекст эчендә бер төшенчә белдергән, бер яки берничә сүздән торган интонацион-мәгънәви берәмлекне атыйлар (Языкознание, 2000: 447). Мәсәлән, *йорт* сүзе *зур, кечкенә, биек, тәбәнәк, иске, кирпеч, агач, җимерек* һ.б. сүзләр белән бер синтагма хасил итә ала. Янәшә килеп, бер төзек мәгънә барлыкка килү телдә горизонталь юнәлештә бара, һәм төрле сүз башка лексик берәмлекләр белән төрле күләмдәге рәт, линия барлыкка китерә.

Сүзләр арасындагы мәгънәви бәйләнешләрнең ике төре – семантик ярашу һәм лексик ярашу төрләре аерыла.

С е м а н т и к я р а ш у ул – сүзнең гомуми мәгънәгә ия булган зур бер төркем сүзләр белән яраклаша алу мөмкинлеге. Мәсәлән, *бару, кайту, җитү, китү, чабу* һ.б. фигыльләр хәрәкәтне белдерәләр һәм кешегә карата кулланылалар. Шунлыктан алар *кеше, малай, ир, сабый, апа, әни, әби, укытучы* һ.б. кешене белдергән сүзләр белән мәгънәви яктан бик иркен ярашалар. Шул ук вакытта үсемлекләр дөньясын белдергән сүзләр белән алар яраша алмый. Татар телендә *агач бара, үлән китә, чәчәк бара* һ.б. дип сөйләмиләр, ягъни бу төр сүзләр семантик яктан ярашмый.

Л е к с и к я р а ш у дип сүзнең бер семантик төркемгә караган сүзләрнең кайберләре белән генә кушылып, бер сүз тезмәсе хасил итә алуын атыйлар. Мәсәлән, хайваннарның төсен белдергән лексик-тематик төркемдә *ала, кола, туры, күк, җирән, көл, коба* һ.б. сүзләр бар. Хайван атамалары бу сүзләр белән чикле яраша: *туры ат* дип әйтеп булса, *туры эт* сүз тезмәсе татар телендә кулланылмый, *җирән сыер* телдә кулланылышта йөри, әмма *җирән сарык* тезмәсе юк; *соры бүре – соры төлке, ала сарык – ала аю* һ.б. Күләмне, үлчәмне белдерә торган нумератив сүзләр *чеметем, кашык, уч, тотам, төп, йотым, телем, кочак, саплам* һ.б.ның да лексик яктан ярашу чикләре бар. Аерым алганда, *(бер) чеметем тоз, (бер) саплам җеп, (бер) йотым су, (бер) төп алмагач, (бер) кочак печән (салам, үлән), (бер) төп алмагач, (бер) телем ипи, (бер) уч көнбагыш, (бер) кашык май* һ.б. дип сөйләү татар телендә кабул ителгән, әмма *(бер) уч җеп, (бер) телем тоз, (бер) саплам май, (бер) йотым көнбагыш, (бер) кашык печән* кебек тезмәләрдәге сүзләр үзара яраша алмыйлар.

Шулай ук *ак чәчәк, ак кар, ак хыял, ак сүз* тезмәләре татар телендә кулланылса, *кара кар, сары хыял, зәңгәр сүз* тезмәләрендәге сүзләрнең бергә кулланыла алмавын беләбез.

Мондый очракларны телнең һәр лексик-тематик, лексик-семантик төркемнәреннән табарга була. Сүзләрнең халык аңында барлыкка килгән, шуның нәтиҗәсендә телдә чагылган ярашу принцибы тел катламында идиоматик (грек. *idiota* – үзенчәлекле) гыйбарәләр хасил итә. Бу төр гыйбарәләр телнең лингвокультурологик фондын тәшкил итә, телне өйрәнүчеләр өчен дә кабул итүдә авырлык тудыра.

Югарыда аталган семантик һәм лексик ярашуларның һәр икесендә дә грамматик бәйләнешкә кергән сүзләрнең с е м а н т и к я к т а н т у р ы к и л ү е күзәтелә. Семантик яктан туры килү асылында текстта адресат өчен билгеле булмаган яки махсус төшереп калдырылган сүзне дөрес аңлау ята. Контекстта аерым бер семаларның кабатлануы, синтагматик мөнәсәбәтләрнең үзара очрашуы нәтиҗәсендә төшеп калган элементны торгызырга мөмкин. Шулай итеп, семантик яктан туры килү текстның контекстуаль эчтәлеген барлыкка китерә һәм ул семемалар ярашуында норма вазифасын башкара. Мисал өчен, *сибү* фигылен алыйк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә әлеге фигыльнең түбәндәге мәгънәләре бирелгән: 1) чәчеп тарату (*ашлама сибү*); 2) нәрсәнедер салу (*ашка борыч сибү*); 3) бирү (*күгәрченнәргә ярма сибү*); 4) бөркү (*су сибү*); 5) тарату (*хуш ис сибү*); 6) сарыф итү (*акча сибү*) һ.б. Бирелгән һәр очракта да эшне кемдер башкаруы күзаллана: *Әни тавыкларга бодай сипте. Гүзәл гөлләргә су сипте. Әти бакчага ашлама сипте* һ.б. Әгәр мәгънәне аңлап бетермичә, субъект урынына объект куллансак, мәгънәләрнең туры килмәвен, мәгънә ягыннан бөтенләй аңлаешсыз җөмләләр барлыкка килүен күрербез: *Өстәл гөлләргә су сипте. Китап бакчага ашлама сипте.* Сөйләмнең төгәл, аңлаешлы булып оешуы өчен, контексттагы сүзләрнең семантик яктан бер-берсенә туры килүе мәҗбүри. Татар телен камил белгән кешеләргә бу үзенчәлекне даими, максатчан рәвештә истә тоту кирәкми, чөнки автоматлашкан сөйләмдә сүзләр үзеннән-үзе ярашалар.

Шул ук вакытта бу норманың сөйләмдә махсус рәвештә бозылуын да очратырга мөмкин. Мондый алым еш кына сөйләм көчле экспрессиягә, эмоциональ эчтәлеккә ия булганда һәм поэтик сөйләм

кысаларында күзәтелә. Семантик читләшү күчерелмә мәгънәнең формаль күрсәткече булып тора. Түбәндәге шигъри юлларда субъектка хас үзенчәлек объектка күчерелә: *җил, буран* сүзләренең ‘предметлык’, ‘җансыз’ семалары *сызгыра, дулый, төкерде* сүзләрендәге ‘активлык’, ‘эш башкару’ семалары белән каршылыкка керә.

*Җил сызгыра,*
Үрсәләнә,
*Дулый буран.*
Бөтен җир-күк,
Бөтен урам
Ак-ак буран
Белән тулган… (Ф. Зыятдинова)
Эч пошты да, йортка чыккан идем,
*Буран тиле,* күзгә *төкерде.* (Х. Туфан)

Шул ук вакытта, метафорик яки метонимик мәгънәнең, образлылыгын югалтып күчерелмәлелек төсмере югалган очракларында, семантик туры килү үзенчәлеге кире әйләнеп кайтырга мөмкин. Мәсәлән, тел метафоралары буларак татар телендә кулланыла торган *сәгать йөри, сәгать сукты, сәгать теле, өстәл аягы* кебек очракларда семантик туры килү күзәтелә, чөнки алар образлылыгын югалткан, телнең табигый агышына яраклашкан саналалар.

Сүзләр арасында синтагматик мөнәсәбәтләр, лексик берәмлекләрнең яраша алу мөмкинлеге тәрҗемә мәсьәләләрендә дә гаять әһәмиятле роль уйный. Төрле телләрнең семантик системасы, лексик берәмлекләрнең мәгънәви тәңгәллеге бертөрле түгел, әгәр сүзнең номинатив мәгънәсе ике телдә дә тәңгәл булса, сүз күчерелмә мәгънәдә кулланылганда, мондый тәңгәллек юкка чыгарга мөмкин. Мәсәлән, *алу* сүзе туры мәгънәдә килгәндә, рус телендәге *брать* фигыле белән семантик яктан тәңгәл килә: *брать в долг – бурычка алу; брать ручку – ручканы алу.* Күчерелмә мәгънәдә түбәндәгеләрне күзәтергә мөмкин: *брать верх – өстен чыгу; брать на себя смелость – батырчылык итү; брать за живое – нык тәэсир итү; брать влево – сулга тоту; брать своё – үзенекен итү; брать курс – юл тоту; брать высоту – күтәрелү* (Фидаева Л.И., Юсупов Р.А., 2002: 22) һ.б. Һәр телдә сүзләрнең синтагматик бәйләнешләрен һәм тел берәмлекләренең ярашу үзенчәлекләрен аңлап эш итү нигезендә генә мәгънә бөтенлеген һәм төгәллеген бирергә мөмкин.

Шулай итеп, тел берәмлекләре арасында вертикаль (парадигматик) һәм горизонталь (синтагматик) мөнәсәбәтләр телнең берберсе белән тыгыз бәйләнештә яшәгән тулы бер система буларак яшәешен тәэмин итәләр.

## Сүзнең күпмәгънәлелеге

### § 17. Тел белемендә күпмәгънәлелекне өйрәнү тарихы

Күпмәгънәлелек, ягъни полисемия, сүзнең мәгънә үсеше мәсьәләсе гомуми тел белемендә төрле яклап өйрәнелгән өлкә санала. В.В. Виноградов, Н.М. Шанский, Р.А. Будагов, Д.Н. Шмелёв, А.М. Смирницкий, В.А. Звегинцев, П.А. Соболева, Л.А. Новиков, Е.С. Кубрякова, В.В. Морковкин, Л.В. Щерба, А.А. Уфимцева, В.В. Колесов, И.Г. Ольшанский, В.П. Скиба, М.Г. Арсеньева, Т.В. Строева, А.П. Хазанович, С.Д. Кацнельсон, С. Ульман, К. Рейзиг, Г. Пауль, К. Эрдманн, В. Вундт, Г. Шпербер һ.б. танылган лингвистлар күпмәгънәлелек проблемасын тирәнтен тикшергәннәр. Хәзерге тел белемендә Ю.Д. Апресян, Е.В. Падучева, М.А. Стернина, М.В. Никитин, Л.С. Пухаева, А.А. Зализняк, С.А. Песина, Г.И. Кустова, Е.В. Рахилина, Э.В. Кузнецова, В.А. Плунгян һ.б. бу юнәлештә актив эшләп киләләр.

Тюркологиядә күпмәгънәлелек мәсьәләсе шулай ук төрле аспектлардан чыгып М.М. Миртаджиев, М.Х. Ахтямов, М.И. Кидирниязова, У.М. Батырмурзаева, С.Р. Биджиева, В.И. Рассадин, Т. Аликулов, К.М. Мусаев, А.А. Юлдашев, Б.И. Татаринцев һ.б. хезмәтләрендә өйрәнелә.

Лексик күпмәгънәлелек – гаять катлаулы һәм бәхәсле тел күренеше. Гомуми тел белемендә полисемиягә карата берничә караш яшәп килә.

1. Телдә бары бер генә денотатка туры килгән бер мәгънәле сүзләр бар. Бу фикер тарафдарлары – күренекле рус галимнәре А.А. Потебня, Л.В. Щерба. Шулай ук Г. Пауль, К. Эрдманн, П. Стерн кебек танылган чит ил галимнәре хезмәтләрендә дә полисемия «аномалия, тел закончалыкларының тайпылышы, бозылуы» буларак карала.

2. В.В. Морковкин, Н.Д. Шведова һ.б. телдә бары тик күп мәгънәле сүзләр генә бар дип фаразлый.

3. Күпчелек галимнәр телдә бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр бергә яши дип саный (В.В. Виноградов, А.И. Смирницкий, О.С. Ахманова, Д.Н. Шмелёв, Р.А. Будагов, Ю.Д. Апресян, Н.М. Шанский, Л.А. Новиков һ.б.)

Гомуми лингвистикада шулай ук лексик-грамматик полисемия концепциясе дә гамәлдә йөри. Әлеге концепция нигезендә, семантик күпмәгънәлелектән тыш, сүзләрнең лексик-грамматик төркемнәренең күпмәгънәлелеге дә карала (В.А. Абаев, В.М. Жирмунский, С.И. Богданов, М.А. Стернина һ.б.).

Татар телендә күпмәгънәлелекне өйрәнү XX гасыр урталарында башлана, һәм бу мәсьәлә Ш.А. Рамазанов, Ш.С. Ханбикова, К.С. Сабиров, Г.Х. Әхәтов, Ф.С. Сафиуллина, И.Б. Бәширова, Д.М. Гаптелганиева, Ә.К. Булатова һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба.

Татар тел белгечләре арасында Ш.А. Рамазанов беренчеләрдән булып сүзнең мәгънә үсешенә игътибар итә. Галим күпмәгънәлелекне семантик сүз ясалыш ысулы белән бәйләп карый. Аның фикеренчә, күп мәгънәле сүзнең аерым мәгънәләре аерымлану лексик омонимнарны китереп чыгара (Рамазанов, 1954: 126).

Ш.С. Ханбикова хезмәтләрендә полисемантик сүзнең мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре, башка сүзләрнең мәгънәләре белән билгеле бер тәртипкә салынган бәйләнеш системасы буларак карала. Күпмәгънәлелекне өйрәнеп, Ш.С.Ханбикова полисемиянең төп сәбәбе – диффузлык, ягъни мәгънәләрнең уртаклыгы, күчеше дигән нәтиҗәгә килә (Ханбикова, 1997: 50–57).

Ф.Ә. Ганиев күпмәгънәлелекне хәзерге татар телендә лексик системаның үсеш юлларының берсе итеп карый. Галим күп мәгънәле сүзләрнең төрки телләрдә борынгыдан ук килүен дәлилли (Ганиев, 1998: 96).

Г.Ф. Саттаровның татар ономастикасына багышланган хезмәтләрендә географик атамаларның күпмәгънәлелеге яктыртыла. Галим билгеләвенчә, күп кенә географик объектларны белдерә торган сүзләрнең мәгънәләре киңәю нәтиҗәсендә, аларның яңа лексик-семантик вариантлары барлыкка килә, шулай ук аерым очракларда омоним сүзләр дә хасил була: мәсәлән, *үзәк, баш, каш* сүзләре (Саттаров, 1982: 56).

Л.К. Бәйрәмова «Татарстан: языковая симметрия и асимметрия» монографиясендә бер үк сүзнең төрле лексик-семантик вариантларда килә алуын парадигматик ассиметрия дигән

термин белән атый. Ул ассиметриянең ике төрен аерып чыгара: семасиологик полисемия һәм омоносиологик синонимия. Семасиологик полисемияне галимә бер билгеләүчедә берничә билгеләнүченең туры килүе буларак күрсәтә. Шулай ук галимә сүз ясалышы өлкәсендәге күпмәгънәлелеккә дә тукталып уза (Байрамова, 2001: 217–218).

Татар теле лексикологиясе буенча басылган дәреслекләрдә күпмәгънәлелек күренеше лексик мәгънәне өйрәнү темасы кысасында карала һәм, нигездә, тел белемендә киң таралыш тапкан традицион яссылыкта аңлатыла.

К.С. Сабировның 1965 елда дөнья күргән «Хәзерге татар әдәби теле» дәреслегендә күп мәгънәле сүзләргә карата түбәндәге фикер әйтелә: «Әйбернең исеме аның төп билгеләреннән чыгып бирелә. Икенче бер әйбердә башка әйберләргә хас кайбер билгеләр, сыйфатлар табылса, бу әйберләрнең исеме бер үк авазлар комплексы белән белдерелергә мөмкин. Шул рәвешчә, телдә бер үк исем төрле әйбер яки күренешләрнең атамасы булып йөри башлый» (Сабиров, 1965: 28).

Г.Х. Әхәтов үзенең 1975 елда басылган дәреслегендә күпмәгънәлелекне сүзнең предметларны (күренешләрне) гомумиләштерә алу үзенчәлегенә бәйләнгән булуын ассызыклый. Традицион планда полисемиянең төрләре буларак каралган метафора, метонимия, синекдохага туктала. Төркемләү барышында автор О.С. Ахманова, А.И. Смирницкий, Р.А. Будагов һ.б. рус тел галимнәренең хезмәтләренә таяна (Әхәтов, 1975: 139).

Ф.С. Сафиуллинаның 1999 елда дөнья күргән һәм бу төр дәреслекләр арасында шактый тулы һәм төгәл саналган «Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен)» хезмәтендә лексик мәгънәләрнең төрләре аерыла, күчерелмә мәгънәлелеккә зур игътибар бирелә. Галимә: «әгәр һәр яңа төшенчәне яңа сүз белән атый башласак, сүзләр шулкадәр күбәеп китәр иде, хәтта кеше барлык кирәкле сүзләрне хәтерендә саклап бетерә алмас иде. Шуңа күрә кеше акылы иң экономияле юлны – бер үк сүзне яңа мәгънәләрдә куллану алымын сайлаган», – дип белдерә (Сафиуллина, 1999: 19–20).

Югары уку йортлары студентлары өчен язылган әсбапларында Г.Р. Галиуллина сүзнең ике һәм аннан да артык мәгънәгә ия булу сәләтен билгели, һәм «күп мәгънәле сүздә барлык мә-

гънәләр дә үзара бәйләнештә яшиләр һәм шактый катлаулы саналган сүзнең семантик структурасын барлыкка китерәләр. Күп мәгънәле сүз эчендә булган семантик бәйләнешләр лексиканың системасын хасил итәләр. Бу төр бәйләнешләр барлык телләрдә дә бертөрле түгел, шунлыктан сүздәге күпмәгънәлелек күренеше халыкның миллилегенә, үзенчәлегенә ишарә итә торган бер күренеш булуын», – ассызыклый (Галиуллина, 2013: 18).

Танылган тел белгече И.Б. Бәшированың күп кенә хезмәтләрендә татар теле семасиологиясенең катлаулы мәсьәләләре яктыртыла. И.Б. Бәширова хәзерге семасиологиянең методологик нигезендә лексик мәгънәләрнең сөйләмдә һәм статик хәлдә кулланылышы ятуын әйтә: «Аерым бер сүзнең күпмәгънәлелеге дип аңлатыла торган күренеш, асылда, сүз-мәгънәнең эчтәлеген хасил итә торган денотат һәм сигнификат элементларның нинди сүзләр белән бергә кулланылуына, ягъни нинди сүзформа, сүзтезмә ясауларына карап, төрле вариант-парадигма хасил итә алуы һәм шул нигездә, мәгънә эчтәлеген төрлечә реальләштерә алуы булып чыга. Әмма бу очракта әлеге вариантларның семантик яктан бөтенләй аерылып китүе күзәтелә дип әйтеп булмый, чөнки мәгънәнең нигез-берлеге саклана» (Бәширова, 2010: 165)

М.Б. Хәйруллин хәзерге тел системасының үсеш-үзгәреш проблемаларын өйрәнү барышында күпмәгънәлелекнең үзенчәлекләренә тукталып: «Күпмәгънәлелекнең төп үзлеге – объектив чынбарлыктагы бер предмет яки күренеш атамасының икенче бер предмет яки күренешкә күчерелүе», – дигән нәтиҗә ясый (Хайруллин, 2006: 454)

Татар телендәге фигыль сүз төркеменә караган лексикада күпмәгънәлелек һәм омонимия күренешләрен монографик планда өйрәнгән Д.М. Гаптелганиева полисемияне семантик омонимнарның чыганагы буларак тикшерә, җентекле һәм эзлекле рәвештә контекстуаль мәгънәләрнең барлыкка килүләрен яктырта. «Полисемия – сөйләм билгеләренең саны белән телгә кергән зур сандагы төшенчәләр арасындагы диспропорциянең котылгысыз нәтиҗәсе», – дип белдерә ул (Гаптелганиева, 1999: 70).

Г.И. Бичурина татар һәм рус телләрендә фразеологизмнар арасындагы күпмәгънәлелек күренешен чагыштырма планда тикшерә. Ул татар һәм рус телләренең күп мәгънәле фразеологик

берәмлекләре кулланылышын өйрәнә, шулай ук фразеосемантик кырлар мисалында фразеологизмнарның компонент составының үзенчәлекләрен күрсәтә (Бичурина, 1998).

2012 елда Ә.К. Булатова «Хәзерге татар әдәби телендә полисемия күренеше» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Әлеге хезмәттә күпмәгънәлелекнең асылы, үзенчәлекләре, барлыкка килүенә сәбәп булган факторлар, күчерелмә мәгънәлелек нәтиҗәсендә сүзләрнең берничә мәгънәгә ия була алулары яктыртыла (Булатова, 2012).

Татар тел белемендә күпмәгънәлелек күренеше буенча төрле юнәлештәге хезмәтләр булуга карамастан, бу өлкәдә хәл ителмәгән проблемалар, аерым алганда, термин мәсьәләсе, күп мәгънәле сүзләрне аеру критерийлары, аларның телдә кулланылыш мөмкинлекләре буенча ачыклыйсы сораулар шактый, һәм алар яңа тикшеренүләр таләп итә.

## § 18. Күпмәгънәлелек күренешенә гомуми билгеләмә

Тормышта, җәмгыятьтә, яшәештә барган вакыйгалар телнең үзенә дә йогынты ясамый калмый. Аеруча телнең лексик системасы даими үзгәрештә яши. Бу исә – яңа сүзләр барлыкка килә, иске сүзләр кулланылыштан төшеп кала, кулланылышта йөргән сүзләрнең мәгънәләре үзгәрә һәм яңа мәгънәләр барлыкка килә дигән сүз.

Телнең лексик системасындагы сүзләр ике төркемгә: бер мәгънәле (моносемантик) һәм күп мәгънәле (полисемантик) сүзләргә бүленәләр. Сүзнең бер генә мәгънәгә ия булу үзенчәлеге, икенче төрле әйткәндә, сүзнең билгеле бер авазлар җыелмасы белән бирелгән тотрыклы лексик мәгънә алуы бермәгънәлелек яки моносемия (грек. *monos* – бер + *sema* – билге) күренеше дип атала. Бермәгънәлелек семантик яктан берпланлылык белән характерлана. Бер мәгънәле сүзләрдә әйбер, күренеш белән аның атамасы арасында тәңгәллек, туры пропорция урын ала (сүз ↔ әйбер (күренеш)), ягъни сүз туры, конкрет мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән, *измәче* ‘измә ясаучы эшче’: *Исәнмесез, бетончы һәм измәче дуслар.* (З. Нури)

Моносемантик сүзләргә, нигездә, түбәндәгеләр керә:

а) ялгызлык исемнәре алар конкрет мәгънәләре бер төрдә булган әйберләрнең берсенә генә бирелә торган исемгә карый, вариантлылык чикләнгән була (кеше исемнәре, фамилияләр, географик

атамалар, газета, журнал, китап исемнәре һ.б.): *Габдулла, Вәлиев, Язилә, Теләче, Мишә елгасы, Мияубикә* һ.б.;

ә) терминнар, фәндәге, техникадагы, сәнгатьтәге берәр төшенчәнең төгәл атамасы булганлыктан, бермәгънәлелеккә омтылалар: *кертем* (взнос), *климатология, сульфат, түләмә, зарбәлек* (амортизация), *антисызыкча, радиоалгыч, төрекөмеш азиды, экспроприацияләү, изафә* һ.б.;

б) тар предметлылыкка ия булган сүзләр, гадәттә, махсус кулланылышта булган предметларны атаганда файдаланылалар, сөйләмдә сирәк очрыйлар, шул рәвешле бермәгънәлелекне саклап киләләр: *рәислек, чәчәклек* һ.б.;

в) неологизмнар – телдә барлыкка килгән яңа сүзләр, аларның мәгънәләре гомуми сөйләмгә кереп китәргә өлгермәгән, яисә киң кулланылыш тапмаган булырга мөмкин: *бәрәңгече, дымүлчәгеч, күчергеч, җанатар, кертемче, йөгенеш, көярмән* һ.б. Татар теле җирлегендә туган окказиональ сүзләрне дә монда кертеп карап була: *башлаткыч, көлкизм, токымдар, җирский* (Р. Гаташ), *сәясмән* (Н. Сафина) һ.б. Бу төр сүзләр, аеруча башлангыч чорда, бер мәгънәгә ия булалар.

Тел белемендә бермәгънәлелек күпмәгънәлелеккә каршы куела. Бер мәгънәле сүзләр, вакыт үтү белән, өстәмә мәгънәләргә ия булырга мөмкин, шулай ук кире процесс күзәтелүе дә ихтимал.

Сүзнең мәгънәсе чынбарлыкны чагылдыра торган аерым тел формасы булып та, авазлар комплексының чынбарлыкка мөнәсәбәте буларак та билгеләнә ала. Күп сүзләр (шулай ук сүзнең кайбер грамматик формалары һәм синтаксик конструкцияләр), бер генә мәгънә белән чикләнмичә, берничә мәгънәгә ия булалар, ягъни берничә төрле предмет яки күренешне белдерәләр. Нәтиҗәдә телдә к ү п м ә г ъ н ә л е л е к (полисемия) күренеше барлыкка килә.

П о л и с е м и я дип (грек. *polysemos* – билгеләр күплеге) сүзнең бер-үк вакытта бер-берсе белән бәйле берничә мәгънәгә ия булу семантик үзенчәлеге атала[1]. Мисал өчен, *йөз* сүзен алыйк. Сүзнең төп,

[1] Термин фәнгә француз галиме Мишель Бреаль тарафыннан кертелә. Ул үзенең 1897 елда басылып чыккан «Семантика буенча тәҗрибә, мәгънәләр турындагы фән» («Essai de sémantique, science de significations») хезмәтендә «сүзгә яңа мәгънәләр өстәлү нәтиҗәсендә сүз киңәя, «үрчи» ди, формалары бердәй, әмма мәгънәләре аерылып торган яңа тел берәмлекләре бүлеп чыгара. Без бу үзенчәлекле «үрчүне» полисемия дип атарбыз», – дип яза (цит. Аничков хезмәте буенча бирелә).

номинатив мәгънәсе буенча, *йөз* сүзе кеше башының алгы өлешен, битне аңлата: *Бу авыр фаҗиганең, бу күренешнең очына чыгу мәгәр хәзрәтнең генә кулыннан килә торган эш кебек белеп, һәркем аның йөзенә карады.* (М. Гафури) Номинатив мәгънәдән тыш: 1) нинди дә булса корылманың алды, алгы ягы, фасады: *Бинаның йөзе бәйрәмчә бизәлгән иде.* (И. Гази); 2) нәрсәнең дә булса өске ягы, өсте: *Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга.* (Ә. Еники); 3) нәрсәнең дә булса өске яссылыгы, өслеге, күренеп торган киңлеге: *Таңда сүнсә, кич кабына / Күк йөзендә йолдызлар.* (Г. Зәйнашева); 4) кечкенә әйберләрнең мәйданы, йөззурлык: *Бер чөгендернең яфрак йөзе шулкадәр булгач, бер гектардагы яфракларның йөзе күпмегә җитә.* (Г. Галиев); 5) кемнең яисә нәрсәнең үзенә хас сыйфаты, асылы: *Казан бөтенләй йөзен үзгәртте.* (Г. Ахунов); 6) намус, дәрәҗә, абруй: *Минем хәзер дус-иш арасына күренерлек йөземне калдырмадыгыз* (Ф. Амирхан) кебек өстәмә мәгънәләргә дә ия. Әлеге мәгънәләр арасында уртаклык, бәйләнеш саклана. Һәр очракта да номинатив мәгънәдән аңлашылган ‘алгы өлеш’ яки ‘бит’ семаларының активлашуын күрәбез.

Татар телендәге сүзләрнең абсолют күпчелеге – күп мәгънәле. Сүз мәгънәләренең берсе – төп (беренчел, номинатив) мәгънә, калганнары – шуңа бәйле өстәмә (икенчел) мәгънәләр.

Шулай ук тел белемендә «лексик-семантик вариант» термины да яшәп килә. Лексик-семантик вариантлар дип бер үк сүздә ике яисә аннан да күбрәк, логик-предметлык ягыннан бер-берсеннән аерылып та, сүзнең бөтенлеген саклаучы мәгънәләр атала. Лексик-семантик вариант телдәге сүзне сөйләмдәге сүзгә реальләштерүче икеьяклы тел билгесе булып санала.

Сүзнең предметларны, күренешләрне атаганда белдерә торган төп мәгънәсе чынбарлыктагы төшенчәне турыдан-туры чагылдыра. Мәсәлән, *оя* сүзе номинатив мәгънәдә кош-кортларның йомырка салу, бала чыгару өчен ясалган яисә кеше тарафыннан махсус эшләнгән урынын белдерә: *Һәр кош үз оясын үзе корыр.* (Мәкаль)

Төп мәгънәләр, икенчел мәгънәләр белән чагыштырганда, парадигматик яктан бәйле, синтагматик яктан ирекле, икенче төрле әйткәндә, номинатив мәгънә контекстка бәйле түгел. Телдә камил сөйләшүче кеше аңы, сүзне атаганда, һәрвакытта диярлек төп мәгънәсендә кабул итә. Икенчел мәгънәләр исә контекстка

бәйле ачылалар. Шул рәвешле, сүзнең төп мәгънәсе өстәмә мәгънәләрдән контекстта аерылырга мөмкин.

Икенчел мәгънәләр беренчел мәгънәдән чыгып аңлатыла. Мисал өчен, *арка* сүзен карыйк. Әлеге сүз номинатив мәгънәдә – кешенең гәүдәсенең билгә кадәр булган арткы өлеше; хайваннарда муеннан койрыкка кадәр булган сырт буе: ***Арка*** *сөякләрем дә төне буе сызлады.* (Г. Әпсәләмов) Шулай ук тора-бара бу авазлар җыелмасы белән кулның учка каршы ягын, артын да аңлата башлаганнар, әлеге мәгънә бары контекстта гына аерыла ала (бу очракта аерым сүзтезмә дә җитә), контексттан тыш алганда бирелгән лексик берәмлек төп мәгънәдә килә: *кул* ***аркасы*** (*Хәлим иптәшен кул* ***аркасы*** *белән генә бер якка этеп җибәрде.* (Г. Гобәй))

Күп мәгънәле сүзнең яңа өстәмә мәгънәләренең мәгънәви мөмкинлекләре тар, чикләнгән булырга мөмкин. Әлеге тар мәгънәләр, башка бер сүзнең номинатив төп мәгънәсе белән бәйләнешкә кереп, тотрыклы сүзтезмәләр ясый ала. Мәсәлән, *тамак* исем сүз төркеме аерым бер күчерелмә мәгънәдә көндәлек азык-төлек, ризыкны белдерә, *ялгау* ‘бәйләп, ябыштырып, тегеп һ.б. юл белән әйберләрне бер-берсенә кушу, тоташтыру’ фигыле белән бергә килеп, *тамак ялгау* ‘ачыкканлыкны басар өчен, аз гына ашап алу’ мәгънәсендәге фразеологизмны китереп чыгара: *Фатыйма да, Шмит та өйләренә сугылып, тамак ялгау өчен, берәр сынык икмәк, берничә пешкән бәрәңге алдылар.* (А. Расих)

Полисемантик сүзнең компонентлары арасында аерым семантик бәйләнеш яши. Әлеге бәйләнеш нигезендә мәгънәләрнең бу сүзгә караганлыгын дәлилли алабыз. Шушы бәйләнеш сүзнең мәгънәләре арасында аерым гомуми семантик элементлар булуыннан чыгып билгеләнә. Мисал өчен, *киртә* сүзен алыйк.

Әлеге сүзнең номинатив мәгънәсе – ‘егып ботаклардан арындырылган юан булмаган озын агач кәүсәсе, колга’: ***Киртәләрдән*** *генә корылган койма һәм җил капка аша йорт эче күренеп тора.* (Ш. Маннур) Сүзнең икенчел мәгънәсе – ‘өй, бакча, басу һ.б. әйләнәсендә шундый агач кәүсәләрен казык баганалар арасына буйга салып эшләнелгән аралы койма’: *Илгизәр, киртә арасыннан кысыла-кысыла кереп, әтисе янына килде.* (Г. Бәширов) Шулай ук аның ‘сугыш кырында дошманның хәрәкәтен тоткарлау өчен, чәнечкеле тимерчыбыктан ясалган ныгытма’ мәгънәсе дә бар:

*Сапёрлар бер тар участокны миналардан арчыйлар, тимерчыбык* ***киртәне*** *кисәләр.* (А. Шамов)

*Киртә* сүзе күчерелмә мәгънәдә ‘тоткар, тоткарлык’ дип бирелә: *Күршем инде билгеле киртә миңа һәр эштә.* (М. Җәлил) Яисә нәрсәнең дә булса ахыры, чиге, тәмамлануын аңлата: *Яхшылыкның киртәсе юк.* (М. Галиев)

Сүзнең барлык мәгънәләре арасында ‘гомуми тоткарлык, барьер’ мәгънәсе сиземләнә (схема):




Позицион яктан бәйле булсалар да, күп мәгънәле сүзнең лексик-семантик вариантлары бер-берсенә карата бәйсез яшәп киләләр, алар тәңгәл килергә мөмкин, әмма бер-берсенә каршы килмәскә тиешләр.

Яңа, әле таныш булмаган предметлар, күренешләр белән танышканда, без аларның башка предметлар, күренешләр белән охшаш якларына игътибар итәбез. Шунлыктан әлеге охшаш предмет, күренешләр бер сүз белән атала башларга мөмкин. Әлеге күренешнең даими булуы да бар.

Р е г у л я р (даими) к ү п м ә г ъ н ә л е л е к дигәндә, без бер семантик класска кергән сүзләрнең барысына яисә күбесенә хас булган семалар комбинациясен күздә тотабыз. Мәсәлән, ‘уку йорты’ архисемасына караган *мәктәп, университет, институт, мәдрәсә* кебек сүзләрне алыйк һәм әлеге төркемгә кергән *мәктәп* сүзе мисалында күпмәгънәлелек очракларын карап үтик. ‘Бина, корылма’ мәгънәсен белдерү: *Габделкаюм авыл мәктәбендә өч кыш укыды.* (М. Гали); *Ул алты почмаклы зур мәктәп салдырып*

*китте.* (Г. Ибраһимов) ‘Әлеге бинадагы кешеләр’ мәгънәсендә кулланылуы: *Бөтен мәктәп җыелышины көтте.* (М. Мәһдиев)

Нәтиҗә итеп әйткәндә, татар телендә бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр яшәп килә. Татар телендә күп мәгънәле сүзләр сан ягыннан күбрәк.

## § 19. Күп мәгънәле сүзнең семантик структурасы

Сүзнең мәгънәләре, икенче төрле әйткәндә лексик-семантик вариантлары, аның семантик структурасын тәшкил итәләр. Сүзнең семантик структурасы дип аның мәгънәви төзелеше атала.

Ул гаять хәрәкәтчән: яңа мәгънәләр барлыкка килә, искеләре юкка чыга, шул рәвешле төп мәгънә белән икенчел мәгънә арасында бәйләнеш үзгәрергә дә мөмкин. Аерым очракларда сүзнең икенчел мәгънәсе номинатив мәгънә булып китә. Мәсәлән, *башлы* һәм *башсыз* сүзләре. Электән үк әлеге сыйфатлар баш (гәүдә өлеше) булган һәм бу өлеш булмаган кешене (хайванны) аңлаткан. Тора-бара, алар сөйләмдә ‘акыллы, зиһенле, зирәк’ – ‘уйламыйча эшләүче, дуамал’ мәгънәләрендә кулланыла башлый. Әлеге лексик-семантик вариантлар аларның төп мәгънәләренә әйләнгәннәр: *Бу машинаны уйлап табучы кеше бик* ***башлы*** *булган, ул да синең кебек төрлечә уйлаган.* (А. Алиш); *(Ул) бик* ***башсыз*** *нәрсә, катр китүдән дә курка торган түгел.* (Г. Камал)

Сүз үзара бәйләнгән лексик-семантик вариантлар җыелмасын тәшкил итә, әлеге лексик-семантик вариантлар бер-берсе белән семантик ияртүле бәйләнеш белән якынаялар һәм аерым иерархик берлекне (топологияне) тәшкил итәләр. Күпмәгънәлелекнең берничә топологик төрен аерып күрсәтергә мөмкин.

1. Семантик чылбырлы төр. Әлеге төр күпмәгънәлелек булганда, лексик-семантик вариантлар бер-берсенә бер-бер артлы бәйләнеп килә, һәм шул рәвешле бер семантик чылбыр тәшкил итәләр. Мәсәлән, *йомшак* сүзен карап узыйк. Аның мәгънәләре түбәндәгечә: 1) ‘каты булмаган, капшап, тотып карауга тыгыз булмаган’: *Коймалар, өй түбәләре һәммәсе яңа яуган* ***йомшак*** *кар белән түшәлгәннәр.* (Г. Ибраһимов); 2) ‘тыйнак, басынкы’: *Госпитальдә эшләү дәверендә аның* ***йомшак*** *холкы шактый ныгып өлгерде.* (Г. Әпсәләмов); 3) ‘кешегә карата кискен, тупас булмаган’: *Көләч йөзе,* ***йомшак*** *сүзе белән керә кешеләрнең эченә.* (М. Гафури)

**Йомшак**




Татар телендә чылбырлы полисемия – сирәк очрый торган күренеш.

2. Радиаль полисемия дигәндә, барлык лексик-семантик вариантларның туры мәгънәгә бәйле булуы күздә тотыла. Мәсәлән: *аклык* сүзе. Аклык – 1) ‘ак булу’: *Җир йөзе йомшак **аклык** белән капланды.* (Г. Ибраһимов); 2) ‘битнең, тәннең төссезлеге’: бит ***аклыгы***; 3) ‘яктылык’: *Еракта таң **аклыгы** беленеп килә иде.* (И. Гази); 4) ‘вөҗданлылык, намуслылык, сафлык’: *Ул яна, бу дөньяны күрмәк булып **аклык** белән.* (Ш. Бабич)

**Аклык**




3. Катнаш полисемия (чылбырлы-радиаль) булганда, икенчел мәгънәләр төп мәгънәгә карата төрле мөнәсәбәттә яши. Әлеге күпмәгънәлелек төре еш очрый: *ырым* – 1) хорафат, йола: *Бередә төзәлмәс гарип кешеләрне, авыру атларны алып килеп, аларны*

*әфсенләү-өшкерү бик күптәннән бер* ***ырымга*** *әйләнгән иде.* (М. Галәү); 2) юрау: *Саран гына, йомыкый гына бу адәм, яшь булуына карамастан, һәртөрле дини хорафатларга,* ***ырымнарга*** *бик ышанучан кеше иде булса кирәк.* (Ф. Хөсни); 3) им-том, сихер: *Тәгъзимәнең үтереп башы сызлый. Имче карчыкны да чакырып карады. Тик өшкерүләр,* ***ырымнар*** *килешмәде.* (А. Расих); 4) сихерле дәвалау әйбере: *Син нәрсә, сеңлең урынына үзең миңа киләм дип, үз* ***ырымнарыңны*** *үзең эчеп тулгаклап утырасыңмыни?* (Н. Исәнбәт)

**Ырым**




Аерым сүз биргән барлык мәгънәләрнең һәм бу сүз кергән тезмәләрнең нигезендә сүзнең төп номинатив мәгънәсе ята дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Төп мәгънәдән барлыкка килгән икенчел мәгънәләр үзләре тагын яңа лексик-семантик вариантлар тудырырга мөмкин. Шундый икенчел мәгънәдән ясалган яңа күчерелмә мәгънәләр төп мәгънәдән ераклашырга, төп мәгънә белән бәйләнә торган чылбырның бер буыны өзелергә яки өстәмә мәгънә үзе телдән төшеп калырга мөмкин. Мондый очракта яңа лексик-семантик вариант, бу семантик системадан чыгып, үзенә яңа микросистема хасил итә, ягъни ике сүзгә әйләнә, омоним барлыкка килә. Мәсәлән, *исәпсез* сыйфатын карасак, түбәндәге нәтиҗәгә килә алабыз. Сүзнең төп мәгънәсе – 'исәбе алынмаган, бик күп': *Болар, меңләгән елкылары, яхшы нәсел дөяләре,* ***исәпсез*** *куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында күчеп йөриләр.* (Г. Ибраһимов) Икенче лексик-семантик варианты – 'экономиясез, гамьсез арту': *Качакларның* ***исәпсез*** *күбәеп китүләре бушлай ярдәм бирү гайрәтен бик*

*тиз сүрелдерде.* (К. Нәҗми) Кайчандыр сүзнең икенче варианты ‘ваемсыз, сансыз’ (кешегә карата) мәгънә төсмерен бүлеп чыгара, вакыт узу белән, әлеге вариантлар арасында бәйләнеш югала, омоним барлыкка килә: ***Исәпсез*** *кеше су эчеп тә симерә.* (Мәкаль)

## § 20. Лексик мәгънә үзгәреше

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр яңа төшенчәләр барлыкка килүгә этәргеч булып торалар. Телдә яшәп килгән сүзләр, яңа төшенчәләргә атама буларак күчеп, яңа мәгънә төсмерләре белән байыйлар. Шуның нигезендә сүзләрнең семантик кыры киңәю күзәтелә. Бу исә телнең эчке мөмкинлекләренең күрсәткече һәм татар теленең сүзлек составы сан һәм сыйфат ягыннан үсү һәм баюының үтемле һәм экономияле юлы булып тора.

Телнең сүзлек составы үзгәрештә булган кебек, сүзнең мәгънәләре дә даими үзгәреп тора, моңа үз чиратында күп алшартлар сәбәп булырга мөмкин. Күпмәгънәлелекнең барлыкка килүенә экстралингвистик (телдән тыш) һәм интралингвистик (тел белән бәйле) факторлар йогынты ясавын инде искәртеп үткән идек.

Экстралингвистик шартларга килгәндә, без беренче чиратта экономия принцибын атап китәргә тиеш. Яңа барлыкка килгән һәр төшенчәне яңа сүз белән атау мөмкин түгел, бу – телдәге сүзләр санының чиксез артуына китерә, кеше барлык сүзләрне хәтерендә саклап кала алмаска мөмкин. Мисал өчен, *җөй* сүзен алып карыйк. Номинатив мәгънәдә әлеге сүз ‘тукыма, тире һ.б. нәрсәләрнең кисәкләрен бер-берсе белән тегеп беркеткән урын’ны белдерә: *Һәр чигештә күпме яшь тамчысы, / Күпме сагыш һәрбер* ***җөендә.*** (М. Җәлил). Тормыш барышында *җөй* сүзе «хирургик операцияләрдә тән тукымасын ялгау өчен тегелгән урын, шул операциядән соң калган эз» төшенчәсен дә аңлата башлый: *Күлмәгенең ачык якасы астыннан муенындагы яра* ***җөе*** *күренә иде.* (Г. Әпсәләмов) Охшашлыктан чыгып, шулай ук ул ‘техник эретеп ябыштырылган урын’ны да белдерә, мәсәлән, *эретеп ябыштырылган* ***җөй.*** Шул рәвешле, бер сүз ярдәмендә кешегә берничә төшенчәне атау мөмкинлеге туа, бу очракта телнең сүзлек составы сыйфат ягыннан үсеш ала, *җөй* сүзенең лексик-семантик вариантлары арасында уртак ‘беркетелгән урын’ семасы сакланганлыктан, мәгънә буталчыкларыннан азат ителә.

Мәгънә үзгәрешләрендә икенче экстралингвистик фактор булып кеше аңының гомумиләштерү үзлеге тора. Иң бай телләрнең сүзлек составы да чиксез түгел, төшенчәләр мәгънәләр санына караганда күпкә артыграк була. Шул сәбәпле кеше аңы, гомумиләштереп, бер төрдән булган төшенчәләрне бер үк сүз белән атый башлый. Мәсәлән, *итәк* сүзе туры мәгънәсендә ‘күлмәк, алъяпкыч, пальто һ.б. билдән түбәндәге өлеше’н белдерә: *Ханым, чүгәләп, күлмәк **итәген** кайтара төште дә җылы тимер идәнгә утырды.* (Ә. Еники) Тарихи үсеш дәверендә сүзнең шулай ук башка лексик-семантик вариантлары барлыкка килгән: 1) юбка, кием төре: *Ул киенгән газ **итәкләр** Җил-давылда ялтырый.* (Н. Исәнбәт); 2) тез өсте, ал: *Никтер әнине сагынам. Аның **итәгенә** ятып, озак еглыйсым, дөньяның мине җәберләве турында йөрәгемдә уянган зардан күз яшем белән бушанасым килә.* (Г. Ибраһимов); 3) үлчәү берәмлеге, итәкнең алгы өлеше кадәр: *Сиңа менә, бер **итәк**... кәнфит, прәннек, чикләвек, җимеш.... бары да бар.* (Ф. Бурнаш); 4) салават күперенең чите: *Салават күперенең бер **итәге** иген кырына терәлгән.* (Ә. Еники); 5) урман, болын һ.б. кырые, чите: *Урман **итәгендә**, безнең яткан чокырдан бер ярты километр биредә, кечкенә авыл.* (Ф. Кәрим); 6) биек нәрсәнең сөзекләнеп җәелеп киткән астагы кырые, чите: *Ниһаять, соңгы үрне менеп, тау **итәгендә** яткан авыл каршына килеп чыкты Гыйлемхан.* (Р. Мөхәммәдиев); 6) диңгез, елга, океан яры: *Фәтхи инеш **итәгенә** төшеп китте.* (Ш. Камал); 7) эз, игътибарлылык: *Авыл халкы, аның (этнең) улавын ишетү белән, таралган **итәген** тиз генә җыеп ала.* (Ф. Кәрим)

Сүзләрнең семантик үзгәрешләргә дучар булуына социаль факторлар да зур йогынты ясый. Һәрбер иҗтимагый төркем, җирлек үзенә генә хас атамалар белән характерланырга мөмкин. Сүз, әлеге иҗтимагый, мәдәни, һөнәри төркемнәрдә аерым мәгънә төсмерләренә ия булып, күп мәгънәле булып китә. Мәсәлән, *бозҗра* сүзе спортчылар телендә ‘көрәш мәйданы’ мәгънәсендә кулланыла.

Лексик мәгънәнең үзгәрү күренеше арго һәм жаргон сүзләр арасында да шактый киң таралган. Мәсәлән, *карга* сүзенең номинатив мәгънәсе – ‘козгыннар семьялыгыннан елтыр кара яки шәмәхә каурыйлы урта зурлыктагы кош’: *Карга килсә, кар китә.* (Мәкаль) Жаргон лексикада *карга* сүзе уен кәртенең билгеләренең берсе, пикины аңлата, мәсәлән: ***карга** короле*. *Койрык* сүзенең номинатив мәгънәсе – ‘хайван гәүдәсенең төп өлешеннән артка чыгып тора

торган озынча үсенте': *Эт тә ашатканда **койрык** болгар.* (Мәкаль) Әлеге сүз студентлар, яшьләр сленгында исә 'тапшырылмаган имтихан, зачёт' мәгънәсендә актив кулланыла, мәсәлән, *Вәлинең экономикадан **койрыгы** бар.* Латин теленнән кергән *академия* сүзенең төп мәгънәсе 'фән һәм сәнгатьне үстерү бурычы йөкләнелгән югары дәүләт учреждениесе' дигәнне аңлата: *Мин аның белән 1968 елның декабрендә Новосибирск янындагы **Академия** шәһәрчегендә таныштым.* (Вакытлы матбугаттан) Караклар сөйләмендә исә *академия* сүзенең коннотатив, өстәмә 'төрмә' мәгънәсе очрый.

Лексик мәгънә үзгәрүенә психологик факторларның да йогынтысы зур. Бирегә без төрле тыюларны, табу, эвфемизмнарны кертеп карыйбыз. Әлеге тыюлар курку, дини вазгыятьтән, әхлакый моментлардан чыгып билгеләнергә мөмкин. Шуңа бәйле, яңгырашлары һәм семантик эчтәлекләре ягыннан тупас, тискәре коннотатив мәгънәле сүзләр нейтраль мәгънәле башка берәмлекләр белән алмаштырыла. Мәсәлән, кандала – кеше каны белән тукланучы паразит бөҗәк. Татар халкы әлеге бөҗәкне *кандала* сүзе белән атаудан тыела, моның сәбәбе – кандала үрчергә мөмкин дип санауда. Шунлыктан еш кына номинатив мәгънәсе 'башаклы игеннәрне сукканда барлыкка килә торган калдыклар' булган кибәк сүзе белән атау очрый: *Болай да җилпуч-җилпуч **кибәк** җилгәреп, бер уч бөртек җыябыз.* (Н. Әхмәдиев); *Йосыф муеныннан **кибәк** тотты.* (Г. Коләхмәтов)

Интралингвистик факторлар дигәннән, без икетеллелек шартларында киң таралган калькалаштыру нәтиҗәсендә сүз мәгънәсе киңәюне күз алдында тотабыз. Мәсәлән, *тәрәзә* сүзен алыйк, аның номинатив мәгънәсе – 'эчендә кеше яши, эшли яисә кереп йөри торган корылмаларның диварында яктылык керсен өчен, пыяла куелган ачыклык, уем'. Ассоциатив мәгънәнең һәм структур модельнең рус теленнән алынуы нәтиҗәсендә, телебездә 'эш вакытында берәр сәбәптән килеп чыккан буш ара, буш сәгать' мәгънәсе активлашты: *Минем буш дәресем – **«тәрәзәм»** бар иде.* (Э. Касыймов)

Телгә бәйле сәбәпләргә әдәби тел белән диалектлар арасындагы бәйләнеш нәтиҗәсендә барлыкка килгән күпмәгънәлелекне дә кертеп карый алабыз. Әдәби телгә диалектизмнар теге яисә бу төшенчәгә аңлатма булмаган очракта үтеп керәләр. Әдәби тел сүзләре белән бер үк әйтелештә булган, әмма мәгънәләре аерымланган диалектизмнар саны байтак. Кайберләре мисалында аңлатма биреп

үтик. *Әсәр* сүзе әдәби телдә ‘нинди дә булса өлкәдә берәүнең иҗади хезмәте, иҗат җимеше’: *Әдәби **әсәр** укучының күңеленә тәэсир итәргә тиеш.* (А. Яхин) Сүз мишәр диалектының кузнец сөйләшендә ‘тамаша, кызык’ мәгънәсендә кулланыла, мәсәлән: *Тыңлагыз. Тагын бер **әсәр** сүлим* (ТТЗДС, 2009: 88).

*Бүлмә* сүзенең әдәби телдәге номинатив мәгънәсе ‘өйнең стена белән яки бүтәнчә аерып эшләнгән өлешләренең берсе’: *Мин аш **бүлмәсенә** кердем.* Урта диалектның минзәлә, каргалы сөйләшләрендә әлеге сүз ‘чолан’ мәгънәсендә дә очрый: *Безнең **бүлмә** йуг, әнә келәт* (минзәлә сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 142).

Тел белемендә «семантик деривация» термины яшәп килә. Гадәттә, деривация дигәннән, аерым билгене теләсә нинди икенчел билгеләр ярдәмендә үзгәртүне аңлыйлар, һәм термин сүз ясалышына кайтып кала. Семантик деривация булганда, лексик күпмәгънәлелек, ягъни сүзнең яңа мәгънәләр алуы күздә тотыла. Танылган рус лексикологы Д.Н. Шмелёв бу очракта әле мәгънәләр арасында ияртүле бәйләнеш (эпидигматик бәйләнеш) булуы мәҗбүрилеген ассызыклый.

С е м а н т и к д е р и в а ц и я (латинчадан *derivation* – тайпылыш, күчеш) дип сүзнең семантик ясалма, икенчел мәгънәләре, семантик коннотацияләре, алардан чыгып семантик синкретизм барлыкка килү процессы атала. Әлеге термин тел белеме фәненә XX гасырның 30 нчы елларында поляк лингвисты Е. Курилович тарафыннан кертелә. Семантик деривация семантик үзгәрешләрнең сан ягыннан күрсәткече санала, ягъни яңа мәгънәләр сүзнең семантик кырын, күләмен киңәйтә.

Семантик деривация, барыннан да элек, сөйләм күренеше буларак характерланырга мөмкин, чөнки теге яисә бу коннотацияләрнең актуальләшүе әлеге тел берәмлеге кулланылган контекстка бәйләнгән була. Әлеге очракта телнең үз законннарына яраклаштырылып кулланыла торган сүзләрнең мәгънәләрен бутау куркынычы янамый. Чөнки күп мәгънәле сүз аерым бер сөйләм моментында үзенең бер мәгънәсендә генә очрый.

Мәгънә киңәю дүрт төрле юнәлештә барырга мөмкин:

1. Тормыштагы үзгәрешләргә бәйле барлыкка килгән яңа төшенчәләрне атау өчен, телдә инде яшәп килгән сүзләрне яңа мәгънәдә куллану. Мәсәлән, *ташлама* сүзе: 1) кемгә дә булса гомуми таләпләрне йомшарту, аның хаталарын һ.б. өлешчә гафу итү:

*Сиңа моннан соң **ташлама** булмаячак, аны белеп тор.* (Г. Галиев); 2) кемнең дә булса таләбеннән яки теләгеннән өлешчә үтәү йөзеннән эшләнгән эш, чыгыш: *Хуҗаларга килгән зарарны профсоюзлардан түләтүне тыя торган закон ... эшчеләргә кайбер **ташламалар** ясауны аңлата.* («Яңа тарих» дәреслеге); 3) хак-бәя мәсьәләсендә үзара тизрәк килешүгә юнәлтелгән тәкъдим: *Үсеп баручы илләр белән сәүдәдә **ташламалар** ясау* лексик-семантик вариантларында кулланыла. Соңгы ун-егерме елда сүзнең мәгънәләре киңәеп, ‘льгота, гомуми кагыйдәләрдән чыгарма буларак ниндидер җиңеллек бирү’ варианты барлыкка килде: *Хезмәт ветераны таныклыгы алдым, әмма миңа **ташламалар** бирүдән баш тарттылар.* («Мәдәни җомга»)

*Кыйммәт* сүзенең мәгънәләренә тукталыйк: 1) югары бәяле, зур бәяле: *Налогның зыяны һич безгә булмый аның өчен, мин товарны **кыйммәт** сатам.* (М. Гафури); 2) билгеле бер әһәмияткә ия булу, нәрсәнең дә булса әһәмияте, мөһимлеге: *Үзагачта ботаклар никадәр зуррак булса, үзагачның **кыйммәте** шулкадәр югарырак була.* (Г. Әпсәләмов); 3) кадер, бәя: *Тукай җәмгыятьтә кешенең авторитеты һәм **кыйммммәте** булуны күрергә теләде.* (Г. Халит); 4) мат. математик зурлыкларның эчтәлеге, мәгънәсе: ***Кыйммәтләрен** үзгәртмичә саклый торган зурлыклар даими зурлыклар дип атала.* (Алгебра) Югарыда китерелгән лексик-семантик вариантлар белән беррәттән, ‘икътисади товарны җитештерү өчен билгеле бер микъдарда сарыф ителгән абстракт хезмәт’ мәгънәсе дә өстәлә. ***Кыйммәт** – товар җитештерүчеләрнең товары әйберләшкән иҗтимагый хезмәте ул*(«Политэкономика» дәреслеге)

*Иптәш* сүзенең телдә даими, традицион кулланылыштагы мәгънәсе –‘эштә, тормышта, дөньяга караштa уртак сыйфат булудан якынайган, дуслашкан кеше’: *Әгәр **иптәшләре иптәш** булмаса, Корбангали абзый быел тегүгә, ихтимал, бөтенләй икенче бер малай ияртеп чыгарга мәҗбүр булган булыр иде.* (Ф. Хөсни) XX гасырның 20 нче елларында әлеге сүз ‘революцион партия, эшчеләр коллективы члены’ лексик-семантик вариантында кулланыла башлый: ***Иптәш** элементар нәрсәне аңламый: татарларны, башка милләтләрне христианлаштыру дәүләтне ныгыту максаты белән эшләнә.* (Х. Камалов) Әлеге сема соңыннан ‘совет җәмгыяте члены, совет гражданины’ мәгънәсенә киңәя: *Илле тугызынчы елны авылларны бер калхузга берләштереп, читтән китереп яңа*

*җитәкче – **иптәш** Гатауллинны куйдылар.* (Р. Батулла) Шулай ук сүз ‘гаиләдәге ир яки хатын (бер-берсенә карата)’ мәгънәсендә дә йөри башлый: *Еллар итү белән минем **иптәш** үзе шулай малай тудыдыр.* (Һ. Такташ)

*Күзлек* сүзенең номинатив мәгънәсе – ‘күзнең күрү сәләтендә кимчелекләр булганда яисә күзне көчле яктылыктан зарарланудан саклау өчен, күзгә киелә торган, ике пыяладан гыйбарәт оптик әсбап’: *Нәфисә бөтен йөзен каплап торган зур **күзлеге** аша әле бер якка, әле икенче якка карап ала.* (Г. Бәширов) Сүз, аерым ассоциацияләргә бәйле, ‘кемгә яки нәрсәгә дә булса билгеле бер караш, уңай яки тискәре мөнәсәбәт’ лексик-семантик вариантын ала. *Бөтен уен шушы метод **күзлегеннән** торып, җентекләп эшләнгән.* (М. Җәлил)

2. Алынма сүзләрне алыштыру өчен, телнең үз сүзләрен яңа мәгънәдә куллану, мәсәлән: *Берлек* – 1) бер сумлык акча: *(Ләйсән) йомарланган **берлек** сузды.* («Азат хатын»); 2) лингв. сүз бер генә кеше яки предмет турында барганда очрый торган төрләнү формасы: *Сан категориясенең берлек төре һәрвакыт нуль формада була, **берлекнең** үзенә аерым формативы юк.* (В. Хангилдин); 3) русча *союз, объединение* сүзләрен алыштыру максатыннан кулланыла, сүз «бердәмлек оешканлык» мәгънәсен дә ала: *Шулай ук Рәссамнар **берлеге** бинасында Габдулла Тукайның 120 һәм Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды.* («Казан утлары» )

3. Калькалаштыру юлы белән татар теленең үз сүзләренә яңа мәгънәләр өстәлә: *текә* «җир өстеннән зур почмак ясап күтәрелгән». *Ике тау арасындагы **текә** юлдан атны тыя-тыя төшетеләр.* (Ә. Еники) Соңрак әлеге сүз рус теленнән калькалаштыру нәтиҗәсендә *югары хакимлеккә ия булу* лексик-вариантында да кулланыла башлый. *Бездә законнар, кагыйдәләр көчлеләр, **«текәләр»** ягына авышырга бик сәләтле.* («Безнең гәҗит»)

Шулай ук *түбә* сүзенең «ниндидер бер криминал эшләрдә сакчы, ярдәмче, яклаучы ролен башкаручы структура» мәгънәсен дә монда кертеп карап була: *Шуңа күрә юлда **«түбә»** ролен башкарырга тиеш була.* («Безнең гәҗит»)

4. Күчерелмә мәгънәлелек нәтиҗәсендә сүздә барлыкка килгән семантик үзгәрешләр. Күчерелмә мәгънә дигәннән, бер предмет, күренешнең атамасы билгеле бер метонимик, метафорик яисә башка ассоциатив билгеләр ярдәмендә икенче бер предмет,

күренеш атамасына күчүе истә тотыла. Мәсәлән, *бәйрәм* сүзе туры мәгънәсендә – күңел ачып ял итү көне яки көннәре: ***Бәйрәм** көн шикелле Авианос эчендә: / Нindидер сөенеч һәркемнең йөзендә.* (Х. Туфан), ассоциацияләр нәтиҗәсендә сүз шулай ук «зур шатлык, куаныч тантана» күчерелмә мәгънәсен алган: *Мәдинәгә тик эш кенә булсын, эш – аның куанычы, шатлыгы, **бәйрәме.*** (М. Хәсәнов)

Сүзнең мәгънәләре арасында бәйләнешнең саклануы күчерелмә мәгънәлелек булганда туры мәгънә белән уртак билгенең саклануын да тәэмин итә. Мәсәлән, *авыз* сүзен карыйк, туры мәгънәсендә сүз «өске һәм аскы казналыклар арасыннан йоткылыкка кадәр куышланып киткән сөйләм (кешедә) һәм ашау өчен хезмәт итә торган әгъза»: ***Авызың** кыек булса, көзгегә үпкәләмә.* (Мәкаль) Әлеге сүз түбәндәге күчерелмә мәгънәләрдә дә очрый: «гаилә тәрбиясендәге кеше, тамак»: *Менә шул фәкыйр вә шуның өстенә әллә ничә **авызы** булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.* (Г. Тукай); «ваза, кувшин, шешә һ.б. савытларның тараеп яки киңәеп беткән, гадәттә, ябыла торган, өске ачык өлеше»: *Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның **авызын** бәйләп куя.* (А. Алиш); «мич, шалаш, оя, чокыр, кое һ.б. кебек эче куыш нәрсәләрнең алгы яки өске ягындагы ачык өлеше»: *Нургали тартып бетермәгән тәмәкесен, сүндермичә, мич **авызына** ыргытты.* (Ә. Еники); «елга, инеш коя торган урын, тамак»: *Без пароход йөртеп уйнаган ермак **авызында** пристань була.* (Г. Гобәй).

Тел белемендә күчерелмә мәгънәле сүзләрне генетик күчерелмә һәм күчерелмә мәгънәле сүзләргә бүлеп карыйлар.

Генетик күчерелмә мәгънәләр телдә туры мәгънәләр белән беррәттән кулланыла, алар эмоциональ-экспрессив бәяләү төсмерен алмый, аларның үзләренең мәгънәләре килеп чыгышлары ягыннан күчерелмә булалар. Мәсәлән, *койрык* сүзенең «хайван гәүдәсенең төп өлешеннән артка чыгып тора торган озынча үсенте» мәгънәсе (*Тиен дә **койрыктан** уңган: сикерсә – пружинадай булган, йокласа – юрган.* (А. Алиш)) татар теле җирлегендә барлыкка килсә, «йөзгеч җайланмаларында арткы өлеше һәм киль» дигән лексик-семантик вариант исә генетик күчерелмә мәгънәдә килә, мәсәлән, *Пароходның **койрык** ягында ышык һәм җылы иде.* (Ә. Еники)

Күчерелмә мәгънәләр исә образлылык белән характерланалар, аларда нindидер бәяләү төсмере була. Мәсәлән, *йөрәк* сүзен алыйк. *Йөрәк* ‘анат. кешедә яки хайванда күкрәк куышлыгында урнашып,

кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы капчыксыман үзәк орган'ны аңлата: *Мин сугышка керсәм, дошманымның / **Йөрәгенә** төзәп атармын.* (Ф. Кәрим) Күчерелмә мәгънәдә 'үзәк, кешенең эчке дөньясы' лексик-семантик вариантлары да кулланыла: *Кемне сөя икән Гөлчирәбез, / Кемдә икән аның **йөрәге**?* (Ф.Кәрим); *Сугыш башланып өлгермәде, дошман безнең илебезнең **йөрәгенә** кулын суза башлады.* (И. Гази).

Сүзне диахроник планда караганда, аның мәгънәләре, вакыт узу белән, кулланыштан төшеп калырга да мөмкин, бу мәгънә тараю күренеше була. Мәсәлән, *аш* гомумтөрки сүзе гомумән 'ризык' мәгънәсендә кулланылган: *Кеше кешедән өстен, әмма берәү дә **аштан** өстен түгел, – дип, фәлсәфәгә керешеп китте Гыймади.* (Ә. Фәйзи) Вакыт узу белән, әлеге лексик-семантик вариант пассивлашкан. Хәзерге татар телендә исә *аш* сүзе номинатив мәгънәдә 'беренчегә бирелә торган шулпалы ризыкны, ашамлыкны' белдерә: *Сыер итеннән пешкән кәбестә **ашыннан** да ким булмый бу.* (Г. Гобәй)

Күргәнебезчә, сүзнең мәгънәләре һәрдаим үзгәрештә, үсештә була. Алар, вакытлар узу белән, экстралингвистик, интралингвистик факторлар тәэсирендә я киңәергә, я тараерга мөмкиннәр. Мәгънәләр, артык киңәеп, семантик уртаклыкны югалта да ала, бу очракта күпмәгънәлелекнең таркалуы һәм омоним сүзләр хасил булу күзәтелә.

## § 21. Метафора һәм аның төрләре

Телнең үсешен, яшәеш үзенчәлекләрен билгеләүдә күпмәгънәлелекнең бер төре булган метафораның роле гаять зур. Метафорик күчешкә нигезләнгән полисемия, – һичшиксез, катлаулы күренеш.

М е т а ф о р а (грек. *metaphora* – күчеш) бер предмет атамасын билгеле бер төс, форма, урнашуы һ.б. ягыннан охшашлык нигезендә икенче бер предметка күчерү дигәнне аңлата. Мәсәлән, *Аннан хәнҗәрен кынысыннан тартып чыгарды, чәч пәкесе үткерләгән кеше кебек, бармак **битләре** белән хәнҗәренең үткерлеген тикшерергә кереште.* (Ф. Кәрим) *Бит* – кеше башының алгы өлеше, *йөз, бармак бите* дигәндә исә сүз «бармак очының тырнакка каршы, кабарынкы ягы» мәгънәсендә килеп, метафора тәшкил итә.

Метафорада бер үк вакытта ике мәгънә берләшә: аның беренчесе контекст аша белдерелә, ул – күчерелмә мәгънә, ә икенчесе –

номинатив мәгънә. Бу ике мәгънә арасында билгеле бер охшашлык барлыкка килә.

Тел белемендә метафораның түбәндәге охшашлыкка нигезләнеп ясалган очракларын аералар:

а) әйберләрнең форма ягыннан охшашлыгы: *алка* – коршау формасындагы боҗра: *Ул да булмый, Мәфруза, чыгып, туры айгырларны өзәңгедән тотып тынычландыра да көмеш тәңкәле каешларны капка башына кагылган **алкаларга** бәйли.* (Р. Вәлиев); икенче мәгънәсе – колак йомшагына тага торган асылма бизәнү әйбере: *Менә сиңа бүләк итеп бер алтын **алка** алып килдем.* (Г. Камал); шулай ук ’су яисә башка сыеклык өстендәге боҗралар лексик-семантик варианты бар: *Хәлим ишкәк очы чумган җирдәге су **алкаларына** карап бара.* (И. Гази)

Бу метафорик күчеш төре, барыннан да элек, конкрет семантикага ия булган исемнәргә хас. Татар телендә кеше (хайван) организмының аерым әгъзасы (өлеше) → нинди дә булса предметның детале (өлеше) комбинациясе (моделе) киң таралган. Мәсәлән, *колак:* 1) ‘ишетү органының колак тишеге тирәсендәге тышкы, кимерчәкле өлеше, тышкы колак’: *Җамали куяннарны, **колакларыннан** тотып* берәм-*берәм карап, санап, үз капчыгына сала.* (А. Әхмәт); 2) ‘колакчын’: *Шлем **колаклары** җилдә җилферди.* (Ф. Кәрим); 3) төрле әйберләрдә тотарга, элеп куярга уңайлы булсын өчен эшләнгән җайланма, колак сыман чыгынты: *Әби әллә ничә җиренә ямау салып бетергән кечкенә генә самавыр **колагына** барып тотына.* (Г. Гали)

*Тел:* 1) *анат.* умырткалыларда авыз куышлыгында тәм тату һәм азык чәйнәргә ярдәм итү өчен, кешеләрдә сөйләү өчен дә хезмәт итә торган орган*: Теш дигән койма артында / **Тел** дигән арыслан йөри.* (Мәкаль); 2) сәгатьләрнең озын саплы түгәрәк пластинка рәвешендәге маятнигы: *Фатих (аны) сәгатьне ачкыч белән борып-тикшереп карады, **телен** җибәрде.* (Э. Касыймов) һ.б.;

ә) әйберләрнең урнашу ягыннан охшашлыгы: *түбә:* 1) корылманың кар-яңгырдан саклый торган капламасы: *Монда бик шәп салынган, такта **түбә** белән ябылган йорт бар.* (М. Гафури); 2) башның иң югары өлеше: *Карт **түбәсе** түп-түгәрәк булып пеләшләнеп килгән башын түбән иде.* (А. Шамов)

Әлеге юл белән ясалган метафоралар даими полисемия күренешен хасил итәләр һәм кеше (хайван) организмының аерым әгъ-

засы (өлеше) → нинди дә булса предметның детале →‘географик объект (яки аның өлеше)’ моделе буенча ясалалар: *бугаз* 1) муенның алгы өлеше: *Бүре шунда ук бер атның* ***бугазына*** *ябышкан* (А. Алиш); 2) ике диңгезне, күлне һ.б. сулыкны тоташтыра торган тар су мәйданы: *диңгез бугазы* һ.б.

Шулай ук киемнең өлеше → географик объект комбинациясе дә бар, әмма ул сирәк таралган: *Сөмбел аңа куркып карады, үзе* ***итәк*** *очларын бөтерде.* (З. Кадыйрова); *Биек тау* ***итәгендә*** *матур елга ага, елга аръягыннан киң җәйләү, болын башлана.* (Р. Батулла);

б) аваз охшашлыгы: *улау*: 1) бертөрле сузып, өзлексез каты тавыш чыгару, гадәттә, ерткыч җанварлар чыгарган авазлар: *Төннәрдә бүреләр посёлокка якынрак килеп* ***улыйлар****, ә иртән каядыр посалар.* (Г. Әпсәләмов); 2) һава агымының бүре улавына охшатып тавыш чыгаруы: *Җил* ***улый****, сызгыра, диңгез һаман дулкынлана, дулый бара иде.* (Ш. Камал); 3) сузып елау: *Әпипә капка төбендә* ***улый*** *калды.* (Г. Бәширов)

*Сызгыру:* 1) һава агымын бөрелгән ирен яки кысылган теш яисә сыбызгы һ.б. аркылы көч белән үткәреп, нечкә ачы-кискен аваз чыгару: *Хәлил ике бармагын авызына кабып, әче итеп* ***сызгыра*** *(*М. Фәйзи); 2) сызгыруга охшаш тавыш белән чыңлау, ыжгыру: *Колак төбендә эче җил* ***сызгыра****.* (Р. Вәлиев)

*Ыңгырашу:* 1) авыртудан яки кайгыдан сузынкы, әрнүле авазлар чыгару: *Рифкать иреннәрен кысып* ***ыңгырашты.*** *(*Р. Вәлиев); 2) охшаш тавышлар чыгарып шыгырдау: *Мәчет манарасы, җил чыккан саен, менә-менә авам дип* ***ыңгыраша****.* (Р. Вәлиев);

в) эчке охшашлык һәм ассоциация охшашлыгы: *усал*: 1) ачулы, кырыс, начар холыклы (кешегә карата): *Үземнең киленем* ***усал****, кызымның биеме* ***усал****.* (Мәкаль); 2) бик каты, салкын җил хакында: *Ярыктан кергән җил* ***усал*** *була.* (Мәкаль)

Шушы юл белән ясалган метафораларның күп өлешен шулай ук хайван атамалары → кешенең холкы комбинациясе тәшкил итә. Мәсәлән, *төлке*: 1) этләр семьялыгыннан эттән кечерәк ерткыч хайван: *Бар* ***төлке*** *дә үз койрыгын мактар.* (Мәкаль); 2) хәйләкәр, елгыр кеше: *Әнә базар капкасына бит: «Хак сәүдәгәр, алданма, күршең –* ***төлке****, көндәшең – бүре!» – дип язылган.* («Безнең гәҗит»);

г) эш, процесс охшашлыгы: *карау*: 1) карашны кемгә яки нәрсәгә юнәлтү, төбәү: *Төштә көзгегә* ***карау*** *яки яңа аяк киеме кию –*

*тормышка чыгу* (юрау); 2) тәрбияләү, кем яисә нәрсә турында кайгырту: *Зөлфия авыру әнисен* ***карады;***

д) тәэсир калдыру буенча охшашлык: *кайнау:* 1) кайнар хәлгә килү (сыеклык турында): *Бәрәңге пешеп чыккач, сөт салып* ***кайнау*** *хәленә җиткерәбез.* (Г. Әхмәтҗанов); 2) ярсып, ашкынып тору, ярсу: *Аның хисләре* ***кайнап*** *тора.* Күп очракта әлеге төр күчеш эмоциональ-экспрессив төсмергә ия;

е) халәт билгесе буенча охшашлык: *бозу:* 1) яраксыз хәлгә кертү: *Май ботканы* ***бозмый.*** (Мәкаль); 2) холыкны начар якка үзгәртү: *Әле сөйләп туктаган бабай безне кешеләрне* ***бозуда****, диннән яздыруда гаепли.* (М. Әмир);

ж) хәрәкәт динамикасы охшашлыгы: *яшен*: 1) атмосфера электрының һавада бушануыннан барлыкка килгән, кисәк кенә ялтырап киткән көчле чаткы: ***Яшен*** *яшьнәп, җир йөзе ялтырап киткән иде.* (Ш. Камал); 2) җитез кеше турында: *Яшел күлмәк Фәйрүзәкәй эштә нәкъ* ***яшен*** *иде.* (М. Җәлил) Әлеге төр күчешләрдә төп мәгънә тереклек дөньясына, икенчел күчерелмә мәгънә кеше, кеше тормышына бәйле була: борча номинатив мәгънәсендә паразит вак бөҗәкне белдерсә, шулай ук күчерелмә мәгънәдә үтә хәрәкәтчән кешегә карата да кулланыла: *Кандалалар белән* ***борчалар*** *үзен үрле-кырлы сикертәләр бугай.* (Г. Камал); *– Ә бу* ***борчалар****? Ни эшләп йөриләр? – Кызык күреп йөриләр.* (Г. Гобәй);

җ) зурлык, күләм охшашлыгы: *уймак*: 1) бармак очын энә тишмәсен өчен кулланыла торган кул эше әсбабы: К*орбангали абзый, түшенә энәләр кадап, янына кайчысын, акбурын, уймагын алып, иләгән тиреләр арасына утырды.* (Ф. Хөсни); 2) кечкенә буйлы кеше хакында: *Минем балам* ***уймак*** *кына әле;*

з) халәт билгесенең процесс билгесе белән охшашлыгы: *кору*: 1) коры хәлгә килү, кибү: *Тәрәзә төбендәге чәчәкләр корыган иде*; 2) нәрсәнең дә булса яшәү мөмкинлекләре юкка чыгу: *Нәсел* ***кору*** *– аяныч күренеш.*

*Чуму*: 1) суга яки берәр төрле сыеклыкка күмелү: *Бу арада хакимлек иткән эссе көннәрдә салкын суга* ***чуму*** *хакында кем генә хыялланмый икән?!* («Ватаным Татарстан»); 2) уй биләп алу, хискә бирелү: *Эстетик ләззәт алып, китап дөньясына* ***чуму*** *– ул икенче.* («Ватаным Татарстан»)

Барлыкка килү ягыннан метафора түбәндәге төркемнәргә аерыла:

1. Гомумтел (номинатив, үле) метафоралары. Әлеге төр метафоралар образлылыкларын югалтканнар, мәгънәләре стандартлашкан: *Үзе китапның* ***бите*** *буенча борынын йөртә һәм иреннәрен селкетә икән. Яссы идәндә зыр-зыр бөтерелгән шешәнең* ***авызы*** *әле беребезгә, әле икенчебезгә карады.* («Безнең гәҗит»)

2. Гомумпоэтик (образлы) метафоралар укучы яки сөйләүче тарафыннан образ буларак кабул ителә торган сүзләр булып торалар. Мисаллар: *Әйтерсең ул аның белән түгел, ә тәрәзә артындагы төпсез* ***төн диңгезе*** *белән сөйләшә иде.* (Р. Вәлиев); *Күк йөзен* ***яшен камчысы*** *сызып узды.* (М. Мәһдиев); *Мәрьям урамда* ***халык ташкыны*** *белән бергә атлады.* (Г. Бәширов); ***Язмыш дулкыннары*** *белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган өйләрдә туып үстеләр.* (Г. Ибраһимов); *Язилә* ***җир куенына*** *кереп ятты.* (Р. Рахман)

3. Индивидуаль (автор) метафоралар – автор тарафыннан уйлап табылган, телдә моңа кадәр күзәтелмәгән яңа төр күчерелмә мәгънәдәге сүзләр: ***Мич көймәсенә*** *тулган ут толымнары тагын да шәбрәк ялкынлана башлый.* (Ш. Маннур); *Әйтерсең шушы поездддан төшеп калса, ул* ***вакыт арбасыннан*** *төшеп калыр.* (Р. Вәлиев)

Функция буенча күчешне күп очракта метафораның бер төре буларак кабул итәләр. Ул бер үк яисә охшаш функция башкарган ике төрле денотатның бер гомуми атама алуына нигезләнә. Вакыт үтү белән, әйбернең формасы, төсе, зурлыгы, күләме үзгәреш кичерсә дә, башкарган функциясе шул ук калырга мөмкин. Мәсәлән, *чүмеч* сүзен алыйк. Лексик берәмлекнең номинатив мәгънәсе ‘су, аш һ.б. сыеклыкларны сосып алу өчен саплы савыт, гадәттә, кечкенә күләм (1–3 литр) сыйдырышлы’: *Фатыйма, агач табак белән* ***чүмеч*** *тотып, казан янына килде.* (И. Гази) Экскаваторның җир казу эшләрен башкару яки транспортка йөк төяү өчен кулланыла торган махсус җайланмасын вазифа охшашлыгы буенча шулай ук чүмеч дип атый башлыйлар: *Әлегәчә археолог күрәге, экскаватор* ***чүмече*** *яки бульдозер калагы актарып чыгарганны «көтеп», җир астында ятканнары да хәйран күптер.* (Р. Фәхретдинов)

Шулай ук функция буенча күчеш *аяк* сүзенең мәгънәләре арасында да күзәтелә. *Аяк:* 1) кешенең, кошларның һәм кайбер хайваннарның басып йөри торган әгъзалары: *Акбүз хуҗасының күкрәгенә алгы* ***аякларын*** куйды. (Г. Гобәй); 2) төрле механизмнарның

җиргә, идәнгә утыртып, бастырып куя торган терәге, җайланмасы: *Шунда ук күмерне бушатып, трубага су салу да файда итмәгән, самавырның **аягы** кубып төшкән.* (Ә. Фәйзи)

Метафора төс, форма, хәрәкәт, процесс тизлеге, ешлыгы һ.б. охшашлыкларга нигезләнсә, функция буенча күчеш исә вазифа буенча охшашлыкка нигезләнә: *Өстәлгә ике тәлинкә, юка гына итеп туралган ипи телемнәре һәм ике **кашык** куелган – Мөшкә **кашыгы**.*

Шулай итеп, метафора, күпмәгънәлелекнең бер төре буларак, татар теленең лексик системасын баетуда зур роль уйный.

## § 22. Метономия, аның нигезендә булган бәйләнешләр

Полисемиянең аерым бер төре буларак, метонимия – күп планлы күренеш. Метонимия (грек. *metonymia* – яңадан атау) – теге яисә бу предмет, күренеш атамасының, янәшәлеккә нигезләнеп, икенче бер предмет, күренешкә күчеше. Метонимик күчешнең асылын аерым бердәй һәм бердәй булмаган предметлар яки аларның билгеләренең яссылык, логик, синтагматик бәйләнешләре тәшкил итә. Мәсәлән, *ике чынаяк эчү* дигәндә *чынаяк* ‘савыт’ сүзе әлеге савыттагы эчемлекне аңлата.

Метонимия күренешендә алыштыручы һәм алмашынучы сүзләр арасында гомуми семантик өлеш булмый. Бу – метонимияне метафорадан аерып тора торган төп билге.

Метонимия түбәндәге күчешләргә нигезләнә:

1) эш, процесс һәм аның нәтиҗәсе: *яралану очрагы – аяк яралану;*

2) эш һәм аның урыны: *Болгар*: 1) дәүләт: ***Болгар** бөек дәүләт булган;* 2) шушы дәүләттә эшләнгән күн әйбер: *Аның олтаны – **болгар** олтаны, кырыеннан киселгән* (Г. Исхакый);

3) материал һәм аннан эшләнгән әйбер: *чуен*: 1) углерод һәм тимер катнашмасыннан гыйбарәт эретмә: *Хәзергесе көндә Сары Хисмәт **чуен** эретә торган домна мичендә.* (Ш. Маннур); 2) чуеннан эшләнгән: *Газинур, ишек төбендәге **чуеннан** су коеп, кулларын юа башлады.* (Г. Әпсәләмов)

*Бәллүр*: 1) материал: *Бер караганда, съезд сарае һавадан җиңел сыман, икенче караганда, **бәллүрдән** үтә күренмәле.* (Г. Әпсәләмов); 2) бәллүрдән эшләнгән савыт: *Өстәлдә эчемлекләр салынган кечкенә-кечкенә графиннар, алма тутырылган алсу-зәңгәр **бәллүрләр*** (Г. Әпсәләмов);

4) форма (сыйдырышлы әйбер) һәм аның эчтәлеге: *самовар:* 1) чәй кайнаткыч: ***Самавырга*** *чыра салгансың да күмер салмый чыгып кикәнсең, самоварың бөтенләй сүнеп беткән;* 2) әлеге савыттагы су, чәй: ***Самавырың*** *кайный бит.* (И. Гази);

5) оешма һәм аның урнашу урыны: *лаборатория:* 1) тәҗрибәләр үткәрү юлы белән төрле фәнни тикшеренү эшләре алып бара торган оешма: *Рамил Рәхмәтуллин – Оренбург дәүләт университетының фәнни* ***лаборатория*** *мөдире, Гиаматрикс, ягъни ясалма биотире авторы.* («Безнең гәҗит»); 2) тәҗрибәләр үткәрүче фәнни оешманың аерым бер бүлмәсе, кабинеты: *Ярый, барыйк, – дип, кинәт риза булды Алик һәм, теләр-теләмәс кенә,* ***лабораториягә*** *атлады.* (В. Исламетдин);

6) оешма һәм анда эшләүче кешеләр: *завод:* 1) эре сәнәгать һәм һөнәрчелек оешмасы: *Безнең урам көндез чиксез матур, / Әллә инде* ***завод*** *булганга?! / Завод матур, әллә станында / Син сызганып басып торганга?!* (М. *Җәлил)*; 2) завод эшчеләре: ***Завод*** *эшкә кереште*;

7) аерым бүлмә һәм анда булган кешеләр: *аудитория*: 1) лекция, доклад укыла торган зал яки зур бүлмә: *университетның зур* ***аудиториясе;*** 2) шунда лекция, доклад тыңлаучылар: *Алар, үз телләрен, милләтләрен яклап, теләсә нинди* ***аудитория*** *алдында чыгыш ясарга әзер.* («Сабантуй»);

8) торак пункт һәм анда яшәүчеләр: *Алда авыл күренде. – Бөтен авыл печәнгә төште.* Шуны искәртеп китәргә кирәк: барлык торак пункт атамалары анда яшәүче кешеләр мәгънәсендә кулланыла ала (гадәттә, *бөтен, барлык* алмашлыклары белән): ***Арча*** *шәһәре зур түгел. – Бөтен* ***Арча*** *бу хәбәргә шатланды;*

9) дәүләтнең башкаласы һәм дәүләт хакимияте: *Мәскәү, Берлин, Вашингтон, Лондон, Париж* һ.б. Мәсәлән, *Мәскәү илә Казанда юк, Питербур илә Оренбурда бар; Ташкент илә Уфада юк, Әстерхан илә Самарда бар.* (Табышмак); *Мәскәү үзенең тәкъдимнәрен кертте;*

10) фән тармагы һәм әлеге тармакның өйрәнелү предметы: *грамматика* (тел структурасы) – *грамматика* (тел белеме бүлеге);

11) социаль чара һәм анда катнашучылар: ***Конференция*** *май аена билгеләнде. –* ***Конференция*** *түбәндәге карарга килде;*

12) автор һәм ул иҗат иткән әсәр, әйбер, ачыш: *Габдулла* ***Тукай*** *– татар халкының бөек шагыйре. – Мин* ***Тукайны*** *яратам;*

13) эш һәм аны башкаручы предмет: *игәү*: 1) металл, мөгез яки агачны шомарту, үткенләү коралы; 2) шушы корал белән эш башкару;

14) абстракт предметның исеме һәм торышы: *яңалык*: 1) моңарчы билгеле булмаган яңа нәрсә: *хезмәтнең* ***яңалыгы;*** 2) хәбәр: *Радиодан* ***яңалык*** *әйттеләр;*

15) кош-корт исеме һәм шул кош итеннән әзерләнгән ризык: ***Каз*** *килсә – яз килә.* (Мәкаль)*; Тутырылган* ***каз*** *чыгардылар.*

Метонимия контексттан ирекле булырга мөмкин, шулай ук семантик, ситуатив һәм синтаксик яктан бәйлеләре дә очрый, аларны түбәндәге төрләргә аерып карыйлар:

1) лексик, ягъни телгә кереп киткән метонимия. Башка төрле аны номинатив дип тә атап йөртәләр: *язу* ***кәгазе*** *– кирәкле* ***кәгазь;***

2) конструктив метонимия, ягъни төрле синтаксик бәйләнешләр ярдәмендә текстның кыскаруы (эллипсисы) нәтиҗәсендә барлыкка килгән күчеш. Бу күчеш һәрвакытта үзенең кулланылыш контекстына бәйле: *Бер яктан* ***Бетховен,*** *астан* ***Сен-Санс,*** *форточкадан* ***Чайковский*** *ишетелә.* (М. Мәһдиев)

Метонимиянең үзенчәлекле төре буларак синекдоха аерыла. Синекдоха (грек. *synekdoche* – бәйләнешле, сүзгә-сүз күчерү, шуны ук күз алдында тоту) – сүз мәгънәсен бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчерү дигән сүз. Мәсәлән: *Аргы якка китеп бара, /* ***Чигүле путалылар*** (Татар халык җыры) мисалында *чигүле путалылар* чигүле путалы кешеләрне аңлата. Гадәттә, синекдоха ситуатив номинациядә объектны аерып күрсәтә торган тышкы билгесе буенча атау өчен кулланыла.

Синекдоханың түбәндәге төрләрен аерып чыгарырга мөмкин:

1) күплек сан урынына берлек сан куллану: *сыер башы* (сыерның әгъзасы) һәм *сыер башы* (сыерларның сан берәмлеге). Күплек сан урынына берлек санны куллануны, лексик-семантик күренештән бигрәк, семантик-синтаксик һәм стилистик күренеш буларак тикшерү дөресрәк булыр, чөнки сүздәге сан грамматик категориясе аның лексик мәгънәсен үзгәртми;

2) бөтенне өлеш урынына куллану: *Моннан соң кызлар белән, мондагы вак-төяк эш беткәнче дип,* ***җиләк җыярга*** *киттеләр.* (М. Гафури); ***Урман*** *ягыннан мылтык аткан тавышлар ишетелде...* (Г. Гыйльманов); *Мин урман кистем* (берничә агач күздә тотыла); *Мин китап укыдым; Китап – белем чишмәсе;*

3) гомуми урынына хосусыйны куллану (бөтен атамасы урынына өлеш атамасын куллану): *Дәрәҗәле авыл картлары, эшнең начар бетәчәген күреп, тиз генә* ***Кара сакал*** *(мулла) ягыннан төштеләр.* (И. Гази)

Татар телендә, *кеше* сүзен алыштырып, киемнең ниндидер (әлеге кеше кигән, яисә күзгә ташланып торган) бер детале, өлеше атамасы яки аерым бер тән өлеше, әгъза исемен куллану еш очрый: *Коридорда* ***эшләпә*** *күренде.* (Т. Гыйззәт); *Ә* ***зәңгәр күзлек,*** *әйтерсең, тырнак астына энә тыга* .(М. Мәһдиев); ***Сары баш*** *сөрлегеп китте.* (Р. Вәлиев); ***Ак сакаллар*** *алардан тагын бер мәртәбә сорау алдылар.* (И. Гази)

Аерым очракларда бу төр синекдохалар ярдәмендә кешенең аерым бер иҗтимагый төркем вәкиле булуы да ассызыкланырга мөмкин: *Мин поездның Шәмәрдәнгә кермәячәген әйткәч,* ***зәңгәр пижамаларның*** *кәефе китте.* (М. Мәһдиев); ***Ак якалар*** (инглиз теленнән калька, ягъни физик хезмәт белән шөгыльләнмәүчеләр, офис хезмәткәрләре) *өчен авыр көннәр башланды.* («Ватаным Татарстан»); ***Кара беретлар*** (диңгезчеләр) *хезмәттәшләре, полкташлары белән очраша.* («Татар-информ»); *Төбәк бүлеге ачылгач, җирле* ***зәңгәр беретларның*** (десантникларның) *мөмкинлекләре тагын да артты.* («Татар-информ»)

Аерым милләтнең барлык вәкилләрен яисә телен күздә тотканда, милләт атамасын гына куллану шулай ук шушы төр синекдохага керә: ***Русны,*** *жидны гына түгел,* ***немецны*** *җиңәрлек булганчы укыйм.* (Г. Ибраһимов); ***Герман*** *безгә каршы сугыш ачкан.* (В. Нуруллин); ***Үзбәкне, казахны*** *солдатка алмыйлар икән.* (Г. Ибраһимов);

4) төр атамасы урынына төркемчә атамасын куллану. Мәсәлән, татар телендә еш кына, гаилә яки нинди дә булса кешеләр төркемен атау өчен, гаилә башлыгы (төркем башлыгы) исеме файдаланыла: *Яңа елны* ***Әминәләрдә*** *каршы алырга булдык.*

Татар телендә кешене, холкыннан, төс-кыяфәтеннән чыгып, башка сүзләр белән атап йөртү дә очрый: ***Сакаллы сабый*** (тиз ышанучан, самими кешегә карата); *Әнә,* ***Тиктормасов*** *бар ич әле.* (Ә. Әхәт)

Синекдоханың метонимиядән үзгә билгеләре дә бар. Метонимия тышкы уртаклыкны күздә тотса, синекдоха тышкы һәм эчке сыйфатларның уртаклыгына нигезләнә. Мәсәлән, ***алтын теш***

(материал һәм шул материалдан эшләнгән әйбер буенча тышкы уртаклыкка нигезләнгән метонимик күчеш) һәм ***Аксак** килеп китте* (кешенең физик кимчелеге белән үзенең эчке халәтенең бердәмлегенә нигезләнгән синекдоха).

Нәтиҗә итеп әйткәндә, метонимия телдә яңа мәгънәләр барлыкка килүгә һәм аларның үсешенә китерә, шул рәвешле, татар теленең лексик семантикасын тагын да баету чарасы булып тора.

Татар телендә күп мәгънәле лексик берәмлекләр шактый күп. Сүзнең лексик-семантик вариантлары уртак мәгънә бәйләнешләренә ия һәм аның семантик структурасын тәшкил итәләр. Сүзнең семантик структурасы гаять хәрәкәтчән: телдә даими рәвештә яңа мәгънәләр барлыкка килә, искеләре юкка чыга. Сүзнең яңа мәгънәләре хасил булу төрле экстралингвистик һәм интралингвистик факторларга бәйле. Телдә полисемиянең чикләре моносемия һәм омонимия күренешләренә бәйле күзаллана, ягъни, вакытлар узу белән, бер мәгънәле лексик берәмлекләр полисемантик сүзләргә әйләнергә мөмкин (яисә, киресенчә, күпмәгънәлеләре аерым мәгънәләре тараю нәтиҗәсендә моносемантик сүзләр булып китә ала). Күп мәгънәле сүзнең мәгънәләре ераклашуы нәтиҗәсендә, ике яисә аннан күбрәк омоним сүзләр барлыкка килергә мөмкин.

Сөйләм барышында сүзләр үзләренең бер генә лексик-семантик вариантын реальләштерә, шуңа күрә мәгънә буталчыклыгы булмый, ягъни, контексттан чыгып, без сүзнең нинди мәгънәдә кулланылуын аңлыйбыз. Аерым очракларда сүзнең мәгънә күчеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәгънә төсмерләре, үзләренең образлылыкларын саклаган хәлдә, ниндидер бер стилистик максаттан чыгып та кулланылырга мөмкин. Бу очракта без әдәбият белеме, стилистика, риторика фәннәрендә троп термины белән аталган сурәтләү чараларын истә тотабыз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, телдәге күпмәгънәлелек – һәрбер милли телнең гаять үзенчәлекле күренеше. Ул шул тел иясе булган халыкның көнкүреш үзенчәлекләренә, гореф-гадәтләренә һәм тел үсешенә бәйле.

## Татар телендә омономия күренеше

### § 23. Тел белемендә омонимнарны өйрәнү тарихы

Хәзерге тел белемендә бу мәсьәләгә багышланган хезмәтләрнең шактый булуына карамастан, әлеге көнгә кадәр омонимиянең табигатенә карата өч төрле фикер яшәп килә.

1. Телдә авазлар комплексының очраклы туры килүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән этимологик (гетероген) омонимнар гына бар дип санала (Ж. Жильерон, Р.И. Меннер, Ж. Орр, В.И. Абаев).

2. Омонимнар төрле сүзләр һәм формаларның фонетик конвергент эволюциясе[1] (алынмаларны да кертеп) һәм аерым бер сүзнең семантик конвергент эволюциясе[2] нәтиҗәсендә барлыкка киләләр (Л.А. Булаховский, Р.А. Будагов, К. Нюроп, С. Ульман).

3. Омонимнар сүзьясалыш процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килә (В.В. Виноградов, А.И. Смирницкий, Ю.С. Степанов, Ш. Балли һ.б.).

Татар тел белемендә дә омонимия күп кенә галимнәрнең тикшерену объекты булып тора. Мәсәлән, М. Бактиков «Телдә тышкы формалары бер булып, функцияләре ягыннан бер-берсенә бөтенләй охшамаган сүзләр бар. Гадәттә, мондый сүзләр исем дә, сыйфат та булып киләләр. Мәсәлән: *ат* сүзе, зат исеме булып килгәндә, дүрт аяклы бер хайванны белдерсә, икенче бер урында боерык фигыль булып, атарга тиешлекне белдерә», – дип күрсәтә. Күрсәтмәлелек итеп, М. Бактиков таблица рәвешендә зат исеме, боерык фигыль, хәл фигыль, сыйфат, сан сүз төркемнәренә кергән омонимнарга мисаллар китерә (Бактиков, 1931: 64–65).

Әдәбият теориясе буенча хезмәтендә Г. Сәгъди омонимнарга мондый билгеләмә бирә: «Сөйләмдәге сүзләр арасында аваз төзелешләре ягыннан бер төрле булып та, үзләре башка-башка мәгънәләрне аңлаткан сүзләр дә байтак. Аваз төзелешләре ягыннан берсе икенчесенә охшап та, мәгънәләре башка булган сүзләр омонимнар дип атала (*очсыз* – чиге юк, кыйммәт түгел; *төш* – югарыдан түбәнгә төш, вакыт – төш вакыты, урын, җир, орлык – чия төше һ.б.)». Галим

[1] Фонетик конвергент (латин. *con* – бергә + *vergere* – берләшү) эволюция – төрле сүзләрнең (формаларның) төрле авазлары арасында ниндидер охшашлык нәтиҗәсендә килеп чыккан үзгәреш процессы.

[2] Семантик конвергент эволюция – аерым сүзнең мәгънәләре арасында охшашлык, бәйләнеш нигезендә туган үзгәреш процессы.

омонимнарны дөрес һәм урынлы куллануның фикерне ачыклауда зур әһәмияткә ия булуын искәртә (Сәгъди, 1941: 116).

Ш.А. Рамазанов омонимнар дип аваздаш сүзләрне атый, аларны төп һәм ясалма төрләргә аера, омонимия күренешенең килеп чыгу сәбәпләренә туктала (Рамазанов, 1954: 126–127).

В.Н. Хангилдин да омонимнарны аваздаш сүзләр дип билгели. Ул аларны «бер-бере белән бәйләнешләре булмаган яки андый бәйләнешләре аңлашылмаган төрле мәгънәләрне белдерүче аваздаш сүзләр» дип атый һ.б. Галим шулай ук «яңа алфавитны һәм аның орфографиясен татар теленең үз эчке закончалыкларына тиешенчә буйсындырып җиткермәү аркасында, әдәби телебезнең сүзлек хәзинәсе хәрефтәш сүзләр – омографлар (ягъни авазлары һәм әйтелешләре бөтенләй башкача булган, ләкин бер үк төрле языла торган сүзләр) белән дә байтак чуарланды» дип белдерә. Автор омоним һәм омографларның сөйләмнең аңлашылуына комачаулавын, әлеге авырлыкларны бетерү өчен, бу сүзләрне контекстка куеп карау кирәклеген ассызыклый (Хангилдин, 1976: 41).

Р. Шакирова омонимнарны лексик, морфологик төрләргә бүлә, шулай ук төзелешләре ягыннан аларның төп һәм ясалма төрләрен аера (*сулау* ‘суга манчу’ – *сулау* ‘сулыш алу’ (лексик омонимнар); *-ма/-мә* фигыльдә юклыкны белдерә (*барма*), *-ма/-мә* исемдә сүз ясагыч (өстәмә)) (Шакирова, 1963: 152–157).

Х. Курбатов «Татар телендә грамматик омонимнар» мәкаләсендә омонимнарны «мәгънә ягыннан бер-берсенә һич тә якын булмаган аваздаш сүзләр яки аваздаш грамматик формалар» дип билгели (Курбатов, 1959: 85), ул омонимнарны лексик, лексик-грамматик һәм грамматик төрләргә һәм омоформаларга бүлеп карый. Шулай ук төрле мәгънә аңлата торган омонимик кушымчаларның унике төрен күрсәтә (Курбатов, 1959: 85).

С.М. Ибраһимов «синтаксик төзелешләре белән бердәй булып, берничә мәгънә аңлата торган сүзтезмә, әйләнмә һәм җөмләләрне синтаксик омонимнар» дип атый, аларны уңай һәм стиль омонимнарына бүлә (Ибраһимов, 1970: 210–213).

Г.Ф. Саттаров әйтелешләре бертөрле булып та, мәгънәләре ягыннан аерыла тораган кеше исемнәренә тукталып китә[1]. Омо-

---

[1] Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»ндә (1981) 10 меңгә якын кеше исеме бирелә, шуларның 10 сы – омонимик исемнәр.

нимик исемнәр бер үк исемнең мәгънәсе киңәю, диалектлардан яисә башка телләрдән кергән лексик берәмлекләр исәбенә байый. Мәсәлән, *Түләк* – 'язгы бәти', ***Түләк*** – 'түләнергә тиешле бурыч' мәгънәләрен йөрткән, чыгышлары ягыннан ике төрки телгә яисә диалектка караган борынгы төрки татар теленнән килә торган ир-ат исемнәре. *Назил* 'күктән иңгән фәрештә' – *Назил* 'ил назы, кадерле' исемнәренең беренчесе гарәп теленнән кергән, икенчесе *наз* фарсы, *ил* татар сүзләре кушылып ясалган.

Галим татар телендәге кеше исемнәренең омонимик билгеләрен өйрәнү аларның лексик-грамматик үзенчәлекләрен, мәгънәләрен ачыкларга ярдәм итә дип саный (Саттаров, 1984: 24–31).

Татар лексикологиясе дәреслекләрендә омонимия күренешенә аерым бүлекләр багышланган. Мәсәлән, К.Сабиров омонимнар дип «әйтелешләре һәм язылышлары бердәй, әмма мәгънәләре бөтенләй башка булган сүзләрне» атый (Хәзерге..., 1965: 28). Галим аваздаш сүзләрне лексик һәм лексик-,морфологик төрләргә аерып карый, омонимнарның исем, фигыль һәм сыйфат төркемнәрендә еш очравын күрсәтә. Шулай ук формаль төзелешләре ягыннан ул тамыр (*яшь – яшь кеше, күз яше*) һәм ясагычлы (нигез) (*кылчык – балчык кылчыгы, башак кылчыгы*) омонимнарга бүлә. Грамматик табигатьләре ягыннан омонимнарны К. Сабиров тулы һәм өлешчә төрләргә аера. Ул шулай ук омонимия күренешенең барлыкка килү юлларын да күрсәтеп китә (Хәзерге..., 1965: 27–34).

Г.Х. Әхәтов омонимнарга «әйтелешләре бертөрле, ә мәгънәләре төрле булган сүзләр» дигән билгеләмә бирә, хәзерге татар теленең омонимнарга бик бай булуына басым ясый (*әйләнә* – окружность, *әйләнә* – крутится). Галим омонимнарның телебезнең байлыгын, аның горизонталь үсешен билгели торган лексик берәмлек булуын искәртә (Әхәтов, 1995: 12–17).

Ф.С. Сафиуллина омонимнар дип бер төрле аваз составына ия булган төрле сүзләрне атый. Мәсәлән, *кара* 'төс' – *кара* 'игътибар ит'. Ул омонимнарны күп мәгънәле сүзләрдән аерып карау зарурлыгын ассызыклый, аларны өч төркемгә бүлә: ике төрле мәгънә белдерә торган сүзләр (*үпкә* – үпкә белдерү, *үпкә* – үпкәсе авырта), өч мәгънә белдерә торган сүзләр (*кер* – бельё, *кер* – грязь, *кер* – войди), өчтән артык мәгънә белдерә торган сүзләр (*төш* – сон, *төш* – место, *төш* – семя, *төш* – выходи). Галимә омонимнар барлыкка килүнең җиде юлын аерып күрсәтә (Сафиуллина, 1999: 27–36).

Ф.Ә. Ганиев омонимнарның барлыкка килүен лексик-семантик ысулның шарты буларак күзаллый (*юлдаш* ‘кеше’ – *юлдаш* ‘сателлит’). Ул: «Бер үк чыганак сүзгә барып тоташмаган очраклы омонимнар лексик-семантик ысул белән сүзләр тәшкил итмиләр», – дип билгели (*якут* ‘кеше’– *якут* ‘асылташ’ (Ганиев, 1999: 96–97).

В.Х. Хаков омонимнарның стилистик кулланылышына игътибар юнәлтә, аваздаш сүзләрнең сөйләм эчтәлеген баютуына, аерым бер аһәң бирүенә басым ясап: «Мәгънә ягыннан бер-берсенә ерак торган аваздаш сүзләр (омонимнар) стилистик яктан телне баеталар. Аларның кулланылышы ерак тарих белән бәйләнгән, гасырлар буе үсеш нәтиҗәсендә омонимнар төрле мәгънә үзгәрешләре кичергәннәр, кайберләре исә, искереп, телдән төшеп тә калган», – дип искәртә (Хаков, 1999: 134).

И.Б. Бәширова татар телендә үзара бәйле булмаган ике яки аннан күбрәк мәгънә белдерә алу күренешен җентекле өйрәнә. Ул аны «инвариант – уртак нигезе сүз-лексема булган һәм әлеге сүзнең үзара бәйле булмаган ике яки күбрәк мәгънә белдерүе, ягъни тел күренеше буларак – омонимик сүзләр дип, сөйләм күренеше буларак, тагын каламбурлар дип тә йөртелгән «тел-сәнгать чарасы» дип атый. Табигате, структур төзелеше һәм функциональ мөмкинлеге белән катлаулы микросистема буларак, полисемия, синонимия, антонимия кебек башка катлаулы лексик-семантик категорияләр белән дә ныклы бәйләнеш-мөнәсәбәттә яши, дип белдерә (Бәширова, 2010: 227).

М.Б. Хәйруллин җәмгыятьтә барган глобальләштерү процесслары, барыннан да элек, телнең лексик системасында чагылыш таба дип саный, шунлыктан тел күренешләрен җентекле өйрәнү кирәклегенә басым ясый. Шул нисбәттән ул омонимнарның телне баетуын, татар телендә омонимнарның шактый күп булуын искәртә. Омонимнар арасында бернинди семантик бәйләнеш булмавын, аларның семантик аспектта төрле сүзләр булуын күрсәтә (Хайруллин, 2000: 99–105).

Ф. Хәкимҗанов «Омонимлык һәм омонимнарны төркемләү» мәкаләсендә (2004): «*Омонимия* һәм *омоним* лингвистик төшенчәләре фәкать нинди дә булса да мөнәсәбәт булганда гына билгеләнә алалар. Ике яки берничә мөстәкыйль сүзне аерып алып, аларны омоним дип тәкъдим итү фәнни таләпләргә җавап бирә алмый», – дип яза. Шулай ук ул «омоформалар телнең грамматик бүлегенә карый һәм морфоло-

гия күренеше булып өйрәнелергә тиеш» дип билгели (Хәкимҗанов, 2004: 19).

Г.Р. Галиуллина югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен «Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә» дигән ярдәмлегендә таблица һәм схемаларга салынган теоретик мәгълүмат, омонимнар буенча төрле типтагы күнегүләр, шулай ук омонимнарга лексик-семантик анализ үрнәген бирә (Галиуллина, 2007).

Татар телендә омонимнарны өйрәнү буенча берничә кандидатлык диссертациясе дә якланган. Мәсәлән, Б.С. Сәлимгәрәева, татар теленең омонимнар системасын махсус монографик планда өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый, 1982 елда аның материалларын монография рәвешендә бастырып чыгара. Әлеге монографиядә лексик, лексик-грамматик, грамматик омонимнар җентекле тикшерелә. Галимә шулай ук омонимнарның барлыкка килү юлларына аерым игътибар итә. Күпчелек галимнәр кебек үк, ул омонимнарның шактый өлеше семантик юл, ягъни күпмәгънәлелекнең таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килә дип саный, күчешнең төренә карап, семантик омонимнарны өчкә аерып күрсәтә: функциональ охшашлык буенча күчеш нәтиҗәсендә омонимлашкан сүзләр: *ай* (месяц) – *ай* (луна), *иң* (плечо) – *иң* (ширина); эчке охшашлык буенча омонимлашкан сүзләр: *изү* (мять) – *изү* (эксплуатировать), *биләү* (пеленать) – *биләү* (владеть); мәгънә охшашлыгы буенча омонимлашкан сүзләр: *кыр* (поле) – *кыр* (окраина, край чего-либо) (Сәлимгәрәева, 1982).

Д.М. Гаптелганиева семантик омонимнарның барлыкка килүенең төп чыганагы булган полисемияне тикшерә. Фигыль лексик-семантик омонимнарның барлыкка килү юлларын, шулай ук омонимия белән полисемия күренешләрен аеру критерийларын күрсәтә (Гаптелганиева, 1999).

Р.Р. Сәлахова кандидатлык диссертациясендә бер үк авазлардан торган кушымчаларның (ягъни омонимик суффиксларның) төрле мәгънәдә кулланыла алуын өйрәнә (Салахова, 2004).

Татар телендә омонимнарны туплаган ике сүзлек төзелгән, аларның икесе дә – икетелле, ягъни рус теленә тәрҗемәләр белән бирелә.

Ф.С. Сафиуллина, Л.М. Ризванова тарафыннан төзелгән «Татар теленең омонимнар сүзлеге»ндә (1997) киң кулланылышта

йөргән лексик омонимнар, шулай ук аерым диалектларда һәм татар әдәби телендә урын алган омофоннар китерелгән. Сүзлектә омоним сүз үзе татар телендә, аңлатмасы русча бирелә, барлыгы меңнән артык омоним һәм омоформа теркәлгән.

2004 елда Ф.С. Хәкимҗанов тарафыннан төзелгән«Татар теленең аңлатмалы татарча-русча омонимнар сүзлеге» басыла. Әлеге сүзлектә «А» – «К» хәрефләренә башланган лексик омонимнар һәм кайбер омоформалар урнашкан. Килеп чыгышлары буенча татар әдәби телендә кулланылган сүзләр, шулай ук диалекталь һәм искергән сүзләр урын алган. Сүзлек мәкаләсенең башында омоним сүзнең кайсы төркемгә караганлыгы, кайсы сүз төркеменнән булуы күрсәтелә, русчага тәрҗемәсе, мисал итеп әлеге сүз кергән контекст китерелә.

Омонимнар күптөрле сүзлекләрдә урын ала. Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә, шулай ук икетелле, диалектологик, терминологик һ.б. сүзлекләрдә омонимнар рим цифрлары белән күрсәтелеп, һәрберсе аерым сүзлек мәкаләсе итеп бирелә.

Күргәнебезчә, татар лингвистикасында омонимия мәсьәләсе төрле галимнәр тарафыннан өйрәнелгән һәм аның теге яисә бу үзенчәлегенә карата игътибарга лаеклы фикерләр әйтелгән.

### § 24. Омонимия күренешенә гомуми билгеләмә

Тел гыйлемендә омонимия күренешен өйрәнү гаять мөһим бурычлардан санала. Омонимия күренеше – ике яки аннан да артык сүзнең, тел билгесенең бер үк төрле матди тышчага ия булып, семантик яктан аерылуы ул. Телдә омонимия күренеше төрле катламнарда: лексикада, сүз ясалышында, грамматикада күзәтелә. Биредә без төп игътибарны лексик омонимия күренешенә юнәлтәбез. Лексик омонимнар дигәннән, бер грамматик класстан булган, аваз составлары, грамматик формалары ягыннан туры килә торган сүзләрне карыйбыз. Алар бары тик лексик мәгънәләре буенча гына аерылалар. Мәсәлән, *...Балалар **туп** атсын әйдә, / Уйнасын да шатлансын, / Олылар **туп** шартлатмасын, – / Олылар туп атмасын!* (Ш. Галиев) Беренче очракта туп ‘уенчык’, икенче туп сүзе ‘корал, ядрә’ мәгънәләренә ия.

Димәк, омонимнар (грек. *homos* – бертөрле, *onyma* – исем) – бертөрле язылыш, әйтелеш һәм грамматик формага ия, әмма мәгънәләре ягыннан аерыла торган сүзләр. Мәсәлән, *Нәни*

*кызчык тәүге тапкыр / Басып килә ап-ак* ***карга****. / Гаҗәпләнеп, шул мизгелдә / Аваз сала ала* ***карга.*** (Ә. Ситдикова) *Карга* сүзе – беренче очракта *кар* сүзенең берлек санда юнәлеш килешендә төрләнгән варианты, икенче очракта ‘козгыннар семьялыгыннан елтыр кара яки шәмәхә-кара каурыйлы урта зурлыктагы кош’ мәгънәсендә килә.

Омонимия – һәм эчтәлеге, һәм кулланылышы ягыннан шактый катлаулы лингвистик күренеш. Омонимнар еш кына сөйләмдә, стилистик максаттан чыгып, төрле каламбур төзүдә кулланыла. Бу төр лексиканың лексикографик әһәмияте дә зур, чөнки хәзерге компьютерлаштыру дәверендә, телнең корпусын формалаштырганда, электрон сүзлекләр төзегәндә, әлеге тел күренешен өйрәнү һәм системалаштыру аеруча мөһим.

Семантик яктан караганда, омонимнар арасында мәгънә-төшенчә бәйләнеше юк, аларның уртак семантик билгеләре булмый. *Мәсәлән: Күңел каралыгын бернинди* ***сабын*** *да агарта алмый.* (Мәкаль); *Балтасы суга төшкән* ***сабын*** *да атар.* (Мәкаль) мисалларында *сабын – сабын* сүзләре мәгънә ягыннан мәгънә-төшенчә уртаклыгына ия түгел, алар бары тик аерым грамматик формада әйтелеш һәм язылыш ягыннан тәңгәл киләләр.

Омонимнарның барлыкка килүенә сәбәп булырдай факторлар да шактый. Татар телендә омонимнар түбәндәге юллар белән барлыкка киләләр:

1) күпмәгънәлелек (полисемия) күренешенең таркалуы нәтиҗәсендә. Әлеге төр лексик омонимнар, күпмәгънәле сүзнең элек булган мәгънә уртаклыгы характерына карап, берничә төргә бүленәләр: *кыр* (урмансыз тигезлек, ачык мәйдан): *Урман – колак,* ***кыр*** *– күз.* (Мәкаль); *кыр* (нәрсәнеңдер чите, кырые, тирәсе): ***Кырындагын*** *кырык ел эзләгән.* (Мәкаль)

Әлеге процесс гаять катлаулы һәм дәвамлы, сүз мәгънәсе, тармакланып, омоним хасил итсен өчен, күп вакыт кирәк. Лексик мәгънәнең уртак семантик «үзәген», уртак компонентын югалту омоним сүзләр барлыкка килүнең төп билгесе булып тора. Омонимнарның күпмәгънәле сүзнең таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килүе шулай ук экстралингвистик факторларга да бәйле булырга мөмкин. Мәсәлән, *каурый* сүзенең семантик структурасы таркалуы әлеге реалийның юкка чыгуы белән бәйле. Чаг.: *Торна каурыен салган – Аяклары да томшыгы калган.* (Мәкаль);

*Сизә булыр, кулындагы каурый / Яктылыкка алып чыгасын* (З. Насыйбуллин);

2) әдәби телдәге сүзләр һәм диалекталь сүзләрнең омонимлашуы нәтиҗәсендә. Мәсәлән, әдәби телдә *диңгез* сүзе ‘океанның як-яктан коры җир һәм таулыклар, биеклекләр белән чолганып алынган, бүленеп калган өлеше’н белдерә: ***Диңгез*** *янында кое казымыйлар.* (Мәкаль) Урта диалектның минзәлә, бөре, мамадыш, пермь, златоуст сөйләшләрендә ‘нигез, өйнең фундаменты, шулай ук туып үскән төп йорт’ мәгънәсендә килә торган сүз: *Салқыннар башланғанчы, өйгә* ***диңгез*** *қорасы бар* (мамадыш сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 168).

*Алка* I – кыршау формасындагы боҗра, гадәттә, бизәнү әйбере*:* ***Алка****, нихәтле кыйммәт булса да, колак бәясе тормый.* (Мәкаль) *Алка* II мишәр диалектының ләмбрә, кузнец сөйләшләрендә ‘ачыга изгән бодай камырыннан клиндер формасында ясап, майда пешерелә торган ашамлык’: ***Алканы*** *келәңгеч майында пешерәләр, уртасы тишек* (ләмбрә сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 39).

*Өзү* I – бауны, җепне һ.б. тартып аеру; билгеле бер процессның барышын туктату: *Китапханәгә Кәбир әфәнде эшне* ***өзү*** *теләге белән барган иде.* (Ә. Фәйзи) *Өзү* II мишәр диалектының сергач сөйләшендә йөзү мәгънәсендәге сүз: ***Суга төшсә өзә белми ол, бата*** (сергач сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 509).

Татар теленең диалектларында да омоним сүзләрнең саны шактый. Алар төрле диалектларда, сөйләшләрдә сүзләрнең очраклы тәңгәл килүе нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Мәсәлән, *чылдыр* I – мишәр диалектының хвалын сөйләшендә хатын-кызның бизәнү әйбере, чулпы: *Чылдыр чәчнең очона куйыла, акчадан йә ахыктан йасап* (ТТЗДС, 2009: 771). *Чылдыр* II – урта диалектның пермь, красноуфим сөйләшләрендә ‘иске’ мәгънәсендә: *Инәдән бер генә малай,* ***чылдыр*** *ызбаға чықтинде (пермь сөйләше)* (ТТЗДС, 2009: 771).

*Қарамал* I – урта диалектның пермь сөйләшендә каражиләкне белдерә. *Қарамал* II – себер диалектларының төмән, тобол сөйләшләрендә ‘хәтфә, плюш’ мәгънәсендә: Қарамал камсуллар булган сәдәпле (төмән сөйләше). *Қарамал* III – урта диалектның әстерхан сөйләшендә ‘сыер малы’ (ТТЗДС, 2009: 391).

*Өргәү* I – урта диалектның пермь сөйләшендә ‘көйрәү’ мәгънәсендәге сүз: ***С****амаwырын куйган,* ***өргәб*** *утыра. Өргәү* II – урта

диалектның пермь, бөре, златоуст, красноуфим, мишәр диалектының башкыбаш сөйләшләрендә үрчү, ишәюне белдергән сүз: *Быйыл берсенең дә **өргәмәде** каз* (ТТЗДС, 2009: 512);

3) конверсия нәтиҗәсендә (исем фигыльләрнең исемләшүе): *буяу* ‘аерым махсус матдә сөртеп әйберне бүтән төскә кертү’ (*Алар ишекләрне зәңгәргә **буяу** хакында килештеләр*) – *буяу* ‘әйберне башка төскә кертү өчен кулланыла торган матдә’ (*Аның тузган чәчен буяганда, / Нинди **буяу** белән буйыйм да, / Зәңгәр күзкәйләрен, җанлы итеп, / Ничек кенә буяп куйыйм да, / Ничек тәрсим итим мин аны?* (Һ. Такташ)) *Үлчәү* ‘кемнең яисә нәрсәнең булса да зурлыгын, күләмен билгеләү’ (*Монда инде **үлчәү** юк, кем күпме һәм ничек кычкыра ала – кычкыра, кочаклый, үбә һәм тыела алмый елый.* (И. Салахов)); *үлчәү* ‘күләм, зурлыкны билгеләү җайланмасы’*: (Галиулла) инде арышлы капчыклар арасыннан үзенекен эзләп тапкан. Күтәреп, **үлчәү** янына алып бара* (И. Гази);

4) фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсендә. Татар телендә *бар* (*бару* фигыленең боерык фигыль формасы) һәм *бар* (барлыкны, булуны белдергән хәбәрлек сүз) сүзләре борынгы төрки телдә *бар* һәм *баар* формасында яшәгәннәр. Хәзерге телдә исә сузыклар озынлыгы сакланмаган, шул рәвешле, әлеге парга кергән сүзләр бертөрле әйтеләләр һәм омонимнар булалар: *Бармаган җирдә бакыр **бар,** күрмәгән җирдә көмеш **бар**, алмаган җирдә алтын **бар***. (Мәкаль); *Барсаң табып **бар**, егетне танып **бар.*** (Мәкаль) Шулай ук монда *ут* (ялкын) – *ут* (үлән), *ат* (исем) – *ат* (йорт хайваны), *ул* (зат алмашлыгы) – *ул* (ата-ананың ир баласы), *туры* (төз) – *туры* (ышанычлы) сүзләрен дә кертеп карап була;

5) башка телләрдән лексик омонимнар алу нәтиҗәсендә. Мәсәлән, *фокус* ‘сферик көзгедән кайтарылган яки линза аш үткәрелгән параллель нурларның кисешкән ноктасы’: *Тәрәзәдән төшкән иртәнге кояш нурын **фокуска** җыеп, линзадан ут алып утырган малай – Әскәров иде.* (М. Мәһдиев); *фокус* ‘күз алдый торган хәйлә, күренеш’: *Карт исә **фокус** күрсәтүче артист осталыгы белән чакма чагып, ут кабызды* (А. Шамов);

6) алынмаларның татар теленең үз сүзләре белән аваздашлыгы нәтиҗәсендә. Этимологик анализ ярдәмендә күп кенә омонимнарның алынмалар хисабына барлыкка килүе ачыклана. Алынма сүзнең фонетик структурасы телгә җайлаша ала. Асиммиляцияләнгән форма телнең үз сүзләре белән берничек тәңгәл килә алмый, әмма

реципиент-телнең аерым бер сүзе белән яңгыраштa туры килергә мөмкин. Мисаллар. *Бер **кит** балык куып килә, / **Кит** аннан, **кит** тимәсен. / Китеп китте **кит** ишкәкне, / Тишеп китте көймәсен.* (Мөҗәһит) *Карта* – ‘җир йөзенең төзелешен шартлы билгеләр ярдәмендә сурәтләгән сызым’: ***Карта** челтәрләре / Киртә булып ятты юлларга./ Кайда хәзер Кавказ, кемдә Кырым? / Карпаты да бары җырларда.* (М. Сәгъдиев) – *карта* ‘күшәүче хайваннар ашказанының агы аерым өлеше’: *Гаҗәп таныш ис аның борынын кытыклады: пешкән **карта** исе.* (Ә. Фәйзи);

7) морфологик ысул, ягъни аффиксация юлы белән: ***Кычыткан** / Әллә **кычыткан**, / Әллә юк. / Тик **кычыткан** – **кычыткан**. / Кычытмаганга чыкмаган, / Ул кычытканга чыккан.* (Мөҗәһит) ***Комсыз**, абынып егылса да, бер әйбер учлап алмыйча тормас.* (Мәкаль); ***Комсыз** гына пыяла ясап булмый. Баш сау булса, **башка** бүрек табылыр.* (Мәкаль); *Үз илем – алтын бишек, **башка** илнең төбе тишек.* (Мәкаль);

8) сүзнең күчерелмә мәгънә алу нәтиҗәсендә: *чиертү* ‘бөгелгән урта яки имән бармак ярдәмендә турайтып җибәреп кемгә яки нәрсәгә дә булса бәрү’: *Мәрьям хәзрәтнең борынына **чиерткәндә**, Закир санап торды.* (Ф. Әмирхан) – *чиертү* ‘кулга төшерү’: *Дүрт-биш тәңкә **чиертә** дип торганда гына, харап булдым!* (Г. Камал);

9) гади сүзтезмәләрнең фразеологик әйләнмәләргә әйләнүе. Мисаллар. *Ярминкәдә күпләп суган саттылар.* – «***Суган саттык***» (юк-бар сөйләп вакыт уздыру мәгънәсендә), – *диде Ислам теләр-теләмәс кенә.* (Н. Фәттах); *Алар, **киртәдән** чыгып, уңга борылдылар; Салкынның артык катылыгы аларга бераз **киртәдән** чыгарга* (тәртип бозу, иркенәю) *да хокук бирә дип уйлыйлар, күрәсең.* (Ф. Хөсни);

10) Сүзләрнең аббревиацияләр белән омонимлашуы нәтиҗәсендә. Бу инициаллы, ягъни сүзтезмәдәге, тезмә исемдәге сүзләрнең беренче хәрефе яки авазы кыскартылып ясалган аббревиацияләргә генә карый. Мәсәлән, *КАР* (Көньяк Африка Республикасы) – *кар* (явым-төшем), *РАК* (Республика азык-төлек корпорациясе) – *рак* (авыру атамасы), *АНТ* (Андрей Николаевич (аның конструкциясендәге самолётларның маркировкасы)) – *ант* (вәгъдә), *АТА* (Америка татарлары ассоциациясе) – *ата* (туганлык атамасы), *БАС* (балансның актив сальдосы) – *бас* (*басу* фигыленең

боерык фигыль формасы), *БИК* (бердәм икътисади киңлек) – *бик*, *БИШ* (Берләшкән ипи ширкәте) – *биш* (сан) һ.б.

Нәтиҗә итеп әйткәндә, омонимнар телнең эчке законнарына нигезләнеп барлыкка киләләр. Бу телгә хас башка үзенчәлекләр кебек үк омонимия дә – табигый күренеш.

## § 25. Омонимнарның төрләре

Омонимия күренеше телнең төрле катламында очрый һәм тел белеменең төрле яссылыгында өйрәнелә.

Язылышлары, мәгънәләре, ясалышлары, әйтелешләре ягыннан омонимнарны берничә төрле төркемләү яшәп килә.

Ясалышлары ягыннан омонимнар түбәндәге төрләргә бүленәләр:

1) төп (тамыр) омонимнар: *яр – яр, килеш – килеш, бал – бал*;

2) ясалма омонимнар: *басма – басма, ирен – ирен, ата – ата.*

Лексик категория буларак, лексик-семантик һәм грамматик мәгънәләре ягыннан омонимнар дүрт зур төркемгә бүленәләр:

1) лексик омонимнар: бер сүз төркеменә керәләр, тамыр сүз булып торалар: *ай – ай, ис – ис, табак – табак, кыек – кыек;*

2) лексик-грамматик: төрле сүз төркеменә карыйлар: *ач – ач, көй – көй, чык – чык, төш – төш;*

3) грамматик омонимнар сүздә грамматик формаларның омонимлашуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Аларның 2 төре аерыла:

а) морфологик (*омоморфема*– төрле функция үти торган кушымчаларның омонимлашуы: *тот**ка** – ат**ка**, җыр**сыз** – тоз**сыз***);

ә) синтаксик, омосинтагмалар (*омомодель* – төзелеше, формасы бертөрле, ә грамматик мәгънәсе төрле булган җөмлә яки җөмлә кисәкләре һәм әйләнмәләр: ***аңа*** *киләм* – ***аңа*** *юллыйм, белгән кеше – кеше белгән*). Омомодель – телнең синтаксик төзелешендә була. Төзелеше, формасы бертөрле, ә грамматик мәгънәсе төрле булган җөмлә яки җөмлә кисәкләре һәм әйләнмәләр омомодельләр яки синтаксик омонимнар дип аталалар. Омомодельләрне, сөйләмдә кулланылышларына карап, икегә – стиль омонимнарына һәм уңай омонимнарга бүләргә мөмкин. Боларның беренче төре җөмлә кисәкләре һәм җөмләләр белән бәйле. Ә икенчесе фразеологик

әйләнмәләр белән бәйләнештә карала. Грамматик омонимнар телнең «Грамматика» бүлегенә карый һәм сүзьясалышы, морфология һәм синтаксис кысаларында өйрәнеләләр;

4) фразеологик омонимнар[1]: *кул сузу – кул сузу* (урлау), *баштан сыйпау – баштан сыйпау* (ризалашу, үз итү); *башка бүрек кию – башка бүрек кию* (авторитет, дан казану).

Әйтелеш һәм язылышлары ягыннан омонимнарның дүрт төрен аерып күрсәтәләр:

1) саф лексик: *сыз – сыз, чокыр – чокыр;*

2) омофон: *бал авыз – балавыз, карт аю – картаю, Газиз – газиз, Себер–себер;*

3) омограф: *бал – бал, тир – тир*;

4) омоформа: *сала – сала, ага – ага, хатын – хатын.*

Лексикологиядә омонимнарны абсолют, тулы һәм өлешчә омонимнарга бүлеп карау да очрый.

Тулы омонимнар дигәннән, без бер үк сүз төркеменнән булган һәм барлык формалары да туры килгән сүзләрне күздә тотабыз (лексик омонимнар), мәсәлән, *исәп* ‘нәрсәнең дә булса гомуми саны, микъдары’; *исәп* ‘уй, фикер’.

Өлешчә омонимнарга бер үк сүз төркеменнән формалары аерымланган омонимнар кертелә (лексик-грамматик омонимнар): *сулау* ‘су сибү’ – *сулау* ‘сулыш алу’.

Бер үк авазлар җыелмасыннан булып, әмма килеп чыгышлары ягыннан төрле (фонетик үзгәрешләр, алынмалар хисабына) булган омонимнар фәндә г е т е р о г е н  о м о н и м н а р дип йөртелә. Бер үк сүзнең мәгънәләре таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән омонимнар г о м о г е н  о м о н и м н а р дип карала.

Л е к с и к  о м о н и м н а р тулы булалар, килешләр белән төрләнгәндә дә бер үк төрле кушымчалар алалар, мәсәлән, *Тәлгать токкан бер* ***тиен****, Мин Тәлгатьне үртимен: Менә, сиңа ун* ***тиен****, Бир син миңа бер* ***тиен.*** (Ш. Галиев) Төрләндереп карыйк:

[1] Фразеологик омонимнар турында тулырак «Фразеология» бүлегендә бирелә.

| Килешләр | ТИЕН 1 ‘җәнлек’ | | ТИЕН 2 ‘акча берәмлеге’ | |
|---|---|---|---|---|
| | берлектә | күплектә | берлектә | күплектә |
| Баш к. | тиенем | тиеннәрем | тиенем | тиеннәрем |
| Иялек к. | тиенемнең | тиеннәремнең | тиенемнең | тиеннәремнең |
| Юнәлеш к. | тиенемә | тиеннәремә | тиенемә | тиеннәремә |
| Төшем к. | тиенемне | тиеннәремне | тиенемне | тиеннәремне |
| Чыгыш к. | тиенемнән | тиеннәремнән | тиенемнән | тиеннәремнән |
| Урын-вакыт к. | тиенемдә | тиеннәремдә | тиенемдә | тиеннәремдә |

Лексик омонимнар, барлыкка килүләре ягыннан, этимологик һәм семантик омонимнарга бүленәләр.

Этимологик омонимнар дип бер-берсенә аваз җыелмасы ягыннан очраклы рәвештә туры килгән сүзләрне атыйлар, мәсәлән, *атлау* ‘йөрү, кешенең аяк атлавы’: *Вәлитов сикереп торды да, кызу-кызу* ***атлап****, урамга чыгып китте.* (Г. Бәширов); *атлау* ‘май язу’: *Урак урмак – уйнамак, гөбе* ***атламак*** *– җан чыкмак.* (Мәкаль) *Табак* – ‘билгеле бер зурлыктагы һәм формадагы кәгазь, калай, пыяла һ.б. үлчәме’*: Николай Анисимович бер* ***табак*** *пыяланы үзе кискәләп бирде.* (А. Расих) – *табак* ‘савыт’: *Сафия абыстай тыштан* ***табак*** *белән май алып керде* (А. Шамов) һ.б.

Күпмәгьнәлелекнең таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән лексик омонимнар семантик омонимнар дип атала: *кабу* I. ‘яна башлау’: *Дөрләп янды таш кибетләр, / Ут* ***капты*** *диварларга. / Бу ялкынның сөремнәре / Җитте Кызылъярларга.* (Ф. Яруллин); *кабу* II. ‘ашау өчен авызга алу, ашап-эчеп алу’: *Әби алдына гына карап утыра, аз-азлап кына ашын* ***каба****, җавап биргәндә, әледән-әле учы белән авызын сөрткәләп ала.* (Ә. Еники)

Татар телендә лексик омонимнар төрле сүз төркемнәрендә очрыйлар. Алар бигрәк тә исем, фигыль, сыйфат сүз төркемнәрендә күп күзәтеләләр, мәсәлән, *ял* – ‘арыганнан соң көч җыю, эштән туктап тору хәле’: *Көн – эш өчен, төн –* ***ял*** *өчен.* (Мәкаль); *ял* – ‘яллanып эшләгән өчен бирелә торган түләү, эш хакы’: *Тамак* ***ялына*** *бер малай яллыйм да малларымны үзем теләгәнчә көттерәм.* (М. Гали); *ял* – ‘кайбер хайваннарның муенындагы озын куе йон’: ***Ялыннан***

*тота алмасаң, койрыгынннан тота алмассың.* (Мәкаль); *Кундыру* – ‘төн үткәрү’: *Асияне әбиләре **кундырды;** кундыру* – ‘сугып җибәрү’: *Менә шунда яңакка шалт итеп **кундырдылар** берне.* (М. Гафури); *Зур* ‘күләмле, олы’: *Ул бернәрсәгә карамады, **зур** урамнан сулга, кечкенә тыкрыкка борылды* (Г. Ибраһимов); *зур* – ‘көчле, каты’: *Йыгыра чыктым. Эт бик **зур** өрә* (ТТЗДС, 2009: 139).

Шулай итеп, лексик омонимнар телнең эчке законнарына нигезләнеп барлыкка киләләр, төрле сүз төркемнәре эчендә яшиләр.

Татар телендә л е к с и к - г р а м м а т и к о м о н и м н а р байтак урын ала. *Омоформалар* (грек. *homos* – бертөрле + *forma* – форма) – аерым бер грамматик формада омонимлашкан сүзләр. Аларны шулай ук лексик-морфологик дип тә атыйлар: *Булмады миңа күңел **ачу,** Күңел ачу урынына артты **ачу.*** (М. Гафури)

Мондый омонимик дублетлар лексик мәгънәләре белән генә түгел, грамматик яктан да аерылалар. Омоформаларга бер үк сүз төркемендәге сүзләр белән бергә, төрле сүз төркемнәреннән булган сүзләр дә керәләр: ***Көзге** (сыйфат) боз **көзге** (исем) калынлыгы булса да ышан, язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма.* (Мәкаль)

Татар телендә омоформалар бик күп һәм төзелешләре ягыннан шактый төрле, мәсәлән, *Саран кеше – төпсез **мичкә** шикелле: аны һич тутырып булмый* (Мәкаль); ***Мичкә** ут керде – өйгә кот керде.* (Мәкаль); ***Ул** да булды – кыз кирәк.* (Әйтем); *Ялкауга эш кушсаң, **ул** сиңа акыл өйрәтер.* (Мәкаль); *Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, Вә юлны тапмый калмый һәр **адашкан**.* (Г. Тукай); ***Адашкан** кешегә эт өргән тавыш сандугач сайравыннан да ләззәтлерәк тоела.* (Мәкаль) Аларның күпчелеге исем – исем, фигыль – фигыль тибындагы омоформаларны тәшкил итә.

Татар телендә юклык кушымчалы фигыльләрнең (*-ма/-мә*) сүз ясагыч кушымчалар белән ясалган исемнәр белән аваздашлыгы киң таралган: *Йоклаган еланның койрыгына **ба́сма**.* (Мәкаль); *Агыйделгә **басма́** салдым, Каеннан сайлап кына. Яннарына барыр идем, Кош булып сайрап кына.* (Җыр); *Зәрия апасы **измә́** ташып өлгерә алмый.* (Г. Гыйльманов); *Ә менә татар, аны нихәтле кысма, **и́змә** – әле дә телен, тарихын онытып бетермәгән.* (Ә. Кәримуллин); *Йөгәнне тискәре **э́лмә,** урынсызга туңкәрелмә.* (Мәкаль); *Барда районында Рәшит Ягъфәров истәлегенә дүрт **элмә́** такта куелды* («Безнең гәҗит»). Аларның беренчесе исем сүз төркеменә карый,

ә икенчесе исә II зат боерык фигыльнең берлектәге юклык формасында килә.

Әлеге сүзләрне аеруда басымның ролен ассызыклап, омографлар рәтенә кертү дә очрый, әмма бу төр лексик берәмлекләрне, бары тик юклык формасында гына омонимлашканлыктан, омоформалар рәтендә карау дөресрәк. Мисалларга тукталып үтик: *Берәүгә **тормá** кирәк, берәүгә хөрмә кирәк.* (Мәкаль); *Мин бит сине чакырып китермәдем, үзең кит, җанны үртәп **тóрма**!* (Г. Гыйльманов).

Татар телендә язылышлары һәм мәгънәләре ягыннан аерылып, аваз составлары белән туры килә торган сүзләр бар. Алар о м о ф о н н а р (грек. *homos* – бертөрле + *phone* – аваз) дип атала. Шулай ук аларны фонетик омонимнар дип тә йөртәләр. Мәсәлән, татар телендә *Алсу* (кеше исеме) һәм *алсу* (төсне белдерүче сыйфат) үзара омофон булалар: *Кешеләргә ышанычым белән Гашыйк булдым гөлгә, каеннарга, **Алсу** таңга, тауга, давылларга, Күккә, җиргә, Бөтен дөньяга... Яшәү – сиңа, Тормыш – сиңа!..* (И. Иксанова); ***Алсу**, бүлмәсенә керү белән, Өске киемен алып ташлады, Ватык көзгесенә карый-карый, Карлы чәчен сүтә башлады...* (Һ. Такташ)

Мондый сүзләрнең төп өлешен омонимнар тәшкил итә, ләкин кайвакыт ике лексик берәмлекнең янәшә килүе дә аерым сүзләр белән бердәй яңгыраш бирә, алар да омофоннар рәтенә кертеп карала: *Абыйлары булганнарга хәтта **Картаю** да, **Карт аю** да кыймый тияргә, Сезгә без бар абый дияргә.* (Ш. Маннапов)

Татар телендәге омофоннар бер үк һәм төрле сүз төркемнәреннән булырга мөмкиннәр:

*Безнең **Галим** бигрәк **«галим»**,*
*Белгәннәре күп кенә...*
*Тискәре яклар дигәндә,*
*Зур **галим** безнең **Галим.*** (З. Хөснияр)

Гадәттә, яңгырашы белән охшаш булган сүзләрнең һәр икесенә дә мөстәкыйль функция хас, мәгънә бәйләнеше юк.

Татар телендә шулай ук бер төрле яңгырый торган аерым сүзләр һәм сүзтезмәләр бар. Алар мәгънәләре һәм язылышлары белән генә аерылалар. Аларны да омофоннар рәтенә кертеп карарга мөмкин: *Яхшылыкка эреп китәм, **балавыз** мин, / Мактап сөйлим изге эшне – **бал авыз** мин.* (Г. Тукай); *Кыш көне мин һәр иртәдә / Бит юарга **кар алдым.** / Ә җәй көне, юлда йөреп, / Кырда эшләп **каралдым.***

(Г. Нәбиуллин); *Бик җылы булгач бүлмә, / Йоклатырга* ***җыена*** *– / Күз алдында –* ***җыен «А».*** */ Аннан күзгә* ***күренә*** */ Бөтен җирдә* ***күр, энә,*** */ Һәм күзгә* ***«Б» эленә;*** */ Шуннан гына* ***беленә****: Минем дәрес әзерләүнең / Шундыйрак* ***төше*** *бу – / Абзагызның* ***төше*** *бу.* (Г. Рәхим)

Ясалышы ягыннан омофоннарның төрле модельләре була. Мисаллар: *Ни чүмәлә, ни* ***зурат****, ни акыллы, ни дурак.* (Әйтем) – зур ат: *Бу бик* ***зур ат****; Хуҗабикәләр теләсә* ***бишбармак*** *пешерә, теләсә токмач кисә. – Һәр кулда* ***биш бармак****. Яныннан* ***кит, мәче****; Әй, Апуш – изге балачак – югалмачы,* ***китмәче****, мине салкын бу дөньяда кабат ятим итмәче...* (Р. Харис)

Татар телендә күмәклек (уртаклык) һәм ялгызлык исемнәр тәңгәл килгәндә, сүзләр бер төрле яңгырый. Мондый омофоннар – чыгышлары ягыннан, гадәттә, бер үк сүзләр, әмма, саф омонимнардан аермалы буларак, төрле язылышлы була (омофон төзүче компонентларның берсе баш хәрефтән, ә икенчесе юл хәрефеннән языла): *Аның исеме –* ***Былтыр****! («Сабантуй») – Ул өеннән /* ***былтыр*** *чыгып киткән.*

Омофоннар матур әдәбият стилендә киң кулланылалар, аеруча поэтик жанрда сөйләмнең яңгырашын, эмоциональлеген арттырырга, аһәңлелекне көчәйтергә ярдәм итәләр.

О м о г р а ф л а р (бор. грек. *homos* – бертөрле һәм *grapho* – язам) аваз составлары һәм язылышлары бер үк, әйтелешләре һәм мәгънәләре белән аерыла торган сүзләр. Башкача аларны график омонимнар дип тә атыйлар.

Омографлар татар телендә омонимнарның башка төрләренә караганда чагыштырмача аз очрый. Компонентлары нинди сүз төркеменнән булуына карап, аларны түбәндәге төрләргә бүлеп карарга мөмкин:

1) татар теленең үз җирлегендә барлыкка килгән омографлар: *Ярый, ярый,* ***кодача****; Ходай, мәсәлән, шифасын бирсен.* (Ф. Әмирхан) – *Алар Әсмаларга* ***кодача*** *килгәннәр иде.* (С. Рафиков); *Бай абый! Бирче* ***хәер****! бик ач торам, – Йөз чытып, бай бер тишек акча ата*. (Г. Тукай) – *Минем кебекләр, әлбәттә, Һәркемгә дә эләкми…* ***Хәер****, мин дә синнән башка Беркемгә дә кирәкмим*. (Р. Миңнуллин); *Каракош та кояштан* ***ары*** *күтәрелә алмый.* (Мәкаль). – *Син эшләп* ***ары;***

2) татар теленә чит телләрдән кергән омографлар: *Күптән түгел генә Голландиядән мини* ***орган*** *килде.* («Шәһри Казан») – *ТР*

*Президенты Указы нигезендә, Татарстанда коррупциягә каршы даими эшче* ***орган*** *көрәшәчәк.* («Ватаным Татарстан»);

3) алынмалар белән татар теленең үз сүзләре арасында очраклы тәңгәллек нәтиҗәсендә килеп чыккан омографлар: *Исемемә* ***арка*** *сөяп, оныкларым уйга талыр.* (Р. Харис) – *Цилиндр өстә очлаеп тора торган* ***арка*** *белән төгәлләнгән, алары исә бизәлгән кирпечтән эшләнгән «пута» белән уратылган.* («Шәһри Казан»)

## § 26. Омонимия һәм полисемия күренешләрен чикләү

Хәзерге лексикология фәне алдында семантик омонимнарны өйрәнүдә омоним сүзләр һәм күп мәгънәле сүзләрне аеру мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Моны лексикография фәне дә ассызыклый. Чөнки еш кына аерым бер сүзлектә күп мәгънәле лексик берәмлекләр буларак теркәлгән сүзләр башка чыганакларда омоним дип күрсәтеләләр. Омонимия – сүзләрнең очраклы тәңгәллеге булса, полисемия – сүзнең диахроник планда бәйләнгән берничә мәгънәгә ия була алу үзенчәлеге.

Кайбер галимнәр омонимия һәм полисемияне чикләү критерийлары итеп, объектив факторлар буларак, сүз ясалышы һәм синтаксик характеристикаларын күрсәтәләр. Әмма шуны истә тоту зарур: сүз ясалышы рәтләре аерым мәгънәләр арасындагы бәйләнешнең өзелүе, таркалуы хакында гына түгел, бәлки икенчел мәгънәләр турында сөйли. Сүзнең аерым мәгънәләренең төрле синтаксик конструкцияләрдә кулланылуы һәрвакыт семантик таркалу була алмый.

Хәзерге тел белемендә омонимия һәм полисемия күренешен чикли торган берничә критерий аерылып чыгарыла.

1. Семантик (лексик) принцип. Омоним һәм күп мәгънәле берәмлекләрнең синонимик бәйләнешләрен ачыклау: әгәр дә охшаш яңгырашлы сүзләр бер үк синонимик ояга караса, омонимия күренеше урнашкан дип әйтү иртәрәк. Синонимнары төрле булган очракта исә, омонимия урнашкан дип әйтә алабыз. Шулай ук омоним сүзләрнең мәгънәләре бер-берсенә каршы килә, күп мәгънәле сүзләренең мәгънәләре исә, семантик уртаклык саклаган хәлдә, бер мәгънә структурасы тәшкил итәләр. Мәсәлән: *чишү* – ‘сүтү’: *Төеннәрне* ***чишү*** *тырышлык та, түземлек тә, ихтыяр көче дә тәрбияли* (Р. Нуруллин); *чишү* – ‘хәл итү’: *Чөнки ул барыбер сурәт*

*аша мәгънә эзләү булганга, табучы өчен гади мәсьәлә* ***чишү*** *булып кына калмый, һаман да мавыктыргыч кызыклы, поэтик иҗади процесс була.* (Н. Исәнбәт)

2. Грамматик (морфологик) принцип буенча күп мәгънәле сүз һәм омонимнар арасындагы аерма төрле сүз ясалышы ягыннан чыгып характерланырга мөмкин. Берничә мәгънәгә ия булган лексик берәмлекләр бер үк кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясарга мөмкин. Омоним сүзләрнең сүзьясалыш модельләре туры килми. Бу – әлеге сүзләрнең тулаем бер-берсеннән ераклашуы була. Мәсәлән:

*басу* I – ‘аягүрә торыш алу’; *баскыч* – ‘менү-төшү җайланмасы’– *басма* – ‘күперчек’.

*басу* II – ‘көч белән хәрәкәт ясап эш башкару’; *басма* – ‘китап, журнал һ.б. дөньяга чыгару эше’; *басым* – ‘көчлерәк тавыш белән әйтелеш’.

*басу* III – ‘кысу, сүндерү’; *баскак* – ‘халыктан салым җыю өчен куелган кешеләр’; *баскын* – ‘тыныч халыкларга, кабиләләргә каршы оештырылган талау яулары’.

3. Лексик-грамматик (катнаш) принцип булганда, сүзләрнең мәгънә яклары да ачыклана һәм шул ук вакытта сүзформаларның тәңгәл килүе дә истә тотыла. Сүзформаларны чагыштыру, ягъни деривацион бәйләнешләрне ачыклау әлеге ысулга кайтып кала. Сүзформалар охшаш яисә тәңгәл килгән очракта, бу сүзләр арасында семантик уртаклык күзәтелгәндә, без полисемия хакында сүз йөртә алабыз.

4. Тарихилык принцибы (этимологик принцип) булганда, синхрония белән диахрония арасында бәйләнеш урнаштырыла. Күп мәгънәле сүзнең лексик-семантик вариантлары арасында һәрвакыт бәйләнеш, мотивлашу хас. Шунлыктан аерым мәгънә кулланылыштан төшеп калганда, бер буын югалу тарихи мотивлашу тәртибен җимерергә мөмкин. Әгәр, вакыт үтү белән, сүзнең мәгънәләрен әлеге буын белән бәйләп булмаса, бу – омоним хасил булган дигән сүз. Мәсәлән, *ай* ‘күк җисеменең исеме’: ***Ай*** *белән кояш берәр генә була.* (Мәкаль) Халык, айга карап, ел фасылларын билгеләгән, шул рәвешле, вакыт үлчәү берәмлеген дә шулай ук атый башлаганнар: *Көне* ***ай*** *кебек, ае ел кебек.* (Әйтем); Хәзерге вакытта әлеге мәгънә уртаклыгы юк, шуңа алар омоним сүзләр була дип әйтә алабыз.

5. Структур принцип булганда, контекстуаль анализ алып барыла, ягъни сүзнең тематик бәйләнеше, лексик бәйлелекнең типик модельләре ачыклана, контекстның тулы семантикасы өйрәнелә.

Шуны искәртү зарур: югарыда күрсәтелгән ысуллар омонимнар белән полисемантик сүзләрне тулысынча аерып карарга ярдәм итә дигән сүз түгел. Күп мәгънәле сүзне омонимик сүзләрдән чикләү өчен, чагыштыру төрле яклап алып барылырга тиеш: әлеге чагыштыру нәтиҗәсендә охшаш яисә аермалы билгеләргә карап, омонимия – полисемия хакында сүз йөртә алабыз.

## § 27. Омонимнарның функциональ-стилистик вазифасы

Хәзерге татар телендә күп кенә омоним сүзләр кулланылышта йөри. Шуны да искәртү зарур: тел үсеше процессында аларның саны тагын да арта. Омонимнар сүзнең мәгълүмати функциясен чикли, чөнки төрле мәгънәләр бер үк формада чагылыш табалар. Тел белемендә омонимия күренеше аралашу өчен тискәре дип, гомумән тел өчен кире күренеш дип санала. Чыннан да, тыңлаучы, омонимик сүзләрнең мәгънәләрен аерганда, кыенлыклар кичерергә мөмкин, шулай ук телне чит тел буларак өйрәнгәндә дә каршылыклар тууы ихтимал.

Аерым очракларны искә алмаганда, омонимнарның телдә кулланылышы кыенлыклар тудырмый дияргә була, һәрвакыттта диярлек контекст омоним сүзләрнең мәгънә структурасын ачыклап килә һәм аларны дөрес аңлауның шарты булып тора. Шулай ук омонимнар еш кына кулланылыш даирәләре ягыннан аерылалар, экспрессив төсмерләре белән дә төрле булалар, гадәттә, сөйләмдә бик сирәк бергә туры киләләр. Шулай да омоним сүзләрнең бергә туры килүе мөмкин, бу очракта аерым стилистик максат шарт булып тора (телнең функциональ стильләрендә әлеге максатлар аерыла). Мәсәлән, матур әдәбиятта аваздаш сүзләр – бик үзенчәлекле стилистик чара, алар нигезендә телдә к а л а м б у р л а р (фр. *calambour* – сүз уйнату) – сүз уйнатулар барлыкка килә[1], мәсәлән, *Бер тауда ун* ***чишмә,*** *Сереңне син* ***чишмә****.* (С. Хәким); *Бу инешнең ике ярын / Тоташтыра такта* ***басма****. – Тар басмадан чыккан чакта, / Берүк сак бул, читкә* ***басма.*** (Ә. Ситдикова)

[1] Омоним рифмаларга корылган дүрт юллык шигырь төрки классик поэзиядә хәтта т о е к дигән аерым жанр тәшкил иткән.

Сөйләмне аһәңле һәм яңгырашлы итүдә, стилистик төсмерләр белән баетуда омонимнар, омоформалар зур роль уйныйлар. Эчтәлек белән тыгыз бәйләнешле рәвештә, бер җөмлә, бер фраза эчендә кулланылган омоним сүзләр сөйләмдә каламбур булып киләләр. Каламбурлар теге яисә бу персонажны, күренешне ачыкларга ярдәм итәләр, шулай ук геройның рухи халәтен, аның эчке кичерешләрен ачып бирүнең бер чарасы булып торалар.

Омонимнарның омофон, омограф төрләре, каламбур буларак, ешрак кулланыла. Мәсәлән, *Карбыз белән Мин* ***тату***. *– Рәхәт аның Тәмен* ***тату.*** (Г. Нәбиуллин); *Кайчакта күмелеп* ***ай калды***. *– Кемнеңдер күңеле* ***айкалды***. (М. Әгъләмов)

Омографлар әдәби әсәрләрдә, башлыча шигъри әсәрләрдә, стилистик максаттан, ягъни нинди дә булса сүз уйнату, тәэсир көчен арттыру максатыннан файдаланылалар. Мисал өчен, Г. Рәхимнең балалар өчен язылган «Кем дә кем тиз төшенә?» шигырь-уеныннан өзек китерик. *Мин әни сүзен тыңлыйм* / *Һәм эчтән генә уйлыйм* /: *«Өй түрендә* ***карамá,*** / *Ә син тышка* ***карáма.*** / *Озакламый* ***яз инде,*** / *Ә син монда дәфтәреңә* / *Өй эшләрең* ***яз инде****»*.

Омонимик сүзләр сөйләмдә кулланылганда, аваздаш сүзләр арасында бары тик аваз тәңгәллеге генә урнаша, мәгънә бәйләнеше булмый. Шунлыктан омонимнарны бергә куллану һәрвакытта диярлек көтелмәгәнлек эффекты барлыкка китерә, төрле сүз уйнатулар өчен мөмкинлекләр тудыра.

Каламбурлар (каламбур рифмалар) поэзиядә еш очрый, алар образ тудыру өчен, сөйләм ситуациясенең мөһим булуына басым ясау өчен кулланылалар.

Шулай итеп, омонимнар телнең тарихи үсеш нәтиҗәсе, төрле стильләрдә, аеруча матур әдәбиятта, публицистикада шактый еш очрыйлар. Мәгънә ягыннан бер-берсеннән ерак торган аваздаш сүзләр телне стилистик яктан баеталар.

## Татар телендә паронимия күренеше

### § 28. Тел белемендә паронимнарны өйрәнү тарихы

«Пароним» төшенчәсен билгеләүдә гомуми тел белемендә төрле фикерләр яши, мәсәлән, Европа тел белемендә паронимнар дип сөйләмдә бер-берсенә охшатып ялгыш кулланылган сүзләрне атыйлар.

Охшаш яңгырашлы сүзләргә игътибар рус тел белемендә башка милләт вәкилләренең рус телен үзләштерүдәге кыенлыкларын өйрәнүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килә. Биредә дә паронимнарны төрлечә атау белән очрашабыз: охшаш яңгырашлы, ләкин төрле мәгънәгә ия булган сүзләр (А.Н. Гвоздев); бер сүз төркеменә караган охшаш яңгырашлы сүзләр (М.М. Покровский); охшаш яңгырашлы сүзләр арасында мәгънә бәйләнешләре туу (В.В. Виноградов); аерым морфемалары тәңгәл килгән охшаш яңгыраштагы сүзләрнең ялгышлык белән яки махсус рәвештә (каламбур буларак) сөйләмдә кулланылуы (О.С. Ахманова); охшаш яңгырашлы сүзләр белән бергә, охшаш мәгънәле, әмма синонимия күренешеннән һәм күпмәгънәлелектән аерылып торган берәмлекләр (Ю.С. Степанов) һ.б. (Бу турыда: Вишнякова, 1984: 6–15.) Охшаш яңгырашлы сүзләрне өйрәнүгә О.В. Вишнякова махсус хезмәт багышлый (Вишнякова, 1984). Аның хезмәтеннән күренгәнчә, паронимнар белдергән төшенчәләре яки стилистик кулланылышлары ягыннан бер-берсеннән аерылып та торалар. Парономаслар исә категориаль уртаклыгы булмаган төрле төшенчәләрне белдерәләр. Паронимнар –лингвистик күренеш, ә парономаслар – психо-лингвистик күренеш, дип билгели автор (Вишнякова, 1984, 30).

Димәк, тел белемендә паронимнар турында фикерләр, нигездә, ике төрлегә кайтып кала: 1) сөйләшкәндә, аралашканда мәгънәләре бутала торган охшаш яңгырашлы сүзләр; 2) бер тамырдан барлыкка килгән, хәзерге тел үсешендә төрле мәгънәгә ия булган охшаш яңгырашлы сүзләр.

Татар тел белемендә пароним сүзләрне фәнни өйрәнүне К. Сабиров беренчеләрдән булып башлап җибәрә. Ул «пароним – языльшлары һәм әйтелешләре белән бер-берсенә шактый якын, әмма мәгънәләре белән бердәй булмаган төшенчәләрне атау өчен кулланыла торган термин» дип билгели (Сабиров, 1963: 35).

Югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен татар теле дәреслеге охшаш яңгырашлы *тугры – туры, гөл –гел, мең – мен* сүзләрен омонимнар дип аңлата (Хәзерге татар әдәби теле, 1965: 32–33). Искәрмә итеп әйткәндә, *тугры – туры, гөл – гел, мең – мен* сүзләрен синхроник планда әдәби тел күзлегеннән омонимнар дип аңлатып булмый, ләкин әдәби телне диалекталь сөйләм белән чагыштырганда (җирле сөйләшләрнең аваз

яңгырашы теге яки бу ягы белән әдәби телнекеннән аерылып тора), аларны омонимнар дип карау ихтималы бар.

В.Х. Хаков «пароним» атамасын әйтмәсә дә, охшаш яңгырашлы *баг – бәй – бәйге, ия – өй* кебек сүзләрнең тамырдаш булулары турында язып, күпмәгънәлелек турындагы мәгълүматны тирәнәйтеп бирә. Галим: «Телнең тарихи үсешендә кайбер сүзләрнең төзелеше дә һәм мәгънә эчтәлеге дә үзгәрә, бер мәгънә җирлегендә төрле төсмерләргә ия булган аваздаш сүзләр барлыкка килә», – дип яза (Хаков, 1979: 107–109; Хаков, 1993: 135).

Ф.С. Сафиуллина этимологик яктан бер тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр – сингармоник параллельләр белән таныштырып үтә (Сафиуллина, 1987: 86).

Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев тарафыннан төзелгән татар теле дәреслегендә: «Увуляр (кече тел) **к** тартыгын тел арты **к** тартыгы белән алмаштыру да омографлар хасил итә: *карта* (географик) – *карта* (аш казаны)», – дип бирелә (Сафиуллина, Зәкиев, 1994: 36). Мәгълүм булганча, омонимнарның бер төре омографлар – төрлечә әйтелә, ләкин бер төрле языла торган сүзләр, шуңа күрә *карта – қарта* сүзләрен омографларга кертеп карарга мөмкин. Ләкин сүзләрне мәгънәви аеруда катнашкан кече тел һәм тел арты тартыклары татар телендә икесе ике фонема булуын да искә алмыйча булмас, шуңа күрә аларны охшаш яңгырашлы сүзләр дисәк дөресрәк булыр.

Р.С. Абдуллина, паронимнарның барлыкка килү үзенчәлекләрен билгеләп, паронимнарны һәм парономасларны куллануда булган кайбер стилистик үзенчәлекләрне, стилистик хаталарны күзәтә, аларның сүзлек хәзинәсендә омонимнардан аерылып тора торган бер төркем булуын күрсәтеп уза. Галимә хезмәтләрендә паронимнарның барлыкка килүе, гарәп-фарсы сүзләренең паронимлыгы, пароним һәм парономасларның орфографиясе һәм орфоэпиясе һ.б. мәсьәләләргә туктала (Абдуллина, 1997: 3–61).

Хәзерге татар әдәби телендә, аеруча публицистик стильдә, онытылган лексик байлыгыбыз тергезелә. Монда сүзләр, мәгънә буталчыклыклары да күзәтелә. Шуңа күрә үз телебезнең паронимнарны, шулай ук татар теленә лексик яктан зур йогынты ясаган гарәп-фарсы алынмаларыннан булган паронимнар һәм парономаслар татар тел белемендә җентеклерәк яктыртуны таләп итә.

## § 29. Паронимия күренешенә гомуми билгеләмә

Паронимия (грек. *para* – янында, *onyma* – исем) – сүзләрнең (паронимнарның) авазлары ягыннан өлешчә охшаш, ә мәгънәләре буенча тулысынча яки өлешчә төрле булулары күренеше. Паронимия ул сөйләмдә сүзләрне аңлы рәвештә бер-берсенә якынайту яки аларны уйламыйча бер-берсе белән бутау (соңгысы сөйләмдә ялгыш куллануга кайтып кала) нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Паронимнар – яңгырашы ягыннан якын булган сүзләр; алар бер үк сүз төркеменә карыйлар, әмма төрле мәгънә белдерәләр: *абстрактлык – абстракция, экономия – экономика, кулачный – кулацкий, гоночный – гончий, командированный – командировочный, диктант – диктат, адресант – адресат* һ.б. Паронимнарга хас үзенчәлек – әлеге парларның охшаш яңгыраштa булуы гына түгел, тамыр яки нигез морфемаларның этимологик уртаклыгы да.

Ике сүз арасында табылган теләсә нинди уртак мәгънә охшаш яңгыраштагы сүзләрне паронимнар рәтенә кертеп карарга мөмкинлек бирми.

Мәгънә уртаклыгы ике төрле була ала: 1) теге яки бу сөйләм ситуациясендәге мәгънә уртаклыгы, 2) категориаль мәгънә уртаклыгы.

Кайбер охшаш яңгырашлы сүзләр арасында ситуатив мәгънә уртаклыгы булырга да мөмкин, ә категориаль мәгънә уртаклыгы булмый. Мәсәлән: *«Гәүһәр ташы – йөзек кашым». – Йөзегеңнең* ***ташы*** *нинди? Якутмы, әллә фирүзәме? – Йөзегемнең* ***кашы*** *төшкән.* Әлеге мисалларда *таш* һәм *каш* сүзләре – йөзеккә беркетелә торган таш яки металл кисәге турында сөйләшкәндә генә синонимнар. Ләкин бу ситуатив мәгънә генә әлеге сүзләрне «тамырдаш сүзләр» дип билгеләргә хокук бирми. Пароним сүзләр арасында ситуатив кына түгел, төп мәгънә (категориаль мәгънә) уртаклыгы була, чөнки алар – тамырдаш сүзләр. Паронимнарның мәгънә үзенчәлеген билгеләгәндә, вариант мәгънә, метафорик мәгънә (мәгънә күчеше) игътибарга алына.

Паронимнарның кайберләрендә аерым ситуатив мәгънә уртаклыгы булмаса да, категориаль мәгънә уртаклыгы була. Ягъни алар – ситуатив мәгънә белән бер-берсеннән аерылып торган паронимнар. Мәсәлән, хәзерге татар әдәби телендә *тибрәтү – тирбәтү, тибрәнү – тирбәнү* пароним сүзләре кайвакыт бер үк мәгънә

белдерәләр: *бишек* ***тирбәтү,*** *бишек* ***тибрәтү;*** *Сөялдем сөяннәргә,* ***тибрәлдем*** *имәннәрдә; / Сөялдем сөяннәргә,* ***тирбәлдем*** *имәннәрдә...*(Җыр) Ләкин *тибрәтү – тирбәтү, тибрәнү – тирбәнү* сүзләре арасында мәгънә аермасы да бар. Мәгънәви аермасы булган очракта әлеге сүзләр бер үк сүзләр белән грамматик бәйләнешкә керә алмыйлар. Мәсәлән, *каләм тибрәтә* тезмәсендәге «шигырь язу белән шөгыльләнә» мәгънәсендәге *тибрәтә*не *тирбәтә* белән алыштырып булмый. *«Йомшак кына җылы җилләр исте, /* ***Тибрәндереп*** *матур инешне...»* (М. Җәлил) юлларында да *тибрәндереп*не пароним пары белән алыштырып булмый: *инеш тирбәнү* күренеше матур тойгылар түгел, гаҗәпләнү, шомлы тойгылар уятыр иде, чөнки *тирбәнү* сүзендәге тирбәлеш колачы *тибрәнү*гә караганда күпкә зуррак булып күз алдына килә.

Шул рәвешчә, хәзерге татар әдәби телендә *тибрәнү – тирбәнү* пароним сүзләрендә категориаль мәгънә уртаклыгы бар, ситуатив мәгънә уртаклыгы һәрвакыт сакланмый. Менә шушы үзенчәлек тамырдаш булган *тибрәнү – тирбәнү* пароним сүзләрен стилистик максатта файдаланырга мөмкинлек бирә. Икенче яктан, бер сүздән барлыкка килгән *тибрәл-, тирбәл-, тибрән-, тирбән-* кебек фигыльләр, стилистик пароним хасил итеп, әлеге сүзләр белән грамматик бәйләнешкә керәсе сүзләрне дөрес сайлау (валентлык) проблемасын китереп чыгаралар.

Яңгырашлары охшаш булган теләсә нинди ике сүз пароним дип каралмый, чөнки шигырьләрдә рифма функциясен башкаручы сүзләр һәрвакытта диярлек охшаш яңгырашлы булалар.

Пароним сүзләр арасында синонимнар да шактый күп. Мәсәлән, *күрсәтмә – күргәзмә, туры – тугры, ошый – охшый* сүзләре әнә шундыйлар. *Күрсәтмә* сүзе, мәсәлән, ‘күрсәтмәлелек өчен хезмәт итә торган әсбап’ *(күрсәтмә әсбап)* мәгънәсендә килгәндә, *күргәзмә* сүзе белән бер үк мәгънәле була *(күргәзмә әсбап).* Бу икеләр икесе дә йөкләтү юнәлеше алган *күр-* тамырына исем ясагыч кушымча ялганып ясалганнар. (Йөкләтү юнәлеше кушымчаларының берсе *(-сәт)* – әдәби тел формасы, икенчесе *(-гәз)* – сөйләм теленә хас форма, шунлыктан аңлатмалы сүзлеккә *«күргәзмәле», «күргәзмәлелек»* дигәне *«күрсәтмәле», «күргәзмәлелек»* мәгънәсен белдерә торган сөйләм теле шәкеле итеп бирелгән (ТТАС, 2 т., 1979: 304). Ләкин *күрсәтмә* сүзе, югарыда әйтелгән мәгънәдән тыш, ‘теге яки бу очракта ничек эш итәргә кирәклек-

не өйрәткән киңәш, аңлатма' мәгънәсендә кулланыла (Шунда ук: 307). *Күргәзмә* – алда әйтелгән мәгънәдән башка, тагын «1. Халыкка күрсәтү өчен, берәр җиргә куелган әйберләр, шул әйберләр тупланган урын *(күргәзмә оештырылган), 2.* Бөтен кешегә *(халыкка)* күрсәтү, бөтен кешегә гыйбрәт булсын өчен оештырылган *(күргәзмә суд)»* мәгънәләрен белдерә (Шунда ук: 304).

Берсе икенчесеннән барлыкка килгән охшаш яңгырашлы сүзләр (ягъни паронимнар) семантик яктан түбәндәге төрләргә бүленә.

1. Реаль лексик мәгънә аермасы барлыкка килгән, аерым ситуациядә генә бер-берсе белән алыштырырга мөмкин булган паронимнар. Мәсәлән, *игелек* һәм *изгелек* паронимнары бер-берсенә бик якын мәгънә белдерәләр. Аларны аерым ситуациядә бер-берсе белән алыштырырга да мөмкин булыр иде: *Игелеклелеге ташып тора / Уйчан күзләр, куе кашлардан.* (Р. Фәйзуллин) *Изгелегең миңа шифа булды / Шиңгән чәчәк кебек сулганда.* (К. Булатова) Ләкин борынгы төрки телдәге әйбәт, яхшы, рәхимле мәгънәләрен белдергән *әдгү* (ДТС, 1969: 162) сүзеннән барлыкка килгән бу сүзләрнең һәркайсы үз мәгънәсе белән формалашып үсеп киткән. Мәгънә аермасы ихтыяҗы белән дә алар арасында фонетик дифференциация барлыкка килгәндер. «*Игелек* – 1. Яхшылык, киң күңеллелек; 2. *күч.* файда, табыш; *изгелек* сүзендә “игелек”, “саф күңеллелек” мәгънәсе һәм “тәкъвалык”, “илаһилык” мәгънәләре бар» (ТТАС, 1 т., 1977: 357, 365).

2. Пароним парларның кайберләре уртак категориаль мәгънәгә ия булса да, стильләре ягыннан аерылып тора.

Э.В. Севортян төрки телләрдә *ага* сүзенең өлкән ир туган, абый, эти белән бертуган абый, этинең атасының өлкән улы һәм өстен катлау вәкиле мәгънәләрендә йөрүе турында яза (ЭСТЯ, 1974: 70). Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә *ага* сүзе «яшь ягыннан олы ир туган, абый», «үзеңнән олырак, өлкән ир кеше» (ТТАС, 1 т., 1969: 14) мәгънәләре белән теркәлгән. Ләкин шунысы да бар: хәзерге татар әдәби телендә *ага* сүзе өлкән ир кешегә рәсми төс белән хөрмәтләп эндәшкәндә кулланыла.Төрки тел тарихында бу сүзнең «дәүләт оешмаларының акчасын саклаучы (казначей), хуҗа, әфәнде» мәгънәләрен белдерүе мәгълүм (Баскаков, 1989: 65). Шул рәсми мәгънә төсмере, күрәсең, хәзерге татар әдәби телендә сакланып калган. Азәрбайҗан телендә дә *ага* сүзе шулай аеруча хөрмәт белән рәсми

тонда мөрәҗәгать иткәндә (мәсәлән, профессор кешегә) әйтелә (Балаян, Шабанов, 1982: 91). *Агай* сүзе хәзерге татар телендә гади сөйләмдә еш күзәтелә, аның *-ай* кушымчасы, күрәсең, стилистик дифференциация тудыруга ярдәм итә: аеруча хөрмәтле, рәсми *ага* үз итеп эндәшергә ярый торган агайга әверелә.

3. Пароним сүзләрнең кайберләре аерым бер стильдә генә реаль лексик мәгънәләре белән аерылып торалар. Мәсәлән, хәзерге татар теленең гади сөйләм стилендә *җыр* һәм *җыру* сүзләре бер үк төшенчәне белдерәләр: *Бар* ***җырымны*** *илгә багышладым...* (М. Җәлил) *Җырлар идем, җырлар идем, / **Җыруларым** өч кенә...* (Халык җыры). Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә дә ***җыру*** сүзе «искергән сүз»дип аңлатылган һәм җыр сүзе белән бер үк мәгънә белдерүе күрсәтелгән (ТТАС, 3 т., 1981: 802). Ләкин әдәби телнең бер стиль тармагын тәшкил иткән фәнни стилендә *җыру* сүзе шигъри эпик әсәр, бәет мәгънәсен аңлата: *«Әсәрнең исеме турында берничә сүз. Һ. Атласов, Г. Рәхим һәм Г. Газиз аны «Илаһи йыру» исеме астында бастырганнар, ягъни тиңдәшсез, гүзәл, изге... әсәр. Ә йыру сүзен җыру дип бирү дөресрәк булыр иде. Элегрәк кайбер якларда, бигрәк тә олы буын вәкилләре, борынгы шигъри эпик әсәрне яки озын җырларны шул исем белән атаганнар. Җыру сүзе бәетләргә карата бездә соңрак та кулланылып килде»* (Урманчеев, 1974: 216).

*Аңлы – әңле* пароним сүзләренең реаль лексик мәгънә аермасы гади сөйләм стилендә ачык күренә. Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә *аңлы* сүзе генә теркәлгән һәм аның түбәндәге мәгънәләре аңлатылган:1. Уйлау сәләте булган, аңы булган, зиһенле; 2. Политик аңы үскән; 3. Акыл белән аңлап, уйлап, аңлы рәвештә эшләнгән (ТТАС, 1 т., 1977:102). Хәзерге татар телендә *әңле* дигән сүз дә бар. Э.В. Севортян *әң* тамырының *аң* тамырына барып тоташуын күрсәтә (ЭСТЯ, 1974: 152–155). Бу сүз татар теленең гади сөйләмендә үз файдасына эш итүче мәгънәсен белдерә. Мәзәктән бер мисал: *Бәрәү, үз савытын күршеләрендә күреп: «Бу минем савыт бит, ник кертмәдең?» дигәч, тегесе: «**Әңле** кеше икәнсең, алып та чык, кертеп тә бир сиңа!» – дигән ди.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, сүзләр пароним булсын өчен өч шартның берьюлы үтәлүе зарур: сүзләрнең аваз составлары бер-берсенә якын аһәңле булуы; сүзләрнең мәгънәләре ягыннан төрле предметлар, күренешләрне белдерүләре; сүзләрнең берсен икенчесе урынына ялгыш куллану ихтималы булуы.

## § 30. Паронимнарның барлыкка килү юллары

Паронимнар, төп ике төрле юл белән барлыкка килә: 1) фонетик үзгәрешләр ярдәмендә барлыкка килгән паронимнар, 2) морфологик үзгәрешләр ярдәмендә барлыкка килгән паронимнар.

1. Фонетик үзгәрешләр ярдәмендә барлыкка килгән паронимнар: а) сингармоник параллельләр: *җанлык – җәнлек, ярашу – ярәшү* һ.б.; ә) сузыклар чиратлашу нигезендә барлыкка килгән паронимнар: *аңлы –эңле, ачылану – ачулану* һ.б.; б) авазлар кыскару нәтиҗәсендә барлыкка килгән паронимнар: *әдгүлек* < *изгелек – игелек, карындаш – кардәш* һ.б.; в) метатеза нигезендә барлыкка килгән паронимнар: *тибрәнү – тирбәнү* һ.б.; г) тартыкларның тарихи чиратлашуы нигезендә барлыкка килгән паронимнар: *агыл – авыл, янгын – ялкын* һ.б.

2. Морфологик үзгәрешләр нигезендә барлыкка килгән паронимнар: а) сүз ясагыч кушымчалар ялганып барлыкка килгән паронимнар: *сөйләм – сөйләк, ярдәмче – ярдәмчел* һ.б.; ә) фигыль юнәлешләренең сүз ясау функциясе нигезендә барлыкка килгән паронимнар: *аклану – аклашу, сүгү – сүгенү, күрү – күрешү* һ.б.; б)төр кушымчасы ялганып ясалган паронимнар: *ага – агай, апа – апай, чытыр – чытырый* һ.б.; в)тарихи яктан төр кушымчасы булып, хәзерге тел күзлегеннән караганда сүз ясагыч кушымча ялганып барлыкка килгән паронимнар: *үсеш – үсенте, күрсәтмә – күргәзмә* һ.б.; г) берсенә сүз ясагыч кушымча, икенчесенә төр кушымчасы ялганып ясалган паронимнар: *тагып – тагыл, талган – талгын* һ.б.; д) хәзерге татар әдәби телендә сүз булудан туктаган тамырдан барлыкка килгән паронимнар: *пычак – пычкы, сондык – сандык, касмак – каймак* һ.б.; е)аваз үзгәрешләре белән бергә сүз ясагыч кушымчалар үзгәлеге нигезендә ясалган паронимнар: *яньчел – ямьшәй, пычак – почкак* һ.б.

Морфологик табигатенә килгәндә, бер үк сүз төркемнәренә караган паронимнар да, төрле сүз төркемнәренә караган паронимнар да була: а)бер үк сүз төркеменә керә торган паронимнар: *җыр – җыру – жырау,ашау – ашлау* һ.б.;ә)төрле сүз төркеменә керә торган паронимнар: (исем) *тыш,* (фигыль) *ташы*; (фигыль) *яугыр-,* (исем) *яңгыр* һ.б.

Паронимнарны барлау этимология фәненә барып тоташа. Бу яктан паронимнарны өч төркемгә аерырга була: 1) хәзерге татар әдәби телендә паронимлыгы ачык күренеп торган сүзләр; 2) хәзерге

татар әдәби телендә кулланыла, ләкин паронимлыгы этимологик анализ вакытында гына беленә торган сүзләр; 3) тел тарихында пароним булып, хәзерге татар әдәби телендә пароним сыңарын югалткан сүзләр.

1. Хәзерге татар әдәби телендә паронимлыгы ачык күренеп торган сүзләр. Мәсәлән, *тугры – туры* сүзләренең паронимлыгын мисалга алыйк. Борынгы төрки сүзлектә *тогру* сүзе теркәлгән һәм аның «туры, төз»; «дөрес, гадел» мәгънәләрен белдерүе аңлатылган (ДТС, 1969: 571). XX гасыр башларына хәтле ***тугры*** сүзе татар әдәби телендә «туры», «дөрес, гадел, төз» мәгънәсен белдергән. Мәсәлән: *«Бәдбәхет! **Тугры** сөйлә, сине үтерәбез!» – диде.* («Мәҗмугыл хикәят») *Кем **тугры** килде, аннан әйбер аермак кызларның күңеле бозылуы сәбәп улыр.* (Р. Фәхретдинов) Тел үсешендә *тогру* < *тугры* сүзеннән *туры* сүзе барлыкка килгән.

Хәзерге татар әдәби телендә *тугры* сүзен *туры* сүзе белән синоним итеп карау дөрес булмас. Чөнки бу сүзләр төшенчәләре белән аерылып торалар, алар арасында мәгънә аермасы барлыкка килгән (*Тугры* – хыянәтсез, ышанычлы (***тугры*** *хатын*), *туры* – төз (***туры*** *сызык*).

*Сөйләм – сөйләк* сүзләре дә тамырдаш сүзләр. *Сөйләм* сүзе «аралашу чарасы буларак, тел; фикер белдерү өчен әйтелгән тәгъбир яисә сүз, җөмлә; стиль» мәгънәләрен белдерә. Шушы ук тамырдан булган *сөйләк* – ‘халык иҗатындагы проза жанрларыннан берсе; сөйләүче үзе катнашкан, үзе күргән яки ишеткән вакыйгалар турында, чагыштырмача күптән түгел булган хәлләр хакында хикәят» (Әдәбият белеме сүзлеге, 1990: 176) мәгънәсендә кулланыла.

2. Хәзерге татар әдәби телендә кулланыла, ләкин паронимлыгы этимологик анализ вакытында гына беленә торган сүзләр.

*Авыл – авыз* сүзләренең дә этимологик уртаклыгы бар. *Диде: «Ач **агызың** керәм, чуарым җәннәтем күрәм».* (М. Чиләби. «Мөхәммәдия») *Авыл* сүзе дә борынгы телдә *агыл* булган һәм «ачык һавада мал-туарны туплау өчен ясалган кура» мәгънәсен белдергән. Тартыкларның тарихи чиратлашуы, конверсия ысулы белән *агыл* фигыленнән *авыл, агыз* фигыленнән *авыз* исеме барлыкка килгән: *агыз* – эчкә агыза торган әгъзаны, *агыл* агыласы урынны аңлата башлаган.

*Таш- – тыш – тиш* сүзләренең паронимлыгын алыйк. *Тыш* сүзе төрки баба телдә *таш-* (фигыль) формасында булган (Серебренников, 1980: 26). М. Кашгарый сүзлегендә *таш* исеме «тыш», «тышкы як» мәгънәсен, *таш-* фигыле хәзерге татар әдәби телендәге «ташы-» фигыле мәгънәсен белдереп теркәлгән (ДТС, 1969: 540). Димәк, хәзерге татар әдәби телендәге *ташу* фигыленең тамыры, *тыш* исеме һәм аның *ш ~ ч* чиратлашуыннан барлыкка килгән фигыле, бер тамырга барып тоташып, пароним хасил итәләр. *Тыш* сүзе белән *тиш-* (тышка юл ясა) сүзенең семантик уртаклыгы бар. Төрки телләр үсешендә ***а ~ ы, а ~ э, ә ~ э, ы ~ э*** күчешләре мәгълүм. Борынгы уйгур язмаларында, М. Кашгарый сүзлегендә үк инде *теш-* фигыле «тиш-» мәгънәсен, *тешук* исеме хәзерге татар әдәби телендәге «тишек» мәгънәсен белдергәннәр (ДТС, 1969: 555).

3. Тел тарихында пароним булып, хәзерге татар әдәби телендә пароним сыңарын югалткан сүзләр. Этимологик анализ бер тамырдан барлыкка килгән паронимнар оясын ачып җибәрергә ярдәм итә. Ләкин тел үсешендә паронимнар арта барган дип кенә фикер йөртү берьяклы булыр иде. Мәгълүм булганча, тел үсешендә кайбер яңа сүзләр барлыкка килгән, кайберләре, искереп, телдән төшеп калганнар. Этимологик анализ вакытында күз алдына килгән паронимнарның кайбер сыңарлары хәзерге татар әдәби телендә кулланылмый. Мисал өчен, *шыр – сыз, чыр – яз* кебек паронимнарның кайбер сыңарлары ерак тарихта гына калганнар.

*Шыр – сыр – сыз- –чыр – яз* сүзләренең паронимлыгы да хәзерге тел күзлегеннән аңлашылып җитми. *Шыр* тамырына *-пы* кушымчасы ялганып, *шырпы* барлыкка килгән, *-пы* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр татар телендә бар: *курпы, кырпы, керпе, чулпы* (Ганиев, 1974: 141). *Шырпы* сүзе татар телендә «каты агачтан ясалган кадак, агач чүбе, агач кылчыгы» мәгънәсендә дә йөри (ТТАС, 3 т., 1981: 530). Бу хәл ут яндыру җайланмасы булган *шырпы* сүзенең агач белән бәйле булуын күрсәтә.

Паронимнарны барлау тарихи лингвистикага барып тоташа. Бу яктан тарихи фонетика игътибарны аеруча җәлеп итә. Тел үсешебездә авазларның тарихи чиратлашулары нәтиҗәсендә хәзерге татар әдәби телендә орфоэпик вариантлар барлыкка килгән. Мәсәлән: *менгезү // менгерү, дурчмак // дучмак, кидер // кигер // кигез, шуңар // шуңа* һ.б. Мәсәлән, *җуялу – югалу* сүзләре тамырдаш

һәм бер үк мәгънәле сүзләр. Әле XX гасыр башы әдәби әсәрләрендә, мәсәлән, Ф. Әмирхан әсәрләрендә *җуялу* сүзен очратырга мөмкин: *Бу сүзегез белән сез минем иң бәхетле уздырган төшемне* ***җуялтасыз*** *бит...* (Ф. Әмирхан); *Минем зиһенемдә кызыл ком белән түшәлеп тора торган юллар хәзер каядыр киткәннәр,* ***җуялганнар****, анлар урынында әрекмәннәр, кычытканнар үсеп утыра торган бер ямьсез буталчыклык калган иде.* (Ф. Әмирхан) *Җуялу* сүзе хәзерге татар әдәби телендә кулланылмаса да, тамырдаш *җую* сүзе сакланган. *Җуялу* сүзе искергән, ә *җую* һәм *югалу* сүзләре калган. Алар валентлыклары белән аерылып та торалар. Мәсәлән, *җую* һәм *югалту* сүзләре төшем килешендәге объект белән бердәй бәйләнәләр: *акылын җую, әйберне җую; акылын югалту, әйберне югалту.* Ләкин субъект белән хәбәрлекле мөнәсәбәт белдерелгәндә, *җую* сүзе кулланылмый, төп юнәлештәге *югалу* сүзе файдаланыла: *Ул каядыр китеп* ***югалды.***

Тел үсешендә авазларның тарихи чиратлашулары нәтиҗәсендә барлыкка килгән вариантларның кайберләре арасында реаль лексик мәгънә аермасы хасил булган очраклар еш очрый. Тел үсешендә аваз чиратлашулар фонетик ысул белән сүз ясалу процессында актив катнашкан. Паронимнар ясалышын диахроник күзлектән караганда, сүзнең мәгънәви киңәю күренешенең фонетик чиратлашулар белән үрелеп баруы күзәтелә. Дәрдемәнднең мәшһүр «Кораб»ындагы *«Төн вә көндез Ул* ***йөрәдер****...* – юлында *йөрәдер* сүзе «йөзәдер» мәгънәсен белдерә. *Йөр – йөз* сүзләре дә, мәгънә киңәюе-артуы сәбәпле, мәгънә буталчыклыгы тумасын өчен, формаль яктан фонетик дифференциацияләнгән. Тел үсешендә аваз чиратлашуларның кайберләре фонетик ысул белән сүз ясалу процессында актив катнашкан. *Иш – ил, яшь – ел, бау – бәй, бикә – бичә, аңкау – аңкай, касмак – каймак, калак – кашык, күр – күз, охшый – ошый, сыр – сыз, карындаш – кардәш* һ.б. паронимнар шул рәвешчә барлыкка килгәннәр. Аларның кайберләре стилистик кулланылыш яки мәгънә төсмерләре ягыннан гына аерылып торалар. *Угылы – улы, олуг – олы, ыруг – ыру* мисалларын алсак, бу стилистик парларның беренчеләре борынгыча тулы яңгыраштагы югары стиль сүзләре булып кабул ителә, икенчеләре – киң кулланылышта йөри торган сүзләр.

Хәзерге татар телендә башка теллләрдән пароним хәлдә кергән сүзләр саны да байтак, бигрәк тә бу – гарәп-фарсы алынмалары

арасында күзәтелә. Кайбер гарәп-фарсы алынмалары телебезгә паронимнар буларак кабул ителгәннәр. Мәсәлән, *нәшер – нашир, галим – гыйлем, хөкем – хаким, гарыз – гариза* һ.б.

Шулай ук татар теле җирлегендә фонетик-семантик үзгәрешләр юлы белән барлыкка килгән паронимнар да очрый. Мисал өчен, *гакыл* сүзен карыйк. XX гасыр башларында югары стильдәге *гакыл* сүзе киң кулланылышта булган: *Картның шулкадәр* ***гакыллы*** *сүзенә исем китте.* (Г. Исхакый); *Инде аңарга ышанмасаң, хуҗабыздан сора, ул* ***гакыл*** *чишмәсе, ул бу сүзеңә гаҗәпкә калыр.* (Ф. Әмирхан); *Тукта инде,* ***гакыллы*** *бул. Мә, алай булса, үз читегемне бирәм.* (Г. Исхакый) Ләкин XX гасыр башында, милли әдәби тел формалашу барышында, сөйләм стиленә хас халыкчан *акыл* өстенлек ала башлаган. Аның шушы фонетик үзгәргән варианты өстенлек ала башлагач, бу сүзләр кулланылыш сфералары ягыннан аерыла башлыйлар. Акыллы кешене хөрмәт итүгә басым ясап әйткәндә, купшылык белән, зыялыларча сөйләгәндә, *гакыл* сүзеннән файдаланалар. Көндәлек аралашу хәлләрен язганда, халыкчан *акыл* кулланыла. *Шулкадәр* ***акыллы*** *планым да эшкә ярамады бит!* (Ф. Әмирхан) *Тирә-якта асыллыгы, сылулыгы белән генә түгел, җиңел, җитез, килешле һәм* ***акыллы*** *уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык колын күренми дә, ишетелми дә.* (Г. Ибраһимов)

Татар теле җирлегендә фонетик үзгәреш кичергән алынма сүз шул үзгәреш кичергән икенче сүзгә реаль лексик мәгънәсен дә бүлеп бирә ала.

Мәсәлән, *хәзер* сүзеннән *әзер* сүзе барлыкка килгән. «1. Хәстәрләнеп беткән, әзер. 2. Күз алдында булган, шунда булучы. 3. Хәзер, бу вакыт, шушы вакыт» мәгънәләрендә кабул ителгән *хазир* (ГФТР: 644) сүзендә хәзерге татар әдәби телендә өченче мәгънә ачык сакланган: *Инде* ***хәзер*** *бик популярлашып барган, киләчәге өметле булган бу драматург белән танышырга, аралашырга теләүчеләр шактый иде.* (Ф. Бәйрәмова); ***Хәзерге*** *акылым булсамы? Бөтенесенең күзенә черки булып кадалыр идем.* (К. Тимбикова); *Актау артына эленеп кенә калган кояшның нурлары сүлпән* ***хәзер****, яктыртмый да, җылытмый да.* (Х. Сәрьян) «Күз алдында булган, шунда булучы» мәгънәсе татар теле тарихында булган. Хәзерге татар әдәби телендә бу – архаик мәгънә. Беренче мәгънәне, ягъни «хәстәрләнеп беткән» мәгънәсен

дә башта *хәзер* сүзе белдергән: *Корал **хәзер** иттеләр, кичәдән иртәнгәчә сөрделәр.* (К. Насыйри) Мәсәлән, Г. Исхакыйда *әзерләнү* һәм *хәзерләнү* сүзләре бер үк мәгънәдә: *«Йа Раббем! Бәхетемне ким кылма!» – дидем дә, батыраеп, күрешергә чыгарга **әзерләндем**... Андагы үләннәр дә бик матураеп, үсәргә **хәзерләнеп** торалар.*

Соңыннан *хәзер*нең мәгънәсе ике сүзгә бүленгән. «Хәстәрләнеп беткән» мәгънәсен татар телендә аның аваз ягыннан үзгәргән варианты *әзер* сүзе белдерә башлаган һәм татар әдәби теленең хәзерге чорында «хәстәрләнеп беткән» мәгънәсе *әзер* сүзендә өстенлек алган: *Кайта – ашарына **әзер**, китә – хатыны хәстәрләп озатып кала. Тагы ни кирәк ир уртасы кеше өчен?* (Ф. Бәйрәмова); *Рәдиф тә, мин дә ул чакта борыннарыбызга кызлар исе кергән, кызлар дигәндә җәһәннәмнең аргы ягына барып чыгарга **әзер** торган егетләр идек инде.* (В. Нуруллин)

Кайбер алынма сүзләр, татар теленә кергәч, фонетик үзгәреш кичергән икенче сүзгә мәгънәсен бүлеп биреп кенә калмаганнар, реаль лексик мәгънәләрен киңәйткәннәр.

Хәзерге татар телендә гарәп телендә «күрергә, күрешергә, хәл белергә бару» мәгънәләрен белдерүче *зиярәт* сүзе яшәп килә: *Анда аның авторы, яңа ачылган мәдрәсәгә барып чыгып, шул **зиярәте** турында язган иде* («Татарстан яшьләре»); *Соңыннан халык, тәкбир әйтә-әйтә, бинаны **зиярәт** итәргә китте* («Азатлык» тапшыруы, 1999, 26/8).

*Зирәт* сүзе татар теле җирлегендә мәгънәсен киңәйткән: бу сүздән «каберлек» мәгънәсендәге *зыярат* сүзе ясалган: ***Зиярәт** кылырга хәтта Калмаган зиратлары...* (Р. Гариф); *Япония башкаласы Токио шәһәр **зыяратында** күмелгән авылдашыбыз Нәҗметдин...* («Нур»)

Хәзерге чорда рус һәм Европа алынмалары телебезнең сүзлек хәзинәсендә билгеле бер урын биләп торганлыктан, алар арасында охшаш яңгырашлы сүзләрне шактый очратабыз. Бу телләрнең охшаш яңгырашлы сүзләре рус теленең теоретик хезмәтләрендә киң яктыртылган (Гвоздев, 1955; Вишнякова, 1984 һ.б.), шактый күпчелеге сүзлекләренә теркәлгән булганга (Колесников, 1994), татар теленә үтеп кергәннәре турында да алардан шактый мәгълүмат алып була.

## § 31. Паронимнарның сөйләмдә кулланылышы һәм функциональ-стилистик вазифасы. Парономазия күренеше

Паронимнар тормыш-көнкүрешнең төрле тармакларында кулланыла. Телдә сөйләшүчеләр, сүзләрнең мәгънәләрен аңлап бетермәү, диалекталь үзенчәлекләрнең көчле йогынтысы, сүзләрнең этимологиясен ачык күз алдына китермәү аркасында, охшаш яңгырашлы сүзләрне бутап, урынсыз кулланалар, мәсәлән, *эзлексез – өзлексез, юну – юыну, туры – тугры, изгелек – игелек, охшый – ошый* һ.б. сүзләрне бутау очраклары күзәтелә. Искергән сүзләрнең, бигрәк тә гарәп-фарсы алынмаларының, яңадан кулланыла башлавы сәбәпле, соңгы елларда охшаш яңгырашлы сүзләр тагын да күбәйделәр: *мәгърур – мәгъмүр, гыйбрәт – гыйбарәт, шаһит – шәһит, мәрхүм – мәхрүм, шәргый – шәркый, бәрәкәт – бәраәт* һ.б.

Паронимнар арасында мәгънә уртаклыгы булганлыктан, стилистик хаталар аралашу-аңлашуга тулаем логик зыян китермиләр. Ләкин әдәби нормадан читкә тайпылу сөйләм культурасының җитәрлек дәрәҗәдә булмавын күрсәтеп тора, мәсәлән: *Еракта түгел баганага кадакланган юл күрсәтүче күзгә чалынды* дигән стилистик хатасы булган җөмләне алыйк. *Юл күрсәтүче* гыйбарәсе кешегә карата әйткәндә генә дөрес була ала. Юл күрсәтү өчен кадакланган тактаны *юл күрсәткече* дияргә кирәк.

Паронимнар сурәтләү чарасы буларак та киң кулланылалар. Бигрәк тә халык иҗаты әсәрләрендә һәм поэзиядә паронимнарны күпләп очратырга мөмкин. Алар эчке һәм тышкы рифма кору өчен киң файдаланылалар.

Стилистикада паронимнарны куллану п а р о н о м а з и я дип атала. Парономáзия, парономáсия яки анноминация (грек. *pará* – янында һәм *onomázo* – атыйм) – ике охшаш яңгырашлы яисә морфема составларының өлешчә туры килгән сүзләрне, ягъни паронимнарны махсус янәшә куллануга корылган стилистик чара. Парономазия сөйләмнең образлылыгын көчәйтә, мәсәлән: *Ит ашасаң тешкә керә, ашамасаң төшкә керә.* (Мәкаль); *Кыңгыр салып коңгыр шлемнарны.* (Ш. Маннур); *Чулман өсләрендә / Чулпан яна – / Офыкта.* (Ф. Сафин)

Парономаслар арасында мәгънә уртаклыгы булмый, хыялый ассоциацияләр белән дә мәгънә якынлыгын табу җиңел эш түгел, чөнки парономаслар – этимологик уртаклыгы булмаган, төрле

төшенчәләрне белдерә торган сүзләр. Аларны синхроник планда телнең төп лексик составы чыганаклары ягыннан түбәндәге төрләргә бүләргә мөмкин: 1) үз телебез паронимаслары (*эстәү – өстәү*); 2) рус һәм Европа алынмалары арасындагы паронимаслар (*шифер – шифр*); 3) гарәп-фарсы алынмалары арасындагы паронимаслар (*гыйбарә – гыйбарәт – гыйбрәт – гыйбри; мәгърифәт – мәгъфирәт*); 4) телара паронимаслар: *азан* (гарәп) – *азат* (фарсы) – *азот* (Европа алынмасы) – *озат* (үз сүзебез) һ.б.

Мәгълүм булганча, кеше әйләнә-тирә дөньяны, үзенә таныш булган әйберләрне таныш булмаган әйберләр белән чагыштырып өйрәнә. Беренче тапкыр очрашканда, кешене танышына охшатып бәяли, элекке танышларына булган симпатия яки антипатия хисләре яңа танышларына күчә. Ләкин мондый чагыштыру-охшатулар ялгышларга да китерергә мөмкин. Телне өйрәнгәндә дә, укучы үзенә таныш булмаган сүзне шул сүзгә охшаган икенче бер (үзенә таныш булган) сүзнең мәгънәсеннән чыгып аңлый. Паронимаслар өлкәсендәге хаталар да әнә шундый «психологик контактлар»ны хәтерләтә.

Татар теленең үз лексикасындагы паронимасларны без түбәндәге төрләргә бүлә алабыз:

1. Татар теленә хас фонетик закончалыклар йогынтысында буталуы мөмкин булган паронимас сүзләр: 1) ассимиляция йогынтысында: *кызса – кысса, сүзсез – сүссез* (тартыкларның саңгыраулыкта ярашуы бутарга мөмкин)*; ун каен – уң каен, балан көе – балаң көе* (аңкау тартыгына ярашу бутарга мөмкин) һ.б.; 2) Сузыкларның тараюы-киңәюе йогынтысында: *яныр* (*ялкынланып яныр*) – *янар* (*бармак янар*); *бизер* (*миннән бизер*) – *бизәр* (*чыршыны бизәр*); *төзер* (*йорт төзер*) – *төзәр* (*мылтык төзәр*); *авар* (*аwыр*) – фигыль, *авыр* (*аwыр*) – сыйфат; *сыяр* (*сыйыр*) – фигыль, *сыер* (*сыйыр*) – исем һ.б.; 3) редукция йогынтысында буталуы мөмкин булган охшаш яңгырашлы сүзләр, мәсәлән, еш кына *юына* һәм *юна* сүзләре бутала. Мәсәлән, С. Рәмиевнең: *Сызыла, сызыла, сызыла күңелем, / Сызыла бертуктамыйча, / Сызыла айлар, сызыла еллар, / Сызыла төн йокламыйча...* – дип башланган шигырен: *«Сызла, сызла, сызла, күңелем, / Сызла бертуктамыйча, / Сызла айлар, сызла еллар, / Сызла төн йокламыйча»,* – дип язу гадәткә кергән. Бу очракта сузык кыскару белән бергә, гарәп графикасы үзенчәлеген (гарәп алфавитында **ы, е** хәрефләре булмауны) исәпкә алып җиткермәү дә

ике сүз буталышына китергән; 4) диалект йогынтысында буталуы мөмкин булган охшаш яңгырашлы сүзләр, мәсәлән, мишәр диалектында иренсезләштерү үзенчәлеге күзәтелә. Шуңа күрә бу диалект вәкилләренә охшаш яңгырашлы *өзлексез* (бер дә туктамыйча) сүзен *эзлексез* (күчеш булмаган, логикасыз) сүзе белән бутау очрый. Шулай ук мишәр диалектына хас дифтонгоидларны монофтонглаштыру йогынтысында буталуы мөмкин булган охшаш яңгырашлы сүзләр дә байтак.

Урта диалект вәкилләре сөйләшендә **э** сузыгы урынына **и** сузыгын әйтү күзәтелә: *эре – ире, энә – инә* һ.б. Мондый очраклар парономаслар барлыкка китереп, татар телен белеп бетермәгән тыңлаучылар аңында мәгънә буталчыклыклары тудырырга мөмкиннәр: *«Ире булган икән бу».* Җөмләне ике төрле аңларга була: 1. *Бу кеше аның* ***ире*** *булган икән*. 2. *Бу әйбер* ***эре*** *булган икән*.

2. Телара парономасларның барлыкка килү юллары:

1) сузык авазларның ике төрле әйтелеше ярдәмендә аерыла торган парономаслар. Аларның түбәндәге очраклары күзәтелә: 1. **А (а)** хәрефенең ике төрле укылышы белән аерыла торган парономаслар, мәсәлән, *бал, тара, бар;* 2. **Ы (ы)** хәрефенең ике төрле укылышы белән аерыла торган парономаслар: *сыр* – төрки-татар сүзе: *күлмәк сыры* һәм алынма сүз: *ашыйсы килгәнем – сыр;* 3. **О (о)** хәрефенең ике төрле укылышы белән аерыла торган парономаслар: *тол:* татар сүзе (***тол*** *хатын,* ***тол*** *ир; сугыш чорында* ***толлар*** *күбәйде*) һәм Европа алынмасы (шартлаткыч мәгънәсендә).

2) тартык авазларның ике төрле әйтелеше ярдәмендә дә аерыла торган парономаслар: 1. **К (к)** хәрефенең ике төрле укылышы белән аерыла торган төрки-татар сүзләре һәм рус-европа алынмалары: *канау* төрки-татар сүзе (*борын канау*) һәм алынма исем (*канава*); *бак* – төрки-татар чыгышлы боерык фигыль формасы һәм ‘су савыты’ мәгънәсендәге алынма исем*; арка* – кеше гәүдәсенең бер өлеше һәм архитектура атамасы; 2. **Т (т)** *хәрефенең ике төрле укылышы белән* аерыла торган парономаслар: *тир* – төрки-татар сүзе (***Тир*** *бүленеп чыгу организмга бик файдалы, диләр*) һәм Европа алынмасы (***Тирда*** *атарга өйрәндем*). Сүз азагында ике төрле укыла торган бу парономас сүзләр кушымча ялганышында ачык аерылалар: ***тирга*** *барган –* ***тиргә*** *баткан; сарык* ***тушы****н алдым – аның зәңгәр* ***тушен*** *алдым;* ***«Шик»ка*** *бардым –* ***шиккә*** *калдым.*

Парономаслар сәнгатьле сөйләмдә түбәндәге стилистик функция башкаралар: 1) поэзиядә эчке һәм тышкы рифма кору өчен кулланылалар: *Синдә мәллә чал тарихның гәүһәр* ***ташы,*** / *Матурлык һәм батырлыкның йөзек* ***кашы*** (С. Поварисов); 2) сүз уйнату (каламбур) рәвешендә очрыйлар: *Исәннәрнең* ***кадерен*** *бел, үлгәннәрнең* ***каберен*** *бел.* (Әйтем); 3) юмор төсе бирү, җорлык-тапкырлык максатында бер сүзгә охшаш неологизм – парономас пары ясала: *Бала уйный* ***балалайка,*** / *Бабай уйный* – / ***Бабалайка!*** (Ш. Галиев); 4) парономас сүзләрне яки парономасларның сыңарларыннан рифмалаштырып ясалган яңа сүзләрне парлаштырып бирү газета-журнал рубрикалары исеме буларак файдаланыла: *«Игезәк-тигезәк»* («Идел»), *«Җавап-савап»* («Мәдәни җомга») һ.б.; 5) берәр сүзгә охшатып ясалган яңа гыйбарәләр тапкырлык-җорлык максатында гамәлдә йөри, шул рәвешчә, тыңлаучының игътибарын җәлеп итә: ***Хорейлы*** (хорей – шигъри басымның бер төре) *юл сиңа, яшь иптәш* (Ф. Шәфигуллин); 6) матур әдәбият әсәрләрендә персонажларның гади эшчеләр, гади кешеләр булуын күрсәтү максатыннан, чит тел сүзен аңламаган килеш кулланып, парономас алымын файдаланалар: *Күзенә тавык тизәге сылап, сугышка бармады.* ***Дизинтир*** *ул кабахәт!* (Р. Батулла)

Шул рәвешчә, сүзлек хәзинәбездә парономаслар мәгълүм урын билиләр. Аларның мәгънәләрен бутамас өчен, киң контекстка (сүзнең чыганагына, әйтелешенә, язылышына, морфологик үзенчәлегенә, кайчакта кулланылыш стиленә) мөрәҗәгать итәргә кирәк була.

Йомгаклап әйткәндә, үз сүзләребездәге парономаслар мәсьәләсендә беренче карашка проблемалар юк кебек тоелса да, сүзлек байлыгыбызны синхроник һәм диахроник планда чагыштырганда яки диалект үзенчәлекләрен әдәби тел белән янәшә куйганда, охшаш яңгырашлы тамырдаш булмаган сүзләребез арасында кайбер буталышлар булырга мөмкин.

Паронимнарны, этимологик бер тамырдан мәгънә арту һәм мәгънә күчеше нигезенә таянган булулары ягыннан – күпмәгънәлелек һәм конверсия, ә парономасларны омонимнар белән чагыштырып булганлыктан, бу ике өлкәдә ясалган хаталар үзара аралашуга төрлечә йогынты ясыйлар. Парономаслар арасында мәгънә уртаклыгы, этимологик уртаклык булмаганлыктан, яки булып та җуелганлыктан, аларны куллану өлкәсендәге стилистик хаталар аралашу-аңлашуга логик зыян китерәләр.

## Татар телендә синонимия күренеше

### § 32. Тел белемендә синонимнарны өйрәнү тарихы

Тел белемендә синонимияне өйрәнүгә багышланган шактый бай материал тупланган. Фәнни хезмәтләрдә синонимия күренешенең асылын аңлату, синонимнарны аерып чыгару критерийларын билгеләү, төрле телләрдә синонимнарның барлыкка килү һәм кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау мәсьәләләре үзәктә тора. Синонимия күренешенең асылын аңлатуда да, телнең төрле катламнарында очравына бәйле рәвештә, төрлелекләр күзәтелә. Билгеле булганча, синонимия күренеше лексикада гына түгел, грамматик һәм сүз ясалышы яссылыкларында да очрый, һәм әлеге тел катламнарындагы синонимлык һәр очракта да бертөрле табигатькә ия түгел.

Тел белемендә синонимия күренешенең асылын аңлатуда ике төрле юнәлеш яшәп килә. Беренче юнәлеш вәкилләре (А.Б. Шапиро, А.Н. Гвоздев, Л.Н. Саркисова, П.С. Александров һ.б.) синонимнарны охшаш, әмма мәгънә төсмерләре белән аерыла торган берәмлекләр буларак билгелиләр. Икенче юнәлеш вәкилләре (В.В. Виноградов, Е.М. Галкина-Федорук, Л.А. Булаховский, Н.М. Шанский, Д.Э. Розенталь һ.б.) төп акцентны мәгънә тәңгәллегенә юнәлтәләр. Беренче юнәлеш вәкилләре мәгънә ягыннан тәңгәллекне кире каксалар, соңгылар исә синонимия нигезенә нәкъ семантик тәңгәллекне, мәгънәдәш сүзләрнең бер-берсен тулысынча һәм иркен алыштыра алу үзенчәлеген куялар.

Танылган галим, гомуми тел гыйлемендә билгеле «Мәгънә ↔ Текст» теориясе авторларының берсе Ю.Д. Апресян әлеге юнәлешләрнең төп кимчелеге итеп синонимнарның мәгънәләрен чагыштыруда төгәл алымнар булмавын күрсәтә.

Тел белемендә төрле билгеләмәләр һәм критерийлар булуга карамастан, бу өлкәдәге тикшеренүләрнең зур күпчелеген берләштергән момент булып сүзләрнең лексик-семантик тәңгәллеге алына, шул ук вакытта синоним сүзләрнең семантик төсмерләре һәм стилистик кулланылышларындагы аермалар булу да ассызыклана.

Төп билгеләрне аерган хәлдә, тел белемендә аерым моментларны билгеләүдә фикер төрлелеге күзәтелә. Мәсәлән, Р.С. Гинзбург синоним сүзләр денотатив мәгънәләрендә охшаш, әмма мәгънәләренең стилистик компоненты ягыннан үзгә булуын күрсәтә

(Гинзбург, 1978: 22); бер төркем галимнәр синоним буларак бары тик бер үк төшенчә белдергән һәм, предмет-логик эчтәлеккә зыян китермичә, бер-берсен алыштыра ала торган сүзләрне карыйлар (П.С. Александров, Т.И. Арбекова һ.б.); В.А. Звегинцев сүз мәгънәсен аңлатуга синхроник якын килеп, синонимнарның мәгънә тәңгәллеген билгеле бер вакыт аралыгында тел үсешенә бәйле карарга тәкъдим итә (Звегинцев, 1957: 131); И.В. Арнольд синонимнарны аерганда, аларның нинди сүз төркеменә каравын, бердән артык контекстта бер-берсен алыштыра алу сәләтен, денотатив мәгънәләр тәңгәллеген, фонетик тышча, морфема структурасы, мәгънә төсмере, стиль һәм валентлык ягыннан аермаларын искә алу кирәклеген искәртә (Арнольд, 1973: 102).

Тел белемендә шактый бәхәсләр тудырган тагын бер аспект – абсолют синонимнарны аерып чыгару мәсьәләсе. Тел белгечләренең күбесе бу төр синонимнарны бер төр буларак күрсәтәләр, әмма бер төркем галимнәр (Р.С. Гинзбург, В.Г. Вилюман һ.б.), семантик һәм функциональ тәңгәллекләрен исәпкә алып, аларны бөтенләй танымыйлар.

Төрки тел белемендә синонимиягә караган мәсьәләләр Н.А. Баскаков, Н.З. Гаджиева, Л.С. Левитская, Б.А. Серебренников, А.А. Юлдашев һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә урын ала.

Татар тел белемендә парадигматик мөнәсәбәтләргә корылган төркемнәр арасында синонимия күренеше шактый өйрәнелгән санала. Беренчеләрдән булып татар теленең синонимик байлыгы Каюм Насыйриның «Кабуснамә» әсәрендә һәм сүзлекләрендә урын ала. «Ләһҗәи татари» сүзлеген төзегәндә, галим татар теленең үз сүзләрен һәм алынмаларны синонимнар аша аңлатуны үзәккә ала.

1933 елда «Мәгариф» журналында Х. Сәлимнең «Бездә синонимнар һәм алар өстендә эшләү» мәкаләсе басыла. Әйтергә кирәк, бу – татар теленең синонимнарын өйрәнүгә багышланган беренче хезмәт. Автор татар телендә бу төр берәмлекләрнең өйрәнелмәвен искәртеп, рус тел белемендә яшәгән билгеләмәләрнең дә төгәллек соравын әйтә һәм үзе билгеләмәсен тәкъдим итә, синонимнарның үзенчәлекле сыйфатларын аера.

1940 елда В. Хангилдинның синонимнарның экспрессив-стилистик үзенчәлекләренә, барлыкка килүләренә багышланган ике мәкаләсе дөнья күрә. Автор синонимнарның мәгънәви сыйфатлары, доминанта сүз мәсьәләләренә карата да шактый тирәнтен

мәгълүмат китерә. Татар тел белемендә бу төр берәмлекләрне тикшерүгә этәргән әлеге ике хезмәтнең әһәмияте зур.

XX гасырның 40 нчы еллары ахырында синонимнар мәсьәләсе күренекле әдип, галим Ш. Рамазанов хезмәтләрендә күрсәтелә башлый. Аның 1954 елда басылып чыккан «Татар теле буенча очерклар» хезмәте татар лексикологиясенең төрле якларын, шул исәптән синонимия мәсьәләләрен дә, шактый тулы яктырта. Галимнең синоним сүзләргә билгеләмәсе түбәндәгечә яңгырый: «Синонимнар, нигездә, бер төшенчәне белдерә торган, ләкин аваз төзелеше белән аерым сүзләр алар». Бу хезмәттә татар телендә синонимнарның барлыкка килү юлларыннан китап теле лексикасының халыкның җанлы сөйләм теле, диалекталь лексика белән кушылуы аерым аңлатыла.

Х. Курбатовның 1956 елда басылган «Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре» хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк. Биредә синонимнарның стилистик вазифасына аерым игътибар бирелә.

Татар теле синонимиясе өлкәсендә Ш. Ханбикова эшчәнлеге зур урын тота. Аның 1950–1980 еллар аралыгында дөнья күргән хезмәтләре һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу максатыннан эшләнгән «Татар телендә синонимнар» исемле диссертациясе татар теле синонимиясенә багышланган фундаменталь хезмәтләрдән саналалар. Ш.С. Ханбикова – татар теленең синонимнары буенча эшләнгән беренче сүзлекнең авторы да. Аның 1980 елда басылган «Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр» хезмәте бүгенге көнгәчә татар теленең синонимиясен тирәнтен яктырткан хезмәт булып тора.

Татар теле лексикологиясе буенча дәреслекләрендә Ф.С. Сафиуллина синонимнарны өйрәнүне яңа фәнни казанышлар нигезендә тагын да баета. Ш.Ханбикова белән авторлыкта 1999 елда галимәнең «Синонимнар сүзлеге» басылып чыкты. Биредә хәзерге татар телендә кулланылган 4500 чамасы синонимик оя тупланган, доминанта сүз рус теленә тәрҗемәдә бирелгән, ахырда сүзләр күрсәткече урын алган.

Татар теленең ономастик берәмлекләре арасындагы синонимлык мәсьәләләре Г.Ф. Саттаров хезмәтләрендә тирәнтен яктыртылган.

2009 елда Г.К. Закированың «Алтын Урда чоры төрки-татар язма истәлекләрендә синонимнар» монографиясе (рус телендә)

дөнья күрә. Аңа кадәр автор әлеге темага кандидатлык диссертациясе яклый. Хезмәт үзенең һәм назари, һәм гамәли яктан әһәмиятле булуы белән аерылып тора. Хәзерге тюркология һәм татар тел белемендә синонимнарны өйрәнү торышы, әлеге мәсьәләгә караган теоретик мәгълүмат, тарихи лексикологиягә кагылышлы мәсьәләләр, татар теленең синонимик фонды формалашу һәм үсеше әлеге хезмәттә тулы, эзлекле яктыртылган.

И.Б. Бәшированың 2010 елда басылган «Татар әдәби теле. Семасиология» хезмәтенең шактый күләмле өлеше синонимнарга багышланган. Автор татар тел белеменең төрле катламнарында күзәтелгән синонимия мәсьәләләренә, аларның өйрәнелү торышына туктала. Галимә татар теле лексикасының төрле катламнары мисалында синонимнарның кулланылу үзенчәлекләренә, әлеге төр сүзләр арасындагы мәгънә уртаклыгына, синонимик рәттә семантик бәйләнеш проблемаларына җитди анализ бирә.

Югарыда аталган хезмәтләрдән тыш, хәзерге татар тел белемендә лексика, стилистика, поэтикага, грамматикага багышланган хезмәтләрдә, телнең башка берәмлекләре белән беррәттән, синонимнарга тукталу еш күзәтелә.

## § 33. Синонимия күренешенә гомуми билгеләмә

Синонимия – интеграль һәм дифференциаль семаларны берләштергән лексик-семантик бергәлек ул. Синонимия чынбарлыктагы объектив күренешләрнең үзенчәлекләрен телдә төрле яклап чагылдыра, аның лингвистик табигате тел берәмлекләренең үзара якынлыгы, охшашлыгы белән билгеләнә. Синонимия күренеше телнең төрле катламнарында күзәтелсә дә (мәсәлән, сүзләр, морфемалар, синтаксик конструкцияләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр арасында), термин буларак, гадәттә, лексик синонимиягә бәйле еш кулланыла.

Лексик синонимия телдә һәм семантик, һәм функциональ яктан иң киң таралган күренеш санала. Аның семантик асылы лексик берәмлекләрнең мәгънәви яктан тулысынча тәңгәллегенә (*тел белеме – лингвистика*), аерым мәгънәләрнең тәңгәллегенә (*өмет – ышаныч*), аерым семаларның тәңгәллегенә (*чишмә – чыганак*) корылган. Функциональ яссылыкта караганда, синонимия күренешенең төп асылы тел берәмлекләренең бер-берсен алыштыра алу, төгәллек кертү үзенчәлегеннән гыйбарәт. Бер контекст кысаларын-

да сүзләрнең кабатлануыннан, стилистик бертөрлелектән котылу өчен, синонимик берәмлекләр кулланыла. Мәсәлән, *Башына килгән бөтен уй-хыялы* ***сибелде, таралды,*** *фикер җеп очы кулыннан ычкынды* (М. Хәбибуллин); *Бу серләр аны кайчак* ***шатландыра, сөендерә, канатландыра,*** *ә кайчак куркыта иде.* (Г. Әпсәләмов)

Мәгънә төсмере ягыннан төгәллек кертү һәм стилистик функцияләре лексик синонимия күренешен характерлый торган төп билгеләрдән саналалар. Нәкъ алар нигезендә мәгънә ягыннан охшаш сүзләр арасындагы үзенчәлекле бәйләнеш билгеләнә.

Синоним (грек. *synonуmos* – бердәй исемле) дип мәгънә төсмерләре ягыннан охшаш яки тәңгәл килгән сүзләрне атыйлар. Синоним сүзләр арасында сүзара парадигматик мөнәсәбәтләр яши. Синонимик парадигмадагы сүзләр өчен уртак, аларны бергә туплый торган билге булып тәңгәллек, охшашлык санала, дифференциаль үзенчәлек исә аларның яңгырашлары яки язылышлары ягыннан төрле булуында һәм функциональ-стилистик яктан аерымлыгында күренә.

Синонимик парадигманы традицион рәвештә синонимик рәт (оя) термины белән дә атап йөртәләр. Синонимик парадигма составындагы сүзләр телнең тарихи үсеш процессында берберсенә семантик яктан бик керешкән була, әлеге төр сүзләрнең мәгънә уртаклыгын еш кына контекстка бәйсез дә аңлап була. Мәсәлән, *оҗмах – җәннәт; бабай – дәү әти – карт әтә; барлыкка килү – яралу – дөньяга килү – туу* һ.б. Бу аңлашыла да, чөнки синонимнар семантик уртаклыкка ия, алар арасында бары тик мәгънә төсмерләре, стилистик бизәкләре, экспрессия күләме ягыннан гына аерма булырга мөмкин. Лексик синонимнар бер үк сүз төркеменә карыйлар, бер төшенчәне төрле яклап атыйлар, әмма бер-берсеннән мәгънә төсмерләре яки стилистик бизәкләре белән аерылып торалар: *искиткеч, шаккаткыч, гаҗәп, хәйран калырлык, таң калмалы, уш китмәле.*

Синонимик парадигма составында барлык сүзләр өчен уртак сүз – доминанта аерыла. Доминанта (лат. *dominans* – төп, өстенлек итүче) – синонимик оядагы сүзләрне берләштерә, гомуми төшенчә белдерә һәм телдә продуктив кулланыла торган, стилистик бизәкләрдән азат сүз. Мәсәлән, *кодрәт, куәт, көч, дәрман, хәл, җегәр, гайрәт* синонимик рәтендә *көч* сүзе синонимик оядагы барлык сүзләрнең мәгънәсен дә берләштерә, телнең теләсә кайсы

катламында иркен файдаланыла, нейтраль мәгънәгә ия, телдә продуктив, актив кулланылышта. Синонимик парадигманың күләменә карап, доминанта сүз бер яки ике була ала.

Лексик синонимия – телдәге күпмәгънәлелек күренеше белән бәйләнгән өлкә. Чөнки синонимик парадигма составына кергән сүзләрнең зур күпчелеген күп мәгънәле сүзләр тәшкил итә. Әмма шуны искәртү кирәк: күп мәгънәле сүзнең аерым мәгънәләре төрле синонимик парадигма составында яшәргә һәм бу парадигмалар һәр очракта да кисешмәскә мөмкиннәр. Мисал өчен, *түгәрәк* сүзен алыйк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә аның түбәндәге мәгънәләре теркәлгән: **1.** 1) чикләре әйләнә фомасында булган өслек; 2) әйләнә шәкелендә булган төзелмә, әйбер; 3) күч. үзара бәйләнештә торган кешеләр төркеме, даирә; 4) билгеле бер үзешчәнлек төре белән шөгыльләнүчеләр оешмасы; 5) тирә-як, әйләнә-тирә. **2.** *сф. мәгъ.* 1) әйләнә формасындагы яки шуңа якын; 2) йомры, юантык; 3) *күч.* һәр яктан тулы, җитеш һ.б.

Югарыда саналган һәр очракның диярлек үзенең синонимик парадигмасы, аларның һәрберсенең, үз чиратында, семантик охшашлыкка корылган мөстәкыйль төркеме бар: түгәрәк (1.3 мәгънәсендә) – даирә, төркем; түгәрәк (2.3 мәгънәсендә) – тулы, җитеш, һәр яктан килгән һ.б. синонимнарның мәгънәсе доминанта сүз белән чагыштырылып бирелә.

Синонимия күренеше антонимия белән дә бәйләнештә яши. Кайбер очракларда синонимнар бер-берсен алыштыру урынына капма-каршы мөнәсәбәт белдерә башлыйлар: *Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел, / Һич кайгысыз кеше булса, адәм түгел* (Г. Тукай) шигъри юлларында *кеше* һәм *адәм* сүзләре бер синонимик парадигма кысаларында даими яшәсәләр дә, бу контекстта капма-каршы мәгънә белдереп, образ, экспрессия тудыру өчен хезмәт итәләр.

Шулай итеп, лексик синонимия күренеше сүзара парадигматик мөнәсәбәтләргә корылган лексик-семантик системаны хасил итә.

## § 34. Синонимнарның төрләре

Телдә кулланыла торган охшаш мәгънәле сүзләр ике төркемгә бүленә. Беренчесе аның т е л  с и н о н и м н а р ы термины белән атап йөртелә. Бу төр синонимнар мәгънә охшашлыгына ия, аерым бер төшенчәне төрле яклап тасвирлыйлар, синонимик парадигма

составына керәләр, синоним вазифасында сүзлекләрдә теркәләләр, контекстка бәйсез дә аларның мәгънәви охшашлыгы татар телендә сөйләшүчеләр өчен билгеле. Алга таба бу төр синонимнарның төрләренә аерым тукталырбыз.

Икенче төркемкысасында контекстуаль синонимнар (окказиональ, автор синонимнары) карала. Контекстуаль синонимнарның аермалы билгеләре: 1) контекстка турыдан-туры бәйлелек; 2) индивидуаль семантик характерда булулары; 3) кулланылышлары ягыннан чикле булу; 4) сүзлекләрдә аерым лексик берәмлек буларак бирелмәү; 5) башка телгә тәрҗемә иткәндә, мәгънәне төгәл бирү авыр.

Гадәттә, контекстуаль синонимнар экспрессив бизәкле булалар, чөнки аларның төп вазифасы – чынбарлыктагы күренешләрне атау түгел, бәлки аларга бәя бирү, аларны характерлау. Мисал өчен, әлеге контекстта аерып бирелгән сүзләр – авыру төрләре *холера, хандра* белән бергә шул рәткә кертелгән *идеализм* сүзе синонимик рәт хасил итәләр: *Эсселәр дә безне сукмадылар. / Суыклар да тимәде безгә. / **Холера** да шылды. **Хандрасы** да. / **«Идеализм»** дигәнегез дә.* (Х. Туфан)

Бу төр синонимнар әдәби әсәрләрдә образ һәм сөйләм мелодикасын тудыру өчен хезмәт итәләр һәм күпчелек очракта күчерелмә мәгънәдә булалар. Алар сөйләүче, язучы тарафыннан индивидуаль мәгънә салу нәтиҗәсендә, стиль таләбенә туры китереп, һәм башка сәбәпләр аркасында барлыкка киләләр. Мәсәлән, *Әгъләм абыйны юлында **теш кайраган кешеләр** булган икән. **Дошманнары** юктан вәсвәсә чыгаручылары табылды.* (Т. Галиуллин)

Еш кына бер контекстта кулланылган ялгызлык исеме һәм аның атамасы, аны алыштырып килгән алмашлык синоним булып килә: *Менә шул вакытта Чулпанның гомер юлында **Наил** пәйда булды. Очраклы рәвештә генә каршыга чыккан бу чибәр, акыллы, итагатьле **егет** аны шундук әсир итте.* (Г. Гыйльманов)

Телдә кулланыла торган синонимнарның зур күпчелеген тел синонимнары тәшкил итә. Тел синонимнарның аермалы (дифференциаль) билгеләре берничә төрле булырга мөмкин:

1) эчтәлекләре ягыннан *(агару – чал керү, чал төшү)*;

2) синонимның нинди стильдә кулланылуы ягыннан (*агару – кырпак төшү; ду килү, дуамаллану, җенләнү, тилерү, котырыну* – сөйләм теленә хас);

3) эмоциональ-экспрессивлыгы ягыннан (ирония, иркәләү, ачулану, өнәмәү): *ду килү – кирәген бирү, тетмәсен тетү, арт сабагын укыту*).

Шуның өстенә тел синонимнары структур ясалышлары, телдәге активлыклары белән дә бер-берсеннән аерылып торалар. Мәсәлән, *кундәм – күнүчән, карусыз, карышмаучан, каршылыксыз, тыңлаучы, тыңлаучан, буйсынучан, ипкә килүчән, итагатьле, сүз кайтара белми торган, тыңчан, баш тартмый торган* синонимик парадигмада синтетик төзелешле сүзләр белән беррәттән, аналитик структуралар да урын ала. Шулай ук *карышмаучан, тыңлаучы, тыңчан* сүзләре телдә бу мәгънәне бирүдә пассив кулланылалар.

Татар телендәге синонимик парадигмаларның структур ягына күз салсак, мондый күренешкә тап булабыз. Гадәттә, татар телендә синонимнар төрле тамырга карый, әмма бер тамыр (нигез) тирәсендә берләшкән синонимик сүзләрне дә еш очратабыз. Мисал өчен, *искиткеч* доминанта сүз тирәсенә тупланган синонимик парадигмага мондый сүзләр керә: *искитәрлек, искитәрдәй, искитмәле, гаҗәп, гаҗәеп, шаккаткыч, шаккатырлык, шаккатырдай, шаккатмалы, хәйран калырлык, хәйран калырдай, хәйран калмалы, сокландыргыч, соклангыч, сокланырлык, таң калырлык, таң калмалы, таң калырдай, һуш китмәле, һуш китәрлек, һуш җибәрмәле* (Ханбикова, 1999: 46). Синонимик парадигмада төп алты берәмлек (*искитәрлек, гаҗәп, шаккаткыч, хәйран калырлык, сокландыргыч, таң калырлык*) нигез вазифасын башкара, шулар нигезендә телнең сүз ясагыч һәм грамматик чаралары синонимик парадигманың сан ягыннан артуына китерә. Бирелгән сүзләр бер-берсеннән бик нечкә семантик төсмер белән аерылып торалар. Телнең синонимик байлыгын арттыруда татар теленең лексик составы гына түгел, грамматик чаралары да зур роль уйный.

Тел синонимнарының киң таралган бер вазифасы – эвфемистик роль башкару. Э в ф е м и з м (грек. *euphemismos* – яхшы сөйлим) дип әхлак һәм сөйләм кануннарына туры килми торган сүзләр, әйтелмәләр урынына кулланыла торган берәмлекләрне атыйлар. Гадәттә, бу төр берәмлекләр телдә синонимик рәтләр кысасында даими яшиләр. Мәсәлән, *тазару* сүзе урынына *түгәрәкләнү, тулышу* сүзләрен, *үлү* сүзе урынына *мәңгелек йокыга талу, күзләрен йому, киту* һ.б. берәмлекләр куллану сөйләм әдәбе саклау максатыннан башкарыла.

Аермалы билгеләргә карап, тел белемендә синонимнарның идеографик, эмоциональ-экспрессив, стилистик, абсолют кебек төрләре күрсәтелә.

Идеографик синонимнар ул – мәгънә төсмерләре белән аерылып торган синонимнар. Идеографик синонимнар телдә зур күпчелекне тәшкил итәләр. Алар фикерне төгәл, анык итеп җиткерүдә зур роль уйный. Мәсәлән, *Ә минеке?/ Ә минеке ерак, / Ерак әле моннан шулкадәр;/ Бу төшләргә килеп җитә алмый / Ни бер* ***сәлам****, ни* ***хат****, ни* ***хәбәр****!* (Х. Туфан)

Бу төр синонимнар күпчелек очракта берсе урынына икенчесе килә алмый, чөнки мәгънә төсмерләрен аермыйча куллану фикерне төгәл биреп бетермәү генә түгел, бөтенләй башкача аңлауга да урын калдыра.

Идеографик синонимнарның мәгънә ягыннан аерымлыклары түбәндәгеләрдә күренә: 1) бер-берсеннән аермалы булган предмет яки күренешне белдерүдә *(мендәр, күпчек, түшәк, ястык)* – бер ятак предметлары күләм ягыннан аерылалар; 2) билгенең дәрәҗәсе, аның предметларда күп яки аз табылуы: *кычкыру, акыру, бакыру, улау*; 3) предмет яки күренешнең бер үк билгесен төрлечә чагылдыру ягыннан аерымлык. Бу очракта билгенең бер ягына басым ясала, мәсәлән, *чибәр, матур йөз; сылу, зифа гәүдә;* 4) аерым предмет, күренешләрнең билгесе булып беркетелүгә нигезләнгән аерымлык: *эссе* (көн), *кайнар* (су), *кызган* (тимер).

Стилистик синонимнар дип төрле стильләрдә кулланыла торган синонимнарны атыйлар. Мәсәлән*, йоклау – йокыга талу, черем итү, йокыда изрәү, йокы симертү, йокы бүсү, йокы сүтү* синонимик парадигмада *йокы симертү, йокы бүсү, йокы сүтү* лексик берәмлекләре түбәнәйтелгән стильдә, сөйләм телендә кулланылу белән башкалардан аерылып торалар.

Түбәндәге шигъри юллардагы *дәрман* сүзе әдәби телдә күбрәк кулланылса, *җегәр* сүзе сөйләм теленә хас булуы белән аерыла:

*Суынмадык:*
*Бездә әле* ***дәрман****,*
*Бездә әле* ***җегәр*** *җитәрлек;*
*Әле тагын берәр ярты гасыр*
*«Эһ» тә итми гомер итәрлек!* (*Х. Туфан)*

Эмоциональ-экспрессив синонимнар ул – чынбарлыкка төрле мөнәсәбәт белдерү ягыннан аерыла торган

синонимнар. *Мәсәлән: Ул, нишләргә белмичә* ***ашкынып, ярсып, упкынга ташлангандай,*** *ниндидер башсыз тәвәккәллек белән, ике сакчыны як-якка этеп җибәреп, урамга атылды.* (Г. Бәширов); *Таш өстендә таш калмады, агач затыннан агач калмады, куаклар калмады – һәммәсе* ***янды, көйде, кара күмергә әйләнде.*** (Г. Бәширов)

А б с о л ю т с и н о н и м н а р – бер төшенчә бирү өчен кулланылган, мәгънәләре буенча тулысынча тәңгәл килә торган синонимнар: *тел белеме – тел гыйлеме, лингвистика; бегемот – гиппопотам, су сыеры, су айгыры* һ.б. Бу төр синонимнарда мәгънә дифференциациясе юк, алар бер үк төшенчәне белдерәләр, шуңа аларны тулы синонимнар дип тә атап йөртәләр. Мәсәлән, *Сиңа, балакаем,* ***Аллаһы Тәгалә*** *барысын да биргән,* ***Ходай*** *синнән берни дә кызганмаган.* (М. Хәбибуллин) җөмләсендәге *Аллаһы Тәгалә, Ходай* сүзләре абсолют синоним булып торалар.

Ш.С. Ханбикова абсолют синонимнарның түбәндәге аермалы билгеләрен күрсәтә: 1) семантик тәңгәллек; 2) стилистик битарафлык; 3) синхроник күренеш, ягъни төрле чорга, төрле социаль катламга караган сүзләр абсолют синоним була алмый (Ханбикова, 1980: 113). Бу төр синонимнар телдә күп түгел, аларны билгеләгәндә, әйбер-күренешнең төрле атамасы булуын истә тоту зарур.

### § 35. Синонимнарның барлыкка килүе һәм функциональ-стилистик вазифасы

Синонимнар телдә даими барлыкка килеп торалар. Бу процесс ике әһәмиятле шартка бәйле. Беренчедән, синонимнар хасил булу телнең үз эчендә, тел закончалыклары нигезендә барса, икенчедән, башка телләр белән багланышлар нәтиҗәсендә телнең синонимик байлыгы арта.

Телнең үз закончалыклары нигезендә синонимнар барлыкка килү түбәндәге юллар белән бара:

1) сүзнең мәгънәсе киңәю һәм таркалу нәтиҗәсендә синонимнар ясала, ягъни бер мәгънәле сүзнең ике яки аннан да күбрәк мәгънәсе барлыкка килү әлеге мәгънәләрнең башка сүзләр белән синонимлашуына китерә: *баш – төп, иң әһәмиятле, беренче дәрәҗәле, югары; катлам – төркем, катлау;*

2) сүздә яки грамматик формаларда аваз үзгәрү: *тугры – туры – турылыклы* (фонетик юл);

3) төп сүзгә синоним сүз яки бер үк функцияле кушымчалар ялгану юлы белән – морфологик юл (*ут-күз, бала-чага, булдыклы – булган, эшлекле – эшчән* һ.б.);

4) төрле стилистик һәм эмоциональ-экспрессив катламнарда кулланылган сүзләрнең синонимлашуы: *туплау – җыю, берләштерү, укмаштыру, тарту; әкрен – авыр, мыштырдык, мыштыр, сүлпән, мыштым, авыр кузгалучан;*

5) аерым диалектларда гына куллана торган сүзләрнең әдәби телгә үтеп керүе: *нәни, кечкенә, бәләкәй; начар, алама; беренче, тәүге; бәс – сыкы, зыкы;*

6) табу сүзләрнең һәм аларны алыштырып килә торган эвфемизмнарның үзара синонимлашуы: *симерү – тазару, түгәрәкләнү, юанаю; рак – яман шеш, теге авыру; туберкулёз – чахотка, тбс* һ.б.;

7) сленг, жаргон лексиканың әдәби тел сүзләре белән синонимлашуы: *тулай торак – общага, авыл (ДУ) (универсиада авылының хәзерге студентлар телендә кулланылышы); аракы – акбаш, Чистай малае, шайтан суы* һ.б.

Башка телләрдән алынмалар кабул ителү нәтиҗәсендә, телдә синонимнар барлыкка килү – иң киң таралган күренешләрдән. Мәгънә ягыннан якын булган сүзләрнең телгә үтеп керүе нәтиҗәсендә, синонимик парлар яки синонимик рәтләр хасил булу татар телендә шактый борынгыдан килә һәм хәзерге татар телендә дә киң таралган.

Борынгы заманнарда ук төрки телгә башка телләрдән сүзләр үтеп кереп, синонимнар барлыкка килгән. Ислам мәдәниятенең татар теленә тәэсире башланганнан бирле, татар теленең синонимик байлыгын хасил итүдә гарәп һәм фарсы телләренең роле зур була. Бу төр синонимик рәтләр хәзерге татар телендә милли мәдәниятне чагылдыра торган берәмлекләрдән санала, һәм халык тарафыннан алар башка мәдәният берәмлеге буларак кабул ителми: *Тәңре – Хак Тәгалә, Алла – Ходай; иптәш – дус, ахирәт, дус-иш, әшнә; мәхәббәт – ярату, сөю, гыйшык, дәрт; ватан – туган ил; гыйлем – белем; фәкыйрь – ярлы, хәерче.*

Соңрак телебезгә үтеп кергән рус һәм Европа алынмаларының да татар теленең синонимик системасын баетудагы роле зур: *буразна – ызан; бәйләнеш – мөнәсәбәт, контакт; ара – аралык, бушлык, интервал, дистанция, ераклык; копия – күчермә* һ.б.

Синонимия күренешен аерым сүзләр арасында гына түгел, тотрыклы әйтелмәләрдә дә күзәтергә мөмкин, мәсәлән, *баш тарту – ваз кичү, кире кагу, кире кайту* һ.б. Бу мәсьәлә татар тел белемендә Г.Х. Ахунҗанов тарафыннан «Татар теленең идиомалары» хезмәтендә махсус яктыртыла (Ахунҗанов, 1972). Автор идиомаларны синонимлыгы ягыннан түбәндәге төрләргә бүлә[1]:

1) семантик синонимнар, ягъни компонентлар составы үзгә, ә логик мәгънәләре бердәй яки якын булган һәм мәгънә төсмерләре буенча бер-береннән аерыла торган идиомалар: *кыл да кыймылдатмау – бер эш тә эшләмәү, аркылы ятканны буйга алып салмау;*

2) стилистик синонимнар: *энәдән дөя ясау – чебеннән фил ясау; инә төртер урын юк – алма төшәр урын юк;*

3) семантик-стилистик синонимнар, ягъни компонентлар составы үзгә, ә мәгънәләре бердәй яки якын булган һәм бер-берсеннән семантик төсмер белән дә, стилистик төсмер белән дә аерыла торган идиомалар: *түбәннән күтәрелү – сәнәктән көрәк булу; баш вату – ми черетү; эттән алып эткә салу – пыр туздыру;*

4) абсолют синонимнар, ягъни мәгънәләре һәм стилистик төсмерләре бердәй: *иләк белән су ташу – комнан бау ишү; ике куян артыннан куу – ике көймә койрыгын тоту; баштан сыйпамаслар – рәхмәт әйтмәсләр* һ.б.

Синонимнар – телнең кабатланмас байлыгы. Синонимик чаралар ни дәрәҗәдә бай булса, телдә бер үк фикерне төрле ысуллар белән бирә алу сәләте дә шулкадәр киңрәк була. Сөйләмдә синонимнар куллану, бер үк сүзләрне яки гыйбарәләрне, мәгънә төгәллеген саклаган хәлдә, кабатлаудан коткара. Мәсәлән, *Башына килгән бөтен уй-хыялы* ***сибелде, таралды, фикер җеп очы кулыннан ычкынды.*** (М. Хәбибуллин) Бер контекст эчендә сүз һәм аны алмаштырып килгән алмашлык кулланылу да шуңа нигезләнгән: *Гадел генә каршы төште, ул,нигәдер, бик моңсу иде.*

Синонимнарның төп вазифасы – сөйләмне тәэсирле, үтемле итү, мәгънәнең нечкә төсмерләрен мөмкин кадәр төгәл бирү, охшаш, әмма бер-берсеннән аерылып торган чынбарлык күренешләрен атау. *Ак күбәләккә охшаганга күрә дә аңардан чәчәкләр дөньясына хас табигый* ***садәлек,*** *назлы-нәфис* ***сөйкемлелек*** *аңкып тора иде* (Ә. Еники) мисалында *садәлек* һәм *сөйкемлелек* сүзләрен

[1] Бу турыда тулырак «Фразеология» бүлегендә бирелә.

куллану кешегә хас сыйфатларда урын алган аермаларны төгәл күрсәтү өчен кулланыла.

Контекстта синонимнарның бер-бер артлы килүе семантик градация, ягъни мәгънә көче артуын искәртә: *Әмма бу юлы түздем, тешләремне кыстым, ләкин* ***тавыш-гауга куптармадым, талашмадым, әрләшмәдем.*** (Ф. Латыйфи)

***Сау бул инде, хуш, бәхил бул,***

*И минем торган җирем.* (Г. Тукай)

Р.С. Абдуллина күрсәтүенчә, әлеге шигырь юлларында саубуллашу синонимнары тойгы тәэсирен көчәйтә торган тәртиптә урнашканнар: башта киң кулланылыштагы *сау бул,* аннары аерылышканда яхшы теләк теләп әйтелә торган *хуш* сүзе, аннан соң мәңгегә хушлашканда яки гафу үтенеп хушлашканда әйтелә торган *бәхил бул* гыйбарәсе урын алган (Абдуллина, 2012: 378).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, синонимнар, телнең байлыгы булу белән беррәттән, сөйләмнең төгәллеген, төзеклеген, семантик нечкәлекләрнең дә төп күрсәткече булып тора.

## Татар телендә антонимия күренеше

### § 36. Тел белемендә антонимнарны өйрәнү тарихы

Гомуми тел белемендә, русистикада, тюркологиядә антонимия күренешенең аерым аспектлары җентекле өйрәнелгән. XX йөзнең икенче яртысында антонимнар В.В. Виноградов, А.А. Уфимцева, В.Н. Комиссаров, О.С. Ахманова, Л.Ю. Лесников, В.Н. Клюева, Т.Н. Лукина, А.А. Киреев, Э.И. Родичева, Л.А. Введенская, Л.А. Новиков, М.Р. Львов, Я.И. Гельблу, Н.Л. Камацкайте, Т.И. Арбекова, Р.З. Гинзбург, В.М. Завьялова, Ш. Балли һ.б. тарафыннан тикшерелә.

Антонимия мәсьәләләренә шулай ук тюркологиядә дә шактый игътибар ителә: башкорт тел белемендә – М. Әхтямов, үзбәк телендә – С. Усманов, Б.О. Исабеков, Р. Шукуров, каракалпакта – Е. Бердимуратов, казах тел белемендә – Ж. Мусин, азәрбайҗанда – С.А. Джаффаров, К.А. Талыбов, Кырым татарлары телендә – А. Меметов, кыргызларда – Б.И. Усубалиев, төрекмән телендә Б. Байджанов һ.б. хезмәтләре бар.

Гомуми тел белемендә антонимия күренешенә карата ике төрле фикер яшәп килә. Беренче фараз буенча, төрле тамырдан булган

сүзләр генә антонимнар дип карала ала (Л.А. Булаховский) Икенче фикер буенча, төрле тамырдан булган сүзләр белән беррәттән, тамырдаш сүзләр дә антонимнар була. А.А. Реформатский, Н.М. Шанский һ.б.тарафыннан әйтелгән әлеге фикер күпчелек галимнәр тарафыннан хуплана.

Татар телендә беренчеләрдән булып антонимнарга К.Насыйри игътибар итә. Үзенең «Әнмүзәҗ» китабында ул: «Синоним яисә антоним булган ике фигыльдән шулай ук парлы сүзтезмәләр ясала», дигән фикерне белдерә һәм мисалга *ачалак-җумалак, азган-тузган, алыш-биреш* һ.б. фигыльләрне китерә. Галим антонимнарга шулай ук фигыльнең юклык формасын да кертеп карый: *барыр – бармас, җитәр – җитмәс* һ.б. (Насыйри, 1975: 187).

XX гасырның икенче яртысында татар теленең антонимик системасына караган беренче хезмәтләр языла башлый. Антонимнарның төрле аспектларын анализлау «Хәзерге татар әдәби теле» дәреслегендә күренә. Монда антонимнарның алты төре аерылып карала: а) кеше эшчәнлеген, табигатен һәм хәлен белдерә торган сүзләр: *яшьлек – картлык, эшчән – ялкау* һ.б.; ә) табигать күренешләрен белдерә торган сүзләр: *болытлы – аяз, эрегән – каткан, тау – чокыр* һ.б.; б) вакыт төшенчәсенә бәйләнешле сүзләр: *кыш – җәй, иртә – кич* һ.б.; в) урын төшенчәсенә бәйләнешле сүзләр: *ерак – якын, киң – тар, озын – кыска* һ.б.; г) кешенең хисләренә, кичерешләренә бәйләнешле сүзләр: *көлү – елау, шатлык – кайгы, мәхәббәт – нәфрәт* һ.б.; д) кешеләрнең һәм әйберләрнең сыйфатларын, үзенчәлекләрен белдерә торган антонимнар: *яхшы – начар, пычрак – чиста, ак – кара* һ.б. (Хәзерге татар әдәби теле, 1965: 38–41).

Г.Х. Әхәтовның 1977 елда «Совет мәктәбе» журналында «Татар телендә антонимнар» дип исемләнгән махсус мәкаләсе басылып чыга. Галим, беренчеләрдән булып, татар телендәге антонимнарның лексик-семантик классификациясен тәкъдим итә һәм структур үзенчәлекләренә игътибарын юнәлтә: төп (*яз – көз, кыш – җәй* һ.б.), ясалма (*караңгы – якты, тыныч – хәвефле, кыйммәт – очсыз* һ.б.) һәм антонимик мөнәсәбәткә китергән парлы сүзләрне (*барыр-бармас, ызгыш-талаш* һ.б.) бүлеп чыгара (Әхәтов, 1977: 32–33).

Ш.С. Ханбикованың татар телендә антонимик мәгънәләр буенча махсус мәкаләсе бар. Әлеге хезмәттә автор тарафыннан энантиосемия күренеше җентекле тикшерелә. Галимә аның 2 төрен

күрсәтә: бер сүздә булган капма-каршылык (*дару, йомшак, дан* һ.б.); 2) бер мәгънәдә булган капма-каршылык (*калдыру, китү* һ.б.) (Ханбикова, 1982: 3–6).

Ф.С. Сафиуллинаның лексикология буенча дәреслегендә антонимнар буенча мәгълүматлар системага салынып, гомумиләштерелеп бирелә (*төче – ачы, салкын – җылы, ерак – якын* һ.б.). Галимә антонимнарның парлы сүзләр ясалуда нигез булып торуын искәртә (*юк-бар, азмы-күпме, кайта-килә* һ.б.), антонимнарның мәгънәләре ягыннан биш төрен аерып чыгара. Шулай ук ул сөйләмдә антонимнарның оксюморон, антитеза һәм катахреза кебек стилистик фигуралар ясауда әһәмиятен ачып бирә (Сафиуллина, 1999: 51–56).

М.Б. Хәйруллин хезмәтләрендә лексик антонимнар турында гомуми мәгълүмат китерелә, аларның татар теленең сүзлек составын, татар теленең функциональ стильләрен баетуда тоткан урыны ачыклана. Галим лексик һәм грамматик антонимнарны аерып чыгарып, аларның өч төрен күрсәтә: тамыр антонимнар (*үлем – яшәү, ут – су* һ.б.), ясалма антонимнар (*ямьле – ямьсез, аркылыга – буйга* һ.б.), парлы антонимнар (*чиле-пешле* һ.б.) (Хайруллин, 2000: 105–108).

Х.Р. Курбатов татар теленең лингвистик стилистикасын һәм поэтикасын өйрәнү барышында антонимнарның стилистик яктан кулланылышына аерым туктала һәм антонимия күренеше белән бәйле булган оксюмороннарга игътибар итә. Шулай ук капма-каршылыкка корылган антитеза күренешенең әһәмиятле булуына да басым ясый (Курбатов, 2002: 87–89).

И.Б. Бәширова татар семасиологиясен монографик планда өйрәнгән хезмәтендә татар телендә контраст мәгънәнең (төшенчәнең) капма-каршы мәгънәле ике сүз белән белдерелә алуын, гомумән, антонимия күренешен тәфсилле анализлый. Галимә ассызыклавынча, «билгеле бер уртак нигезгә утыртылган контраст төшенчәнең капма-каршы сүзләр белән белдерелүенә корылган тел күренеше булганда – антоним, сөйләм күренеше булганда – антитеза, үзенең табигате, структур төзелеше һәм функциональ мөмкинлеге белән катлаулы микросистема буларак, телдәге күпмәгънәлелек – полисемия, омонимия, энантиосемия, синонимия кебек, шулай ук катлаулы булган лексик-семантик категорияләр белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә яши» (Бәширова, 2010: 364). И.Б. Бәширова сүз-мәгънәнең поляррлашуына, ягъни энантиосемиягә аерым тукталып уза (Бәширова, 2010: 232–264).

Татар тел белемендә антонимия күренеше буенча ике кандидатлык диссертациясе якланган. Л.Г. Хәбибов, беренчеләрдән булып, антонимия күренешен системалаштырып өйрәнә, татар телендәге антонимнарны тикшерү өчен, гомумтеоретик нигез тәкъдим итә. Антонимнарның структур-семантик төзелеш үзенчәлекләрен анализлаганда, ул антонимия күренешенең телдәге лексик-семантик система буларак, каршы куелуның төрләре һәм телдә чагылышы, антонимиянең полисемия, синонимия белән бәйләнеше, энантиосемия, антонимнарны сурәтләү чарасы буларак кулланылуы мәсьәләләренә аерым тукталып үтә. Хезмәтнең тагын бер уңышлы һәм әһәмиятле өлеше – кушымтасы, монда антонимнар сүзлеге төзү өчен материаллар һәм критерийлар бирелә (Хәбибов, 1984).

Р.М. Закирова «Татар телендә антонимнар» дип исемләнгән фәнни эшендә антонимнарны төркемләү принципларын, критерийларын тәкъдим итә. Ул татар теленең антонимнарын дүрт яктан классификацияләп була дип саный: лексик-грамматик (ягъни кайсы сүз төркемнәренә керүләре буенча), семантик яктан (лексик мәгънәләр буенча капма-каршылыклары, энантиосемия, фразеологик антонимнар), структур яктан (тамыр, суффиксаль, кушма), һәм синтаксик-стилистик принцип буенча (контекстуаль, оксюморон, катахреза, антитеза). Диссертант антонимнарның морфологик классификациясен җентекле өйрәнә, исем, сыйфат, фигыль, рәвеш сүз төркемнәренә кергән капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне тирәнтен тикшерә (Закирова, 2002).

М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, Д.Г. Тумашева, Ә.М. Ахунҗанов, Р.А. Йосыпов, Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, Л.М. Ризванова, Д.Б. Рамазанова һ.б. хезмәтләрендә антонимнарның структурасы, грамматик һәм стилистик үзенчәлекләре, аларның фольклорда, ялгызлык исемнәре системасында кулланылышлары турында мәгълүматлар бирелә.

Хәзерге көндә татар теленең өч антонимнар сүзлеге бар. Ф.С. Сафиуллина Л.М. Ризванова белән берлектә 1997 елда «Татарча-русча антонимнар сүзлеге» бастырып чыгара (Сафиуллина, 1997). Татар тел белемендә бу антонимнарның беренче сүзлегендә 1000 парга якын антоним теркәлә. Шулай ук Ф.С. Сафиуллина авторлыгында 2003 елда «Татарча-русча, русча-татарча антонимнар» сүзлеге дөнья күрә. 2005 елда Ф.С. Сафиуллинаның «Антонимнар сүзлеге» нәшер ителә. Әлеге сүзлектә антонимнар хәзерге татар поэзиясе һәм мә-

кальләрдән тупланып бирелә, сирәк очракта антонимнарның чыганагы итеп татар сөйләм теле алына (Сафиуллина, 2005).

Антонимия мәсьәләсе тел галимнәренең игътибарын даими җәлеп итә, шулай да әлеге яссылыкта, телнең хәзерге торышын да исәпкә алып, махсус өйрәнүләр күтелә. Антонимнарны җентекле тикшерү татар теленең тулы антонимнар сүзлеген төзү өчен аеруча әһәмиятле.

### § 37. Антонимия күренешенә гомуми билгеләмә

Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр антонимнар (грек. *anti* – каршы, *onyma* – исем) дип атала. Мәсәлән, ***Алны, артны, уңны, сулны*** *белмичә утын кисә.* (Г. Тукай); ***Язгы*** *көн киендерә,* ***көзге*** *көн сөендерә.* (Мәкаль); ***Галим*** *белгәнен әйтер,* ***ахмак*** *җиңгәнен әйтер.* (Мәкаль) Лингвистиканың антонимнарны өйрәнә торган бүлеге антонимия яисә антонимика исемнәрен йөртә.

Антонимнарның барлыкка килүе, үсеше чынбарлыктагы күренешләрнең, билгеләрнең капма-каршылыгына барып тоташа. Капма-каршылык үзеннән-үзе абсолют төшенчә булып тора, шулай да аның телдә чагылышы, ягъни капма-каршы мәгънәдәге тел берәмлекләре белән бирелеше һәрвакыт шартлы.

Антонимнар булып логик бәйләнешләре ягыннан бер-берсенә туры килгән сүзләр генә тора ала. Мәсәлән, ***Кайгылы*** *чагымда килмәде. / Авыр булды, түздем. /* ***Шатлыклы*** *чагымда килмәде. / ...Арабызны өздем* (Р. Фәйзуллин) җөмләсендә *шатлыклы – кайгылы* антонимнары арасында билге буенча логик бәйләнеш урнашкан.

Шулай ук семантик һәм грамматик мәгънәләр ягыннан да антоним сүзләр арасында уртаклык булырга тиеш. Шуңа күрә барлык сүзләрнең дә антонимик парлары булмаска мөмкин. Мәсәлән, конкрет мәгънәдәге исемнәр, саннар, кайбер алмашлыкларның антонимнары юк: *өстәл, дивар, икешәр, уналты, ничә, үзе* һ.б. Антонимик мөнәсәбәткә керә алу үзенчәлеге иң беренче чиратта ниндидер билгене белдергән сүзләргә хас: *озын – кыска, киң – тар, зур – кечкенә, яхшы – яман, күп – аз, туры – кыек, күмәк – ялгыз, куе – сыек, батыр – куркак* һ.б.

Антонимнар мәгънәләре ягыннан вакыт, билге, урын, күләм, табигать күренешләренә бәйле булган контраст төшенчәләрне белдерәләр. Мәсәлән:

1. Предметларның, процессларның, күренешләрнең сыйфатларын, билгеләрен тасвирлый торган антонимнар: *Эшләве **авыр** булса, ашавы **җиңел.*** (Мәкаль); *Үзең **юаш** кебек, үзең **усал.** / Чакырасың гүя кыяр-кыймас...* (Г. Афзал); ***Ачы** дөреслек **татлы** ялганнан яхшырак.* (Мәкаль)

2. Вакыт төшенчәсен белдерә торган антонимнар: ***Кич** ятсам да, **иртә** торсам да, / Әллә нәрсә җитми шикелле.* (М. Җәлил); ***Җәйге** эшләпә җилләтә, **кышкы** эшләпә тирләтә.* (Мәкаль); *Юк, **соң** да түгел, **иртә** дә...* (Ә. Давыдов)

3. Күренешләрнең озынлыгын, күләмен, урнашуын ачыклый торган антонимнар: ***Юан** сузылганчы, **нечкә** өзелер.* (Мәкаль); *Яшел урман булып еракта / Күксел урман сузыла һәр якка...; Ул **ерак** та кебек, **якын** да...* (М. Ногман); ***Аз** сөйлә, **күп** тыңла.* (Мәкаль)

4. Табигать күренешләре белән бәйле антонимнар: *Казан – төтен. Йолдызлары тере – / **Күктә** дә дар алар, **җирдә** дә...* (С. Гәрәева); ***Кояшың** батып, калыкмас **аең,** / Очып сайрамас күңел тургаең.* (Ф. Яхин); ***Сай** елга шалтырап ага, **тирән** – тавышсыз.* (Мәкаль)

5. Процессларны каршы куя торган антонимнар: ***Ни аласы, ни сатасы** бар соң? / Авыз ачсаң – үпкә күренә!* (Ф. Яхин); *Олыларда курку, борчылу, / **Үгетләп тә** кара, **тиргәп тә,** – / Үч иткәндәй, яшен вакытында / Бала-чага җыела тирәккә.* (С. Хәким); ***Чыгасы** чыкмый, **керәсе** кермәс.* (Мәкаль)

6. Гомуми төшенчәләрне белдерә торган антонимнар: *Илең өчен янып **яшәве** дә, / **Үлүе** дә мең кат саваплы.* (Х. Хөснуллин); *Җирдә шатлык, җирдә кайгы, Җирдә **тынычлык, сугыш.*** (М. Гыймазетдинов); ***Бәхет** тәрәзәдән карый, **кайгы** ишектән керә.* (Мәкаль)

7. Урын төшенчәсен белдерә торган антонимнар: *Тикшерде күк аннан а**стны, өстен** / Язу өстәленең* (С. Хәким); ***Уң** күзең күргәнне **сул** күзең күрмәсен.* (Мәкаль)

Татар телендә сүз белән сүз: *бүген – иртәгә, кич – иртә, бару – кайту* һ.б., сүз һәм сүзләр җыелмасы: *кар – ләйсән яңгыр, бирү – мәхрүм итү, җәяү – машинага утырып бару* һ.б., сүз – фразеологизм: *үлү – дөньяга килү, дәшмәү – сүз әйтү,* фразеологизм – фразеологизм: аркылы төшү – көеннән тору, ачык йөз – караңгы чырай, аяк чалу – юл ачу, авыр сүз – җылы сүз һ.б. арасында антонимик мөнәсәбәтләр урнашырга мөмкин.

Мәгънәләре капма-каршы булган фразеологик берәмлекләрнең күп булуы – татар теленең үзенчәлекле ягы. Фразеологик берәмлекләр структур яктан ике төркемгә аерылалар:

1) үзгә структуралы антоним фразеологик берәмлекләр (эчке формалары, образ структурасы үзгә): *Син, Газиз, чынлап сөйләшкәндә* ***авызыңны ерма*** *әле.* (Ф. Әмирхан); *Хатын-кыз* ***балавыз сыкмый*** *гына яши алмыйдыр инде.* (Б. Камалов); *Ләкин шома гимназист* ***буй бирергә*** *һич тә теләми иде.* (Ф. Хөсни); *Тик бер өмет, дуслар, сезнең сафта / Табар соңгы көрәш теләгем, / Яраланган, ләкин тар коллыкка /* ***Баш имәгән*** *керсез йөрәгем.* (М. Җәлил); *Бүген генә* ***эч катып көлдем*** *исә, / Иртәгә* ***күземне кайнар яшь кисә.*** (Ф. Яхин);

2) уртак структуралы антоним фразеологик берәмлекләр (эчке формасы, образ структурасы уртак, әмма лексик һәм грамматик составы ягыннан өлешчә үзгә): *Чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы* ***дөньяга килгәнгә,*** *мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы юатып, тирбәтеп утыра идем.* (Г. Тукай) – *Ике ел шулай өстерәлде, көзге пычракларның берсендә* ***дөньядан үтте.*** (Г. Ибраһимов); *Аерылып китсәм дә синнән* ***гомеремнең таңында*** *мин...* (Г. Тукай) – ***Гомернең*** *дә* ***көзе*** *бардыр бит дип / Уйламый да, уйламый да идек без. (*Х. Туфан); *Таныш кешене шуннан соң күргәләсәм дә, ул, берни дәшмичә, минем яннан* ***борынын күккә чөеп*** *уза торган булды.* (А. Расих) – *Байтак вакыт* ***борынын салындырып*** *йөргәннән соң, ул, ниһаять, яңадан терелеп китте.* (Г. Әпсәләмов)

Антонимнар барлык сүз төркемнәрендә диярлек очрый. Мәсәлән, антоним исемнәр: *авыл – кала, караңгылык – яктылык, ата – ана, гыйлемлек – наданлык* һ.б.; антоним сыйфатлар: *матур – ямьсез, ачы – татлы, усал – юаш, зур – кечкенә* һ.б.; антоним фигыльләр: *бару – кайту, ачу – ябу, эшләү – тик тору* һ.б.; антоним рәвешләр: *аз – күп, акрын – тиз, яхшы – начар* һ.б.; антоним алмашлыклар: *бу – ул, анда – монда, һәркайда – һичкайда* һ.б.; антоним саннар: *бер – мең;* антонимик бәйлек сүзләр: *аст – өст, артыннан – алдыннан* һ.б. Татар телендә сыйфат, рәвеш һәм фигыль сүз төркеме составына кергән сүзләрнең антонимнары аеруча күп булуы күзгә ташлана.

Шунысын искәртү зарур: антоним пар төзүче сүзләр бары тик бер генә сүз төркеменә карый, компонентларның төрле сүз

төркеменә караган очраклары татар телендә очрамый, мәсәлән, *Йокының җиде сәгате* ***дару!*** */ Шуннан артканы –* ***агу*** мәкалендәге *дару – агу* антонимнары икесе дә исем сүз төркеменә керә; ***Иске*** *хәтер,* ***яңа*** *үпкә* мәкалендәге *иске* һәм *яңа* сүзләре икесе дә сыйфатлар.

Үзләренең лексик составы буенча антонимик парлар – төрки-татар чыгышлы сүзләрдән: ***Акрын*** *барган* ***тиз*** *җиткән.* (Мәкаль) һәм алынма сүзләрдән тора: *Без* ***фронтта,*** *ә сез тирән* ***тылда,*** */ Һәм байраклар безнең югары.* (Ә. Камал); *Бөтен нәрсәм булды инде, / Калмады ла бер тиен! / Иң шатлыклы* ***гимндыр*** *бу! / Иң сагышлы* ***реквием.*** (Н. Измайлова)

Грамматик яссылыкта караганда, антоним сүзләр, гадәттә, сөйләмдә тиңдәш кисәкләр булып килә. Алар үзара теркәгеч яки интонация ярдәмендә бәйләнеп килергә мөмкин: *Яфрак* ***озын*** *яшел, /* ***Көзен*** *сары һаман. / Укыган – белемле, / Укымаган – надан.* (Г. Рәхим); ***Кояш*** *белән* ***болыт*** *гел янәшә – / Бер-берсенә дошман булса да.* (Ф. Яхин); *Менә кабып карачы – / Үзе* ***тәмле*** *һәм ...* ***ачы.*** (В. Хәйруллина)

Антонимнар лексик парадигманың периферияседә урнашалар, шунлыктан алар арасында билгенең төрле дәрәҗәсен белдерә торган сүзләр дә очрый. Мәсәлән, *Күршең бай булса да, җигәреңә тай булсын.* (Мәкаль); *Хәлле кеше – хәленчә, барлы кеше – барынча.* (Мәкаль); *Ярлы беләгенә ышаныр.* (Мәкаль); *Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә, Мин фәкыйрь михнәттә – гүя чарлагыннан бай көлә!* (Г. Тукай) һ.б.

Әлеге капма-каршылык теге яисә бу билге, хәлнең артуына, башкача әйткәндә, градациясенә (латинчадан *gradatio* – тора-бара арту, үсү) бәйле. Шул рәвешле, семантик градация билге дәрәҗәсенә ия булган семантик структуралы антонимнарга гына хас була: *яшь – урта яшьтәге – карт, зур – бәләкәй, олы – кечкенә* һ.б. Аерым антонимик парлар исә градуальлек билгесенә ия булмый: *көн – төн, ир-ат – хатын-кыз, аст – өст, яшәү – үлү* һ.б.

Сөйләм барышында туган окказиональ сүзләр дә антонимнар булып килә ала: *Ишетәсеңме икән, югалтышкан / Казлар кебек кыйгылдашканын – Җаннар бергә сарылсын әле,* ***Шатлыкташлар, кайгыдашларым.*** (Х. Әюп); ***Бала-чага*** *чага башлар беркөн, /* ***Олы-чага*** *тагар гомум җәепкә...* (М. Әгъләмов); ***Хыялстанда*** *да /* ***Җирдәге*** *күк / Юллар бик күп! / Ерак барасы... / Ләкин, беләсең:*

*/ Барыбер кире* ***Җиргә*** *кайтасы.* (Р. Гаташ); *Елыйм, / шәфкать сорыйм – /* ***антиминем миннән*** *көлгән була.* (Ә. Рәшит)

Татар телендә эвфемистик антонимнар аерым урын биләп тора. Алар капма-каршылыкны йомшарталар, сөйләмне әдәпсез, вульгар сүзләрдән арындыралар. Мәсәлән, *ялган* сүзе урынына *дөрес түгел, алай түгел, яман – яхшы түгел, явыз – мәрхәмәтсез, суык – җылы түгел, ямьсез – матур түгел* һ.б. сүзләр куллана алу моңа ачык мисал булып тора.

Әгәр дә ике яисә аннан күбрәк булган семантик-тематик яктан якын сүзләр капма-каршылык китереп чыгарсалар, алар антонимик рәт урнаштыралар, аларны икенче төрле антонимик блок дип атап йөртәләр. Кайбер очракларда тематик уртаклык һәм капма-каршылыкка сүзьясалыш һәм грамматик юллар ярдәмендә дә ирешеп була: *ак – аграк, кара – карарак, аклык – каралык, агару – каралту* һ.б.

Аерым очракларда антонимик блоклар бер тематик парадигманы тәшкил итәләр: *шатландыру – көендерү: Кешеләрне* ***шатландыру*** *өчен юмарт булу гына җитми, нечкә зәвыклы булу да кирәк.* (Р. Мирхәйдәров); *Бу хәбәр мине бик* ***көендерде;***

*мактау – хурлау: Күз алдында* ***мактама,*** */ Күз артында* ***хурлама.*** (Мәкаль);

*хуплау – шелтәләү: Дөнья эшен өйделәр. / Атланырга соңардым. / Җитез Пегас атына. / Шуңадыр бер* ***хуплау*** *да / Тапмадым иҗатымда.* (Ф. Давлетбаев); *Ананың бу сүзләрендә Фәһимә бераз* ***шелтәләү*** *дә, үпкә дә, үз язмышына ачыну да сиземләде.* (Д. Каюмова)

Антонимнар шулай ук ялгызлык исемнәрен ясауда да актив кулланылалар: *Акбай – Карабай, Акбикә – Карабикә, Акбатыр – Карабатыр, Акморза – Караморза, Ак диңгез – Кара диңгез, Акмулла – Карамулла* һ.б.

Аерым диалект һәм сөйләшләрдә генә кулланыла торган антонимнар да телебездә шактый очрый: *йаwык* мишәр диалектында ‘якын’: *Ышкулга* ***йаwык*** *тип көчкән* (ТТЗДС, 2009: 224) – *алыс* ‘ерак’: *Безгә кала бик* ***алыс,*** *илле чакрым* (урта диалектның эчкен сөйләше) (ТТЗДС, 2009: 42). *Алдым-салдым* – тубыл-иртыш диалектының түбән сөйләшендә туйда кияү ягыннан китерелә торган ашамлыклар, кием-салымнар һ.б.: *Суратып килсә, кийәү* ***алдым-салымын*** *бирәте, үсләре йарашып бирәтеләр* (ТТЗДС, 2009: 39). *Акыш-макыш*

мишәр диалектының чүпрәле сөйләшендә «рәтле-рәтсез, ялгыш-йолгыш» мәгънәсендә килә: ***Акыш-макыш*** *сүли* (ТТЗДС, 2009: 35).

Югарыда китерелгән күзәтүләрдән шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: антонимия – шактый катлаулы һәм бәхәсле тел күренеше, аның барлыкка килүе, үсеше чынбарлыктагы вакыйгалар, билгеләрнең капма-каршылыгына барып тоташа.

## § 38. Антонимнарның төрләре

Гомуми тел белемендә антоним сүзләрне берничә төрле төркемләү күзәтелә.

Антонимнар төрле төшенчәләрне чагылдыру ягыннан түбәндәге төрләргә аерылып өйрәнеләләр:

– контрадиктор (комплементар) антонимнар – бер-берсен тулыландыра торган капма-каршы мәгънәдәге сүзләр, аларның берсенең инкяр ителүе икенчесенең мәгънәсен китереп чыгара: *Ялган түгел – чын: Коела, әйләнә туфракка / Гайбәте,* ***ялган, чыны.*** (Н. Гамбәр); *Юмарт түгел – саран:* ***Юмарт*** *белән* ***саран*** *бер елгадан су эчмәс.* (Мәкаль); *Исән түгел – үлгән:* ***Исән*** *дуслар ярдәм сорый, / Ярдәм итеп җаның корый. /* ***Үлгән*** *дуслар кадерлерәк.* (Г. Афзал)

– контрар коррелятлар – антоним сүзләр бер-берсенә карата билге буенча капма-каршылыкны белдерәләр, аларга градуальлек хас: *Буйга* ***озын*** *– акылга* ***кыска.*** (Мәкаль); *Ярый, монсы инде үткән-беткән, /* ***Турысы*** *бар сүзнең,* ***кыегы****...* (Л. Шагыйрьҗан); ***Җитез*** *үзен бетерер,* ***акрын*** *эшен бетерер.* (Мәкаль)

– конверсивлар – хәл һәм процессларның капма-каршылыгын белдерә торган антонимнар: ***Алдың*** *ефәк,* ***саттың*** *ефәк.* (Мәкаль); *Нәрсәсенә моның исең китә:* ***Бирәү*** *откан,* ***Меңнәр*** *оттырган.* (Г. Садә); *Ул укытучыга* ***имтихан бирә****. – Укытучы аннан* ***имтихан ала.***

Антонимнарны тәшкил итә торган берәмлекләрнең санына карап, антонимнар ике төркемгә бүленә:

а) бер сүз эчендәге капма-каршылык (энантиосемия): *Чыгару* ‘бастыру, нәшер итү’: *Татарстан дәүләт нәшрияты җырлар җыентыгын* ***чыгарды.*** (М. Җәлил); ‘эшеннән (урыннан) алу, бушату, азат итү’: *Мин хезмәтчеләремнең яртысын* ***чыгарам,*** *... бер дә ситсыны соратучы юк.* (Г. Тукай)

ә) төрле сүзләр арасындагы капма-каршылык: *Ялган сөйләп яшәгәнче, рас сөйләп үләрсең.* (Мәкаль); *Каз кычкыра... / Мескен*

*кала казым, / Әллә оча, әллә куна ул...* (Х. Әюп); *Гомер буе кемдер кора, төзәтә, Кемдер корганнарны сүтә дөньяда.* (Д. Гарифуллин); *Каенлыкта яңа дуслар белән / Иске җырлар җырлап утырдык.* (С. Гәрәева)

С ө й л ә м д ә к у л л а н ы ш л а р ы я г ы н н а н антонимнарны тел (даими, узуаль) антонимнарына һәм контекстуаль (сөйләм, окказиональ) антонимнарга бүлеп йөртәләр.

Тел антонимнары сүзнең төп, конкрет мәгънәләре буенча капма-каршы булсалар, контекстуаль антонимнар окказициональ мәгънәләрнең каршылыгына кайтып кала.

Т е л а н т о н и м н а р ы контексттан тыш та антоним буларак кабул ителәләр, аларның капма-каршы мәгънәле сүзләр икәнен бу телдә сөйләшүче һәр кеше җиңел тоя: ***Атлы*** *тәртә төзәтер,* ***атсыз*** *киртә төзәтер.* (Мәкаль); ***Ачның*** *хәлен* ***тук*** *белмәс.* (Мәкаль); *Мин еллардан гомер дигән / Бер челтәр үреп барам.* ***Матур*** *һәм* ***ямьсез*** *үрелгән / Төшләрен күреп барам.* (Г. Рәхим); ***Үз*** *үтермәс,* ***ят*** *ярлыкмас.* (Мәкаль)

К о н т е к с т у а л ь а н т о н и м н а р билгеле бер ситуациядә, контекстта гына антоним булып киләләр. Аерым кулланганда, антонимик мөнәсәбәтләр юкка чыга: *Агыйделдән көймә килә / Чит-чите буйлап кына. /* ***Ак*** *йөзләрем* ***сары*** *булды / Гел сине уйлап кына.* (Татар халык җыры); *Очырмакчы булсам* ***былбыл*** *күкрәгемнән, / Әллә ничек мыр-мыр итеп,* ***мәче*** *чыга.* (Г. Тукай); ***Шәфәкъ*** *сүнде – хәзер* ***караңгылык*** */ Каплап алды барлык нәрсәне.* (Н. Думави); ***Чабаталы*** *чакта югалмады, /* ***Татарстанлы*** *чакта югалмас!* (Х. Туфан); ***Тузар*** *илнең җәнҗалы бетмәс. /* ***Узар*** *илнең дәрманы китмәс.* (Мәкаль); ***Рус шәһәрен*** *ярсып яклаганда, / Күзләремә* ***Казан*** *күренә.* (Г. Кутуй); *Чынбарлыкка алсу күзлек аша / Юанганбыз карап – чыдарлык! / Ал пыяла күпме алдый ала? /* ***Алсу ялган – кара чынбарлык!*** (Л. Шагыйрьҗан).

Кайбер очракта тел антонимнары контекстуаль антонимнарны ачыклап та килә: *Вакыт белән Якуп Яраша бервакыт:* ***Вакыт*** *алга чаба,* ***Якуп*** *артка чаба.* (Б. Рәхмәт); *Җанымдагы язгы аҗаган, / Күңелдә көзге күкрәү. /* ***Көзге моң*** *һәм* ***яз ярсуы*** */ Очрашудан бу тетрәү.* (Н. Сафина)

С т р у к т у р я к т а н антонимнар түбәндәге төрләргә бүленә:

1) төп (лексик) антонимнар. Күпчелек антонимнар төрле тамырдан булган сүзләр, алар формаль яктан капма-каршылыкны ачык чагылдыралар. ***Акрын*** *арымас,* ***кызу*** *бармас.* (Мәкаль); *Күзләре* ***ачык,***

/ ***Ябык*** *карашың – / Ничек син мине / Сайлый алгансың!* (Н. Измайлова); *Таш* ***ялгыш*** *тияр, чүлмәк* ***дөрес*** *ватылыр.* (Мәкаль);

2) ясалма антонимнарның үз чиратында түбәндәге төрләре аерыла:

а) аффиксаль (грамматик) антонимнар, аларда капма-каршылык сүз тамырында түгел, бәлки кушымчаларда чагыла. Татар телендә күпчелек ясалма антонимнар түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясала:

*-лы/ле, -сыз/-сез: Иле* ***бәхетсез*** *чагында / Ир* ***бәхетле*** *буламы?* (Ә. Баянов); *Бәхәс-ярыш тынар:* ***хаклы, хаксыз,*** */* ***Гаепле*** *һәм* ***гаепсезләр*** *булмас.* (Ә. Баянов); ***Җимешсез*** *агачка балта чабалар,* ***җимешле*** *агачка таш аталар.* (Мәкаль)

*-дәр/-дар, -сез/-сыз: Теле бер минут / Тормаганга тик / Йөрткәннәр аны /* ***Телдәр*** *түти дип.* (Ә. Исхак); *Шундый аңлатырга тырыша бичара* ***телсез*** *үзенең гаепсезлеген, шундый тырыша.* (Ф. Хөсни)

*-чән/-чан, сыз/-сез: Бу килен* ***сүзсез, талашсыз*** *булып чыкты, кара эшкә гаҗәп батыр иде.* (Г. Ибраһимов); *Син өченче ел шундый* ***сүзчән, хәрәкәтчән*** *идең.* (Ф. Әмирхан)

*-гә/-га, -ка/-кә*: ***Уңга*** *киткән – уңар, /* ***Сулга*** *киткән – туңар.* (Мәкаль); *Бия эштә тирли, колын* ***бушка*** *тирли.* (Мәкаль); ***Акчага*** *арыслан сөте дә табып була.* (Мәкаль)

*-да/-дә, -та/-тә: Сүрелә дан җыры, /* ***Еракта, якында*** */ Тибрәлә җан җыры / Былбыллар хакында...* (И. Юзеев)

*-чылык/-челек*: *Алар ни өчен бәхетсез, чөнки алар* ***азчылык.*** («Безнең гәҗит»); *Илдә* ***күпчелек*** *юллар түләүсез.* («Сабантуй»)

*-лык/-лек: Барыс елы –* ***байлык,*** *куян елы – кытлык.* (Мәкаль)

Аффиксаль антонимнардан тыш, татар телендә алкушымчалар ярдәмендә ясалган антонимнар да бар. Алар, нигездә, гарәп-фарсы, рус теле аша кергән алынма формалар булып тора:

*бәд-/бад-: Юлга фатихасын алган көннән / Менде җирдән өскә, яктыга... / Чакырсам да, кире кайту кая, /* ***Доган*** *нәрсә аңа,* ***бәддоган.*** (Р. Гаташ)

*на-/нә-: лаек – нәлаек.*

*анти-: фашизм – антифашизм;*

*гипо-/гипер-: гиповитаминоз – гипервитаминоз;*

*макро-/микро-: макросистема–микросистема;*

*а-: симмертия – асимметрия;*

*контр-: революция – контрреволюция* h.б.

Бу нисбәттән фигыльнең юклык формасын ясый торган *-ма/ -мә* кушымчаларына тукталып үтү зарур. Бу төр грамматик форма, төп фигыльнең нигезенә ялганып, процессның үтәлмәвен белдерә: *кайт – кайтма, бар – барма, сук – сукма.* Әлеге грамматик форма антонимик категория буларак каралмый, сәбәбе антонимия күренешенең – семантик, ә юклык формасының грамматик категория булуында;

ә) кушма антонимнар. Кушма антонимнар дип икедән дә ким булмаган тулы лексик мәгънәле мөстәкыйль морфемалардан яки берсе тулы мәгънәле, икенчесе тулы мәгънәле булмаган сүздән гыйбарәт берәмлекләрнең үзара капма-каршы мөнәсәбәткә керүе күздә тотыла. Алар үз чиратында өчкә бүленеп каралырга мөмкин:

1) саф кушма антонимнар: *Хәтта кояш чыгышына / каршы аккан бит вакыт – /* ***Көнчыгыштан көнбатышка*** */ ага иде ләбаса!..* (Р. Харис); *Без бит җирдә күбәүләр /* ***Коньякта*** *да* ***төньякта.*** */ Диңгезләр. Таулар аркылы / Дуслык юллары ята.* (Н. Дәүли); ***Икейөзле*** *булуга караганда, /* ***Беркатлы*** *булу яхшырак.* (Р. Батулла);

2) парлы антонимнар: *Бәхет телим ир-егеткә! / ...****Ир-егет*** *бәхетле булса, /* ***Хатын-кыз*** *бәхетле була.* (Р. Харис); *Безнең җир –* ***сыктар-елар*** *җир! / Безнең җир – шүрәле каргар җир... / Җырлады читләрдән кайтучы / Ак йөзле, чал чәчле бер бабай: / Безнең җир –* ***уйнар-көләр*** *җир! / Безнең җир – сандугач сайрар җир!..* (Р. Фәйзуллин) Югарыда әйтелгәнчә, татар телендә антонимнар парлы сүзләр ясауда нигез булып торалар: *Ләкин Олы Кыяның Мәргән белән алыш-биреш итү уе тормышка аша алмады, чөнки вакыйгалар күпкә тизрәк һәм куркынычрак борылыш ясый башладылар: көнбатыштан, Кыялы таулар ягыннан инглизләр турында хәбәр алынды.* (И. Хуҗин); ***Олысы-кечесе*** *рәхәтләнеп уйнады, биеде, җырлады, карга боткасыннан авыз итте.* («Сабантуй»); *Акчаны юк-барга сарыф итәргә ярамый.* («Безнең гәҗит»);

3) тезмә антонимнар: *Нихәл итмәк, шагыйрь дустым, / Улың –* ***кала малае!*** */ Хәер,* ***авыл малае*** *да / Бер чамадыр, мөгаен.* (Л. Лерон); *Үз вакытың җиткәч, Соңга алмый, /* ***Килә белү*** – үзе егетлек./ *... Үз вакытың җиткәч, тыныч кына /* ***Китә белү*** *дә бит егетлек...* (И. Гыйләҗев); *Көзләр җитсә,* ***кыр казлары*** */ Җылы якка кузгалалар. /* ***Йорт казлары*** *карап кала, / Каңгыл-каңгыл сызланалар.* (И. Гыйләҗев); *Син* ***бар булганың,*** *минем* ***юк булганым.*** (Мәкаль)

Шул рәвешчә, антонимнар, семантик, лексик-грамматик, структур, синтаксик яктан чыгып, аерым төрләргә бүленәләр һәм аларның һәрберсе үзенә хас семантикага һәм төзелешкә ия.

## § 39. Антонимия һәм башка тел күренешләре

Антонимия синонимия, полисемия, омонимия кебек башка лексик-семантик категорияләр белән тыгыз мөнәсәбәттә яши. Беренче чиратта аның синонимия белән бәйләнешен ассызыкларга кирәк. Бер лексик берәмлек башкалары белән бер үк вакытта антонимик һәм синонимик мөнәсәбәткә керә ала. Бу күренеш «синонимик рәтләрнең антонимиясе» яки «капма-каршылыкның синонимиясе» терминнары белән дә атап йөртелә.

Антоним парларның үз синонимик рәте булырга мөмкин. Мәсәлән, бер синонимик ояга икенче синонимик рәт антоним була ала:

*башта – соңыннан:* ***Башта*** *үзен зур тоткан,* ***соңыннан*** *хур булган.* (Мәкаль);

*алдан – ахырда, соңыннан:* ***Алдан*** *килгән урын өчен,* ***соңыннан*** *килгән тамак өчен.* (Әйтем);

*әүвәл – аннан:* ***Әүвәл*** *мунча,* ***аннан*** *алыча.* (Мәкаль);

*элек – азактан:* ***Элек*** *җигелеп эшләсәң,* ***соңыннан*** *авыры кала.* (Мәкаль); *Төн үтеп, күңелле / Көн тугач,* ***азактан*** */ Берсе дә булмаган / Шикелле тоела.* (М. Җәлил);

*элгәре – азак: Күкәй салмас тавык көн* ***элгәре*** *кытаклый.* (Мәкаль) – *Тәүдә мәгәрәдә яшәгән ул,* ***азак*** *йортлар салган.* («Безнең гәҗит»)

Ике синонимик рәткә кереп, үзара антоним булган сүзләр арасында радиаль һәм туры бәйләнеш урнашырга мөмкин.

Радиаль бәйләнеш булганда, бер синонимик ояга кергән сүзләрнең һәрберсе икенче рәткә кергән һәр сүз белән антоним була алуы күздә тотыла.




(Введенская, 1969: 107)

*а, б, в* – беренче синонимик рәт оясы, $а_1$, $б_1$, $в_1$ – икенче рәт синонимнар оясы.

*акрын* *тиз: **Акрын** барган **тиз** җиткән.* (Мәкаль)
*салмак* *шәп:* С*үзләре **салмак** аның – койган кеби кургаш белән!* (Г. Тукай) – *Бик **шәп** аккан чишмәнең башы якын була, имеш.* (Мәкаль)

Радиаль бәйләнеш урнашканда, антонимнарны ирекле рәвештә аларның антоним парлары белән алмаштырып була.

*зур* *кечкенә*
*олы* *бәләкәй*

Мәсәлән: ***Зур*** *нәрсәне **кечкенә** белән үлчиләр.* (Мәкаль) – ***Олы*** *нәрсәне **бәләкәй** белән үлчиләр,* дип тә әйтеп була.

Туры бәйләнеш урнашканда, синонимик рәткә кергән сүзләрнең үзләренә генә аерым антонимы була:

*әдәпле – әдәпсез: **Әдәпле** кеше – солтан, **әдәпсезнең** бите олтан.* (Мәкаль);

*ягымлы – ягымсыз: **Ягымлы** сүзгә бераү дә ачуланмый.* (Мәкаль) – С*оң кычкырган әтәчнең тавышы **ягымсыз.*** (Мәкаль)

Бу төр бәйләнештәге антонимнарны парлары белән алыштырып булмый:

*зиннәтле – фәкыйрь: Бай түрәләр күк, ай эчендә **зиннәтле** коттедж өйдереп куяр идем.* (Ф. Дәүләтбаев) – *Аларның торыр җирләре бик тә **фәкыйрь** икән.* («Сабантуй»);

*кыйммәтле – арзанлы: Сатмас егет илен алтын-көмешләргә, / Әгәр югалтмаса вөҗданын; / Алтынны ул чүпкә санар, / Иң **кыйммәтле** күрер ватанын.* (А. Алиш) – *Телевизордан татарчага тәрҗемә ителгән Мексика, Бразилия сериалларын карыйбыз бит әле, Мәскәү каналлары төшергән бетмәс-төкәнмәс **арзанлы** сериалларны да.* («Шәһри Казан»);

*бай – фәкыйрь: Шулай да туйдыралар дөньяда **фәкыйрь** илә **байны**.* (Н. Думави);

*күркәм – мескен: Кыз байлыгы – **күркәм** холык.* (Мәкаль) – *Гакыл башлык булган көннән алып, / Көн-төн елый **мескен** йөрәгем, / Һәр көн ызгыш, һәр көн йөрәгемә / Гакыл-башлык бирә кирәген...* (Һ. Такташ)

Татар телендә туры бәйләнешкә кергән синонимик антонимнар ешрак очрый.

Кайбер очракта синонимик рәткә кергән барлык сүзләргә бер уртак антоним туры килергә мөмкин:

кайгы
хәсрәт
гамь
хафа → шатлык
ваем
сагыш
көенеч
моң

тәмле
татлы → ачы
баллы
төче

Күп очракта теге яисә бу синонимның кулланылышы контекстка бәйле була: ***Күркәм*** *кием* – ***тән зиннәте, күркәм*** *холык* – ***җан зиннәтем.*** (Мәкаль)

Берничә антонимның синонимик парлары барлыкка килгән очракта, аларның берсе доминанта санала. Доминанталарга нейтраль мәгънәле, капма-каршылыкны турыдан-туры чагылдырган сүзләр керә. Мәсәлән:

*саулык – авыру: Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем; / **Саулыгың** – минем саулык, **авыруың** – минем авыруым.* (Г. Тукай);

*сәламәтлек – сырхаулык: **Сәламәтлек** – үзе бер бәхет.* (Мәкаль) – *Бу **сырхаулык** белән аңлатылса да, моңа бәйле имеш-мимеш тарала башлады инде.* («Безнең гәҗит»);

*исәнлек – хасталык: Иң мөһиме – **исәнлек** булсын* («Шәһри Казан») – *Әгәр **хасталык**, яки картлык сәбәпле тота алмаса, мескенне* ашатсын. (Р. Аляутдинов);

*тазалык – чирлелек: Байлыкның башы – **тазалык**.* (Мәкаль) – *Кешелеккә тоташ **чирлелек**, гомуми дистрофия яный.* («Ватаным Татарстан»);

*сихәтлек – сихәтсезлек: Намаз укучы кешедән нур бөркелә, ул аңа үзенә **сихәтлек**, җанына дәва бирә.* (Р. Аляутдинов) – ***Сихәтсезлегем*** *аркасында менә шушында торып калдым бугай.* (Ф. Хөсни);

*сыйххәт – гыйлләт* (иск. кит.): *Җөмлә фикрем кичә көндез сезгә гаид, милләтем, / Сыйххәтеңдер **сыйххәтем** һәм гыйлләтеңдер **гыйлләтем.*** (Г. Тукай)

Әлеге синонимик рәтләрдә *саулык – авыру* антонимик пары доминанта булып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар телендә еш кына ике яисә аннан күбрәк семантик яктан капма-каршы пар үзләренең синонимнарына ия, шул рәвешле алар синонимик (вертикаль) һәм антонимик (горизонталь) рәтләр тәшкил итәләр.

Антонимия һәм полисемия арасындагы мөнәсәбәт лексик берәмлекләр системасы бәйләнеше, үзара тәэсире һәм башка үзенчәлекләрдә чагыла. Шуларга тукталып үтик. Бер сүз, төрле мәгънәләрдә килеп, аерым антонимик парлар тәшкил итә ала:

*Салу* – 1) 'берәр нәрсәнең эченә урнаштыру'[1]: *Хәят карточкаларны китап эченә* ***салды.*** *(*Ф. Әмирхан) – Антонимы *алу: Ул өстәл тартмасыннан китабын* ***алды.*** 2) 'төяү, җәеп-таратып урнаштыру': *Гази чанага салам* ***салды.*** (М. Хәсәнов) – *Пароход тикмәгә генә туктамагандыр,* ***бушатасы*** *я төйисе нәрсәсе бардыр.* (И. Гази) 3) 'кабызып җибәрү, төртү': *Утын, су ташып, мунча мичендә ут* ***салдык.*** (Э. Касыймов) – Антонимы *сүндерү: Е. Лылов итәгенә капкан утны башлангыч чорда ук* ***сүндерү*** *омтылышы да ясаган иде.* («Безнең гәҗит») 4) савытка бүлеп алга кую, бирү: *Әнисе аш* ***салып*** *бирде.* (М. Гали) – *Су* ***түгү*** *ифрат күп көч таләп итә иде.* (И. Хуҗин) 5) 'корылма төзү, кору' – антонимнары *җимерү, сүтү*: *Ир өй* ***салган*** *– хатын* ***җимергән,*** *хатын өй салган – шайтан да җимерә алмаган*. (Мәкаль)

Күп мәгънәле сүзнең төрле антонимик мөнәсәбәтләрдә була алуы аның берьюлы төрле лексик-семантик парадигма составына керүен дәлилли. Кайбер очракта сүз, мәгънәсен үзгәртеп, антонимын алмаштырырга яисә башка антонимик мөнәсәбәткә кермәскә дә мөмкин. Күп мәгънәле сүзләрнең беренчел, төп мәгънәләренең антонимнары була ала, аерым сүзләрнең икенчел лексик-семантик вариантлары антоним сүзләргә ия, нигездә исә сүзнең һәр мәгънәсенә аерым антоним сүз туры килә.

---

[1] Текстта алга таба сүзләрнең мәгънәләре «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (3 томда / Редкол.: Л.Т.Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С.Сабиров һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1981) һәм «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (Редкол. Ф.А. Ганиев, К.С. Миңнебаев, Ф.М. Газизова һ.б. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.) буенча бирелә.

Күп мәгънәле сүзнең барлык мәгънәләре яисә аерым лексик-семантик вариантлары гына башка лексик берәмлекләр белән антонимик бәйләнешкә керергә мөмкин.

Аерым очракларда үзләренең туры номинатив мәгънәләрендә антонимик мөнәсәбәттә тормаган сүзләр, күчерелмә мәгънәдә килеп, капма-каршылык белдерүләре күзәтелә. Мәсәлән, *Сарык булсаң, бүре дә ашый.* (Мәкаль) *Сарык* сүзе юаш, акылсыз кешегә, *бүре* сүзе усал кешегә карата кулланыла. Бу сүзләр әлеге контекстта гына антонимик пар тәшкил итә.

Шулай ук полисемантик сүзнең лексик-самантик варианты берничә антонимга ия була ала. Бу аеруча сыйфатларга һәм фигыльләргә хас: *сүтү – тегү; сүтү – үрү; сүтү – чорнау; сүтү – салу, яңадан ясау.*

Антонимия күренеше омонимия белән дә бәйләнештә яши. Омонимнар, үзләренең лексик мәгънәләреннән чыгып, башка сүзләр белән антонимик парлар төзи алалар. Аерым мисалларга тукталып үтик:

I. *ач – тук: Теләнченең капчыгы* ***тук,*** *күзе* ***ач.*** (Мәкаль)

II. *ач – яп: Ишек* ***ачтым,*** */ Кар, кер, / Сөйләшеп утырыйк бер. / – Я сөйләрсең моң-зар, / Кеше түгел бит мин, кар – / Давылга әйләнермен... / Ишегең* ***яп,*** */ Кермим.* (Р. Харис)

I. *кала – сала:* ***Кала*** *хәлен беләсең килсә,* ***салага*** *бар*. (Мәкаль)

II. *кала – бара: Ул өйдә* ***кала.*** *– Ул өйдән* ***бара.***

I. *салу – җимерелү:* ***Сала*** *белеп салганнар шул, / Селкенергә уйламый да; / Ничә гасыр тора инде / Мисырдагы пирамида... / Без корганы...* ***җимерелде,*** */ Җибәрелгән гаепләрдән.* (И. Гыйләҗев)

II. *салу – кию: Җиргә яттык та без, җирдән тордык, / Кәләпүшне* ***салып,*** *шлем* ***кидек.*** (Г. Афзал)

## § 40. Татар телендә энантиосемия күренеше

Татар телендә бер үк сүз сөйләмдә капма-каршы мәгънәдә кулланылырга мөмкин. Бу күренеш энантиосемия дип атала. Э н а н т и о с е м и я (грекчадан *enantios* – капма-каршы, *sema* – билге) – бер үк лексик берәмлекләрдә капма-каршы мәгънәләрнең барлыкка килүе, мәгънәләрнең полярлашуы дигән сүз. Тел белемендә бу күренешне «сүз эчендәге антонимия» дип карау да очрый[1]. Энан-

[1] Л.А. Новиков әлеге күренешне «внутрисловная антонимия» буларак тикшерә (Новиков 1973: 182).

тиосемия полисемия һәм антонимиянең синтезын тәшкил итә. Мәсәлән, *белдекле* сүзе тирән белемле, күпне күргән кешегә карата кулланыла: *Аларның берсе генә китсә дә, эш тукталачак, чөнки иң **белдекле,** иң тырышлар шулар.* («Безнең гәҗит») Шул ук вакытта әлеге сүз, күчерелмә мәгънәдә килеп, тирән белемле булырга тырышкан, акыл сатучы надан кешегә карата да әйтелә: *Карап кына җибәр инде үзен ,– диде баягы **«белдекле»** хатын.* (Г. Гыйльманов) Әлеге ике лексик-семантик вариант бер-берсенә карата капма-каршы мәгънәдә кабул ителә.

*Тану* сүзен алып карасак, аның беренче мәгънәсе ‘элегрәк күргәнеңне яңадан очраткач, аның шул ук үзе икәнен аңлау, белү’: *кешене тану;* сүзнең тагын бер мәгънәсе бар, ул ‘килешү, кабул итү’: *гаепне тану.*

Энантиосемия антонимия күренешенә якын тора, әмма антонимия булганда, капма-каршылык сүзләр арасында урнаша, энантиосемия исә бер үк сүзнең мәгънәләрен капма-каршы куя. Мәсәлән, *зәһәр* – 1) ‘усал, явыз, агулы’: *Туры сүз башта **зәһәр** булса да, соңы шикәр; ялган сүз башта шикәр булса да, соңы зәһәр.* (Мәкаль); 2) бик шәп, бик яхшы: *Күрше квартал командасы, аерата бер-ике малай бик җитез, бик **зәһәр** уйный иде.* (Э. Касыймов)

Кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып, энантиосемияне ике төргә аералар.

1. Номинатив энантиосемия, ягъни бер үк процессның капма-каршы йомгагы, нәтиҗәсе. Сүз ике төрле объектка карата кулланыла, шул рәвешле капма-каршы мәгънәләре килеп чыга. Бу төр энантиосемия фигыльләрдә очрый, анда нинди дә булса эмоциональлек, бәяләү төсмерләре чагылмый. Сүзнең мәгънәләре арасындагы капма-каршылык контекстта гына билгеләнә ала, мәсәлән, *таралу* – ‘кешедән-кешегә күчеп, бик күпләргә мәгълүм булу’: *Бу җырлар радио дулкыннары аша һәм озын тимерчыбыклар буйлап ерак илләргә **таралды.*** (К. Нәҗми); *таралу* – ‘ниндидер тискәре күренеш, авыруның башкаларга күчүе, йогуы’: *Наркомания **таралу** – аяныч күренеш.*

*Чыгу* – ‘кайдан да булса китү, ул урынны калдыру’: *Баручыларның атлары, корсактан бата-бата, юлдан **чыктылар*** (И. Гази); *чыгу* – ‘кая да булса килү’: *Озын буйлы украинец, итек үкчәләрен бер-берсенә бәреп, строй алдына **чыкты**.* (К. Нәҗми)

*Алу* – ‘кемне дә булса эшкә урнаштыру, кабул итү’: *Аны «Яшь ленинчы»ның ул вакыттагы редакторы Хәким Бәдри эшкә* ***ала.*** («Сабантуй»); *алу* – ‘эшеннән, эш урыныннан чыгару, азат итү’: *Ә күп очракта бу кешене эштән генә* ***алалар****.* («Безнең гәҗит»)

*Килү* – ‘берәр максат белән кая булса да бару, керү’: *Ул эш эзләп Казанга* ***килде;*** *килү* – *‘*берәр максат буенча кайдан булса да килү’: *Разия Әлмәткә Казаннан* ***килде****.*

Күп очракта әлеге төр энантиосемия урнашуга табу һәм эвфемистик сүзләрнең йогынтысы зур, мәсәлән, *баю* – ‘күк җисемнәренең офык артына китүе, горизонтта күздән югалуы, батуы’: *Бүген, кояш* ***баю*** *белән, Рамазан ае керә.* («Дин вә Мәгыйшәт») Татар телендә *үлү* сүзенә табу булганлыктан, *баю* сүзе әлеге сүзнең эвфемизмы буларак да кулланыла: *Минем тормышым* ***баеп*** *бара.* (Г. Гали)

2. Эмоциональ-бәяләүле энантиосемия. Әлеге төр мәгънәләр капма-каршылыгына эмоциональлек, бәяләү төсмере хас. Мәсәлән, бер контекстта *герой* сүзенең мәгънәсе уңай бәяләнсә, аерым контекстта киресе була ала: *герой* ‘батырлык күрсәткән’: *Аларга каршы сугышкан Г. Жуков бу сугышта да* ***герой*** *булды* («Безнең гәҗит»); *герой* ‘сугыш чукмары, әтәчләнергә яратучы кеше, куркак’: *Качып китәрлек булгач, син бигрәк* ***герой*** *икәнсең, – диде Сания.* (М. Әмир)

Күп очракта мондый сүзләр текст эчендә куш җәяләр эченә алынган була, сөйләмдә интонация белән аерып бирелә. Әлеге төр энантиосемиянең чикләрен билгеләп булмый.

Сөйләмдә сүз мәгънәсендә коннотатив семалар алгы планга чыгарга мөмкин: *егет* – ‘яшүсмерлектән өлгергәнлек чорына күчкән, буйга җиткән яшь ир кеше’: *Малай чак белән* ***егет*** *чиген сизми дә калдык* (А. Гыйләҗев); *егет* – ‘яшәү көче ташып торган, җитез, дәртле карт’: *Бабай, син* ***«егет»*** *икәнсең әле.* («Шәһри Казан»)

*Чибәр* – матур, гүзәл кеше турында: *Хатын-кыз ямьсез булалмый, / Хатын-кыз* ***чибәр*** *була! / Шуны күрмәгән ир-ат ул, / Әлбәттә, җүләр була.* (Р. Миңнуллин); *чибәр* – үтә дә ямьсез, матур булмаган кешегә карата күчерелмә мәгънәдә әйтелә: *Чибәрлеккә бик* ***чибәр****, күрсәң гайрәтең чигәр*. (Мәкаль)

Энантиосемия күренеше исемнәр һәм сыйфатлар белән белдерелгән сүзләрдә еш очрый: *батыр* – ‘кыюлык, көчлелек сыйфатларына ия булган шәхес’: *Кичүсез елга юк,* ***батыр*** *җиңмәс дошман юк.* (Мәкаль); сүз шулай ук сугыш чукмары, куркак кешегә карата

күчерелмә мәгънәдә кулланыла: *Җитәр сиңа,* ***батыр****, гел кыйнашып йөрергә.*

Шуны да искәртеп китәргә кирәк: энантиосемия бер сүздәге мәгънәләр арасында яисә бер мәгънәдә урнашырга мөмкин, мәсәлән, *ис* ‘җисемнәрнең, әйберләрнең борын белән сизелә торган үзлеге’: *Аннан килгән тәмле* ***ис*** *Арслан бүлмәсенә дә бәреп керде.* («Сабантуй»); *Чөнки көзән халкының ачуын китерергә ярамаганлыгын, юкса, аннан коточкыч начар* ***ис*** *таралуын яхшы белә иде* («Сабантуй») Бу очракта, *ис* сүзенең бер мәгънәсендә ике төрле капма-каршылык барлыкка килә.

Берничә мисал карап үтик:

*бору*: 1. ‘нинди дә булса җайланманың тавыш көйләү җайланмасын хәрәкәткә китереп тавышны киметү’; бору: киресе ‘арттыру, көчәйтү’. Чагыштыр: *Радионың тавышын* ***бор****, бигрәк кычкыра. Радионың тавышын* ***бор****, берни ишетелми.*

*дару*: ‘чирне яки авыртуны бетерү яисә киметү өчен кулланыла торган, сыекча яки порошок хәлендәге матдә’: *Юкәнең чәчәге – бал, кабыгы – юкә, черегe –* ***дару****, агачы – сөян* (Мәкаль); *дару:* ‘бөҗәкләрне бетерү өчен булган агу’: *Алар өйләренә таракан* ***даруы*** *сибеп чыктылар. Дару* сүзенең әлеге ике лексик-семантик варианты арасында капма-каршылык урнашкан.

*бәясез:* ‘үтә арзан, бәясе түбән’: *– Күпме тора? – дип сорый Әбүзәр абзый аучыдан. – Миллион! – ди теге. Ул елларда акчаның* ***бәясез*** *чагы булса да, Әбүзәр абзый уйлый-уйлый да кыйбатсынып [киекне] алмый китә.* (Г. Әпсәләмов); *бәясез:*‘бик кадерле, бәя биреп бетергегез’: *Ул җыйган, туплаган халкыбыз җәүһәрләре, фольклоры – милләтебезнең* ***бәясез*** *байлыгы.* («Безнең гәҗит»)

Күп очракта энантиосемия ироник мәгънәләр ясауда катнаша:

*Белгеч:* ‘нинди дә булса өлкәдә, тармакта эшләү өчен аерым һөнәргә хәзерлек, белеме, тәҗрибәсе булган кеше’: *Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда йөрәк авырулары буенча иң зур* ***белгечләрдән*** *санала.* (Г. Әпсәләмов)

Икенче мәгънәсе надан, тәҗрибәсез, бары акыл сатучы кешегә карата гына кулланыла: *Ә укудан тизрәк котылырга теләгән* ***«белгеч»*** *кибеттән ары башка җиргә кирәкми шул.* («Безнең гәҗит») Бу мисаллардагы *белгеч* сүзенең мәгънәсе төрле контекстта гына аерыла, ситуациягә карап ачыклана, ачы итеп көлү максатыннан файдаланыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар телендә аерым сүзләр, сөйләмдә капма-каршы мәгънәдә дә кулланылып, энантиосемия күренешен барлыкка китерәләр.

### § 41. Антонимнарның функциональ-стилистик вазифасы

Антонимнар, халыкның иҗтимагый-мәдәни тормышында хасил булып, җанлы сөйләм, матур әдәбият телендә гасырлар буе яшәп киләләр. Алар аеруча халык авазы иҗатында һәм поэзиядә киң кулланылалар. Мәсәлән, *Кенәри үзе* ***читлектә,*** *күңеле* ***иректә.*** (Әйтем); ***Иң элек*** *уйла,* ***аннан соң*** *эшлә.* (Мәкаль); ***Галим*** *белгәнен әйтер,* ***ахмак*** *җиңгәнен әйтер.* (Мәкаль); ***Утта*** *янмый,* ***суда*** *батмый.* (Табышмак); ***Аттан биек, эттән тәбәнәк.*** (Табышмак); *Шахтёр, лампаң тотып, бусагада / Син ничәмә тапкыр күрендең; /* ***Җир астында*** *йөреп исән кайттың, /* ***Җир өстендә*** *йөреп күмелдең.* (Ш. Галиев); *Ага көннәр, канда* ***Сөю*** *булып, /* ***Нәфрәт*** *булып ага кемгәдер. /* ***Сөю*** *белән* ***Нәфрәт*** *бик еш кына / Каршы чыгалар да бергә-бер...* (Н. Әхмәдиев); ***Ите*** *сиңа,* ***сөяге*** *миңа.* (Әйтем)

Антонимнар афоризмнарда, аеруча автор афоризмнарында бик еш очрыйлар: ***Яшьлегем*** *кызык,* ***картлыгым*** *– мыҗык. Мин үзем* ***юан*** *булсам да, күңелем* ***нечкә.*** (Л. Лерон); ***Ир кеше*** *тәрәзә уя,* ***хатын-кыз*** *пәрдә кора. Ялкау* ***байдан ярлы*** *туар. Ак* ***йортта таң атканда – Кремльдә караңгы төшә.*** (К. Кәримов); *Сезгә мин кирәк чакта, мин –* ***бар,*** *миңа кирәк чакта, сез –* ***юк.*** (Ә. Гаффар); *Карак ул – уңнан да, сулдан да карак дип укыла. Угрылар тәгәрмәч кебек:* ***эресе – акрын, вагы тиз*** *әйләнә.* (Х. Бәдигый)

Антоним сүзләр, бер-берсенә каршы булган күренеш, хәл, вакыйгалар, процессларны чагылдыручы, мөһим стилистик чара буларак, төрле стилистик фигуралар, троплар төзүдә актив катнашалар.

Антоним сүзләр кулланып сурәт ясау а н т и т е з а (грек. *antithesis* – капма-каршылык) дип атала. Антитеза нигезендә капма-каршы төшенчәләрне бер-берсенә параллель кую ята. Антитезалар фикерне логик яктан көчәйтүдә, күренешләрне ачык итеп күз алдына китерүдә зур урын тоталар. Алар, әсәрдә контраст фонда кулланылып, тәэсирне көчәйтәләр, каршылыкларны тояргa хезмәт итәләр. Мәсәлән, *Без* ***сугышта*** *юлбарыстан көчлебез, / Без* ***тынычта*** *аттан артык эшлибез.* (Г. Тукай); *Җырла әйдә! – /* ***Дошман*** *кара көяр, / чит илдәге* ***дуслар*** */ Елмаер.* (Х. Туфан); ***Суга*** *төште – сүнмәде /*

***Утка*** *керде – көймәде.* (Һ. Такташ); ***Яткач*** *урын алама,* ***торгач*** *– кием алама.* (Мәкаль); *Шаша, таша елгалар – / Тотып торалар ярлар: / Берсе –* ***текә****, берсе –* ***сөзәк****... / Берсе акыл, берсе – йөрәк.* (Н. Сафина); ***Тугры*** *баласын пәйгамбәр / Итәргә әзер тора. / Ә инде* ***угры*** *баладан / Үзеңә нәрсә сора?..* (Р. Әхмәтҗанов)

Антитезаның йогынтысы зур булу аерым контекстка бәйле, әлеге контекст х и а з м (грек. *chiasmós* – грек алфавиты хәрефе с (хи) урнашу рәвеше) стилистик фигурасы белән аталып йөртелә: *Кыз бала яка камый, /* ***Камый*** *да тагын* ***сүтә.*** (Ә. Баян)

Хиазм урнашканда, җөмләнең ике өлеше дә эчтәлек, структурасы һәм интонациясе буенча капма-каршы була: ***Якты*** *барга беленә* ***караңгылык.*** (Мәкаль)

Шулай ук антонимик кабатлаулар да аерым стилистик чара булып тора: ***Улы*** *түгел, улы түгел бу! / Бу* ***егет*** *бүтән, бүтән, /* ***Арслан*** *кебек – өлкән бу, /* ***Генерал*** *кебек күркәм.* (Х. Туфан)

Исемнәре антонимнарга нигезләнгән әдәби әсәрләр дә бар: *«Яшәү белән үлем арасында»* (Н. Дәүли), *«Ут һәм су»* (Ә. Баянов), *«Бай белән фәкыйрь»* (Б. Шоу), *«Сугыш һәм солых»* (Л.Н. Толстой), *«Аталар һәм балалар»* (И.С. Тургенев), *«Мәкер һәм мәхәббәт»* (Ф. Шиллер), *«Җинаять һәм җәза»* (Ф.И. Достоевский), *«Исәннәр һәм үлеләр», «Көннәр һәм төннәр»* (К. Симонов) һ.б.

Антоним сүзләр сөйләмдә кайчак үзара бәйләнешкә керәләр һәм бер сүзтезмә булып йөри башлыйлар. Мондый күренеш о к с ю м о р о н (грек. *oxymoron* – тапкыр-ахмак сүз, үткер мәгънәсезлек) дип атала. Оксюмороннар капма-каршылыкның билгеле бер шартларда яраша алуы нигезендә ясала. Шул рәвешчә, капма-каршы мәгънәдәге ике төшенчә, үзара ярашып, аерым шартларда яңа берәмлек хасил итә, яңа өстәмә сыйфат ала: *сакаллы сабый, күзле сукыр, чын ялган, надан галим, бай хәерче, камыр батыр, коры диңгез.* Оксюмороннарга эмоциональ-экспрессивлык хас, аларда ике капма-каршы төшенчә бергә кулланылганнан соң, компонентларның төп мәгънәләре икенче планга чыга һәм яңа бәяләү төсмере барлыкка килә: *Без – мәңгелек, / Чиклелек –* ***җанлы үлек.*** (Һ. Такташ); *Ямьсез, авыр, көзге җилле, яңгырлы,* ***елак тынлык*** *иде бу.* (А. Расих); *Их, син, сәях дустым,* ***нәни гигант!*** (Зөлфәт); *Гөрли базар. Берәү генә тыныч. / Ымлый гына бара, сөйләми. / Дөньядагы* ***телле телсезләргә*** */ Тылмач була ала бу әби.* (Р. Әхмәтҗанов); ***Ягымлы ялган*** *булса да килешә хатын-кызга.* (М. Галиев);

*Кагылма каенга – / кагылма /* ***кадерле кайгыма.*** (Р. Гатауллин); *Мәңгелектән* ***татлы ялган*** *даулап, / Меңәрләгән мизгел – гомер уза.* (Ф. Мөслимова); *Һәрбер тантаналы фаҗига –* ***мескен бәет.*** (Ә. Гаффар)

Капма-каршылыкка корылган катахреза күренешен дә атап үтәргә кирәк. К а т а х р е з а (грек. *katachresis* – кирәгеннән артык мавыгу) – каршылыклы төшенчәләрне бергә кушу, сүзнең лексик мәгънәсенә игътибар итмичә куллану, сүзнең башка сүзләр белән сәер мөнәсәбәтләргә керүе. Мәсәлән: *кызыл кара*, *зәңгәр кара*, *кара аккош*, *утсыз яну*, *сусыз юу; төтенсез ут*, *ачкычсыз йозак*, *дәвасыз сырхау*, *тәмле шәраб*, *йөксез авырлык*, *йокысыз сәфәр.* ***Утсыз төтен*** *булмый.* (Әйтем); ***Пычаксыз суйдың, җилсез киптердең.*** (Мәкаль); *Күңелләрдә* ***утсыз ялкын*** *дөрли, / Шатлык оча, җиргә сыймыйча.* (Н. Әхмәдиев); *Тик* ***салкын җылы*** *бу – / Әбиләр чуагы. / Язмышым соңарып, / Кызганып елмайды.* (Н. Измайлова)

Ирония белдерелгән контекстта антонимик парга кергән сүзнең берсе икенчесен алыштырып килә ала. Бу стилистик чара а н т и ф р а з и з (грек. *antiphrasis* – капма-каршы мәгънәдә куллану) дип атала. Гадәттә, сөйләм телендә еш кына акылы чамалы булган кешегә *«ай-һай башлы икәнсең син»,* усал, ачулы кешегә карата *«син шундый яхшы»* дип әйтәләр.

Гомумән алганда, антонимнар, стилистик чара буларак, сөйләмнең төгәллегенә, сәнгатьлелегенә, нәфислегенә ирешүдә әһәмиятле, алар, эчтәлекне дөрес чагылдыру максатында, телдән файдалану мөмкинлекләрен арттыралар, предмет-күренешләрнең эчке каршылыкларын, табигый халәтен җыйнак итеп сурәтләргә ярдәм итәләр. Төрле стилистик төсмерләргә ия булып, телне лексик-семантик яктан баетуда зур урын алып торалар.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ФРАЗЕОЛОГИЯСЕ

### § 42.Тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү тарихы

Телнең лексикасы һәм фразеологик катламы халыкның тарихын, географиясен, иҗтимагый-сәяси төзелешен, яшәү шартларын, көнкүрешен барлык билгеләре, үзенчәлекле яклары белән чагылдыру сәләтенә ия. Тел үзе тәэмин иткән халыкның мәдәни-тарихи хәзинәләрен саклый, шулай ук хәзерге заман белән бәйле фактларны да ачып сала. Шул сәбәпле фәндә телнең мәдәни трансляторы ролен үти торган фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү ихтыяҗы һәрвакыт булган һәм хәзер дә кимеми.

Фразеология фәненең үсешенә француз лингвисты Ш. Балли (1865–1947) идеяләре йогынты ясый (Балли, 1955). Фразеология, мөстәкыйль тел тармагы буларак, ватан тел белемендә XX гасырның 40 нчы елларында формалашып җитә. Рус фразеологиясе турында беренче теоретик мәгълүматларны А.А. Потебня (1894, 1976, 1999), И.И. Срезневский (1873), Ф.Ф. Фортунатов (1898) хезмәтләрендә табабыз. 50 нче елларда В.В. Виноградов хезмәтләрендә фразеологиягә кагылышлы төп төшенчәләр ачыклана, өйрәнү бурычлары билгеләнә, юнәлешләр күрсәтелә (1947, 1954, 1959, 1972). Алга таба фразеологизмнар, телнең структур берәмлекләре буларак, А.И. Смирницкий (1952, 1954, 1956), О.С. Ахманова (1957) хезмәтләрендә яктыртыла, шулай ук фразеологизмнарны төркемләү, аларның составы, ясалыш-структур үзенчәлекләре, семантикасы, лексикографик тасвирлау, лингвокультурологик аспектта тикшерү, башка телләр белән чагыштырып өйрәнү белән бәйле мәсьәләләр В.Л. Архангельский (1960, 1964, 1968, 1969, 1978), Н.Н. Амосова (1951), В.П. Жуков (1978, 1986), А.В. Кунин (1970), Н.М. Шанский (1957, 1969), В.М. Мокиенко (1986, 1989, 1990), В.Н. Телия (1986, 1996) һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба.

Төрки телләрдә фразеологизмнарны өйрәнү дөнья һәм рус филологларының фәнни эзләнүләре белән параллель алып барыла. Мәсәлән, үзбәк фразеологиясе нигезләре Ш.У. Рахматуллаев (1966), М.С. Рузыкулова (1966) тарафыннан салынган; фразеологик берәмлекләрне аерым язучыларның стиль чарасы буларак өйрәнгән азәрбайҗан һәм төрекмән галимнәренең хезмәтләре игътибарга лаек (Мамедов, 1964; Кязимов, 1966), казах телчеләре фразеологик берәмлекләрнең грамматик структурасын һәм семантик мәгънәсен тикшерәләр (Ахмеджанова, 1988) һәм стилистик аспектта характерлыйлар (Джакибеков, 1956; Кожахметова, 1967); башкорт фразеологизмнарын өйрәнүгә багышланган Ж.Г. Киекбаеваның (1966) монографияләре кызыклы.

Татар тел белемендә дә бу юнәлештә тикшеренүләр шактый. Беренче булып «фразеология» төшенчәсенә аңлатманы К. Насыйри «Әнмүзәҗ»ендә (1895) бирә. Бу төр әйтелмәләрне ул үзләренең төп мәгънәләреннән күчерелгән, яшерен (читләтелгән) мәгънәле сүзләр (кәлимәләр) дип билгели.

Татар халык авыз иҗатын җыю буенча зур хезмәт күрсәткән Х. Бәдигый «Борынгылар әйткән сүзләр» (1912) дигән җыентыгында шактый материал теркәгән. Бу җыентык 1919 һәм 1952 елларда кабат басыла. Г.Х. Алпаров тарафыннан төзелгән «Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе. Халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр җыентыгы» (1926) китабының «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма» бүлегендә читләтеп әйтелгән сүзләр (кинаяләр), тапкыр җаваплар, каргышлар һәм алкышлар кебек баш астында телебездә киң таралган фразеологик әйтелмәләр дә байтак бирелгән (ТАССР халык мәгариф комиссариаты, 1926).

Димәк, фразеологияне фәндә тел гыйлеменең аерым бер тармагы итеп тану XX гасыр башына карый. Шушы вакыттан башлап фразеологик берәмлекләрне фәндә тел гыйлеменең һәм стилистиканың мөстәкыйль һәм мөһим бер тармагы итеп карау һәм тану башлана. 50 нче елларда исә бу эзләнүләр тагын да киңрәк төс алып тирәнәйтелә һәм тел гыйлеменең яңа бер тармагына әверелә. Фразеологик берәмлекләрнең төрләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәнү, системага салу үзәккә алына. Ш.А. Рамазанов (1954), Г.Х. Әхәтов (1954, 1975), Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Г. Мәхмүтова (1957), Г.Х. Ахунҗанов (1972), Р.А. Йосыпов (1980, 2000, 2007), С.Ш. По-

варисов (1982), В.Х. Хаков (1999), Ф.С. Сафиуллина (1979, 1999, 2001), Х.Ш. Мәхмүтов (1999, 2008) кебек галимнәрнең хезмәтләрендә татар фразеологиясе төрле яклап тикшерелә: «фразеологизм» һәм «фразеология» төшенчәләренә билгеләмә бирелә, фразеологизмнарның сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аермасы аңлатыла; бу төр әйтелмәләрнең барлыкка килү, туплау, аларны төркемләү мәсьәләсе кузгатыла; фразеологик әйтелмәләрнең стилистик кулланылышы яктыртыла, аларның семантик, грамматик һәм лексикографик үзенчәлекләре тасвирлана, башка телләргә тәрҗемә итү проблемалары турында сөйләнелә, этимологияләре ачыклана һ.б.

Г.Х. Әхәтов үзенең «Татар теленең фразеологик әйтелмәләре» исемле кандидатлык диссертациясендә фразеологиянең предмет буларак фәндә тоткан урынын билгели, беренче тапкыр мәкальәйтемнәрдән, табышмаклардан аерып, бу төр әйтелмәләрне аерым категория итеп карый. Үзләренең структур-семантик билгеләре буенча фразеологик әйтелмәләрне идиомаларга, фразеологик тезмәләргә (штамплар һәм берәмлекләргә) һәм фразеологик термин-атамаларга бүлә (Әхәтов, 1954).

Фразеология фәне теориясенә зур өлеш керткән хезмәтләрнең берсе – Г.Х. Ахунҗановның «Татар теле идиомалары» китабы (Ахунҗанов, 1972). Монда идиомага билгеләмә бирү һәм бу тармактагы терминология мәсьәләләренә автор яңача якын килә, аерым алганда, «фразеология» сүзенең атама буларак уңышсыз булуын, ә «идиоматика» терминының уңышлырак икәнен дәлилли. Биредә галим идиоманы идиома итүче үзенчәлекләрне, ягъни күчерелмә мәгънә дип аталган күренешне игътибар белән өйрәнә, бу мәсьәләгә төрле тел белгечләренең фикерләрен китерә.

Әлеге хезмәтнең кыйммәте – идиомаларның төрле аспектлардан чыгып төркемләнгән булуында да. Мәсәлән, автор, әйтелмә составына кергән сүзләрнең санына карап, ике сүзле, өч һәм аннан да артыграк компонентлы идиомалар булуын әйтә; идиома компонентларының беренчел (ягъни лексик) мәгънәләре ягыннан караганда, мөстәкыйль мәгънәле сүзләрдән генә төзелгән, берничә мөстәкыйль һәм бер яки берничә ярдәмлек сүздән оешкан, бер мөстәкыйль һәм бер яки берничә ярдәмлек сүздән торган, ярдәмлек сүзләрдән генә торган әйтелмәләр була, ди. Мәгънә төзелеше ягыннан караганда тулаем күчмә һәм аналитик мәгънәле ике типка аеру мөмкинлеген искәртә. Компонентларның

мәгънә һәм форма ягыннан берегүенә, әйтелмәнең эчке формасы онытылу-югалу дәрәҗәсенә карап, идиомаларны бердәмлек һәм берекмә дигән төрләргә бүлә (Ахунҗанов, 1972: 14–15).

Идиомаларны берничә принципны гомумиләштереп төркемләгәндә, галим 13 төр идиома барлыгын ассызыклый. Алар составына әйтем (*ай күрде, кояш алды; әйттем исә кайттым* һ.б.), афористик идиома буларак мәкаль (*үзе юкның күзе юк; кешенеке кешнәктә*), әйтем белән мәкаль арасында тора торган арадаш төрләр, «фигыль-фигыль» калыбындагы идиомалар (*күтәреп алу, ярылып яту, коелып төшү*), аналитик идиома (*ак он; ак өй; ак икмәк)*, «мөстәкыйль + ярдәмлек сүз» калыбындагы идиома (*күңел өчен; әйтмә дә; баш чаклы*), ярдәмлек сүзләрдән тора торган идиома (*иллә дә мәгәр, әмма ләкин*), лексик-грамматик идиома (*чана шуу*), кинетик идиома (*кул кысу, аяк чалу*), термин идиомалар (*үги ана яфрагы, сару кайнату*), канатлы әйтелмә (*Халык – зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул* (Г. Тукай), образсыз идиомаларның (*куласты, аяк асты*) керүен раслый. Аңлашылганча, «идиома» төшенчәсе «фразеология» төшенчәсенә караганда киңрәк планда алына.

Әлеге хезмәттә Г.Х. Ахунҗанов идиомаларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен дә ачыкларга тырыша.

Күргәнебезчә, Г.Х. Ахунҗанов татар идиоматикасы фәненең, шул исәптән фразеология фәненең дә, үсешенә бик зур өлеш керткән, теория нигезен салган.

Соңгы елларда (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башларында) чыккан хезмәтләрнең күбәюе фразеология тармагын өйрәнүнең актуальләшүе турында сөйли. Аның әһәмияте төрле объектив сәбәпләр белән аңлатыла. Беренчедән, киң таралган милли-рус икетеллелеге шартларында ике телдәге гомуми фразеологик фондның барлыкка килүе һәм үсүе юлларын, бер тел чаралары өлгесендә икенче телдә яңа фразеологик әйтелмәләр ясалу ысулларын, бу процесстагы уңышлы һәм уңышсыз якларны тикшерү таләбе туа. Ике яки берничә телдәге тотрыклы сүзтезмәләрне чагыштырып өйрәнү төрле телләрдәге фразеологизмнарның үзара нисбәтен, гомуми һәм үзенчәлекле якларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Бу тикшеренүләр ике телдә сөйләшүче кешеләрнең сөйләм культурасын үстерү өчен дә, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү проблемаларын киметү өчен дә кирәк.

Икенчедән, XX гасырның 70 нче елларында Көнбатыш Европада, аннан соң рус тел белемендә, тел һәм мәдәният бәйләнеше проблемасы белән төптән кызыксыну нәтиҗәсендә, фәндә яңа лингвокультурология дигән тармак барлыкка килде. Бу тармакның өйрәнү объекты булып мәдәният трансляторы ролен үтәүче тел берәмлекләре һәм тел күренешләре тора. Өйрәнү предметы гаять киң кырлы булуы белән характерлана. Шулар арасында милләтнең мәдәни-тарихи, иҗтимагый-сәяси, табигый-географик, көнкүреш һ.б. билгеләре чагылыш тапкан фразеологик әйтелмәләр күренекле урын тота. Шушы тел берәмлекләре һәм тел күренешләре җирлегендә өйрәнелгән концептлар җыелмасы аерым милләтнең милли-психологик характеры, ягъни менталитеты турында мәгълүмат бирә.

Татар тел белемендә әлеге юнәлештә тикшеренүләр Р.Р. Җамалетдиновның «Национальная языковая картина татарского мира» исемле докторлык диссертациясе (2004) белән башланып китте һәм соңгы вакытта киң колач алды. Татар милли тел картинасын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдән Э.М. Җиһангирова (2005), Э.Н. Гыйләҗева (2006), Ә.Ш. Василова (2006), Л.Р. Гарипова (2007), Ф.Х. Хәсәнова (2008), Р.Р. Закирова (2008) һ.б.ның монографияләре игътибарга лаек. Шулай ук төрле телләр белән чагыштырып өйрәнелгән хезмәтләрдән Г.А. Баһаутдинова (2007), Г.А. Биктаһирова (2007) һ.б.ның монографияләрен атарга була.

Татар телендә фразеологик сүзлекләр басылу да – фразеологик әйтелмәләрнең үзенчәлекләрен һәм төрләрен өйрәнү, системага салу өчен әһәмиятле күренеш. 1957 елда Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Г. Мәхмүтоваларның «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дөнья күрде, 1959 елда Н.Б. Борһанова, Л.Г. Мәхмүтова тарафыннан төзелгән «Русча-татарча фразеологик сүзлек», 1982 елда Г.Х. Әхәтовның «Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге», 1991 елда Л.К. Бәйрәмованың «Русча-татарча тематик фразеологик сүзлеге», 2001 елда Ф.С. Сафиуллинаның «Татарча-русча фразеологик сүзлеге» басылды. Н. Исәнбәтнең 1989–1990 елларда басылган ике томлык «Татар теленең фразеологик сүзлеге» әлегә кадәр нәшер ителгән иң тулы сүзлек булып тора.

Татар тел белемендә фразеологиягә кагылышлы хезмәтләр алда әйтеп үтелгән монографияләр, дәреслекләр белән генә чикләнми, билгеле. Татар фразеологиясен телнең башка тармаклары белән,

бигрәк тә лексикология, сүз ясалышы, синтаксис, морфология, тел тарихы белән бәйләнештә тикшергән аерым мәкаләләр даими чыгып тора, диссертацияләр яклана. Болар һәммәсе фразеологиянең тел фәнендә ныклы позицияләрне яулавы, лингвистикада аерым өлкә булып формалашуы турында сөйли. Ләкин татар тел белемендә фразеология буенча булган белемнәрне туплап, системага салган, фразеологизмнарны төрле аспекттан чыгып анализлаган һәм төгәл, конкрет нәтиҗәләр ясаган, бу өлкәдә алдагы тикшеренүләр өчен нигез булып торачак монография әзерләү көн кадагында торган мәсьәләләрнең берсе булуы аңлашыла.

Тел белемендә «фразеологизм категориясе» төшенчәсе конкрет билгеләнмәгән, төр һәм күләм-состав мәсьәләсе хәл ителеп бетмәгән. Телдәге кыска әйтелешле, составлары буенча бөтен булган, телдә әзер килеш саклана һәм кулланыла торган һәр төрле әйтем-тәгъбирләрне (мәсәлән, канатлы сүзләрне, мәкаль һәм әйтемнәрне, атама-терминнарны, афоризмнарны һ.б.) фразеологизмнар составында карауны хуп күрүчеләр аз түгел. Татар фразеологизмнарының төгәл составын билгеләү, аларның категориаль билгеләрен күрсәтү мәслихәт. Шулай ук термин мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк. Болар барысы үз чиратында «фразеологизм» төшенчәсенә билгеләмәне яңача формалаштыруны таләп итәчәк. Алда әйтеп үткән хезмәтләрдә татар фразеологизмнары башлыча В.В. Виноградов тәкъдим иткән классификациягә (Виноградов, 1947) нигезләнеп төркемләнәләр, ягъни компонентларның берләшү дәрәҗәсенә карап, өч төре күрсәтелә: фразеологик ныгымалар, фразеологик бердәмлекләр, фразеологик тезмәләр. Тел берәмлекләрен тиешле фәнни дәрәҗәдә тикшерү иң беренче чиратта бу берәмлекләрне барлап системага салу, аларны төрле принципларга нигезләнеп төркемләүне күз алдында тота. Бигрәк тә тематик, функциональ-семантик классификация булдыру зарури.

### § 43. Фразеологик система турында гомуми мәгълүмат

Телебезнең сүзлек составында ф р а з е о л о г и к  ә й т е л м ә дип атала торган лексик берәмлекләр мөһим урын алып торалар. Аларны атау өчен, берничә төрле термин кулланыла: фразеологик әйтелмә, фразеологик берәмлек, фразеологизм, тотрыклы әйтелмә, тотрыклы сүзтезмә, идиома, паремия. Образлы итеп, тел җәүһәрләре, телнең энҗе-мәрҗәннәре дип атаучылар да бар.

Ф р а з е о л о г и я (грек. *phrasis* – тәгъбир, гыйбарә, әйтем, әйләнмә, *logos* – өйрәнү) сүзе ике мәгънәдә йөри: 1) телнең тотрыклы сүзтезмәләр җыелмасы; 2) тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тел белеме тармагы.

Фразеологик әйтелмә мәгънәсе белән бер сүзгә синоним булып тора ала, дигән фикер яши, һәм күпчелек бу фикерне раслый, мәсәлән: *алтын куллы* – оста*; карт төлке* – тәҗрибәле*; керфегеннән гөл тама* – матур*; мәми авыз* – юаш*, булдыксыз; ике яклы пәке* – ялагай; *тамырына балта чабу* – бетерү; *теңкәгә тию* – аптырату; *түбәсе күккә тию* – шатлану; *кот очу* – курку; *куян йөрәк* – куркак һ.б.

Дөрес, кайберләренең күчерелмә мәгънәләрен бер сүз белән генә белдереп булмый, сүзтезмә яки җөмлә ярдәмендә аңлатырга кирәк була, мәсәлән, *бер канат сыну* – якын, кадерле кешеңне югалту, *күз күрер* – вакыты җиткәч, нишләргә икәне билгеле булыр, *күз йөртү* – өстән-өстән карап чыгу.

Формаларына килгәндә, фразеологик әйтелмәләр сүзтезмәләргә яки җөмләләргә охшыйлар: ике яки берничә сүздән оешалар. Г.Х. Әхәтов язганча, «фразеологик әйтелмәдә форма эчтәлектән бик нык артта кала, эчтәлек эчке формага нигезләнә. Димәк, форма ягы – фразеологик әйтелмәләрне сүздән, мәгънә ягы сүзтезмәләрдән аеру өчен төп критерий исәпләнә. Шулай итеп, фразеологик әйтелмә – сүз белән сүзтезмә арасында ята торган категория ул» (Әхәтов, 1982: 4).

Гомуми тел белемендә «фразеологик әйтелмә» төшенчәсенә билгеләмә бирүдә һәм аның компонентларының мөстәкыйльлек дәрәҗәсен күрсәтүдә ике юнәлеш яши. Беренчесе фразеологизмнар тулысынча лексик һәм грамматик билгеләрен югалткан сүзләрдән тора дип аңлатудан гыйбарәт. Бу юнәлеш тарафдарлары әйткәнчә, фразеологизм – генетик яктан гына сүзтезмәгә якын торган гыйбарә һәм ул тарихи планда гына таркатыла ала (Молотков, 1977: 26).

Икенче төр фикерләр фразеологик әйтелмәләрнең аерым сүзләрдән торуын һәм бу сүзләрнең, телнең грамматик нормаларына буйсынып, үзара бәйләнештә булуын ассызыклауга кайтып кала. «Фразеологизмнар – тулысынча яки өлешчә үзләренең туры мәгънәләреннән читләшкән аерым сүзләр тезмәсе» (Кунин, 1986: 24). «Мәгънәсе буенча бер төшенчә белдергән үзара тыгыз бәйләнешле сүзләр группасын фразеологик әйтелмә дип атыйбыз» (Әхәтов,

1979: 48). «... бербөтен мәгънә белдерүче, семантик һәм синтаксик яктан таркалмый торган тотрыклы сүзтезмә» (Хаков, 1999: 154).

Төрле карашларны анализлау нигезендә, фразеологизм компонентлары үзләренең «сүзлек» үзлеген саклаган дип әйтү уңышлы булыр. Димәк, телдә, сүзләр белән беррәттән, мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре буенча сүзләргә якын торган, ә структур яктан сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне хәтерләткән күчерелмә мәгънәле үзенчәлекле төзелмәләр яши.

Фразеологик әйтелмәләрнең чиген билгеләү, аларны сүзләрдән һәм иректе сүзтезмәләрдән һәм бигрәк тә башка төр тотрыклы тезмәләрдән аеру гаять катлаулы, һәм тел белемендә бу мәсьәләләргә карата фикерләр төрлелеге күзәтелә. «Фразеологик әйтелмә» термины белән нинди берәмлекләр аталырга хокуклы? Аларга нинди билгеләр хас? Бу сорауларга җавап табу өчен, иң элек фразеологик әйтелмәләрнең сүз һәм иректе сүзтезмәдән аермалы якларын карап үтик.

Ф р а з е о л о г и к  ә й т е л м ә  һ ә м  с ү з.

Фразеологизмнарны сүзләрне өйрәнгән кебек үк өйрәнәләр, чөнки алар да, телнең үзенчәлекле атау берәмлекләре буларак, төшенчәләрне белдерәләр.

Фразеологик әйтелмәләр, сүзләрнең семантик эквивалентлары буларак, билгеле бер сүз төркеме белән мөнәсәбәттә булалар һәм җөмләдә аерым синтаксик функцияне башкаралар. Мәсәлән, *Ул баласын уйлап ут йота* һәм *Ул баласын уйлап борчыла* дигән җөмләләрнең хәбәрләре булып *ут йота* тезмәсе һәм *борчыла* фигыле килгән. Бу үзенчәлек сүз һәм фразеологик әйтелмәне иректе сүзтезмәдән аерып тора.

Сүз белән фразеологик әйтелмә беренче чиратта матди составлары буенча тәңгәл түгел. Сүзләр морфемалардан тора, мәсәлән, *тамашачыларыбызга* сүз формасы *тамаша, -чы, -лар, -ыбыз, -га* морфемаларына таркала. Фразеологик әйтелмәләр аерым сүзләрдән төзеләләр. Мәсәлән: *биш былтыр* фразеологизмы *бик күптән* дигән күчерелмә мәгънәгә ия, ул *биш, былтыр* сүзләренең семантик берләшүеннән барлыкка килгән.

Сүзләрдән аермалы буларак, фразеологик әйтелмәләрнең компонентлары, төп мәгънәгә зыян китермичә, төрле үзгәртелүләргә дучар булырга мөмкин. Мондый күренешләр башлыча матур әдәбият әсәрләрендә һәм публицистикада стиль таләпләренә туры

китереп башкарыла. Мәсәлән, *арага шайтан керде* фразеологик әйтелмәсен *шайтан керде арага,шайтан арага керде* яки *керде шайтан арага* һ.б.үзгәртүләрдән төп мәгънә үзгәрми. Фразеологик әйтелмәнең компонентлары бер-берсеннән башка сүз белән аерылырга мөмкин: *Тагын бер көн мәңгелеккә китте, **Хәтереңә**, кешем, **салып куй**!* (М. Әгъләмов); *Хәзер аларның укыганда яки әйткәндә **телеңне** шартлап **сындырырдай** һәм тиз генә аңлашылмый торган «кәттә»ләре дә очрап куя әле.* (Көндәлек матбугаттан)

Морфемалар мондый үзгәрешләргә бирелмиләр, чөнки бу – сүзләрнең җимерелүенә китерә.

Сүзләр дә, фразеологизмнар да, лексик берәмлек буларак, беренче чиратта номинатив функция башкаралар. Шулай ук бу ике берәмлеккә дә затларга, предметларга, күренешләргә һәм вакыйгаларга бәя бирү үзенчәлеге хас. Дөрес, бу үзенчәлек күбрәк фразеологик әйтелмәләрдә чагылыш таба һәм ул төрле эмоциональ-экспрессив, стилистик төсмерләр белән баетыла. Мәсәлән, *чибәр* һәм *бер бите ай, бер бите көн* дигән берәмлекләр кешенең йөз матурлыгын тасвирлыйлар, ә *саран* һәм *бер ширпыны бишкә ярып кабызу* кебек берәмлекләр кешенең бер тискәре сыйфатын атыйлар, ләкин икенчеләрендә мәгънә интенсиврак яңгырый һәм тискәре эмоциональ төсмер белән сугарыла. Фразеологик әйтелмәләрнең күбесе үз эчендә берничә мәгънә төсмерен тупларга сәләтле. Мәсәлән, кемнедер *утта янмый, суда батмый* дип характерлаганда, ул кеше үзендә үткенлек, батырлык, тәвәккәллек, түземлелек сыйфатларын берләштергәнлеге аңлашыла. Сүзләрне һәм фразеологик әйтелмәләрне аеручы мөһим критерий булып соңгыларында булган образлылык һәм экспрессивлык санала.

Фразеологик әйтелмә һәм иректе сүзтезмә

Фразеологик әйтелмәләр иректе сүзтезмәләргә кимендә ике сүздән торулары һәм бу сүзләрнең телнең синтаксик нормаларына нигезләнеп бәйләнешкә керүләре белән якын торалар. Аерымлыклары түбәндәге лексик-семантик, стилистик һәм грамматик үзенчәлекләр белән билгеләнә:

1) фразеологик әйтелмәләр күчерелмә мәгънәгә ия, ә иректе сүзтезмәләр туры мәгънәдә генә кулланылалар, мәсәлән: *Сүзгә карап **бәя биргән** кешеләрне җенем сөйми.* (Ш. Галиев); *Әгәр яман ният белән булса, ул **йодрыгын испәтер иде.*** (М. Кәрим); *Ләкин инде соң: үзе заводта, хатыны кием тегү фабрикасында, балалары*

*мәктәптә, кыскасы –* ***койрык бозга каткан.*** (Г. Ахунов); *Яңа вахтаның килеп җитә алмаячагы* ***көн кебек ачык иде.*** (Г. Ахунов); *Мин элеккеге башлыкларның берсен дә* ***сөттән ак, судан пакь*** *итеп күрсәтергә теләмим* (Көндәлек матбугаттан) кебек җөмләләрдә *бәя биргән, җенем сөйми, йодрыгын иснәтер иде, койрык бозга каткан, көн кебек ачык иде, сөттән ак, судан пакь* тезмәләре күчерелмә мәгънәгә ия, фразеологик әйтелмә була.

Кайбер сүзтезмәләр бер очракта – фразеологик әйтелмә буларак, икенче очракта туры мәгънәдә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *Оешма җитәкчеләре* ***идән астына*** *күчкәннәр иде* (К. Нәҗми) һәм ***Идән астыннан*** *салкын керә* кебек җөмләләрдә *идән асты* сүз тезмәсе беренче очракта күчерелмә мәгънәгә ия, ягъни яшерен эш, легаль булмаган, рәсми булмаган сәяси хәрәкәт дигәнне аңлата һәм фразеологик әйтелмә булып тора, ә икенче җөмләдә туры мәгънәдә кулланылган һәм ирекле сүзтезмә булып килгән;

2) фразеологик әйтелмәләр сөйләм барышында яңадан төзелмиләр, сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр, ә ирекле сүзтезмәләр телнең грамматик законнары нигезендә сөйләм барышында бернинди чикләнүсез ясалып торалар;

3) фразеологик әйтелмәләрнең составы даими, бу составка, мәгънә бөтенлегенә зыян китермичә, яңа сүз өстәү, я компонентларның берсен төшереп калдыру, я башка сүз белән алмаштыру күренеше чикләнгән, үзгәртелгән очракта да катгый рамкаларда башкарыла,ә ирекле сүзтезмәләрдәге сүзләрне бернинди каршылыксыз төшереп калдырырга, араларына башка сүз өстәргә, бер сүз урынына башка сүз кулланырга була. Мәсәлән: *боз киптерү* (тик яту) – *кер киптерү; борчак ату* (ялганлау) – *туп ату; кан эчү* (изү) – *су эчү; кәкре кабыргалы* (тиз үпкәләүчән) – *кәкре аяклы; бавырга төшү* (аптырату) – *коега төшү; акыл җыю* (белем алу) – *гөмбә җыю.* Беренче сүзтезмәләр done бербөтен мәгънәгә ия, аларны таркатып булмый, икенчеләре туры мәгънәдә кулланылган, аларны таркатырга, төрле комбинацияләрдә кулланырга була;

4) фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе аның компонентларының гади суммасына тигез түгел, ә ирекле сүзтезмәләрнең мәгънәсе аерым компонентларның мәгънәләре суммасына тигез;

5) фразеологик әйтелмәнең семантик яктан бөтенлеге аны гади бер сүз белән алыштырып булуында да күренә: *тамырына балта чабу* – бетерү, *теңкәгә тию* – аптырату, *түбәсе күккә*

*тию* – шатлану, *кот очу* – курку, *куян йөрәк* – куркак һ.б. Ирекле сүзтезмәгә мондый бөтенлек хас түгел;

6) фразеологик әйтелмәләргә сурәтлелек хас, ягъни алар кешеләрнең эмоциональ-эстетик кичерешләрен сурәтләүгә хезмәт итәләр. Мәсәлән, *эч яну, йөрәк әрнү*, *җан телгәләнү, ут йоту, үзәк өзелү* фразеологизмнарында процессның турыдан-туры үзе түгел, бәлки аңа охшатылып абстракцияләнгән икенче бер хәлнең сурәте генә күз алдына килеп баса: борчылу, кайгы-хәсрәт кичерү. Ә ирекле сүзтезмәләр объектив чынбарлыктагы әйберләрнең, күренешләрнең исемнәрен атау хезмәтен үтиләр. Мәсәлән, *эч авырта, йөрәк тибә, кием телгәләнә, ут яна, бау өзелә* кебек сүзтезмәләрдә реаль күренешләр турында хәбәр ителә;

7) фразеологик әйтелмә составында берәр сүз, тулысынча яисә өлешчә ирекле мәгънәсен югалтып, фразеологик чикле мәгънәгә ия була башлый. Мәсәлән, *җиде юл чаты* дигәндә *җиде* сүзе, «күп» мәгънәсен белдерә башлап, фразеологик берәмлек барлыкка китергән;

8) фразеологизмнар составында хәзерге телдә мөстәкыйль кулланылмый һәм аңлашылмый торган, архаиклашкан, диалекталь сүзләрнең булуы – гадәти күренеш: *гөрбәт чигү; сөмсере коелу; киләп сарып йөрү; трай тибү; акылга сапкан; поты бер тиен;тугыз мурдан үткән; акча бездә бер букча; анда җиләк кызыл чикмән кебек; азан әйтми камәт төшермиләр; бортак авыз*; *адраеп йөрү; азау тешен ашаган; аздакы көянтәсе; алакайган күз*; *алаюк чагында*; *алыш-бирешкә бик кысмыр* һ.б. Ирекле сүзтезмәләр, башлыча, телдә актив кулланыла торган сүзләрдән оешалар;

8) төрле телләрдәге фразеологизмнар, бер үк мәгънә белдерсәләр дә, составлары ягыннан еш кына бер-берсенә туры килмиләр. Мәсәлән: *дөнья тоткасы – пуп земли, бeткән баш бeткән – двум смертям не бывать, биш былтыр – во времена оно, йөзгә бер тулмаган – винтиков не хватает, әлифне таяк дип тә белми – ни бельмеса не знает, җир тишегендә – у черта на куличиках* һ.б.

Димәк, тәрҗемә ителүче телнең фразеологик әйтелмәсенә тәрҗемә итүче телдән параллельләр эзләнелә, ягъни контекстка туры килгән эквивалент файдаланыла. Кайбер әйтелмәләр калька юлы белән тәрҗемә ителергә мөмкин: *баш вату – ломать голову, борын күтәрү – задирать нос, кул селтәү – махнуть рукой, түшәмнән алу – брать с потолка, бармакка бармак сукмау – палец о палец не ударить*. Ирекле сүзтезмәләр бер телдән икенче телгә бик җиңел тәрҗемә ителәләр.

## § 44. Фразеологик әйтелмәләрнең чиген билгеләү

Фразеологик әйтелмәләрне берәмлек буларак билгели торган критерийларны барлау фразеология теориясендә генә түгел, ә фразеологик сүзлекләр төзү практикасында да үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу критерийлар төгәл күрсәтелмәү сәбәпле, фәнни әдәбиятта мәкаль, әйтем, табышмак, составлы термин, канатлы сүзләр, афоризмнарны, метафораларны, гади чагыштыруларны да фразеологизмнар составына кертеп карау күзәтелә. Димәк, тел белемендә фразеологизмнарның составы, аларның чиге әле конкрет билгеләнмәгән.

Рус тел белемендә бу мәсьәләне чишүнең ике юнәлеше күрсәтелгән. Беренче юнәлеш тарафдарлары (А.И. Молотков, В.П. Жуков, Б.Л. Ларин, С.И. Ожегов, Л.Г. Руднев һ.б) фразеологик әйтелмәләр составына күчерелмә мәгънәле аерым сүзгә эквивалент булган катлаулы семантик берәмлекләрне генә кертүне хуплыйлар. Лексик яктан бүленми торган, күчерелмә мәгънәдән азат булган тезмәләр, мәсәлән, мәкальләр, әйтемнәр, күпчелек цитаталар, барлык катлаулы терминнар фразеология өлкәсеннән алып ташлана.

Л.Л. Реформатский, Н.М. Шанский, А.И. Ефимов, В.Л. Архангельский, Л.И. Ройзензон, С.Г. Гаврин, Е.И. Диброва кебек галимнәр төп фразеологик берәмлекләр белән беррәттән фразеологиягә мәкаль-әйтемнәрне, цитаталарны, канатлы тезмәләрне, катлаулы терминнарны да кертүне дөрес дип табалар.

Татар тел белемендә дә бу мәсьәлә бертөрле генә чишелеш тапмаган. Мәсәлән, алда әйтелгәнчә, Г.Х. Ахунҗанов идиомалар составына әйтем, мәкаль, әйтем белән мәкаль арасында тора торган арадаш төрләр, сүзтезмә формалы терминнар, канатлы әйтелмәләрне дә кабул итә (Ахунҗанов, 1972: 16–35).

Г.Х. Әхәтов *халыклар дуслыгы, коллектив хуҗалык, хезмәт көне, Югары Совет, Министрлар Кабинеты, Көньяк Америка, Төньяк боз океаны, Ерак Көнчыгыш, Польша Халык Республикасы, Америка Кушма Штатлары, Бөтендөнья тынычлык Советы, Берләшкән Милләтләр Оешмасы, Менделеев таблицасы, Ньютон законы, җитештерүче көчләр, электр кыры* һ.б. тезмәләрне фразеологик терминнар яки фразеологик атамалар дип атый. (Әхәтов, 1995: 67–68).

В.Х. Хаков стилистик планда *мәгърифәт нуры, өмет маяклары, милли болытлар, азатлык кошы* кебек тезмәләрне әдәбият-китап телендә кулланыла торган фразеологизмнарга кертә, ә *милләт*

*кортлары, ирек дулкыннары, халык рухы, халык җилкәсен кимерү, милләт йокысы, явыз язмыш, тигез ихтыяр* тезмәләрен махсус иҗтимагый-сәяси фразеология исеме белән бирә (Хаков, 1999: 155).

Телдәге барлык тотрыклы сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне «фразеологик әйтелмә» термины белән бирергә ярамый. Мәсәлән, *үги ана яфрагы, комендант сәгате, ак шигырь, карга борыны, туганнан туган, кызыл почмак, туганнар кабере, көн тәртибе, көзән җыеру, Сабан туе* кебек сүзтезмә формасындагы терминнар һәм тезмә сүзләр синтаксик яктан тотрыклы булып, бербөтен мәгънә белдереп килсәләр дә, аларны фразеологик әйтелмәләр составына кертү – хата. Терминнарны фразеологик берәмлекләрдән аерып торучы төп билге – аларда күчерелмә мәгънәнең булмавы. Шулай ук терминнар фразеологизмнар кебек сурәтлелек, образлылык, эмоциональлек, теге яки бу күренешкә бәя бирә алу үзенчәлекләреннән дә мәхрүм. Аларны башка телгә тәрҗемә итү бернинди дә авырлык тудырмый. Терминнар (атамалар), үзләренең семантик кулланылыш ягыннан аерым төшенчә рамкасында чикләнеп, моносемантик характерда булалар, ягъни бер мәгънәне төгәл, конкрет белдерәләр. Шул рәвешле, ике яки берничә сүздән торган, сүзтезмә формада булган һәм конкрет мәгънәдә кулланылган терминологик атамаларны фразеологик әйтелмәләр составына кертеп карау дөреслеккә туры килми.

Кайбер терминнар, билгеле бер контекстта үзләренең туры мәгънәләрен югалтып, күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла башларга мөмкин. Бу очракта терминнан фразеологик әйтелмә ясалу күренеше күзәтелә. Мәсәлән, *тавык күзе,* термин буларак, караңгы төшкәч начар күрү чире атамасын белдерә. Кайбер контекстта бу атама ирония чарасы, кешене хурлап әйтү өчен файдаланыла һәм фразеологизмнарга хас билгеләргә ия була: ***Тавык күзе*** *булмаган кешегә тимерченең эше күренеп тора бит. 3–4 көн эчендә утызлап сабанны төзәтеп ташлаган.* (Т. Гыйззәт)

*Сару кайнау* туры мәгънәсендә аш юлы авыруын аңлатып, термин булып килә, ә *Мәхәббәтсез, тәмам* ***саруымны кайнатып*** *бетерде инде, Ибраһим кайтты исә шуның белән чокырдаша* (Г. Камал) җөмләсендә фразеологик әйтелмә булып тора, чөнки күчерелмә мәгънәдә килгән; йөдәтү, ачу китерү, эч пошырып йөрүне белдерә.

Фразеологик әйтелмәләрнең мәкаль һәм әйтемнәр, канатлы сүзләр, афоризмнар, хәтта кайбер табышмаклар белән дә уртак

сыйфатлары бар. Мәкаль һәм әйтемнәр, фразеологик әйтелмәләр кебек үк, кыска, оста әйтеләләр, күчерелмә мәгънәдә кулланылалар, образлы-сурәтле булалар, сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр. Шуның өстенә фразеологик әйтелмәләрнең дә, мәкаль һәм әйтемнәрнең дә күбесе ритм, рифма, аллитерация белән төзелә. Мәсәлән, *бүрәнә аша бүре куу; берне биш итү; сөйкемле сөяк; серкәсе су күтәрми; сабыр төбе сары алтын; иштең ишәк чумарын; чүлмәкчедән күрмәкче; типсә тимер өзәрлек; кешенеке – киштәктә* һәм *тырышкан табар, ташка кадак кагар; бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй; алай диеп, болай булмый, бодай чәчеп, арпа булмый; баллы кеше – маллы кеше, сыерлы кеше – сыйлы кеше; ит ашасаң, тешкә керә, ашамасаң – төшкә керә; калган эшкә кар ява; яхшы белән юлдаш булсаң – эшең бетәр, яман белән юлдаш булсаң – башың бетәр*. Китерелгән берәмлекләрне төркемнәргә аеру гаять катлаулы.

Мәкальләр төгәлләнгән җөмләләрдән тора, образлы була, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп, билгеле бер нәтиҗә, хөкем чыгара, гыйбрәт, үгет-нәсыйхәт өчен, ягъни дидактик максатта әйтелә, сөйләмгә тәэсирлек өсти. Сөйләүче мәкальләрне башка кеше сүзләре рәвешендә куллана. Фразеологизмнар исә сөйләмгә кешенең үз сүзе буларак урнаштырылалар.

Мәкальләр фразеологизмнар кебек семантик яктан бөтен түгел, мәгънә аларны оештыруда катнашучы лексик элементларның суммасыннан килеп чыга. Димәк, мәкальне аерым сүз яки сүзтезмә белән алмаштырып булмый. Теләсә кайсы мәкаль структур яктан төгәлләнгән була, ул аерым сүз һәм сүзтезмәләргә таркала ала, синтаксик анализда мәкальне төрле җөмлә кисәкләренә аерып була. *Баллы кеше – маллы кеше, сыерлы кеше – сыйлы кеше* мәкален алыйк. Бу – бер җөмлә, баш кисәкләре – *кеше* (ия һәм хәбәр), *баллы, маллы,сыерлы, сыйлы* – аергычлар. Бу мәкаль *баллы кеше, маллы кеше, сыерлы кеше, сыйлы кеше* кебек сүзтезмәләргә таркала, алар ияртүле бәйләнештә тора.

Әйтемнәр мәкальләргә якын торалар, аларны еш кына, бер-берсеннән аермыйча, мәкаль-әйтемнәр дип тә атап йөртәләр. Мәкаль шикелле үк, әйтемгә дә текстның тотрыклы булуы хас, ул да сөйләмне сәнгатьчә бизәү, аның эмоциональ көчен арттыру өчен хезмәт итә. Әмма әйтемнең мәкальдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә ясау сыйфаты юк (Әйтем – чәчәк,

мәкаль – җиләк, 2002: 8). Мәкаль һәм әйтемнәрне аерып торучы билге итеп соңгыларының мәгънәсен бер синоним сүз белән алмаштырып булу үзенчәлеге әйтелә (Әйтем – чәчәк, мәкаль – җиләк, 2002: 9). Мәсәлән, *ай күрде, кояш алды; әйттем исә, кайттым; авызыңнан җил алсын; эш бетте, көлтә җыясы гына калды; җитмәсә артып калыр; эт – баш, сыер – аяк; чүлмәкчедән күрмәкче; агач атка атландырды; утлы табага бастырырмын; аркылы ятканны буйга алып салмау*. Димәк, әйтемнәр бернинди каршылыксыз фразеологизмнар рәтендә карала ала.

Канатлы әйтелмә – халык теленә читтән: әдәби чыганаклардан, мифологиядән, чит телнең афоризмнарын яки канатлы әйтелмәләрен калькалау юлы һ.б. юллар белән килеп кергән берәмлек. Г.Х. Ахунҗанов аларны китап теле идиомасы дип атый һәм түбәндәге мисалларны китерә. Татар әдипләре теленнән кергән канатлы сүзләр: *Халык – зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул*; *Эш беткәч уйнарга ярый; Акча барда бар да дус шул, акча исе чыкмый торса, бар яныңнан таяр; Гамәле юк галимнән кысыр тавык яхшырак; Кысканга былтыр кычкыралар ди мени быел.* (Г. Тукай); *Ярлылык белән үткән тереклек.* (М. Гафури); *Үлем турында уйлама, илең турында уйла.* (Ф. Кәрим); башка телләрдән кергән канатлы сүзләр: *уңышлардан баш әйләнү, очкыннан ялкын кабыну, аю хезмәте күрсәтү, үле җаннар, чуртан кушуы буенча* (рус теленнән кергән); *дәүләт эчендә дәүләт, аппетит ашаганда килә, кызыл җеп булып үтү, бишенче колонна, дәүләт машинасы, тимер пәрдә* (Көнбатыш Европа телләреннән рус теле аша кергән); *бер карлыгач килүдән яз булмый, чебеннән фил ясау, ызгыш алмасы, Домокл кылычы, акчаның исе юк, канатлы сүз* (борынгы грек һәм Рим чорыннан килә торган канатлы сүзләр); *Тау Мөхәммәткә килмәсә, Мөхәммәт тауга килә* (Корьәннән алынган), *утырган ботагыңны кисү* (Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләрдән алынган) (Ахунҗанов, 1972: 32). Канатлы әйтелмә, үзенең туры мәгънәсен югалтып, күчерелмә мәгънәдә кулланыла башлагач кына, фразеологизмга күчә. Бу төр әйтелмәләр фразеологизмнар ясалу өчен чыганак булып торалар.

Табышмаклар төзелеш, тематик яктан мәкаль һәм әйтемнәргә якын. Табышмак хәтта мәкаль функциясен дә үтәп килергә мөмкин. Мәсәлән, *«Сакалы бар, акылы юк»* тәгъбире, табышмак буларак, кәҗәгә ишарә итә, мәкаль буларак, күп яшәп тә, аз белүчегә карата әйтелә (Әхәтов, 1995: 56).

Табышмак белән фразеологик әйтелмәнең уртаклыгы – аларның метафорик характерда булуы. Табышмакта бер реаль әйбер турында төшенчә икенче бер аңа охшаган әйберне сурәтләү һәм аның белән яшерен чагыштыру рәвешендә күз алдына китерелә. Мәсәлән, *Багана яна, күмере-көле юк* (шәм), *«Җансыз җанлыны уята* (сәгать), *Асты диңгез, өсте нур* (бәби), *Тимер тәкә тау яра* (чәч алу) һ.б.

Кайбер фәнни мәкаләләрне укыганда, метафорик төркемгә кергән сүзләрне – метафораларны, чагыштыруларны, эпитетларны – фразеологик әйтелмә итеп күрсәткән очракларга юлыгабыз. Мәсәлән, *серле сукмак, дәртле көй, моңлы көй, дәртле йөрәк, сихри аваз, серле аваз, чишмә авазы, татлы хыял* һ.б. тезмәләрне авторның индивидуаль фразеологизмнары итеп күрсәтүчеләр бар. Метафоралар – башка предметларга яки күренешләргә охшату нигезендә ясалган күчерелмә мәгънәдәге сүзләр. Алар, фразеологизмнар кебек үк, сөйләмне җанландыруда һәм, гомумән, образлы итүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Ләкин метафора ул – бер сүзнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуы, ә фразеологизм дигәндә кимендә ике сүзнең семантик бөтенлеге күз алдында тотыла. Метафораларның күбесе сөйләм барышында ясала, ә фразеологизмнар телгә әзер килеш килеп керә.

Шулай ук хәзерге тел белемендә фразеологизмнарны «паремия» дигән термин белән биреп, бу төр берәмлекләрнең асылын билгеләүдә буталчыклар очрый. «Паремия», «паремиология» терминнары соңгы елларда актив кулланылышка кереп китте. Паремиология (борынгы грек сүзе, *paroimia* – мәсәл, гыйбрәтле хикәя, мәкаль һәм *logos* – сүз, өйрәнү) – мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, афоризмнарны, сынамышларны, канатлы әйтелмәләрне һ.б. тышкы төзелешләре белән кыска, эчтәлекләре белән җыйнак, үткен һәм сурәтле итеп әйтеп бирә торган фикер җәүһәрләрен өйрәнә торган тел белеме тармагы. Фразеологизмнар да төзелешләре һәм эчтәлекләре буенча паремияләр рәтендә каралырга хокуклы. Димәк, «паремия» төшенчәсе «фразеологизм» төшенчәсеннән киңрәк. Фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, канатлы әйтелмәләр, цитаталар кебек, паремиянең аерым берәмлеге булып тора. Ирекле сүзтезмәләрдән, тезмә терминнардан фразеологизмнарны аларга хас булган образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык кебек билгеләр аера.

### § 45. Фразеологик әйтелмәләрнең билгеләре

Бер төркем рус галимнәре, фразеологик әйтелмәләрнең башка берәмлекләрдән аерып торучы төп билгесе итеп аларны башка телләргә тәрҗемә итеп булмауны күрәләр (Л.А. Булаховский, А.А. Реформатский). Чыннан да, кайбер фразеологизмнар башка телләргә турыдан-туры тәрҗемә ителми. Ләкин бу күренеш фразеологизмнарга гына түгел, кайбер сүзләргә дә хас (мәсәлән, телнең эквивалентсыз лексикасы).

Икенчеләр, мәсәлән, А.И. Ефимов фразеологизмнарның төп билгесе итеп образлылыкны саный. Ләкин бу да фразеологизмнарны фразеологизм булмаган башка берәмлекләрдән аерып торучы төп билге була алмый, чөнки образлылык мәкаль-әйтемнәргә дә, табышмакларга да, канатлы сүзләргә дә, афоризмнарга да карый.

Өченче төр хезмәтләрдә фразеологизмнарның структур-семантик билгеләре алгы планга чыгарыла (В.В. Виноградов, А.И. Смирницкий, Б.А. Ларин, С.И. Ожегов, Н.Н. Амосова, О.С. Ахманова, Н.М. Шанский, В.Л. Архангельский, Л.И. Ройзензон һ.б.).

Фразеологизмнар турында фикер йөрткәндә, В.В. Виноградов иң элек аларның түбәндәге сыйфатларына игътибар итәргә киңәш итә: 1) фразеологизмнар, сүзләр кебек үк, сөйләмдә әзер килеш кулланылалар; 2) фразеологизмнар структур яктан тотрыклы. Бу тотрыклылык компонентларның семантик бердәмлегеннән килеп чыга; 3) фразеологизмнар бер-берсеннән компонентларының семантик берләшүе һәм мәгънәнең мотивлашкан булуы дәрәҗәсеннән чыгып аерымланалар.

Татар тел белемендә «фразеология» төшенчәсенә төрле галимнәр төрле билгеләмә бирә. Г.Х. Ахунҗанов фразеологизмнарны идиомалар дип атый һәм түбәндәгечә характерлый: идиома – сүзлек берәмлеге сыйфатында теркәлә торган, кимендә ике сүзле һәм специфик мәгънәле тотрыклы әйләнмә (Ахунҗанов, 1972: 10).

«Мәгънәсе буенча бер төшенчә белдерүче үзара тыгыз бәйләнешле сүзләр группасына фразеологик әйтелмә дибез» (Әхәтов, 1995: 40).

Ш.А. Рамазанов фразеологизмнар составындагы компонентларның үзара мөнәсәбәтен өстен күреп, билгеле аерым төшенчә нигезендәге төзелешләре белән ныгып киткән һәм сөйләмдә, башлыча, шул төзелешләрендә кулланыла торган сүз тезмәләрен фразеология дип атый (Рамазанов, 1954: 129).

В.Х. Хаков фразеологияне үзенең мәгънәсе, төзелеше һәм функциональ үзенчәлекләре ягыннан аерым сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аерылып тора дип саный. «Фразеология ул, асылда, гаять бербөтен мәгънә белдерүче, чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы, семантик һәм синтаксик яктан таркалмый торган тотрыклы сүз тезмәсе» дип ассызыклый, мәсәлән, *балавыз сыгу*, *күңел тулу*, *күңел ярасы*, *баш күккә тию* һ.б. (Хаков, 1999: 154).

Ф.С. Сафиуллина, фразеологик әйтелмәләргә билгеләмә биргәндә, күбрәк компонентлар арасындагы бәйләнешкә игътибар итә: «Фразеологизмнар – бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган тотрыклы сүз тезмәләре», – дип яза (Сафиуллина, 1999: 135).

Фразеологизмнар турында мәгълүмат З.М. Вәлиуллина хезмәтләрендә дә бар. Галимә, нинди дә булса бер конкрет лексик төшенчә белдерү өчен, һәрвакыт диярлек үзгәрешсез, бертөрле формада кулланыла торган эмоциональ-экспрессив эчтәлекле ныгыган сүз тезмәләрен фразеологик әйтелмәләр дип атый. Аның фикеренчә, фразеологик әйтелмәләрнең күпчелеге җанлы сөйләмдә киң таралуы һәм эмоциональ-экспрессив көчкә ия булуы белән ирекле сүз тезмәләреннән аерылып тора (Вәлиуллина, 1965: 71).

Алдагы бүлекчәләрдә әйтелгәннәрдән чыгып, татар телендәге фразеологик әйтелмәләргә түбәндәге үзенчәлекләр хас булуын беләбез:

1) кимендә ике сүзнең семантик бөтенлеге;

2) күчерелмә мәгънәдә кулланылу;

3) фразеологизмны барлыкка китерүче сүзләрнең тотрыклылыгы, сөйләмдә әзер килеш кулланылу;

4) башка сүз яки сүзтезмә белән алмаштырып булу;

5) образлылык;

6) сурәтлелек;

7) экспрессивлык, теге яки бу күренешкә бәя бирү, аны уңай яки тискәре яктан характерлау;

8) бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүдә авырлыклар туу.

Бу билгеләрне аерым фразеологизмнар мисалында тикшереп үтик: *Шәбрәк җиһаз белән барса, Галиябануның үзенә дә кайниш арасында* ***йөз аклыгы*** *булыр.* (М. Фәйзи); *Сарыклар салып бетер-*

*гән тар сукмакларны **биш бармак кебек** белә иде.* (Г. Ибраһимов); *Хәзер инде Илсөяр, Бикмуш бабайча әйтсәк**, акны карадан аера** белә башлаган иде.* (Г. Гобәй); *Рөстәм үз язмышын үзе хәл итәргә кирәк икәнлекне аңлады һәм зурларча **акыл йөртә** башлады.* (Г. Кутуй); *Авылда озаклап кунак булу хәзер Динә өчен **кул кушырып, түшәмгә төкереп яту** белән бер иде.* (Н. Гыйматдинова); *Иясенә үзең тапшыр. Сезнең килешүгә шәхсән мин **кул куймадым**.* (Н. Гыйматдинова); *Без сиңа **менә дигән** бүлмә әзерләдек.* (Н. Гыйматдинова); *Алайса, ник **телгә килеп** әйтми, ник болай **җанны телгәли**?* (Н. Гыйматдинова); *Мунчасы **кул сузымы** арада гына лабаса!* (Н. Гыйматдинова); *«**Биш былтыр** элгәре мунча тәрәзәсенә баккан зат – сән идеңме?» – диде.* (Н. Гыйматдинова); *Дөнҗагыз буталгырлары, һәр тишеккә **борын тыгасыз.*** (Н. Гыйматдинова); *Кыз бу сүзләргә әһәмият бирмәде, ишегалдыннан тиз генә **табанын ялтыратты**.* (Н. Гыйматдинова); *Авылның бердәнбер изге карчыгы Акъәнинең **урыны түрдә**, юкка борчылма, ул бездә яшәячәк.* (Н. Гыйматдинова); ***Күз ачып йомганчы** сикереп торып тәрәзә янына килсәме! Әллә күпме халык җыелган ишегалдына: кайсы көлә, кайсы елый, бер-берсен кочаклашалар.* (Көндәлек матбугаттан)

Китерелгән мисаллардагы фразеологик әйтелмәләр билгеле бер мәгънәгә, төшенчәгә ия, мәсәлән: *йөз аклыгы* – абруй, дәрәҗә, яхшы исем*; биш бармак кебек белә* – бик яхшы белә; *акны карадан аера* – яхшы белән начарны аера алырлык тормыш тәҗрибәсе бар; *акыл йөртә* – төрле яктан уйлый; *кул кушырып яту, түшәмгә төкереп яту* – эшләмичә тик яту; *кул куймау* – риза булмау; *менә дигән* – бик яхшы; *телгә килү* – тавыш бирү; *җанны телгәләү* – җәфалау, интектерү*; биш былтыр* – бик күптән; *борын тыгу* – кирәкмәгән җиргә тыкшыну, катышу; *табан ялтырату* – качу; *урыны түрдә* – кадерле, дәрәҗәле кеше турында; *күз ачып йомганчы* – бик тиз. Бу мәгънәләр аерым компонентларның гади суммасыннан килеп чыкмый. Алар икенче, сыйфат ягыннан яңа, күчерелмә мәгънәләр булып торалар һәм үз чиратында эмоциональ-экспрессив төсмерләр белән сугарылганнар. Авторлар аларны сөйләм барышында уйлап тапмаган, ә телдән әзер килеш алып кулланганнар. Әлеге фразеологик әйтелмәләрнең составы даими, аларны үзгәртүдән мәгънәгә зыян килә, тотрыклылык югала, мәсәлән: *йөз аклыгы*н *йөз каралыгы* дип әйтсәк, башка мәгънәдәге (*кара йөз*) фразеологик әйтелмә килеп чыга, *йөз* сүзе янында башка төс атамалары куллансак (*кызыл йөз, сары*

*йөз*), фразеологик әйтелмә булудан туктый, ирекле сүзтезмә барлыкка килә. Саналган фразеологик әйтелмәләрдән *биш бармак кебек белү,борын тыгу, табан ялтырату* дигәннәре генә рус теленә турыдан-туры тәрҗемә ителә: *знать как свои пять пальцев,совать нос, засверкать пятками, собачья жизнь*; калганнарына мәгънәдәш фразеологик әйтелмәләр эзләнелә, мәсәлән, *кул кушырып яту, түшәмгә төкереп яту – бить баклуши, биш былтыр – во времена оно,* я туры мәгънәле сүз белән алмаштырыла: *йөз аклыгы – авторитет, менә дигән – отличный, телгә килү – заговорить.*

Алда сөйләгәннәрдән чыгып, фразеологик әйтелмәләр дигәннән, барлык яки бер компонентының туры, номинатив лексик мәгънәләре көчсезләнеп яки бөтенләй юкка чыгып, күчерелмә мәгънәдә кулланыла башлаган тотрыклы сүзтезмәләрне күз алдында тотабыз. Фразеологик әйтелмәнең төп билгеләре булып күчерелмә мәгънәгә ия булуы һәм конструкциянең тотрыклылыгы (контекстның үзгәрмәве) тора. Калган билгеләрнең дә, мәсәлән, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык, башка телләргә тәрҗемә итүдә кыенлыклар һ.б.ның булуы мөһим.

Димәк, фразеологизм дип күчерелмә мәгънәле, семантик һәм структур яктан бөтен, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык билгеләренә ия булган, сөйләмгә әзер килеш килеп кергән тотрыклы тезмәләр атала.

### § 46. Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы

Фразеологик әйтелмәләр формалашу процессы телнең лексик фонды, лексик составы, фонетик, грамматик, лексик-семантик һәм стилистик яктан үсеше, камилләшү процессы белән органик бәйләнештә дәвам иткән һәм дәвам итә.

Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килүе – зур тарихи үсеш нәтиҗәсе. Аларда халыкның мәдәнияте, милли аңы, бай тарихы, тормыш тәҗрибәсе һәм тапкырлыгы чагылыш таба. Әлеге төр берәмлекләрне халык үзен чолгап алган, үзенә бик яхшы таныш булган әйбер һәм күренешләргә нигезләнеп тудырган.

Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составын кулланылыш активлыгы ягыннан актив һәм пассив сүзләр, кулланылыш сферасы буенча киң һәм тар кулланылыштагы сүзләр, килеп чыгышы ягыннан гомумтөрки һәм татар теленең үз сүзләре, алынмалар тәшкил итә. Ләкин бу сүзләр фразеологизмнар ясауда бертигез катнашмыйлар.

Фразеологик әйтелмәләр составындагы актив сүзләр сөйләмдә еш очраулары, сөйләшүчеләр өчен аңлаешлы булулары белән характерлана, аларның төп өлешен гомумхалык сүзләре тәшкил итә: *йөрәккә боз булып утыру; бәхет күгәрчене; бөере бала басмаган, арты йомырка салмаган; дөнья бәясе; каккан казыгы да юк; асыл кош; бөкесе атылу* һ.б.

Пассив лексикага көндәлек тормышта даими кулланылмый торган, татар теле лексикасының хәзерге хәлен билгеләүдә төп күрсәткеч булмаган, төшенчәсе әһәмиятен югалтып, телдән төшеп калган яисә яңа гына туып, телдә урнашырга өлгермәгән сүзләр – искергән сүзләр һәм неологизмнар керә. Әлеге төр сүзләрнең күбесе, бигрәк тә искергән сүзләр составындагы архаизмнар һәм тарихи сүзләр, фразеологик әйтелмәләр составында гына кулланыла, шуңа күрә бу төр берәмлекләр – тел тарихын өйрәнүдә алыштыргысыз материал. Мондый фразеологизмнар фразеологик ныгымалар (идиомалар) булып тора. Фразеологик әйтелмәләр составында архаизмнарның түбәндәге төрләрен очратырга мөмкин:

1) семантик архаизмнар (актив сүзлек составындагы сүзнең искергән мәгънәсендә килүе): *акшарлы кыз* (сатлык, фахишә кыз); *елдырым камчысы* (яшен ялтыравы);

2) лексик архаизмнардан:

а) саф лексик архаизмнар (бөтенләй искергән яки башка лексик берәмлек белән алмаштырылган сүзләр): *аз азыклы, күп языклы* (язык – гөнаһ); *ай йөр, аман йөр* (аман – исән-имин); *ай җык тигере* (җык – авыру); *акчасыз кәмит* (кәмит – цирк); *алпарына күрә толпары* (толпар – ат); *анда гарасат* (гарасат – көчле давыл);

ә) лексик-морфологик архаизмнар (грамматик формасы үзгәреш кичергән сүзләр): *Алланың бирмеш көне; алмакка бар, бирмәккә юк; белә әтәч синең хәрфе җәреңне; дәшмеш кеше; көн күрмеш*;

б) лексик-фонетик архаизмнар (аваз ягыннан үзгәреш кичергән сүзләр): *ай юктан чыраг* (чыраг – чыра); *анай (атай) кабәм* (кабә – кәгъбә).

Фразеологик әйтелмәләр составындагы бер төркем тарихи сүзләрнең мәгънәләре бүгенге көндә дә аңлашыла, бу сүзләр сүзлекләрдә күрсәтелә: *поты бер тиен; потка тулмаган; тугыз мурдан үткән; акча бездә бер букча; анда җиләк кызыл чикмән кебек;азан әйтми камәт төшермиләр; биштәр тагып кайту; гөрәнкәсе җиңел; Идел суы илле батман; менге ат; чабудан тоту.*

Кайбер тарихи сүзләр билгеле бер фразеологик әйтелмә составында гына очрыйлар, һәм аларның мәгънәләрен билгеләү өчен, махсус этимологик хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк: *гөрбәт чигү; гөрбәттә яшәү; сөмсере коелу; сөмсез сыер; киләп сарып йөрү; трай тибү; акылга сапкан; ике сәкыйм – бер мөстәкыйм; зыкысын чыгару; бохыны чыкканчы; бушка лашман тарту; бәбәлән йомыркасы.*

Кулланылыш даирәсе ягыннан караганда, фразеологик әйтелмәләрнең составын киң һәм тар кулланылыштагы сүзләр бiләп тора. Тар кулланылышлыларга диалекталь, профессиональ, жаргон һәм арго сүзләр керә.

Фразеологик әйтелмәләр составында диалекталь сүзләр кулланылышына түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *бортак авыз* (авызын-телен тыя белмәүче, тотнаксыз кеше); *адраеп йөрү* (гайрәтләнеп, этәчләнеп йөрү); *азау тешен ашаган* (күп яшәгән); *аздакы көянтәсе* (усал карчык); *алакайган күз* (акай күз); *алаюк чагында* (башка вакытта); *алыш-бирешкә бик кысмыр* (кысмыр – саран); *беткеле түгел* (бетә торган түгел); *бөҗыр өтү* (сасы ис чыгару); *дахат бетү* (ару, хәлсезләнү); *дебрән колак* (чукрак); *диңгез янында суга мыхтану* (мыхтану – мохтаҗ булу); *дыдык кеше* (сакау, тотлыгып сөйләшүче); *дәгел кебек* (зифа буйлы); *зыкымы тию* (йогынтысы тию).

Һөнәри лексикага караган сүзләр түбәндәге фразеологик әйтелмәләр белән билгеләнә: *беренче скрипка; телсез сәхнә; баш рольләрне уйнау* (сәхнә); *ут ачу; хәрәкәттәге армия* (хәрби) һ.б.

Фразеологик әйтелмәләрдәге сүзләрнең килеп чыгышы ягыннан төп составны гомумтөрки, татар теленең үз сүзләре һәм борынгы чорларда телебезгә кереп урнашкан алынмалар тәшкил итә. Бу сүзләрне мәгънә үзенчәлекләре буенча берничә зур төркемчәгә берләштереп карап була.

1. Кешенең тән төзелешенә караган сүзләр (*баш, күз, каш, колак, керфек, теш, кул, аяк, бавыр, бугаз, муен, йөрәк, үпкә* һ.б.): *алдан аяк ялый, арттан үкчә тешли; күзле-башлы булу; каш төзәтәм дип күз чыгару; колак итен ашау; керфек тә какмау; тел-теш тидерерлек түгел; бавыр итен ашау; бөергә таяну; бугазына ябышу; муенын бору; йөрәгендә бете бар; мәсьәләне кабыргасы белән кую.*

2. Кешенең акыл, характер үзенчәлекләрен атаган сүзләр: *акылын кәҗә ашаган; уңганлыгы ялкаулыгы белән генә беленми; уңмаган утын тукмагы; рәхиме килү; сабыр казаны шарт-*

*лау; юмакай тел; юләр нәрсә; яхшы атлы булу; әдәп саклау; куш йөрәкле; куркак җан; иһаһай кыз.*

3. Кешенең физик һәм физиологик үзенчәлекләрен атаучы сүзләр: *азрак баш-күз алу; айнымас сырхау; акча бүсере; бизгәк тоткандай; саруы кайнау; башка кабу; башка йөгерү; башны авыруга салу; бирән корсак; гарип баш; имгә калу; ите бетеп, сөяккә калган; йөрәк кубу; как сөяккә калу; калын тиреле; калын җилкәле; киртләч борын; нечкә бил; теше сирәк; тән ватылу.*

4. Туганлык атамалары (*әти, әни, ата, ана, әби, бабай, ул, кыз, туган* һ.б): *ак бабай; ак карт әти; ак карт атай; ак туган; ак тутай; ак тәтәй; ана күргән; анасына кыз; [анда] ата улын, ана кызын белми; анда әти белән әни генә юк; бабайныкы – илнеке [дип әйтте ди бер кияү]; баба тел; әби авыз; әбиең сызгыра беләме; әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен; әбиләр чуагы; килен төшсә киртәгә; кияүгә бирәсе кыз түгел, ашка саласы тоз түгел; кияү көткән кыз кебек калтырый; бала акылы чыкмаган; бала атасы.*

5. Урын, вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр (*көн, төн, иртә, кич, ал, ян, як, арт*): *ае-көне җиткән; ай белән көндәй, һәркемгә бердәй; ай киткән, ел киткән, энә буе җир киткән; айлык җирне алты атлап, еллык юлны җиде атлап; ак як; алгы сызык; алдан күрү; алдындагысын алты ай эзләгән; алны-артны, уңны-сулны белми; бер дә бер заманны; замана баласы.*

6. Хайван, кош, бөҗәк исемнәре: *айда бетмәс аю ите; айга шыңшыган эт кебек; аккош сөте; акча корты; алап сугып чәүкә куркытма; ала сыер тиресе; алмаган ат, тумаган колын; алмаган тавык, салмаган йомырка; бака ботыннан гына; чыпчык тезеннән; бака йоткан еландай; бүре авыз; бүре белән куй бергә су эчә; карга оясында үскән кәккүк; карга санап калу; кәҗә маен чыгару; оясыз кәккүк; песи битен юмаган; сыерга камыт кидерү; сыерчык бураны; тавык көләрлек; таракан булу; әтәч җибәрү; үгез булып үкерү.*

7. Үсемлек исемнәре: *абага чәчәк аткач; агач тел; алда гөл, артта кычыткан; алдар борчагын чәчү; арпа күрсәтеп бодай саткан; арыш камчылау; кычыткан чыпчыгы; тигәнәк белән сырганак; нарат сагызы булу; имәндә икән чикләвек; кабак йоту; каен җиләге түгел лә; суган сату; шалкан бәясе; кәбестә кебек киенү; кәкре каенга терәтү; кыяр карачкысы;чыршы колак; үлән астыннан ут йөртү; әрекмән шулпасы эчмәгән; әремгә таяну.*

8. Табигать күренешләре (*ай, кояш, җил, давыл, яңгыр*): *ай бирде, кояш алды; ай битен юды; айлар батып, чулпаннар калыкканчы; ай тотылу; ак яңгыр; боз кузгалу; боз яуган көнне туган; болыт баскан, яңгыр яварга тора; болыт чәйнәп, боз бөркәнгән көннәр; буран туздыру; гарасат кайнау (кубу, кубару); дала давылы кебек; кара явым; карга бураны; сыерчык бураны; чатнама суык.*

9. Саннар: *алты колак, дүрт күз белән; бер сүзгә килү; ике ут арасында калу; мең дә берне белү; биштән үткән, бишектән чыккан; берсен көйләп, икенчесен сөйләп, өченчесен чөйләп; кырык ямаулы; җиде ят; ике сөйләмәү; дүрт куллап; үз туксаны – туксан; унҗиде яшьлек җилкенчәк; йөзе белән кайтару; бер колактан керә – икенчесеннән чыга; артына бер төшеп, алдына биш төшеп; берәү таба, бишәү каба; береӊ арба юлыннан, береӊ чана юлыннан; кырыкмаса кырык; туксан тугыз; йөз дә бер.*

10. Төс атамалары: *ак күңел; ак бәхет; ак белән караны аеру; ак йөземне сары алды; акка кара белән язылган; бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән өч карга шикелле; кара акыл; зәңгәр күзлек аша карау; зәңгәр фирәзәм; йомырка эчендәге сары кебек; безгә дөнья кармазин* (кызгылт төс); *йөзе кызыл комач япкан кебек; кызыл кар яугач; яшел елан; яшел урам.*

11. Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр: *айкап җибәрү; айкап чыгу; алып та ега, чалып та ега; бармакка бармак та сукмау; барса кайтмас; барыр җир, басар тау калмау; басмаган, сукмаган, какмаган ишек калмау; баш кагу; ике кул болгап; инә өстендә бию; йодрык күтәрү; казып чыгару; кая басканын белми; кулы ут уйный; пычракка салып таптау.*

12. Тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр: *ак келәт; акча кою; аннан ит тә юк, сөт тә юк; базары калмау; (башы) карабодай саламы белән япкан; булмаганда арыш икмәге дә күмәч; бәйрәм ашы; бәлешнең төбе, чананың түре; итәк-җиң бөтәйтү; казан төбе кызганчы; ишегалдында кычыткан үстерми; каз биреп үрдәк алу; каккан казыгы да юк; мич ашы; балта сораганга шөшле тоттыру; такта чәем, якты чыраем.*

13. Ялгызлык исемнәре: *Акбүз ат; Ялгыз Ярулла; Кырым чирүе кебек; Балык Бистәсе – ун тиен дистәсе; Болгар олтан; Бохара мәчесе; Габдел корсак; Габдулла биясе; Дусай сумасы; Закуан лапасы; Идел суы илле батман; Каф тавы; Мәскәү күренә; Таза Мортаза; ушсыз Микуш; Чистай хәерчесе; Казан ятиме.*

14. Алмашлыклар: *алай-болай иткәләгәнче; алай гына барып чыкмый; анда минем ни эшем бар; анда синең ни эшең бар; андай гына [гаеп] мулла кызында да була; андый-мондый хәл булу; аннан бер, моннан бер; бездә дә бер кояш чыгар әле; бездә булмас гаеп, үзегездән чыкмасын таеп; бер аягың монда, берсе анда; бүген миндә, иртәгә синдә; мин минме икән, мин кем икән; син бел дә мин бел; үзе баш, үзе муен.*

Фразеологик әйтелмәләрдәге алынма сүзләрнең төп өлешен гарәп-фарсы алынмалары алып тора. Тематик яктан түбәндәге киң таралган төркемнәрне аерып була:

1) дин белән бәйле сүзләр кулланылган фразеологизмнар: *адәм галәйһиссәләм киемендә; адәм шайтаны; азан әйтми камәт төшермиләр; акча өчен җанын саткан; алганда – бисмилла, биргәндә – әстәгъфирулла; алдында сәҗдә кылу; Алла әҗерен бирсен; алырсың шайтаннан иман; амин тотып торучы;*

2) фән һәм мәгариф өлкәсенә караган сүзләр кулланылган фразеологизмнар: *әлифне таяк дип тә белмәү; китап корты; китап мактый; каләме үткен; каләм йөгертү; каләм әһле; замирын кайтару; гыйлемгә бай, фикергә бай;*

3) кешенең эчке һәм тышкы сыйфатларын, психологик кичерешләргә бәйле төшенчәләрне белдерүче сүзләр кулланылган фразеологизмнар: *адәм кыяфәте калмау; адәм рисвае итү; Алла мәхлугы; вәкарь саклау; вөҗдан сату; гадәтен куа; дөньядан гафил яту; ике талигале;*

4) төрле өлкәләргә караган конкрет һәм абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр кулланылган фразеологизмнар: *адәм акылы; акылга муафыйк; акылга зәгыйфь; акылы хәзинә; акылы камил; акылын-фигылен белү; алдына килгән бәхеттән колак каккан; Алла шаһит; анда теләсә дөнья асты өстенә килсен;*

5) көн исемнәре кулланылган фразеологизмнар: *берсе чәршәмбегә, берсе дүшәмбегә (җомгага) караган* (күз турында); *чәршәмбе йомыркасы өшкереп йөрү; шимбәне үтмичә, җомганы көтмичә йөрү; я җомга түгел, я шимбә түгел; ни атна, ни шимбә; булмаса да булмый икән шимбә базарында төче күмәч;*

6) вакыт төшенчәләрен белдергән сүзләр кулланылган фразеологизмнар: *алтын дәвер; бер дә бер заманны; замана баласы; сәгате белән;*

7) ялгызлык исемнәр кулланылган фразеологизмнар: *ала-кола Габбас кода; Алапай белән Шалапай* (алапа – гар. ганимәт, трофей; шалапай – әзер табынга бәзер булып йөрүче бушбугаз); *ел елга, ел Мөхәммәткә җиткәндә*; *Гали кылычы кебек; Ихсан тәкәсе; син дә мин, Мөхәммәт Әмин; сират кИчереп, Фирдәвестә утыргандай; Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни.*

Рус һәм рус теле аша кергән алынмалары кулланылган фразеологизмнар: *акчасыз фатир; акча үзе образауный; интеллигент җыбыткысы; гайкасы бушаган; граммофоныңны күтәр дә ычкын; законга сыймый; закон сату; замаска булды; йодрык дискуссиясе кору; конфузга калу; карандаш очына алу; кара реакция; келәймә сугу; коеп куйган кәртинкә; кәнитилле эш; мода артыннан чабу.*

Соңрак чорларда кергән һинд-европа алынмалары кулланылган фразеологизмнар: *аклы ситсы; ак офицер* (алман теленнән)*; Адисон (Эдисон) уты* (инглиз теленнән)*; гернадыр (гренадер) кебек* (француз теленнән)*; Гиппократ оныклары* (Гиппократ – мәшһүр грек врачы)*; Эзоп теле* (Эзоп – борынгы грек мәсәлчесе); *акылың әфләтун* (Әфләтун – Платон, борынгы грек галиме); *сардоник көлү* (итальян теленнән).

Алда күренгәнчә, татар телендә барлык мөстәкыйль сүзләр дә фразеологик әйтелмә оештыруда бертигез дәрәҗәдә катнаша алмый. Кайбер лексик берәмлекләр фразеологизм төзү мөмкинлеگеннән тулысынча мәхрүм. Тотрыклы сүзтезмәләр беренче чиратта халык телендә актив кулланылган, телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткән һәм килеп чыгышы белән төрки-татар булган сүзләр хисабына барлыкка килә. Бу сүзләр тематик яктан да чикләнә, төп составны кешеләрнең иҗтимагый тормышында һәм көнкүрешендә булган төрле күренешләрне, вакыйгаларны, предметларны, затларны, төрле сыйфатларны, гамәлләрне, эчке кичерешләрне атаучы сүзләр тәшкил итә. Кайбер сүзләр фразеологизм ясауда аеруча актив, мәсәлән, *ай, көн, кеше, баш, йөз, күз, койрык, колак, кул, йөрәк, күңел, тел, сүз, дөнья, корт, май, шайтан, ак, кара, кызыл, бер, ике, җиде, мин, син, үз, булу, күрү* кебек сүзләр берничә фразеологизм составына кергәннәр.

Пассив лексикадан архаизмнарның һәм тарихи сүзләрнең күплеге, фразеологизмнарның борынгы заманнарда ук барлыкка килеп, озын тарихи үсеш юлы үтүе белән аңлатыла. Кайбер тари-

хи сүзләрнең мәгънәләре бүгенге көндә бөтенләй аңлашылмый. Дөрес, бу төр фразеологизмнар кайчандыр ирекле сүзтезмәләрдән килеп чыккан дигән фараз бар. Мәсәлән, *киләп сарып йөрү* берәмлеге файдасызга эшләмичә яисә ниндидер шикле, ярамас ният белән ике арада бара-кайта, керә-чыга кат-кат йөрүчеләрне өнәмичә әйтелә. Бу әйтелмәнең барлыкка килүе элек татарларда нык үсеш алган тукучылык һөнәре белән бәйле. Орчыктагы яки йомгактагы җепне япьле итеп киләп агачына сарганнар (ягъни чорнаганнар). Аңлашылганча, җеп сарып йөрүче кешегә, кулына йомгак тоткан хәлдә, киләп агачы янында арлы-бирле йөреп торырга кирәк булган. Әнә шуны «киләп сарып йөрү» дигәннәр. Ә бүгенге көнгә кадәр сакланып, телебездә актив кулланыла торган берәмлекнең мәгънәсенә бөтенләй капма-каршы эчтәлек салынган. (Мәхмүтов, 2008: 198–199). Хәзерге телдә искергән сүзләр яңа фразеологизмнар төзүдә катнашмыйлар.

Фразеологик әйтелмәләр составында неологизмнарның булуы – гайре табигый хәл. Халык телгә яңа килеп кергән сүз белән тотрыклы сүзтезмә ясарга ашыкмый, бу сүз күбрәк термин составында туры мәгънәсендә генә яши. Тора-бара составлы термин фразеологизм булып китәргә дә мөмкин, ләкин бу вакытта ул, фразеологизм составында ныгып өлгергәнче, үзенең яңалык төсмерләрен югалта. Тотрыклы сүзтезмәләр составында шулай ук халык телендә киң таралыш тапмаган диалект сүзләр, профессионализмнар, терминнар, жаргон сүзләр, чит тел алынмалары, халыкара сүзләр сирәк очрый яки бөтенләй юк. Татар телендә абстракт исемнәр фразеологик әйтелмә ясауда пассив позициядә тора. Мәсәлән, *ягымлылык, канәгатьсезлек, басынкылык, игътибарлылык, арзанлык, бүленүчәнлек, дымлылык, тынлык, төшенкелек, күңелсезлек, язучылык, мөмкинлек, зарурлык* һ.б. сүзләр белән фразеологизмнар табып булмый.

## § 47. Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килү юллары һәм чыганаклары

Теләсә нинди телне бөтен нечкәлекләре белән үзләштерү өчен, аның лексикасын һәм грамматикасын гына өйрәнү аз. Һәр телнең үз афористик хәзинәсе бар, әнә шул хәзинә телнең матурлыгын билгели, алай гына түгел, шул телдә сөйләшүче халыкның милли аңын, омтылышларын, күңел нечкәлекләрен ачып бирә.

Шуларга карап, теге яки бу чорда әдәби телнең торышын, үсеш дәрәҗәсен билгели алабыз.

Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килүе иң борынгы заманнардан ук башланып, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Аларның барлыкка килүен галимнәр иң элек кешеләрдә абстракт, шулай ук метафорик уйлау сәләте үсү белән бәйләнгән дип исәплиләр. Ягъни фразеологизмнар әйберләрне, күренешләрне бер-берләренә охшату, чагыштыруга нигезләнгән. Мәсәлән, *тозсыз сүз* дигән тезмә тозсыз аш (ашамлык) белән чагыштырудан килеп чыккан (Әхәтов, 1995: 41).

Фразеологик әйтелмәләрнең төп өлеше, чыннан да, ирекле сүзтезмәләрнең метафорик мәгънәдә кулланылуы нигезендә барлыкка килә: *алтын кеше; бәлеш авыз; бугазыннан тотып алу; түшәмгә төкереп яту; сукыр тавык; тавык йөрәк; тавышы таш яра; таш маңгай; таш күңел; озын куллы; пычрак авыз; сәнәктән көрәк булган; тукмак борын; чиләгенә капкачы; кара эчле; колагы – ишек, авызы – капка* һ.б.

Кайбер составлы терминнар фразеологик әйтелмә булып китәләр. Бу очракта алар, үзләренең туры мәгънәләрен югалтып, күчерелмә мәгънәдә кулланылышта йөриләр, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык кебек билгеләргә ия булалар. Мәсәлән: *кызыл юл; нәсел агачы; салкын сугыш; тел алу; йөз сиксән градуска әйләндерү; фундамент салу; сару кайнау; тавык күзе.* Фразеологик әйтелмәләрнең хасил булу чыганакларын икегә бүлеп карап була: татар теленең үз җирлегендә барлыкка килгән берәмлекләр һәм алынмалар.

Татар халык мәкальләре, кыскартылып, фразеологизм буларак кулланыла башлыйлар, мәсәлән, *ата малы улга йокмас; йөрәккә боз булып утыру;авыз пешү;баш бетү; бүрәнә аша бүре күрү;күз чыгу;акка тук яшәү; ботка пешмәү; маңгай йолдызлы булу; ике тәкә башы; кан тарту; чанасына утыру* кебек берәмлекләрнең чыганагы булып *Үзебез тапкан мал түгел, атай тапкан җәл түгел; Маңгайдан аккан ачы тир табанга җитсә тоз булыр, колактан кергән ачы сүз йөрәккә җитсә боз булыр; Авызы пешкән – өреп кабар; Баш бетмәсә, мал бетмәс; Өйдә утырган түрә бүрәнә аша бүре күрә; Сүз артыннан сүз чыга, күп сөйләсәң – күз чыга; Бер тарыдан ботка пешми; Маңгаең йолдызлы булса, бүрегең кондызлы булмаса да ярый; Ике тәкә башы бер казанга сыймый; Җан*

*тартмаса, кан тарта; Кем чанасына утырсаң, шуның җырын тыңларсың* мәкальләре санала.

Фразеологик әйтелмәләрнең бай чыганагы булып халыкның җанлы сөйләме исәпләнә. Аларда кеше тормышының төрле яклары чагылыш таба. Мәсәлән, көнкүреш, көндәлек тормыш белән бәйле фразеологизмнар: *су язып, май төшерү; мүкләк сыер; башына тай типмәгән; аягыңа сыер басмаган;ат ачуын тәртәдән алу; аның талканы коры*; *аш ашка, урыны башка; беленеңне белеп из; бер тырмага ике тапкыр басу; ите синңа, сөяге миңа; морҗадан төтен чыгару; башта борчак үстерү; тозсыз әлбә; чиләгенә күрә капкачы.*

Төрле эшчәнлек даирәләренә караган фразеологизмнар бихисап, мәсәлән, һөнәрчеләр теленнән кереп калган фразеологизмнар: *башыңа төшсә, башмакчы булырсың; кәнитилле эш; киләп сарып йөрү; бау урынына ишү; бура батыру; йон урынына тетү; йорт күтәрү; йорт тергезү;* игенчелек белән бәйле берәмлекләр: *башакка да юк, саламга да юк; без дә сөрдек; бодайдан борайны аера белмәү; борчак сибү; борчак чүмәләсе төсле ишелгән; кара пар; учма төшерү;* терлекчелек белән шөгыльләнү түбәндәге фразеологизмнарда күренә: *йон да юк, сөт тә юк; кара мал; сыер урынына кәҗә саву; кәҗә савып көн күрү; сарык көтүе; бәрән йонын алдыру;* аучылык, балыкчылык белән бәйле фразеологизмнар: *атасы болан атмаганны, баласы куян атмас;кулга иyләштерү; бер атар мылтык; бер атканда ике куян; болганчык суда балык тоту; кармакка эләгү; кармак йоткан балык кебек.*

Татар халкының төрле ышанулары һәм гореф-гадәтләре шулай ук фразеологик әйтелмәләрдә чагылыш тапкан: *бүресе улау; йолдыз атылу; елан мөгезе; җен алыштырган; аягүрә ашарга карга боткасы түгел бу; ант эчү; бүләк багу; бүрек белән бирсәң егылмаслык булган; Вәли вәкил; дөм-дөмгә төшү; карга боткасы; колагын тешләтеп кую; май чабу; мактап йөрисең; уч төбе кычыту; хозур җыю; хәер-фатиха бирү; яңгыр боткасы.*

Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә ант эчү берәмлеге бар: *Сәясәтне йөриткәймен тию шаһ / Бу сүз үзрә тәлим* ***ант эчте*** *нәгәһ.*

Хәзерге телдә *ант эчү* фразеологизмы «ант итү» мәгънәсендә кулланыла. Элек төркиләрдә ике кеше гомерлек дус булырга ант бирешкәндә, шуның билгесенә һәр ике дус, үз кулларын кисеп,

бер савыт кымызга каннарын тамызып эчкәннәр, бу ант эчү дип аталган һәм бу дуслар ант эчешкән – мәңгелек дус һәм кан кардәш хөкемендә булып, алар бер-берсе өчен җан бирешкәннәр. (Исәнбәт, Т. 2, 1990: 78). Әлеге фразеологизмның барлыкка килүе шушы йола белән бәйле.

Шулай ук татар тормышындагы игътибарга лаек вакыйгалар яки күренешләр, тотрыклы сүзтезмәләр рәвешендә сакланып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән: *Лаеш шулпасы эчү; Бәдигъ мәзин күркәсе; Бакыр бабай бакчасы; Балык Бистәсе – ун тиен дистәсе; Закуан лапасы; Ихсан тәкәсе.*

*Лаеш шулпасы эчү* фразеологизмы, мәсәлән, Казан янындагы Лаеш авылына якын юл өстендәге баткаклык белән бәйле. Бу сазлыкны eрактан әйләнеп йөрергә теләмәгән юлчыларның күбесе шунда батып яткан. Бу җәфага дучар булу «*Лаеш шулпасы эчү*» дип йөртелгән һәм хәзерге телдә «тормышта зур авырлыклар кичерү, нужаны күп күрү» мәгънәсендә йөртелә (Исәнбәт, 1990, т. 2: 7).

*Бер нужа чигеп, **Лаеш шулпасы эчеп** кайтса, китәм дигән тыны булмас иде*. (А. Гыйләҗев)

Фразеологик әйтелмәләрнең килеп чыгышы татар дөньясындагы тарихи вакыйгалар белән бәйләнгән: *«алтмыш кадак»лар; ишетмәсәң ишет, идән асты кишет; Кырым чирүе чаклы; иман сату; иске бистәне кузгату; лашман тарту; мең башы; сәнәк сугышы*.

Фразеологизмнарның шактый өлеше халык авыз иҗаты әсәрләреннән алынган, мәсәлән, татар халык әкиятләреннән телгә түбәндәге тотрыклы сүзтезмәләр үтеп кергән: *су анасы; акбүз ат; алаймы булган, болаймы булган; алтмыш колач алайгыр; кәкре каенга терәтү; башын алса, койрыгы ябыша; койрык бозга бату; иләк белән су ташу; камыр батыр; урман сарыгы; сихерче карчык;* мәзәкләрдән кергәннәре дә бар: *анысы әле баласы, мич башында ята анасы; үзең утырган ботакны кисү; бер адым алга, ике адым артка; аңа бар да «кырыккан»; арыслан тотарлык кына эчү; былтыргы «А»; йә ишәк, йә патша үлә; ни башына ни кунган; пәри башка, җен башка* һ.б.

Кайбер фразеологизмнарның килеп чыгышы матур әдәбият әсәрләренә барып тоташа: *сертотмас үрдәк* (А. Алишның шул исемдәге әкиятеннән); *вәссәлам – чут тәмам* (Г. Хаҗибәковның «Аршин мал алан» әсәреннән); *Габделбасыйр гыйшкы*

(Ф. Әмирханның шул исемдәге хикәясеннән); *Галиәкбәр кантуры* (Ш. Мөхәммәдов. «Җәһаләт, яки Галиәкбәр агай хикәясе»).

Башка телләрдән фразеологизмнарның күп өлеше калькалаштыру юлы белән кабул ителә: *шестое чувство – алтынчы тойгы;медвежья услуга – аю хезмәте; открыть Америку – Америка ачу;все дороги ведут в Рим – барлык юллар Римга илтә; родился в рубашке – күлмәктә туган; красная строка – кызыл юл; играть на нервах – нервыда уйнау; сжечъ за собой мосты – күперләрне яндыру; пора ставитъ точки – нокта куярга вакыт җитте; железный занавес – тимер пәрдә; об этом история умалчивает – ансы турында тарих эндәшми; семь пятниц на неделе – атнасына биш җомга; по последнему слову – соңгы сүзе буенча; муки творчества – иҗат газабы; играть вторые роли – икенче рольләрне уйнау; первая скрипка – беренче скрипка; взять на мушку – мушкага алу; кайнар линия – горячая линия* һ.б.

*Нинди төрмә ди ул? Нигә дип* ***чебеннән фил ясыйбыз****?* (В. Имамов); *Безне косметиканың* ***соңгы сүзе буенча*** *бизәнгән бер ханым каршы алды.* (А. Расих); *Ул өйгә кайтып кердеме, шулай* ***иҗат газабы*** *кичерә.* (А. Расих); *Күптән түгел генә Татарстанның Роспотребнадзор идарәсе әлеге проблемага «багышлап» махсус ачылган* ***«кайнар линия»*** *телефоннары буенча беренче нәтиҗәләрне ясады.* (Көндәлек матбугаттан) Бу төр фразеологизмнар рус теленнән яки рус теле аша башка телләрдән алынган.

Фразеологизмнарның кайберләре исә дини чыганакларга (Коръән, Инҗил, Тәүрат) барып тоташа: *сират күпере аша чыгу; ай икегә ярылу; таш ату; сарык тиресе бөркәнгән бүре; Бабил манарасы; ахыр заман; ахирәттә дуңгыз булып кубарылу; ләгънәт камыты кию; Нух заманыннан калган; тәмуг кисәве; тәмуг газабы; хур кызы* һ.б.

Фразеологизмнар барлыкка килү – катлаулы тарихи һәм мәдәни процесс. Халыкның үткәне турында борынгы кульязмалар, кабер ташлары, тарихи язмалар, сәнгать әсәрләре аша гына түгел, ә шул халыкның теле буенча да белеп була. Без элеккеге тормыш, гореф-гадәтләр тудырган сүзләр һәм тәгъбирләр кулланып сөйләшәбез. Фразеологизмнарны белү безнең аңыбызны баета, телне яхшырак өйрәнергә, грамоталы сөйләшергә ярдәм итә, аларны дөрес һәм урынлы куллану сөйләмгә кабатланмас аһәң, төгәллек, образлылык бирә.

## Татар тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне төркемләү

### § 48. Тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне төркемләү мәсьәләсе

Фразеологик әйтелмәләргә бердәм, уртак билгеләмә булмаган кебек үк, аларны төркемләүдә төгәл генә классификация дә юк. Фразеологик берәмлекләрне төркемләүдә тел белемендә төрле принциплар билгеле. Чыннан да, фразеологик әйтелмәләр төзелеш (структура) тотрыклылыгы ягыннан һәм семантикалары белән бердәй түгелләр. Аларның бер төркеме, урнашкан мәгънәләрен саклаган хәлдә, үзләренең стандартлашкан төзелешләрен үзгәртмичә, телдә бары тик бер төзелештә һәм күчерелмә мәгънәләрдә генә кулланылып йөриләр. Ә икенче төркеме исә, составындагы аерым сүзләр үзләренең туры мәгънәләрен саклаган хәлдә, структура үзгәрешенә дә бирешәләр.

Рус тел белемендә фразеологик берәмлекләрне төркемләүнең төрле принциплары билгеле:

семантик принцип (В.В. Виноградов, Д.Н. Шмелёв);

структур принцип (А.И. Смирницкий);

структур-семантик принцип (А.В. Кунин);

функциональ-контекстологик принцип (Н.Н. Амосова);

килеп чыгышы ягыннан (И.И. Чернышева);

стилистик билгеләре буенча (А.И. Ефимов) һ.б.

Кайбер галимнәр берничә классификация тәкъдим итәләр. Мәсәлән, Н.М. Шанский фразеологик берәмлекләрне семантик яктан, морфологик үзенчәлекләре буенча, структур һәм килеп чыгышы ягыннан төркемли (Шанский, 1972: 112).

Иң танылган төркемләүләрнең берсе – В.В. Виноградов тәкъдим иткән семантик классификация. Аның нигезләрен Ш. Балли эшләгән. Әлеге төркемләү күп кенә галимнәрнең фәнни хезмәтләрендә һәм күпчелек дәреслекләрдә бөтенләй диярлек үзгәртелмәгән хәлдә кулланыла.

В.В. Виноградов күрсәтмәләренә нигезләнеп, фразеологик берәмлекләрне берничә яктан төркемләп була: 1) аны төзүче кисәкләрнең мәгънәви-грамматик кушылуы ягыннан; 2) чыганаклары ягыннан; 3) тематикалары ягыннан; 4) стилистик функцияләре ягыннан; 5) лексик составы ягыннан (Виноградов, 1947: 27).

Әлеге төркемләү киң таралган һәм актив кулланылган булса да, аны бик үк төгәл дип кабул итеп булмый, чөнки төркемләү бер генә үзенчәлеккә, ягъни бер генә принципка нигезләнми. Фразеологик ныгымалар белән фразеологик берәмлекләр, чыннан да, семантик принципка таянып төркемләнә, ә фразеологик тезмәләрне әлеге принцип буенча аерып булмый. Бу турыда академик В.В. Виноградов үзе дә әйтә: «Фразеологические сочетания не являются безусловными семантическими единствами. Они аналитичны. В них слова с несвободным значением допускают синонимическую подстановку и замену» (Виноградов, 1947: 27). Шул сәбәпле кайбер очракларда бер үк фразеологизмнарны төрле галимнәр төрле төркемнәргә кертеп карыйлар.

Н.М. Шанский да В.В. Виноградовның төркемләвенә нигезләнә, ләкин, кайбер галимнәр кебек үк, фразеологик тәгъбирләр дигән дүртенче төрне дә өсти. Бу – ирекле мәгънәле сүзләрдән төзелгән, әмма сөйләмгә әзер килеш килеп керә торган әйләнмәләр: *авырлык үзәге*, *гәҗит сүзе* һ.б. Гомуми мәгънә һәр сүзнең лексик мәгънәсеннән җыела.

А.И. Смирницкий исә, фразеологизмнарны төркемләгәндә, бөтенләй башка үзенчәлекләргә таянып эш итә һәм фразеологизмнарны структур яктан икегә бүлеп карый: 1) «бер баскычлы»; 2) «ике (күп) баскычлы».

Беренче төркемгә ул ярдәмлек һәм мөстәкыйль сүз төркемнәреннән торган фразеологизмнарны (*күз алдында, борын төбендә*), икенчеләренә исә ике яки аннан да күбрәк мөстәкыйль сүзе булган берәмлекләрне кертә (Смирницкий, 1956).

Структур яктан төркемләүне шулай ук башка галимнәр дә хуплыйлар: Н.Н. Амосова, В.Л. Архангельский, А.В. Кунин, А.М. Бабкин, Н.М. Шанский.

Өченче төрле классификацияне Б.А. Ларин тәкъдим итә. Аның фикеренчә, фразеологизмнар бары тик тарихи планда гына өйрәнелергә тиеш. Ул фразеология составында өч төрле берәмлекне аерып чыгара:

1) гади (үзгәрүчән, «ирекле») сүзтезмәләр;

2) тотрыклы метафорик сүзтезмәләр (В.В. Виноградов һәм Н.М. Шанскийдагы «фразеологик бердәмлек»ләргә туры килә);

3) идиомалар (В.В. Виноградов һәм Н.М. Шанскийдагы «фразеологик ныгыма»ларга туры килә) (Ларин, 1956: 222).

Н.Н. Амосова, фразеологизмнарны төркемләгәндә, бер генә үзенчәлеккә нигезләнергә кирәк, ди һәм фразеологизмнарны контекстологик принцип буенча ике төркемгә бүлеп карый:

1) фраземалар;

2) идиомалар (Амосова, 1963: 191).

Татар тел белемендә фразеологизмнарны төркемләү мәсьәләсенә күзәтү ясаганда, төрле һәм урыны белән каршылыклы фикерләргә юлыгабыз. Мәсәлән, татар галимнәренең фразеологик әйтелмәләрне компонентларының семантик берләшүе, катнашуы дәрәҗәсенә карап төркемләүдә уртак фикернең булмавы сизелә.

Г.Х. Ахунҗанов идиомаларның бердәмлек һәм берекмә дигән төрләрен аерып чыгара. Идиоматик бердәмлек – тулаем күчерелмә мәгънәле һәм эчке формасын югалтмаган әйтелмә. Аны компонентларының беренчел мәгънәләреннән яисә якынча чамалап аңлап була. Мисаллар: *җил куу; алтын куллы; сусыз юып, җилсез киптерү; теле булмаса, күптән карга күтәреп китәр иде; акылы алтын икән* һ.б.

Идиоматик берекмәнең эчке формасы югалган була, аның мәгънәсен составындагы сүзләрдән чыгып кына аңлап булмый. Мондый мәгънә традиция буенча гына күчә килә. Мисаллар: *ваз кичү* – «баш тарту», *бәладән баш-аяк* – «кирәге юк, аның белән бәйләнмәвең хәерле», *тузга язмаган* – «кеше ышанмастай», *теңкә кору* – «бик җәфалану», *сөмсере коелу, борчак пешмәү, серкәсе су күтәрмәү* һ.б. (Ахунҗанов, 1972: 14–15).

Г.Х. Әхәтов татар телендәге фразеологик әйтелмәләрне ике төркемгә бүлеп карый: 1) идиомалар, 2) фразеологик тезмәләр.

Идиомалар – структураларын үзгәртмичә саклый һәм күчерелмә мәгънәдә генә кулланыла торган фразеологик әйтелмәләр. Галим аларның ике төрен күрсәтә: факультатив идиомалар һәм даими идиомалар. Факультатив идиомалар бер контекстта идиома, икенче контекстта иректе сүзтезмә буларак кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *«Чулпан»ның эше бик тиз үргә менеп китте*. (Г. Бәширов) һәм *Ул җәяүләп үргә менеп китте* җөмләләренең беренчесендә *үргә менеп китте* – идиома, чөнки күчерелмә мәгънәдә кулланылган, «Чулпан» колхозындагы эшнең алга китүен аңлатып килгән; икенчесендә исә идиома була алмый, чөнки ул монда туры мәгънәдә генә файдаланылган. Г.Х. Әхәтов әйтүенчә, сүзтезмәләрнең, үз контекстларыннан аерылып, икенче

контекстта күчерелмә мәгънәдә кулланыла башлаулары идиоманы барлыкка китерә.

Икенче төр идиомалар – даими идиомалар, алар контекстка бәйле түгел, теләсә кайсы контекстта идиома булып торалар, мәсәлән: *кылны кырыкка яру, арага кыл сыймау, арт сабагын укыту, түбәсе күккә тию, көлен күккә очыру, баш вату*. Димәк, соңгыларын ирекле сүзтезмә итеп куллану мөмкин түгел.

Фразеологик тезмәләр компонентларының лексик бөтенлекләрен саклыйлар һәм бербөтен төшенчә белдерәләр. Алар, нигездә, бер үк конструкцияләрне сөйләмдә күп файдалану нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, телдә күп кулланылу нәтиҗәсендә катып калалар. Функцияләре ягыннан сүзгә эквивалент булып торалар һәм бер җөмлә кисәге булалар. Идиомалардан аермалы буларак, аларга образлылык хас түгел. Мисал итеп *бизгәк тоту* фразеологизмы китерелә. Беренчесендә *бизгәк* сүзе төп мәгънәне белдерә һәм тезмә составында үзәк урынны алып тора. Ә *тоту* сүзе төп мәгънәдә түгел, өстәмә мәгънәсендә кулланылган. Димәк, монда *тоту* сүзенең куллану даирәсе тарая. *Бизгәк тоту* тезмәсенең компонентлары үзара шундый берегеп киткән ки, алар һәрвакытта бергә йөриләр, бергә кулланылалар.

Г.Х. Әхәтов фразеологик тезмәләрнең фразеологик штамп һәм фразеологик берәмлек төрләрен дә аерып чыгара. Фразеологик штамплар, башлыча, сөйләүченең сөйләмгә төрлечә мөнәсәбәтен чагылдыралар: *шуның белән бергә; бер-бер артлы; озын сүзнең кыскасы; әзергә хәзер; иш өстенә куш; бер дә бер; чүп өстенә чүмәлә; сәгатьтән сәгатькә; шатлык шатлык белән; эткә этчә; ни ылтара ни пылтара; көн артыннан көн; чәй чәй урынына*. Фразеологик берәмлекләр, галим фикеренчә, мөстәкыйль рәвештә күп куллану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аларны, гадәттә, бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз тәрҗемә итеп булмый. Мәсәлән: *ай тотылу; күңел болгану; эч пошу; йөрәк яну; таң ату; юл тоту; башка чыгу; кул чабу; кысыр калдыру; берне биш иту*. Шулай ук Г.Х. Әхәтов фразеологик берәмлекләргә атамалар функциясен үти торган күп сандагы составлы терминнар керергә тиешлеген дә ассызыклый (Әхәтов, 1995: 61–67).

В.Х. Хаков, фразеологик әйтелмәләрне төркемнәргә бүлгәндә, аларның мәгънәләрендәге төрле үзенчәлекләрне истә тотып эш итә һәм фразеологик ныгымаларны, фразеологик тезмәләрне

аерып чыгара. Фразеологик әйтелмә составындагы компонентларның аерым-аерым мәгънәләре белән шул әйтелмә белдерә торган гомуми мәгънә арасында бәйләнеш булмаса, фразеологик нығыма барлыкка килә. Мәсәлән: *кот очу; сару кайнату; борчак ату; җик күрсәтү; Лаеш шулпасы эчү; ләчтит сату; сөмсере коелу; теңкәгә тию; сөрән сугу*. Фразеологик әйтелмәдәге сүзләр белән аның мәгънәсе арасында турыдан-туры бәйләнеш булса, фразеологик тезмәләр оеша. Мәсәлән: *акыллы баш; акылдан язу; җилгә очу; гомерем таңы; борын күтәрү; койрык болгау; күңел суыну; акыл теше; тамак ялгау* һ.б. (Хаков, 1999: 154–155).

З.М. Вәлиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле» хезмәтендә фразеологик әйтелмәләр, В.В. Виноградов төркемләвенә таянып, төп өч төркемгә бүленә: фразеологик нығымалар (яки идиомалар), фразеологик бөтеннәр һәм фразеологик тезмәләр.

Галим фикеренчә, фразеологик әйтелмәләрнең башка төрләре белән чагыштырып караганда, фразеологик нығымалар элегрәк барлыкка килергә тиеш, чөнки аның составындагы кайбер сүзләрнең нәрсә аңлатулары, нинди төшенчәдә йөрүләре дә хәзер мәгълүм түгел. Мәсәлән, *ләчтит сату*; *сару кайнату*; *теңкәне корыту*; *сөмсере коелу; гарык булу* кебек нығымалар составындагы *ләчтит*, *сару*, *теңкә*, *сөмсер* сүзләренең конкрет төшенчәләре хәзер билгесез, алар аерым сүз буларак кулланылмыйлар.

З.М. Вәлиуллина, лексик төзелешләре ягыннан чыгып, фразеологик нығымаларны ике төркемгә аерып карый:

1) составындагы кайбер сүзләрнең конкрет, реаль мәгънәләре югалган яки аерым кулланылмый торган нығымалар (*кот очу; шыр җибәрү; пыр туздыру* һ.б.);

2) составындагы кайбер сүзләрнең конкрет, реаль мәгънәләрен югалтмаган, ләкин идиома бөтен килеш белдерә торган төшенчәгә һичбер мөнәсәбәте булмаган нығымалар (*Лаеш шулпасы эчү; салпы ягына салам кыстыру; серкәсе су күтәрми* һ.б.).

Иң күпчелек очракта фразеологик бөтеннәр аерым сүз тезмәләренең күчерелмә мәгънәдә йөрүләре нәтиҗәсендә теге я бу төшенчәгә берегеп калганнар. Мәсәлән: *кызыл кар яугач; утлы табага бастыру; кеше кубызына бию; арт сабагын укыту* һ.б.

Фразеологик тезмәләр составындагы сүзләр күп очракта әйтелмәнең үзендәге гомуми төшенчәне турыдан-туры белдерәләр, ягъни аерым-аерым сүзләрнең мәгънәләре белән тулаем төшенчә мәгънәсе

арасындагы тыгыз бәйләнеш, уртаклык була. Фразеологик тезмәләрнең туры мәгънәләре дә, күчерелмә мәгънәләре дә күп очрый.

З.М. Вәлиуллина фразеологик тезмәләрне түбәндәге төркемнәргә бүлә:

1. Халыкның җанлы сөйләмендә киң кулланыла торган ныгыган сүз тезмәләре: *башка тай типмәгән; акылдан язу; күктәге торнага ышанып, кулыңдагы кошны очыру; суга төшү; җеп нечкә җиреннән өзелә;күңел суыну; авызыңнан җил алсын; ерак куйсаң, якын алырсың; сабыр төбе – сары алтын* һ.б.

Бу төркемгә шулай ук күчерелмә мәгънәдә кулланыла торган ике кисәкле сүз тезмәләре дә керә: *акыллы баш; башлы кеше; акылга сай; ачык авыз; тавык баш; йөрәк яргыч; җилле кеше; гайбәт капчыгы; чыбыксыз телефон; яшьлек иртәсе; борын күтәрү* һ.б.

2. Составындагы компонентлар, туры мәгънәсендә булып, конкрет төшенчәләргә беркетелгән ныгыган сүз тезмәләре. Бу төркем фразеологик тезмәләр, гадәттә, эмоциональ-экспрессив төсмерләргә ия булмый: *акыл теше; урт теше; акылдан язу; чебен гөмбәсе; сорау билгесе; ял йорты; сүз башы; ай башы; агач башы; ачу килү; тамак ялгау; батыр йөрәк; күз акайту; колак тону* һ.б.

3. Административ-политик, топонимик-географик төшенчәләрне белдерә торган ныгыган сүз тезмәләре: *Берләшкән Милләтләр Оешмасы, Байкал күле, Кара диңгез, яңа тарих, экономик география, политик география* һ.б. (Вәлиуллина, 1965: 72).

Ф.С. Сафиуллина фразеологизмнарның төп мәгънәләре буенча өч төрен аера.

Беренче төркемгә мәгънәләре атау характерында иректе булган тезмәләр кертелә һәм *пәйгамбәр тырнагы* дигән мисал китерелә. Галим фикеренчә, әлеге «чәчәк атамасын белдерүче фразеологизмда сүзләр чынбарлыкта логик яктан бик төрле. Бу үсемлек матур, сары, куе сары, биек булырга мөмкин; аны утыртырга, үстерергә, вазага куярга мөмкин, әмма бу үсемлек исемен белдергән сүзнең төп мәгънәсе нык үзгәргән» (Сафиуллина, 1999: 136).

Икенче төркем фразеологизмнарның башка сүзләргә бәйләнеше фразеологик бәйле була. Мәсәлән, *җан-фәрманга чабу* тезмәсендә беренче компонент *чабу* сүзе белән генә бәйләнешкә керә ала – *җан-фәрманга ашау* дип булмый. *Баш бармагым шикелле* дигән тезмәдә беренче өч сүз *беләм* сүзе белән генә кулланыла һәм аерым бер мәгънә белдерә. Бу сүзләрнең бәйләнешләре

предметлы һәм логик бәйләнештән чыгып түгел, ә хәзерге телнең лексик-фразеологик системасыннан, аның тарихи үсешеннән килеп чыккан (Сафиуллина, 1999: 36).

Өченче төр фразеологизмнарның синтаксик бәйле мәгънәләре була. Ул мәгънәләр теге яки бу җөмлә кисәге (хәбәр) функциясендә генә реальләшә: *акча тора; ак сакаллы карт булыр идең; үзеңә дошман түгелсең; бәласеннән башаяк; син күр дә мин күр; акмаса да тама; акча җимеше түгел, бакча җимеше* (Сафиуллина, 1999: 36).

Татар тел белемендә дә фразеологизмнарны төркемләүдә катгый кабул ителгән калыплар күзәтелми. Фразеологизмнарның табигате үзенчәлекле һәм каршылыклы булганлыктан, аларны аерып караганда, ниндидер бер принципка гына нигезләнеп эш итәргә ярамый. Киресенчә, фразеологизмнарның асылын чагылдыру өчен, аларны төрле яклап карарга һәм төрле принципларга таянып төркемләргә кирәк. Алда тәкъдим ителәчәк классификацияләр татар фразеологизмнарының структур-семантик асылына төшенергә, стилистик мөмкинлекләрен ачарга, образ тудыру үзенчәлекләрен күзалларга ярдәм итәчәк:

1) компонентларының семантик берләшүе, катнашуы дәрәҗәсенә карап;

2) стилистик функцияләре һәм стилистик бизәлеше ягыннан.

## § 49. Фразеологик әйтелмәләрне компонентларының семантик берегүе, катнашуы дәрәҗәсенә карап төркемләү

В.В. Виноградов өйрәтүе буенча, компонентларның берегү дәрәҗәсенә карап, фразеологизмнар өч төркемгә: фразеологик ныгымалар, фразеологик бердәмлекләр, фразеологик тезмәләргә бүлү татар теле фразеологизмнарына карата да уңышлы дип табыла. Бу фикер Ф.С. Сафиуллина тарафыннан да раслана (Сафиуллина, 1999: 135–136; 2001: 164–165).

Фразеологик ныгымалар (идиомалар) – составындагы компонентлары бер-берсенә нык береккән һәм андагы сүзләрне алыштырып, төшереп, өстәп булмый торган тотрыклы тезмәләр. Фразеологик ныгымаларда сүзләрнең мөстәкыйль мәгънәләре тулысынча югала, В.В. Виноградов әйткәнчә, «әгәр дә аларның элементлары телнең нинди дә булса мөстәкыйль, аерым сүзләре белән аваздаш икән, бу – бары саф омонимик аваздашлык кына». (Виноградов, 1947: 27). Фразеологик ныгыманы бер сүз белән алмаштырып

була. Бөтеннең мәгънәсе аерым кисәкләрнең мәгънәсеннән килеп чыкмый, һәм еш кына аның составында архаик сүзләр очрый.

В.В. Виноградов төркемләвендәге фразеологик ныгымаларга татар тел белемендә Г.Х. Ахунҗановның фразеологик берекмәләре, Г.Х. Әхәтовның даими идиомалары, В.Х Хаковның фразеологик ныгытмалары туры килә. Мисаллар: *ташка үлчим* – тормыштагы тискәре хәлләрне ырым ташына тиңләп әйтү. *Боларны, **ташка үлчим**, ирем дип йөрергә дә.* (Г. Толымбай); *кикриге шиңү* – кемнең дә тәкәбберлеге, масаюы кимү, мескен хәлгә килүе. *Шуннан инде аның бунтарьлык **кикриге шиңде**.* (Г. Толымбай); *канына тоз салу* – газаплау. *Җүнләп сугышканы юк, халыкның **канына тоз салып** йөрүдән башканы белми* (В. Имамов); *күз буяу* – дөреслекне яшерү. *Миңнеханны мөдирлектән очырмасыннар өчен, **күз буярга** гына чакыргандыр.* (В. Имамов); *ис китмәү* – гаҗәпләнмәү, битараф калу. *Сепараторда сөт аертырга кергән күрше-күлән хатын-кызларының үзара гәпләшүләренә дә әллә ни **исе китми** аның.* (Көндәлек матбугаттан)

Фразеологик ныгымаларны җөмләдә аерым сүз белән дә алмаштырып була, мәсәлән: *ис китмәү* – гаҗәпләнмәү; *үзәккә (үзәгенә) үтү* – бик нык интектерү; *үзәк өзелү* – борчылу, эч пошу; *түшәмгә төкереп яту* – берни эшләмәү; *кырт кисү* – кискен каршы килү; *кот чыгу* – кинәт бик каты курку; *җәнҗал куптару* – ызгыш, низаг, кычкырыш, тавыш күтәрү һ.б. Аларга образлылык хас, ягъни алар әдәби яктан эчтәлеклерәк, аһәңлерәк, тәэсирлерәк.

Фразеологик бердәмлекләр – компонентлары арасындагы бәйләнешләр йомшарган булса да, семантик бөтенлеге һәм структур тотрыклылыгы сакланган тезмәләр. Монда да сүзләр мәгънәви яктан бүленми, бөтеннең мәгънәсен алар бергә бирә. Бу төр берәмлекләрдә образлылык көчле, алар эмоциональ-экспрессив төсмерләр белән сугарылган. Сүзләр, фразеологизм составыннан чыккач, үзләренең туры мәгънәләрендә иркле сүзтезмәләр төзүдә актив катнашалар. Мисаллар: *күз төшерү* – кызыксынып карап алу. *Дания ханымны күрсә, **чылбырыннан ычкына**, ди.* (Н. Гыйматдинова); *Кызның иңнәренә берьюлы ике **канат үсте**.* (Н. Гыйматдинова); *Исем-фамилиягезне мөселманча итеп язганда да хата җибәрүем мөмкин. **Авыз пешкәне** бар.* (Көндәлек матбугаттан)

Фразеологик бердәмлекләрнең иркле сүзтезмәләр белән охшашлыгы алар арасында ассоциатив элемтәләрне урнаштырырга,

күчеш нигезен һәм метафорик фразеологизацияне ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, *Шунда ул бераз читтәрәк, затлы урындыкларда утырган әти-әнисенә карады. Ничектер,* ***кечерәеп калганнар*** *иде алар.* (Г. Гыйльманов) Әлеге җөмләдәге *кечерәеп калу* фразеологизмы «оялу, читенсенү» мәгънәсендә кулланылган. *Киң катлам халык массаларына аңлашылмый,* ***барып җитми торган*** *сүзләр белән эш иткәндә, шулай ук чама хисе кирәк.* (Көндәлек матбугаттан) Биредәге *барып җитми торган* фразеологизмының мәгънәсе – *аңлашылмый торган.*

Ф р а з е о л о г и к т е з м ә л ә р – компонентлары арасында бәйләнеш күпкә йомшак булып, ирекле сүзтезмәләргә бик якын торган тезмәләр. Фразеологик тезмәләрдә бер сүз – туры, икенчесе күчерелмә мәгънәдә килә. Шуңа күрә бөтеннең мәгънәсе өлешләрнең мәгънәләренә шактый бәйләнгән була. Фразеологик ныгымалар һәм фразеологик бердәмлекләр белән чагыштырганда, монда экспрессивлык дәрәҗәсе кимрәк, алар күбрәк предмет-күренешләрне атау функциясен башкаралар. Мисаллар: *бусага таптау* – берәр җиргә йомыш белән еш керү. *Шуннан соң Васыйфа астай ... Салих абзый* ***бусагасын таптый башлаган.*** (Г. Толымбай); *каш сикертү* – яшьләрнең бер-берсенә яшерен ишарә белән ым кагып каш сикертеп куюлары. *...кызларга бер күз* ***кысып каш сикертеп куйсаң*** *хәтәр инде!* (Г. Толымбай); *эч катканчы көлү* – бик каты көлү. *Башта* ***эч катырганчы көлеп тә,*** *аннары сөйләмәскә маташу, билгеле, Гөлҗан ханымга ошамады.* (Г. Толымбай); *ике күз белән карау* – ике төрле мөнәсәбәт белдерү. ***Ленар аларга ике төрле күз белән,*** *дөресрәге, хис белән карады.* (Г. Гыйльманов)

Югарыда билгеләнгәнчә, бер төркем галимнәр фразеологик тәгъбирләр дигән дүртенче төрне өстиләр. Ф р а з е о л о г и к т ә г ъ б и р л ә р дип ирекле мәгънәле сүзләрдән төзелгән, әмма сөйләмгә әзер килеш килеп керә торган әйләнмәләр атала. Мәсәлән, *авырлык үзәге, гәҗит сүзе* һ.б. Алар – «семантик яктан таркалмый гына түгел, ә тулысы белән ирекле мәгънәле сүзләрдән торган» фразеологизмнар (Шанский, 1969: 62). Фразеологизмнарның алда карап үткән төрләреннән фразеологик тәгъбирләр образлылык, сурәт ясау, экспрессивлык дәрәҗәсе ягыннан шактый калышалар. Мисаллар: *чәчәк ату* – үсеш алу. *Татарстанда финанс пирамидалары белән бәйле вазгыять һаман да шактый кискен булып кала бирә. Әлеге оешмаларның* ***чәчәк атуы*** *беренче чиратта халык-*

*ның финанс ягыннан белем дәрәҗәсе түбән булу белән аңлатыла*. (Көндәлек матбугаттан); *сукмак салу* – юл ачу. *Бәкер авылында яшәүче ике малай һәм бер кыз беренче булып шул мәктәпкә* ***сукмак сала***. (Көндәлек матбугаттан); *юллар аерылу* – очрашмый башлау. *Бер-берсен яхшы беләләр. Әмма кыз 7 класстан соң медучилищега укырга кергәч, хат язышып торуларын исәпкә алмаганда,* ***юллары аерыла***. (Көндәлек матбугаттан)

Шулай итеп, татар тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне компонентларының семантик берегүе ягыннан дүрт төргә бүлеп карау кабул ителгән. Фразеологизмнарның структур яктан ныклыгы, бердәмлеге фразеологик ныгымаларда һәм бердәмлекләрдә сизелә, бу төр берәмлекләрнең компонентлары сөйләмдә таркалмавы, башка сүзләр белән алмаштырып булмавы белән аңлатыла.

Фразеологик ныгымалар белән фразеологик бердәмлекләр арасындагы аерма шуннан гыйбарәт: беренчеләрендә логик яктан туры мәгънә юк, яисә ул мотивлашмаган; фразеологик мәгънәнең күчерелмә булуы тарихка мөрәҗәгать итеп кенә беленә; фразеологик бердәмлекләрдә исә туры мәгънә дә, күчерелмә мәгънә дә бар, һәм алар тарихи комментарийларсыз да аңлашыла.

Фразеологик тезмәләрнең семантик бердәмлеге һәм экспрессивлык дәрәҗәсе түбәнрәк, алар ирекле сүзтезмәләргә якын торалар, компонентларын башка сүзләр белән алмаштырып була, бу очракта фразеологик әйтелмәләрнең синонимик вариантлары барлыкка килә.

Фразеологик тәгъбирләр – ирекле мәгънәле сүзләрдән төзелгән, калыплашкан, сөйләмдә әзер килеш кулланыла торган берәмлекләр, компонентлары арасында семантик бердәмлек көчле түгел.

## § 50. Фразеологик әйтелмәләрне стилистик функцияләре ягыннан төркемләү

Фразеологик әйтелмәләр, тел берәмлекләре буларак, халыкның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте, гореф-гадәте, яшәү шартлары, рухи омтылышы, чынбарлыкка мөнәсәбәте, эстетик идеалы белән органик бәйләнгән. Фразеологик әйтелмәләр образлылык һәм экспрессивлыкны арттыра торган мөһим чара да булып тора. Алар әдәби, сәяси, публицистик әсәрләрнең идеясе, мәгънәсе тәэсире көчәюгә хезмәт итә. Шуна күрә алар стилистика фәнендә дә зур вазифа үтиләр.

Функциональ-стилистик яктан фразеологик әйтелмәләр ике зур төркемгә аерымлана: 1) стильара яки нейтраль фразеологизмнар, 2) функциональ яктан береккән фразеологизмнар.

Стильара яки нейтраль фразеологизмнарга, гадәттә, фразеологик тәгъбирләр карый, алар билгеле функциональ стиль белән даими бәйләнештә түгел, алар әдәби телдә дә, сөйләм телендә дә бертигез кулланылышта, экспрессив бизәктән азат, эмоциональ яктан битараф: *күп булса; көн итү; кыш чыгу; йөз тоту; йөз яшәр; исәп тоту; исәпкә алу; алгы сызык; авыр хәл; аек караш; актык гомерендә; актык чиктә; акыл иясе; алга бару; алга сөрү; алга җибәрү; алдан күрү; бала йоны; ахыр сәгатьтә; ахыр чиктә.* Мисаллар: ***Алгы сызыкның*** *үзәгендә мин ун ай чамасы булдым.* (Г. Бәширов); *«Москвич»ын калдырып җәяү генә чыгып китә дә* ***юл уңаенда*** *туры килгән машиналардан файдалануны артыграк күрә.* (А. Гыйләҗев); *Дөрес, яшь ягыннан тугызынчы унны куса да, болай* ***күрер күзгә*** *таза иде әле үзе.* (М. Әмир); *Мин сиңа* ***сүз бирәм,*** *моннан соң сезне беркайчан да төнгә ялгызыгызны калдырмам, без гел бергә булырбыз.* (Г. Тавлин); *Укыса,* ***зур урыннарда*** *эшләмәс идемени?* (Г. Мөхәммәтшин); *Ул чактагы Шөгер районына керүче Бәкер авылында яшәүче Зөбәрҗәт һәм Фаварис Галәветдиновлар гаиләсе күптән инде* ***аяк өстендә.*** (Көндәлек матбугаттан)

Функциональ яктан береккән фразеологизмнар үзләре берничә катламга аерымлана, алар стилистик яктан тәңгәл түгел, экспрессивлык дәрәҗәсе белән дә, эмоциональ үзенчәлекләре белән дә бер-берсеннән аерылалар.

Бу төркемдә иң зур катламны әдәби тел фразеологизмнары алып тора. Алар сөйләм телендә һәм матур әдәбият стилендә актив кулланылалар. Әдәби тел фразеологизмнары образлы булалар, сөйләмне тәэсирле, тирән мәгънәле итәләр, хискә һәм тойгыга баеталар, көчле сәнгатьчә сурәтләү чарасы булып торалар.

*Һәрнәрсәгә матур, сөйкемле булып,* ***шатлыгым эчкә сыймый, күңелем әллә кая сикерә,*** *әллә нәрсәм әллә ни белән тула да* ***ташып түгелергә тора төсле*** *хис ителә.* (Г. Ибраһимов); ***Типсә тимер өзәрдәй*** *12 егет килеп, бер шобага печәнне дә бетермәгәч, ул нигә ярый?* (Г. Ибраһимов); *Күпләрнең шулай үз-үзләрен яклый алмаулары,* ***бер сукканга егылып төшүләре*** *минем өчен кызык кына иде.* (Ф. Яруллин); *Әмма бу хәбәр Сәфәргали абзыйның,* ***авыруга сабышып, эштән чыгуына*** *сәбәп булды.* (С. Рахманколый);

*Ничә еллар* ***ир кулы тимәгән*** *квартираны* ***ал да гөл итеп куйды*** (С. Сөләйманова) җөмләләрендә күрсәтелгән әдәби тел фразеологизмнары, сурәтләү чаралары буларак, сөйләмне сәнгатьле һәм образлы итәләр.

Гади сөйләм теле фразеологизмнары күбрәк кешеләрнең рәсми булмаган көндәлек аралашу телендә, сирәк матур әдәбият әсәрләрендә персонаж сөйләменең үзенчәлекләрен күрсәтү, тискәре образны сурәтләү максатыннан файдаланылалар. Бу төргә караган берәмлекләр составында семантик гади сөйләм элементлары, вульгаризмнар, дорфа, тупас сүзләрнең булуы табигый хәл. Алар ирония, мыскыллап көлү, мәсхәрәләү, кимсетү, тиргәү, хурлау кебек тискәре эмоцияләрне белдерә.

***Иштең ишәк чумарын****! Мин сиңа алай дип әйттеммени?* (Г. Камал); *Асыгыз, кисегез, мулла абзый җаным, яратмыйм шул* ***уҗым бозавын,*** *дип, кыз калку күкрәкләрен калтыратып елады.* (М. Мәһдиев); *– Ә-ә, Бибисара! Ярый, ул күргән икән әле* ***мур кыргырын****, – диде Җамал карчык.* (А. Гыйләҗев); *Хатыннар тәмле сүзгә зарыкканнармы, тәки мактап эреттеләр Мәүлиха апаны,* ***авызын бәлшәйтеп****, Чулакка карап-карап торды да,* ***буасы ерылды*** *берзаман!* (А. Гыйләҗев); *«И, укымаган наданнар,* ***сукыр тавыклар****, кибәк, пумала,* ***чүбек башлар****!» – дип тезеп китте картлач* (А. Тимергалин) җөмләләрендәге билгеләнгән берәмлекләр көчле экспрессия белән сугарылганнар, тискәре эмоцияләрне белдерәләр һәм гади сөйләм теле фразеологизмнарына мисал булып торалар.

Китап теле фразеологизмнары стилистик яктан чикләнгән, нормага салынган әдәби язма һәм сөйләмә телдә, публицистикада, фәнни, эш кәгазьләре һәм рәсми стильләрдә, матур әдәбиятта кулланыла. Бу төр фразеологизмнарның кайберләре язма телгә тантаналык төсмере бирәләр, күтәренке рух белән сугарылалар. Аларның эмоциональ-экспрессив үзенчәлекләре стилистик яктан нейтраль сүзләр фонында ачык сизелә. Мәсәлән: *йөз сиксән градуска әйләндерү; ваз кичү; гайре табигый; заты шәрифләрегез.*

Ләкин барлык китап теле фразеологизмнары да экспрессивлык сыйфатына ия түгел, алар стилистик яктан нейтраль дә булырга мөмкин. Мәсәлән: *Гиппократ оныклары; Адисон (Эдисон) уты; ак алтын; ак билет; өлгергәнлек аттестаты; фундамент салу; тормыш юлы; йомгаклап әйтү; йомгак ясау.*

Китап теле фразеологизмнарын үз эчендә аерым төркемнәргә бүлеп карарга була. Мәсәлән, тотрыклы сүзтезмә булып киткән составлы фәнни терминнар: *ак күмер; ак салу; ак шигырь; алтын дәвер; алтын чор; бөтеркә бизәк;* публицистик фразеология: *дуслык миссиясе; югарыда очрашулар; актык могикан; салкын сугыш; байрак күтәрү; басма сүз; мәйдан алу; мәйданга килү (чыгу);* рәсми-эшлекле фразеология: *ачыклык кертү; ачык суд; кизүдәге мәсьәлә; сүз алу; сүз алып бару; сүз бирү; түгәрәк өстәл (янында); фәтва бирү; хәл кылу.*

Кайбер фразеологизмнарның вариантлары төрле стильләргә карарга мөмкин. Мәсәлән: *акыл өйрәтү (әдәби тел) – акыл сату (гади сөйләм теле); авызын сурәтләндерү (әдәби тел) – авызын бәлшәйтү (гади сөйләм теле).*

Фразеологизмнарны стилистик бизәлешләре ягыннан төркемләүнең асылында эмоциональ-экспрессив төсмернең булу-булмавы ята. Шуннан чыгып, алар ике төркемгә бүленә: 1) эмоциональ-экспрессив фразеологизмнар; 2) нейтраль фразеологизмнар.

Эмоциональ-экспрессив фразеологизмнар, исеменнән аңлашылганча, сөйләмне төрле модаль төсмерләр белән баеталар, коннотатив функция барлыкка килүгә нигез булалар. Үз чиратында алар ике төркемчәгә бүленә:

а) уңай мөнәсәбәтне белдерүче фразеологизмнар: *менә дигән; алтын куллы; кечкенә дә төш кенә; бер бите ай, бер бите кояш* һ.б.

б) тискәре мөнәсәбәтне белдерүче фразеологизмнар (ирония, көлү, каршы килү, кимсетү, хурлау, тиргәү, каргау һ.б.): *башын ашау; борын чөю* һ.б.

Нейтраль фразеологизмнар коннотатив билгеләрдән азат: *баштан аяк*; *эштән чыгу*. Алар гомумкулланыштагы яки стильара фразеологизмнар белән туры киләләр.

Шулай итеп, фразеологизмнарны функциональ-стилистик яктан төркемләү аларның аерым даирәләрдә файдалану үзенчәлекләрен ача, экспрессив-стилистик мөмкинлекләрен аңларга ярдәм итә. Фразеологик мәгънәнең төп элементы булып сөйләм предметына уңай я тискәре бәя бирү, аңа мөнәсәбәт белдерү тора, шуңа күрә бу төр берәмлекләрнең бик азы нейтраль стильдә кулланыла.

## Фразеологик әйтелмәләрнең семантик үзенчәлекләре

### § 51. Фразеологик мәгънә үзенчәлекләре

Тел чаралары ярдәмендә кеше үз фикерен җиткерә, теге яки бу күренешкә карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә ала. Бу вакытта ул затларны, предметларны, күренешләрне, вакыйгаларны атаган сүзләрдән һәм фразеологик әйтелмәләрдән файдалана.

«Семасиология» бүлегендә сүзнең лексик мәгънәсе, аның типлары һәм үзенчәлекләре җентекләп аңлатылды. Биредә, әлеге мәсьәләгә аерым тукталмыйча, төп игътибарны фразеологик мәгънә үзенчәлекләрен ачуга юнәлтәбез.

Тел белемендә «фразеологик мәгънә» төшенчәсе төрлечә аңлатыла. Соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә аны денотатив, эмоциональ-экспрессив һәм грамматик мәгънәләрнең комплексы итеп карауга өстенлек бирелә. Фразеологик әйтелмәләр семантик яктан берләшкән бербөтен мәгънә белдерәләр, үзләре атаган предмет, күренешләр белән мөнәсәбәттәшлекне саклыйлар. Фразеологизмнарга һәрвакыт күчерелмә мәгънә хас. Фразеологик мәгънә фразеологизм составындагы сүзләрнең лексик мәгънәләре суммасыннан барлыкка килми, ә аңа тулаем хас була, бербөтен тәшкил итә. Тотрыклы сүзтезмәнең элементлары таркалудан яки алмашынудан фразеологик мәгънә юкка чыга яки башка мәгънәдәге фразеологизм туа. Мәсәлән, *ярага тоз салу* дигән өч сүздән торган тезмә «күңел җәрәхәтен тагын да арттыру» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәгә берләшкән, әгәр бу тезмәнең бер компонентын, әйтик, *яра* сүзен төшереп калдырсак, яки бу сүзне башка сүз белән (*ашка тоз салу*) алмаштырсак, аның тотрыклылыгы юкка чыга, туры мәгънәле сүзтезмә барлыкка килә. Фразеологик әйтелмәгә салынган күчерелмә мәгънәнең югалуы андагы эмоциональ-экспрессивлык элементларының коннототив үзенчәлеген дә бетерә. Шулай итеп, фразеологик әйтелмә составындагы сүзләр бәйле мәгънәдә булалар.

Фразеологизмнар, аерым сүзләр кебек үк, номинатив функция башкаралар. Аларның бу функциясе безне чолгап алган дөнья күренешләрен исемләргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, *дөнья бәясе* дип бик кадерле кешегә я әйбергә карата әйтәбез, *колагына да элми* дип, дикъкатьсез кешеләрне характерлыйбыз, *иркен куллы* дип хәлле тормышлы, дәүләтле, бай кеше турында сөйлибез, *аты артта, тәртәсе алда* дип – арттырып сөйләүчене, *китап корты* дип –

китап укырга яратучыны, *аягын алып селкесәң, бер хәреф (әлиф) төшмәс* дип надан, томана кешене атыйбыз һ.б.

Ләкин фразеологик әйтелмәләр теге яки бу предметны, күренешне атап кына калмыйлар, бәлки шул предметка, күренешкә карата сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерәләр. Димәк, фразеологик мәгънә көчле эмоциональ-экспрессив, стилистик төсмерләр белән баетылган.

Мәсәлән, *чибәр* һәм *бер бите ай, бер бите көн* дигән берәмлекләр икесе дә кешенең йөз матурлыгын тасвирлыйлар, яхшы яктан бәялиләр, ләкин икенчесендә бу мәгънә интенсиврак яңгырый һәм уңай эмоциональ төсмер белән сугарылган. *Берсе чәршәмбегә, берсе дүшәмбегә (җомгага) караган; бер күзе мәшрикъта, бер күзе мәгърибтә; бер күзенә ак салган, икенчесе чак калган* фразеологизмнары, киресенчә, тискәре экспрессияне белдерәләр, *күзе кылый* кебек тезелмәләр күзендәге кимчелеккә карата ирония белән әйтеләләр.

Фразеологик әйтелмәләрнең күбесе үз эчендә берничә мәгънә төсмерен тупларга сәләтле. Мәсәлән, кеше турында *изге җан* дип әйткәндә, күз алдына һәркемгә яхшылык итүче, шуннан тәм табучы, кешелекле, ярдәмчел кеше килеп баса. *Йомшак авыз* дип җебегән, үтә юаш, үз-үзен яклый алмый торган кешегә карата әйтелә.

Сүзләр кебек үк, фразеологик әйтелмәләр бер һәм күп мәгънәле булалар. Мәсәлән, *йоммый түгеп ява* тотрыклы сүзтезмәсе – бер мәгънәле, ул бик елак баланың, күзләрен бер дә йоммыйча, яшь агызып торуын белдерә, *кулы озын* – ике мәгънәле, беренче мәгънәсе – карак кеше, икенчесе – кулын тыя белмәүче, сугышырга яратучы.

Димәк, фразеологик әйтелмәләр, сүзләр кебек үк, күп мәгънәле булалар, бер-берсе белән синонимик, антонимик һәм омонимик мөнәсәбәтләргә керәләр.

Фразеологик әйтелмәләрдә күпмәгънәлелек күренеше аерым сүзләрнең күпмәгънәлелегенә караганда азрак таралыш тапкан. Татар телендә күпчелек фразеологизмнар – бер мәгънәле. Бер мәгънәлелек бигрәк тә фразеологик ныгымаларда (идиомаларда) күзәтелә. *Ис кит(мә)ү; үзәк өзелү; юкны бушка аудару (бушату); түшәмгә төкереп яту; кырт кисү; тузга язмаган(ны сөйләмә); кара коелу; биш былтыр; салам сыйрак; яла ягу; суйган да каплаган; ташка үлчим; изге җан; ике дөнья бер кәнди; вәли нигъмәт; трай тибү; аягүрә саташу; аягын дагалау; бер атка ике камыт; гайбәт боткасы; зур күрү; кикрикле тавык; киләп сарып йөрү; бер*

*балык башы; дилбегәне җыя төшү; йөзен яшерү* – болар барысы да бер мәгънәдә генә кулланылалар, фразеологик вариантлар ясамыйлар, компонентлары бер-берсенә береккән, аларда сүзләрне алыштыру, төшерү, өстәү мөмкин түгел.

Фразеологик бердәмлекләр, тезмәләр, тәгъбирләр арасында да бер мәгънәлеләр аз түгел. Мәсәлән, *колагына да элми; борын тыгу; эт көне; канлы яшь түгү; ярага тоз салу; кәеф боз(ыл)у; җай чыгу; ишетсен колагың; уйга бату; биш бәягә сату; туры сүзле; бәлага тару; күп сорамый (алмый); бәреп әйтү; чиргә сабышу; бусагасын таптау; тамак кыру; гомер кичерү; көн күрү; соң дәрәҗәдә; җан иясе* һ.б.телдә, нигездә, бер мәгънәдә генә очрыйлар.

Күп мәгънәле фразеологизмнарның төп өлешен ике мәгънәле фразеологизмнар тәшкил итә. Мәсәлән, *телдән калу (телдән язу)*:

1) авыру, хәлсезлектән сөйли алмый башлау. *Барыңыз, бар, Сахип абый үлә, **телдән калган**, ди*. (Г. Ибраһимов);

2) курку, оялу, уңайсызланудан сүз әйтә алмый тору. *Күтәрелеп карарга да чак-чак баздык, Тик торабыз – икебез дә **телдән яздык.*** (Р. Миңнуллин).

*Эченнән энә үтәрлек:*

1) үтә ябык, арык. *– Аңа ни әйтәсең... Үзенең **эченнән энә** үтәрлек, ә үзе һаман бүрәнәнең юан башыннан күтәрә...* (В. Имамов);

2) нечкә билле (кызлар турында):

*Зифа буең, талчыбыктай билең,*

***Эчләреңнән энә үтәрлек**...* (Г. Сәгыйров).

Шулай ук өч, дүрт, биш һәм анннан да күбрәк мәгънәле фразеологизмнар да бар. Мисал өчен, Г.Х. Ахунҗанов *баш күтәрү* фразеологизмының 11 мәгънәсен күрсәтә:

1) эштән аерылып тору: *Буразналар өстеннән кешеләр башларын күтәрделәр. Яңгыр коеп яварга керешге.* (М. Галәү);

2) йокыдан тору: *Кышкы авыл яңа баш күтәрә, ә җәен бу вакытта халык кырга китеп беткән була инде*. (Ә. Еники);

3) авырудан соң торып йөри башлау: *Мәрьям апа кайтып егылды да башын күтәрә алмады. Кичә җирләделәр.* (Г. Гобәй);

4) тиешлек, буйсынганлык хәленнән аерылу, үзеңне горур тота башлау: *Күтәр башың, туктат яшең.* (Ф. Бурнаш);

5) һавалану, тәкәбберләнү: *Искә төшә симез капиталның баш күтәреп йөргән чаклары; миллионланган эшче, батракларны эттән түбән күргән чаклары*. (М. Гафури);

6) килешмәвеңне белдерү, каршы чыгу: *Гөлчирәнең болай кан йотып йөрүенә семьяда каршы беренче булып Нурия баш күтәрде.* (Г. Әпсәләмов);

7) сыйнфый мәнфәгатьләрне яклау өчен, изүче сыйныфларга каршы массалы коралллы чыгыш ясау: *Баш күтәрүчеләр белән җәзалау отрядлары арасындагы сугыш кара көзгә хәтле барды.* (И. Салахов);

8) төрле каршы көчләр турында: активлашу, җанлылык күрсәтә башлау, күтәрелеп чыгу: *Прогресс дошманы булган кара көчләр әле тегендә, әле монда яңадан баш күтәрәләр.* (Г. Иделле);

9) хисләр, уйлар турында (җанлану, көчәю): *Кызның астыртын горурлыгы вакыт-вакыт баш күтәрә.* (А. Гыйләҗев);

10) искергән мәгънә: барлыкка килү, дөньяга, мәйданга чыгу: *17 октябрьдән соң һәр тарафтан яхшы ук шагыйрьләр баш күтәрделәр.* (Г. Тукай);

11) үсемлек турында: үсеп чыгу. Мәсәлән: *Кар китәр-китмәс беренче яз чәчәге – умырзая баш күтәргән.* (Г. Әпсәләмов) (Ахунҗанов, 1972: 46). Г.Х. Ахунҗанов мисал итеп китергән фразеологизмның төп мәгънәсе «уяну, активлашу, көчәю, күтәрелеп чыгу»га кайтып кала.

Сүзләрдәге кебек үк, димәк, фразеологик әйтелмәләрдә күпмәгънәлелек мәгънәләрнең эчке мотивациясе сакланганда гына барлыкка килә. Мәсәлән, *ахыр сәгатьтә* тотрыклы сүзтезмәсен карап үтик: 1. Иң соңгы мизгелдә, 2. Үлем сәгатендә. Бу ике мәгънәне берләштерүче үзәк – вакыт ягыннан чикне белдерү.

Тагын бер мисалга тукталыйк: *китү җаен карау* фразеологизмының мәгънәләре булып 1) «китү хәстәрен күрү», 2) «качу, ычкыну җаен карау» тора. Һәр ике очракта да «китү, югалу»мәгънәсе алга чыга. Мәгънәләр арасында мондый бәйләнеш югалса, фразеологик омонимнар барлыкка килә.

### § 52. Фразеологик омонимнар

Аваз төзелешләре бертөрле, әмма мәгънәләре төрле булган фразеологик әйтелмәләрне фразеологик омонимнар дип йөртәләр. Мондый фразеологик берәмлекләр, гадәттә, ике төрле мәгънә белдерәләр. Мәсәлән, *башка ут кабу* дигән фразеологизмның түбәндәге мәгънәләре бар: 1) нык гашыйк булу; 2) нык борчылу. *Кагылып-сугылып йөрү* тәгъбире шулай ук ике төрле мәгънәдә кулла-

ныла: 1) җәберләнү, тибәрелү, кыерсытылу; 2) эшкә кереп яисә бер җиргә төпләнеп, урнаша алмыйча йөрү һ.б.

Тел белемендә омонимлык күренеше элек-электән тел белгечләренең игътибарын җәлеп иткән. Гомуми тел белемендә һәм татар тел белемендә дә әлеге мәсьәләне яктырткан дистәләгән хезмәт бар. Әмма фразеологик омонимнар бу хезмәтләрнең кайберләрендә генә телгә алынган.

Фразеология өлкәсендә иң нәтиҗәле эшләгән галим Г.Х. Ахунҗанов, фразеологизмнарның омонимлыгын өйрәнеп, болай ди: «Татар телендә фразеологик омонимнар әллә ни күп түгел. Мәсәлән, *теш күрсәтү* «елмаю» мәгънәсен дә, «усал ниятне сиздерү» мәгънәсен дә аңлата. *Сүз йөртү* – гайбәт ташу һәм сүз алып бару, тикшерү мәгънәләрен; *сүзгә килү* «сөйли башлау» һәм «ызгышу» мәгънәләрен белдерә. *Телгә килү* сүзенең 3 омонимы бар: *телгә килү* – хәтергә килү; *телгә килү* – сөйли башлау; *телгә килү* – ызгышу» (Ахунҗанов, 1972: 79).

Г.Х. Әхәтов: «Фразеологизмнар бер контекстта фразеологизм, ә икенчесендә булмаска мөмкин. Мәсәлән, *Чулпанның эше бик тиз үргә менеп китте* (Г. Бәширов) җөмләсендә *үргә менеп китте* – фразеологизм, чөнки ул бу контекстта образлыландырылган, күчерелмә мәгънәдә кулланылган, «Чулпан» колхозындагы эшнең алга китүен аңлатып килгән. Шул ук *үргә менеп китте* тезмәсе *Ул җәяүләп үргә менеп китте* җөмләсендә фразеологизм була алмый, чөнки монда ул туры мәгънәсендә генә файдаланылган. Шулай итеп, сүзтезмә, үз контекстыннан аерылып «чит» контекстка килеп урнаштыру белән, төп мәгънәсеннән тайпыла, өстәмә мәгънә ала. Димәк, сүзтезмәләрнең, үз контекстларыннан аерылып, икенче контекстта күчерелмә мәгънәдә кулланыла башлаулары фразеологизм барлыкка килүнең төп факторларыннан берсе», – дип яза (Әхәтов, 1979: 8–9). Күргәнебезчә, галим фразеологизмның омонимик кулланылышта булуын исәпкә алмый.

Ф.С. Сафиуллинаның «Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология» хезмәтендә, фразеологиягә бәйле рәвештә, нәкъ шундый ук характердагы билгеләмә бирелгән. Омонимнарны төркемләүдә хезмәт авторының карашы түбәндәгечә: 1) лексик; 2) лексик-грамматик; 3) грамматик (омоморфемалар, омомодельләр) (Сафиуллина, 1999: 142). Бу төркемгә фразеологик омонимнар кертелмәгән.

М.Б. Хәйруллин лексик-семантик омонимнар төркеменә фразеологик омонимнарны да кертә: 1) лексик омонимнар; 2) лексик-грамматик омонимнар; 3) грамматик омонимнар; 4) фразеологик омонимнар. Автор аларны контекстка бәйле рәвештә үзләренең туры һәм күчерелмә мәгънәләрендә кулланыла торган фразеологик әйләнмәләр дип атый. Мәсәлән: *койма комга терәлү* (туры мәгънәсендә) – *көймә комга терәлү* (күчерелмә мәгънәдә авыр хәлдә калуны белдерә), *кул сузу* (туры мәгънәдә) – *кул сузу* (күчерелмә мәгънәдә урлауны белдерә) һ.б. (Хайруллин, 2002: 101–102).

Ф.С. Хәкимҗанов «Омонимлык һәм омонимнарны төркемләү» мәкаләсендә омонимнарның түбәндәге төрләрен аерып чыгара: 1) лексик омонимнар; 2) грамматик омонимнар (яки омоформалар); 3) фонетик омонимнар (яки омофоннар); 4) график омонимнар (яки омографлар); 5) фразеологик омонимнар; 6) синтаксик омонимнар (омомодельләр, омосинтагмалар). Фразеологик омонимнарга галим төп мәгънәдә кулланылган тезмәләр белән фразеологик әйләнмәгә әверелгән берәмлекләрне кертә: *сырт йонын кабарту* (туры мәгънәдә: нинди дә булса хайван белән бәйле) – *сырт йонын кабарту* (каршы килү, киреләнү); *сөялгә басу* (туры мәгънәдә) – *сөялгә басу* (гаебен яки кимчелеген төрттереп әйтү) һ.б. (Хәкимҗанов, 2004: 16–23).

Татар телендә өч, хәтта дүртәр мәгънәгә ия булган омоним тотрыклы сүз тезмәләре очрый. Мәсәлән: *баш салу* фразеологизмы нәкъ шушы ук аваз составында берьюлы өч мәгънәне аерып чыгарырга мөмкин: 1) авыру, ару яки кайгыдан башны түбән ию, сүлпәнләнеп аска салындыру; 2) буйсыну, ялынып баш ию, багыну; 3) корбан булу, көрәшеп үлү.

Кайбер сүз тезмәләре бер очракта – туры мәгънәләрендә, икенче очракта бер контекстта күчерелмә төшенчәдә фразеологик әйтелмә булып йөриләр. Тел белемендә мондый сүзтезмәләргә шартлы фразеологик омонимнар диләр. Фразеологик әйтелмә эчтәлеге буенча бер төшенчәне белдереп килә, формасы буенча сүз тезмәсенә охшый. Мәсәлән, ***Теш агарту** өчен, щётка сатып алдым* җөмләсендә *теш агарту* үзенең туры мәгънәсендә килгән. *Браунингтан ату хакында малай, билгеле, **теш агартмады*** (Х. Ибраһим) дигән контекстта *теш агарту (агартмау)* – астыртын каршылык күрсәтү мәгънәсендәге фразеологик әйтелмә. *Ботка пешү*: *Бер тарыдан **ботка пешми*** (Мәкаль) җөмләсендә *ботка*

*пеш(мә)ү* – туры мәгънәдә кулланыла торган гади сүзтезмә; *Болай итсәк, миңа да җәбер, сиңа да җәбер булмас, моңар күнсәң, безнең* ***ботка пешәр*** (Г. Тукай) контекстында күчерелмә мәгънәдә килгән тотрыклы сүзтезмә, ул үзара килешеп, уртак тел табып эшләү яки яшәү мәгънәсен белдерә; *өреп кенә тоту* – 1. Туры мәгънәсендә; 2. Бик кадерләү, кадер-хөрмәт күрсәтү. *Өреп кенә, җаным, татармын дип, Буш вәгъдәләр сиңа биргәнен.* (Р. Вәлиев); 3. Кадерләүнең киресен белдерә: – *Ну, хатыннан уңдым мин, малай! Өреп озата, өреп каршы ала,* ***өреп кенә тота.*** (И. Хәйруллин)

Алда әйтелгәннәрдән чыгып, фразеологик омонимнарның түбәндәге төрләрен күрсәтергә була:

1) саф фразеологик омонимнар: *җан бирү* – үлү; *җан бирү* – тереклек бирү, яшәргә мөмкинлек бирү. Бу очракта фразеологизмнар арасында омонимия күренеше күзәтелә;

2) шартлы фразеологик омонимнар: *баш түшәмгә тию* (туры мәгънәсендә); *баш түшәмгә тию* – шатлану, куану. Биредә фразеологизм һәм гади сүзтезмә арасында омонимия күренеше бар. Мондый күренеш ирекле сүзтезмәләр (*кул буяу*) һәм шулардан килеп чыккан фразеологик әйтелмәләр (күчерелмә мәгънәдәге тотрыклы сүз тезмәләре: *кул буяу* – әһәмиятсез, юк-бар эшкә катышу, исем пычрату) арасында туа;

3) катнаш фразеологик омонимнар: *койрыгы кысылу* (туры мәгънәсендә); *койрыгы кысылу* – хәрәкәт мәйданы калмау, карьерасы барып чыкмау; *койрыгы кысылу* – шүрләү, курку, теләсә ни кыланмас булу. Әлеге төрдә гади сүзтезмә һәм фразеологизмның үзенә карата да омонимик характерда булган тотрыклы сүзтезмәләр арасында барлыкка килүе күзәтелә.

Бу төр фразеологизмнарның (мәсәлән: *түбәсе күккә тию; арт сабагын укыту; арага кыл сыймау*) ирекле сүзтезмә вариантындагы омонимнары булмый. Алар күчерелмә мәгънәдә генә йөриләр.

Кайбер фразеологик омонимнарның компонентлары составында үзара омонимик бәйләнештәге сүзләрне дә очратырга туры килә: ***өреп*** *кенә тору* – кадерләү; ***өреп*** *кенә тору* – тавыш-гауга куптару.

Үзара антонимик характердагы фразеологик омонимнар да очрый. Мәсәлән: ***җан бирү*** – үлү; ***җан бирү*** – тереклек бирү, яшәргә мөмкинлек бирү.

Димәк, сүзләр кебек, фразеологизмнар да бер-берсе белән омонимик мөнәсәбәтләргә керергә сәләтле, дөрес, икенчеләрендә

мондый мөмкинлек чикләнгән. Фразеологизмнарда омонимия күренеше үзара, ягъни фразеологизмнар арасында да, фразеологизм белән ирекле сүзтезмә арасында да булырга мөмкин. Фразеологизмнарның омонимлыгы – тел байлыгын билгеләүче фактор.

## § 53. Фразеологик синонимнар

Тел берәмлеге буларак, фразеологизм гомуми семантик законнарга буйсына, ягъни башка фразеологизмнар белән системалы семантик мөнәсәбәткә керә. Фразеологизмнарның семантик системалылыгына хас бер билге булып аларның синонимик мөнәсәбәткә керүе тора. «Объектив чынбарлыкның бер үк предметны белдергән төрле әйләнмәләре синонимик фразеологизмнар булалар» (Шанский, 1969: 70).

Фразеологик әйтелмәләр аерым сүзләргә карата да үзара да синонимнар була алалар. «Фразеологик синонимнар – ул аваз формасы ягыннан төрле, ә мәгънәләре буенча тәңгәл яки бик якын булган тел берәмлекләре», – дип билгели С.Ш. Поварисов (Поварисов, 1982: 158).

Күргәнебезчә, фразеологик синонимнарга бирелгән әлеге билгеләмә гади синоним билгеләмәсенә якын. Аларның функцияләре дә бер үк: сүз синонимы кебек, фразеологик синонимнар да теге яки бу мәгънә (яки стиль) төсмерен аерган вакытта кулланылалар. Мәгънә төсмерләренең күләменә карап, синоним фразеологизмнарның да синонимик рәтендә дистәгә якын фразеологизм булырга мөмкин.

Фразеологизмнарның синонимик рәтендәге тотрыклы сүз тезмәләре бер-берсеннән мәгънә төсмерләре, стилистик бизәкләре, функциональ-сөйләм даирәсе яки санап үткән сыйфатларның барысы белән дә берьюлы аерылырга мөмкиннәр. Мәсәлән: *тиккә күсәк күтәрү; телгә-тешкә килү; тәмсезгә китү; сафура бураны куптару; сәхнә ясау; тавыш күтәрү; тавыш чыгу; тузан кубару* кебек фразеологизмнар барысы да «кычкырышу» мәгънәсен аңлата. Ләкин *тиккә күсәк күтәрү* фразеологизмы, мәсәлән, бер «сәбәпсезгә кычкырышу» дигән төсмердә кулланыла, *тузан кубару, тавыш күтәрү* – аерым бер кызу кеше аркасында чыккан кычкырышны белдерә, *сәхнә ясау* – кешеләр алдында кычкырышуны аңлатса, *өйдә ың-шың чыгу* дигәне «гаиләдә кеше күзенә күренмичә кычкырышу» мәгънәсендә йөри. *Телгә-тешкә килү, сүзгә килү* җиңелчә генә кычкырышуны белдерсә, *тәмсезгә китү* – ямь-

сез сүзләр әйтеп кычкырышу, *сафура бураны куптару* – «бик нык кычкырышу, тиргәш-талаш» мәгънәсендә кулланыла.

Кайбер фразеологик синонимнарны башка күренеш яки вакыйгалар сурәтләнгән контекстлар эченә урнаштырсак, алар мәгънә һәм стилистик, эмоциональ-экспрессив төсмерләрен, синонимлыкларын югалтулары яисә яңа синонимик төркем хасил итүләре мөмкин. Мәсәлән: *чырайларында кан әсәре калмаган; чак авызыннан тыны чыга; рәтләп сүзен дә әйтә алмый; тәмам изрәп төшкәннәр* кебек синоним фразеологизмнар билгеле бер контекстта «курку, каушап калу» мәгънәсендә кулланылырга, ә башка бер контекстта бөтенләй икенче мәгънәдәге сүзгә тәңгәл булырга мөмкин. Мәсәлән: *чырайда кан әсәре калмау* – ябыгу, авыру*; изрәп төшү* – каты йоклау, ару, хәлдән таю, каты исереп китү; *авызыннан чак тыны чыгу* – сөйләшә алмау, авыр хәлдә яту; *чак аяк өстендә тору* – ару, хәлсезләнү, авыру, гаҗәпләнү; *рәтләп сүзен дә әйтә алмау* – юньсезлек, исереклек һ.б.

Кагыйдә буларак, синонимик рәткә кергән фразеологизмнар я бер төрле, я төрле конструкцияле булалар. Бер төрле фразеологик синонимнарга мисаллар: *кул кую – пичәт басу; эшкә ашу – барып чыгу; сөмсере коелу – карага бату; аска карау – күзне түбән төшерү, (акчаны) суга салу – (акчаны) җилгә очыру, баш күккә тию – куаныч эчкә (култыкка) сыймау* (фигыль)*; соры корт – эрәм тамак; җан көеге – күзле бүкән – аяклы каза* (исем). Алар күбесе, бигрәк тә фигыль һәм рәвеш белән мөнәсәбәттәш булганнары, бер төрле мөстәкыйль мәгънәле сүз белән бәйләнешкә керәләр. Мәсәлән, *(нәрсәгә) кул кую – (нәрсәгә) пичәт басу; (нәрсә) эшкә ашу – (нәрсә) барып чыгу; (нәрсәдән) сөмсере коелу – (нәрсәдән) карага бату, (кемгә) мәдхия уку – (кемгә) дан җырлау; (нәрсәдән) җан алыну – (нәрсәдән) кот ботка җиту.*

Төрле конструкцияле фразеологик синонимнарга мисаллар: *биш былтыр – күпме еллар үтте, күпме сулар акты; чиләгенә күрә капкачы – ике сыңар – бер кием; ике сөяк – сандырак; ике чабата – бер кием* һ.б. Мондый синонимик рәттә сүзләр төзелешенең охшашлыгы түгел, ә мәгънәнең бертөрле булуы мөһим.

Шулай итеп, фразеологик синонимнар – мәгънәләре буенча якын яки тәңгәл, грамматик һәм стилистик кулланылыш үзенчәлекләре, функциональ-сөйләм сфералары буенча аерылып торган берәмлекләр.

Фразеологик синонимнарның тел һәм контекстуаль төрләре бар. Тел синонимнарының аермалы (дифференциаль) билгеләре берничә булырга мөмкин: үз эчендә эчтәлекләре ягыннан (семантик синонимнар), нинди стильдә кулланылуы һәм эмоциональ-экспрессивлыгы ягыннан (стилистик синонимнар).

Семантик синонимнарга эчке формалары һәм мәгънә төсмерләре буенча бер-берсеннән аерыла торган фразеологизмнар керә. Мәсәлән, *эч яну; йөрәк әрнү; җан телгәләнү; ут йоту; үзәк өзелү* фразеологик әйтелмәләре, бер мәгънәдә – «борчылу, кайгы-хәсрәт кичерү» мәгънәсендә берләшсәләр дә, бер-берсеннән семантик төсмерләре белән аерымланалар: *эч яну* фразеологизмы кешегә сиздермичә генә кайгыру, борчылуны белдерә, *йөрәк әрнү* ачынуны, кызгану белән бәйле рухи газапларны белдергәндә кулланыла, *җан телгәләнү* – «җан әрнү, кызганудан үтә борчылу, нинди дә булса вакыйганы авыр кичерү» мәгънәсен җиткерә, *ут йоту* бик тирән ваем чигү, кайгы-хәсрәт кичерүне белдереп килә, *үзәк өзелү* борчылу, эч пошуны белдерү өчен файдаланыла.

– *Инде бөтен авыл белә икән.* ***Эчем яна*** *минем.* (Н. Гыйматдинова); *Яшьлегемә шаһит булган өемне ишкәндә,* ***йөрәгем әрни****.* (Н. Гыйматдинова); *Алайса, ник телгә килеп әйтми, ник болай* ***җанны телгәли?*** (Н. Гыйматдинова)

– *Икегез дә* ***ут йотасыз*** *шул, балалар. Сак белән Сок күек кавышалмыйсыз, арагызга тау үсте.* (Н. Гыйматдинова); *Бер кич күрмәсәм, сагынудан* ***үзәгем өзелә****.* (Н. Гыйматдинова)

*Җанга урын тапмау, тамактан аш үтмәү, башны кая илтеп тыгарга белмәү* фразеологизмнары алда санап киткән берәмлекләрнең мәгънәләренә якын: кайгыдан, мәшәкатьтән я пошынудан өзгәләнү, борчылуны белдерәләр, ләкин беренчеләреннән матур әдәбият стилендә түгел, ә күбрәк гади сөйләм стилендә кулланылулары белән аерылалар, эмоциональ төсмерләре дә башка. Икенче төркемдәгеләр үз эчендә түбәндәге семантик төсмерләр белән аерымланалар: *җанга урын тапмау* – бик нык борчылу, пошыну, нишләргә дә белмәү, *тамактан аш үтмәү* – бик нык борчылудан, ашый алмау, *башны кая илтеп тыгарга белмәү* – чарасызлык. Мәсәлән, *Ә Галия* ***җанына урын тапмады****.* (Н. Гыйматдинова); ***«Тамагымнан аш та үтми*** *бу Шәрәф белән», – диде хатын, мескен кыяфәт чыгарып.* (Н. Гыйматдинова); *Ул* ***башын кая илтеп тыгарга белмәгәннән*** *генә каңгырап, Карачутырның капкасына төртелде.* (Н. Гыйматдинова)

*Кызу канлы, тоткан җиреннән өзеп ала торган* фразеологизмнарының логик мәгънәләре бердәй, икесе дә усал кешене атап киләләр, әмма беренчесе тиз кабынучан, холерик темпераментлы, ярсучан кешегә карата кулланылса, икенче берәмлек усаллык өстенә тәвәкәллек, кискенлек мәгънә төсмере белән баетылган.

*Киленнең атасы* ***кызу канлы****. Бирнәләрен олауга төяп кире сыптырмасын дим.* (Н. Гыйматдинова); *Монысы* ***тоткан җиреннән өзеп ала торган*** *усал хатын икән.* (Н. Гыйматдинова)

*Оятка калдыру, хур итү, биткә кара ягу* – «кешене яманатлы, оятлы итү» мәгънәсендә берләшәләр, әдәби әсәрдә өчесе, бергә килеп, градация тудыралар. Мәсәлән, *Ни генә әйтим инде, тәмам* ***оятка калдырды, хур итте, биткә кара якты*** *бит...* (Г. Бәширов)

С т и л и с т и к   с и н о н и м н а р г а төрле стилистик өлкәләргә карый торган синоним фразеологизмнар керә. Алар матур әдәбиятта, гомумкулланылыш һәм гади сөйләм телендә кулланылалар; бер-берсеннән мәгънәләренең эмоциональ-экспрессивлык дәрәҗәсе, бер үк стильдә кулланылу интенсивлыгы белән аерылып торалар. Язучылар бу төр синонимнар аркылы бер үк вакытта сурәтләнгән күренеш һәм вакыйгаларга, эш-хәлләргә, предметларга, кешеләргә карата үзләренең төрле мөнәсәбәтләрен белдерә алалар. Стилистик төсмерләрнең байлыгы конкрет ситуациядә урынлы әйтелгән фразеологизмны сайлап алуга хезмәт итә. Мәсәлән, *кәеф бозылу* һәм *кикриге шиңү* берәмлекләренең беренчесе нейтраль, икенчесе ирония төсмере белән әйтелә, ягъни стилистик яктан түбәнәйтелгән. Мәсәлән, *...әллә инде бу арада* ***кәефе бозылганмы****?* (Г. Толымбай); *Шуннан чират көтүчеләренең дә* ***кикриге шиңә****...* (Г. Толымбай)

*Каф таулары артына, җәһәннәм читенә, җәһәннәм тишегенә* фразеологизмнарының өчесе дә «бик еракка» мәгънәсен белдереп киләләр, беренчесе матур әдәбият стиленә, калганнары гади сөйләм теленә карый. Соңгыларында экспрессивлык көчлерәк яңгырый. Мәсәлән, – ***Каф таулары артына*** *качарсың шуларны күрмәс өчен, Раббым Аллам.* (Н. Гыйматдинова); *Китәм,* ***җәһәннәм читенә*** *китәм, – дип елады.* (Н. Гыйматдинова); *Бигрәк* ***җәһәннәм тишегендә*** *инде бу Рухиясе. Сыерына да шуннан ташы, җиләк-җимешенә дә сибәргә дә шунда чап.* (Н. Гыйматдинова)

*Кот чыгу* – гомумкулланылыш теленә, *йөрәге өзелеп төшү* – матур әдәбият стиленә, *җан табан астына төшү* гади сөйләм

теленә карый, өчесе дә куркуны белдерә. ***Котым чыкты****, валлаһи*. (Н. Гыйматдинова); *Буа ташу уен эш түгел иде. Галиянең* ***йөрәге өзелеп төшкәндәй булды****.* (Н. Гыйматдинова); *«Куркымыш ясап* ***җаныңны табан астына кем төшермәктә*** *ие?» – диде*. (Н. Гыйматдинова)

*Күз төшерү, күз тәгәрәтү, күз текәү, күз йөртү* фразеологизмнары «карап алу» дигән уртак мәгънәгә ия булсалар да, семантик һәм стилистик яктан берникадәр аерылалар. Бу аерма мисалларда ачык сизелә: ***Күзне төшерсәм****, теге төшкән комиссар Садыйков кул куйган.* (Г. Толымбай); *Амин итеп бетергәч тә әле, малай,* ***күзне тәгәрәтеп****, чыкмыйча тордык.* (Г. Толымбай); *Сагышлы кеше чырае белән* ***күзен*** *бер тынышка* ***текәп торган итә.*** *Ул насоска* ***күз йөртте.*** (Г. Толымбай)

*Кара көю, ачу казаны ташу, сару кайнау* фразеологизмнары «ачулану» мәгънәсендә берләшәләр, ләкин мәгънә төсмерләре, кулланылыш даирәләре, эмоциональ-экспрессивлык дәрәҗәләре төрле. *Кара көю* – каты ачудан төс китүне, карасу кыяфәткә керүне, *ачу казаны ташу* – каты ачулану, ачуыннан төрле явызлыкларга сәләтле булуны белдерә*, сару кайнау* ниндидер ошамаган нәрсәгә эч пошу, күңел болгану төсмере белән сугарылган. Беренче икесе – матур әдәбият стиленә, соңгысы гади сөйләм теленә каравы аңлашыла. Мәсәлән, *Йорт саен имеш-мимешләр таралган, тик берәү дә Сәрбиянең кинәт явызланып,* ***кара көеп*** *китүен аңламаган*. (Н. Гыйматдинова); *Өтерманнан кайтышлый ялгыш тәрәзәсен ваткан иде малай, шуңар* ***ачу казаны ташыгандыр*** *убырның.* (Н. Гыйматдинова); *Килгән саен, аягымдагы туфлиләрне күреп,* ***саруы кайныйдыр*** *мескеннең.* (Н. Гыйматдинова)

Татар тел белемендә фразеологизмнарны төркемләүдә карашлар төрлелеге булган кебек, алар арасындагы синонимлыкны билгеләүдә дә фикерләр байтак. Әмма югарыда күрсәтелгән бүленеш татар тел белемендә генә түгел, рус тел белемендә дә (мәсәлән, Н.М. Шанский, В.Н. Клюева хезмәтләрендә) таныла.

Контекстта аерым сүзгә, ирекле сүзтезмәгә һәм җөмләгә синоним булган фразеологик әйтелмәләр дә кулланыла. Алар, гадәттә, бер җөмлә составында булалар һәм төрле функция үтиләр. Беренчедән, мәгънәне төгәлләп аныклау, ачыклау вазифасын башкаралар, икенчедән, әйтергә теләгән фикерне үтемлерәк, көчлерәк итәләр, эмоциональ-экспрессивлык дәрәҗәсен арттыралар.

*Тургайлы үзәнгә* ***карыйм*** *да* / *Җанымны җылыткан уй табам,* / *Кызыл төс* ***күрдисәм*** *– кан уйный,* / *Зәңгәр төс күңелгә моң сала.* / *Сап-сары көземә* ***күз багып,*** / *Җаныма сагышлы уй табам.* (Р. Вәлиев); *Бу ноктадан бөтен зал күренә. Монда кергән-чыкканны* ***күздән кичергәләп,*** *өстенә чикләвек сибелгән мороженое капкалап, озын салам аша коктейль суыра-суыра, тамаша* ***карап*** *утыру рәхәт иде.* (С. Шәмси) *Юк ла, кунакка түгел,* ***яшәргә, тормыш итәргә****...* (И. Хәйруллин); *Әле синдә азатлык хыялы* ***яши****. Син әле, Финляндиягә кайтып, хатыныңны, улыңны кочакармын дигән өмет белән* ***җан асрыйсың.*** (З. Хәким); *Дөрес, хәзергә бу илдә мондый казаныш белән* ***мактанып, түш киереп*** *йөреп булмас булуын...* (М. Маликова); *Минем аркада* ***интегәсең*** *шикелле. Зыятдин. Ә миңа син минем аркада* ***җәфа чигәсең*** *кебек.* (З. Хәким); *Соңгы вакытта аның коточкыч өянәкләре кузгала. Торымнан-торымга* ***телсез кала****. Бөтенләй* ***сөйләшә алмый****.* (З. Хәким); *Васятькә тиң, шуңадыр* ***күңелне кузгата,*** *үз вакытында хәтта* ***шомландыра*** *да иде аның сүзләре...* (Көндәлек матбугаттан)

Алдагы мисалларда күренгәнчә, фразеологик берәмлек сүзгә караганда һәрвакыт диярлек образлырак һәм экспрессиврак яңгырый, күпчелек очракта сүзләргә карата образлы аныклагыч вазифасын үти. Бай фразеологик синонимия язучыларга якын мәгънәле әйләнмәләр күплегеннән иң төгәл, иң отышлыларын сайлап алырга мөмкинлек бирә. Туган телнең синонимик байлыгыннан оста файдалану каләм иясенең профессионализмы һәм осталыгы турында сөйли.

Татар телендә *кесәдә тузан уйный – кесәдә җилләр уйный – кесәдә җилләр исә – кесәдә буран уйный, йокы базарына киту – йокыга талу – йокыдан кибән кую – йокы симертү – йокы сутү, диннән язу – деннән язу, сыткый сагыз – сыткы сагыз* шикелле, бер үк мәгънәне белдереп, я лексик, я морфологик, я синтаксик, я фонетик, я әйтелгән билгеләрнең берничәсе белән аерылып тора торган фразеологик әйтелмәләр дә еш очрый. Болар – ф р а з е о л о г и к в а р и а н т л а р. Фразеологик синонимнар белән фразеологик вариантлар арасында охшашлык булу аларны бер-берсе белән бутау мөмкинлеген барлыкка китерә.

Ф.С. Сафиуллина синонимик вариантларга түбәндәге мисалларны китерә: *бүгенге көн белән яшәү – хәзерге көн белән яшәү; тере мәет – җанлы мәет; арка кашу – җилкә кашу; бер түбә*

*астында – бер түшәм астында; авыз пычрату – авыз буяу; таш йөрәк – таш күңел – таш бәгырь; тамактан үтмәү – тамакка үтмәү; сулыш алу – сулу алу; авызга тел сыймау – теле авызга сыймау; сукыр да күрерлек – сукыр гына күрмәс; кеше көлкесе – адәм көлкесе* (Сафиуллина, 1993: 116).

Фразеологик синонимнар фразеологик вариантлардан лексик составларының тулысынча яңартылулары, бер үк төшенчәнең төсмерләрен төрле образлар аша чагылдыру белән аерылалар (Кирсанов, 1959: 52). Мәсәлән: *күзгә төтен җибәрү – кәкре каенга терәтү – агач атка атландыру – борчак сибү – сафсата сату – торна йомыркасы тоттыру* фразеологизмнары «кешене алдау, ялган сөйләү» мәгънәсендә берләшкәннәр. Болар – мәгънәләре буенча якын, ләкин эчке формалары һәм стилистик кулланылыш үзенчәлекләре, функциональ-сөйләм даирәләре буенча аерылып торган фразеологик синонимнар.

*Акыл өйрәтү – акыл сату – акыл чәчү; гомер кичерү – гомер чигү; акылдан язу – акылдан шашу* – синонимик вариантлар, аларның мәгънәләре якын яки бердәй, эчке формалары уртак, ә компонентлар составы өлешчә үзгә. Дөрес, синонимик вариантларның мәгънәләре уртак булса да, стилистик кулланылышлары төрле булырга мөмкин. Алда китерелгән фразеологик вариантларның беренчеләре гомумкулланылыш теленә карый, икенчеләре матур әдәбият стилендә актив кулланыла.

Татар телендә фразеологик вариантлар ясалуда иң продуктив алымнарның берсе – аны төзүче компонентларның берсен яки берничәсен алмаштыру. Бу – фразеологик әйтелмәләрнең лексик вариантын тәшкил итә. Мәсәлән, *йөрәк әрнү, йөрәк ярсу, йөрәк телгәләнү, йөрәк өзелү* фразеологик вариантларын алып карыйк. Аларны бер-берсеннән аеручы компонентлар – *әрнү, ярсу, телгәләнү, өзелү* – семантик-стилистик буяулары бер үк дәрәҗәдәге сүзләр; үзләренең иректе мәгънәләренә синоним булмасалар да, фразеологизмнар составына кергәч, синонимик сүзләр функциясен үтиләр. Үзәк уртак компонентның саклануы әлеге фразеологик вариантларны бер гомуми төшенчә астына берләштерсә, үзгәртелгән компонентлар язучыга сурәтләүдәге бертөрлелектән арынырга, шул ук төшенчәне яңачарак яңгыраштa бирергә ярдәм итәләр. Ә менә *йөрәктән кан таму* әйтелмәсе фразеологик вариант була алмый, чөнки ул экспрессив-эмоциональ төсмере белән алдагылардан бик

нык аерыла, «кан таму» компонентының образлылык дәрәҗәсе үткенрәк булып, психик процессның (тирән эчке газаплануның) тагын да киеренкерәк үтүен аңлата. Шуңа күрә *йөрәктән кан таму* әйтелмәсен *йөрәк әрнү, йөрәк ярсу, йөрәк телгәләнү, йөрәк өзелү* берәмлекләренә карата семантик-стилистик синоним итеп карау дөресрәк булыр.

*Даян сөйләүдән туктады, ә Габдулла ханның йөзе балавыз кебек катып калган иде.* ***Авызына*** *вак* ***таш капканмыни****, бер сүз дә дәшми.* (В. Имамов); ***Авызларына су капкандай*** *дәшми барулары шуны раслый сыман.* (В. Имамов) Мисалларда урын алган *авызга таш кабу, авызга су кабу* фразеологизмнары – лексик вариантлар, ләкин бирелгән җөмләләрдә мәгънәләре бертөрле – сораганга җавап бирмәү, дәшми тору.

Кайбер авторлар әсәрләрендә, фразеологик әйтелмәләрнең я компонентларын алмаштырып, я аңа яңа сүз өстәп, үз вариантларын барлыкка китерәләр. Мәсәлән, Ф. Хөснидә *башны ташка бәрү* тотрыклы сүзтезмәсенең *башны кара ташка бәрү, башны ташка орырдай булу, башын алып ташка орырдай, башка ташны китереп орырлык* вариантлары очрый; Ә. Еники *телгә оста* фразеологизмын *телгә бигрәк тә оста, теле үтә дә оста, теле барыннан да оста* кебек вариантларда куллана.

Чагыштыру сүзләренең алмашынып килүе дә синонимик вариант тәшкил итә. Мисаллар: *Ил-көндәге кайгы-хәсрәтләрне ишеткән саен, күргән саен, минем җилкәмне басып торган олуг хәсрәтем кечерәя барып,* ***инә очы хәтлем*** *генә калды.* (Н. Гыйматдинова); *Яктылык торган саен көчәя бара, инде стенадагы* ***энә очы кадәрле*** *тишекләр дә, идәндәге тар ярыклар да ап-ачык булып күренә иде*. (Н. Гыйматдинова)

Шулай ук морфологик һәм сүз ясагыч чаралар (мәсәлән, исемдә килеш, фигыльдә юклык кушымчалары, инкяр кисәкчәсе, яки *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез*, *-лык/-лек* кушымчалары һ.б.) да синонимик вариантлар тудыра ала. Мәсәлән, *әдәп саклау – әдәпсезлек күрсәтмәү* фразеологизмнарында фигыль белән белдерелгән компонент, юклык формасында кулланылып, *әдәп саклауга* мәгънәдәш булган фразеологик вариант төзи. *Чиктән ашу – чикне ашу; әллә нигә бер – әллә нидә бер; тамактан үтмәү – тамакка үтмәү; ике сөйләмәү – ике сөйләшмәү; беткән баш беткән – беткән баш бетсен; шайтан алгыры – шайтан алсын; һава алмаштыру – һава*

*алмашу; җан үртәү – җан үртәлү; иртәге көн – иртәгесе көн; эче калтырый, тышы ялтырый – эчтән калтырый, тыштан ялтырый; су сорасаң бал бирәләр – су сораганга бал бирәләр; чебен очканы да ишетелә – чебен очканы да ишетелми; тасма тел – тасма телле; юл аерылу – юллар аерылу* – морфологик вариантларга мисаллар. Контекст эчендә кулланылышын карыйк:

***Тын алгысыз*** *кысан тар бушлыктан*
*Җаным очар кебек кош булып.* (Р. Аймәт)
*Сулыш җитми аңа, дөнья тар*
***Тынын ала алмый*** *җан асрый...* (Г. Сәгыйров)

Синтаксик яктан синоним фразеологик әйтелмәләрнең компонентларының сүз тәртибе үзгә була. Мәсәлән: *илаһи уптым – уптым иллаһи, авызга тел сыймау – тел авызга сыймау, кул-аяк тимәгән – аяк-кул тимәгән, алга-артка карамау – артка-алга карамау.*

Фонетик вариантларда аваз үзгәрешләре була. Мәсәлән: *сыткый сагыз – сыткы сагызы; нәгъләт камыты – нәләт камыты; Ходай бәндәсе – Хода бәндәсе; илла мәгәр – иллә мәгәр; диннән язу – деннән язу.*

Фразеологизмнарның синонимик төрләре, вариантлары контекст эчендә сүзләрнең кабатлануыннан, стилистик бертөрлелектән арындыра, телне баетуда, үтемле итүдә зур роль уйный.

## § 54. Фразеологик антонимнар

Мәгънәләре белән капма-каршы характерда булган фразеологик әйтелмәләрне ф р а з е о л о г и к  а н т о н и м н а р дип йөртәләр. Фразеологик берәмлекләрнең антонимик характерда була алуы, күбесенең аерым сүзләргә һәм сүз тезмәләренә капма-каршы мөнәсәбәттә торуы – үзенчәлекле күренеш. Фразеология мәсьәләләрен яктырткан кайбер хезмәтләрдә (Л. Җәләй, Г. Алпаров, Ш. Рамазанов) фразеологизмнарның, гади тел берәмлекләре кебек, бер-берсенә капма-каршы характерда булулары искәртелә. «Кайбер тәгъбирләр билгеләрне бер-беренә каршы куеп сурәтләүне белдерәләр: *зәмһәрир тәмугысы, зәмһәрир суык*: дини ышану буенча, Зәмһәрир – җиде тәмугның берсе булган салкын тәмуг, гөнаһлыларны җәзалау өчен иң зәһәр суыклар суыгы; *баш мие кайнарлык*: бик эссе, бөркү һава (Рамазанов, 1954: 49).

Фразеологик антонимнарга җитди караш Г.Х. Ахунҗановның «Татар теленең идиомалары» хезмәтендә ачык чагыла. Ул,

беренчеләрдән булып, әлеге тел күренешенә билгеләмә бирә һәм капма-каршы мөнәсәбәттәге фразеологик әйтелмәләрнең төрләрен аерып чыгара. «Бер-берсенә һәм аерым сүзләргә, сүз тезмәләренә карата капма-каршы мәгънәдә торучы күчерелмә мәгънәдәге тотрыклы сүз тезмәләре фразеологик антонимнарны тәшкил итә» (Ахунҗанов, 1972: 62).

В.Х. Хаковның «Татар әдәби теле тарихы» хезмәтендә антонимик характердагы фразеологизмнарның кулланылышына мисаллар китерелгән. «Төрле мәгънә төсмерләренә ия булган сүзләр (полисемантик сүзләр), фразеологик әйтелмәләр составында катнашып, бер-берсенә капма-каршы булган мәгънәгә дә ия булырга мөмкиннәр. Мәсәлән, *тел* сүзе кергән тезмәләр: *тел бәйләнү – теле телгә йокмау, телдән төшү – телдән төшмәү, ачы телле – татлы телле, телсез калу – тел озайту* һ.б.; *баш* сүзе кергән фразеологик берәмлекләр*: баш кагу – баш тарту, баш бирмәү – баш бөгү, башка килү – баштан чыгу, башка бәхет кошы куну – баш бетү* һ.б.» (Хаков, 1993: 136–137).

Фразеологик антонимнар, образлы сурәтләү чаралары буларак, матур әдәбиятта һәм сөйләү телендә әһәмиятле урын тоталар. Аларның сәнгатьлелеге, стилистик төсмерләре, тәэсир итүчәнлекләре, гади антонимнар белән чагыштырганда, күпкә көчлерәк, үтемлерәк һәм җанлырак. Дөрес, бөтен сүзләрнең дә антонимнары була алмаган кебек, барлык фразеологик әйтелмәләрнең дә антонимнары юк. Алар фразеологик синонимнарга караганда сирәгрәк очрый. Төрләренә килгәндә, фразеологик антонимнарның үзгә һәм охшаш төзелешле төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Беренче төрнең эчке формалары, образ структурасы төрле, ә мәгънәләре капма-каршы була. Мисаллар: *егылып эшләү – юкны бушка аудару; кара гыйлем – ак сихер; нужа сөрү – рәхәт күрү; телгә килү – авызга су кабу; кул сузымы арада – җәһәннәм читендә; якты чырай күрсәтү – кара көю; менә дигән – ни санга, ни чутка; менә дигән – өч тиен тормау; бер аягы белән кабердә тору – борын асты кипмәгән; йөз аклыгы – кара йөз; бармак белән санарлык – тавык чүпләп бетерә алмаслык;*

*Гарифә. Нидән* ***күңелең*** *болай* ***күтәренкеләнде****?*

*Басыйр. Синең* ***чыраең караңгы*** *булганга сөенеп. Һи-һи-һи.* (З. Хәким) *– күңел күтәренке булу – шатлану, куану – чырай караңгы булу – борчылу, кайгыру; Кәшифә. Мин инде* ***үземне кая куярга***

***белмим***. *Өйдәгеләр борчылуымның сәбәбенә төшенсәләр дә, **исләренәдә кертеп чыгармыйлар.*** (З. Хәким); *үзеңне кая куярга белмәү* – кайгы-хәсрәт кичерү, бик нык борчылу, газаплану; *исләренә дә кертеп чыгармау* – уйлап та карамау, тыныч булып калу, беригә дә борчылмау; *Башкалар янында көлеп-шаярып, **җүләр сатып** йөрергә яраткан егет мәгъшукасы янында бөтенләй икенче кешегә әверелә – уйчанлана, **акыл иясенә әйләнә.*** (Х. Ибраһим) *Үзе дә шыр аңгыра түгел, казах абый ачыктан-ачык әйтмәсә дә, нинди **кармакка килеп капканын** тиз аңлады ул. Һәм, студентларның үз иптәшләре өстеннән әләк ташыган «стукач»ларга мөнәсәбәтен яхшы белгәнгә күрә, беренче минутта, ничек тә булса **шома гына ычкынырга** кирәк моннан дип, эченнән генә бик катгый карарга килеп куйды.* (М. Маликова); *кармакка килеп эләгү* – хәйләкәрнең татлы сүзенә, ялтыравыклы вәгъдәгә, хәйлә-мәкеренә алдану; *шома гына ычкыну* – берәр кешегә бәйлелектән котылу, буйсынудан чыгу.

Икенче төр фразеологик антонимнар уртак төзелешле, бары кайбер лексик составлары ягыннан гына өлешчә үзгә булалар: *авыз ачу – авызга су кабу;җеп очын югалту – җеп очын табу; җил каршы исү – җил уңай исү; агым уңаена йөзү – агымга каршы йөзү; сөйкемле сөяк – сөйкемсез сөяк; җан рәхәтләнү – җан газаплану; акыл сату – юләр сату; кулга төшерү – кулдан ычкындыру; дөньяга килү – дөньядан китү; борын күтәрелү – борын төшү; күңел төшү – күңел күтәрелү; кәеф килү – кәеф китү; сүздә тору – сүздә тормау; сүздән кайту; тәкать итү – тәкать китү*. Күргәнебезчә, мондый фразеологик антонимнар компонентларның берсен антоним сүзгә алмаштыру юлы белән ясалганнар.

***Сүз өзелеп** торды. Әмма Давыт биреште, саламга тотынгандай, **сүзне ялгап** китте.* (М. Маликова); *сүз өзелү* – сүз тәмам булмыйча калу, ахырга кадәр сөйләшеп бетермәү; *сүз ялгау* – башланган сөйләшүне дәвам итү. *Шундый авыр уйлар белән **башым** тәмам **тулган** иде, рәхмәт сиңа, тыңлаганың өчен, аңлаганың өчен рәхмәт. Эчемне бушаттым, җиңел булып китте. Бәлки, бүген уянмый йоклап булыр. **Башның саф булуы** кирәк миңа.* (М. Маликова); *баш тулу* – баш юк-бар уй белән тулу, зиһен чуалу, кирәген уйлый алмау; *баш саф булу* – кирәкмәс нәрсәләрне уйламау, оныту. *Бу юлы чиратта утырасын алдан белеп, кулына берничә гәзит тотып барды ул һәм тирә-ягындагы сөйләшкәннәрне **колагына***

***алмаска** тырышты. Әмма пенсия яшьләрендәге бер абыйның кызып-кызып нидер сөйләвенә битараф кала алмады, **колакларын торгызды.*** (Ф. Бәйрәмова); *колакка алмау* – ишетмәү; *колакларын торгызу* – ниндидер сүзне, хәбәрне, яңалыкны ишетергә теләп бик игътибар белән тыңлау.

Контекст эчендә генә антоним итеп карый ала торган фразеологик әйтелмәләргә түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *Ләкин Каюмның Марзияга: « – Ташла, юләр! Сине бөкәй белән курыктканнар. **Бала булма, башыңа миеңне җыйна**».* (Ш. Камал); *Сезнең терлекчеләр өе **оҗмах кебек**, ә безнекеннән **куркып качарсың**.* (А. Гыйләҗев)

Фразеологизм аерым сүзгә һәм иректле сүзтезмәгә дә антоним булып килергә мөмкин: *шалкан бәясе – бик кыйммәт; бака ботыннан гына – биек; балагын җыя алмау – пөхтә, җыйнак булу; буа буарлык – бик аз; мәми авыз – уңган; ут борчасы – җебегән; куян йөрәкле – батыр; онытканда бер – еш; күпне күргән – тәҗрибәсез; күктән төшү – тырышып эзләп тә таба алмау; телеңне йотарлык – бик тәмсез.*

Һидият (Мостафага): *Ячейка секретаре булганнан бирле әмма да вәгазь-нәсихәткә остардың, Мостафа! Гел **сөйләтеп кенә торырлык** үзеңне! – Ә синең гел **авызыңны ябып тотарлык.*** (Ш. Камал)

Шулай итеп, фразеологик антонимнар язучылар өчен телнең байлыгын һәм образлылыгын күрсәтүдә төп чыганакларның берсе булып тора. Әдәби әсәрләрдә капма-каршы мәгънәле фразеологик әйтелмәләрне куллану – бик нәтиҗәле стилистик алым, чөнки алар төрле күренеш, билге, халәт, сыйфатларны капма-каршы куярга, үсеш һәм каршылыкларда күрсәтергә мөмкинлек бирәләр.

## § 55. Фразеологизмнарның эмоциональ-экспрессив һәм коннотатив үзенчәлекләре

Коннотация төшенчәсе бәяләү, эмоциональлек, экспрессивлык кебек элементларны берләштерә. Эмоциональлек – сөйләүченең (язучының) сөйләм (язу) предметына карата хис-тойгыларын белдерү ул. Экспрессивлык исә – эш-хәрәкәтнең, билгенең белдерелү интенсивлыгы. Бәя бирү дигәннән, теге яки бу предметны, затны, күренешне һ.б. уңай яки тискәре яктан бәяләү күз алдында тотыла.

Фразеологик әйтелмәләр, сүзләр кебек, атау функциясен башкаралар. Ләкин бу функция фразеологизмнар өчен беренчел түгел. Аларның төп вазифасы – сөйләмне эмоциональ итү, экспрессив төсмерләр белән баету, затларга, предметларга, күренешләргә һәм вакыйгаларга бәя бирү. Әйтик, *бай* һәм *май кайнаган көнне туган* берәмлекләре икесе дә кешенең матди хәленең яхшы булуын күрсәтә, ләкин икенчесендә бу мәгънә интенсивләк һәм уңай эмоциональ төсмер белән сугарылган. *Бер тиен өчен җанын сатар* берәмлеге саран кешене атап кына калмый, мондый сыйфатка ия кешегә карата тискәре мөнәсәбәт белдерә һәм сөйләмне эмоциональ-стилистик төсмерләр белән баета. Фразеологизмның бәя бирү үзенчәлеге көчлерәк булган саен, аның атау функциясе арткырак планга күчә. Контекстта тотрыклы сүзтезмәләрнең мондый сыйфаты аеруча ачык сизелә. Мәсәлән, *Мәктәп баласы бит син, Минһаҗева. Тәртибең **өч тиенгә яраксыз*** (Н. Гыйматдинова) җөмләсендә *өч тиенгә яраксыз* фразеологизмын мәгънәдәш *бик начар* сүзе белән алыштырсак, контекст эмоциональ яктан сизелерлек ярлыланыр, экспрессивлык тоныкланыр иде.

Бу бүлекчәдә без татар телендә кешенең кайбер эчке һәм тышкы сыйфатларын уңай яки тискәре яктан характерлый торган фразеологик берәмлекләрне барлап, аларга хас стилистик үзенчәлекләрне билгеләрбез.

Алдарак фразеологизмнарның милләтнең иҗтимагый-психологик үзенчәлекләрен ачуын искәрткән идек инде. Әлеге фикер кешегә бәя бирә торган фразеологизмнарны өйрәнгәндә аеруча урынлы. Татар халкы кешенең нинди сыйфатларын аеруча мактый, кайсы сыйфатларын башкалардан өстен куя? Әлеге сорауларга җавапны без фразеологизмнар ярдәмендә табарга тырышырбыз.

Әйтәсе сүзен матур итеп оештыра белгән, җор телле кешеләрне мактаучы фразеологизмнар: *авызы белән кош тота; авызына карата; авызына Хозыр төкергән; авызында кош уйната; авызыннан энҗе-гәүһәр түгелә; бал авыз; бер әйтер – берәгәйле әйтер; илне авызына карата; сүзе белән эретә; сүзгә алгыр; тел чарлаган; телгә үткен; теле белән кош тота; теле белән тигәнәк алыр; теле белән судагы шайтанны чыгарып утка кертә; теле белән эретә; теле чарланган; теле шомарган; телләреннән гөлләр түгелә; теле телгә йокмый; җавапка кесәгә керми; җавапка күршегә керми; эчеңә кереп ятар; ыспай сүзле*. Мәсәлән, Үзе ***сүзгә бик алгыр***, бик чапак. (Г. Ибраһимов)

Биргән вәгъдәсенә туры калучы, һәр әйткән сүзен үлчәп сөйләшүче кешеләрне тасвирлаучы фразеологизмнар: *авызына хуҗа була белә; сүзенең ире; үз сүзенә үзе хуҗа.*

Кешенең акылын зурлый торган берәмлекләр: *аек фикерле; аек фикер иясе; авыздан чыгуга эләктереп алу; акылга беткән; акылга утырган; акыл иясе; акыл кергән; акылга беткән; акыл капчыгы; акыллы баш; акылы камил; акылы хәзинә; башлы кеше; башлы көлтә; иллә дә баш үзендә; фикер иясе; хикмәт иясе; бер сүзе мең алтын.*

Болар янына гыйлемне зурлаучы берничә фразеологик берәмлек килеп кушыла: *гыйлем иясе; фән иясе; уникe фән күргән.* Мәсәлән, *Шәкерт әнисе, **гыйлем иясе** булачак кешенең әнисе...* (Ә. Еники)

Фразеологизмнарның күбесе кешенең тәрбиялелеген, затлылыгын, зыялылыгын тасвирлый: *агызмаган бал; алтын кеше; асыл зат; асыл кеше; ата баласы; газиз баш; изге җан; изге җанлы; халык улы; менә дигән.* Мәсәлән: *Кызыйның **менә дигәне** эләкте. Телле-тешле түгел. Кая җибәрсәң, шунда бара, шәп кыз дип мактаган иде.* (А. Гыйләҗев)

Халык арасында абруй казанган, өстен дәрәҗәле кешеләр турындагы берәмлекләр: *ат алу; ил кешесе; ил кызы; илне авызына карату; хөрмәт иясе; өстен кеше.*

Дөньяны күргән, тәҗрибә туплаган кешеләргә карата әйтелә торган фразеологик берәмлекләр дә күп: *адәмгә саналу; адәм булу; азау теше ярган; азау тешен ашаган; акыл теше чыккан; дөнья күргән; пешеп чыккан.* Мәсәлән: *Ә анда эшне тиз тоталар: белемле, яшь кенә булуына карамастан, шактый **дөнья күреп өлгергән** егетне ДОСААФ курслары буенча алты айга шофёрлыкка укырга җибәрәләр.* (Көндәлек матбугаттан)

Әлеге берәмлекләр рәтеннән кешенең илгә-гаиләгә файдалы, ышанычлы терәк булуын ассызыклаучы фразеологик берәмлекләрне дә әйтик: *алтын багана; алтын бусага; арка таянычы; арка терәге; дөнья терәге; дөнья тоткасы.*

Акыл белән эш итүче, алдан күрүчән кеше турындагы фразеологизмнар да табыла: *алдын-артын карап эш итү; итәген җыеп йөрү; биш үлчәп бер кисәр; үлчәп сөйләү*.

Кешенең уңганлыгын, тырышлыгын аңлаткан фразеологизмнар иң зур күләмле тармакларның берседер, мөгаен: *алтын кул;*

*алтын куллы; арбасын тауга менгергән; арыслан сырты; билне буып туган; бер дә килмәгән җире юк; бер дигән; дөнья шауламу; дөнья җимертеп эшләү; егет дисәң дә егет; егет җелеге; егет солтаны; кулдан эш килү; таякны тоткан җирдән сындыру; төскә матур, эшкә батыр; төшеп калганнардан түгел; ут егет; ут кул; ут кебек йөрү; ут уйнату; ут чәчеп, буран уйнатыр; эшкә кулы ята; эшкә оста, сүзгә кыска; эш рәтен белү; эш җанлы; югын бар итеп, барын бал итеп; өлгер тоту; өстенә кояш чыгармау; елан аягын кискән; җылан күзле; арыслан тырнаклы; җиңел аяклы; җиңел сөякле; җиңелнең астыннан, авырның өстеннән; җепне тешләгән җиреннән өзә; яшен ташы кебек.* Мәсәлән: *Себеркесе белән **ут уйната**, ат сараеның идәне уңган килennнең сәкесе тиң ялтырый.* (А. Гыйләҗев)

Батырлыкка, кыюлыкка, чыдамлылык турында сөйләүче фразеологик берәмлекләр: *арыслан авызыннан сөяк алырдай; арыслан йөрәк; сырты сынса да, сер сынатмас; сырты сынар – сер сынатмас; тимер йөрәк; әҗәлен авызына тешләп; өркә торган куян түгел; һәлакәт күзенә карау.*

Физик көчне тасвирлаучы берәмлекләргә түбәндәгеләр керә: *аю егарлык егет; аю кебек; басса бакыр өзәрдәй, типсә тимер өзәрдәй; гернадыр кебек; сукса тимер өзәрдәй; сукса тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек; сукса, тугыз көн чумар ашамассың; сукса, чумарыңны чыгарыр; таза мортаза; үгез кебек.*

Мәсәлән: *Бер яктан, эшелон-эшелон булып, сугышта имгәнгән кешеләр кайта, икенче яктан, алар урынына **басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек** егетләрнең китеп торган чагы.* (К. Әмири)

Кешенең тышкы матурлыгын тасвирлый торган фразеологик берәмлекләр: *ай дисәң авызы, көн дисәң күзе; алма бит; бер кашык суга сал да йот; асыл кош; йөзе кояш булу; йөзе якты, бите ачык; керфегеннән гөл тамар; кура җиләге күк; нечкә бил; нәзкәй бил; эшкә батыр, төскә матур; тал чыбыгы кебек; угата чибәр; хур кызы* һ.б. Мәсәлән: *Менә, ди, Шаһи картның **алма кебек** кызы бар, эшкә дисәң, авылда бер. Үзе шундый сылу, шундый зифа – **бер кашык суга сал да йот**.* (Г. Ибраһимов); *Мин, **хур кызы** дип мактасагыз да, сезнең коры сүзегез буенча, башкода җибәрү ихтималым юк.* (Г. Ибраһимов); *Зифа буең, талчыбыктай билең, **Эчләреңнән энә үтәрлек**...* (Г. Сәгыйров)

Фразеологизмнарның бер өлеше ачык, кунакчыл, саф күңелле, эчкерсез, һәркемгә гадел мөнәсәбәттә торган кешеләрне аерып, аларны метафорик чаралар ярдәмендә, матур сүзләр кулланып сурәтли: *ай белән көндәй, һәркемгә бердәй; ак күңелле; ак эчле; ачык йөз; ачык йөзле; ачык кеше; ачык куллы; ачык күзле; ачык күңелле; зур йөрәкле; ил фәрештәсе; икмәкле-тозлы кеше; йөз ак булу; йөзе ак; алыны ачык; йөзе ак; кулы ачык; йөзе ачык; кече күңелле; кулым ачык; йөзем ак; кулым кара; йөзем ак; судан пакь, сөттән ак; сөттән ак, судан пакь; сөттән ак, чынаяктан пакь; туры кеше; тәкъва кеше; тәүфыйклы яр; шәфкать иясе; эче белән тышы бер; Әюп пәйгамбәр сабырлыгы; өй кысан, күңел иркен.*

Мөстәкыйльлеккә омтылучан, җаваплылыкны үз өстенә ала торган кешеләр турында болай диләр: *үзе баш, үзе муен; үзе баш, үзе түш; үзенә үзе баш; үз исәбе үзендә; үз көнен үзе күрү*. Мәсәлән, *«Әти, – диде, –* ***үз көнемне үзем күрә башлаганчы****, миңа бәләкәй генә матай алып бирерсең инде, яме, мин буш вакытларымда синең янга кайтып йөрермен»*. (Г. Ахунов)

Бәхетле кешеләрне татар фразеологизмнары түбәндәгечә тасвирлый: *алтын бишектән төшкән; әтәче дә күкәй сала; май кайнаткан көнне туган.*

Кешегә тискәре мөнәсәбәт, аны санламау, дәрәҗәсен төшереп күрсәтү мәгънәсе *сукыр бер тиен дә тормый; аяклы каза; бер тырнагына да тормый; арбаның бишенче көпчәге; хаҗәте бер тиен; ужым бозавы; мәми авыз; юаш бозау; шомарган бер тиен; бер тиенгә дә кирәкми; бер тиенгә дә санамау; Балык Бистәсе – ун тиен дистәсе; бары-югы бер; баш-аягың бер казан; Алла аны дөньяның бер җире буш калмасын дип яраткан; поты бер тиен; ни җитте кеше; адәм рәтле булмау; башы-тоягы бер тиен* кебек берәмлекләрдә чагыла. Мәсәлән, *«Юкка түгел, Ишмөхәммәт абый, – диде Мәдинә, –* ***ни җитте кешегә*** *кияүгә чыгам дигән булып башыма бәла аласым юк. Ә инде* ***адәм рәтлесе*** *балалы хатын белән нишләсен?»* (Ш. Камал); *Имгәк! Җебегән! Куркак! Мондый* ***юаш бозау*** *булып үссәң, синнән тәхет яуларлык хан чыгачакмыни?* (В. Имамов); *Синең кебек* ***аяклы казалар*** *белән авыл тулган!* (С. Шәмси)

Татар фразеологизмнары арасында акылы зәгыйфь кешеләрнең кимчелекле булуына ишарәли торганнары күп: *акылга тулы түгел; акылга зәгыйфь; балта сабы кыска булу; унга тугыз тулмаган; акылы утыз тугызлы гына; унга бер тулмаган; туксан*

*тугызлы; тугыз төймә; потка бер кадак тулмый; башка тай тибү*. Мәсәлән, *Мондый зур эшне аларга ышанып тапшыру ярамас... Рушанның вакыты бик тар, ә тегесенең* ***балта сабы кыска,*** *– диде ул, бераз уйланып алганнан соң*. (Р. Мирхәйдәров); *Шуны да аңламаска,* ***башыма тай типмәгәнлә!*** (Ф. Бәйрәмова)

Саранлыкка карата кулланылган фразеологик берәмлекләр: *үлгән вакытында бер эчем (йотым) су бирмәс (җан биргәндә дә авызыңа бер кашык су салмас); ике тишекле бер тиен бирмәү; бер шырпыны бишкә ярып кабызу; бер тиенгә бетәшкән; бер тиене онытылып калса, йөз чакрым кире кайту; бер тиен өчен дерелдәп тору; бер тиен өчен чәрәеп каткан; бер төйнәгән йодрыгын патша килсә дә ачмас; бер тавыкны унга бүлү*. Мәсәлән, *Бүтән ялчылар кебек* ***бер тиенгә бетәшеп*** *азапланмавы үзе үк Сәлимне бу шат күңелле егет алдында яшерен шиккә салган иде*. (Ф. Хөсни)

*Бер агач утын юк; бер тиенсезгә калу; бер күлмәк белән калу; уникенең бере юк* дип фәкыйрь, акчасы булмаган кешеләргә әйтәләр. Мәсәлән, *Ичмасам, хатын да* ***бер күлмәк белән калуны белми,*** *көннәр салкынайды, җылы кием кирәк иде дип борчый*. (Г. Толымбай)

*Бер тиен өчен йолдызга кармак ату; бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулашу; бер тиен өчен чукынып тору; бер тиен өчен җанын сатар; бер тиен өчен җәһәннәмгә керер* әйтелмәләре исә акча колы, бер тиен өчен җанын, иманын саткан, акчага табынып, җинаятьтән дә курыкмаган кешеләр турында әйтелә. Мәсәлән, *Иманкол исә* ***бер тиен өчен кара тиргә төшеп*** *сатулаша*. (К. Нәҗми)

Сүз көрәштерә торган яки сөйләүдән туктатып булмый торган кешеләр турында *бер теленә баш була алмый; бер телгә биш тел; бер сүзгә биш (ун; мең)сүз; бер дә атасы-анасы юк; бер тиен биреп сөйләтеп булмас, ике тиен биреп туктатып булмас* диләр. Мәсәлән, *Ай Алла,* ***бер телеңә баш була алмадың*** *лабаса.* (М. Әмир)

Татар фразеологик берәмлекләре арасында кеше талау, җәзалау, туганнардан үч алу, сугышу, дошманлык мөнәсәбәтләрен белдергәннәре дә бар: *берне кундыру (тамызу); җиде буынга җитү; җиде кат тиресен тунау; җиде бабасын таныту; берне бирү (ману, сибү, сылау, ямау, чалтырату); ипи шүрлегенә менеп төшү; кулы белән уйнау; бер-ике рәт ману; бер-бер артлы кундыру; биштән төргәнне күрсәтү (иснәтү); озын кул*. Мәсәлән, *Мин әле сине болай гына калдырмам****, җиде буыныңа җитәрмен.***

(Г. Камал); *Берни булды исә, күкерт кебек кабынып китә дә хәзер* ***кулллары белән уйный*** *башлый.* (Ф. Бәйрәмова); ***Кулы белән уйнамаган*** *булса, гафу да итәр идем, тик хатын-кызга кул күтәргән ир ирмени инде ул?*(Х. Ибраһим); *Син үлчәп сөйләш, агай-эне... Юкса мин* ***ипи шүрлегеңә менеп төшәргә*** *дә күп алмам.*(Х. Ибраһим)

Ялгыз кешегә мөнәсәбәтле мондый фразеологизмнар очрый: *бер башы; бер башы да бер тамагы; үзем дә ике күзем; ялгыз Ярулла*.

Кешеләрнең башка тискәре сыйфатларын тасвирлаганда түбәндәге берәмлекләр кулланыла: *бер нәфесен тыя алмый* (комсыз); *артына бер төшеп, алдына биш төшеп; ике койрыклы; тәлинкә ялый; тәлинкә тота; алдында тугызга бөгелә* (ялагай); *сабын куыгын очыра* (мактану); *борын күтәреп йөрү* (тәкәбберлек); *кырыгы кырык җирдә ярылып ята* (җыйнаксыз; тәртипсез); *ике кулы кесәсендә; ике кул белән җил аударучы* (эшлексез); *алты сукканга бер атлаган ала бия кебек; бер аягын атлаганчы икенчесен эт ашый* (ялкау); *анасының карынында ничек тугыз ай да ун көн чыдап торган* (түземсез); *кырык алдар; ике аяклы бүре; кәкре каенга терәткән* (алдакчы); *ике ат бер тиен, ике чабата бер кием; кырыгы кырылып ятсын, әйләнеп тә карамас; ике дөнья – бер морҗа; ике йоклап бер төшенә керә* (ваемсыз; битараф); *сиңа ышанганчы, диңгездә батканда ике терсәгеңә ышанган артык* (ышанычсыз); *ике яклы пычак (икейөзле); кырыгына бер иман* (имансыз); *ике битле ком икмәк; ике йөзле (яклы) пычак; ике сүзле; ике телле; ике яклы кеше; ике йөзле* (икейөзле); *башындагы бүреген бер көн буе эзләгән; юка баш* (хәтерсез). Мәсәлән, *Миңсылу: «Водокачка китердек дип, Каюм абзый белән Әхмәт* ***борыннарын күтәргән*** *иделәр. Водокачкалары су бирә алмагач,* ***борыннары төште*** *бугай».* (Ш. Камал); *Сиңа шул* ***сабын куыгы очырырга*** *булсын, бер башласаң, туктатып булмый* (М. Мәһдиев); *Хәер, кешеләр бөтен җирдә дә Фирдүс кебек* ***ике яклы пычак*** *түгел лә!* (М. Маликова); *Дөньялардан китеп йөрисең, туган... соң бит, кичә генә сөйләшенде, Бака күле янында җыелышабыз дип, син* ***юка баш*** *аркасында күпме балык әрәмгә китте...* (И. Хәйруллин)

Татар телендә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлый торган фразеологик берәмлекләр арасында ямьсез итеп сыйфатлаганнары да бар. Мәсәлән, үтә ябык, арык гәүдәле кешегә карата *бер карга туярлык ите юк; ике күзе генә калды; тәндә бер җаны гына бар; эченә сәнәк белән төртсәң, бер тамчы каны чыкмас; үтәдән-үтә*

*күренә торган* дип әйтәләр. Мәсәлән, *Ә өрәк кебек **утәдин-утә күренә торган** чиле-пешле пер... персонажлар монда кертелми*! (А. Тимергалин)

Какча гәүдәле кешегә карата исә *тугыз буын; биш бөкләм* әйтелмәсе кулланыла. Юан, таза кешеләргә карата *ярсаң ике, томырсаң өч булырлык; сиңа, болай ашасаң, унике башлы тегермән дә җитмәс* дип әйтәләр. *Дөя шикелле бер төз җире юк* әйтелмәсе ямьсез буй-сынлы кешене тасвирлый.

Сукыр кешегә *тугыз сукырның сыңар таягы* диләр. Озын борынлы кешене *борыны белән бер сукса, үләрсең* яки *борынына тугыз күркә сыярлык* дип тиргиләр. Төсе-бите кара кешеләргә *чуенның ундүртенче кичәсе кебек* диләр. Мәсәлән, *Безнең бер асрау бар, йөзе нәкъ менә **чуенның ундүртенче кичәсе төсле** кап-кара.* (Г. Камал) Ямьсез, котсыз әйбердән яки кешедән бизүгә карата *бер күрмәскә әллә ни бирерсең; җиде еллык бизгәгең качырырлык; пәри чабаклаган* берәмлекләрен кулланалар. Мәсәлән: *«Әйдәгез, – мәйтәм, – егетләр, төкерегез үзләренә, шул **пәри чабаклаган**, чалыш аяклы кызларга!»* (А. Шамов) Калын иренле кешегә исә ирене куянныкы кебек ике бүлтәкле диләр.

Карт яки үлеме якынлашкан кешегә карата ачуланып әйтелә торган фразеологик берәмлекләр дә очрый. Мәсәлән, *Үзеңнең **бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә,** картайган көнеңдә мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде*. (Г. Камал) *Ике аяк, бер таяк* дип авыруларга, таякка таянып йөрүче аксакка карата әйтәләр.

Кайбер фразеологик берәмлекләр кешегә карата ирония белдерәләр. Шулай ук мәзәкчәдән кереп калган фразеологизмнар да бар. Мисал итеп, елкы көтәргә ялланган Мокыт агайның үзе атланган атны исәпкә кертмичә, бер атым югалды дип, ат эзләп йөрүе турындагы мәзәкчәдән алып әйтелгән *астындагын алты ай эзләгән* әйтелмәсен китерергә була. Ул хәтерсез кешеләрнең үз кулына тоткан яки күз алдында гына яткан әйберләрен эзләгәндә көлеп әйтелә.

Күргәнебезчә, фразеологик берәмлекләр аерым сүзләргә яки ирекле сүзтезмәләргә караганда сөйләмне образлы, бизәкле, тәэсирле итүдә отышлы чара булып торалар. Алар зат, предмет, билге, эш-хәрәкәт, вакыйга, күренешләрне генә атап калмыйлар, ә авторның яки сөйләүченең шуларга карата фикерен белдерәләр, уңай яки тискәре яктан бәялиләр, көчле экспрессия белән сугарылып, сөйләмне стилистик яктан бизиләр.

## Фразеологик әйтелмәләрнең грамматик үзенчәлекләре һәм структур модельләре

### § 56. Фразеологизмнарны грамматик яктан характерлау

Фразеологик әйтелмәләр лексик-грамматик мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре буенча сүзләргә якын торалар, ә структур яктан сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне хәтерләтәләр. Фразеологик берәмлекләр дә, сүзләр дә, тел берәмлекләре буларак, гомуми тел төзелеше закончалыкларына буйсынып төзеләләр, бер үк грамматик нормаларга нигезләнәләр, лексик яктан затларны, предметларны, күренешләрне, вакыйгаларны атау, характерлау һәм аларга бәя бирү өчен кулланылалар. Дөрес, фразеологик әйтелмәләрдә һәм сүзләрдә телнең лексикасы да, грамматикасы да, бу берәмлекләрнең төзелеш үзенчәлекләреннән һәм эчтәлекләреннән чыгып, төрлечә, үзенчәлекле чагылыш таба.

Фразеологик әйтелмәләрнең грамматик формалары турында мәгълүмат биргәндә, галимнәр, башлыча, аның сүзтезмә формалы булуына игътибар итәләр. Мәсәлән, Г.Х. Әхәтов: «…фразеологик әйтелмә – сүз белән сүзтезмә арасында ята торган категория ул», – дип яза (Әхәтов, 1982: 4).

Татар тел белемендә фразеологик әйтелмәләрнең грамматик формаларын тулы яктырткан беренче хезмәтләрдән Г.Х. Ахунҗановның «Татар теленең идиомалары» (Казан, 1972) монографиясен атыйбыз. Монда ул идиомаларның сүзтезмә һәм җөмлә формалы булуын ассызыклый, аларның грамматик үзенчәлекләрен тикшерә. Дөрес, җөмлә формалы идиомалар арасында мәкаль һәм әйтемнәр, канатлы сүзләр дә бар.

Синтаксик яктан сүзтезмәләр, компонентлар арасындагы мәгънә кисәкләренең югалу-югалмавыннан һәм шуның нәтиҗәсендә сүзтезмәнең ныгып калуыннан чыгып, ирекле сүзтезмә һәм фразеологик сүзтезмәгә бүленә. Синтаксис фәнендә ирекле сүзтезмәләр өйрәнелә. Фразеологик сүзтезмәләр исә синтаксиста сүзләр арасында бәйләүче чараларны тикшергәндә генә искә алыналар. Чөнки алар ирекле сүзтезмәләргә компонентларының телнең синтаксик нормаларына нигезләнеп бәйләнешкә керүләре белән якын торалар. Безнең фикеребезчә, «фразеологик сүзтезмә» терминын киң куллану төгәл түгел, чөнки: беренчедән, фразеологик әйтелмә кимендә ике сүздән тора һәм инде, асылда, сүзтезмә

тәшкил итә, икенчедән, фразеологик әйтелмә җөмлә формалы да булырга мөмкин.

Чыннан да, күпчелек фразеологик әйтелмәләрнең төзелеше традицион синтаксис нормаларына туры килә. Дөрес, фразеологик әйтелмәләрнең гади сүзтезмәләр һәм җөмләләр белән мөнәсәбәттәшлеген шартлы күренеш итеп карарга кирәк.

Сүзтезмә формалы фразеологик әйтелмәләргә килгәндә, алар гади һәм катлаулы булалар, ияртүле һәм тезүле бәйләнешкә нигезләнеп төзеләләр. Гади сүзтезмә формалы фразеологик әйтелмәләр ике мөстәкыйль сүздән тора: *бишенче көпчәк;биштән йомарлау; кырык ямаулы; беренче карлыгач; икенче яшьлек; җиде ят; мең төрле; ике талигале;* икедән артык мөстәкыйль сүздән торса, катлаулы сүзтезмә формалы фразеологик әйтелмә оеша: *ике кулга бер эш; диңгездән бер тамчы; унҗиде яшьлек җилкенчәк.*

Ияртүле бәйләнешкә нигезләнгән берәмлекләрнең компонентлары арасында төгәлләүле мөнәсәбәт урнаша. Алар бу фондта төп урынны алып тора: *бер сүзгә килү; мең дә берне белү; биш көнлек дөнья; кырыкка ярылу; йөзгә бер тулмаган, бер сүзгә килү; ике ут арасында калу; мең дә берне белү; биштән йомарлау.*

Тезүле бәйләнеш үз чиратында җыю, каршы кую һәм бүлү бәйләнешләренә нигезләнгән фразеологизмнардан тора. Җыю бәйләнешенә нигезләнгән фразеологик әйтелмәләр: *ал да гөл, биштән үткән, бишектән чыккан; берсен көйләп, икенчесен сөйләп, өченчесен чөйләп; алты колак, дүрт күз белән; айга бер дә кайда бер; тапма да, бүлешмә дә, бер башы да бер тамагы; үзем дә ике күзем; бер кулы балда, икенчесе майда.* Компонентлары каршы кую бәйләнешендә булган фразеологик берәмлекләр дә шактый: *берне сөйли, икенчене эшли; бер колактан керә – икенчесеннән чыга; исәпкә бар, санга юк; акмаса да тама*. Җыю бәйләнешеме, каршы куюмы икәнлеген аеру кыен булган очраклар да бар. Мәсәлән, *артына бер төшеп, алдына биш төшеп; берең арба юлыннан, берең чана юлыннан.*

Бүлү бәйләнешендәге компонентлы фразеологик берәмлекләр күп түгел*: йә баш, йә җан; малыңмы, җаныңмы; йә уңасың, йә туңасың.*

Сүзтезмә формалы фразеологизмнар төрле сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттәш. Бу бигрәк тә тотрыклы сүзтезмә составында кайсы компонентның хакимлек итүеннән һәм фразеологизмнарның җөмләдәге вазифасыннан чыгып билгеләнә.

Фразеологик әйтелмәләрне, ияртүче сүздән чыгып, шартлы рәвештә түбәндәге төркемнәргә бүлеп карыйбыз: исем сүзтезмәләр, сыйфат сүзтезмәләр, фигыль сүзтезмәләр, рәвеш сүзтезмәләр, хәбәрлек сүз сүзтезмәләр.Фразеологик әйтелмәләр арасында сүзтезмә оештырмый торганнары да бар, мәсәлән, мөстәкыйль сүз һәм ярдәмче сүз белән белдерелгән тезмәләр. Үз чиратында аларның һәрберсе билгеле структур-морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләр белән сыйфатлана.

Исем сүзтезмә формасындагы фразеологизмнарның төп компоненты булып исем килә, исем исемне, сыйфатны, сыйфат фигыльне, санны ияртә. Контекстта мондый төр сүзтезмәләрнең грамматик мөмкинлекләре чикләнмәгән, ягъни фразеологизмның исем компоненты морфологик яктан сан, тартым, килеш белән бик җиңел төрләнә, фразеологизм бербөтен берәмлек буларак теләсә нинди җөмлә кисәге (күбрәк ия һәм тәмамлык) булып килә ала. Мәсәлән, *акыллы баш; асыл зат; ачык йөз; аю егарлык егет; алма битле кара каш; газиз баш; изге җан; нечкә бил; таза мортаза; туры кеше; тәүфыйклы яр; өстен кеше; беренче карлыгач; икенче яшьлек; җиде ят; ике тәкә башы; бер авыз сүз; ике кулга бер эш; диңгездән бер тамчы; унҗиде яшьлек җилкенчәк; шомарган таш* һ.б. Бу төр әйтелмәләрнең контекст эчендә кулланылышын карап үтик: *Тәкһиб итәргә, вәгазь кылырга фараз итәләр, җитмәсә, шундый **җебегән авызны** җибәрәләр.* (Г. Ибраһимов); *Мин, **хур кызы** дип мактасагыз да, сезнең коры сүзегез буенча, башкода җибәрү ихтималым юк.* (Г. Ибраһимов); *Шәкерт әнисе, **гыйлем иясе** булачак кешенең әнисе...* (Ә. Еники); *Имгәк! Җебегән! Куркак! Мондый **юаш бозау** булып үссәң, синнән тәхет яуларлык хан чыгачакмыни?* (В. Имамов); *Кер касапка, эшләсәң, эшләрсең, эшләмәсәң, сугымны **озын кулдан** сакларсың.* (М. Хәбибуллин); *Сөйләшкәндә, шактый ук **шомарган таш** булып кылана белә.* (З. Хәким); *Нишләп бу кеше болай да **караңгы уйлар** белән йөргән чагымда очрады?..* (З. Хәким) һ.б.

Сыйфат сүзтезмә формалы фразеологизмнарның составында төп компонент булып сыйфат килүе аңлашыла. Сыйфат исемне, сыйфатны, санны ияртә. Мондый фразеологизмнар сыйфатның грамматик билгеләре белән характерланалар: исемне ачыклап җөмләдә – аергыч, ирекле позициядә хәбәр булалар. Контекстта исемләшү очраклары еш күзәтелә. Фразеологизм составында сыйфат

дәрәҗә белдерә ала. Бу төр сүзтезмә – фразеологизмнарның иң таралган формаларыннан берсе: *аек фикерле; ак күңелле; алтын куллы; ачык йөзле; ачык күңелле; бала җанлы; икмәкле-тозлы; йорт җанлы; каты серле; кече күңелле; олы җанлы; ыспай телле; эш җанлы; җиңел аяклы; җиңел сөякле; җылан күзле; арыслан тырнаклы; җылы канлы; зур йөрәкле; тук күзле; ике йөзле; кырык ямаулы; мең төрле; бер тактасы ким; акылы камил; йөзе ак; йөзе ачык; йөзе якты; бите ачык; кулым ачык, йөзем ак; кулым кара, йөзем ак; кулы җиңел; сере каты; төтене кыек; кырмыскадай кыю; сөттән ак, судан пакь; телгә үткен; каләмгә ия; төскә матур, эшкә батыр; эшкә оста; эшкә сизгер; сүзгә кыска; җилдән өлгер* һ.б. Мәсәлән, *Син аның белән сүз куертма, Мортаза! **Кырык катлы** ул, аныкын белеп булмый...* (З. Хәким); «*Бөтен кеше дә синең кебек **каты бәгырьле** түгел бит», – дип әйтеп ташлаганын Тәлгать үзе дә сизми калды.* (З. Хәким); *Арнольд кебек **таш бәгырьле** кешеләр булмаса, дәүләт дигән механизмның, төрмәләрнең, тәртип саклаучы органнарның кирәге калмас иде.* (З. Хәким); ***Кырыс холыклы** булса да, Халисә әнә шундый якты уй-теләкләр белән яши иде.* (З. Хәким); *Әгәр дә берәр **нечкәрәк күңеллесе** үзен гаепле дисә, камерадагы иптәшләре аңа төрмә врачына мөрәҗәгать итеп, башын тикшертергә тәкъдим итәләр.* (З. Хәким)

Фигыль сүзтезмә формалы фразеологизмнарның төп компоненты – фигыль формалары. Сүзлекләрдә нинди фигыль формасы белән бирелүеннән чыгып, фразеологик әйтелмәләрнең берничә структур төркемчәсен күрсәтергә мөмкин.

1 нче төркемчәгә сүзлекләрдә төп компоненты исем фигыль формасында бирелә торган фразеологик әйтелмәләр керә. Алар эш-хәлләрне белдерәләр, я кешегә хас сыйфатларны процесс буларак тасвирлыйлар. Фигыльгә ияреп килүче исемнәр туры яки кыек тәмамлыклар, хәлләр булалар. Җөмлә составында исем фигыль үзенең формасын бик җиңел үзгәртә, ягъни барлык затланышлы һәм затланышсыз фигыль формаларында килә ала, төрле грамматик категорияләр алып төрләнә. Җөмләдә мондый төр фразеологизмнар теләсә нинди җөмлә кисәге була. Мәсәлән, *авызга хуҗа булу; авызына карату; адәмгә саналу; алдын-артын карап эш итү; алдын-артын җыеп йөрү; ат алу; бер күз белән карау; дөнья шаулату; дөнья җимертеп эшләү; йөзе кояш булу; кулдан эш килү; мәйдан алу; мөрәүвәт матдәсе ягылу; рәт белү; сөйкемле сөягең*

*булу; сүзе белән эретү; тауны ташка түнтәрү; ташка кадак кагу; таякны тоткан җирдән сындыру; теле телгә йокмау; тере тоту; теше төшү; ут кебек йөрү; эш рәтен белү; ялт итеп тору; әдәп саклау; өлгер тоту; өстенә кояш чыгармау; үлчәп сөйләү; җавапка күршегә кермәү; җиде кат җир астында елан йөргәнне сизү; һәлакәт күзенә карау* һ.б. Мәсәлән, ***Ике аякны бер балакка тыкмагыз*** *әле, иптәш доктор. Кырыкка ярылырга җиткән чакта...* (Г. Әпсәләмов); *...Совет властен күпме сүксәң дә гаепләмәгез, тик башкаларның гына* ***теле чишелсен*** *дә* ***эчендәге тычка чыксын*** *дип, очрашкан саен искәртеп торды ул.* (М. Маликова); *Вилен,* ***телен аркылы тешләгән*** *хәлдә башын иеп утыруында булды.* (М. Маликова); *Бүген дә безнең җитешсезлекләребез, ялгышларыбыз* ***чиктән ашкан****. Алар турында беләбез. Гамәлгә ашканчы ник* ***авызыбызны йомып торабыз****?* (Көндәлек матбугаттан)

2 нче төркемчәне төп компоненты хикәя фигыль белән белдерелгән фразеологик әйтелмәләр тәшкил итә. Хикәя фигыль билгеле бер заман формасында килеп, контекстта үзенең грамматик формасын үзгәртми. Бу калыпка керүче берәмлекләр эш-хәлләрне, я кешегә хас сыйфатларны процесс буларак белдерәләр, җөмләдә хәбәр функциясен үтиләр. Мәсәлән, *арага мылтык салдылар; арбасын такырга чыгарды; аргы ягына чыккан; аркага атланды; бетте-китте; бетәсе булмады; исенә төшкәч, исе киткән; исләрем-акылларым китте; көл сипкәндәй булды; кисеп ташлаган тырнагына да тормый; кулы белән төймә генә коймый; кулы кулга йокмый; кулына туфракны учласа, алтын итә; кулы килә; су кебек эчә; теле белән кош тота; ут чәчеп, бурын уйната; җепне тешләгән җиреннән өзә; бер алдын, бер артын күрсәтә; ике ятып бер төшенә керә; төшеп калганны эзли; әлифне таяк дип белми; бер әйтер – берәгәйле әйтер; биш үчәп бер кисәр; сукса тугыз көн чумар ашамассың; сукса чумарыңны чыгарыр; сырты сынса да сер сынатмас; эчеңә кереп ятыр; куркып качарсың; керфегеннән гөл тамар; теле белән тигәнәк алыр; ни булса да булыр.* Кайбер мисаллар: *Ә мин әле яшь, таза.* ***Кулдан*** *ни тотсам, шул* ***килә****.* (С. Җәлəл); *Менә таптың кыз!* ***Әлифне таяк дип белми…*** (Г. Ибраһимов); *«Аларның* ***кисеп ташлаган тырнагына да тормый****», – диде.* (А. Шамов); «*Галиябану*»*ны* ***өзә дә куя,*** *йөз Хәлилең үлемгә барырлык.* (С. Сөләйманова); *Вәли Фәтхинең тешләрен кыскартырга да* ***кыйбат алмас****!* (Ф. Сәйфи-Казанлы); *«Сатма,*

*әти, **дөнья хәлен белмәссең**, кайтып керергә куыш булыр», дип, Әмин каршы төште.* (К. Әмири); *Сезнең терлекчеләр өе оҗмах кебек, ә безнекеннән **куркып качарсың**.* (А. Гыйләҗев)

3 нче төркемчәгә фигыле боерык һәм теләк фигыль формаларында килгән фразеологик әйләнмәләр керә. Алар үгет-нәсыйхәт бирү, боеру, киңәш итү, ирония белдерү, тиргәү, яхшы теләкләр теләү яисә каргау буларак әйтеләләр. Көчле модальлек белән сугарылганнар. Мисаллар: *үзең бел дә май кап; үзең тапкан мал, капчык тутырып ал; үзең чәчтең, үзең ур; үзеңә кара; теләсәң шартлап үл; теләсәң ела, теләсәң көл; бер аягың анда, бер аягың монда булсын; икенче аяк атлама*; *йөз яшә, йөзем аша; төшеңә кермәсен; муеның астыңа килгере; ни күзем белән күрим, ни колагым белән ишетим.* Контекстта кулланылышына мисаллар: *Менә Шаһи картның алма кебек кызы бар, эшкә дисәң, авылда бер. Үзе шундый сылу, шундый зифа – **бер кашык суга сал да йот.*** (Г. Ибраһимов); *Син дә шул «телсез күке» кебек сөйлисең, әллә сез... – Дәшмә. **Май кап!*** (З. Хәким); ***Ходай рәхмәтеннән ташламасын** инде сезне, – диде ул, Сөләйманның җылы түшенә пышылдап.* (З. Хәким); *Рәхмәт, туган. **Ходай озын гомер бирсен** үзеңә.* (З. Хәким); *Әрәмтамак! Уйныйсың килдемени? **Муеның астыңа килгере!** Менә сиңа, менә! Бирән!* (И. Нуруллин)

4 нче төркемчә фигыле сыйфат фигыль формасында килгән фразеологизмнардан тора. Алар җөмләдә, исемне ачыклап, аергыч булалар. Затны я предметны эш-хәле буенча сыйфатлыйлар. Мәсәлән, *азау тешен ашаган; акылга беткән; акылга утырган; алтын бишектән төшкән; арбасын тауга менгергән; билне буып туган; дөнья күргән; пешеп чыккан; таш астыннан чыккан; тел чарлаган; тугыз мурдан үткән; унике фән күргән; елан аягын кискән; бер күлмәк белән калган; бер чыбыктан сөрелгән; җиде бабадан килгән; унга (йөзгә) бер тулмаган.* Контекстта кулланылышы: *Ярый, арада **күпне күргән**, күп мәртәбәләр хаҗ юлында булган бер карт хаҗи бар.* (Г. Ибраһимов); «*Уңай каһарман, – диде **телгә беткән** Батыр. – Бакчы, гел плюслардан гына тора».* (А. Тимергалин); – ***Хан заманыннан калган** корал куллану катгый рәвештә тыелганны оныттыңмы әллә?* (А. Тимергалин); *Айдар Хәлим хикәяләре жанр үзенчәлеге, тирән лиризм белән сугарылуы, сюжет төгәллеге, тематик масштаб, психологик-рефлекс камиллеге ягыннан **коеп куйган** новеллалар иде.* (Көндәлек матбугаттан)

5 нче төркемчәгә төп компоненты хәл фигыль белән белдерелгән фразеологик әйтелмәләр берләшә. Алар эш-хәлне икенче бер процессның билгесе итеп бирәләр, шуңа күрә сөйләмдә үзләреннән соң башка бер фигыль таләп итәләр: *аяк тибеп; аяк терәп; югын бар итеп, барын бал итеп; әҗәлен авызына тешләп; җил-буран уйнатып; үзен үзе белештермичә; ике дә уйламыйча; өч катлы итеп; өч адымны бер итеп; билен биш җирдән бөгеп; айлык җирне алты атлап, еллык юлны җиде атлап*. Мәсәлән, *Ул, төннәрен Хәйдәрне* ***эт итеп, эттән алып селкеп салып*** *тиргәсә дә, мәҗлесләрдә кеше алдында һичбер серне белгертмәде.* (Г. Исхакый); *Энем көлтә бирә,* ***күз ачып, күз йомганчы****, дүрт-биш арбаны бушатып та ташлыйбыз.* (Г. Ибраһимов); *Рәшат, өчәр аратаны берьюлы сикерә-сикерә,* ***ә дигәнче*** *икенче катка менеп җитте.* (А. Гыйләҗев); *Училище ду килә,* ***җир бетереп*** *Динәне эзлиләр*. (Н. Гыйматдинова); *Нишләп әле без монда иза чигеп,* ***очны-очка көчкә ялгап*** *гомер сөйрибез, ә алар галәм буйлап рәхәтләнеп, җилләнеп очып йөриләр?!* (З. Хәким)

Рәвеш сүзтезмәдән торган фразеологик әйтелмәләр, рәвешләр кебек, эш-хәлнең яки билгенең билгесен белдерәләр һәм җөмләдә, күбрәк фигыльне, сыйфатны, рәвешне ачыклап, хәл функциясендә киләләр. Исемне ачыкласалар, аергыч булу мөмкинлекләре дә бар.

Эш-хәлне төрлечә ачыклап килгән бу төр фразеологик әйтелмәләрне конкрет берничә семантик төркемчәгә бүләргә мөмкин:

1) эшнең үтәлү рәвешен белдерә торган фразеологизмнар: *бәрәңге ашау белән бер (бәрәңге ашаудан да җиңел); дүрт куллап; авыз эченнән; дүрт күзләп; арттан караганда алда (бара); бер күз белән; исерек баштан*. Мәсәлән, *Берничә җыр җырлагач, тәрәзәдән башын алып, идәнгә төште дә,* ***авыз эченнән генә*** *көйләп, әрле-бирле әйләнгәләп йөри торгач, тәрәзәдән алган мендәргә башын куеп, күзләрен йомды*. (К. Әмири); *Үги баласын да үзенекеннән аермый,* ***бер күз белән*** *карый*. (З. Хәким)

2) күләм-чаманы белдерә торган фразеологизмнар: *санап бетергесез; буа буарлык; тау хәтле; әллә нидә бер; кырыкмаса кырык тапкыр; оныткanda бер (онытылганда бер); айда бер, кайда бер; ике дә бер; ике көндә бер; ике көннең берендә; ике сүзнең берендә; ике адымның берендә; ике авызның берендә; туксан тугыз; йөз дә бер; мең дә бер; ике дә өч*. Мәсәлән, *Амбар ишегалдында* ***тау хәтле*** *тары өелеп ята.* (Г. Мөхәммәтшин); *Кайсы якка карасаң да,* ***күз күреме кадәр*** *җирләрдә иген кырлары*. (А. Гыйләҗев); *Кызыклары*

*аның* ***санап бетергесез****.* (А. Гыйләҗев); *Хәзерге заманда, өйләнмәсәң дә, кызлар* ***буа буарлык****.* (А. Гыйләҗев); *«Кем эте бу?» – дип,* ***кырыкмаса кырык тапкыр*** *кабатлады кондуктор.* (Батулла);

3) чагыштыруга нигезләнгән фразеологизмнар: *ай белән көндәй, һәркемгә бердәй; арыслан авызыннан сөяк алырдай; басса бакыр изәрдәй, типсә тимер өзәрдәй; сукса тимер өзәрдәй; балта асып куярдай; ике бармак кебек; урта бармак кебек; ике тамчы су кебек; коеп куйган төсле; койрыгы киселгән эт кебек; койрыгы пешкән мәчедәй; котырган эт шикелле; кош тоткандай.* Контекстта кулланылышына мисаллар: ***Авызларына су капкандай*** *дәшми барулары шуны раслый сыман.* (В. Имамов); ***Типсә тимер өзәрдәй*** *12 егет килеп, бер шобага печәнне дә бетермәгәч, ул нигә ярый?* (Г. Ибраһимов); *Бераздан мин, хәл алгач,* ***бизгәк тоткандай*** *калтыранып, Сибгатне чәйнәп ташлардай булып: «Бу ни эш?» – дидем.* (А. Шамов); *Бәлки, Мәрданша да* ***күз явын алырдай*** *кызга өйләнгәч, бәхетеннән матурланып китәрмен дип уйлыйдыр...* (З. Хәким); *Шулай диде дә, болар, тагын* ***җан дуслардай*** *җитәкләшеп, каядыр китеп бардылар.* (А. Тимергалин);

4) урын мәгънәсен белдергән фразеологизмнар: *ике адым җирдә; Каф таулары артында; җәһәннәм тишегендә; борын төбендә; борын астында; кош очмас җирдән.* Мәсәлән, ***Каф таулары артына*** *качарсың шуларны күрмәс өчен, Раббем Аллам.* (Н. Гыйматдинова); *Бигрәк* ***җәһәннәм тишегендә*** *инде бу Рухиясе. Сыерына да шуннан ташы, җиләк-җимешенә дә сибәргә дә шунда чап.* (Н. Гыйматдинова);

5) вакыт мәгънәсен белдергән фразеологизмнар: *бер таңнан икенче таңга кадәр; җиде төн уртасында; өченче әтәчкә кадәр; бер дә бер көнне; бер дә бер заманны; биш былтыр; бүгенгесе көнне; бүген таңда; кояш күзендә; кояш сөңге буе күтәрелгәч; таң тишегеннән; әби патша заманында; әче таңнан.* Контекстта кулланылышы: ***«Таң тишегеннән*** *кая бара икән бу кызый актыгы?» – дип мыгырданган әле Миннәхмәт.* (А. Гыйләҗев); ***Таң күзеннән*** *кая кузгалган икән?* (Ә. Гаффар); *Әмирхан Еники –* ***патша заманында*** *туып, гасырны иңләп-буйлап кичкән ил агасы.* (Көндәлек матбугаттан)

Хәбәрлек сүз сүзтезмә төркемчәсенә ахырда хәбәрлек сүз килгән фразеологик әйтелмәләр карый: *уемда да юк; әллә бар, әллә юк; имгә дә юк; баш юк, аяк юк; бүген бар, иртәгә юк; вәгъдәләшкән ярым юк, елап калыр балам юк; дус бар, дошман бар; дәрт бар, дәр-*

*ман юк; ерак китәсе юк; исеме бар, җисеме юк; кагарга казыгы, ашарга азыгы юк*. Мәсәлән, *Мин аны юньләп аңламадым да, бугай… Гомумән, миңа дөнья* ***әллә бар иде, әллә юк*** *иде*. (Г. Ибраһимов)

Болардан тыш, татар телендә традицион синтаксис нормалары буенча сүзтезмә итеп карап булмый торган фразеологик әйтелмәләр дә очрый. Шулар арасында [мөстәкыйль сүз + бәйлек/бәйлек сүз] калыбындагы берәмлекләр шактый. Мәсәлән, *көне белән;кырык кат; йөз тапкыр; бернигә дә карамастан; дөнья читендә.* Контекстта алар мондый формада очрыйлар: *Мин, туган, шуны таптым; шуның эченә* ***баш-аягым белән*** *чумдым.* (Г. Ибраһимов); *Ул заманнарда солдатларны* ***җир читенә*** *җибәргәннәр имеш, диләр.* (Г. Ибраһимов); *Шаһәдәтнамә кулыма кергәннән бирле, мин аны* ***мең тапкыр*** *укыган, анда ни барын яттан ук белгән идем.* (Г. Ибраһимов); *Аның кендек әбисе булган Бәдри карчык* ***меңдә беренче мәртәбә*** *үзенең зарын, хәйрәтен сөйли.* (Г. Ибраһимов); *Йортны ташлама: имчәк баласы түгелсең,* ***атлаган саен,*** *өеңә кайтып йөрмә!* (Г. Ибраһимов); *Мин алай-болай сүз ишетсәм, мәсьәләне* ***кабыргасы белән*** *куярмын.* (Х. Ибраһим)

*Кебек, төсле, кадәр* кебек бәйлекләргә тәмамланган фразеологизмнар чагыштыруны белдерәләр: *аю кебек; гернадыр кебек; кура җиләге күк; үгез кебек; сөлек кебек; төп кебек; эт кебек; куян кебек.* Мәсәлән, *Ул шушы* ***сөлек кебек*** *егетнең әнисе бит!* (Ә. Еники)

Лексик-грамматик табигате белән ымлыкларга туры килә торган фразеологизмнар да очрый. Мисаллар: *менә сиңа мә; кара син аны; менә бит; кит аннан; менә инде; менә тагы; менә сиңа кирәк булса; менә бер тамаша; менә агай; выж галләм; валлаһи газим; и Алла!*

Җөмлә формалы фразеологизмнарда ия белән хәбәр мөнәсәбәте урнаша. Алар арасында бер яки ике баш кисәкле, төзелешләре ягыннан гади һәм кушма җөмлә формалылары бар: *авызыннан энҗе түгелә; кулы бии; икесе бер кашыктан ашый; кырыгы кырык җирдә ярылып ята; ике күзе генә калган; ике арага кара мәче керү; бездә акча бер букча; чебен чукындырырга бер тиен акча юк; аты-саны бар; бер дә килмәгән җире юк; кулыннан килмәгән эше юк; җитмәгән җире юк; үз сүзенә үзе хуҗа* – гади, ике составлы, тулы җөмләләр; *берәү таба, бишәү каба; кеше белән кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар; алты аласым юк, биш бирәсем юк; убыр китте – урыны калды* – тезмә кушма җөмләләр; *ботыннан тотып селкесәң, авызыннан бер әлиф төшмәс;*

*эченә сәнәк белән төртсәң, бер тамчы каны чыкмас; син монда бер ай торсаң, без монда мыек үстердек; син болай ашасаң, унике башлы тегермән дә җитмәс* – иярченле кушма җөмләләр. Мәсәлән, *Абау, харап икәнсең син, Мәхдүм! Юаш кына булсаң да, бер кызсаң, **авызыңнан ут чыга** икән.* (Г. Ибраһимов); *Нуретдингә, кем әйтмешли, **ике дөнья – бер морҗа** дигәндәй, Су анасы да, алтын да кирәк түгел иде.* (З. Хәким); *Техникум янына килеп җиткәндә, **йөрәгем табан астына төшеп китте** – эскәмиядә Арнольд утыра иде.* (З. Хәким); *Бер-берсен яхшы беләләр. Әмма кыз 7 класстан соң медучилищега укырга кергәч, хат язышып торуларын исәпкә алмаганда, **юллары аерыла**.* (Көндәлек матбугаттан)

Җөмлә формалы фразеологик әйтелмәләр җөмлә составында да, аерым җөмлә булып та кулланылырга мөмкин: ***Алмагачның алмасы ерак төшми**, диләр, бик шәп булган инде.* (Г. Толымбай); ***Ботыннан тотып селкесәң, авызыннан бер әлиф төшмәслек** карчыклар безгә акыл саталар.* (М. Әмир); *Аны мин сиңа үзем алып киләм. Ә каян алачагымны **син сорама, мин әйтмим**.* (В. Нуруллин); *Инде **узган эшкә салават**.* (Көндәлек матбугаттан)

Моннан тыш, диалогларда я кереш сүз буларак, я әзер җавап буларак кулланылган фразелогик әйтелмәләр бар, алар сүзтезмә яки җөмлә формалы булалар: *бер сүз белән әйткәндә; иллалла, кырык (җиде) мулла (хәйлә) белән; эш юктан бер эш дигәндәй; шуның белән беррәттән; туксан авыз сүзнең төене шушы; озын сүзнең кыскасы; тора торгач бер амин; анысы бер хәл; анысы аның бер хәер; икенче төрле әйткәндә; икенче сүз белән әйткәндә; ансы да монсы, бер йомырка ватылды (дигәндәй); кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла; ие бит; ие шул; әйтәсе дә юк; әйтәм аны.**Кем әйтмешли, без дигәнчә генә дә бармый**, сез дигәнчә генә дә бармас бу дөньялар.* (Көндәлек матбугаттан)

Димәк, фразеологик әйтелмәләрнең грамматик төзелеше җанлы тел грамматик нормаларына якын тора. Дөрес, бу мөнәсәбәттәшлек, – алда әйткәнчә, шартлы күренеш. Фразеологик әйтелмәләр, гомуми грамматик система элементы буларак, грамматик төзелеш законнарына буйсыналар, ләкин ирекле синтаксик формалардан эчтәлекләре, мәгънә бөтенлеге, сурәтлелек, тотрыклы синтаксик бәйләнешкә ия булу белән аерылып торалар. Шул сәбәпле фразеологик әйтелмәләрдә телнең лексикасы да, грамматик нормалары да үзенчәлекле чагылыш таба.

## § 57. Фразеологик әйтелмәләрнең кулланылышындагы семантик һәм структур үзгәрешләр

Фразеологизмнарның төп билгеләре: телдә әзер килеш куллanылу, структур һәм лексик составларының тотрыклылыгы. Чыннан да, татар телендә кайбер тотрыклы сүзтезмәләр һәм җөмләләр грамматик яктан «катып калган», аларның компонентларының урынын алмаштыру яисә төшереп калдыру, яңа сүз өстәү мөмкин түгел. Бу бигрәк тә фразеологик ныгымаларга кагыла. Мәсәлән, *биш былтыр* берәмлеген *алты былтыр, былтыр биш, биш һәм алты былтыр* дип үзгәртеп куллану гайре табигый хәл. *Киләп сарып йөрү; сәлам сыйрак; ис китү; ә дигәнче; пыр тузу; биш бармак кебек; кырт кисү; чыбык очы; трай тибү; мур кыргыры; буа буарлык* һ.б. фразеологизмнарда теләсә нинди контекстта үзгәртелмичә кулланылалар. Үзгәрмичә генә, үзенә хас мәгънәне саклап килүче фразеологизмнар традицион фразеологизмнар дип аталалар. Дөрес, кайбер фразеологизмнарның билгеле бер автор телендә семантик һәм грамматик яктан кайбер үзгәртүләргә дучар булу очраклары күзәтелә. «Фразеологик әйтелмәләрнең төшенә (төп сүзгә) өстәлгән элемент компонент буламы, юкмы – бу махсус өйрәнүне таләп итә. Язучы, билгеле, аны исәпләп тормый. Бу урында фразеологизм, бу урында чагыштыру, метафора кулланыйм дип тә уйламый ул. Геройның портретын тасвирлау, эчке дөньясын ачыклау, вакыйга-күренешләрне чагыштыру өчен, аңа образлы сүз кирәк. Ничек кенә булмасын, фразеологик әйтелмәләрне киңәйтү халык телендә дә, әдәби әсәрләрдә дә күп очрый. Бу, – билгеле, кеше фикерләвенең, сөйләм культурасының, җәмгыятьнең үсешенә бәйле күренеш. Шуңа күрә өстәлгән элементның эчке мәгънәсе әсәрнең идея эчтәлеге белән генә түгел, тарихи вакыйгаларга да бәйле була» (Поварисов, 1982: 66–67). Димәк, татар язучылары әзер фразеологик әйтелмәләр белән генә чикләнмиләр, ә аларны үзгәртеп тә кулланалар. Традицион гыйбарәләргә яңалык рухы кертү – тел остасы өчен мөһим эш. Аның фразеологик осталыгы шушы җирлектә ачыклана. Әлбәттә, үзгәртү туган телнең рухына, эчке кануннарына зыян китермәскә тиеш.

Фразеологизмнарны үзгәртү күренеше компонентлары арасында йомшаграк бәйләнеш булган, ирекле сүзтезмәләргә якын торган берәмлекләрдә күзәтелә. Фәндә алар т р а н с ф о р м а ц и я л ә н г ә н

яки ү з г ә р т е л г ә н ф р а з е о л о г и к ә й т е л м ә л ә р дип йөртеләләр.

Халык гыйбарәләрен матур әдәбият әсәрләрендә иҗади куллану борынгыдан килә. Мәсәлән, *дәрт бар, дәрман юк* гыйбарәсен Кол Гали үзенең мәшһүр әсәрендә «Бу дәрдә һичбер дәрман булумасвән» дип куллана. Фразеологик әйтелмәләрне үзгәртеп куллану Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә дә бихисап:

*Йокы күздин, сабыр китте күңелдин,*

*Яш урнына кара каннар түгелде* шигъри юлларындагы *күздән йокы качу* – күзне йокы алмау, борчылып йоклый алмас булуны аңлата.

*Исемем шулкадәр булгач шикәрле,*

*Тигезләр ул телем ачы икәнне* өзегендә *ачы телле* – усал, төртмә теллене белдерә.

*Ишәк миен ашаган бер өметсез,*

*Гаять ямьсез, ачы сүзле вә битсез.*

Биредә *ишәк миен ашаган* кебек мыскыл итү формасы бар. Хәзерге телдә аның *тавык мие эчкән* синонимы актив кулланыла, «башсыз, аңгыра, зиһенсез» мәгънәсендә килә.

*Алтынбуга атлы остазым мәрхүм,*

*Теле бай һәм татлы, саф күңел галим.*

Әлеге өзектәге *теле татлы* фразеологизмы, үзенең яман ниятенә ирешү өчен, татлы теле белән юмалап алдашучыга ишарә.

*Шикәрен татмыйча, камышка бакма,*

*Наданнар сүзе буш, син бушка бакма.*

Әлеге контекстта *буш сүз* фразеологизмы «төпсез, мәгънәсез сүз, сафсата, ялган» мәгънәсен белдерә.

Фразеологик әйтелмәне, составына нинди дә булса сүз өстәп, киңәйтергә мөмкин. Өстәлгән сүз фразеологизмның төп мәгънәсенә зыян китерми, бары төсмерләр генә кертә. Мисаллар: *«Тагын ат сыртын каезларга килдеңме, егеткәем?» – дип, күзләре белән* ***каш астыннан сөзеп кенә каршылый*** *аны Фәтхерахман карт.* (В. Имамов) Бу җөмләдә *каш астыннан карау* берәмлеге яңа сүзләр белән баетып бирелгән, төп мәгънә (кашын салындырып, ят нәрсәгә караган күк карау) үзгәрмәсә дә, стилистик яктан аңа яңа төсмерләр өстәлгән, авторның әйтәсе килгән фикере көчлерәк яңгырый. Түбәндәге мисаллардагы трансформацияләнгән фразеологизмнарны чыганаклары белән чагыштырып карыйк.

*Әйдә, монда* ***суган әкияте сатып****, корыны бушка әйләндереп утырмыйк әле без*. (В. Имамов) – суган сату; ***Авызы чамасыз нык пешкән иде*** *Луизаның*. (А. Гыйләҗев) – авыз пешү; ***Лаеш шулпасының иң әчесен бергә-бергә эчкән*** *чордашлар*. (А. Гыйләҗев) – Лаеш шулпасын эчү; *Без әлеге мәкаләне,– әлбәттә, алдан һични белмәгән килеш, (ә «Болгар номерлары» сүтелергә атна-ун көн генә калган икән), газетада кабат бастырттык.* ***Кырмыска оясына тагын бер таяк тыгасы килгәнгә түгел.*** (Көндәлек матбугаттан) – кырмыска оясына таяк тыгу.

Өстәлгән сүзләр фразеологизм компонентларының урынын үзгәртә, ягъни тышкы (формаль) яктан конструкция өзелә, таркала кебек. Ләкин компонентларның аерым урнашуы фразеологизмның мәгънәсенә зыян китерми. Нәтиҗәдә төрле контекстта төрлечә үзгәрә алган өстәлмә сүзләрнең булуы сөйләмә телнең бер күренеше итеп карала (Мостафина, 2000: 92).

Кулланылышта фразеологизмнар «тарая», ягъни теге яки бу компонент төшереп тә калдырыла ала. Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы кыскару нәтиҗәсендә эллиптик формалар яки факультатив компонентлар барлыкка килә. Фразеологизмнарның тулы һәм эллиптик вариантлары телдә параллель кулланыла, компонентларның кыскаруыннан фразеологик әйтелмәнең мәгънәсенә зыян килми, ул үзгәрешсез кала. Фразеологизмнарның, гадәттә, икенче өлеше кыскара: *типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек; ул да тумас, кыз да тумас, туса да, тормас; чиләгенә күрә капкачы, тәресенә күрә тактасы; дөньясы түгәрәк, тормышы бөтен; ике чабата бер кием, икесе дә бер тиен* һ.б. Әгәр фразеологизм составында андый тиңдәш кисәкләр булмаса, кыскару мөмкинлеге чикле.

Фразеологизмдагы мәгънәгә үзгәреш кертмичә төшеп кала торган компонентны факультатив дип атарга мөмкин. Хәзерге теленең торышы, фразеологизмның файдалану активлыгыннан чыгып, «артык» саналган компонент кыскаруга дучар була, ә фразеологик әйтелмә аннан башка да мәгънәсен югалтмый. Еш кына кисәкчә, бәйлек яки бәйлек сүз, сан, сыйфат һәм үзәк компонент булмаган сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр кыскара: (*бишкә) ярылырдай булу; алдыңнан артың (артык); башка (күсәк белән) суккандай булу; кулыннан (пычак та) килми; барыннан югы (артык); тиле бәрән орлыгы ашаган (сарык кебек); бабайныкы – илнеке (дип*

*әйтте ди бер кияү); исәнме, кодагый (ата казың йомырка саламы?)* һ.б. Әлеге төр фразеологизмнарның контекстта кулланылышын карап үтик: *Низамига азрак **салам кыстырып җибәрү** өчен булса кирәк: – Анысын шулаен шулай да, ләкин бит, Низами абый, синең шикелле кешеләр бу заманда үзе дә бик сирәк шул ул.* (С. Җәләл) – *салам якка салпы кыстыру* фразеологизмыннан үзгәртелгән; *Әйе, **типкәч тимер өзәрлек** егет идем мин*. (А. Шамов) – типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек.

Фразеологик әйтелмәләрнең лексик компонентын башка сүз белән алмаштыру аларны лексик һәм стилистик яктан яңарта, яңа образ тудырырга ярдәм итә. Мисаллар: *Ул, төннәрен Хәйдәрне эт итеп, **эттән алып селкеп салып** тиргәсә дә, мәҗлесләрдә кеше алдында һичбер серне белгертмәде.* (Г. Исхакый) – эттән алып эткә салу; *Миңнехан, энесе белән күрешкәннән бирле, һәр минутта үзен **энәләр өстендә йөргәндәй** хис итеп килсә дә, Хәйдәрнең бу җавабын ишеткәч, тәмам коелып төште.* (В. Имамов) – энә өстендә утыру.

«Кушылу, оешу» мәгънәсендәге «контаминация» термины фразеологик әйтелмәләрнең контекстта ике яки берничә фразеологизмның кушылып, бербөтен буларак кулланылуын белдерә, мондый төр гыйбарәләрне контаминацияләнгән фразеологизмнар дип атыйлар. Мәсәлән, *Авызыңны ерма, карт төлке! **Арт сабагыңны тыңлатырга** хәзер дә **кыйбат алмам***. (А. Шамов) – *арт сабагын укыту* һәм *кыйбат алмау* фразеологизмнарының бер контекстта кушылуы; *Күрмисезмени, **авызын ничек ерган, колакларына җиткән.*** (А. Шамов) – *авыз еру* һәм *авызы колагына җиту*; *Кайтып та, **күңелләргә май булып сеңәрдәй җылы сүз** катканы юк.* (Х. Сарьян) – *күңелгә май булып сеңү* һәм *җылы сүз; «Алай була күрмәсен! **Тавыгыгыз күркә булып күренсә, сыерлары фил хәтле икән** дип кайтыр китәр ул», – дип көлде Зөбәрҗәт.* (А. Гыйләҗев) – *тавыгы күркә булып күренү* һәм *сыеры фил булып күренү* тотрыклы әйтелмәләренең кушылуы һ.б.

Фразеологизмнарны үзгәртүнең тагын бер стилистик алымы – образ мәгънәсен җимерү. Ул ике юл белән тормышка ашырылырга мөмкин. Беренчесе – фразеологик әйтелмәләрне ирекле сүзтезмә рәвешендә куллану. Бу очракта тотрыклы сүзтезмә үзенең формасын саклый, ләкин контекстта метафорик мәгънәсен югалтып, туры мәгънәдә файдаланыла башлый. Фразеологизмнарның һәм

ирекле сүзтезмәләрнең омонимиясенә нигезләнгән каламбурлар барлыкка килә. Мәсәлән: ***Авызы бер пешеп карамыйча****, кайнар ашны өреп кенә кабарга кирәклеген кеше каян белсен.* (В. Имамов). Икенче юл – фразеологизмны, традицион мәгънәсеннән читләшеп, башка мәгънәдә куллану. Мәсәлән: ***Миләр катып калган****, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай.* (М. Мәһдиев) *Миләр катып калган* фразеологизмы «бик озак уйлаудан баш ару» мәгънәсен белдерсә дә, китерелгән җөмлә киресенчә аңлашыла.

Фразеологизмнарның образ мәгънәсен җимерү, күргәнебезчә, аларның лексик-грамматик составына зыян китерми, тышкы формалары ничек бар, шулай саклана, ләкин эчке формалары яңача яңгыраш таба.

Без алда традицион, трансформацияләнгән фразеологик әйтелмәләрне тикшердек. Халык иҗат иткән әзер фразеологик әйтелмәләрне куллану белән бергә, язучылар үзләре дә яңаларын уйлап табалар. Иҗат итү процессында туган андый тәгъбирләр индивидуаль фразеологик әйтелмәләр дип атала. Тел осталары фразеологик әйтелмәләрне әсәрнең идея-эчтәлегенә, персонажларның эчке дөньясын ачуга, жанрга бәйле рәвештә һәм башка стилистик максатларда кулланалар. Мәсәлән, Н. Гыйматдинова әсәрләрендә фразеологик әйтелмәләр булып телгә кереп китәргә лаек берәмлекләр шактый күп: *Дания ханымны күрсә,* ***чылбырыннан ычкына****, ди.Чылбырыннан ычкыну* фразеологизмы *бәйдән ычкынган эт кебек* берәмлегә семантикасына нигезләнеп барлыкка килгән, ләкин структурасы үзгәртелгән. *Икегез дә ут йотасыз шул, балалар. Сак белән Сок күек кавышалмыйсыз,* ***арагызга тау үсте.*** *Арага тау үсү* фразеологизмы *арага елан керү, арага мәче керү, арага шайтан керү, арага чөй кагу* берәмлекләре аналогиясендә төзелгән, ләкин мәгънәсе – дошманлашу, ара бозылу түгел, ә очрашу, кавышу өчен үтеп булмаслык каршылыклар килеп чыгу.

*– Әлеге дә баягы* ***сарык башы пешерәсез****. Нинди надан Тынсу кешеләре сез!* Билгеләнгән берәмлек *бер балык башын чәйнәү* фразеологизмына охшатып барлыкка килгән, шундый ук мәгънәне – һаман бер үк әйберне, бер сүзне кайта-кайта сөйләп торуны белдерә. *Шәрәфнең теленнән* ***бал тамызып*** *сөйләшүе кызны куркуга гына салды. – Их сине, балакай!* ***Күзең бәйләнгән килеш аксак атка атлангансың икән****. – Шәрәф бу юлысы* ***бүрәнә тәгәрәтмәс****, шәт? Алдын-артын уйлап тормыйча,* ***ялангач кул***

***белән утлы күмер соскан*** *дуамал ир өчен Галия җавап бирергә тиеш икән ләбаса!*

Сөйләмдә һәм язуда фразеологизмнарның семантик яки структур яктан үзгәртелеп кулланылуы автор теленә хас стиль үзенчәлекләрен билгели, аның сурәтләү чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген күрсәтә. Фразеологик әйтелмәләрне үзгәртү, сүз уйнату тышкы эффект өчен генә түгел, ә сюжет-композиция, идеяэчтәлек таләбе буенча һәм геройларның эчке дөньясын ачу өчен дә башкарыла. Әлбәттә, фразеологик әйтелмәләрне стилистик, экспрессив максаттан чыгып үзгәртү язучыдан зур осталык һәм саклык таләп итә.

Тел белеменең фразеология тармагын өйрәнүгә йомгак ясап әйткәндә, татар теле фразеологиясе, лексика кебек үк, төзек бер система тәшкил итә, аңа мөстәкыйльлек, автономиялелек хас. Фразеологизмнар, бер яктан, сүзләрдән, икенче яктан, ирекле сүзтезмәләрдән һәм җөмләләрдән аерылалар, шул ук вакытта катлаулы гомумхалык теле системасының аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр. Фразеологиянең өйрәнү объекты булып күчерелмә мәгънәле, семантик яктан бөтен, составы һәм структурасы ягыннан тотрыклы, аралашканда әзер килеш кулланыла торган, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык кебек сыйфатлар хас булган берәмлекләр тора. Бу берәмлекләр, сүзтезмә яки җөмлә формалы булып, билгеле структур-морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләр белән сыйфатланалар.

Фразеология, лингвистик дисциплина буларак, фразеологик характердагы аерым күренешләрне генә түгел, ә гомумән, телнең фразеологик системасын тикшерә. Фразеологик система телнең лексикология, фонетика, морфология, синтаксис тармаклары белән бәйләнештә өйрәнелә һәм үз эчендә билгеле категориаль билгеләр (парадигмалар) белән характерлана. Фразеологизмнар бер-берсеннән тарихи-генетик билгеләре, лексик составлары, компонентларның мәгънәви-грамматик кушылу дәрәҗәсе, тематикалары буенча, стилистик функцияләре һәм бизәлеше ягыннан, лексик-грамматик мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре буенча аерылалар. Шулай ук фразеологик әйтелмәләр сүзләр кебек бер һәм күп мәгънәле булалар, бер-берсенә карата синонимик, антонимик һәм омонимик мөнәсәбәтләрдә торалар. Фразеологизмнарның синонимик вариантлары хасил булу – татар фразеологиясен баетуның иң продуктив юлларының берсе.

Татар теленең фразеологик фонды бертуктаусыз үсештә һәм үзгәрештә. Бу, беренчедән, телнең сүзлек составы үзгәрүе белән бәйле, ә икенчедән, яңа метафорик образлар тууыннан да тора. Фразеологизмнарның барлыкка килүе, үсеше халыкның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәте, ышанулары, яшәү шартлары, рухи омтылышы, чынбарлыкка мөнәсәбәте, эстетик идеалы белән тыгыз бәйләнгән.

Фразеологик әйтелмәләр телнең эмоциональ көчен, эстетик тәэсир итү мөмкинлекләрен арттыра, алар фикернең үткенлегенә, сөйләмнең кыскалыгына ирешүдә әһәмиятле стиль чарасы булып тора. Бу төр берәмлекләр шулай ук әдәби, сәяси, публицистик һ.б. әсәрләрнең, сөйләм төренең идеясе, мәгънәсе, тәэсире көчәюгә хезмәт итә.

# ЭТИМОЛОГИЯ

## § 58. Тюркологиядә һәм татар тел белемендә этимология тармагын өйрәнү тарихы

Этимология термины антик чорда ук стоиклар тарафыннан уйлап табылган, әмма фәнни нигезләнмәгән, күбрәк халык этимологиясе рәвешендә сүзләрнең охшашлыгына таянып, аларның килеп чыгышын аңлатуга корылган була.

Фәнни этимология чагыштырма-тарихи тел белеме белән бергә һинд-европа телләренә мөнәсәбәттә барлыкка килә. Чагыштырма-тарихи тел белеменең нигезен тәшкил иткән аваз охшашлыкларын, аларга бәйле фонетик закончалыкларны өйрәнү, шулар нигезендә аерым телләрдәге охшашлыкларны билгеләү һәм телләрнең кардәшлеген ачыклаганда аларга таяну этимологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә бара. Үз чиратында нәкъ фонетик һәм башка закончалыклар этимология өчен методик фундамент ролен үтиләр.

Гомуми тел белемендә, этимологиягә караган беренче фәнни-теоретик хезмәт буларак, А.Ф. Поттның 1833–1836 елларда басылып чыккан ике томлык «Этимологические исследования в области индогерманских языков» хезмәте тора. Этимология фәненең үсешендәге төп этаплар буларак түбәндәгеләр аерыла:

– диалектларның әһәмиятен билгеләү һәм географик лингвистика методының эшләнеше;

– сүзнең мәгънә үсеш-үзгәрешен, лексиканы семантик кырлар кысасында өйрәнү;

– мәгънә – чынбарлык күренешләренең бәйләнешен игътибар үзәгенә алу;

– лексик берәмлекләрне халыкның тарихы һәм мәдәнияте белән бәйләнештә өйрәнү методларының үсеше;

– сүзләрнең беренчел формасын, аларның эволюциясен, тарихын өйрәнү активлашу.

XX гасырда этимология фәнендә структур принциплар да иркен кулланыла. Этимологик анализ вакытында сүзләрнең төрле семантик, лексик-грамматик, тамыр һәм морфемалар ягыннан төркемнәргә берләшүе, система барлыкка китерүче принциплардан охшашлык, капма-каршылык, ассоциацияләр һ.б. да исәпкә алына башлый. Беренчел тамырларны ачыклау һәм, гомумән, сүзне реконструкцияләү, телдә киң таралыш тапмаган күренешләрне дә игътибар үзәгенә алу алга таба һәр сүзнең этимологиясен өйрәнүдә нигез булып тора.

XX гасырның икенче яртысыннан этимологик эзләнүләр яңа метод һәм алымнар, тикшерү принциплары белән тулыланып, киң колач алып, этимологик сүзлекләр төзү эше эзлекле үсеш ала башлый. Төрки тел белемендә дә нәкъ шушы чорда этимологик сүзлекләр төзүгә игътибар арта.

Төрки телләрнең этимологиясен өйрәнү һәм сүзлекләр төзү өлкәсендә Э.В.Севортян хезмәтләре аерым урын били. 1974 елда Э.В. Севортян «Этимологический словарь тюркских языков (общетюркские, межтюркские основы на гласные)» сүзлеген чыгара (Севортян, 1974: 767). 1978 елда шул ук сүзлекнең «Общетюркские и межтюркские основы на букву «Б» дигән томы дөнья күрә (Севортян, 1978: 350). 1980 елда галим төзегән этимологик сүзлекнең «Общетюркские и межтюрские основы на букву «В», «Г», «Д» томы басылып чыга (Севортян, 1978: 395).

1989 елда «Этимологический словарь тюркских языков» хезмәтенең «Общетюркские и межтюркские основы на букву «Җ», «Ж», «Й» томы нәшер ителә. Бу томның авторлары – Э.В. Севортян һәм Л.С. Левитская (Севортян, 1989: 292).

Э.В. Севортянның «Этимологический словарь тюркских языков» хезмәтендә сүзләрнең этимологиясе күп очракта барлык төрки телләрдәге мәгънәләре белән аңлатыла, шул яктан бу сүзлек чагыштырма-тарихи методны куллану буенча да барлык башка хезмәтләрдән уңай якка аерылып тора.

Э.В. Севортяннан да иртәрәк чорда фин галиме Марти Рясянен да төрки телләрнең этимологик сүзлеген төзегән (Räsänen, 1969: 382).

Соңгы берничә дистә еллар бу өлкәдә Г.Ф. Благова, Э.Р. Тенишев, А.В. Дыбо актив эш алып баралар. Соңгы еларда гына

да А.В. Дыбо җитәкчелегендә төзелгән алтай телләренең һәм төрки телләрнең берничә этимологик сүзлеге дөнья күрде (Дыбо, 2000; 2003; 2013).

Аерым төрки телләрнең сүзлекләренә килгәндә, хәзерге вакытта татар (Әхмәтьянов, 2001, 2015), чуваш (Егоров, 1964; Федотов, 1996), төрекмән (Мухамедова, 1973), казах (Казах..., 1966), якут (Попов, 2003) телләренең махсус эшләнгән этимологик сүзлекләре бар.

Татар этимологиясеннән беренче хезмәтләр XX гасыр башында күренсә, аны системалы өйрәнә башлау XX гасырның 50–60 нчы елларына, тел белемендә этимология фәнендә эзлекле эшчәнлек башланган чорга туры килә.

Татар тел белемендә этимология юнәлешен фәнни дәрәҗәгә күтәрүдә Р.Г.Әхмәтьяновның роле зур. 1970 елда ул «Этимологические основы лексики татарского языка» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Татар теле этимологиясе өлкәсендәге эшчәнлеге барышында галим этимологиянең актуаль мәсьәләләрен яктырта. Аерым алганда, Р.Г. Әхмәтьянов «Об историзме в этимологии» хезмәтендә этимологиянең тарих белән бәйләнеше турында сөйли: «Этимология тарихи белемнән башка лексик берәмлекнең килеп чыгышын дөрес итеп ача алмый», – ди (Ахметьянов, 1985: 67–70).

Галимнең этимология өлкәсендә тагын бер әһәмиятле хезмәте – «Принципы этимологических исследований в области татарской лексики» (Әхмәтьянов, 1970: 93–101). Татар лексикасында этимологик эзләнүләр башланган чорда бу хезмәт тә үзенең әһәмиятле ролен уйнады. Ул иң элек барлык фәнни эзләнүләргә куела торган ике принципны этимологиягә дә тәкъдим итә: 1) материалны киңрәк, тулырак туплау, 2) аны системага салу һәм гомумиләштерү (Шунда ук). Этимологиянең үз төп принциплары дип Р.Г. Әхмәтьянов 1) фонетик үзгәрешләрне исәпкә алу, 2) мәгънә үзгәрешләрен дөрес табарга тырышу, 3) телгә хас сүз төрләнешенә һәм сүз ясалышына таянуны, ягъни фонетик, семантик һәм морфологик принципларны атый (Шунда ук). Галим бу принципларны билгеләгәндә, морфонология юнәлеше бөтенләй исәпкә дә алынмый иде әле.

Чагыштырма-тарихи тел белеме юнәлешендә башкарылган хезмәтләрдә этимология фәненең әһәмиятле өлкәләренә караган материалны күпләп табарга мөмкин. Аерым лексик-семантик, тематик төркемнәрне, сүзнең фонетик, грамматик һәм сүз ясалышы уртаклыгына нигезләнгән төркемнәрне өйрәнү, диалект һәм

сөйләшләрдә кулланылган лексиканың борынгы төрки телгә һәм башка кардәш һәм кардәш булмаган телләргә мөнәсәбәтен ачыклау мәсьәләләре, аларны үсештә анализлау Л. Җәләй, В.Х. Хаков, Л.Т. Мәхмүтова, Д.Г. Тумашева, Ф.М. Хисамова,Ф.Ә. Ганиев, Ф.Й. Йосыпов, А.Г. Шәйхулов, Ф.Ш. Нуриева, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова, Э.Х. Кадыйрова, Х.Х. Кузьмина һ.б.ның хезмәтләреннән билгеле.

Аерым сүзләрнең этимологиясе буенча Р.И. Куряева, Р. Мостафин, Ф.Ф. Гаффарова, И.Г.Добродомов, Ә.Г. Кәримуллин, Р. Мөхәмәтдинов, Мостафа Өнәр, А. Рәхимова, А. Тимергалин, Ф. Фасеев, Ф. Хәкимҗан һ.б.ның фикерләре дә игътибарга лаек.

Төрки телләрнең этимологиясе буенча материаллар барлык төрки телләрдә дә шактый җентекле эзләнүләр нәтиҗәсе булган ономастик хезмәтләрдә шактый. Н.А. Баскаков үзенең «Русские фамилии тюркского происхождения» (М., 1971) хезмәтендә 500 исем-фамилиягә этимологик аңлатма бирә.

Ономастика өлкәсендә күп хезмәт куйган татар галимнәреннән Г.Ф. Саттаровның «Атамалар дөньясына сәяхәт» (1992) һәм «Татар топонимиясе» (1998) исемле хезмәтләрендә бик күп топонимнарга, ә «Исемең матур, кемнәр куйган» (1989) һ.б. хезмәтләрендә кеше исемнәренә этимологик анализ ясала.

Ономастик берәмлекләргә этимологик анализ өлкәсендә Ф.Г. Гарипованың эшчәнлеге шулай ук аерым урын тота. Аның татар топонимиясе һәм гидронимиясе буенча басылган сүзлекләрендә һәм монографик хезмәтләрендә ялгызлык исемнәргә тарихи-этимологик анализ ясала (Гарипова, 1984, 1990, 1991, 1994, 2003 һ.б.).

Ономастик берәмлекләргә этимологик анализны Л.Ш. Арсланов, Х.Ч. Алишина, З.Ф. Әхәтова, Р.Г. Әхмәтьянов, И. Габдуллин, Г.Р. Галиуллина, Ф.Ф. Гаффарова, Ә. Кәримуллин, Р.И. Куряева, Ф.Л. Мәҗитова, Р. Ногмани, С. Поварисов, А. Тимергалин, Ф.С. Фасеев, А.Ю. Филькова, Г.К. Хадиева, О.Р. Хисамов, А.Г. Шәйхулов һ.б.ның хезмәтләрендә күрергә мөмкин.

Татар теленең этимологиясе өлкәсендә академик М.З. Зәкиевнең эшчәнлеге аерым урын били. Аның «Происхождение тюрков и татар» (2003), «Türklerin ve Tatarların kökeni» (2006) һ.б. хезмәтләрендә бик күп тел берәмлекләренә этимологик анализ бирелә. Авторның «История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие)» (2008) һәм «Татар халкы тарихы (этник

тамырлары, оешуы һәм киләчәге)» (2008) дигән китапларында этнонимнарга, топонимнарга этимологик анализ тагын да тулырак һәм системалырак эшләнеп, лингвистик археология дип атап йөртелүче фәнни юнәлешкә кадәр үстерелгән.

Югарыда әйтелгәннәрдән шундый нәтиҗә чыгара алабыз: тюркологиядә, шул исәптән татар тел белемендә, этимология туып һәм үсеп килә торган фән дәрәҗәсенә күтәрелгән.

## § 59. Этимология тармагы турында гомуми мәгълүмат

Этимология (грек. *etymon* – хакыйкать, чынлык, дөреслек һәм *logos* – өйрәнү) термины өч мәгънәдә кулланыла: 1) сүзнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән; 2) сүзнең килеп чыгышын ачыклау максатыннан файдаланыла торган алымнар җыелмасы һәм әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе; 3) сүзнең килеп чыгышы (Лингв. энцикл., 2000: 596). *Этимон* сүзе үзе генә хәзерге фәндә «сүзнең билгеле булган иң борынгы формасы» мәгънәсендә кулланыла.

Сүзләрнең килеп чыгышын тикшерү һәм этимологик сүзлекләр төзү гадәткә кергәч, этимология фәненең өйрәнү объекты да киңәйде: ул – сүзләрнең килеп чыгышы белән түгел, сүзлек составының килеп чыгышы. Димәк, сүз генә түгел, ә гомумән, сүзлек составының формалашу тарихы этимология фәненең объектына керә. Бу – этимология фәне объекты киңәюнең бер юнәлеше.

Аның икенче юнәлеше шуннан гыйбарәт: хәзер этимология сүзнең генә түгел, сүздәге морфемаларның – тамырның, нигезнең, кушымчаның да килеп чыгышын өйрәнә. Кушымчаларның килеп чыгышын өйрәнү ул – *морфологик категориянең килеп чыгышын* тикшерү дигән сүз. Соңгы елларда синтаксик модельләрнең килеп чыгышына да игътибар артты, бу юнәлештә эшләүче галимнәр «синтаксик категорияләрнең этимологиясе» терминын да кулланалар. Телдәге теге яки бу авазның барлыкка килү тарихын өйрәнүне дә теге яки бу *аваз этимологиясе* дип атау тел гыйлемендә ят бер нәрсә түгел. Димәк, этимологияне лингвистик берәмлекнең формалашу тарихы дип тә әйтеп була. Шуңа бәйле этимологик сүзлекләрне тарихи-этимологик сүзлек дип атау да очрый.

Шулай итеп, лексикологиядә формалашкан этимология фәне, гомумән, тел гыйлеме өлкәсенең бер бүлегенә әйләнде, ләкин аның тууында сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнү беренче планга куелганлыктан, этимология фәнен лексикология эчендә карау дәвам итә.

Хәзерге тел гыйлемендә э т и м о л о г и я ясалышы бүгенге (синхроник) сүз ясалу кагыйдәләре белән аңлатылмый торган сүз нигезләренең һәм фразеологизмнарның тарихын тикшерә торган фән дип билгеләнә. Ләкин гамәлдә этимология объекты итеп гади, бүгенге тел күзлегеннән бүленми торган морфемаларны да алалар. Шулай итеп, «Этимология» фәне һәм этимологик тикшеренү объектларына:

а) гади морфемалар;

б) ике яки күбрәк морфемадан торган, ләкин ул морфемалар тезмәсе хәзерге караштa аңлашылмый торган нигезләр;

в) составындагы сүзләрдән мәгънәләре чыгарылмый торган сүзтезмәләр – идиомалар керә.

Этимология фәне гомумфәнни һәм махсус принципларга таянып эш итә.

Г о м у м ф ә н н и п р и н ц и п л а р г а 1) төгәллек, 2) тикшереп һәм кабатлап булучанлык, 3) тикшеренүдә логик төзеклек карый. Барлык гуманитар фәннәр өлкәсендә кулланылган тарихилык принцибы этимологиядә дә зур әһәмияткә ия. Аның төп асылы чынбарлык күренешләрен үсештә карау, этимологик анализ объекты булган сүзләрнең үсеш-үзгәреш моделе билгеле тарихи факт яки закончалыклар нигезендә аңлаешлы, бәйләнешле булырга тиеш.

М а х с у с (х о с у с ы й) п р и н ц и п л а р – сүзнең чыгышын һәм тарихын билгеләгәндә, 1) фонетик, 2) морфологик, 3) синтаксик һәм 4) семантик үзгәреш закончалыкларын исәпкә алу дигән сүз. Бу закончалыкларны яхшы белми торып, ышандырырлык этимология ясап булмый. Төгәллек принцибы буенча, этимологиядә сүзләр мөмкин кадәр төгәл транскрипциядә бирелә һәм аларның мәгънәләре дә тулысынча ачылырга тиеш.

Күп кенә сүзләрнең формасы белән эчтәлеге арасында бәйләнеш ачык күренеп тора, ягъни мәгънәсеннән чыгып, сүзнең төзелешен, аның ничек ясалуын белеп була. Мәсәлән, *бүген* сүзенең *бу көн* дигән ике сүздән ясалуы һәр кеше өчен ачык, чөнки аның мәгънәсе шул фикергә китерә. *Кулъяулык, алъяпкыч, байбикә, гөлбакча, җилкуар, икейөзле, кулбау, кулбаш, имәнлек, уен-көлке, эшлекле, эшлексез, юлбашчы, юлдаш, яманатлы, өчпочмак, көнүзәк, җитәкче, җитәкчелек, һәрвакыт, һәрвакыттагыча, һичкайчан* сүзләренең дә мәгънәләре аларның ясалышларын (формаларын) ачык күрсәтә, димәк, кабул ителгән фәнни ысул белән әйткәндә,

бу сүзләрнең формалары (төзелеше) һәм эчтәлеге арасындагы мөнәсәбәт бозылмаган. Ләкин бу сүзләрне төзүче тамыр һәм кушымчаларның килеп чыгыш тарихы (ягъни этимологиясе) һәр очракта да ачык дип булмый әле, аларның кайберләренең этимологиясен фәнни юл белән өйрәнеп кенә белеп була, яисә дөреслеккә якын килергә мөмкин.

Сүз кулланылу барышында төрле фонетик үзгәрешләр кичерә (телнең үз сүзләре генә түгел, алынмаларда да очрый), чөнки аңа төрле диалектлар да, әйтү өчен уңайлы итү омтылышы да тәэсир итә. Сүз фонетик үзгәреш кичерсә, аның мәгънәсенә туры килә торган форма югала, бу форманы табу (ягъни сүзнең ясалыш тарихын белү) өчен, этимология фәнендә кабул ителгән методларны кулланып, сүзгә этимологик анализ ясарга туры килә. Мәсәлән, *сиксән* (сигез-ун) сүзендә бик аз гына фонетик үзгәреш бар: ахырдан икенче [у] ирен авазы, сүз башындагы тамырда ирен авазы булмаганлыктан, ирен белән әйтелү үзенчәлеген югалткан, нәтиҗәдә иренсез әйтелә торган [ә] авазына әйләнгән. *Сигез/сикес – ун* сүзе *сикесән* формасын алган, соңрак [к] һәм [с] арасында кыска [э/е] төшеп калган, сүзнең иҗек төзелеше дә *сикез-ун* нан *сиксән* булып үзгәргән, сүз басымы да күчкән. Бу этимологик аңлатманың дөреслеген *тукыс-ун* сүзеннән *туксан* сүзе туу да раслый. Мондый охшатуларны семантик параллель дип атыйлар. Семантик параллельләр сүзләрнең этимологиясен ачуда, ачылганнарының дөреслеген дәлилләүдә ярдәмче рольне уйныйлар.

Этимологиянең төп алымы булган чагыштырмалы-тарихи методны кулланып кына сүзнең барлыкка килүен дөрес билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, безгә якын булган *Казан* топонимын аш пешерә торган *казан* сүзеннән алынган, *Казан* елгасы исеменнән алынган, ә *Казан* дигән елга исеме (мондагы су юлны үзеннән-үзе) *казыган* сүзенең огузча [г] дан башка әйтелүеннән (*казыган* – кыпчакча, ә *казан* – огузча ‘прорыл’) килә дип аңлатып йөрттеләр. Бу ике төрле аңлату да чагыштырма-тарихи метод белән тарихи мәгълүматларны да кушып аңлатуга каршы килә.

Чагыштырма-тарихи метод кулланып ирешелгән этимологик нәтиҗәләр, гадәттә, күп санлы диалектлардан, шивәләрдән, телләрдән алынган сүзләрне чагыштыру нигезендә ясала. Шулардан иң мөһимнәре – кардәш телләргә караган сүзләр. Һәр этимологның кардәш телләрне мөмкин кадәр яхшырак белүе зарур.

Этимологик анализ, гадәттә, түбәндәге тәртиптә бара. Беренче чиратта тарихы тикшереләсе сүзнең лингвистик һәм экстралингвистик даирәсе тәгаенләнә, сүзнең төрле телләрдә, төрле тарихи чорлардагы кулланылыш вариантлары төрле язма чыганакларда теркәлгән очраклары туплана, аларга объектив, тулы бәя бирелә.

Кайбер очракларда тулы булмаган материал яки сүзләрнең тышкы охшашлыклары нигезендә сүзнең беренчел асылын аңлатырга тырышу күзәтелә. Мондый анализ фәннилектән ерак тора, һәм аны халык этимологиясе яки реэтимологизация термины белән атау гадәткә кергән. Халык этимологиясе дип таныш булмаган сүзнең мәгънәсен җиңел аңлашыла торган сүзләр җирлегендә аңлатырга тырышуны әйтәләр. Ул җанлы сөйләмдә алынма сүзләрнең мәгънәсен аңлатканда еш очрый, мәсәлән, *трамвай – утырамбай, тротуар – плитуар.*

Сүзнең беренчел формасын һәм мәгънәсен халык этимологиясе ярдәмендә аңлатырга омтылу әдәби әсәрдә махсус чара буларак та кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *Бабайда – зур балалайка, / Оныгында – бик нәни. / – Дөрес әйтмиләр бит болар, / Болай кирәк бит, әни: / Бала уйный –/ Балалайка, / Бабай уйный – / Бабайлайка!* (Ш. Галиев)

Нәтиҗә ясап әйткәндә, этимология фәне тел белеменең шактый катлаулы тармагын тәшкил итә. Фәнни нигезләнгән этимология сүзнең чын тарихын тергезә, аның килеп чыгышын тәгаенләргә ярдәм итә.

## § 60. Этимологик тикшеренү ысуллары[1]

Этимологик анализ махсус ысулларга таянып алып барыла. Аларга түбәндәгеләр керә: эчке реконструкция, аналогия (индукция), күперчекләр табу һәм изоглоссалар табу (Әхмәтьянов, 2015: 7).

Эчке реконструкция дип бер тел мәгълүматлары нигезендә теге яки бу тел элементларының баба телдәге прототипларын эзләүне атыйлар. Эзләнү вакытында төп игътибар сүз нигезенә, аның беренчел яки ясалма булуына, сүз үсеше процессында морфемаларның үзара керешүенә, сүзнең фонологик ягы һәм мәгънәсе бәйләнешенә юнәлә һәм телнең үзендә генә яки үзендә дә

[1] Бүлекчә Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда» (Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015) хезмәтенең кереш мәкаләсе нигезендә эшләнде.

булган, була алган фонетик, морфологик, лексик һ.б. үзгәрешләрне күз алдында тотып эш итела. Мәсәлән, татар телендә *а > ә* күчеше нигезендә барлыкка килгән: *аз > әз, ачы > әче, акрын > әкрен, байрам > бәйрәм, җай > җәй (шулай ук җай-у > җәй-ү)* кебек палатальләшү очраклары киң таралган. Әлеге фонетик үзенчәлек нигезендә татар теленең үз җирлегендә *җәнлек < җанлык, тәртә < тарта* (борынгырак формасы *тартна*) сүзләре хасил булган дип әйтеп була.

Татар телендә сузыклар редукциясе еш очрый һәм, шуны истә тотып, *чорма < очырма, терлек < терелек, шүрлек < шүрелек* дип аңлатулар (әлбәттә, һәртөрле бүтән принципларны да онытмыйча) ышандырырлык.

Татар теленә кушма сүзләр кыскартылу күренеше дә ят түгел. Мисал өчен, *чабагач < чәп агачы (чабагач* ~ рус *цеп), читек < эч итек* татар телендәге гаплологик тамыр ясалыш очраклары булса кирәк.

Татар теленең үзендә килеп чыккан тарихи мәгънә үзгәреш очраклары да юк түгел. Мәсәлән, «түбә кыегының терәк өчпочмагы» мәгънәсендәге *атлама* сүзе башта А хәрефен хәтерләткән җир үлчәгечне (таяк дип тә атала) белдергән, аны атлатып, җир озынлыгын үлчиләр. Шул формадагы терәкне дә *атлама* дип атый башлаганнар.

*Кыек* сыйфатыннан ясалган *кыек* исеме корылма түбәсенә авышрак итеп куела торган җайланманы белдерү өчен кулланыла. *Түшәм* сүзе исә – түшәлгән нәрсә, *түшәү* фигыленең нәтиҗәсе дигән сүз. Бу мәгънә үзгәрешләре шулай ук татар халкының көнитеше белән бәйле, алар татар теле җирлегендә барлыкка килгәннәр.

Эчке реконструкциядә морфологик закончалыкларны файдалану аеруча нәтиҗәле. Башлап иң беренчел билгеле аффикслар ярдәмендә билгесез тамырлардан ясалган сүзләрне истә тотарга кирәк. Андый тамырларны аерым алып карау уңай нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, *шикелле* (кебек) һәм диалекталь *шикелсез* (кыяфәтсез) сүзләреннән чыгып, элекке телебездә *шикел* сүзе булган дип ышанып әйтеп була. Алга таба бу сүз элекке татар телендәге *шәкел* (схема) (һөнәрчелек лексикасында «металл кою формасы») сүзе белән чагыштырыла; бу нигезнең исә гарәпчә *шакл* сүзеннән икәнлеге мәгълүм. Бу очракта иң кызыклысы шул: а > ә күчеше гомумкыпчак телендә булган. Шул *ә* исә татар телендә *и* гә күчә:

димәк, *шәкел* сүзе VII–VIII гасырларда ук кыпчак телләренә гарәп теленнән кереп, татар телендә дә бик иртә таралыш алган.

Шулай итеп, бу сүзләрдә чагылган *а* > *ә* > *и* күчешләре тел үсешенең нисби хронологиясен билгеләү өчен дә әһәмиятле.

Борынгы нигез һәм тамырларны билгеләүгә хезмәт итә торган кызыклы мисаллар фигыльләрдә очрый. Мәсәлән, *юан-у* һәм *юат-у* фигыльләреннән чыгып, без борынгы телдә *юа-у* фигыле булган дип ышанып әйтә алабыз; *йуан* – шул фигыльнең кайтым юнәлеше. Ә *йуат* йөкләтү юнәлеше булып чыга. Шулай ук *уян-* һәм *уят-* фигыльләре төп **уя-у* фигыленнән икәнлеге ачык. Хәзерге татар телендә *уяу* сыйфат фигыле хәзер дә кулланыла.

Эчке реконструкция борынгы яки искергән кушымчалар нигезендә дә башкарыла. Мәсәлән, *бугай* сүзенең *булгай* сүзеннән икәнлеге элекке язма телдә шактый киң файдаланылган *-кай* кушымчасының мәгънәләреннән чыгып дәлилләнә. Борынгы төрки телләрдә (һәм хәзерге чуваш телендә дә) *-н* аффиксы белән ясала торган инструменталь килеш актив кулланылган. Ул хәзерге телебездә *ялгыз → ялгызын, кич → кичен, иртә → иртән* кебек очракларда чагыла. Шуны белеп, без *кырын ← кыр, саен (сайын) ← сайы («сан» мәгънәсендә), тиген ← тик* һ.б. ны әйтә алабыз. Әлбәттә, бу фаразлар диалекталь материал һәм башка төрки телләр материалы белән чагыштыргач кына расланалар. Мәсәлән, *сайы* «саен» сүзе төньяк Башкортстан татар сөйләшләрендә кулланыла. Тик һәрбер *-(ы)н* // *-(е)н* кушымчасына беткән рәвеш яки сыйфат инструменталь килештән килә дип әйтеп булмый. Эчке реконструкция – этимологиянең башлангыч һәм мөһим этабы, ләкин аның белән артык мавыгырга да ярамый. Әлбәттә, туган тел сүзләренең этимологиясен туган телдән эзләү эздәнлек принцибына бик тәңгәл вә ярашлы. Ләкин бәхәсле очракларда сүз этимологиясен туган тел җирлегендә генә ачыкларга омтылу объективлыктан читкә этәрергә мөмкин.

А н а л о г и я ы с у л ы – этимологик тикшеренүләрдә иң нәтиҗәле, әһәмиятле ысул. Этимологиянең төп принципларына туры китереп караганда, аналогиянең түбәндәге төркемнәрен аерырга була: 1) изофонетик аналогияләр, 2) изоморфик аналогияләр, 3) изосемантик аналогияләр. Боларның һәрберсендә телнең үзендә, телләрнең аерым төркемендә, аннары дөньядагы барлык телләргә хас изо- (типик, фреквенталь) күренешләр аерым аңлатылаа.

Аналогияләр моңа кадәр таныш булмаган сүз үсешенең гипотетик моделен реконструкцияләү өчен кирәк. Мәсәлән, *тыкрык* сүзен алыйк. Иң элек татар телендә фигыльләрдән -*к* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр рәте барлыгын искә төшерү: *боз-* → *боз-ык, көй-* → *көек, яз-* (юлдан яз-) → *язык* («гөнаһ») һ.б. Сүз ясалышының шушы моделеннән чыгып, *тыкыр-ык* сүзе *тыкыр*- сүзеннән дип фаразлыйбыз. Андый фигыль гомумхалык татар телендә юк. Ул диалекталь сүзлекләрдә дә, кардәш һәм күрше телләр сүзлекләрендә дә урын алмаган. Инде татар телендә еш кына интервокаль (ике сузык арасындагы) -*к*- борынгы ике *к* (кк) авазыннан килеп чыгуын истә тотып, *тыкрык* ул *тыккыр-ык* булырга мөмкин дип уйлыйбыз. Кыпчак телләрендә *тыккыр-* «тыгылу, тупикка терәлү» фигыле барлыгын табабыз. Димәк, *тыккыр-ык* «тупикка терәлгән» дигән сыйфат булган, ул сыйфат, семантик үзгәреш кичереп, исемгә әверелгән (чагыштыр: *ватык, кисек* – сыйфат та, исем дә булып киләләр).

Аналогия ысулының фонетик, морфологик һәм семантик аспектлары бар. Фонетик аспект бу очракта этимологик аңлатманың фонетик үзгәреш законнарына хилаф булмавы гына түгел,монда бөтен бер аваз комплексларының, бер тип сүзләрнең охшаш үзгәрүе, гаплология модельләре күз алдында тотыла. Мәсәлән, *борынла-у* > *борна-у, кешенлә-у* > *кешнә-у, сарынла-у* («ритуаль җыр җырлау») > *сарна-у;* шулардан чыгып, *тырнау*ның элекке формасы *тырынла-у* булган, ә *чорна-у* фигыле *чорынла-у* формасыннан килеп чыккан дип уйлый алабыз һәм шуны раслый торган фактлар эзлибез. Әлбәттә, мондый аналогик фаразларда этимологик мәсьәләнең бүтәнчә чишелешләре булу ихтималын да истән чыгарырга ярамый.

Мәсәлән, *белдек, калдык, урындык* һ.б. исемнәрдә -*дык*//-*тык* аффиксы барлыгыннан чыгып, *сандык* сүзе дә ниндидер *сан*- нигезеннән ясалган дип фаразларга мөмкин. Ләкин *сандык* сүзенеңбарлык параллельләрен карап чыксак, аның Көнбатыш һәм Көньяк Азиядә электән киң таралганлыгы (гарәп, фарсы һ.б. телләрдә бар) һәм һинд телләрендәге *самдана* (сандык) сүзенә кайтып калуы мәгълүм була. Борынгы һинд телендә *sam dhana* – *sam* – «барчасы, бөтенесе», *dhana* – «савыт, сыйдыргыч; эченә салына торган нәрсә», *dhe* – «кую, салу» фигыленнән ясалган исем; борынгы фарсы телендә бу сүзгә кечерәйтү кушымчасы -*к* ялганып, ул *сан*-

*данак* формасын алган, шуннан *сандак, сандук, сундук* һ.б. вариантлар барлыкка килгән. Бу мәгълүматлар булмаса, татарча *сондык* варианты «сона торган нәрсә» дип фаразларга мөмкинлек бирер иде. Чынлыкта бу вариант халык этимологиясе буенча гына аңлату була.

Морфологик аналогия сүз ясалышы модельләре нигезендә башкарыла. Этимологиядә, әлбәттә, сүз ясалышының ысулларын, кушымчаларын һ.б.ны гына түгел, борынгыларын да белергә кирәк. Мәсәлән, борынгы төрки телләрдә (хәзерге инглиз телендәге шикелле) исем (һәм сыйфат) нигезләр бик җиңел рәвештә фигыль булып китә алганнар. Татар телендә бүгенгәчә сакланган *куш* (сыйфат) ~ *куш*- (фигыль), *ту*- (исем һәм сыйфат) ~ *ту*- (фигыль), *тын* (сыйфат) ~ *тын*- (фигыль), *у* (сыйфат) ~ *у*- (фигыль), *шеш* (исем) ~ *шеш*- (фигыль) шул халәтнең калдыкларыдыр. Моны белү күп кенә сүзләрнең чыгышын ачыкларга ярдәм итә.

Борынгы телебездә (татар теле үсешенең урта бер этабында) *-к* һәм *-лык* < *л-ык* интенсивлык фигыль аффиксы киң кулланылган: хәзерге телдә моның калдыклары: *йот-у → йотлык-у, кыз-у→ кызык-у, яз-у → яз лык-у* һ.б. Моны белү безгә атлык *-у ← ат-у, ашык-у ← аш-у* (менү, менеп җитү), *курык-у ← куры-* (төрекчә *koru* – «һөҗүмнән саклану»), *тотлык-у ← тот-у* дип ышаныч белән расларга мөмкинлек бирә. Алай гына да түгел, бу морфологик закончалыкны истә тотып, татар телендә онытылган фигыльләрне реконструкцияләргә дә мөмкин. Мәсәлән, *күзек-ү* фигыле *күз-ү* фигыленнән дип фаразлап була. Һәм, чыннан да, кайбер төрки телләрдә *köз- (гöз-)* (текәлеп карау, ачык күрү) фигыле билгеле (ЭСТЯ, 3: 60–63). Бу сүз исә – исем сүз төркеменә караган *күз* < *köз* сүзенең фигыль коррелянты.

Семантик аналогия бигрәк тә катлаулы. Этимологик анализ вакытында әлеге аналогиягә игътибар итмәү ялгышка китерергә мөмкин. Мәсәлән, элекке текстларда очрый торган *үчер-ү* (янган утны сүндерү) фигылен *очыр-у* дип укырга да була. Хәлбуки *очыру > сүндерү* күчеше беркайда да теркәлмәгән. *Үчер-ү* < гомумкыпчакча *öчир-,* кыргызча, уйгурча *öчүр* (сызып ташлау, исемлектән сызу; сүндерү), *öч* (юкка чыгу; сүнү) сүзеннән килә (себер татар сөйләшләрендә *үцер-ү* (сүндерү), *үц-ү, үч-ү* (сүнү) (Д.Г. Тумашева, 1992: 231). Фонетик яктан да *үчерү* һәм *очыру* арасында зур аерма бар.

К ү п е р ч е к л ә р ы с у л ы ул – этимологик фаразны раслау өчен, арадаш яңгырашлар, нигезләр һәм мәгънәләр эзләү дигән сүз. Мәсәлән, югарыда китерелгән *булгай* > *бугай* фаразын раслауга тукталыйк. Татар халык җырында *Тәрәзәләр ачып яулык болгай,* / – *Без сөясе ярлар шул булгай*, диелә. Монда *булгай* сүзе «бугай» мәгънәсендә килә.

Күперчекләр татар әйтем-мәкальләрендә, борынгы җырларда, әкият-риваятьләрдә, шулай ук әдәби әсәрләр телендә очрый. Ләкин аларның төп чыганагы – татар теленең диалекталь лексикасы, башка төрки телләр һәм аларның шивәләре, фольклоры, әдәбияты һ.б. Шуны әйтергә кирәк: этимологик күперчекләрне табу өчен, сүзлекләр, фольклор һәм язма әдәбият белән эш итү генә җитми, җанлы телләрне дә белү кирәк. Еш кына күперчекләрне кардәш телләрдә генә түгел, ә күрше телләрдә кулланыла торган татар теленнән кергән сүзләр тәшкил итә. Мәсәлән, *маташ-у* татар телендә «белмичә, юкка, уңышсыз рәвештә тырышу» дигән мәгънәдә генә кулланыла.

И з о г л о с с а л а р а л ы м ы . Изоглосса дигәндә, аерым сүзнең, шулай ук аның яңгыраш яисә мәгънә төсмерләренең, төрләнеш һәм кулланылыш үзенчәлекләренең таралыш чикләрен, шул чик сызыклары эчендәге таралыш ареалын күз алдында тоталар. Изоглосса этимологиясе эзләнә торган сүзнең мөһим характеристикаларының берсе була.

Гомумән, билгеләнгән изоглоссалар күптөрле лингвистик, тарихи-этнографик һ.б. мәгълүмат чыганагы була алалар. Сүзләрнең таралыш ареалы күрше телләрне дә үз эченә алырга изоглоссасы яки телнең үз эчендә генә дә булырга мөмкин. Мәсәлән, татар телендә киң кулланыштагы *гел* (*гелән*) сүзенең бүтән төрки телләрдә (башкорт телен исәпкә алмаганда) юклыгы күренә, ә татар теленең иренсезләштерү үзенчәлеге булган сөйләшләрдә *гөлле, гөллән* формасында очрый. Җ. Вәлиди (Вәлиди, 2007 ) һәм Л. Җәләй (Җәләй, 1947) *гел* (*гелән*) сүзенең килеп чыгышын әлеге формалар белән бәйләп аңлаталар.

Шулай итеп, сүзнең этимологиясен ачыклаганда, фәндә кабул ителгән ысул һәм алымнар комплексta, бер-берсен тулыландырып файдаланылырга тиеш. Шул рәвешле генә сүзнең чын тарихын билгеләп була.

## § 61. Сүз тамыры этимологиясе[1]

Сүз тамырының ясалышы – этимологиянең төп тикшерү предметларының берсе. Синхрон тел гыйлемендә сүз тамыры бүленми торган морфема буларак каралса, этимологиядә исә беренчел тамырларны аеру мәсьәләсе үзәккә куела.

Татар теленең тамырлар составы түбәндәгечә төркемләнә:

1) борынгы төрки чордан ук килеп, хәзерге телдә дә таркатылмый торган тамырлар;

2) алынма тамыр сүзләр;

3) тел үсеше дәвамында ясалган тамырлар.

Тамыр ясалу юллары түбәндәгеләр: гаплология, конверсия һәм лексикалашу, чит телдән үзләштерү, дублетлашу һәм кабат таркалу.

Гаплология (грек. *haploos* – гади, *logos* – өйрәнү) дип комбинатор үзгәрешләрнең бер төрен, диссимиляция нәтиҗәсендә бербер артлы янәшә килгән ике авазның берсе төшеп калуын атыйлар (Языкознание, 2000: 93). Ул ике төрле була: а) элекке кушымчалы сүз кыскару очраклары, мәсәлән, *бугай* < *булгай* (булырга тиеш) (*бул-* фигыль тамырына теләк фигыль кушымчасы *-гай* ялганып ясалган сүз, борынгы текстларда, мәсәлән, (төшлек китапларында) – юраунамәләрдә еш очрый), *күмәч* < *күммәч* (*-мач//-мәч* – ашамлык атамалары ясагыч кушымча), *күтәрү* < *күлтәрү* (элекке *күл- йөкләү* фигыленең йөкләтү юнәлеше формасы), *ылыгу* < *ыклыгу* (диалекталь *ыгу* (су уңаена агу) сүзенең интенсивлык формасы) һ.б.; ә) сүзтезмәләр берегеп кыскару очраклары, мәсәлән: *кузгалак* < *кузыйкалак* < *кузый колак*, *ябалак* < *йабаколак* < *йабай колак* (*йабай* – кыргый ат төре), *нитү* < *ни итү*; *сиксән* < *сәксән* < *сәккиз он*; *туксан* < *токкуз он; сарут* < *сары ут, ярут* < *яр уты* һ.б.

Конверсия – сүзләрнең нигез (кушымчасыз) формасында бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчүе – төрки телләрдә элек-электән киң таралган булган. Борынгы төрки телләрдә күп кенә тамыр сүзләр исем дә, фигыль дә булып кулланыла алганнар. Моның сакланган үрнәкләре хәзер дә очрый: *җил* (исем) – *җил-ү* (фигыль), *кат* (исем) – *кат-у* (кушу – фигыль), *куш* (исем һәм сыйфат) – *куш-у* (фигыль) һ.б. Исем – сыйфат, сыйфат – рәвеш бәйләнешләре хәзерге телдә шактый еш очрый.

---

[1] Бүлекчә Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда» (Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015) хезмәтенең кереш мәкаләсе нигезендә эшләнде.

Этимологик тикшеренүләрдә, конверсиянең борынгылыгын искә алып, мәсәлән, хәзерге фигыль тамырының элек исем буларак та кулланылу ихтималын хәтердә тоту мөһим. Фараз буларак, *кыр-у* фигыленең тамыры *кыр* (кырылган җир) булуы ихтимал һәм моның *кыр* (басу) сүзе белән бердәй булу ихтималы юк түгел. Шуның шикелле үк, тюркологлар *яр-у* һәм *яр* (крутой берег) сүзләрен чагыштыралар икән, бу бәйләнешне дә игътибардан читкә җибәрмәсеннәр.

Татар сөйләшләрендә киң таралган *чый-у* (очлы нәрсә белән язу, сызу) сүзенең исем коррелянты да бар: себер сөйләшләрендә *цый* (очлы нәрсә белән сызылган сызык). Бу сүзнең кытайча *цзый* (иероглиф) сүзеннән килеп чыгу ихтималы бар, һәм бу фаразның дөреслегенә өстәмә дәлилләр дә табыла: *чый* сүзенең *чыймай* варианты – ул «икмәк, кабартма һ.б. өстенә төшерелгән бизәк» һәм «шундый бизәк төшергеч корал» дигән сүз. Казах теле сөйләшләрендә «аркылы-торкылы сызыклар» мәгънәсендәге *шимай* < *чимай* сүзе кулланыла. Кытай телендә шулай ук *цзый-ма* (иероглиф сызымы) сүзе дә очрый. Бу этимологик процедурада иң мөһим момент – кытай телендәге исем сүз төркеменә караган сүзнең фигыльгә күчүе. Беренче карашка, бу гайре табигый кебек, әмма борынгы дәверләрдә ул гадәти күренеш булган.

Конверсиягә эллиптик тамыр ясалышы якын. Лексик эллипсис дип кушымчалы сүздән кушымча, сүзтезмәдән бер сүз төшеп калуны атыйлар. Шундый редукция нәтиҗәсендә сүзнең грамматик һәм лексик мәгънәсе кискен генә үзгәрергә мөмкин. Мәсәлән, татарча *кәләш* сүзе шулай килеп чыккан. Кардәш кыпчак телләреннән һәм чуваш теленнән күренгәнчә, *кәләш* – «сөйләшү, сөйләм» (*кәлә* – сөйләү фигыленең уртаклык юнәлеше) дигән сүз. «Сөйләшү» мәгънәсендәге сүзнең «кыз ярәшү» мәгънәсен алуы – типологик күренеш («кыз сөйләштек» дип хәзер дә әйткәлиләр). Борынгырак этапта *кәләшле* (сөйләшенгән, ярәшелгән (кыз)) сүзе ясалган булган. *Кыз* сүзе һәм *-ле* кушымчасы кыскарып, *кәләш* сүзе килеп чыккан.

Шулай итеп, эллиптик яңа тамыр ясалышы өчен, транзитив-арадаш ясалмалар булуы шарт. Мондый шартлар исә бик үк еш булмый. Югарыда телгә алынган очракта *кәләш*-ү (сөйләшү) сүзенең онытыла баруы зур роль уйнаган. Нәтиҗәдә *кәләш* (сөйләш) һәм *кәләш* (невеста) сүзләренең берсе телдән бөтенләй төшеп калган.

Татар телендә эллиптик тамыр ясалышы, гомумән, еш кына *-лы//-ле* кушымчасы төшеп калу юлы белән бара. Мәсәлән, гарәп

сүзләренең чыганактагы мәгънәсе үзгәреп, асылда яңа сүз – яңа тамыр килеп чыгу очракларын карыйк: гарәпчә *тәвәккәл* (риск) сүзеннән татарча *тәвәккәлле* сүзе ясалган, бу сүзнең *-ле* өлеше кыскарып, *тәвәккәл* «берәр эшкә керешкәнче, карар кабул иткәндә, икеләнмичә, кыю эш итүче» мәгънәсе килеп чыккан. Шулай ук *сабыр* (гарәпчә бу сүз – исем) → *сабырлы* → *сабыр* (сыйфат), *хәтәр* (исем) → *хәтәрле* → *хәтәр* (сыйфат) һ.б. мисалларны китерергә мөмкин.

Лексикалашу – төрләнеш формасындагы сүзнең төп формадагы сүз булып аңлашылуы (һәм еш кына фонетик яктан да үзгәрүе) – артык таралыш тапмаган. Лексикалашуга хәзерге телебездә кайбер бәйлек һ.б. ярдәмлек сүзләрнең, исемнәрнең юнәлеш килеше (мәсәлән, *башка, үзгә*), фигыльләрнең хәзерге заман өченче зат (мәсәлән, *аша* ← *ашу, үтә* ← *үтү*) формаларыннан килеп чыгуларына мисал булып тора. Кайбер вакыт рәвешләре дә шушы рәттә тора, мәсәлән, *иртәгә, кичкә* һ.б. Татар телендә борынгы (*-н* кушымчалы) инструменталь килеш формаларының рәвешкә әверелү очраклары күп: *җәй* → *җәен, көз* → *көзен, кыр* → *кырын, өст* → *өстен, ялгыз* → *ялгызын, кич* → *кичен, иртә* → *иртән*[1] һ.б.

Ч и т  т е л д ә н  ү з л ә ш т е р ү дигәндә, алынмалар алу түгел, ә алынма сүзләрнең фонетик яктан да, семантик яктан да үзгәрү, күчеш очраклары күз алдында тотыла, мәсәлән, татарча *дәрт* – «күңел кузгалу, ярсынучанлык» < фарсыча *дәрт* – «авыру, чир, хасталык»; татарча *мут* – «елгыр һәм хәйләкәр» < русча *мот* – «мал-мөлкәтен (бигрәк тә акчасын) әрәм-шәрәм итүче» мәгънәләрен белдерәләр.

Э т и м о л о г и к  д у б л е т л а ш у нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүзләрнең оригиналга иң якыннан калганнары – яңа тамыр, мәсәлән, *газап* һәм *азап* парының беренче сыңары – алынма сүз, икенчесе – татар теле җирлегендә ясалган яңа тамыр сүз. Төрки чыгышлы *бөек* һәм *биек*, *олуг* һәм *олы*, *ыруг* һәм *ыру* һ.б. шундый парларның һәр сыңары – аерым тамыр.

К а б а т  т а р к а л ы ш  к ү р е н е ш е, тамыр ясалу ысулы буларак, артык киң кулланылмый. Бу ысулга мисал – парлы *исе-косы* (юк) < борынгы *иесе-конысы*: монда *исе* – борынгы *ийе (< ыйыз, ыйыд)* (ис, аңкыш) сүзенең өченче заттагы тартым формасыннан:

---

[1] Конверсия һәм лексикалашу очраклары синхроник планда Ф.Ә. Ганиевнең «Конверсия в татарском языке» китабында яктыртылган.

*ие-се*. Вакытлар үтеп, *ийе* тамыр сүзе үзе онытылгач, *ие-се* сүзе *иес-е* дип «кабат таркатылган» һәм шуңарчы булмаган *ис* (запах) сүзе ясалган (шуннан элекке *ис* < *эс* (хәтер) сүзенә омоним килеп чыккан). Нәкъ шуның шикелле, *куу-сы* > *коы сы* > *кос-ы* (кебек аңлашылган). *Төс* сүзе борынгы *тө*-се «тө-се» (*тө* – атның һ.б. терлекләрнең йон-ябагасы) сүзеннән. *Микән* кисәкчәсе *-мы икән* компонентларыннан кабат таркалыш юлы белән ясалган һ.б.

## § 62. Нигез һәм кушымчалар этимологиясе

Төрки тел белемендә, гомумән, алтаистикада «нигез» һәм «тамыр» төшенчәләрен аеруда төгәл критерийлар эшләнеп җитмәгәнлектән һәм беренчел тамырны билгеләүдә фикер төрлелеге күзәтелгәнлектән, сүзнең нигезен аеруда да төрлелек бар. Мәсәлән, Н.А. Баскаков беренчел нигез дип сүз тамыры һәм лексик-грамматик кушымчаларның бергәлеген аера, икенчел нигез буларак тамыр һәм функциональ-грамматик кушымчалар берлеген күрсәтә (Баскаков, 1979: 145). К.М. Мусаев исә караим теле мисалында сүз нигезенең таркалмый торган тамырдан гына, шулай ук тамыр һәм сүз ясагыч морфемалардан да тору ихтималлыгын ассызыклый (Мусаев, 1984: 83).

Татар телендәге таркатылмас нигезләр тарихи яктан түбәндәгечә классификацияләнәләр:

1) гомумтөрки нигезләр;

2) татар теленең үзендә генә булган нигезләр;

3) төрки булмаган телләрдән алынма нигезләр.

Гомумтөрки нигезләргә барлык яисә күпчелек төрки телләрдә теркәлгән нигез сүзләр һәм борынгы баба төрки телдә булган дип фаразланган нигез сүзләр керә. Гомумтөрки сүзләр арасында һинд-ирани, кытай, монгол һ.б. телләрдән борынгы чорда ук кергән алынмалар да бар.

Татар теленең үзендә генә булган нигезләр мәсьәләсе дә гади түгел. Бу төр нигезләр арасында: а) гомумтөрки тамырлардан ясалганнары, ә) алынмалардан ясалганнары, б) фонетик дублетлашу юлы белән ясалганнары, в) чыгышы билгесез сүзләр бар.

Алынма нигезләрне классификацияләү шулай ук катлаулы: гомумтөрки алынмаларны синхрон тел белеме күзлегеннән аңлаткан хәзерге татар телендәге алынмалар рәтенә кертү-кертмәү мәсьәләсе шактый четрекле. Бу төркемдә түбәндәге асклассслар бар:

а) төрки телләрдән алынмалар;

ә) калькалар һәм лексикологик субституцияләр;

б) чыгышы билгесез халыкара, «мәдәни» сүзләр;

в) бер борынгы сүздән таралып, татар теленә төрле чыганаклардан һәм төрлечә килеп кергән полиплет алынмалар.

Таркатылмас нигезләрне төркемләгәндә, аларның сүз төркемнәре буенча бүленүләре дә исәпкә алына. Этимология өчен сүз төркемнәренең дихотомик бүленеше уңайлы һәм нәтиҗәле. Һәр аерым сүз төркеменең этимологиясе үзенчәлекле була, һәм аны аңлап эш итү сорала.

Сүз төркемнәренең этимологик үзенчәлекләре буенча классификациясенә аерым тукталыйк.

Ымлыклар (беренчел, төп ымлыклар) барча телләрдә дә охшаш: *а, э, уф!, и-и, ыы* һ.б. Алар рефлектор авазларны белдерәләр. Алмашлыклар һәм төп саннар һәр телдә чикләнгән санда була. Алмашлыкларда һәр телдә регуляр булмаган төрләнеш (супплетивизм) һәм лексикализация еш очрый. Алар һәр төрки телдә үзенчә. Саннар, алмашлыклар һәм фигыльләр составында алынма сүзләр бик сирәк була. Исем һәм сыйфат сүз төркемнәре составында алынма сүзләр шактый күп.

Этимологиягә караган нигезләр типологик яктан да тикшерелә. Типологик яктан нигезләрнең түбәндәге төркемнәре аерыла:

1) төрки телләрдән элеккерәк (гомумтөрки телгә төзү материалы биргән) телләрдән калган билге тамыр сүзләр;

2) ясалганлыгы билгеле билге тамырлар;

3) алынмалыгы билгеле билге тамырлар;

4) ымлык тамырлар;

5) ияртем (тәкълиди) тамырлар һәм нигезләр;

6) чыгышы билгесез тамырлар һәм нигезләр.

Ясалма тамыр һәм нигезләрне аерганда, аларның ясалыш мотивациясе шактый катлаулы як булып тора. Этимологик анализда аеруча субституция һәм калька кебек мотивлаштыруны белү мөһим.

С у б с т и т у ц и я – чит тел элементларын үз телеңнең элементлары белән алмаштыру дигән сүз. Субституция күренеше берничә яссылыкта ачыла.

Фонетик субституция чит тел авазларын, башка фонетик элементларны телнең үз фонетик элементлары белән алмаштыру (мәсәлән, *ведро* > *бидрә, грузди* > *гөреҗдә, печь* > *мич* һ.б.) дигән

сүз. Фонетик субституция, ягъни һәр ике тел арасындагы фонетик тәңгәллекләр аерым закончалыкларга буйсына, һәм этимологиядә аларны белеп эш итү зарур.

Лексик субституция дигәндә, башка телдән «тәрҗемә ителеп», шул тел сүзе яки сүзтезмәсе урынына ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләр күз алдында тотыла, мәсәлән, *тракторчы (тракторист), эшчеләр сыйныфы (рабочий класс)* һ.б. Хәзерге татар әдәби телендәге күп кенә административ терминнар рус телендәге сүз һәм тәгъбирләрдән лексик субституцияләр саналалар, мәсәлән, *дәүләт комитеты, профильле мәктәп, яшьләр үзәге* һ.б. Мондый сүзтезмәләрнең конкрет мәгънәсе еш кына аларның русча тәңгәлләрен белгәндә генә ачык аңлашыла. Шул ук вакытта алар алынма буларак карала алмыйлар.

Чит телдәге сүзнең яки сүзтезмәнең ясалыш яисә мәгънә структурасын туган телгә тәрҗемә итүне калька дип атыйлар. Калькалаштырганда, нигездә, семантик мотивлашу барлыкка килә, ягъни сүзнең икенчел мәгънәсе алына.

Татар халкы инде озак дәверләр дәвамында икетеллелек шартларында яши. Шунлыктан тел үсешендә калькалар татар теле лексикасының сүз ясалыш структурасына һәм семантик системасына зур йогынты ясый. Сүзнең калькамы яки телнең үз җирлегендә барлыкка килү-килмәвен ачыклау өчен, экстралингвистик детальләрне белү мәҗбүри.

Шуны искәртү зарур: субституция һәм калькалар ясалышы этимология өчен гаять зур әһәмияткә ия, әмма бу – тел белемендә гаять аз өйрәнелгән өлкә. Сүз нигезенә этимологик анализ ясаганда, кыенлык тудыручы мәсьәлә булып сүзлекләрдә сүзләрнең төп һәм кайбер күчерелмә мәгънәләре, сүзтезмәләр составында актив кулланылган очраклары гына күрсәтелү тора. Шуның өстенә сүзнең семантик үсеше – диахроник планда дәвамлы күренеш, кайчандыр актуаль күчерелмә мәгънә тел үсешенең башка этапларында мотивлаштыру җирлеген югалтырга яки бу үзенчәлек онытылырга мөмкин.

Калькалар өлкәсендә тагын бер җитди мәсьәлә: еш кына бер-берсеннән ерак торган телләрдә дә сүзләр һәм сүзтезмәләрнең мәгънә структуралары бердәй булырга мөмкин. Мифларда, әкиятләрдә, барча телләрдә дә йолаларда охшаш элементлар табылган шикелле, сүз структураларында да телләрнең үзара тәэсирләшүен-

нән тыш килеп чыккан охшашлыклар булгалый. Мәсәлән, русча *бабье лето* ~ татарча *әбиләр чуагы* ~ алманча *Altweiber sommer* – көзге җылы көннәрнең фигураль атамасын игътибарлап карасак, рус һәм алман тәгъбирләрендә үзара тәэсирләшү нәтиҗәсе күрсә дә, *әбиләр чуагы* тәгъбиренең нәкъ менә рус яисә алман сүзе тәэсирендә килеп чыгуы шикле.

Бер төркем тел гаиләләрендә – төркиләрдә, монголларда, финугорларда, кытайларда һәм дравидларда (Көньяк Һиндстан) модификатор фигыльләр кулланыла һәм аларның мәгънәләре бертөсле. Мәсәлән, «китү» мәгънәсендәге фигыльләр модификатор буларак «кинәт башлануны» (балкып китү, ярсып китү), «чыгу» мәгънәсендәге фигыльләр «тәмамлау, һәммәне эченә алуны» (укып чыгу, карап чыгу) белдерә һ.б. Бу очракта да модификатор фигыльләрнең функцияләре – мәгънә структуралары охшашлыгы борынгы тәэсирләшү нәтиҗәсе дип әйтү өчен өстәмә дәлилләр кирәк.

XX гасырның 10–20 нче елларында татар әдәби телендә бик күп калька (башлыча, рус сүзләреннән күчереп) ясалган. Иң элек алар – иҗтимагый-сәяси терминнар: *алым* ~ *приём* («ысул» мәгънәсендә), (социаль) *чыгыш* ~ (социальное) *происхождение* (исходить «чыгу»). Соңрак матди мәдәнияткә мөнәсәбәтле сүзләр калькалаштырыла: *азыктамыр* ~ *корнеплод, субүләр* ~ *водораздел, водораздельный, суүсем* ~ *водоросль; очлыклар* ~ *конечности* һ.б. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә дә кайбер сүзләр, сүзтезмәләр чынлыкта калька түгел, күп дигәндә, субституция генә, мисал итеп *ташландык* ~ *бросовый, утчәчәк* ~ *горицвет, еллык балдаклар* ~ *годичные кольца* кебек номинацияләрне китерергә була.

Сүз нигезенә этимологик тикшеренүләр үткәргәндә аларның омонимлыгын да истә тоту зарур. Татар телендә омоним нигезләр һәм тамырлар шактый күп. Омоним беренчел нигезләрнең күпчелек өлешендә сүзләрнең берсе – сыйфат, рәвеш яисә исем, икенчесе – фигыль. Мәсәлән, *аз – аз, күп – күп, кыл – кыл, тел – тел, чык – чык, ят – ят* һ.б.

Этимологиягә мөнәсәбәттә карап, омонимнарны чыгышлары буенча түбәндәге төркемнәргә аерырга мөмкин: 1) фонетик үсеш-үзгәрешләр нәтиҗәсендә пәйда булганнары, 2) омоним тамырлардан яисә омоним кушымчалар ярдәмендә бердәй тамырлардан ясалганнары, 3) төрле мәгънә үзгәрешләре нәтиҗәсендә бер үк сүзләрнең ике мәгънәдә һәм төрле валентлыкта кулланыла башлау очраклары –

радиация, 4) лексик һәм фразеологик эллипсис нәтиҗәләре, 5) чит теллэрдэн сүзлэр алу яисэ калькалаштыру нэтиҗэлэре.

Фонетик үзгәрешләр, башлыча, позицион һәм тоталь характерда була. Позицион үзгәрешләр үзе ике төрле: аваз кыскарулар (редукция һ.б.) һәм позицион аваз күчешләре (ассимиляция, диссимиляция һ.б.). Махсус тарихи фонетика курсларында фонетик үзгәрешләрнең башка сирәк төрләре дә күрсәтелә, без аларга аерым тукталмыйбыз.

Барча телләрдә сүзләрнең кыскара баруы – фонетик үсешнең генераль линиясе ул. Бигрәк тә сүз нигезенең ахыргы өлеше редукцияләнә. Ләкин һәрбер тел механизмы үзендәге кыскару процессына үзенчә җайлаша, үзрегуляция һәр телдә үзгәрәк бара. Төрки телләрдә бер-берсенә ялганып килә торган төрләндергеч кушымчалар кыскартылуга бирешмиләр, чөнки аларның һәрберсе үз урыннарында алыштыргысыз: һәр төрләндергеч үз мәгънәсендә һәм үз сингармоник рәтендә бер генә һәм ул бер генә грамматик мәгънәгә ия. Ә менә тамырлар һәм нигезләр кыскаручан. Нәкъ менә шундый кыскарулар нәтиҗәсе буларак, *ат* (< ахта) һәм *ат* (< айыт) (исем), *кул* (< кол) һәм *кул* (<коол) (тирән үзән), *сай* һәм *сай* (< сагай) (рәт, тезем) һ.б. омоним тамырлар.

Кайбер төрки телләрдә омонимнар тоталь фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсендә ясалганнар; казах телендә *бас* «бас» (бас-у фигыленең башлангыч формасы) һәм *бас* «баш» сүзләренең омонимлыгы казах телендә тоталь *ч* > *ш*//*ш*> сүзара багланышлы күчешләре нәтиҗәсендә килеп чыккан. Чуваш телендә велярлашу (*ә* > *а, ү* > *у* һ.б.) нәтиҗәсендә *анра*- «аңгырау» – *анра*- «иңрәү», *антӑх*- «ант итү» – *антӑх* «интегү», *ас*- «азу» – *ас* «ис», *ват*- «вату» – *ват* «ут», *какӑр* «кәкер, кәкре таяк» – *какӑр* «каһәр» кебек омонимнар пәйда булган. Башкорт телендә *з* > *ҙ* һәм *д* > *з*, күчешләре (тоталь диярлек ҙ-ләштерү) нәтиҗәсендә омонимнар ясала: *биҙәр* «бидәр» һәм *биҙәр* «бизәр». Татар теле тарихында тартыклар өлкәсендә (позицион-тоталь -*к* > -*г, -г*//-*г, г* > *w, v* күчешен исәпкә алмаганда) тоталь аваз күчешләре булмаган диярлек. Шунлыктан аваз күчешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән омонимнар юк. Сүз уңаеннан шуны әйтергә кирәк: аваз күчешләре нәтиҗәсендә омонимнар барлыкка килү, шул аваз күчешләренең нисби хронологиясен билгеләү өчен, ышанычлы чыганак булып тора. Омоним кушымчалар бер үк тамырларга вә нигезләргә ялганып яңа омоним нигезләр ясалуга ачык мисал: татар

телендә *килеш-* (фигыль нигезе *кил-ү* сүзенең уртаклык юнәлеше) һәм *килеш* (исем, шул ук *кил-* тамырына исем ясагыч *-еш* кушымчасы ялганып ясалган) шикелле пардашлар сериясе.

Омоним тамырлардан омоним нигезләр дә ясала ала, әлбәттә: *атлы* ← *ат* (хайван) һәм *атлы* ← *ат* (исем); *парлы* ← *пар* (бу) һәм *парлы* ← *пар* (икелек). Ләкин андый сүзләр күп түгел, телдә омонимнардан качарга омтылу тенденциясе яши.

Л е к с и к  р а д и а ц и я г ә  бердәйлекләре нык үзгәргән һәм хәзер инде танып булмый торган сүзләр карый (гади конверсия һәм синкретизм күренеше боларга керми). Мәсәлән, борынгы *балык* (кала, шәһәр) һәм *балык* (рыба) сүзләрен тюркологлар борынгы *балыг, балуг* < *баллуг* (балчыклы, сазламык) сүзенә кайтарып калдыралар. Хикмәт шунда: киез торакларда яшәргә күнеккән төркиләр өчен чи кирпечтән эшләнгән кала корылмалары «балчык» булган. Шул ук вакытта, сазлыкларда яшәгән сазан, табан кебек балыклар да «балчык, саз җанвары» буларак күзалланган.

*Ут* һәм *ут* (үлән) сүзләре учакка коры үлән ягып яшәгән заманнардан калган булса кирәк (чагыштырыгыз: шул ук *учак* < *ут чак* һәм *утын*). *Ял* (хезмәтченең эш хакы) һәм *ял* (тәнәфес) сүзләре дә бер үк сүздән булырга тиеш һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, радиацияне билгеләү өчен, борынгы замандагы яшәү шартларын һәм борынгыларның фикерләү рәвешен яхшы белергә кирәк. *Кер* (пычрак) һәм *кер* (юылган тукыма, кием), *уба* (ясалма) һәм *уба* (чокыр), *чүпләү* (чүпле итү) һәм *чүпләү* (чүпләрне җыю) кебек очраклар төрле этник төркемнәрдә төрлечә уйлау нәтиҗәләре.

Радиациянең икенче бер төре бер үк телгә төрле диалект, шивә һәм телләрдән сүзләр керүдән килеп чыга. Мәсәлән, *керешү* (бер-берсенә керү) һәм *керешү* (башлау, тотыну) омонимнары лингвистик ситуация үзенчәлекләре нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Эллипсис нәтиҗәсендә радиация килеп чыгуга мисал: *килеш* (килү күренеше) һәм *килеш* (рәвеш) – *килешли* сүзеннән (килеш – грамматик термин беренче сүздән күч. мәгъ.); *тибеш* (тибү күренеше) һәм *тибеш* (сыйфат – «көчле, импульсив») – *тибешле* сүзеннән; *тиеш* (тию күренеше) һәм *тиеш* (хәбәрлек) – *тиешле* сүзеннән.

Чит телләрдән сүзләр алу (яисә керү) нәтиҗәсендә татар телендә хасил булган омонимнарга мисаллар: *бур* < русча «вор» – *бур* «известь таш», *бит* < «ведь» (кисәкчә) – *бит* «йөз», *көшел*

«ындырда ашлык өеме» (русча *кошель* сүзеннән булса кирәк, аның шундый мәгънәсе дә бар) – *көшел* «су күсесе», *кул* «тән әгъзасы» (борынгы төрки *кол* сүзеннән) – *кул* «кечкенә инешле яки инешсез үзәнчек» (борынгы монголча *коол* сүзеннән), *сабак* (*сап* сүзеннән) – *сабак* «үзләштерәсе уку материалы» (гарәпчәдән), *сала* «зур авыл (село)» – *сала* «тезем (биш бармак бергә, яссыга тармакланган ботаклар)» һ.б. очраклар.

Шулай ук омоним парларның икесе ике телдән алынма булу очраклары да сирәк түгел, мәсәлән: татарча *пот* < рус. пуд – *пот* < һинди Будда (һәйкәле). Кайбер очракларда омонимнар икесе дә бер үк телдән алынма була, мәсәлән, *җәһәт* (тиз генә, эшлекле рәвештә) – *җәһәт* (як, тараф) икесе дә гарәпчәдән (гарәпчәдә алар, икесе ике сүз); *тут* (агач) – *тут* (тигез төшкән буяу, төс – шуннан *кер тутлату*) икесе дә фарсыдан, *хур* (*хур булу сүзендәге*) – *хур* (кызы) икесе дә гарәпчәдән; *хәл* (гомуми торыш) – *хәл* (чишелеш – хәл итү) икесе дә гарәпчәдән (чыганак телләрдә бу сүзләр төрлечә язылалар).

Шулай итеп, омоним яисә радиатив пардашы булу сүзнең алынмалык билгеләренең берсе дип расларга мөмкин. Икенче төрле әйткәндә, әгәр телдәге таркатылмас нигезләрдә бер үк сүз төркеменә кергән омоним сүзләр бар икән, шуларның кимендә берсе алынма дип фараз итү һәм тикшереп карау тиеш.

Сүзләргә дөрес этимологик анализ ясау кушымчаларны аера белү, аларның башлангыч формаларын таба алуга да бәйләнгән. Кушымча морфемаларның ясалыш юллары:

1) кушымча тулы лексик мәгънәле сүздән, мәсәлән, -*чы* исем ясагыч кушымчасы (*башчы, итекче, эшче*) борынгы *чын* (кеше, кемсә) сүзеннән; *балтырган, бөрлегән, карлыган, кылган, шалкан* үсемлек исемнәрендәге -*ган*/-*кан* кушымчасы монгол телләрендә сакланган *гана* / *кана* (үсемлек, җимешле үлән) сүзеннән (татар сөйләшләрендә *кана-у* – үсеп чыгу, курпылау) һ.б. (Әхмәтьянов, 2015: 24). Н.А. Баскаков фикеренчә, -*лык*/-*лек* (*урманлык*) кушымчасы уйгур телендәге «тулы, күп» мәгънәсен белдерә торган *лик* сүзенә кайтып кала, -*лык* кушымчасыннан атрибутив -*лы* ясалган (Ганиев, 1998: 247); -*ча* кушымчасы (*юлгача, көзгәчә*), вакыт һәм урын мәгънәсендәге *чак, чаклы* сүзенә барып тоташа, -*чык*/-*чек* (*кызчык, китапчык*) кушымчасы да *чак*/*чаклы* сүзеннән (шунда ук: 252). -*ыш*/-*еш* кушымчасы (борылыш) *эш* сүзеннән кыскарган (шунда ук: 257), -*ыч* (таяныч) кушымчасы – -*чак* кушымчасының

үзгәргән варианты (шунда ук: 261); *-ла*/*-лә* (*эшлә, көйлә*) кушымчасы атрибутив *-лы*/*-ле* кушымчасы үзгәрүдән туган дигән фикер бар (шунда ук 326). Л.Ш. Арсланов «К вопросу о происхождении аффикса страдательности» (1992) мәкаләсендә фигыльләрдәге төшем юнәлеше кушымчасын *ал* фигыленнән кыскарып ясалган дип яза: мәсәлән, *ясалды* сүзендәге *-л* кушымчасы, ләкин нигездә [л] авазы булса, бу кушымча *-н* га әйләнә: *үлчәнде* (Арсланов, 1992: 244). Төрки телләрдә һәм, гомумән, алтай телләрендә кушымчаларның әлеге юл белән барлыкка килү карашы киң таралыш тапкан, һәм шул нигездә кайбер галимнәр бу телләрнең борынгы чорда аналитик телләр булу мөмкинлеген да фаразлыйлар;

2) кушымча борынгы ике-өч кушымча яисә лексик мәгънәле сүз һәм кушымча берегүдән килеп чыга, мәсәлән, *-кыч* кушымчасы элекке *-кучы* < *-ку+чы* кушма кушымчасыннан; *-ла* һәм *-лы* < *-лыг* кушымчаларының *-л* өлеше борынгы *ул* (җыен, масса, туплам, күплек) сүзеннән (*-ла* < *-ул-а, -лыг* < *-ул-ыг*); *-ты* билгеле үткән заман фигыль кушымчасы борынгы *-т* + *ы* кушылмасыннан (*-т* фигыльдән исем ясагыч, *-ы*/*-е* тартым кушымчасы); *-ныкы*/*-неке* кушымчасы *-ны*/*-не*+*-ке* кушымчаларыннан тора һ.б.;

3) кушымча чит телдән үзләштерелә, мәсәлән, фарсы теленнән *имәнсәр, каенсар* кебек сүзләрдәге *-сар*/*-сәр*; *акылдар, илдар, колдар* кебек сүзләрдәге *-дар* кушымчасы алынган; *Думав-и* (Дума авылыннан), *Утыз Имәни* (Утыз Имән авылыннан) кебек фамилияләрдәге, шулай ук *әкият-и, дәүләт-и* кебек сүзләрдәге *-и, -ви* – гарәп теленнән һ.б.;

4) яңа кушымча борынгы кушымча дублетлашу нәтиҗәсендә барлыкка килә, мәсәлән, *-лы*/*-ле* һәм *-лык*/*-лек* борынгы *-лыг* кушымчасыннан килә һ.б.

Сүзләргә этимологик анализ ясаганда, кушымчаларның кайсы сүздән, кайчан, ничек ясалганлыгына аерым игътибар җитеп бетми, югыйсә кушымчаларның кайчан нинди формаларда кулланылуын исәпкә алалар.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, этимологиядә сүзнең нигезен һәм кушымчасын аеру, аңа объектив аңлатма бирү өчен, телнең үсеш закончалыкларын, аерым катламнарында барган үзгәрешләрне, төрле чорларда башка телләрдән кергән сүз һәм сүз элементларының үзенчәлекләрен һәм телдән тыш факторларның тәэсирен комплекслы өйрәнү әһәмиятле.

## § 63. Татар теленең үз сүзләре һәм алынма сүзләр этимологиясе

Югарыда әйтелгәнчә, этимология барлык фәнни принципларга тайпылышсыз җавап бирергә һәм логикага корылган булырга тиеш. Бу таләп аеруча идентификация мәсьәләсендә ачык чагыла. Мисалга татарча *баш*, казахча *бас*, хакасча *пас*, чувашча *поç*, *пуç* сүзләренең бер сүз булуын ачыклауны карыйк. Саналган телләрдә меңнәрчә сүз һәм морфема гаять зур систематик охшашлык хасил итә һәм әлеге сүзләр бу телләрдәге аваз тәңгәллекләре кысасыннан чыкмый. Тарихи яктан әлеге телләрдә сөйләшүче халыкларның бер баба телдән чыгулары һәм күптөрле багланышлар кичергәнлеге билгеле. Шунлыктан аларның бер үк сүз булуы шик тудырмый.

Кардәш булмаган телләрдәге сүзләрне чагыштыруда мәсьәлә катлаулана. Мәгънәләре дә, яңгырашлары да бик охшаш, әмма төрле генетик фондка караган сүзләр бар. Мәсәлән, латин телендә татар сүзләренә охшаш сүзләр очрый: *cardo* «чик сызыгы (киртә – ?)», *carpo* «эләктереп алу (балык карпыту – ?)», *delirium* «тилерү», *macto* «мактау – ?)», *maturus* «өлгергән (матур – ?)», *salus* «саулык – ?)», *tuber* «тубырчык – ?)». Этимологик тикшерү барышында латин һәм татар сүзләрнең мәгънәви, фонетик һәм морфематик үсешләре бөтенләй үзгә булуы беленә. Аннары латин телендә сөйләшкән халык белән төркиләрнең сүзләр алышырлык тыгыз багланышта булганлыгы тарихта ачык түгел. Шулай ук алманча *schelten* һәм татарча *шелтә*, *saugen* (имү, саву) һәм татарча *сау-у* мәгънәдәш вә аваздаш булсалар да, тамырдаш, нигездәш түгелләр һ.б.

Чит телләрдәге сүзләр белән татар теле сүзләрен чагыштырганда шуңа да игътибар итү мөһим: ике-өч аваздан торган сүзләрнең охшашлыгы бернигә дә ишарә итми, чөнки дөньяда ике фонематик аваз тезмәләренең саны чикле, шулар арасында охшашрак мәгънәлеләре очрау бер дә гаҗәп түгел. Ике-өч авазлы төрки-татар чыгышлы тамыр сүзләргә мәгънә ягыннан да охшаш ике-өч авазлы сүзләрне дөньядагы һәрбер телдән табып була. Дүрт-биш авазлы тамыр сүзләр (мәсәлән, югарыда телгә алынган латин сүзләре) дә, бүтән сәбәпләр булмаса, үзләре генә этимологлар игътибарын җәлеп итмиләр. Тик биш авазлы мәдәни мәгънәле, киң таралган семантикалы тамырлар гына (ә андыйлар, гомумән, аз) уйландырырга мөмкин. Әмма андый очраклар да тулысынча ышандырырлык түгел.

Бердәй мәгънәдәге фраземалар, җөмлә эчендә килгән сүзләр рәте бердәйлеге генә тулысы белән ышандырырга мөмкин. Һәм, әлбәттә, бу очракта да фонетик закончалыкларны истә тоту зарур.

Һәрбер телнең сүзлек составында үз сүзләре һәм алынмалар барлыгын беләбез. Татар теленең сүзлек составында өч катлам аерыла: 1) төрки мирас, 2) тарихи алынмалар, 3) татар теленең үзендә барлыкка килгән сүзләр.

Төрки мирас дигәндә а) гомумтөрки сүзләр, ә) көнбатыш төрки (мөселман төркиләре телендә барлыкка килеп, христиан вә яһүди төркиләргә дә кергән) сүзләр, тәгъбирләр, б) гомумкыпчак сүзләре күзаллана.

Тарихи алынмалар тематик төркемнәре һәм чыганакларына (кытай-тибет; һинд-иран, согдий; фарсы-таҗик; гарәп-семит; монгол; рус-славян; фин-угор; билгеле һәм билгесез башка телләр) карап, берничә төргә бүленә, әмма бу бүленештә аерым искәрмәләр бар.

Һинд-иран һәм согдий алынмаларыннан фарсы-таҗик алынмалары яңа (IX–X гасырларда формалашкан) фарсы теленнән булулары белән генә аерыла.

Монгол алынмаларының бер өлеше бәхәсле, бу төркемгә тунгус-маньчжур телләреннән килгәннәре дә кертелә, чөнки алар төрки телләргә монгол телләре аша кергән булырга тиеш.

«Бүтән телләр» дигәндә, иң беренче чиратта борынгы Балтыйк телләре, Кавказ телләре, әрмән теле һәм, ихтимал, тохар теле күз алдында тотыла. Татар телендә борынгы герман (остгот) сүзләре дә булу фаразлана (Әхмәтьянов, 2015: 44).

Күрсәтелгәннәрдән тыш, татар әдәби һәм гомумхалык телендә кардәш төрки телләрдән кергән катлам да бар һәм алар арасында төрки булмаган (алынма) сүзләр дә очрый. Күренә ки, «алынма» төшенчәсе шактый катлаулы һәм киң аспектлы икән.

Сүзлекләрдә, гадәттә, сүзнең турыдан-туры алынма чыганагы, ягъни татар теленә турыдан-туры кайсы телдән кергәнлеге күрсәтелә. Әлеге сүз ул телдә үзе икенче бер телдән, икенче телдәге сүз өченче телдә һ.б. алынма булырга мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге *пижама* сүзе рус теленнән алынган, рус теленә бу сүз француз теленнән, француз теленә – инглиз теленнән, инглиз теленә – Һиндстан телләреннән, Һиндстан телләренә – фарсыча *пайҗама* (аяккием), ягъни «аякларны каплап торган озын итәкле өс киеме»

сүзеннән. Аерым махсус хезмәтләрдә билгеле булган иң беренче (иң борынгы) чыганак кына күрсәтелә, ләкин бу ысул популяр түгел. Татар телендәге *пижама* сүзен шулай ук фарсы алынмасы дип әйтү дөрес булмас иде. Алынма сүз турында сүз алып барганда, беренче чиратта сүзнең бөтен үткән юлын яктыртырга кирәк.

Сүзләрнең алынмалыгы чагыштырма лексикологик хезмәтләрдә билгеләнә. Алынмаларның фонетик, морфологик һәм мәгънәви-семантик билгеләре була.

Алынмаларның фонетик билгеләре. Татар әдәби телендә алынмалар ике зур төркемгә бүленә. Беренчесе – фонетик яктан үзләштерелгән алынмалар, икенчесе – үзләштерелмичә кулланыла торган алынмалар. Менә бу үзенчәлек соңгы гасырларда, башлыча, китап теле аша кергән һәм чыганак телләрнең таныткыч билгеләрен саклаган хәлдә, татар гомумхалык теленең фонетик үзенчәлекләренә буйсынмаган күп санлы алынмаларны танып алырга мөмкинлек бирә.

Этимологик тикшеренүләр өчен, татар теленең гомумтөрки үзенчәлекләр нигезендә һәм борынгы субстрат тәэсирендә кимендә мең ел дәвамында формалашкан үз, төп фонетик законнарын а) авазлар составы, ә) аларның кулланылыш кагыйдәләре, б) иҗек һәм сүз басымы үзенчәлекләре ягыннан аңлату уңайлы.

Иске кыпчак-татар телендә авазлар составы хәзергедән ярлырак: анда тугыз сузык (*а, ә, у, ү, о, ө, е, ы* һәм *и*), унтугыз тартык (җиде сонор – *л, м, н, ң, р, w, й* һәм унике парлы – *б/п, г/к, д/м, з/с, җ/ч* һәм *ж/ш*) булган. Каты һәм йомшак тартыклар һәм шул исәптән *ķ, ғ* һәм *г* аерым фонема булмаганнар. Күрсәтелгәннәрдән *ж* авазы ымлык, ияртем сүзләр тамырларында һәм шулардан ясалган сүзләрдә генә очраган (мәсәлән, *ажгыру* ‘котырынып исү; нык давыллау’, *ыжсылдау* ‘туктаусыз ыж-ыж кебек тавыш чыгару’, *жуылдау* ‘жу иткән тавыш чыгару’). *Ф* авазы да бары тик ымлык һәм ияртем сүзләрдә генә очраган һәм асылда фонематик аваз булмаган. Увуляр *ғ* һәм *г*, шулай ук *ф, х, һ, хәмзә* авазларын аерым аваз итеп тану һәм фонемалаштыру борынгы ирани (согдий, фарсы) телләрдән күп санлы сүзләр алу процессында барлыкка килгән.

Авазларны куллану сингармонизм закончалыклары нигезендә башкарылган: рәт гармониясе саклану; сузыклар янында тартыкларның сыйфат ягыннан беркадәр үзгәреш кичерүләре; иренләшү гармониясе күзәтелү; сузык авазларның беренче, икен-

че һәм өченче (һәм аннан соң килгән) иҗекләрдә төрлечә кулланылышы (беренче иҗектә барча сузыклар файдаланылса, икенче иҗектә шуларның өч пары гына кала (*э, ә, ө; ы, а, о*), өченче һәм аннан соң килгән иҗекләрдә *э, ә* һәм *ы, а* авазлары гына куллаyыла. Шуңа күрә дә татар теле кушымчаларында тик *э, ә* һәм *ы, а* авазлары гына очрый).

Татар консонантизмы законнарын белү дә этимологиядә мәҗбүри шарт. Тартыкларның борынгыдан килгән кыпчак телендәге кулланылыш закончалыклары түбәндәгеләр:

1) сүз башында ике тартык бергә килми;

2) сүз башында *л* һәм *р* авазлары кулланылмый;

3) иҗек азагында *б, ғ, г, ж, җ* һәм *д* авазлары килми;

4) саңгырау авазлардан соң яңгырау тартыклар (кайбер сонорлардан кала) килми;

Тартыкларның үзара бәйләнеп бергә килүендә дә аерым закончалыклар булган һәм бар. Төрки-татар телендә тартык аваз бергәлекләрен (тезмәләрен) түбәндәгечә күрсәтергә була:

йw, йй, йл, йм, йн, йр, йб, йг, йг, йк, йк, йд, йт, йч, йт, йз, йс
лw, лл, лм, лн, лб, лп, лз, лг, лк, лк, лд, лт, лҗ, лч, лш, лс
рл, рм, рн, рб, рп, рг, рг, рк, рк, рд, рт, рҗ, рч, рш, рс
мл, мм, мн, мр, мб, мп, мг, мч, мк, мк, мд, мт,
мч, мш, мс
ww, wл, wм, wн, wр, wз, wг, wк, wк, wд, wґ, wш, wс
пл, пм, пн, пр, пк, пк, пт, пч, пш, пс
кл, км, кн, кр, кт, кч, кш, кс (к дә шулай да)
тл, тм, тн, тр, тк, тк, тч, тш, тс
чл, чм, чн, чр, чк, чк, чч, чс
шл, шм, шн, шр, шм, шк, шч, шс
зл, зм, зн, зр, зз, зг, зд, зч, зс
сл, см, сн, ср, ск, ск, ст, сч, сс
ңл, ңм, ңм, ңг, нг, нк, нд, ңт, нч, ңш, ңс
җл, җм, җн, җр, җг, җд, җч
хл, хм, хн, хр, хт
фл, фм, фн, фр, фч

Болардан тыш, сүзләр кыскару процессында яңарак килеп чыккан *бр, пр, гр, др, тр* аваз тезмәләре һ.б. очрый.

Сонор тартыклардан *й, л, м, р* барлык башка тартыклар белән янәшә килә ала.

*б* һәм *п* авазлары парлы тартыклардан соң килми; парлы тартыкларның бер-берсенә ияру мөмкинлеге, гомумән, чикләнгән.

Иҗек төзелешенә бәйле дә үзенчәлекләр бар. Татар теленең үз сүзләрендә җиде иҗек калыбы бар (Т – тартык, С – сузык аваз): С, СТ, СТТ, ТС, ТСТ, ТСТТ һәм иярtемнәрдә генә ТТСТ (мәсәлән, *прых*). Шуларның да СТТ һәм ТСТТ калыплары иҗек азагында *т* яисә, сирәгрәк, *п* авазы килгәндә генә очрый: *-йт (әйт, кайт), -лт (гөлт, кылт, чалт), -нт (ант, кәнт), -рт (арт, карт, урт), ст (аст, өст), жт (выжт), -шт (кышт, пышт), -мп (гөмп, чумп)*.

Татар теленең үз сүзләрендә сүз басымы һәрвакыт соңгы иҗеккә төшә. Бу кагыйдәдән чыгарылмалар барлыгы, аларның төп үзенчәлекләре хәзерге татар теленең фонетикасы буенча эшләнгән хезмәтләрдә тәфсилләп бирелә, биредә аларга тукталып тормыйбыз.

Регуляр кушымчаларда татар телендә *л, м, н, р, з, г, , к, т, д, с, ч, ш* авазлары кулланыла. *Б, ж, җ, ф, х* авазлары исә кушымчаларда очрамый.

*П* авазы борынгы фигыль кушымчасы составында очрый (мәсәлән, *җилпе-, салпы, талпы-н-* һ.б.).

*З* авазы кушымчаларда бары тик иҗек азагында гына очрый.

Алынмаларны фонетик билгеләр буенча тану өчен, югарыда телгә алынган үзенчәлекләрне истә тоту кирәк. Әгәр нинди дә булса сүз нигезе югарыда саналган үзенчәлекләргә туры килми икән, аны алынма буларак карау мөмкинлеге бар.

Гадәттә, алынма сүздә берничә алынмалык билгесе була, мәсәлән, *абзар* сүзендә төрки-татар телендә күзәтелми торган *-бз-* аваз тезмәсе һәм иҗек азагында *б* авазы очрый; *катгый* сүзенең алынма икәненә сүз уртасындагы *-тг-* аваз тезмәсе ишарәли; *алебастр* сүзенең алынма икәнлеген күрсәтә торган үзенчәлекләр булып сингармонизм законы сакланмау һәм сүз азагында өч тартык бергә килү тора. Сүзлекләрдә әлеге сүзнең килеп чыгышы болай билгеләнә: русча *алебастр*, немецча *Alabaster* < латинча *alabastros*, грекча *alabastros* < борынгы Мисыр телендә *ala baste* «*Эбастә* дигән алиһә мае» – алдан җәрәхәтләргә ябыла торган шифалы балчыкны белдергән (Фасмер II: 71, Kluge: 27). *Игълан* сүзен карасак, аның алынма икәненә ишарә итә торган төп билге – сингармонизм законы сакланмау һәм иҗек азагында *г* авазы килү.

Сүзнең алынма булуын, хәтта конкрет кайсы телдән икәнлеген дә яңгырашыннан белеп була. Бу аеруча телебезгә соңрак чорлар-

да үтеп кергән алынмаларда шактый җиңел ачыклана, борынгырак алынмалар исә фонетик яктан үзләштерелгән һәм алар татар теленең закончалыкларына буйсындырылганнар.

Татар телендә фонетик яктан рус теленнән һәм рус теле аша Европа телләреннән алынган сүзләр аерылып тора. Аларның төп билгеләре[1]:

1. Басым соңгы иҗектә түгел: а́рмия, архите́ктор, бухга́лтер, гала́ктика, тра́ктор һ.б.

2. Авазлар составында татар теленә хас булмаган озын *ō* авазы һәм киң әйтелешле э очрый: *орган, район; эра, этап, нетто*. Шулай ук тартыклардан татар телендәге *г, к* авазларыннан сыйфатлары белән үзгә *г, к*: *газ, магазин; кило*, *тактика*; аффрикат *ц*: *центнер, милиция* һ.б. авазлар кулланыла.

3. Сингармонизм законы сакланмый.

4. Сүз (һәм иҗек) башында һәм азагында төрле сыйфаттагы ике һәм өч тартык бергә килә ала (мәсәлән, *скрипка, трест, фронт, курс, оркестр*).

5. Тартыкларның төп татар телендә булмаган тезмәләре очрый (мәсәлән, *лз: гильза, рз: бурзай* < *борзая; дж:* (*джоуль, джин, бридж* һ.б.); сүз башында *р* тартыгы килә ала (мәсәлән, *рам, рәт, руда* һ.б.); *ж* авазы еш очрый (*дож, ложа, паж* һ.б.) һ.б.

6. Нечкәлек билгесе (*ь*) кыска *й* кебек укылган бер төркем сүзләр (*батальон, каньон, лосьон* һ.б.) кулланылу.

7. Алынма сүзләрнең бер төркемендә каты *л* һәм йомшак *л'* фонемалары исем һәм сыйфатны аерып тора: *вокал – вокаль, генерал – генераль, дифференциал – дифференциаль, интеграл – интеграль, капитал – капиталь, маргинал – маргиналь, магистрал – магистраль, оригинал – оригиналь, радикал – радикаль, театрал – театраль* һ.б.

Йомшак *л'*гә беткән парсыз исемнәр тагын да күбрәк: *аномаль, бактериаль, вербаль, визуаль, виртуаль, гениаль, горизонталь, диаметраль, диагональ, зональ, иррациональ, колониаль,*

---

[1] Бу төр аермалы билгеләр хәзерге татар теле лексикологиясе буенча дәреслекләрдә, теге яки бу төр алынма лексиканы махсус өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдә тәфсилләп бирелә, без, барлык билгеләрне дә тулысынча күрсәтүне максат итеп куймыйча, кайбер киң таралганнарына, этимологик анализ өчен күзаллау җирлеге тудыра торганнарына гына тукталабыз.

*континенталь, клерикаль, меридиональ, номиналь, нормаль, радиаль, сентименталь, социаль, термаль, территориаль, уникаль, формаль, федераль* һ.б. Бу сүзләр рус телендәге сыйфатлардагы *-ный* аффиксының төшеп калуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Татар телендәге г а р ә п  а л ы н м а л а р ы н ы ң  кайбер билгеләрен карап үтик:

1. Кайбер сүзләрдә басым соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин: *әлбә́ттә, го́мумән, лә́кин* һ.б.

2. Аерым очракларда сингармонизм законы сакланмый: *исраф* (*и – а* чылбыры); *икътисад* (*и – и – а* чылбыры) һ.б.

3. Тартыкларның төрки-татар телендә булмаган тезмәләре очрый, мәсәлән: *-гз-: әгъза, -гн-: мәгънә, -гҗ-: могҗиза, сх: мәсхәрә,* ике *р* бергә килү: *кәррә* һ.б.

4. Төрки-татар телендә булмаган *ф, х, һ, хәмзә* авазлары кулланыла: *фетнә, халык, һөҗүм, тәэсир* һ.б.

Ф а р с ы  а л ы н м а л а р ы н ы ң  кайбер фонетик билгеләре:

1. Аерым очракларда сингармонизм законы сакланмау: *дивана, кәрван* һ.б.

2. Сүзләрдә *ф, х*, *һ* (*әфәрин, тәхет, һәр, һич*), сүз башында *р-: рас, раушан* һ.б. очрый.

3. Тартыкларның татар теленә хас булмаган тезмәләре: *-др-*: *гөлбадран* һ.б.; ике *р* бергә килү: *дәррәү* һ.б.

Биредә күрсәтелгән фонетик билгеләрнең күпчелеге гомуми ориентир булып кына хезмәт итә, югарыда билгеләнгәнчә, алынмаларны өйрәнү буенча язылган махсус хезмәтләрдә аларның башка төрләре дә күрсәтелгән. Бу үзенчәлекләрдән тыш, чыганакларны сүзлекләр буенча тикшереп чыгу мөһим.

Татар телендәге гарәп һәм рус, Европа алынмаларының бик ачык м о р ф о л о г и к  б и л г е л ә р е  дә бар. Фарсы һәм монгол алынмаларында бу билгеләр күзгә ташланып тормый.

Рус теленнән кергән сүзләрдә сүз ясагыч кушымча һәм «окончание»ләр, башлыча, исемнәрдә саклана: *-ка* (*линейка, клиника, юбка*), *-ник* (*мошенник, начальник, парник*), *-щик* (*натурщик*). Ләкин бу тип сүзләрнең саны күп түгел. Ә менә Европа телләреннән кергән сүзләрдәге *-изм, -ист, -ия, -ция, -ика* кушымчаларының һәркайсына йөзләрчә алынма мисал китерергә мөмкин: *анимизм, плюрализм; артист, дантист; авария, авиация, модификация, модуляция; техника, физика* һ.б.; *-ер, -нер, -ор, -тор* кушымчалы ак-

тив шәхес (орган, деталь) мәгънәсен белдергән сүзләр дә шактый: *актёр, легионер, планёр, револьвер, механизатор* һ.б. -*аль* аффиксына бәйле үзенчәлекне югарыда билгеләп үттек.

Гарәп алынмаларына *тә-, мә-, ма-, мо-* префикслары [*тәгълим* (чаг. *гыйлем*); *тәэсир* (чаг. *әсәр*); *мәктәп* (чаг. *китап, китапханә*); *мәрхәмәт* (чаг. *рәхмәт*); *могҗиза* (чаг. *гаҗиз*)], *-ия, -ият, -ат/әт* постфикслары [*гадлия* «юстиция» (чаг. *гадел*), *әдәбият* (чаг. *әдәп*); *хөррият* (чаг. *хөр*); *хайванат* (чаг. *хайван*)], сыйфат ясагыч -*и*//-*ый* кушымчасы: *гамәли* (чаг. *гамәл*); *гомуми* (чаг. *гомум*); *фәнни* (чаг. *фән*) характерлы.

Гарәп сүзләренә шулай ук бер үк сүзнең мөзәккәр (мужской род) һәм мөәннәс (женский род) формалары булу (*гали – галия, галим – галимә, гашикъ – гашика* һ.б.), -*ан*/-*ән* рәвеш ясагыч кушымчасы (*шәхсән*, чаг. *шәхес, шәхси*; *горуран*, чаг. *горур*) характерлы.

Редупликатив нигезләрнең -*а*/-*ә* кушымчасы белән ясалуы да гарәп теле үзенчәлеге булып тора, мәсәлән, *вәсвәсә, зилзилә, силсилә* һ.б.

Монгол алынмаларының морфологик билгеләре булып сыйфат ясагыч *-гай//-гәй, -агай//-әгәй* (*болагай* ‘шапшак’, *комагай* ‘нәфесле, комсыз’, *карагай* ‘нарат’), *-дар//-дәр, -тар//-тәр* (*каудар* ‘кипкән үлән’), исем ясагыч -*сын*//-*сен*(*кавырсын* ‘эре каурый’, *селәүсен* ‘урман мәчесе, рус. рысь’) аффикслары хезмәт итә. Шуны искәртү зарур: монгол алынмаларының күпчелеге махсус тарихи лингвистик тикшеренү нәтиҗәсендә генә беленә.

Фарсы теленнән кергән сүзләрнең морфологик билгеләре катлаулы. Шуны әйтергә кирәк: кайбер фарсы кушымчалары татар теленә үзгәрешсез диярлек кергән. Мәсәлән, -*анә*//-*әнә* (*мәгъруранә* ‘горурланып’, *галибанә* ‘җиңеп, җиңү белән’), *-зар//-зәр > -сар//-сәр* (*гөлзар* ‘гөлләр бакчасы’, *имәнсәр, каенсар* һ.б.), -*ханә* (*китапханә, чәйханә*), -*намә* (*васыятьнамә, рөхсәтнамә*) һ.б.

Алынма сүзләр м ә г ъ н ә в и - с е м а н т и к б и л г е л ә р е һәм т е м а т и к т ө р к е м н ә р е белән дә аерылып торалар.

Борынгы төркиләр иң беренче чиратта ике мәдәни даирә – көньяк-көнчыгышта Кытай, көнбатышта ирани халыклар арасында яшәгәннәр. Көнчыгыш Азия белән Урта Азия һәм Иран арасында сәүдә эше (Бөек ефәк юлы) булган; яңа эра башларында бу сәүдәгә төркиләр кушылып, согдийлар белән аралашып, катнашып киткәннәр һәм V гасырга соңгылары үзләре төркиләшә башлаган. Шул

чорда төрки телләргә ирани телләрдән бик күп сүзләр кергән һәм калькалар ясалган. Шушы факттан чыгып, төрки телләрдә сәүдә өлкәсенә (товар атамалары, үлчәү-бәяләү терминнары һ.б.) караган күп кенә сүзләр согдий теленнән дип фаразлана. Согдий теленең үзендә борынгы (исламны кабул иткәнче формалашкан) фарсы һәм һинд телләреннән алынмалар бик күп булган. Алар да соңрак төрки телләргә күчкәннәр.

Бөек ефәк юлындагы сәүдә әйберләренең төп җитештерүчесе – борынгы Кытай теленнән дә күп сүзләр алынуы табигый. Иң беренче чиратта товар, әйбер атамалары кытайчадан булырга тиеш. Аннары кытайлардан төркиләргә мәдәни казанышларның атамалары да кергән. Музыкага караган кайбер сүзләрнең (*көй, кубыз, чәһ* һ.б.) кытай теленнән булуы шуның белән аңлатыла.

Идарә һәм суд эшләре терминологиясендә дә кытай теле тәэсире сизелә. Ләкин бу өлкәләрдә төркиләргә бигрәк тә ирани халыклар үрнәк булган.

Монголлар белән төркиләр озак гасырлар буена бик тыгыз бәйләнешләрдә яшиләр. Нәтиҗәдә монгол һәм төрки телләр арасында сүзләр алмашу шактый актив барган. Хәзерге тел белемендә күп кенә уртак сүзләрнең кайсы телдә беренчел икәне ачык түгел.

Гарәп теленнән, иң беренче чиратта,дини терминология үтеп кергән. Ислам дине белән бәйле сүзләр белән берррәттән, тормышның төрле өлкәләренә караган лексика да күпләп кергән, мәсәлән: 1) гомуммәдәни терминнар, 2) шигырь теориясе, әдәбият терминнары, 3) мораль, әхлак төшенчәләренең атамалары, 4) хокук, дәүләтчелек терминологиясе, 5) матди мәдәният (хуҗалык-икътисад) терминнары һ.б.

VIII–XI гасырларда гарәп мәдәнияте үрнәкләре, фәне, сәнгате һәм әдәбияты гаять киң таралыш ала. Шул нигездә һәм гарәпләрнең иҗтимагый-сәяси роле тәэсирендә күп кенә гарәп сүзләре Европа телләренә үтеп керә. Хәзерге Европа лексикасындагы *агат, адмирал, алгебра, алгоритм, алкоголь, альманах, алюминий, амальгама, анемона, анилин, арабеска, арсенал, атлас* (тукыма), *алзур* (лазурь), *балдахин, бальзам, гитара, фанфара* (гарәпчә *фарфара*), *гамаши, газ* (тукыма исеме), *жираф, карат, коттон* (тукыма исеме), *магазин, маскарад* (шуннан – *маска*, киресенчә түгел), *мохер* (кәҗә мамыгы), *мокко* (кофе төре), *муссон, оранжерея, ракета* (челтәрле чәпәмә), *сандалия, сатин, сода, софа, та-*

*лисман, тамбур, түн* (русча *тунец* [балык төре]), *цифра* (цифр) һ.б. шундыйлардан. Бу рәт экзотизмнар белән дә тулылана.

Шуны әйтергә кирәк ки, гарәп сүзләренең шактый өлеше төп семит тамырларыннан түгел, алар алынма саналалар. Гарәпләр үзләре борынгы Мисыр, бабиллылар, фарсы, грек, римле, төрек халыклары телләреннән күп кенә сүзләр алганнар. Әлеге алынмалар, үз чиратында гарәп җирлегендә үзләштерү үтеп, татар теленә кергәннәр. Мәсәлән, *ризык* (борынгы фарсы теленнән), *фәлсәфә* (грек теленнән), *кыйсса, сират* ‘күпер’ (латин теленнән), *бөреҗ* ‘бастион, кирмән’(герман телләреннән) сүзләре шундыйлардан.

Фарсы алынмаларының аерып күрсәтерлек семантик-тарихи билгеләре юк: алар һәртөрле тематик төркемдә табылалар. Моның хикмәте шунда: ирани халыклар белән төркиләр кимендә ике мең ел тыгыз аралашып яшиләр. Безнең эраның беренче меңьеллыгында төркиләр күчмә скиф-сармат кабиләләрен (ә алар ирани телләрдә сөйләшкәннәр) төркиләштерәләр. Икенче яктан, бик күп төркиләр үзләре фарсылаша һәм еш кына кабаттан төркиләшә. Шул ук вакытта фарсы рухы һәм матди мәдәнияте төркиләр өчен үрнәк булып торган. Бу контактлар нәтиҗәсендә төрки-фарсы телләр союзы барлыкка килгән дип әйтеп була: төрки һәм яңа ирани телләр арасында лексик кына түгел, морфологик охшашлыклар һәм өлешчә уртак лексика пәйда булган.

Алынмалар татар теленең төрле диалектларында, сөйләшләрендә төрлечә кулланылу ягыннан да аерылып торалар, мәсәлән, фин-угор алынмалары Татарстанның төньяк районнарында, рус теленнән кергән сүзләр – мишәр диалекты сөйләшләрендә, Урта Азия халыклары телләреннән алынмалар көнчыгыш диалект сөйләшләрендә актив.

Шулай итеп, этимологик тикшеренүләрдә тел үсешенең төрле аспектларын комплекслы күзаллау сорала. Телнең лексик составында кулланылган лексик берәмлекләрнең фонетик, грамматик үзенчәлекләре, башка кардәш һәм кардәш булмаган телләр белән бәйләнеш мөмкинлеге һәрьяклап өйрәнелергә тиеш.

## ЙОМГАК

Әлеге хезмәт тел гыйлеменең гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм күпкырлы өлкәсе булган лексикология буенча әзерләнде. Телне өйрәнү беренче чиратта сүздән башлана.Сүзнең табигате, аның кулланылыш мөмкинлеге һәм даирәсе, яшәеше, мәгънә тирәнлеге аша без халыкның мәдәни-рухи мирасын барлыйбыз, милләтнең үсеш кыйбласын, башка халык, дәүләтләр белән бәйләнышын ачыклыйбыз. Җәмгыять үсеше дәвамында сүзләрнең мәгънәләрендә халыкның көнкүреш йола, гадәтләре сакланып кала, милли яшәеш үзенчәлекләрен алдагы буыннарга җиткерү вазифасын да сүз башкара. Шул сәбәпле телнең сүзлек байлыгын тирәнтен өйрәнү милләтнең үткән тарихын, рухи кыйммәтләрен ачыклауга да ярдәм итә.

Т а т а р  л е к с и к о л о г и я с е дип аталган һәм өчтомлык әлеге хезмәтнең беренче томында сүз һәм тотрыклы әйтелмәләрнең мәгънәсе, семантик үзенчәлекләре һәм килеп чыгышы мәсьәләләре каралды.

Беренче томның беренче бүлегендә сүзнең мәгънәсе, мәгънә үсеш-үзгәреше, татар теленең лексик-семантик системасындагы бәйләнешләр, телдәге вертикаль (парадигматик) һәм горизонталь (синтагматик) мөнәсәбәтләр, аларның үзенчәлекләре бирелде.

Сүзләр семантик табигатьләренә бәйле рәвештә төрле функция башкаралар һәм иерархик система ята һәм системаның үзәгендә мөстәкыйль мәгънәле сүзләр тәшкил итә, ә башка сүз төркемнәре периферияcенә керәләр, үз чиратында аларны якын (алмашлык сүзләр) һәм ерак (ярдәмче сүзләр, модаль сүзләр һәм ымлыклар) перифериялэргә аералар. Сүзнең семантик табигате – катлаулы күренеш, аның эчтәлегендә денотатив һәм сигнификатив мәгънә компонентлары табыла, сөйләм агышында исә сүзләр коннотатив эчтәлеккә дә ия булалар. Аларның бергә кулланылышы сүзнең

эчке табигатен, формасын барлыкка китерә һәм сөйләм эчендә төрле семантик вариантлылыкка юл ача. Лексик мәгънә сөйләм эчендә ачыла ала торган барлык төр компонентларны да берләштерә, шулар ярдәмендә чынбарлык күренешләрен атап кына калмый, бәлки төгәл бәя дә бирә.

Сүзнең мәгънәсе үзара тыгыз бәйләнгән, бер-берсен тулыландыра торган буыннардан торган иерархик төзек сема структурасыннан гыйбарәт. Әлеге семалар сүз мәгънәсенең киңәюен, күчүен барлыкка китерүдә төп рольне башкара. Күчерелмә мәгънә хасил булган вакытта, архисема һәм дифференциаль семалар үз әһәмиятләрен беркадәр югалтса, потенциаль семалар исә, киресенчә, дифференциаль сема вазифасын үти башлыйлар.

Әлеге бүлектә лексик мәгънә типлары аерылып, аларга җентекле анализ ясалды. Шулай ук сүзара парадигматик һәм синтагматик мөнәсәбәтләр, аларның төрләре һәм төп үзенчәлекләре тасвирланды.

Татар теле лексикасында күпмәгънәлелек күренешенең асылы, халыкның дөньяны кабул итү нәтиҗәсендә сүзнең лексик мәгънәсе киңәю юллары, күчерелмә мәгънәнең төрләре буларак метафора, метонимия һәм аның бер төре булган синекдоха күренешләре, сөйләм агышында сүзнең күчерелмә мәгънәләре ясалу турында шактый җентекле мәгълүмат бирелде. Шулай ук тел белемендә фикер төрлелегенә уяткан паронимия күренешен махсус яктыртуга да игътибар юнәлтелеп, аларны аеру юллары, барлыкка килү сәбәпләре һәм башка әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелде.

Хезмәтнең икенче бүлеге татар фразеологиясен комплекслы өйрәнүгә багышлана. Татар теле фразеологиясе, лексика кебек үк, төзек бер система тәшкил итә. Аңа автономиялелек хас, чөнки фразеологизмнар бер яктан – сүзләрдән, икенче яктан ирекле сүзтезмәләрдән һәм җөмләләрдән аерылалар, шул ук вакытта катлаулы гомумхалык теле системасына да керәләр. Фразеологиянең өйрәнү объекты булып күчерелмә мәгънәле, семантик яктан бөтен, составы һәм структурасы ягыннан тотрыклы, аралашканда әзер килеш кулланыла торган, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык кебек сыйфатлар хас берәмлекләр тора. Бу берәмлекләр сүзтезмә яки җөмлә формалы булып, билгеле структур-морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләр белән сыйфатлана.

Фразеологик система телнең башка тармаклары белән бәйләнештә өйрәнелә һәм үз эчендә билгеле категориаль билгеләр

(парадигмалар) белән характерлана. Татар теленең фразеологик әйтелмәләре бер-берсеннән тарихи-генетик билгеләре, лексик составлары, компонентларның мәгънәви-грамматик кушылу дәрәҗәсе, тематикалары буенча, стилистик функцияләре һәм бизәлеше ягыннан, лексик-грамматик мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре буенча аерымланалар. Шулай ук фразеологик әйтелмәләр, сүзләр кебек, бер һәм күп мәгънәле булалар, бер-берсенә карата синонимик, антонимик һәм омонимик мөнәсәбәтләрдә торалар. Фразеологизмнарның синонимик вариантлары барлыкка килү – татар фразеологиясен баетуның иң продуктив юлларының берсе.

Татар теленең фразеологик хәзинәсе (гомумән, татар теле кебек үк) бертуктаусыз үсештә һәм үзгәрештә. Бу, беренчедән, телнең сүзлек составы үзгәрүе белән бәйле, ә икенчедән, яңа метафорик образлар тууыннан да тора. Фразеологизмнарның хасил булуы, үсеше халыкның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәте, ышанулары, яшәү шартлары, рухи омтылышы, чынбарлыкка мөнәсәбәте, эстетик идеалы белән тыгыз бәйләнгән. Фразеологизмнарның лексик составы, лексик-грамматик үзенчәлекләре, компонентларның бәйләнеш характеры тел тарихы фәне өчен алыштыргысыз бай һәм кыйммәтле материал булып тора.

Фразеологик әйтелмәләр телнең эмоциональ көчен, эстетик тәэсир итү мөмкинлеген арттыра, алар – фикернең үткенлегенә, сөйләмнең кыскалыгына ирешүдә әһәмиятле стиль чарасы да. Бу төр берәмлекләр шулай ук әдәби, сәяси, публицистик әсәрләрнең идеясе, мәгънәсе, тәэсире көчәюгә хезмәт итә.

Китапның өченче бүлеге сүзнең килеп чыгышы, беренчел мәгънәләрне барлауга йөз тоткан этимология тармагына багышланды. Биредә татар тел белемендә этимология тармагы формалашу һәм үсүгә кагылышлы мәгълүмат, лексикологиягә караган хезмәтләрдә моңарчы беркадәр игътибар үзәгеннән читтәрәк калып килгән этимологик тикшеренү ысуллары, сүзнең состав өлешләре булган тамыр, нигез һәм кушымчалар этимологиясенә махсус анализ ясалды, төрки-татар һәм алынма лексиканың аермалы билгеләре күрсәтелде.

Шулай итеп, әлеге хезмәттә тел белеме казанышлары һәм татар тел белеме фәне үсешендә ирешелгән нәтиҗәләр гомумиләштерелеп, телнең төп лексик берәмлекләре булган сүз һәм тотрыклы әйтелмәләрнең семантикасы һәм килеп чыгышы комплекслы тасвирлана.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

## *Татар телендә*

*Абдуллина Р.С.* Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

*Абдуллина Р.С.* Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Монография. – Яр Чаллы: КамАЗ, 1997.

*Ахунҗанов Г.Х.* Татар теленең идиомалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

*Әүхәдиев И.Ш.* Гарәп алынмаларының фонетик үзләштерелүе турында // Татар тел белеме мәсьәләләре. – Өченче китап. – Казан, 1969. – 112–131 б.

*Әхәтов Г.Х.* Татар телендә антонимнар // Совет мәктәбе. – 1977. – № 2. –38–39 б.

*Әхәтов Г.Х.* Татар телендә полисемантик сүзләр. – Уфа, 1977.

*Әхәтов Г.Х.* Татар телендә фразеологик әйтелмәләр: Филология фәннәре кандидаты … дис. – Казан: КДУ нәшр., 1954.

*Әхәтов Г.Х.* Хәзерге татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Әхәтов Г.Х.* Татар теленең лексикасы: педагогия институты һәм колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Әхәтов Г.Х.* Хәзерге татар теленең лексикологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

*Әхәтов Г.Х., Закиров Р.* Татар телендә оксюмороннар // Совет мәктәбе. – 1980. – № 11. – 20–22 б.

*Әхтәмов М.Х.* Хәзерге башкорт теле. Лексикология, фразеология, лексикография. – Өфө: Башкорт дәүләт университеты, 2002.

*Бадыйков К.* Фразеологизмнар ясалышы // Мәгариф. – 1991. – № 112. – 23–4 б.

*Бактиков М.* Төрлечә мәгънә аңлаткан бер үк сүзләр төркеме // Мәгариф. – 1931. – № 7–8. – 64–65 б.

*Баязитова Ф.С.* Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. – Казан: Дом печати, 2007.

*Баязитова Ф.С.* Әлмәт төбәге татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан: Мәгариф, 2001.

*Баязитова Ф.С.* Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан: Фикер, 2002.

*Баязитова Ф.С.* Гомернең өч туе. Татар халкының гаилә йолалары. – Казань: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан, 1997.

*Баязитова Ф.С.* Нократ сөйләше. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан: Дом печати, 2006.

*Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы (йола һәм мифология текстлары яссылыгында). – Казан: Алма-Лит, 2010.

*Баязитова Ф.С.* Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан: Фикер, 2001.

*Баязитова Ф.С.* Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Саранск, 2003.

*Баязитова Ф.С.* Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Баязитова Ф.С.* Туй йолалары лексикасы. (Җирле сөйләш һәм фольклор текстлары яссылыгында). – Казан: Паравитта, 2011.

*Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Казан: Фикер, 2002.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бирнә һәм кием-салымнар. – Казан: Алма-Лит, 2009.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). – Казан: Алма-Лит, 2012.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: соңгы туй (дини фольклор һәм җирле сөйләш текстлары яссылыгында). – Казан, 2015.

*Бәширова И.Б.* Сүз белән сурәт ясау. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. – Казан, 2010.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. – Казан: Алма-Лит, 2006.

*Вәлиуллина З.М.* Хәзерге татар әдәби теле. – Казан, 1965.

*Галиуллина Г.Р.* Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә. – Казан: Мәгариф, 2007.

*Галиуллина Г.Р.* Хәзерге татар теле лексикологиясе: уку кулланмасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2013.

*Ганиев Ф.Ә.* Сүзьясалыш // Татар грамматикасы. – Т. I. – Мәскәү: ИНСАН, Казан: Фикер,1998. – 201–464 б.

*Ганиев Ф.Ә.* Сүзьясалышның лексик-семантик ысулы // Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалыш. – Казан: Мәгариф, 2009.

*Ганиев Ф.Ә.* Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалыш. Төзәт. 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Ганиев Ф.Ә.* Хәзерге татар теленең лексик системасы үсеш юллары // Татар грамматикасы: Өч томда. – Т. I. – Мәскәү: ИНСАН, Казан: Фикер, 1998.

*Гарипова Ф.Г.* Авыллар һәм калалар тарихыннан (Из истории сёл и городов). – Т. I. – Казань, 2001.

*Гарипова Ф.Г.* Авыллар һәм калалар тарихыннан (Из истории сёл и городов). – Т. II. – Казань, 2003.

*Гарипова Ф.Г.* Авыл – милләтебезнең җаны. – Казан: Идел-Пресс, 2011.

*Гарипова Ф.Г.* Исемнәрдә – ил тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

*Гарипова Ф.Г.* Рухи башкалабыз: мәшһүр татар авыллары. – Казан: Мәгариф, 2005.

*Гарипова Ф.Г.* Татар топонимиясе: халкыбызның тарихи һәм рухи мирасы. – Казан: Идел-Пресс, 2011.

*Гобәев Р.* Телдәге лексик-грамматик омонимнар // Совет мәктәбе. – 1981. – № 10. – 21–23 б.

*Гобәев Р.* Фразеологик омонимнар // Мәгариф. – 1997. – № 7. – 18–20 б.

*Гобәев Р.* Татар телендә омофоннарның ясалыш үзенчәлекләре // Совет мәктәбе. – 1978. – № 3. – 39–40 б.

*Гобәев Р.* Телебездә омографлар // Совет мәктәбе. – 1985. – № 7. – 22–24 б.

*Гобәев Р.* Телебездә омоформалар // Совет мәктәбе. – 1983. – № 10. – 22 б. (№ 11. – 23 б.).

*Гыйззәтуллин И.* Канатлы сүзләр // Мәгариф. – 2000. – № 1. – 29–32 б.

*Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. – Казан: Татгосиздат, 1947.

*Җәләй Л., Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т.* Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре.– Казан, 1957.

*Закирова Р.М.* Татар телендә антонимнар // Фән һәм мәктәп. – Яр Чаллы, 1999. – № 9–10. – 83–84 б.

*Закирова Р.М.* Хәзерге тел белемендә антонимнарны өйрәнү // Фән һәм мәктәп. – Яр Чаллы, 2000. –№ 1–2. – 131–133 б.

*Зәкиев М.З.* Туган тел үсеше. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы теленең барлыкка килүе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

*Зәкиев М.* Сүзлек составында терминнар һәм аларны тәртипкә китерү // Мәгариф. – 1997. – № 4. – Б. 32–35.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. – Казан–Мәскәү, 1998.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы тарихы (этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге). – Казан, 2008.

*Зәкиев М.З., Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002.

*Зөлкарнәй Ф.* Заманча иҗтимагый-мәдәни мәгънәләр сүзлеге // Идел. – 1996. – № 5. – 41–57 б.

*Ибраһимов С.М.* Синтаксик стилистика. – Казан: КДУ нәшр., 1989.

*Ибраһимов С.М.* Татар телендә синтаксик синонимнар һәм омонимнар // Вопросы тюркологии. – Казань: КГПИ, 1970. – 207–218 б.

*Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С.* Практик стилистика. Күнегүләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән хәзергенең чагылышы // Фән һәм тел. – 2001. – № 4. – 35–38 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Т. 2. –Казан: Татар. кит. нәшр.,1962.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Т. 3. –Казан: Татар. кит. нәшр.,1967.

*Кәримуллин Ә.* Татарлар: исемебез һәм җисемебез. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

*Кәримуллин Ә.* Татар тел белеме библиографиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

*Курбатов Х.Р.* Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962.

*Курбатов Х.* Татар телендә грамматик омонимнар // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан, 1959. – 86–94 б.

*Курбатов Х.Р.* Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002.

*Мәхмүтов М.И.* Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы элементлары // Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – II том. – Казан, 1993.

*Мәхмүтов Х.* Канатлы сүз – хикмәтле сүз. – Казан, 1999.

*Миннуллин К., Валиуллин Р.* Татар теле – сүзлекләрдә. Библиографик күрсәткеч. – Казан, 1998.

*Мостафина Ф.* Лексик кабатлаулар ярдәмендә төзелгән синтаксик фразеологизмнар // Фән һәм мәктәп. – 1999. – № 5–6. – 144–147 б.

*Мостафина Ф.* Лексик һәм синтаксик фразеологизмнар арасында мөнәсәбәт // Фән һәм мәктәп. – 2000. – № 3. – 96–98.

*Мостафина Ф.* Лексик һәм синтаксик фразеологизмнар арасында мөнәсәбәт // Фән һәм мәктәп. – 2000. – № 4. – 91–94 б.

*Мөхәммәдиев М.Г.* Татар проза телен үстерүдә фразеологиянең роле (XIX йөз ахыры –XX йөз башы) // Проблемы лексикологии и терминологии татарского языка. – Вып. 1. – Казань, 1993. – С. 101–116.

*Мөхәммәдиев М.Г.* Шәриф Камал әсәрләрендә фразеологик синонимнар һәм антонимнар // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 178–185 б.

*Мөхиярова Р.Х.* XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәби теле лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.

*Мөхиярова Р.* Көндәлек матбугат теленә бер караш // Мәгариф.– 1996. – № 2. – 17–18 б.

*Насыйри К.* Әнмүзәҗ. – Казан, 1975.

*Низамов И.М.* Матбугатның тәэсирле сүзе: Газета лексикасы мәсьәләләре. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1981.

*Низамов И.М.* Яңалык һәм сүз. – Казан: Тат. ГЗК нәшр., 1990.

*Низамов И.М.* Уем – тел очында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

*Низамов И.М.* И туган тел... – Казан: Мәгариф, 1998.

*Ногман М.* XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульъязма сүзлекләр. – Казан: КДУ нәшр., 1969.

*Нуриева А.Х.* Татар теле тарихыннан материаллар. – Казан: КДУ нәшр., 1975.

*Поварисов С.Ш.* Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.

*Поварисов С.Ш.* Тел – күңелнең көзгесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.

*Поварисов С.Ш.* Сүз эчендә энҗе бар // Мәгариф. – 1992. – № 12. – 24–25 б.

*Рамазанов Ш.А.* Татар әдәби теле терминологиясенең үсеш юнәлеше. (Тел экспедициясе материалларыннан) // Мәгариф. – 1935. – № 6. – 22–32 б.

*Рамазанов Ш.А.* Татар әдәби теленең гамәлдәге терминологиясен тәртипкә салу, яңа терминнар эшләп чыгару һәм терминологик сүзлекләр төзү эшендә төп принциплар һәм инструкция. – Казан, 1944.

*Рамазанов Ш.А.* Татар теле буенча очерклар. – Казан: Татгосиздат, 1954.

*Рамазанова Д.Б.* Туйлар, туйлар… –Казан, 1997.

*Рамазанова Д.Б.* Себер татарларының мәдәнияте һәм теле буенча материаллар. – Төмән, 2000.

*Рамазанова Д.Б.* Себер диалектларыннан материаллар. – Казан: Фикер, 2001.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

*Рамазанова Д.Б.* Атамаларда гаилә һәм туганлык мөнәсәбәтләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

*Рәхимова Р.К.* Татар телендә һөнәрчелек лексикасы. – Казан, 1985.

*Сабиров К.* Татар телендә паронимнар // Совет мәктәбе. – 1963. – № 2. – 34–37 б.

*Сабиров К.* Лексикология // Хәзерге татар әдәби теле (Лексика. Фонетика, орфоэпия. Графика һәм орфография. Морфемика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 17–38 б.

*Сабитова И.И.* Татар телендә антоним исемнәрдән ясалган сүзьясалыш ояларының төзелеше // Тенишевские чтения. – Казань: ТГГПУ, 2008. – 221–224 б.

*Сарьян Х.* Уеңны уйдырып сал... – Казан: Татар. кит. нәшр.,1977.

*Саттаров Г.Ф.* Татар теленең антропотопонимнары. – Казан, 1990.

*Саттаров Г.Ф.* Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. – Казан, 1998.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: Раннур,1999.

*Саттаров Г.Ф.* Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

*Саттаров Г.Ф.* Исемең матур, кемнәр куйган. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

*Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998.

*Саттаров Г.Ф.* Синоним, омоним һәм антоним кеше исемнәре // Мәгариф. – 1989. – № 8. – 23 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теленең лексикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

*Сафиуллина Ф.С.* Сүз иясе белән йөри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

*Сафиуллина Ф.С.* Тел дигән дәрья бар.– Казан, 1979.

*Сафиуллина Ф.С.* Тел белеменә кереш. 1 кисәк. – Казан: КДУ нәшр, 1987.

*Сафиуллина Ф.С.* Текст төзелеше / Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1993.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999.

*Сафиуллина Ф.С.* Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. –Казан: ТаРИХ, 2001.

*Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002.

*Сәгъди Г.* Әдәбият теориясе. – Казан, 1941.

*Сәгыйтов Р.* Татар теле синонимиясендә гарәп-фарсы алынмалары // Мәгариф. – 1992.– № 10. – 21–22 б.

*Сәгыйтова А.М.* Татар телендәге агач архитектурасы атамалары белән бәйле фразеологизмнар // Фән һәм тел. – 2002. – № 2. – 31–33 б.

*Сәгыйтова А.М.* Татар фразеологизмнарының күпмәгънәлелеге: (агач архитектурасы лексикасы материалларына нигезләнеп)// Милли мәдәният. – 2002. – № 2. – 98–99 б.

*Сәләхетдинова З.Ф.* Татар прозаигы В. Имамов әсәрләренең лексик үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 2010.

*Сәлимгәрәева Б.С.* Хәзерге татар телендә омонимнар. – Уфа: БДУ нәшр., 1982.

*Сәлимгәрәева Б.С.* Татар телендә лексик омонимнар // Татар теле, әдәбияты укыту методикасы мәсьәләсе. – Уфа: БДУ нәшр., 1971. – 82–85 б.

*Сәлимгәрәева Б.С.* Татар телендә омонимнарның барлыкка килүенә карата // Совет мәктәбе. – 1972. – №5. – 26 б.

Татар грамматикасы. 3 томда. – Т. 2. – М.: ИНСАН, Казан: Фикер, 2002.

*Таҗиева Л.К.* Татар телендә гарәп алынмалары. – Казан: КДУ нәшр., 1972.

*Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле (грамматик очерк һәм сүзлек). – Казан, 1961.

*Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан: КДУ нәшр., 1978.

*Урманчеев Ф.И.* Халык авазы. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1974.

*Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.

*Фәттахова Р.Ф.* Татар телендә кешегә уңай бәя бирә торган лексик һәм фразеологик берәмлекләр (лексик, структур, лингвокультурологик анализ) // Актуальные вопросы татарского языкознания. Выпуск 6. – Казань, 2007. – 121–132 б.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

*Хаков В.Х.* Күп мәгънәле сүзләрнең һәм омонимнарның семантик-стилистик үзенчәлекләренә карата // Исследования по татарскому языку. – Казан: Изд-во КГУ, 1977. – 3–19 б.

*Хаков В.Х.* Стилистика һәм сүз сәнгате. –Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20–30 нчы еллар). – Казан: КДУ нәшр., 1985.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы. – Казан: КДУ нәшр., 1993.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе.– Казан, 2003.

*Халит Г.* Татар теленең составында гарәбизм һәм фарсизм // Совет мәктәбе. – 1939. – № 8. –57 б.

*Ханбикова Ш.С.* Сүз һәм аның мәгънәләре // Татар теле һәм әдәбияты. – Чыг. 6. – Казан, 1997. – 50–57 б.

*Ханбикова Ш.С.* Сүздәге антонимик мәгънәләр // Лексика и стилистика татарского языка. – Казань, 1981. – 3–6 б.

*Ханбикова Ш.С.* Татар телендә синонимнар сүзлеге. – Казан, 1980.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.

Хәзерге татар әдәби теле. Лексика, фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография, морфология. Югары уку йорты студентлары һәм урта мәктәп укытучылары өчен. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

*Хәкимҗан Ф.С.* Омонимлык һәм омонимнарны төркемләү // Гыйльми язмалар. – 12 нче чыгарылыш. – Казан, 2004. – 16–23 б.

*Хәкимҗан Ф., Хәкимҗан Д.* 1001 әйтем. – Казан: Gumanitarya, 2004.

*Хәкимҗан Ф. О*монимлык һәм омонимнарны төркемләү // Гыйльми язмалар (ТДГИ). – Казан, 2004. – № 12. – 16–22 б.

*Хәкимҗан Ф.* Омонимнарны табу һәм төркемләү // Милли мәдәният. – Казан: Гуманитария, 2004. – № 6. – 33–34 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Хөсни Ф.* Ни әйтергә? Ничек әйтергә? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Шакирова Р.* Лексик омонимнар һәм аларның этимологиясе // Татар теле һәм әдәбияты. – Чыг. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 152–157 б.

*Йосыпов Ф.Й.* Сафакүл татарлары: тарих, тел, фольклор. – Казан, 2003.

*Йосыпова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р.* Татар паремияләренең теле. – Казан: Ихлас, 2010.

### *Рус телендә*

*Абдуллин И.А.* К вопросу о хронологизации русских и западноевропейских заимствований в татарском языке // Двуязычие: типология и функционирование. – Казань, 1990. – С. 21–32.

*Абдуллина Ф.А.* О моделях семантического словообразования в татарском языке // Словообразование в тюркских языках: исследования и проблемы. – Казань, 2011. – С. 106–110.

*Алексеева Л.М.* Термин и метафора. – Пермь: Изд-во Перм. ун-та, 1988.

*Алефиренко Н.Ф., Валюх З.О.* Теоретические основы фразеографической репрезентации формально-содержательной вариантности фразеологизмов // Проблемы русской и общей фразеографии. – Новгород, 1990. – С. 23–32.

*Алишина Х.Ч.* Ономастика сибирских татар. В 2 частях. Ч. I. –Тюмень, 1999; Ч. II. – Тюмень: Изд-во ТюмГУ, 1999.

*Алишина Х.Ч.* Тоболо-иртышский диалект языка сибирских татар. – Казань, 1994.

*Амиров Г.С.* Синонимы в произведениях Г. Тукая. – Тюркская лексикология и лексикография. – М.: Наука, 1971.

*Амосова Н.Н.* Основы английской фразеологии. – ЛГУ, 1963.

*Аничков И.Е.* Об определении слова // Морфологическая структура слова в языках различных типов: сб. ст. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1963. – С. 58–67.

*Аничков И.Е.* Труды по языкознанию / Состав. В.П. Недельков. – СПб.: Наука, 1997.

*Аппаева Ф.К.* Генетически родственные омонимы в карачаево-балкарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Нальчик, 2002.

*Апресян Ю.Д.* Избранные труды. – Т. 1. Лексическая семантика. – М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 1995.

*Апресян Ю.Д.* Лексическая семантика. Избранные труды. – Т. 1. – М.: Наука, 1995.

*Апресян Ю.Д.* Лексическая семантика. Синонимические средства языка. – М.: Наука, 1974.

*Апресян Ю.Д.* Экспериментальное исследование семантики русского глагола. – М.: Наука, 1967.

*Аракин В.Д.* Об омонимах в турецком языке // Советская тюркология. – 1988. – № 1. – С. 12–19.

*Арнольд И.В.* Лексикология современного английского языка. – М.: Изд-во лит-ры на ин. яз., 1959.

*Арнольд И.В.* Основы научных исследований в лингвистике. – М.: Наука, 1991.

*Арнольд И.В.* Семантическая структура слова в современном английском языке и методика её исследования. – Л.: Изд-во ЛГУ, 1966.

*Арнольд И.В.* Стилистика современного английского языка. – Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1973.

*Арсентьева Е.Ф.* Фразеология и фразеография в сопоставительном аспекте (на материале русского и английского языков). – Казань, 2006.

*Арсентьева М.Г., Строева Т.В., Хазанович А.Т.* Многозначность и омонимия. – Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1966.

*Арсланов Л.Ш.* К вопросу о происхождении аффикса страдательности // Языки, духовная культура и история тюрков. Труды международной конференции в трёх томах. – Т. I. – Казань, 1992. – С. 243–244.

*Арсланов Л.Ш.* Татары Нижнего Поволжья и Ставрополя: язык, фольклор, словарь. – Наб. Челны, 1995.

*Арутюнова Н.Д.* Типы языковых знаков. – М.: Наука, 1988.

*Арутюнова Н.Д.* Язык и мир человека. – М.: Языки русской культуры, 1999.

*Арутюнова Н.Д.* Языковая метафора (синтаксис и лексика) // Лингвистика и поэтика. – М., 1979. – С. 54–68.

*Архангельский В.Л.* Устойчивые фразы в современном русском языке. – Ростов: Изд-во Ростовского ун-та, 1964.

*Афанасьев П.С.* Современный якутский язык. Лексикология. – Якутск: Изд-во Якут. гос. ун-та, 1996.

*Афанасьева С.П.* Регулярная полисемия абстрактных существительных со значением процесса (на материале английской строительной терминологии): автореф. дис … канд. филол. наук. – Л., 1984.

*Аханов К.* Омонимы в казахском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1956.

*Ахатов Г.Х.* Некоторые вопросы системного изучения лексико-семантических категорий татарского языка // Вопросы структуры татарского языка: межвузовский сборник научных трудов. – Казань, 1986. – С. 135–143.

*Ахманова О.С.* Очерки по общей и русской лексикологии. – М.: Учпедизд., 1957.

*Ахметьянов Р.Г.* Об историзме в этимологии // Теория и практика этимологических исследований. – М., 1985. – С. 66–72.

*Ахметьянов Р.Г.* Об отражении регулярного и исторического в татарско-русском словаре // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1976. – С. 76–90.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. – М.: Наука, 1989.

*Ахметьянов Р.Г.* Принципы этимологических исследований в области татарской лексики // Вопросы тюркологии. Учёные записки КГПИ. – Казань, 1970. – С. 93–101.

*Ахметьянов Р.Г.* Этимологические основы лексики татарского языка: автореф. дис... канд. филол. наук. – Казань, 1970.

*Ахтямов М.Х.* Проблема омонимии в современном башкирском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – М., 1966.

*Ахунзянов Э.М.* Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. – Казань: Изд-во КГУ, 1983.

*Ахунзянов Э.М.* Русские заимствования в татарском языке. – Казань: Изд-во КГУ, 1968.

*Ахунзянов Э.М.* Русские кальки в татарском литературном языке // Вопросы татарского языкознания. – Кн. II. – Казань: Изд-во КГУ, 1963. – С. 38–66.

*Бабкин А.М.* Русская фразеология, её развитие и источники. – М.; Л.: Наука,1970.

*Багаутдинова Г.А.* О некоторых вопросах изучения фразеологизмов // Совет мәктәбе. – 1989. – № 2. – С. 38–39.

*Багаутдинова Г.А.* Человек во фразеологии: антропоцентрический и аксиологический аспекты: дис. … д-ра филол. наук. – Казань, 2007.

*Байрамова Л.К.* Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. – Казань: Изд-во КГУ, 2001.

*Балалыкина Э.А.* Развитие противоположных семантических оттенков в пределах одного слова в истории русского языка // Семантика русского языка в диахронии. – Калининград: Изд-во Калинингр. ун-та, 1994. – С. 3–10.

*Балаян А.Р., Шабанов А.Ш.* Некоторые особенности коммуникативного поведения азербайджанцев // Национально-культурная специфика речевого общения народов СССР. – М.: Наука, 1982. – С. 88–93.

*Балли Ш.* Общая лингвистика и вопросы французского языка. – М.: Изд-во лит-ры на ин. яз., 1955.

*Балли Ш.* Французская стилистика. – М.: Изд-во иностр. лит-ры, 1961.

*Баранов А.Н.* О типах сочетаемости метафорических моделей // Вопросы языкознания. – 2003. – № 2. – С. 73–94.

*Барлыбаев Р.* Расширение и сужение значений слов в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1963.

*Барсукова Р.С.* Заболотный говор тоболо-иртышского диалекта татарского языка в сравнительном освещении. –Казань, 2004.

*Бартольд В.В.* Сочинения. – Т. 2. – Ч. 1. – М., 1963. – С. 175–176.

*Баскаков А.Н.* К проблеме китайских заимствований в тюркских языках // Советская тюркология. –1987. – № 5.

*Баскаков Н.А.* Русские фамилии тюркского происхождения. – М., 1971.

*Баскаков Н.А.* Историко-типологическая морфология тюркских языков (структура слова и механизм агглютинации). – М.: Наука, 1979. – С. 14–146.

*Батырмурзаева У.М.* Лексико-семантическая структура слова в кумыкском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 1996.

*Бекджанова Р.* Омонимы в киргизском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. –Фрунзе, 1967.

*Белеева И.Д.* Сопоставительное исследование русских и французских существительных с развитой многозначностью: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Екатеринбург, 2000.

*Бердимуратов Е.* Очерк лексикологии современного каракалпакского литературного языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ташкент, 1964.

*Березин Ф.М., Головин Ф.И.* Общее языкознание: учебное пособие для студентов пед. ин-тов. – М.: Просвещение, 1979.

*Беркутов В.М.* Народный календарь и метрология булгаро-татар. – Казань, 1987.

*Беширов Б.Ш.* Омонимы в современном кумыкском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 2002.

*Биджиева С.Р.* Многозначность имён существительных в карачаево-балкарском языке и её лексикографическая разработка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Нальчик, 2001.

*Биишев А.Г.* Разработка системы значений многозначного слова в толковом словаре // Языкознание. Тезисы докладов и сообщений. – Ташкент, 1980. – С. 123–126.

*Биктимирова А.Р.* Лексическая система татарского языка.– Казань: Изд-во Казан. гос. технич. ун-та, 2008.

*Бичурина Г.И.* Фразеологическая полисемия в русском и татарском языках: дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1998.

*Блумфилд Л.* Язык: Пер. с англ. – М.: Прогресс, 1968.

*Блэк М.* Метафора // Теория метафоры. – М.: Наука, 1990. – С. 153–172.

*Богданов С.И.* Форма слова и морфологическая форма. – СПб.: Изд-во СПбГУ, 1998.

*Болганбаев А.* Лексикология казахского языка. – 2-е изд., испр. и доп. – Алма-Ата: Мектеп, 1988.

*Бродский М.Ю.* Лексическая энантиосемия в сопоставительном аспекте (на материале современного английского и французского языков): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Екатеринбург, 1998.

*Будагов Р.А.* Слово и значение. – Л.: Изд-во Ленин. ун-та, 1974.

*Будагов Р.А.* Человек и его язык. – Москва: Изд-во МГУ, 1974.

*Булатова А.К.* Полисемия в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2012.

*Булаховский Л.А.* Введение в языкознание. – М.: Учпедиз, 1953.

*Булаховский Л.А.* Энантиосемия. Развитие противоположных значений // Русская речь. – 1988. – № 2. – С. 68–70.

*Бурнашева С.А.* Изменения словарного состава татарского языка в советскую эпоху: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1952.

*Валитова Ю.А.* Иноязычные элементы в поэтических произведениях Г. Тукая: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 1966.

*Валиуллина З.М.* Философская терминология татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 1953.

*Варбот Ж.Ж.* Этимология // Лингвистический энциклопедический словарь. – Москва: Сов. энцикл., 1990. – С. 596–597.

*Васильев Л.М.* Современная лингвистическая семантика. – М.: Высш. шк., 1990.

Введение в литературоведение / Под ред. Г.Н.Поспелова. – М.: Высш. шк., 1976.

*Введенская Л.А.* О взаимодействии антонимии и синонимии // Вопросы лексики и фразеологии современного русского языка. – Ростов: Изд-во Рост. ун-та, 1968. – С. 59–75.

*Введенская Л.А.* Синонимические пары антонимов // Русский язык в школе. – 1969. –№ 4. – С. 107–108.

*Вендина Т.И.* Введение в языкознание. – М.: Высш. шк., 2001.

*Вердиева З.Н.* Семантические поля в современном английском языке. – М.: Наука, 1986.

*Виноградов В.В.* Об основных типах фразеологических единиц в русском языке // Академик А.А. Шахматов. – М.: Изд-во АН СССР, 1947.

*Виноградов В.В.* Русский язык (Грамматическое учение о слове). – М.; Л., 1947.

*Виноградов В.В.* Словообразование и его отношение к грамматике и лексикологии (на материале русского и родственных языков) // Вопросы теории и истории языка. – М., 1952.– С.99–152.

*Виноградов В.В.* Основные типы лексических значений слов // Вопросы языкознания. – 1953. – № 5. – С. 3–29.

*Виноградов В.В.* Язык художественного произведения // Вопросы языкознания. – 1954. –№ 5. – С. 13.

*Виноградов В.В.* Об омонимии и смежных явлениях // Вопросы языкознания. – 1968. – № 5. – С. 58–76.

*Виноградов В.В.* Избранные труды. Лексикология и лексикография. – М.: Наука, 1977.

*Винокур Г.Г.* Закономерности стилистического использования языковых единиц. – М.: Наука, 1980.

*Витгенштейн Л.В.* Логико-философский трактат. – М., 1959.

*Вишнякова О.В.* Паронимы современного русского языка. – М., 1981.

*Воронцова Г.Н.* Очерки по грамматике английского языка. – М.: Изд-во литературы на иностранных языках, 1960.

*Вундт В.* Проблемы психологии народов. – М.: Академический проект, 2010.

*Гаврин С.Г.* Фразеология современного русского языка (в аспекте теории отражения). – Пермь: Пермск. гос. пед. ин-т, 1974.

*Гак В.Г.* Сопоставительная лексикология (на материале французского и русского языков). – М.: Наука, 1977.

*Галиуллина Г.Р.* К вопросу разграничения терминов «разговорная речь» и «литературный язык» в современном татарском языкознании / Г.Р. Галиуллина, Д.Р. Мубаракзянова // Филология и культура. – № 4 (38). – 2014. – С. 57–61.

*Галиуллина Г.Р.* Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008.

*Галиуллина Г.Р., Юсупова А.Ш., Хадиева Г.К., Денмухаметова Э.Н.* Тюрко-татарская лексика как проекция национального менталитета: на материале лексической группы «Природа». – Казань: Редакционно-издательский центр, 2011.

*Галкина-Федорук Е.М.* Слово и понятие. – М.: Учпедиз., 1957.

*Галкина-Федорук Е.М.* Современный русский язык: Лексика. – М.: Изд-во МГУ, 1954.

*Ганиев Ф.А.* Суффиксальное образование глаголов в современном татарском литературном языке. – Казань: Изд-во КГУ, 1974.

*Гаптелганиева Д.М.* Многозначность и омонимия в системе татарской глагольной лексики: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1999.

*Гарипов Т.М.* Кыпчакские языки Урало-Поволжья. – М.: Наука, 1979.

*Гарипова Ф.Г.* Духовный родник: Знаменитые татарские деревни. – Казань: Магариф, 2005.

*Гарипова Ф.Г.* Исследования по гидронимии Татарстана. – М.: Наука, 1991.

*Гарипова Ф.Г.* История в названиях. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995.

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия (Вопросы этногенеза татарского народа по данным гидронимии). – Книга первая. – Казань, 1998.

*Гасанов А.А.* Омонимия в азербайджанском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Баку, 1980.

*Гвоздарев Ю.А.* Основы русского фразообразования. – Изд-во Ростовского ун-та, 1977.

*Гвоздев А.Н.* Очерки по стилистике русского языка. – М.: Учпедгиз, 1955.

*Гельдымурадов А.* Критерии определения лексических омонимов в туркменском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ашхабад, 1974.

*Гинзбург Е.Л.* Конструкции полисемии в русском языке. Таксономия и метонимия. – М.: Наука, 1985.

*Гинзбург Е.Л.* Одноимённость однокоренных производных // Проблемы структурной лингвистики. – М.: Наука, 1978. – С. 134–136.

*Гинзбург Р.С.* Значение слова и методика компонентного анализа // Иностр. языки в школе. – 1978. – № 5. – С. 21–26.

*Глухов В.М.* Вопросы многозначности фразеологических единиц и ихрешение в «Фразеологическом словаре русского языка» / под ред. А.И. Молоткова // Проблемы устойчивости и вариантности фразеологических единиц. – Тула, 1968.

*Голев Н.Д.* Деривационное развитие слова в русском тексте (на материале лексико-деривационного поля слова «перестройка»)//Явление вариативности в языке. – Кемерово, 1997.

*Голев Н.Д.* Динамический аспект лексической мотивации. – Томск, 1989.

*Голев Н.Д.* Идиоматичность слова в лексическом и словообразовательном аспектах // Вопросы слово- и формообразования в индоевропейских языках: семантика и функционирование. – Часть 1. – Томск: Изд-во Том. ун-та, 1994.

*Голев Н.Д.* Лексико-деривационное пространство русского текста: структура, семантика, прагматика // Фатическое поле языка (памяти профессора Л.Н.Мурзина): Межвуз. сб. науч. трудов. – Пермь, 1998.

*Голев Н.Д.* Эпидигматика и деривационные процессы в речи (детерминационный аспект) // Проблемы деривации в системе языка и в речевой деятельности (синхронное словообразование и номинация): Межвуз. сб. науч. трудов. – М., 1995.

*Головин Б.Н.* Введение в языкознание. – М.: Высш. шк., 1983.

*Головин Б.Н.* О типах лексических значений слов русского языка // Учен. зап. Горьковского ун-та. – 1960. – Вып. 59. – С. 61–73.

*Головин Б.Н.* Основы культуры речи.– М.: Издательский дом ЮНИТИ, 1988.

*Голуб И.Б.* Стилистика современного русского языка. Лексика. Фонетика. – М.: Высш. шк., 1986.

*Губарев В.П.* К типологии фразеологической модели (на материале немецкого языка) // Филологические науки. – 1985. – № 4. – С. 65–68.

*Гузеев Ж.М.* Семантическая разработка слова в толковых словарях тюркских языков. – Нальчик: Эльбрус, 1985.

*Джаффаров С.А.* Лексика азербайджанского языка: автореф. дис. ... докт. филол. наук.– Баку, 1959.

*Диброва Е.И.* О грамматических преобразованиях фразеологических единиц-словоформ // Очерки по лексике и фразеологии. – Ростов н/Д., 1976.

*Диброва Е.И., Касаткин Л.И., Николина Н.А., Щеболева И.И.* Современный русский язык. Теория. Анализ языковых единиц / под ред. Е.И. Дибровой. – Ч. I. – Ростов н/Д.: Феникс, 1997.

*Дроздов Ю.Н.* Тюркская этнонимия древнеевропейских народов. – М., 2008.

*Дронов П.С.* Общая лексикология.– М.: Языки славянской культуры, 2015.

*Ефимов А.* О языке художественных произведений. – М., 1954.

*Жанпеисов Е.Н.* Этнокультурная лексика казахского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук.– Алма-Ата , 1990.

*Жданов О.К.* Метонимия как средствообогащения словарного состава французского языка. – М.: Наука, 1989.

*Жирмунский В.М.* Введение в сравнительно-историческое изучение германских языков. – М.-Л.: Наука, 1964.

*Жирмунский В.М.* История немецкого языка. – М.: Высш. шк., 1965.

*Жуков В.П., Жуков А.В.* Морфологическая характеристика фразеологизмов русского языка. – Л., 1980.

*Жуков В.П.* Русская фразеология. – М.: Высш. шк., 1986.

*Жуков В.П.* Семантика фразеологических оборотов. – М.: Просвещение, 1978.

*Завьялова В.М.* Антонимы (Пособие по лексике немецкого языка). – М.: Высш. шк., 1956.

*Задорожный М.И.* О границах полисемии и омонимии. – М.: Изд-во МГУ, 1971.

*Закиев М.З.* История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие). – М.: ИНСАН, 2008.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. – М., 2003.

*Закирова Г.К.* Синонимы в языке тюрко-татарских письменных памятников периода Золотой Орды. – Казань: Изд-во Казан. гос. техн. ун-та, 2009.

*Закирова Р.М.* Антонимы в татарском языке (лексико-грамматические, семантические и стилистические особенности употребления): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2002.

*Закирова Р.М.* Антонимы в татарском языке: проблемы функционирования.– Елабуга: Изд-во Елабуж. гос. пед. ун-та, 2004.

*Закирова Р.М.* Проблема антонимии в разноструктурных языках / Академик Э.Р. Тенишев и тюркский мир. – Казань: КФУ, 2012. – С. 105–108.

*Закирова Р.М.* Фразеологические антонимы // Некоторые проблемы лингвистики на неязыковых факультетах: сб. ЕГПИ. – Елабуга, 2001. – С. 29–37.

*Зализняк А.А.* Многозначность в языке и способы её представления. – М.: Языки славянской культуры, 2006.

*Звегинцев В.А.* Семасиология. – М.: Высш. шк., 1957.

*Иванникова Е.А.* Синонимические отношения между фразеологическими единицами и словами // Очерки по синонимике современного русского литературного языка. – М.-Л., 1966.

*Исабеков Б.О.* Лексическая антонимия в современном узбекском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ташкент, 1973.

Историческое развитие лексики тюркских языков. – М., 1961.

*Ишбердин Э.Ф.* Историческое развитие лексики башкирского языка. – М.: Наука, 1986.

Калинин А.В. Лексика русского языка. – М.: Изд-во МГУ, 1978.

*Камецкайте Н.Л.* Синонимы в английской фразеологии. – М.: Высш. шк., 1971.

*Кацнельсон С.Д.* Содержание слова, значение и обозначение. – М.-Л.: Наука,1965.

*Кидирниязова М.И.* Полисемия в ногайском языке: дис. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 2003.

*Кирсанова Н.А.* О синонимике фразеологических единиц в трилогии Ф.В. Гладкова // Учёные записки Черновицкого университета. Т. 29. Серия филологических наук. – Вып. 5. – 1958. – С. 52.

*Клюева В.Н.* Проблема антонимов // Учёные записки 1-го Московского педагогического института иностранных языков. – Т. 9. – М.: Изд-во Московского ун-та, 1956. – С. 75–85.

*Кобозева И.М.* Лингвистическая семантика. – М: Эдиториал УРСС, 2000.

*Колесов В.В.* История русского языка в рассказах. – М.; СПб., 2005.

*Колпакова Г.В.* Семантика языковой единицы. – Казань: Изд-во КГУ, 2004.

*Комиссаров В.Н.* Семантическая характеристика слов-антонимов (на материале английского языка). – М.: Наука,1962.

*Коноваленко В.С., Коноваленко С.С.* Антонимы. – М.: Гном и Д., 2003.

*Копыленко М.Н., Попова З.Д.* Очерки по общей фразеологии. – Воронеж: Изд-во ВГУ, 1972.

*Крысин Л.П.* Современный русский язык. Лексическая семантика, лексикология, фразеология, лексикография. – М.: Академия, 2013.

*Кубрякова Е.С.* Типы языковых значений. Семантика производного слова. – М.: Наука, 1984.

*Кузнецова Э.В.* Русская лексика как система. – Свердловск, 1980.

*Кунин А.В.* Курс фразеологии современного английского языка. – 2-е изд., перераб. – М., 1996.

*Курилович Е.* Заметки о значении слова // Очерки по лингвистике. – М.: Прогресс, 1962. – С. 237–250.

*Кустова Г.И.* Типы производных значений и механизмы языкового расширения. – М.: Языки славянской культуры, 2004.

*Лаптева О.А.* Теория современного русского литературного языка. – М., 2003.

*Ларин Б.А.* О народной фразеологии // История русского языка и общее языкознание. – М., 1977.

*Лебедева Т.Е.* Полисемия в русских народных: на материале имён существительных: дис. ... канд. филол. наук. – СПб., 2002.

Лексика и стилистика татарского языка. – Казань: Каз. фил. АН СССР, 1982.

Лексикология узбекского языка / А. Ходжиев, Г. Мухаммаджанова, Э. Бегматов и др.; Отв. ред. А. Ходжиев, А. Ахмедов. – Ташкент: Фан, 1981.

*Леонтьев А.А.* Психолингвистический аспект языкового значения // Принципы и методы семантических исследований. – М.: Наука, 1976. – С. 46–73.

*ЛеонтьевА.А.* Формы существования значения // Психолингвистические проблемы семантики. – М.: Наука, 1983. – С. 154–182.

*Лещева Л.М.* Слова в английском языке. – Минск: Академия управления при Президенте РБ, 2001.

*Литвин Ф.А.* Многозначность слова в языке и речи. – М.: Высш. шк., 1984.

*Мардиева Л.А.* Актуальные тенденции развития лексики русских и татарских газетно-журнальных текстов: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1998.

*Маслова В.А.* Когнитивная лингвистика: Учеб. пособие. – М.: Тетра Системс, 2005.

Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка / авт.-сост.: А.Г. Шайхулов, Л.У. Бикмаева, З.Р. Садыкова. – Т. 1. – Уфа: РИО БашГУ, 2005.

*Медникова Э.М.* Значениеслова и методы егоописания. – М.: Высш. шк., 1974.

*Меметов А.* Крымско-татарский язык: история изучения, лексикология, фонетика, морфология. – Симферополь: Крымучпедгиз, 2013.

*Меметов А.М.* Лексикология крымско-татарского языка: учеб. пособие.– Симферополь: Крымучпедгиз, 2000.

Метафора в языке и тексте // Сб.статей. – М.: Наука, 1988.

*Метхиева Т.М.* Полисемия имён существительных в современном азербайджанском языке: дис. ... канд. филол. наук. – Баку, 1984.

*Миртаджиев М.* Возникновение лексических омонимов в узбекском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Ташкент, 1967.

*Мокиенко В.М.* Загадки русской фразеологии. – М.: Высш. шк., 1990.

*Мокиенко В.М.* Славянская фразеология. 2-е изд., исп. и доп. – М., 1989.

*Молотков А.И.* Основы фразеологии русского языка. – Л.: Наука, 1977.

*Морковкин В.В.* Лексическая многозначность и некоторые вопросы её лексикографической интерпретации // Русский язык. Проблемы художественной речи, лексикологии и лексикографии. Виноградовские чтения. IX–X. – М.: Наука, 1981. – С. 153–166.

*Муравицкая М.П.* Некоторые вопросы полисемии. – Киев: Изд-во МГУ, 1984.

*Мусабаев Г.Г.* Лексика современного казахского языка: автореф. дис. … д-ра филол. наук. – Алма-Ата, 1960.

*Мусаев К.М.* Тюркская лексикология. – М., 1984.

*Мусин Ж.* Антонимы в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1970.

*Мухамеджанов Ш.* Переносные значения слов в современном казахском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1968.

*Мухамедова З.М.* Исследования по истории туркменского языка. Этимологический словарь. – Ашхабад, 1973.

*Мухиярова Р.Х.* Развитие лексики татарского литературного языка в 80–90-е годы XX века (на материале периодической печати): автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1999.

*Назаров А.* Полисемия в туркменском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Ашхабад, 1974.

*Назарян А.Г.* Фразеология современного французского языка. – М., 1987.

*Насипов И.С.* Опыт систематизации финно-угорских заимствований в татарском языке. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2009.

*Насипов И.С.* Финно-угорские заимствования в татарском языке: синопсис и таксономия: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 2010.

*Ненила Н.Г.* Полисемант голова и реализация его словообразовательного потенциала в русском литературном языке и говорах: дис. … канд. филол. наук. – Белград, 2006.

*Низамов И.М.* Язык современной татарской печати (на материале газетной лексики): автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Уфа. – 1981.

*Никатуева З.Ш.* Полисемия и омонимия в даргинском языке: дис. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 2003.

*Никитин М.В.* Лексические значения в слове и словосочетаниях. – Владимир: Изд-во ВГПИ им. П.И. Лебедева-Полянского, 1974.

*Никитин М.В.* Основы лингвистической теории значения. – Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1988.

*Новиков Д.Н.* Разграничение полисемии и омонимии в свете когнитивной лингвистики (на материале английского языка): дис. … канд. филол. наук. – СПб., 2001.

*Новиков Л.А.* Антонимия в русском языке. (Семантический анализ противоположности в лексике). – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1973.

*Новиков Л.А.* Логическая противоположность и лексическая антонимия // Русский язык в школе. – М., 1966. – № 4. – С. 87–88.

*Новиков Л.А.* Семантика русского языка.– М., 1982.

*Новиков Л.А.* Средство выражения антонимии // Русская речь. – М., 1973. – № 1. – С. 48–51.

*Нугуманова А.А.* Метафоры в татарском языке: лексико-грамматический и стилистический аспекты: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2009.

Общее языкознание. Внутренняя структура языка / отв. ред. Б.А. Серебренников. – М., 1972.

*Ожегов С.И.* О структуре фразеологии // Лексикографический сб. – Вып. 2. – М., 1957.

*Ольшанский И.Г., Скиба В.П.* Лексическая полисемия в системе языка и тексте (на материале немецкого языка). – Кишинёв: Штиинца, 1987.

*Остроумов Н.* Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещёных татар Казанской губернии. – Казань, 1876.

*Отаров И.М.* Лексикология карачаево-балкарского языка.– Нальчик: Эльбрус, 1996.

*Падучева Е.В.* Семантические исследования (Семантика времени и вида в русском языке; Семантика нарратива). – М.: Языки русской-культуры, 1996.

*Пауль Г.* Принципы истории языка / Пер. с немец. – М.: Изд-во ин. лит-ры, 1960.

*Песина С.А.* Полисемия в когнитивном аспекте. – СПб.: Изд-во РГПУ им. А.И. Герцена, 2005.

*Песина С.А.* От инварианта многозначного слова к лексическому прототипу // Вопросы когнитивной лингвистики. – 2006. – № 2. – С. 53–61.

*Петров В.В.* Метафора: от семантических представлений к когнитивному анализу // Вопросы языкознания. – 1990. – № 3. – С. 135–145.

*Пизани В.* Этимология. – М., 1956.

*Плотников Б.А., Трайковская В.Ф.* Дихотомическая лексикология. – Минск: Университетское, 1989.

*Пономарёва О.Б.* Семантическая деривация и многозначность: неоднозначность и слияние смыслов в поэтическом тексте // Вестник ТюмГУ. – 2006. – № 4. – С. 212–217.

*Потебня А.А.* Психология поэтического и прозаического мышления. Вопросы теории и психологии мышления. Вопросы теории и психологии творчества. – Т. 2. – Вып. 2. – СПб.: Издание А.С. Суварина, 1910.

*Прохорова В.Н.* Энантиосемия в современном русском языке (о причинах и условиях возникновения и функционирования слов с противоположными значениями) // Вопросы русского языкознания. – Вып. 1. –М.: Изд-во МГУ, 1976. – С. 157–165.

*Прохорова В.Н.* О словах с противоположными значениями в русских говорах // Филологические науки. – 1961. – № 1. – С. 122–127.

*Прохорова В.Н.* Полисемия и лексико-семантический способ словообразования в современном русском языке: лекции по спецкурсу. – М.: Изд-во МГУ, 1980.

*Радлов В.В.* О языке куманов по поводу издания куманского словаря. – СПб., 1884.

*Райхштейн А.Д.* Сопоставительный анализ немецкой и русской фразеологии. – М.: Высш. шк., 1980.

*Рамазанова Д.Б.* Вариативность диалектной лексики татарских говоров юго-западной Башкирии // Нормативность и вариативность в татарском языке. – Казань, 1987. – С. 68–90.

*Рамазанова Д.Б.* Вопросы татарской диалектологии. – Казань, 2008.

*Рамазанова Д.Б.* Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. –Казань, 2002.

*Рамазанова Д.Б.* Существование терминов «мещеряки», «башкиры», «тептяры» в Западной Башкирии // Исследование языка древнеписьменных памятников. – Казань, 1980. – С.142–157.

*Рамазанова Д.Б.* Татарская диалектная лексикография и лексикология на рубеже III тысячелетия // Актуальные вопросы татарского языкознания. – Казань, 2002. – С. 101–106.

*Рамазанова Д.Б.* Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора. – Казань: Магариф, 2001.

*Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань, 1981.

*Рассадин В.И.* Лексика современного тофаларского языка: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Улан-Удэ, 1967.

*Рассадин В.И.* Фонетика и лексика тофаларского языка. – Улан-Удэ: Бурятск. кн. изд-во, 1971.

*Рахилина Е.В.* Когнитивный анализ предметных имён: семантика и сочетаемость. – М.: Русские словари, 2000.

*Рахимова А.Р.* Лексика диалектов сибирских татар: сравнительно-исторический анализ промысловой и хозяйственной лексики. – Казань: Мастер-Лайн, 2001.

*Реформатский А.А.* Введение в языковедение / Под ред. В.А. Виноградова. – М.: Аспект Пресс, 1999.

*Реформатский А.А.* Введение в языкознание. – М.: Просвещение, 1967.

*РодичеваЭ.И.* К проблемам антонимии // Семантические и фонологические проблемы прикладной лингвистики. Филологический факультет. – Вып. 3. – М.: Изд-во Московского ун-та, 1966.

*Розенталь Д.Э., Голуб И.Б., Теленкова М.А.* Современный русский язык. – М.: Айрис-Пресс, 2002.

*Розина Р.И.* Категориальный сдвиг актантов в семантической деривации // Вопросы языкознания. – 2002. – № 2. – С. 3–15.

*Рублёва О.Л.* Лексикология современного русского языка. – Владивосток: Изд-во Дальневосточного ун-та, 2004.

*Руднев А.Г.* Проблема фразеологии. Лекция курса «Современный русский язык». – Л., 1960.

Русский язык: Грамматическое учение о слове. – 2-е изд. – М., 1972.

Русский язык. Энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1979.

*Саберова Г.Р.* Названия растений в татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казан, 1995.

*Сагдеева Ф.К.* О соотношении понятий «семантическая деривация» и «полисемия» // Словообразование в тюркских языках: исследования и проблемы. – Казань, 2011. – С. 337–340.

*Сагдеева Ф.К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. – Казань: Фикер, 2003.

*Садыкбеков Р.* Проблема многозначности слов в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Алма-Ата, 1973.

*Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. –Казань, 1985.

*Садыкова З.Р.* Зоонимическая лексика татарского языка. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1994.

*Садыкова З.Р.* Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. – Казань, 2003.

*Салахова Р.Р.* Омонимичные суффиксы татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2004.

*Саманба Л.Х.* О границах полисемии и омонимии (на материале абхазского языка). – Сухуми: Алашара, 2002.

*Самойлович А.Н. Богатый* и *бедный* в тюркских языках // Тюркское языкознание. Филология. Руника. – Москва, 2005. – С. 291–330.

*Санжеев Г.Д.* О тюрко-монгольских лингвистических параллелях // Советская тюркология. – 1973. – № 6.

*Саттаров Г.Ф.* Синонимичные личные имена в татарском языке // Татарский язык: лексическая и грамматическая семантика. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984.

*Саттаров Г.Ф.* Синонимия, антонимия и омонимия в татарской антропонимии // Советская тюркология. – 1984. – С. 24–31.

*Саттарова З.М.* Омонимы в современном крымскотатарском языке (на уровне лексем и словоформ): дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2003.

*Севостьянова О.И.* Северное Причерноморье в классический период // История Древней Греции. – Изд. II. – М., 1972.

*Серебренников Б.А.* Тюрко-монгольские параллели в истории тюркских языков // Советская тюркология. – 1980, 1983. – № 5.

*Сетаров Д.С.* Тюркизмы в русских названиях лошадей // Советская тюркология. – 1981. – № 6.

*Скляревская Г.Н.* Метафора в системе языка. – СПб.: Наука, 1993.

*Смирницкий А.И.* Значение слова // Вопросы языкознания. – 1955. – №2. – С. 79–89.

*Смирницкий А.И.* Лексикология английского языка. – М.: Изд-во лит-ры на ин. яз., 1956.

*Смирницкий А.И.* Лексическое и грамматическое в слове // Вопросы грамматического строя. – М.: АН СССР, 1955.

Современный русский язык: Теория. Анализ языковых единиц: учеб. для студ. высш. учеб. заведений: В 2 ч. – Ч. 1: Фонетика и орфоэпия. Графика и орфография. Лексикология. Фразеология. Лексикография. Морфемика. Словообразование / Е.И. Диброва, Л.И. Касаткин, Н.А. Николина, И.И Щеболева; под ред. Е.И. Дибровой. – М.: Академия, 2001.

*Солодуб Ю.П.* О семантико-грамматической классификации фразеологизмов // Русский язык в школе. – 1988. – № 3. – С. 39–42.

*Солодуб Ю.П.* Сопоставительный анализ структуры лексического и фразеологического значений // Филологические науки. НДВШ. – 1997. – № 5. – С. 43–54.

*Солодухо Э.М.* Проблемы интернациональной фразеологии. – Казань: Изд-во КГУ, 1982.

*Соссюр Ф.* Курс общей лингвистики // Труды по языкознанию. – М.: Прогресс, 1972.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. – М.: Наука, 2006.

*Степанов Ю.С.* Семиологический принцип описания языка // Принципы описания языков мира. – М., 1976.

*Степанов Ю.С.* Семиотика. Антология. – М.: Академический проект, 1997, 2001.

*Стернин И.А.* Лексическая семантика слова в речи. – Воронеж, 1985.

*Стернина М.А.* Лексико-грамматическая полисемия в системе языка: Опыт разработки интегральной теории полисемии: дис. ... д-ра филол. наук. – Воронеж, 1999.

*Субаева Р.Х., Большаков И.Б.* Справочник татарских личных имён. – Казань, 1973.

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р.* Структурно-функциональная компьютерная модель татарских морфем. – Казань: Фэн, 2003.

*Суфьянова Н.Ф.* Проблема многозначности в башкирском языке и её лексикографическая разработка: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Уфа, 1993.

*Талыбов К.А.* Антонимы в современном азербайджанском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Баку, 1971.

*Татаринцев Б.И.* Монгольское языковое влияние на тувинскую лексику. – Кызыл, 1976.

*Татаринцев Б.И.* Смысловые связи и отношения слов в тувинском языке. – М.: Наука, 1987.

*Телия В.Н.* Метафоризация как основной приём создания лексических и фразеологических средств языковой картины мира // Роль человеческого фактора в языке – языковая картина мира. – М.: Наука, 1988.

*Телия В.Н.* Русская фразеология. Семантический, прагматический и лингвокультурологический аспекты. – М., 1996.

*Толикина Е.Н.* О природе и характере синонимических связей фразеологической единицы и слова // Очерки по синонимике современного русского литературного языка. – М.; Л., 1966.

*Трифонова Е.Н.* Полисемия банковских терминов в английском языке: дис. … канд. филол.наук. – Омск, 2004.

*Ульман С.* Семантические универсалии // Новое в лингвистике. – Вып. 5. – М., 1970. – С.250–299.

*Усманов С.* Антонимнар // Узбек тили ва адабиети масалалари. – Тошкент, 1958. – № 2. – С. 33–40.

*Усубалиев Б.И.* Антонимы в киргизском языке: дис. ... канд. филол. наук. – Фрунзе, 1982.

*Уфимцева А.А.* Лексическое значение. Принцип семасиологического описания лексики. – М.: Наука, 1986.

*Уфимцева А.А.* Семантика слова // Аспекты семантических исследований. – М., 1980.

*Уфимцева А.А.* Типы словесных знаков. – М.: Наука, 1974.

*Фаттахова Р.Ф.* Интенсивность как самостоятельная функционально-семантическая категория и её отражение в татарской фразеологии // Галимджан Ибрагимов и XXI век. Материалы международной научно-практической конференции, посвящённой 120-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. – Казань, 2007. – С. 191–196.

*Фаттахова Р.Ф.* Логико-семантические модели фразеологических единиц с количественным значением // Тюркология: история и современность. К 85-летию со дня рождения акад. Э.Р. Тенишева. – Казань, 2006. – С. 132–134.

*Фаттахова Р.Ф.* О коннотативном и национально-культурном компонентах фразеологических единиц татарского языка с количественным значением // Материалы Всероссийской научно-практической конференции с международным участием «Актуальные проблемы филологии и методики её преподавания в вузе и в школе»,

посвящённой 55-летию филологического факультета ЕГПУ (Елабуга, 20–21 ноября 2008 г.). – Елабуга, 2008. – С. 380–383.

*Фаттахова Р.Ф.* Оценочно-квалифицирующая характеристика татарских фразеологических единиц с лексическим компонентом «число» // Актуальные проблемы татарского языка и литературы. II часть: языкознание. Сборник научно-методических статей. – Стерлитамак, 2004. – С. 256–260.

*Фёдоров А.И.* Лекции по русской фразеологии, прочитанные студентам НГУ. – Новосибирск, 1964.

*Фидаева Л.И., Юсупов Р.А.* Синтагматические отношения лексических единиц русского и татарского языков. – Казань: Изд-во Казан. пед. ун-та, 2002.

*Филоненко Т.М.* Фразеологический образ в языковой модели количества. – Магнитогорск: Изд-во МГПИ, 1999.

*Фомина М.И.* Современный русский язык. Лексикология. – М.: Высш. шк., 1990.

*Хабибов Л.Г.* Структурно-семантические особенности антонимов в татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. –Уфа, 1984 .

*Хабичев М.А.* Карачаево-балкарское именное формообразование и словообразование. – Черкесск, 1977.

*Хайитов Б.Т.* Фразеологизмы в словаре // Русская речь. – 1987. – № 1. – С. 86–89.

*Хайруллин М.Б.* Некоторые вопросы единства интернационального и национального в разносистемных языках. – Казань: Изд-во КГУ, 1991.

*Хайруллин М.Б.* Глобализация и развитие национальных культур и языков. – Казань: Изд-во КГУ, 2006.

*Хайруллин М.Б.* Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. – Казань: ФИКЕР, 2000.

*Хайрутдинова Т.Х.* Бытовая лексика татарского языка. – Казань: Фикер, 2000.

*Хайрутдинова Т.Х.* Златоустовский говор татарского языка. –Казань, 1985.

*Хайрутдинова Т.Х.* Названия пищи в татарском языке. – Казань, 1993.

*Хайрутдинова Т.Х.* Народные названия растений в татарском языке. – Казань, 2004.

*Ханбикова Ш.С.* Однокоренные синонимы в современном татарском языке // Тезисы итоговой сессии ИЯЛИ за 1972 г. – Казань, 1973. – С. 21–23.

*Харченко В.К.* Переносные значения слова. – Воронеж: Изд-во Воронежск. ун-та, 1989.

*Хуснутдинов А.А.* Грамматика фразеологической единицы: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 1996.

*Чернышёва И.И.* Семантические процессы в фразеологии и фразеологическая деривация // Законы семантического развития в языке. – М., 1961.

*Чудинов А.П.* Многозначность в лексике современного русского языка. – Екатеринбург: Изд-во Урал. гос. пед. ун-та, 1999.

*Чудинов А.П.* Россия в метафорическом зеркале: когнитивное исследование метафоры (1991–2000). – Екатеринбург, 2001.

*Шайхулов А.Г.* Историческая и диалектная лексика тюркоязычных народов Волго-Камско-Уральского региона: (Аспекты систем. характеристики). – Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 1988.

*Шайхулов А.Г.* Лексические взаимосвязи кыпчакских языков Урало-Поволжья в свете их историко-культурной общности: (Аспекты систем.-идеогр. характеристики на общетюрк. фоне) / науч. ред. Э.Р. Тенишев. – Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 1999.

*Шайхулов А.Г.* Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья: (Синопсис и таксономия когнитив. сферы «Природа (неживая и живая)» в континууме обще-межтюрк. лексики) / науч. ред: Э.Р. Тенишев. –Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 2000.

*Шанский Н.М.* Лексикология современного русского языка. – М.: Просвещение, 1972.

*Шанский Н.М.* Очерки по русскому словообразованию и лексикологии. –М., 1959.

*Шанский Н.М.* Современный русский язык: Лексика. – М., 1977.

*Шанский Н.М.* Фразеология современного русского языка. – М.: Просвещение, 1985.

*Шендельс Е.И.* О грамматической полисемии // Вопросы языкознания. – 1962. – № 3. – С. 47–55.

*Шкилёв Р.Е.* Метонимический перенос в устойчивых терминологических сочетаниях (на примере юридической терминологии английского и русского языков): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2005.

*Шкуропацкая М.Г.* Метонимические отношения в лексической системе русского языка // Филологические науки. – 2003. – № 4. – С. 70–73.

*Шкуропацкая М.Г.* Системоцентристский аспект лексической деривации (введение в новую парадигму) // Проблемы русистики. – Томск, 2001.

*Шмелёв Д.Н.* Очерки по семасиологии русского языка. – М.: Просвещение, 1964.

*Шмелёв Д.Н.* Проблемы семантического анализа лексики на материале русского языка. – М.: Наука, 1973.

*Шмелёв Д.Н.* Современный русский язык. Лексика. – М.: Просвещение, 1977.

*Шукуров Р.* Антонимы в узбекском языке. – Ташкент: Фан, 1977.

*Щерба Л.В.* Избранные работы по языкознанию и фонетике. – Т. 1. – Л.: Наука, 1958.

*Щерба Л.В.* Опыт общей теории лексикографии // Избранные работы по языку и фонетике. – Т. 1. – Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1958. – С. 54–91.

*Щерба Л.В.* Опыты лингвистического толкования стихотворений // Избранные работы по русскому языку. –М., 1957.

*Юлдашев А.А.* Принципы составления тюркско-русских словарей. – М.: Наука, 1972.

*Юнусалиев Б.М.* Киргизская лексикология. – Ч. 1. – Фрунзе: Киргизучпедгиз, 1959.

*Юрченко В.С.* Философия языка и философия языкознания: Лингвофилософские очерки. – М.: комКнига, 2005.

*Юсупов Г.В.* Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. – Казань, 1971. – С. 217–231.

*Юсупов Р.А.* Лексико-фразеологическиесредства русского и татарского языков.– Казань: Татар. кн. изд-во, 1980.

*Юсупов Ф.Ю.* Изучение татарского глагола. – Казань, 1986.

*Якупова Г.К.* Библиография по татарскому языкознанию. – Казань, 1988.

### Чит телдә

*Barcelona A.* The State of the Art in the Cognitive Theory of Metaphor and Metonymy and its Application to English Studies // The European English Messenger. – 1998. – Vol. VII. – № 1. – P. 45–48.

*Black M.* More about Metaphor // Metaphor and Thought. Cambridge. – 1980. – P. 19–42.

Dictionary of New Words and Meanings. / под ред. З.С. Трофимовой. – М.: Павлин, 1993.

*Galieva N.F., Galiullina G.R.* Emotive idioms Tatar language as national mentality reflection // Journal of Language and Literature. – Volume 6, Issue 1, 1 February 2015. – P. 273–276.

*Galiullina G.R., Yusupova A.Sh.* Foundations of Tatar linguistics in the works of Kayum Nasyri (on the 190th anniversary of the scholars birth) // Tatarica. – 2015. – № 1 (4). – P. 7–17.

*Gregoriou Ch.* «Behaving Badly»: A Cognitive Stylistics of the Criminal Mind. Nottingham Linguistic Circular 17, 2002. – P.6173.

*Günay Karaağaç.* Türkçenin dil bilgisi. – Ankara: Akcag, 2012.

*Jackendoff R.* Semantics and Cognition. Cambridge, Mass.: The MIT Press, 1995.

Handbücher zur Sprach und Kommunikationswissenschaft / Handbooks of Linguistics and Communication Science. – Bd. 21: Lexikologie / Lexicology. – Halbband 1–2 / Hrsg. v. D.A. Cruse, F. Hundsnurscher, M. Job, P. Lutzeier. – Berlin; New York: Walter de Gruyter, 2005.

*Ibrahim Kafesoglu.* Ogurlar // Turk Diinyasi El Kitabi. BirinciCilt. – Ankara: 1992. – 156–159 s.

*Kaşgarlı M.* Divanu Lugat-it-Tűrk Tercumesi. – 3 baski. IV cilt. – Ankara: «Endeks», 1992.

*Karatay Osman*. Bey ile Bűyűcű. Avrasyada Tann, Hűkumdar, Devlet ve Iktisat. Istanbul, 2006.

*Karatay Osman.* IRAN ile TURAN. Hayali Milletler Qaginda Avrasya ve Ortadogu. – Ankara, 2003.

*Kaşgarlı Mahmut.* Divanü lugat-it Türk çevirisi / Çev.: Besim Atalay. – 5. bsk. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2006.

Longman Dictionary of Contemporary English. – English Longman Group Ltd, 1995.

*Rasanen M.* Versuch ernes etimologischen Worterbuchs der Tiirk-spachen. – Helsinki, 1969.

*Talmy L.* Lexicalization Patterns: Semantic structure in Lexical Forms // Language Typology and Syntactic Description. Vol. 3: Grammatical Categories and the Lexicon. – Cambridge: Cambridge Univ. Press, 1985. – P. 57–149.

The Longman Register of New Words. – Longman: Русский язык, 1990.

Typology of Quantification: On Quantifiers and Quantification in Finnish and Languages Spoken in the Central Volga–Kama Region // Editors: Pirkko Suihkonen & Valery Solovyev) / Gulshat Galiullina, Alfiya Yusupova, Gul'nara Mansurova. – University of Helsinki. – LINCOM Studies in Language Typology 28.–Muenich, 2013.

*Yusupova A.S., Galiullina G.R., Denmukhametova E.N.* Representation of national mentality in Turkic-Tatar vocabulary// Life Science Journal. – Volume 11, Issue 7, 2014, Article number 66. – P. 506–508.

*Zekiev M.Z.* Turklerin ve Tatarlain kőkeni. – Istanbul, 2006.

## СҮЗЛЕКЛӘР

Арабско-русский словарь. Т. 2. / Сост. Х.К. Баранов. – М.: Советская энциклопедия, 1970.

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. – М.: Советская энциклопедия, 1969.

*Ахманова О.С.* Словарь омонимов русского языка. – М.: Русский язык, 1986.

*Ахтямов М.Х.* Словарь антонимов башкирского языка (на башкирском языке). – Уфа: Башк. кн. изд-во, 1973.

*Әхәтов Г.Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.

*Әхәтов Г.Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.

*Әхәтов М.Х.* Омонимнар һүзлеге. – Өфө: Башк. кит. нәшр., 1986.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Дүрт томда. – Т.1. – Бирск: БГПИ нәшр., 2005.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.

*Байрамова Л.К.* Учебно-тематический русско-татарский фразеологический словарь. – Казань: ТКИ, 1991.

*Баязитова Ф.С.* Русско-татарский словарь для работников ЗАГСа и ритуальных услуг. – Казань, 1992.

*Борһанова Н.Б., Мәхмүтова Л.Т.* Русча-татарча фразеологик сүзлек. – Казан, 1959.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең тулы сүзлеге. – Ике кисәктә. Кисәк 1. – Казан, 1927.

*Введенская Л.А.* Словарь антонимов русского языка. – Ростов: Изд-во Рост. ун-та, 1971.

*Введенская Л.А., Колесников Н.П.* Учебный словарь паронимов. – М., 2005.

*Вишнякова О.В.* Словарь паронимов русского языка. – М., 1984.

Гарәпчә-татарча-русча алынмаларсүзлеге / Төзүчеләр: М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. – Беренче китап. – Казан, 1984.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. – Икенче китап. – Казан, 1990.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. – Беренче китап. – Казан, 1992.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. – Икенче китап. – Казан, 1993.

*Гарипова Ф.Г.* Татар топонимнары сүзлеге. – Казан, 2010.

*Гаффарова Ф.Ф., Саберова Г.Г.* Татарча-русча идиомалар сүзлеге. – Казан, 2006.

Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969.

*Дыбо А.В.* Этимологический словарь тюркских языков. Т. 9 (дополнительный): Этимологический словарь базисной лексики тюркских языков. – Астана, 2013.

*Дыбо А.В.* Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на Л, М, Н, П, С / Г.Ф. Благова, Л.С. Левитская, В.И. Рассадин. – М.: Восточная литература, 2003.

*Дыбо А.В.* Etymological dictionary of the Altaic languages / А.В. Дыбо, С.А. Старостин, О.А. Мудрак. – Leiden, Brill, 2003.

*Дыбо А.В.* Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на К / А.В. Дыбо, Л.С. Левитская, В.И. Рассадин. – М.: Индрик, 2000.

*Егоров В.Г.* Этимологический словарь чувашского языка. – Чебоксары, 1964.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Казах тилинин кыскача этимологиялылык сөздігі. – Алматы, 1966.

Киргизско-русский словарь / Сост. К.К. Юдахин. – М.: Советская энциклопедия, 1965.

*Колесников Н.П.* Словарь антонимов русского языка. – М.: Высш. шк., 1972.

*Колесников Н.П.* Словарь паронимов русского языка. – Ростов-н/Д, 1994.

*Комиссаров В.Н.* Словарь антонимов современного английского языка. – М.: Международные отношения, 1964.

Лингвистический энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1990.

*Львов М.Р.* Словарь антонимов русского языка / Под ред. Л.А. Новикова. – 4-е изд., стереотип. – М.: Русский язык, 1988.

*Миңнуллин Ф.Г.* Татар теленең кыскартылмалар сүзлеге. – Казан: Алма-Лит, 2005.

*Ожегов С.И., Шведова Н.Ю.* Толковый словарь русского языка. – М., 1992.

*Рамазанова Д.Б.* Музыкальный словарь. – Казань: Мастер-Лайн, 2003.

*Розенталь Д.Э., Теленкова М.А.* Словарь-справочник лингвистических терминов. – М.: Просвещение, 1976.

Русский семантический словарь. IV: Толковый словарь, систематизированный по классам слов и значений / Отв. ред. Н.Д. Шведова. – М.: Азбуковник, 2007.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

*Саттаров Г.Ф., Ганиев Ф.А., Абдуллин И.А. и др.* Татарско-русский словарь личных имён и фамилий. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006.

*Сафиуллина Ф.С.* Антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 2005.

*Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге. – Казан: ТаРИХ, 2003.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарча-русча тел белемнәре терминнары сүзлеге. – Казан, 1998.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001.

*Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М.* Татар теленең омонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997.

*Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М.* Татарча-русча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997.

*Сәлимов Х.Х.* Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков. – М.: Наука, 1974.

Словарь фразеологических синонимов русского языка / В.П. Жуков, М.И. Сидоренко, В.Т. Шкляров. – М.: Русский язык, 1987.

Словарь русской ненормативной лексики [Электронный ресурс]. – М.: Адепт, 2003. – 1 элект. опт. диск (CD-ROM).

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Редкол. Ф.А. Ганиев, К.С. Миңнебаев, Ф.М. Газизова һ.б. – Казан: Матбугат йорты, 2005.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Т. 1 / Төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977; Т. 2. / Төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова һ.б. – Казан:Татар. кит. нәшр., 1979; Т. 3. / Төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / Төз.: Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / Төз.: Ф.С.Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.

Татар теленең орфографик сүзлеге / Төз.: А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1983.

Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәррир М.Х. Хәсәнов. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2002.

Татарча-русча-инглизчә тел белеме терминнары сүзлекчәсе / татарско-русско-английский глоссарий лингвистических терминов / Төз.: Җамалетдинов Р.Р., Йосыпова А.Ш., Галиуллина Г.Р., Нурмөхәммәтова Р.С., Денмөхәммәтова Э.Н. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2014.

Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге / Р.Ф.Шакирова ред. – Казан: Татгосиздат, 1953.

Толковый словарь русского языка: В 4 т. / Под ред. Д.Н. Ушакова. – М., 1935–1940.

Толковый словарь уголовных жаргонов / Под общ. ред. Ю.П. Дубягина и А.Г. Бронникова. – М.: Голос, 1991.

*Тумашева Д.Г.* Словарь диалектов сибирских татар. – Казань, 1992.

*Тумашева Д.Г., Насибуллина А.Х.* Словарь диалектной лексики татарских говоров Тюменьской области. – Тюмень: ТРГИРРО, 2002.

*Федотов М.Р.* Этимологический словарь чувашского языка: В 2 т. Т. 1: А–Р. – Чебоксары: Чувашский гос. ин-т гуманитарных наук, 1996.

Философский словарь. – М.: Изд-во политической литературы, 1980.

Фразеологический словарь русского языка / Л.А. Воинова. – М., 1978.

*Ханбикова Ш.С.* Татар телендә синонимнар сүзлеге. – Казан, 1980.

*Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

*Хәкимҗан Ф.С.* Татар теленең аңлатмалы татарча-урысча омонимнар сүзлеге. – Казан: Гуманитария, 2004.

*Шанский Н.М., Быстрова Е.А.* Учебный фразеологический словарь русского языка для национальных школ. – М., 1979.

Школьный фразеологический словарь русского языка: Значение и происхождение словосочетаний / Сост.: Н.М. Шанский, В.И. Зимин, А.В. Филиппов.– М.: Дрофа, 1997.

Этимологический словарь якутского языка. Часть 1, А–Дь / Саха тылын этимологичаскай тылдьыта. 1 чааха, А–Дь / Г.В. Попов. – Якутск: Академия наук республики Саха (Якутия), Институт гуманитарных исследований, 2003.

Языкознание. Большой энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н. Ярцева. – 2-е изд. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2000.

# КЫСКАРТЫЛМАЛАР

АРС – Арабско-русский словарь. – Т. 2 / Сост. Х.К. Баранов. – М.: Советская энциклопедия, 1970.

ГФТР – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / Төз.: М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

ДТС – Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969.

ТТАС –Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Т.1 / Төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977; Т. 2 / Төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979; Т. 3 / Төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

ТТДС – Татар теленең диалектологик сүзлеге / Төз.: Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, З.Р. Садыйкова, Г.К. Якупова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.

ТТОС – Татар теленең орфографик сүзлеге / Төз.: А.Х. Нуриева, Ф.С. Фасеев, М.И. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

ТТФС. Т. 1. 1989 – Н. Исәнбәт. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

ЭСТЯ – Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. – М.: Наука, 1974.

## ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
ТАТАР ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ ФӘНЕНӘ КЕРЕШ . . . . . . . . . . 8
§ 1. Лексикология фәне турында төшенчә, аның өйрәнү объекты һәм юнәлешләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
§ 2. Татар теле лексикасын өйрәнүдә төп чыганаклар . . . . . . 14
СЕМАСИОЛОГИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
§ 3. Тел белемендә семасиология фәнен өйрәнү тарихы . . . . . . 21
Телнең универсаль берәмлеге буларак сүз . . . . . . . . . . . . 23
§ 4. Сүзгә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
§ 5. Сүзнең асыл сыйфатлары (билгеләре) . . . . . . . . . . . . 27
§ 6. Сүзнең функцияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
§ 7. Сүзләрнең тәңгәллеге һәм аерымлыгы . . . . . . . . . . . . 38
Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның эчтәлеге . . . . . . . . . . . 45
§ 8. Сүз мәгънәсе турында гомуми мәгълүмат. Сүзнең лексик, грамматик һәм сүз ясалыш мәгънәләре . . . . . . 45
§ 9. Сүз мәгънәсенең семиологик ягы . . . . . . . . . . . . . . . 50
§ 10. Сүз мәгънәсенең структур-семантик ягы . . . . . . . . . . 55
§ 11. Сүз мәгънәсенең прагматик ягы . . . . . . . . . . . . . . . 57
§ 12. Лексик мәгънә структурасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
§ 13. Функцияләре буенча лексик мәгънәләрнең типларга бүленеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Хәзерге татар теленең лексик-семантик системасы . . . . . . . . . 79
§ 14. Тел берәмлекләре җыелмасы буларак лексик-семантик система . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
§ 15. Татар теленең лексик-семантик системасында парадигматик мөнәсәбәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
§ 16. Татар теленең лексик-семантик системасында синтагматик мөнәсәбәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Сүзнең күпмәгънәлелеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
§ 17. Тел белемендә күпмәгънәлелекне өйрәнү тарихы . . . . . . 90
§ 18. Күпмәгънәлелек күренешенә гомуми билгеләмә . . . . . . . 94
§ 19. Күп мәгънәле сүзнең семантик структурасы . . . . . . . . . 99

§ 20. Лексик мәгънә үзгәреше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
§ 21. Метафора һәм аның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
§ 22. Метономия, аның нигезендә булган бәйләнешләр . . . . . 114
Татар телендә омономия күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
§ 23. Тел белемендә омонимнарны өйрәнү тарихы . . . . . . . . 119
§ 24. Омонимия күренешенә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . . 125
§ 25. Омонимнарның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
§ 26. Омонимия һәм полисемия күренешләрен чикләү . . . . . 135
§ 27. Омонимнарның функциональ-стилистик вазифасы . . . 137
Татар телендә паронимия күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
§ 28. Тел белемендә паронимнарны өйрәнү тарихы . . . . . . . 138
§ 29. Паронимия күренешенә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . 141
§ 30. Паронимнарның барлыкка килү юллары . . . . . . . . . . . 145
§ 31. Паронимнарның сөйләмдә кулланылышы
һәм функциональ-стилистик вазифасы. Парономазия күренеше . 151
Татар телендә синонимия күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
§ 32. Тел белемендә синонимнарны өйрәнү тарихы . . . . . . . 155
§ 33. Синонимия күренешенә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . 158
§ 34. Синонимнарның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
§ 35. Синонимнарның барлыкка килүе
һәм функциональстилистик вазифасы . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Татар телендә антонимия күренеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
§ 36. Тел белемендә антонимнарны өйрәнү тарихы . . . . . . 167
§ 37. Антонимия күренешенә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . 171
§ 38. Антонимнарның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
§ 39. Антонимия һәм башка тел күренешләре . . . . . . . . . . . 180
§ 40. Татар телендә энантиосемия күренеше . . . . . . . . . . . 184
§ 41. Антонимнарның функциональ-стилистик вазифасы . . . 188
ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ФРАЗЕОЛОГИЯСЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
§ 42.Тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне өйрәнү тарихы . 191
§ 43. Фразеологик система турында гомуми мәгълүмат . . . . . 196
§ 44. Фразеологик әйтелмәләрнең чиген билгеләү . . . . . . . . 202
§ 45. Фразеологик әйтелмәләрнең билгеләре . . . . . . . . . . . 207
§ 46. Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы . . . . . . . . 210
§ 47. Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килү юллары
һәм чыганаклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217

Татар тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне төркемләү . . . . 222
§ 48. Тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне төркемләү мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
§ 49. Фразеологик әйтелмәләрне компонентларының семантик берегүе, катнашуы дәрәҗәсенә карап төркемләү . . . . . 228
§ 50. Фразеологик әйтелмәләрне стилистик функцияләре ягыннан төркемләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Фразеологик әйтелмәләрнең семантик үзенчәлекләре . . . . . . . 235
§ 51. Фразеологик мәгънә үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . 235
§ 52. Фразеологик омонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
§ 53. Фразеологик синонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
§ 54. Фразеологик антонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
§ 55. Фразеологизмнарның эмоциональ-экспрессив һәм коннотатив үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Фразеологик әйтелмәләрнең грамматик үзенчәлекләре һәм структур модельләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
§ 56. Фразеологизмнарны грамматик яктан характерлау . . . . 261
§ 57.Фразеологик әйтелмәләрнең кулланылышындагы семантик һәм структур үзгәрешләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
ЭТИМОЛОГИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
§ 58. Тюркологиядә һәм татар тел белемендә этимология тармагын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
§ 59. Этимология тармагы турында гомуми мәгълүмат . . . . . 282
§ 60. Этимологик тикшеренү ысуллары . . . . . . . . . . . . . . . 285
§ 61. Сүз тамыры этимологиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
§ 62. Нигез һәм кушымчалар этимологиясе . . . . . . . . . . . 294
§ 63. Татар теленең үз сүзләре һәм алынма сүзләр этимологиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
ЙОМГАК . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ . . . . . . . . . . . . . . 315
КЫСКАРТЫЛМАЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348

Научное издание

**ЛЕКСИКОЛОГИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

I том

*На татарском языке*

Редактор *А.А. Давлетова*
Компьютерная вёрстка и дизайн обложки
*Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать: 23.12.2015.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 20,5. Уч.-изд. л. 18. Тираж 1000. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20